Хатыйп Миңнегулов

# Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)–4
М 57

**Миңнегулов Хатыйп**

М 57 Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 367 б.

Бу җыентыкта Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге, ягъни 1919–1954 еллардагы әдәби һәм публицистик эшчәнлеге яктыртыла. «Яңа милли юл» журналын тикшерүгә зур урын бирелә, тиешле шәрех-аңлатмалар белән аерым язмалар да укучыларга тәкъдим ителә.

Китап Г.Исхакый, мөһаҗир татарлар, милләт тарихы белән кызыксынучыларга адресланган. Анда студентлар һәм укытучылар, галимголәма өчен дә файдалы мәгълүматлар күп.

ISBN 5-298-01423-2 © Татарстан китап нәшрияты, 2004

## Кереш сүз

Егерменче йөз башы татар рухи тормышын Гаяз Исхакыйдан башка күз алдына да китереп булмый. Аның исеме, әсәрләре, гомумән, эшчәнлеге бу чор яшәешенең төрле өлкәләренә үтеп кергән, милли тәрәкъкыятьтә (алга барышта) әйдәп баручы көч, катализатор вазыйфасын үтәгән. Әдип хакында Ш.Бабич 1915 елда юкка гына бу парчаны язмагандыр:

Сандугачлар су ташый, кайда икән су башы?
Гаяз хәлфә ялгыз башы, Хозыр булсын юлдашы.

Җамал Вәлиди «Вакыт»та басылган бер мәкаләсендә (1913) «Гаяз исеме, һич шөбһәсез, татар әдәбияты, татар поэзиясенең мәркәзендә тора... Шул зат хәзер татар әдәбиятында иң ачык, иң сөемле бер сима (шәхес; зат. — *Х.М.*) булып күренә» дип искәртә. Г.Исхакыйның олылыгы, юлбашчылыгы турында Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Й.Акчура һәм башка мәшһүр затларның әйткән фикерләре дә укучыларга мәгълүм.

Талантлы милләттәшебез Әнгам Атнабаевның «Син ашыктың, без соңладык» шигырендә (Мәдәни җомга, 1995. — 1 дек.) мондый юллар бар:

Шагыйрь халкы өчен бөтен шартлар
Тудырылган тизрәк үләргә.
Кайда барып бәрелергә белми,
Чәбәләнә алар дөньяда.
Яшәүләре гел тәмугтан торгач,
Оҗмахларын эзләп югала...

Әмма Г.Исхакый бу сүзләрдән бераз чыгарма булып тора. Ул патша вакытында да дөньяның ачысын-төчесен, төрмә-сөргеннәрен күрә, мөһаҗирлеккә киткәч тә лаеш шулпасын күп эчә, төрле эзәрлекләүләргә дучар ителә, үлем куркынычы астында да кала. Ләкин ничек кенә булса да, яшәргә ашкына, халкы өчен, ирек, демократия өчен көрәшүен дәвам иттерә.

Октябрь инкыйлабыннан соң мөһаҗирлеккә китүчеләрнең күпчелеге — матди яктан бай кешеләр. Г.Исхакыйның исә утары-җирләре дә, завод-фабрикалары да, кибет-банклары да, министр-генераллык дәрәҗәләре дә, туплаган алтын-көмешләре дә юк. Аның бар байлыгы — әдәби-сәяси таланты, зирәк акылы, үткен теле һәм иң мөһиме — туган халкына тугрылыгы, хөрлек-бәйсезлек юлында какшамас иман-ышанычы. Моңа кадәр дә патша хакимияте белән көрәшеп килгән әдип большевиклар идарәчелеген бөтен рухы белән кабул итә алмый: татар өчен җан аткан, Идел-Уралны өзелеп сөйгән Исхакый Ватаныннан читкә китәргә — мөһаҗир булып яшәргә мәҗбүр ителә. Мондый затларга карата исә совет хакимиятенең карары катгый: алар — дошман, алар — әшәке, алар — зарарлы.

Г.Исхакый — мондыйларның алгы рәтендә. Советлар Берлегендә аның әсәрләрен бастыру, уку түгел, хәтта исемен дә телгә алу тыела. Алган вакытта да бары каралтып, сүгеп кенә әйтергә мөмкин. Иң аянычлысы шул: Г.Исхакыйны тәнкыйтьләүчеләр, мыскыллаучылар арасында татарның үз әдипләре, хәтта «...Инкыйраз» авторын элек мактаган, зурлаган каләм әһелләре дә шактый. Мәсәлән, совет чорының бик тә мәгълүм бер язучысы, шагыйре үзенең «Шигырьләр» китабында (Казан, 1932) С.Максуди, З.Кадыйри, Г.Терегулов, Г.Исхакый, З.Вәлиди, Г.Баттал, Ф.Туктаров кебек мөһаҗирләргә шарж-рәсемнәр белән мыскыллы «багышлаулар» бирә (93—97 б.). «...Инкыйраз» авторы менә ничек тасвирлана:

Лондон өстендә озак төшми аяз,
Гел томанда каңгырып йөри Гаяз.
Милли илдә «Ил» чыгарлык сәләт
Калды инде аздан аз..., аздан да аз...
Бетте милләт, милли кәбаблар белән,
Милли мәҗлес, милли шәраблар белән.

«Багышлаулар»ның ахырында шагыйрь «соңгы сүз» рәвешендә бу юлларны яза:

«Җиде ирән» әкияте бетте шулай,
Һич береннән тапмадык якты чырай.
Шат вакыт кайтмас аларга инде һич,
Һәр «шаяру» бик кыйбатка килде ич,
Ул чырайда — күпме крәстиән каны?
Ул чырайда — канлы дарның арканы.
Шуңа күрә юк аларга һич гафу!
Ни барсын җыйда төкер:
—Ках — тфү...

Әгәр дә бу затлар илдә калган булсалар, алар репрессия тегермәненең тәүге корбаннарын тәшкил итәрләр иде. Ярый әле мөһаҗирлеккә китеп котылганнар һәм шуның нәтиҗәсендә халыкка, җәмгыятькә файдалы шактый гамәлләр кылып, бай гына рухи мирас калдырганнар...

Совет чорында онытылырга мәҗбүр ителгән Г.Исхакыйның халыкка, Ватанга кабат кайтуы да гаять авыр һәм катлаулы булды. Бу процесс әле һаман да шома гына бармый: төрле каршылыклар, көтелмәгән хәлләр туып кына тора. Әмма ничек кенә булмасын, безнең бүгенге тормышыбызны, XXI гасыр башын, нәкъ моннан йөз ел элеккеге кебек, Исхакыйдан башка күз алдына да китереп булмый. Ул безнең яшәешебезгә, рухыбызга сеңә бара. «Восточный экспресс» гәзитенә биргән интервьюсында (29.08.–4.09.2003) Татарстан Президенты М.Шәймиев XX гасырның мәшһүр татарлары исемлегенә Г.Исхакыйны һәм сәясәтче, һәм язучы буларак беренчеләрдән булып атый. Лена Шагыйрьҗан «...Инкыйраз» авторын милли яшәешебезнең «маягы» дип атый һәм, укучыга дәшеп, болай ди:

Без югалтмыйк әле шул маякны,
Җиргә ныграк басыйк аякны.
Тукталмыйча атлыйк алга, язга —
Бездән алга барган Гаязга!

*(«Гаяз Исхакый юлыннан», 2001)*

Әдипнең Ватанга кабат кайтуы, әсәрләренең халык зиһенен баета баруы — күпләгән каләм әһелләренең, галимнәрнең, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләренең уртак тырышлыгы нәтиҗәсе. Соңгы 10–15 ел эчендә генә дә Исхакый турында дистәгә якын диссертация якланды, берничә монография, күпләгән мәкалә-хезмәтләр дөнья күрде. Аеруча куанычлысы шул: әдипнең әсәрләре бер-бер артлы басылып тора; авырлык белән булса да, күптомлыгының да берничә китабы нәшер ителде. Исхакыйга багышланган конференцияләр, кичәләр, укулар үткәрү дә гадәткә керде. Әдипнең тормыш юлын һәм иҗат мирасын өйрәнүгә мәктәп һәм югары уку йорты программа-дәреслекләре дә шактый урын бирә. Яуширмә авылындагы музей Исхакыйны халыкка җиткерүнең мөһим бер мәркәзенә әйләнеп бара. Бу эштә «Чистай якташлык җәмгыяте»нең дә роле зур.

Исхакый мирасын кайтару, өйрәнү һәм пропагандалау эшендә инде дистә елдан артык без фәкыйрегез дә катнашып килә. Дөрес, әдип иҗаты белән азмы-күпме танышлыгым элегрәк тә бар иде. Әмма Г.Исхакый белән ныклабрак кызыксыну 1990 елда башланды. Мин шул елда Финляндиядә өч айлык гыйльми командировкада булдым. Шәхси һәм дәүләти архив-китапханәләрдә Исхакыйга мөнәсәбәтле шактый гына материаллар табылды. Бу илдә яшәүче милләттәшләребез дә бөек әдип хакында күп кенә истәлекләр сөйләделәр, мәгълүматлар бирделәр. 90 нчы елларда Төркиягә ясаган күпсанлы сәфәрләрем дә Исхакый хакындагы күзаллауларымны шактый баетты. Ничектер шулай килеп чыкты: минем төп игътибар әдипнең мөһаҗирлектәге тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә юнәлтелде. Бу эш исә чит илләрдәге татар әдәбиятын һәм матбугатын тикшерү белән тыгыз бәйләнештә барды. Мәгълүм ки, узган гасырда, аеруча аның икенче-өченче чирегендә Финляндиядә, Кытайда, Япониядә, Төркиядә, Алманиядә һәм кайбер башка илләрдә татар телендә гәзит-журналлар, китаплар басыла. Аларның күпчелеге теге яки бу дәрәҗәдә Исхакый белән бәйләнешле. Мәсәлән, «Милли Байрак», «Азат Ватан», «Kazan» кебек басмаларда әдипкә мөнәсәбәтле материаллар шактый күп. Ә инде Берлинда 1928–1939 елларда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналы Исхакыйның шәхси трибунасы кебек.

Әдип хакындагы безнең язмаларыбыз 1990 елда ук дөнья күрә башлаган. Шунысы әһәмиятле: аларның иң тәүгеләреннән берсе — Г.Исхакыйның васыять тексты һәм аңа безнең аңлатма (Соц. Татарстан, 1990. — 19 окт.; Казан утлары, 1991. —

№ 5). Бу вакыттан соң вакытлы матбугат битләрендә, аеруча «Мирас», «Казан утлары», «Татарстан» журналларында, шулай ук төрле җыентыкларда безнең тарафтан әзерләнгән күптөрле материаллар басылып чыкты. Аларның бер өлешен Г.Исхакыйның «Яңа милли юл» журналында дөнья күргән мәкаләләре һәм аларга безнең шәрех-аңлатмалар тәшкил итә. Язмаларның шактые әдипнең мөһаҗирлектәге әдәби әсәрләре, тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге хакында. Аларның кайберләре 1999 елда укытучыларга адреслап чыгарылган «Исхакый мөһаҗирлектә» китапчыгында да туплап бирелгән иде. (Әмма аз санлы булу аркасында, бу брошюра бик тиз таралып бетте.) Әдипкә мөнәсәбәтле язмаларыбызның басылмый калганнары да бар. Шунысын да әйтик: соңгы дистә елда безгә Исхакыйның юбилейлары уңае белән оештырылган фәнни конференцияләрдә, төрле гыйльми, гамәли чараларда докладлар укырга туры килде. Радио, телевидение аша да чыгышлар булды. Исхакый турындагы берничә диссертациянең (Ә.Сәхапов, Х.Шагбанова, А.Кәримова, Г.Зәйнуллина, Р.Харрасова һ.б.) рәсми оппоненты, рецензенты буларак та катнаштым. Бу төр язмаларның күпчелеге исә дөнья күрмәгән. Фәнни мөхәррире яисә рецензенты булган китаплар да бар.

Кыскасы, соңгы 10–15 елда безнең тарафтан Исхакый турында, аңа мөнәсәбәтле шактый гына мәкаләләр язылган, материаллар басылган. (50гә якын!) Әмма, кызганыч ки, алар төрле китап-җыентыкларда, көндәлек матбугат битләрендә тарау ята. Кулъязма хәлендәгеләре дә бар. Шундый вазгыять бу җыентыкның төзелүенә төп ихтыяҗ тудырды. Андагы материалларның күпчелеген моңа кадәр дөнья күргән язмалар (әмма барысы да түгел!) тәшкил итә.

Узган гасырның 90 нчы еллары — татар һәм, гомумән, дөнья тормышының шактый кайнаган чоры, милли-азатлык хәрәкәтенең көчәйгән дәвере. Мондый атмосфера безнең язмаларга да теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясаган. Шуңа күрә без элек басылган материалларны, гәрчә аларда аерым кабатланулар, бәхәсле моментлар күзгә ташланса да, нигездә үзгәрешсез калдырдык. (Чөнки бу төр язмалар инде автордан аерым тарихи, реаль факт!) Кайберләренә генә өстәмәләр, хосусый, техник характердагы төзәтмәләр кертелде. Мәсәлән, «Татарстан» журналында (1993, № 4) Г.Исхакыйның Ф.Туктаров хакындагы мәкаләсе кыскартып басылган иде. Биредә исә ул тулысынча бирелә. Милләт мәҗлесе турындагы язма белән дә шундый ук хәл. Мондый күренеш янә берничә урында күзәтелә.

Безнең «Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты», «Фәнгә — яңа сәхифәләр», «Казан» һәм «татар» — аерылмас төшенчәләр» («Kazan» мәҗмугасы турында), «Аһ, бу язмыш..., ник шулай», «Азат Ватан» журналы хакындагы мәкаләләрдә,

Х.Габдүш, С.Гыйффәт, М.Исмәгыйли, З.Кадыйри, Х.Хәмидулла турындагы язмаларда һәм кайбер башка публикацияләрдә Г.Исхакыйга теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәтле фикер-күзәтүләр бар. Әмма ул төр материаллар бу китапка кертелмәде диярлек.

* * *

Г.Исхакыйның мөһаҗирлектә басылган бер китабы тышлыгында мондый дүртьюллык бар:

Һавадагы киек каздан
«Син кайдан?» дип сорадым.
Каз кычкырып җавап бирде, —
Мин утырып еладым.

Бу юлларда никадәр сагыш, никадәр драматизм! Алар бөек әдипнең рухи халәтен, теләк-омтылышларын ачык күрсәтә.

Г.Исхакый ярты гомерен, аның җитлеккән дәверен мөһаҗирлектә уздыра. Аның бу чор тормышы һәм эшчәнлеге шактый бай, катлаулы һәм күпкырлы. Кызганыч ки, биредә әле билгесез сәхифәләр, ак таплар гаять күп. Безгә мәгълүм, кул астындагы материалларның да зур өлеше эшкәртелмичә, гыйльми һәм гамәли әйләнешкә кертелмичә ята бирә. Бу китап исә Г.Исхакыйны өйрәнүдә бер тәҗрибә, бер баскыч, бер чыганак булып тора.

Г.Исхакыйның тормышы һәм күпкырлы эшчәнлеге милли яшәешебез белән тамырдан береккән. Шуңа күрә бу тема, бу шәхес хакында фикер йөртү ул халкыбызның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлану да.

Русча, төрекчә язмаларын исәпкә алмаганда, Г.Исхакый гомере буе гарәп графикасы белән эш итә. Мөһаҗирлектәге иҗаты да моннан чыгарма түгел. Әдип үзенең әдәби әсәрләрендә, гыйльми, публицистик хезмәтләрендә нигездә XX йөз башы тел, язылыш традицияләрен дәвам иттерә. Төрек теленең дә өлешчә тәэсире сизелә. Көнбатыш Аурупа телләреннән дә аерым алынмалар очрый. Мәгълүм ки, совет чорында татар теленә урыс теле нык йогынты ясады. Бу хәл исә Г.Исхакый язмаларында һәм, гомумән, мөһаҗирлектәге татар әдәбиятында һәм матбугатында бик күзгә ташланмый.

Бу китапта (аны монография дип тә атарга мөмкин, чөнки аның үзәгендә бер тема — Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеге тора) «Яңа милли юл»да басылган аерым материаллар да (алар, нигездә, Г.Исхакыйныкы яисә аңа мөнәсәбәтле язмалар) укучыларга тәкъдим ителә. Бу әсәрләр автор тарафыннан (Хатыйп Миңнегулов) гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерелде. Кагыйдә буларак, аларның оригинал нөсхәдәге язы-

лышы сакланды. Кайбер аермалар хосусый характерда гына. Мәсәлән, Исхакый, шул чордагы традициягә тугры калып, Төркиядәге төрекләрне дә, башка төрки халыкларны да еш кына «төрек» дип атый. Буталыш чыкмасын өчен, без бу атаманы «төрк» рәвешендә бирүне кулай күрдек. Гарәп язуындагы текстларда «п», «б» авазлары еш кына бер хәреф — «б» белән билгеләнә. Без аларны хәзерге әйтелешкә якынайтып бирергә тырыштык (күреб — күреп, күб — күп...). Аңлашылмаган сүзләргә, гыйбарәләргә аңлатмалар, кагыйдә буларак, җәяләр эчендә бирелде. Ә Г.Исхакыйның үз аңлатмалары исә *Г.И.* инициалы белән күрсәтелде.

*Сентябрь, 2003*

# Әдәби иҗаты

## Кайда да милләтпәрвәр

XX йөз татар зыялыларының гомер юлы, нигездә, Идел-йорт, Рәсәй, Советлар Берлеге белән чикләнгән. Гаяз Исхакый (1878–1954) исә бу яктан кабатланмас язмышка ия. Ул 76 ел гомеренең яртысын туган иленнән читтә уздыра, әсәрләренең өчтән икесен читтә иҗат итә. Шунысын да искә төшерик: мөһаҗәраткә кадәр дә әдипкә Идел-йорттан еш кына аерылып яшәргә туры килә: Архангельскида сөргенлек, Петербург, Мәскәү, Истанбул, Себер һ.б. Әмма Г.Исхакый кайда гына, нинди шартларда гына яшәмәсен, гомере буе Идел-йортка тугры калды, халыкка хезмәт итүнең, милләт юлында фидакарьләрчә көрәшүнең кабатланмас өлгесен тудырды. Үләренә өч көн кала язган бер хатында ул болай ди: *«Минем хәлем бер дә яхшы түгел... Сулар сулышым бу айда, бәлки дә бу атнада киселәчәк... Мин мөселман ата-анадан тудым һәм мөселманча тәрбия алдым... Һичбер төрки кавемгә дошманлык эшләмичә, бөтен гомерем буе үземнең халкым — төрки-татар халкының уңышы һәм бәхете өчен хезмәт иттем».* (Тампере имамы Хәбибрахман Шакирга язылган хат // Казан утлары, 1994. — № 2. — 160 б.)

### I

Бик яшьли әдәби иҗатын публицистик, сәяси, иҗтимагый эшчәнлек белән үреп барган Г.Исхакый 1917 елгы инкыйлаб вакыйгаларының үзәгендә кайный, төрки-татар милли-азатлык хәрәкәтенең, Идел-Урал җөмһүрияте төзүнең, Милли идарә җитәкчеләреннән берсенә әверелә. Әмма ул большевиклар сәясәте белән килешми, шуңа күрә рәсми хакимиятнең эзәрлекләвенә дучар ителә.

Г.Исхакый 1918 елның август аенда Мәскәүдән Казанга килә. Биредә берәр атна торгач, Учредительное собрание урнашкан Самарага юнәлә. Бу калада ул, Фуад Туктаров һәм Милләт мәҗлесенең кайбер башка әгъзалары белән бергә, Идел-Урал җөмһүрияте төзү буенча эш алып бара. Әмма большевикларның эзәрлекләве аркасында Г.Исхакый һәм аның көрәштәшләре Уфага һәм аннан татар мәдәниятенең мөһим үзәге Кызылъярга (Петропавелга) күчәләр. Бу калада алар «Маяк» исемле гәзит чыгара башлыйлар*. Әмма Г. Исхакыйга би-

* Бу айларда Кызылъярга мәшһүр артист һәм режиссер Габдулла Кариев килеп чыга. Ул, Г.Исхакый киңәше белән җирле яшьләрдән труппа оештырып, «Таһир-Зөһрә» әсәрен сәхнәгә куя һәм зур уңышка ирешә. Г.Исхакыйның яңа төгәлләгән «Юлсызлар» исемле драмасын әзерли башлый. Әмма бина булмау аркасында, бу әсәр авторы шунда вакытта сәхнәгә куелмый кала. «Юлсызлар» нинди әсәр, аның алга таба язмышы ничек булган, — бу хакта хәзергә кулыбызда мәгълүматлар юк.

редә дә озак торырга туры килми: ул, Себер авыллары һәм калалары, җөмләдән Иркутск аркылы үтеп, 1919 елның апрель аенда Харбинга барып җитә. Мәгълүм ки, бу чорда Кытайның Харбин, Хайлар һәм кайбер башка калаларында күпләгән татар кешеләре (сәүдәгәрләр, тимер юл эшчеләре, зыялылар, гаскәриләр һ.б.) яши. Биредә әдип алар белән аралаша, Гомәр Тәңреколый (Терегулов) белән берлектә милли-мәдәни чараларда катнаша. Шушы ук елның 3 октябрендә Версаль конференциясендә «Милли идарә» вәкиле буларак катнашу өчен Аурупага юнәлә. Г.Исхакый бу сәфәргә чыгып китүнең шактый мәшәкатьле һәм озакка сузылуын искәртә. «*Без,* — ди ул, — *Гомәр Тәңреколый берлә Япониягә барып, Аурупага чыгар өчен юл визалары эстәсәк дә, дүрт ай эчендә һичбер йирдән мөсәгадә (ярдәм, булышлык. — Х.М.) ала алмаенча, кире Харбинга кайткан идек. Безнең Учредительное собрание әгъзасы Чайковскийга Париска (Парижга. — Х.М.) виза сорап күндерелгән телеграммабыз Садрый әфәнде Максудиның кулына төшеп, ул безгә французлардан виза күндерткән булса да, безгә бу виза килеп җитә алмады*» (Яңа милли юл, 1939. — № 3. — 19 б.).

Сугыш вакытында Рәсәйгә әсирлеккә төшкән чех гаскәриләре Ерак Шәрыктан пароход белән үз Ватаннарына юнәләләр. Фуад Туктаров белән Г.Исхакый да, ниндидер җаен табып, шул пароходка эләгәләр һәм, океаннар, диңгезләр аша үтеп, Сүәеш каналы аркылы Урта диңгезгә чыгалар һәм, 56 көн дигәндә, Триест аркылы Прагага килеп җитәләр. Бу вакытта урыс мөһаҗирләре белән кайнап торган чех башкаласында берничә ай торгач, Франциягә виза юнәтеп, 1920 елның апрель аенда, ниһаять, Париж туфрагына аяк басалар.

Мәгълүм булганча, Версаль конференциясенең үзәгендә халыкара сәяси мәсьәләләр, шул исәптән Рәсәй язмышы да тора. Бу исә Идел-Урал, татар мәмләкәтчелеге проблемасына да турыдан-туры бәйле. Шуңа күрә «Милли идарә» Версаль сөйләшүләрендә катнашуны зарури эш дип саный, «солых һәйәте» төзи һәм С.Максуди, Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Г.Тәңреколый составындагы бу комиссиягә халыкара конференциядә катнашу вәкаләтләрен бирә. С.Максуди, Финляндия аша үтеп, 1919 елда ук Парижга килгән була. Алар Версаль сөйләшүләрендә ике ел буена Идел-Урал татарларының милли таләпләрен бәян итәләр. «*Ләкин,* — ди Г.Исхакый, — *большевиклар бу мәҗлесләргә катыштырылмаганга, бу таләпләрдән билфигыль (чынлыкта) бер кул да ителмәде*» (Яңа милли юл, 1938. — № 1. — 10 б.). «Солых һәйәте» әгъзаларына Париж сөйләшүләре вакытында матди яктан Финляндия татарлары, Америкадагы Заһидулла бәк Агиш, Харбиннан Гыйнаят ахун ярдәм күрсәтеп торалар. Франциядә яшәү елларында Г.Исхакый бу ил-

нең мәдәнияте, күренекле кешеләре, шулай ук мөһаҗирләр белән таныша, аралаша, французчасын да камилләштерә.

Бераздан «солых һәйәте»нең аерым әгъзалары Берлинга күчәргә мәҗбүр булалар. Г.Исхакый биредән берничә мәртәбә Финляндиягә, Польшага, Бельгиягә һәм кайбер башка мәмләкәтләргә дә барып килә. Берлинда ул Фуад Туктаров һәм кайбер башка мөһаҗирләр белән берлектә «Туран җәмгыяте» төзи, рәис сыйфатында аның мәҗлесләрен уздыра, лекция-докладлар укый.

Бу елларда Берлинда гына да 40 тан артык татар кызы һәм егете укый. Болардан тыш Алманиядә күпләгән төркестанлылар, азәрбайҗаннар да белем ала. Аларга милли, сәяси тәрбия бирү өчен оештырылган «Яшьләр берлеге» оешмасы да шактый нәтиҗәле эшли. Әмма большевик агентлары Г.Исхакый һәм аның көрәштәшләренең эшчәнлегенә төрле тоткарлыклар тудырып тора. Ахыр чиктә ул, Ф.Туктаров белән берлектә, «Туран» оешмасы җитәкчелегеннән китәргә мәҗбүр була. Әдип Алманиядә кичергән сәяси, матди кыенлыклары хакында Садрый Максудига 1924 елның 21 февралендә Берлиннан язган бер хатында болай ди: «...*Бик ук төшәргә ярамый әле! Ни булса да булыр. Алла ярдәм итәр. Мин дә соңгы көннәрдә бик авыр хәлләр кичердем. Чәчемнең бик күбен агарттым*» (Казан утлары, 1997. — № 6. — 17 б.).

1925–1927 елларда Г.Исхакыйның Истанбулда яшәве мәгълүм. Биредә ул «Төрек йорды» исемле журналда эшли*. Әмма совет агентларының котыртуы аркасында, аңа караш үзгәрә. Нәтиҗәдә әдип Төркиядән Варшавага күчеп китәргә мәҗбүр була һәм ун еллап гомерен биредә һәм Берлинда уздыра. Мәгълүм булганча, Ләһстан (Польша) — 20–30 нчы елларда мөһаҗир татарларның төп мәркәзе. Биредә элек-электән үк җирле

---

* Милләттәшебез Йосыф Акчура нигезләгән «Төрек йорды» журналы белән Г.Исхакый моңа кадәр дә бәйләнештә тора. Мәсәлән, бу мәҗмуганың 1341/1922 елгы 2 нче санында аның 1920 елда Берлинда язылган «Руслар арасындагы бер фикер җәрәяне (агымы. — *Х.М.*)» исемле мәкаләсе басылган (166–173 б. Ул төрек телендә). Биредә автор соңгы берничә елда миллионлаган русларның (күпчелеге мәшһүр зыялылар) мөһаҗәрәткә дучар ителүе, аларның Париж, Берлин, Прага һәм Аурупаның кайбер башка төбәкләрендә оешып яшәве, төрле-төрле карашларда торулары, күпләгән китаплар, гәзит-журналлар чыгарулары хакында яза. Алга таба Г.Исхакый мәркәзе Чехословакиядә булган евразиячелек агымына туктала, аңа теләктәшлек тә белдерә. Бу уңай белән кызыклы гына фикерләр әйтә. Г.Исхакый карашынча, Рәсәй дәүләте, мәдәнияте — ялгыз русларның гына түгел, Евразиядә яшәгән барлык халыкларның да уртак мәмләкәте, культурасы. Мәкалә авторы төрки-татарларның рус тормышына, теленә, сәнгатенә, идарәчелегенә, гаскәри тормышына гаять көчле йогынты ясавын искәртә, конкрет мисаллар китерә. Язма ахырында Рәсәй яшәешендә һәм дөнья тарихында мөһим роль уйнаган урыслашкан мәшһүр төрки-татар исемнәрен атый (Годунов, Менделеев, Аксаков, Тургенев, Танеев, Плеханов һ.б.). Г.Исхакыйның тирән эчтәлекле бу мәкаләсендә бүгенге көнгә аваздаш яклар да шактый.

милләттәшләребезнең дә күпләп яшәвен онытырга ярамый. Тагын шунысы да мәгълүм: Г.Исхакый Польшаның дәүләт башлыгы Ю.Пилсудский белән заманында Архангельск сөргенендә бергә була. Әдипнең нәкъ менә Варшавага килүендә, әлбәттә, бу фактлар да билгеле бер роль уйнаган. Г.Исхакый бераз вакыт Польшаның Шәрык институтында да эшләп ала.

Икенче мәртәбә Аурупада яшәү дәверендә әдип үзенең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген гаять арттыра. 20–30 нчы еллар аралыгында ул Варшавада «Прометей» хәрәкәте оештыра. Идел-Урал, Төркестан, Кавказ, Кырым, Украина һәм кайбер башка халык вәкилләрен үз эченә алган бу хәрәкәтнең төп максатын милләтләрнең бәйсезлеге өчен көрәш идеясе тәшкил итә.

Г.Исхакый күптөрле чараларны оештыруда башлап йөри, чит илләрдәге төрки-татарларның чын мәгънәсендәге юлбашчысына әверелә. Мәсәлән, аның җитәкчелегендә 1938 елның башларында Милләт мәҗлесе төзелүнең 20 еллыгы киң күләмдә билгеләп үтелә. Аның төп чаралары 4–6 февральдә Варшавада уздырыла.

Г.Исхакыйның 20–30 нчы елларда башкарган иң зур нәтиҗәле эшләреннән берсе — «Яңа милли юл» журналын чыгару. Аның беренче саны 1928 елның 23 декабрендә, соңгысы — 136 нчы саны — 1939 елның октябрендә дөнья күрә. Гарәп хәрефләре белән басылган татарча бу журнал (ул 1930 елга кадәр «Милли юл» исеме белән басыла), нигездә, Берлинда нәшер ителә. Аны чыгаруда татарның мөһаҗәрәттәге күп кенә күренекле затлары катнаша. Авторлар һәм хезмәткәрләр арасында Сания Гыйффәт, Рәшит Рәхмәти Арат, Сәгадәт Чагатай, Закир Кадыйри, Әхмәт Тимер, Ләбиб Каран, Хәсән Хәмидулла, Фуад Туктаров, Мәхрусә Вафа, Гомәр Тәңреколый һ.б. бар. Әмма төп авырлык, әлбәттә, баш мөхәрриргә төшә. Журналдагы күпчелек материаллар да аның тарафыннан язылган.

Иҗтимагый, сәяси, әдәби, тарихи характердагы «Яңа милли юл» журналы факт-мәгълүматларга искиткеч бай. Аны татар тарихының һәм яшәешенең энциклопедиясе, милли-азатлык өчен көрәш трибунасы (мөнбәре) дип тә атарга мөмкин. Мәҗмугада бүгенге көнгә аваздаш яклар да шактый күп. Аның битләрендә шулай ук Советлар Берлегендәге һәм дөньядагы төрлетөрле вакыйга-хәлләр дә гәүдәләнеш тапкан.

1927–1939 еллар аралыгында Г.Исхакый Варшава, Берлин калаларыннан тыш, башка урыннарда да була. Берничә мәртәбә ул Финляндиягә барып кайта. Гомумән, бу мәмләкәттәге милләттәшләребез белән әдипнең элемтәләре озын гомерле була. Аңа китапларын бастыруда, гәзитләр чыгаруда ярдәм итәләр. Г.Исхакый үзе дә аерым язмаларында Финляндия табигатен, кешеләрен гәүдәләндерә. Бигрәк тә ул Тампере имамы Хәбибрахман Шакир һәм аның гаиләсе белән дустанә мөнәсә-

бәтләрдә тора. Әдипнең соңгы васыяти хатлары бу гаиләгә адреслану да күп нәрсә турында сөйли.

Г.Исхакый 1931 елның декабреннән 1932 елның март башларына кадәр Якын Көнчыгышта була. Биредә ул Бөтендөнья мөселманнарының Кодеста үткәрелгән корылтаенда (6–17 декабрь) Идел-Урал вәкиле буларак катнаша. Аның тәкъдиме һәм тырышлыгы белән корылтай Советлар Берлегендәге мөселманнарның хокукларын яклап, махсус резолюция дә кабул итә. Өч ай эчендә Г.Исхакый Фәләстин, Мисыр, Сүрия, Ливан һәм кайбер башка мәмләкәтләрдә була, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр, журналистлар, милләттәшләре белән очраша; сәяси, тарихи, мәдәни темаларга лекцияләр укый, матбугатта чыгышлар ясый. Гомумән, аның Якын Көнчыгыш сәфәре биредәге гарәп, әрмән, төрек, француз матбугатларында киң чагылыш таба, ул тагын да абруйлы сәясәтчегә әверелә. Сәяхәт вакытындагы тәэсирләрен, күргән-ишеткәннәрен әдип «Яңа милли юл» журналындагы мәкаләләрендә һәм аеруча «Ислам мәмләкәтләре» исемле «Юл истәлекләре»ндә чагылдырып бара. Аның бу сәяхәтнамәсе әдәби, тарихи, сәяси яктан да, авторның шәхесен гәүдәләндерү җәһәтеннән дә гаять мөһим.

Әдип 1933 елның көзендә Ерак Шәрыкка килә. Биредә ул өч елга якын була. Япониядәге, Кытайдагы милләттәшләребезне туплау юнәлешендә корылтайлар оештыра, төрле сәяси, мәдәни чаралар үткәрә*. Аның бу сәфәре халыкара яңгыраш ала, дөнья матбугатында төрле-төрле язмалар тууга китерә.

Г.Исхакый Ерак Шәрыкта булган вакытта «Милли байрак» гәзитенә нигез сала. 1935–1945 елларда Мукденда чыккан бу гәзит үзенең рухы белән «Яңа милли юл» журналының туганы кебек. Ул халкыбызның рухи яшәешен тәэмин итүгә, аны туплауга, милли-азатлык көрәшенең дәвам ителешенә үзеннән гаять зур өлеш кертте. Мәгълүм булганча, «Милли байрак» гәзите белән хәзерге вакытта Төркиядә яшәүче мәшһүр профессор Надир Дәүләтнең эти-әниләре — Ибраһим һәм Рокыя Дәүләткилделәр җитәкчелек итә.

1937 елның башларында, бигрәк тә әдипнең туган ае февральдә, Г.Исхакыйның иҗади эшчәнлеге башлануга 40 ел тулу мәмләкәттән читтә яшәгән татарлар арасында киң күләмдә билгеләп үтелә. Юбилей тантаналарының иң зурысы Варшавадагы Шәрык институтының зур залында уздырыла. Анда Польшаның дәүләт эшлеклеләре, галим-әдипләре, шулай ук төрле илләрдән килгән кунаклар, күренекле милләттәшләребез катнаша. Бу халкыбыз тупланунының, милли бәйсезлек өчен көрәшнең үзенә күрә бер корылтае рәвешен дә ала. Матбугатта, биг-

* Бу хакта: Мусин Ф. Гаяз Исхакый (тормышы һәм эшчәнлеге). — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 110–137 б.

рәк тә «Яңа милли юл», «Милли байрак» һәм кайбер башка басмаларда Г.Исхакыйның эшчәнлеге хакында бик күп материаллар дөнья күрә. Аларда әдипнең бөеклегенә, гаять нәтиҗәле һәм күпкырлы эшчәнлегенә, милли-азатлык хәрәкәтенең дөньякүләм танылган лидеры булуына басым ясала. Харбин шәһәрендәге яшьләр исеменнән җибәрелгән бер тәбрикнамәдә, мәсәлән, мондый юллар бар: *«Безгә юл күрсәтеп, юл сызып, дөрес вә тугры юлга димләп, шуңа өндәүче булмаса, без бер кыйблага таба бара алмас идек, яңлышыр идек, таралыр идек... Ходага шөкер, без бу яктан бәхетлеләрбез: бер Харбин яшьләренә генә түгел, мөһаҗәраттәге барлык яшьләребезгә исем вә хедмәтегез берлә рух биреп торучыны без сезнең кыйммәтле шәхесегездә күреп торабыз. Котлы булсын олуг бәйрәмегез! Бу көндә сезгә нинди генә мәдхияләр укылса да, аздыр. Сез, кадерле Гаяз абзый, үзегезнең зур эшләрегез берлә милләтнең вә аның балаларының самими ихтирамын, мәхәббәтен бик лаеклы рәвештә казандыгыз. Яшәгез!»*

1939 елда, икенче бөтендөнья сугышы башлангач, Г.Исхакый Польшадан китәргә мәҗбүр була һәм бераздан Төркиягә барып урнаша. Әүвәл Истанбулда яши, аннан — Анкарада.

Мәгълүм булганча, Г.Исхакый илдә вакытта ук хатынынннан аерыла. Бердәнбер кызы Сәгадәт (1907–1989) мөһаҗәраттә югары белем ала, атаклы тюрколог-профессор булып танылa. Ире Таһир Шакир (Чагатай) — Алманиядәге Гейдельберг университетын тәмамлаган билгеле галим, журналист. Алар да, сугыш башлангач, Төркиягә күчеп киләләр. Г.Исхакый үзе генә дә, алар белән дә яши.

Әдип Истанбулда һәм Анкарада гомер кичерү елларында әдәби иҗат, фәнни һәм җәмәгать эшләре белән шөгыльләнә. 1948 елның 2 октябрендә Истанбул университетында язучы иҗатының 50 еллыгына багышланган кичә үткәрелүе мәгълүм. Г.Исхакый берничә мәртәбә Аурупа илләрендә дә була. Татар халкын туплау, милли рухта тәрбияләү эшен дәвам иттерә. Гомеренең соңгы еллары хакында әдипне яхшы белгән Гали Акыш менә ничек яза: «1953 елда Көнбатыш Германиянең Мюнхен шәһәренә китеп*, анда «Милли байрак» исемле өч айлык журнал чыгара башласа да, каһәр төшкән рак авыруы җанын һәм тәнен кимергәнгә күрә, кире Төркиягә кайтырга мәҗбүр булды. Г.Исхакый 1954 елның 22 июлендә Анкарада яшәгән кызы — хөрмәтле профессор Сәгадәт Чагатайның

* Алманиядә Г.Исхакый 1953 елның май-август айларында була. Бирердә ул татар-башкорт мөһаҗирләре, урыс эмигрантлары (җөмләдән Керенский) белән дә очраша, милли-азатлык хәрәкәтен җанландыру, оештыру турында чыгышлар ясый, төрле чаралар үткәрә.

өендә вафат булды. Гәүдәсе, Истанбулга китерелеп , 24 июльдә Әдернәкапы зиратына җирләнде» (Казан утлары, 1994. — № 2. — 157 б.). Шулай итеп, әдипнең Чулман-Идел буйларында башланган гомер юлы, Аурупа һәм Азия кыйтгаларын үтеп, күп кенә илләрне кичеп, Төркия мәмләкәтендә туктап калды.

## II

Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеге тиешенчә өйрәнелмәгән, андагы материаллар, факт-мәгълүматлар кирәгенчә барланмаган. Моның төп сәбәбе, — әлбәттә, совет хакимиятенең әдипкә тискәре мөнәсәбәттә торуында, аңа каршы көрәш алып баруында.

Г.Исхакый эшчәнлеге күптармаклы: әдәби, сәяси, иҗтимагый, публицистик, гыйльми, тәрҗемәчелек, педагогик һ.б. Боларның һәрберсе махсус һәм җентекле тикшерүгә мохтаҗ. Шунысы мөһим: төрле тармаклардагы бу төр эшчәнлек әдипнең көчле һәм талантлы шәхесе, милли җаны белән, ничектер бергә оешып, табигый бөтенлекне тәшкил итә. Аның һәр язмасында яңалык, фикер байлыгы, тирәнлек, мөстәкыйль караш күзгә ташлана.

Г.Исхакыйның кайбер әсәрләре әле хәзергәчә басылмаган. Аерым язмаларының исемнәре генә билгеле. Әдипнең, татар теленнән тыш, төрекчә, гарәпчә, урысча, полякча, французча, инглизчә, әрмәнчә, алманча һәм кайбер башка телләрдә язылган яисә басылган материаллары да бар. Аның, мәсәлән, «Татар кызы» романы (1943–1945), «Хәят юлында» драмасы (1940, 1946), «Тәүбә иткән хатын» хикәясе (1946–1948) төрек телендә. «Ике ут арасында» («Атәш эчендә») драмасы (1921–1937), «Олуг бәйрәм» хикәясе (1923–1938), «Хатирә дәфтәрләре» һәм кайбер башка язмалары хәзергә кулыбызда юк.

20 нче еллар ахыры–30 нчы еллар — Г.Исхакый эшчәнлегенең иң актив чоры. Шушы дәвердәге иҗтимагый-сәяси, тарихи заруриятне күздә тотып, әдип үзенең мәшһүр «Идел-Урал» китабын яза (1927–1929). Ул 1933 елда Парижда урыс һәм француз телләрендә, бер елдан соң Токиода япон, ә 1938 елда Варшавада поляк телендә дөнья күрә, фин теленә тәрҗемә ителә. 90 нчы елларда исә бу китап безнең илдә урыс һәм татар телләрендә берничә мәртәбә нәшер ителде.

***«Идел-Урал»*** — тарихи-сәяси характердагы хезмәт. Анда халкыбызның этник һәм дәүләтчелек тарихы, рухи, мәдәни мирасы кыскача яктыртыла, татар тормышындагы мөһим вакыйгалар, этаплар бәян ителә. Китап милли бәйсезлек өчен көрәш, мөстәкыйль мәмләкәт төзүгә омтылыш идеясе белән сугарылган. «Идел-Урал» авторның төрки-татар тарихын, Рәсәй сәясәтен шактый тирән белүен күрсәтеп тора. Бу хезмәт халкыбыз-

ның 90 нчы еллар башындагы милли күтәрелешенә гаять зур йогынты ясады.

Мөһаҗирлектә вакытта Г.Исхакый профессор М.Худяковның Казан ханлыгы тарихы хакындагы мәшһүр китабын, Н.Гогольнең «Старосветские помещики» («Деребейләр») (1948) һәм кайбер башка авторларның әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итә.

Әдипнең вакытлы матбугат битләрендә басылган мәкаләләрендә татар, төрк, урыс, дөнья тарихының, сәяси, иҗтимагый һәм мәдәни яшәешенең гаҗәеп күптөрле мәсьәләләре яктыртыла.

## III

Г.Исхакый мөһаҗәрәттә яшәү елларында барыннан да элек әдип, язучы булып калды. Дөрес, аның бу чорда иҗат иткән әсәрләре, Октябрь инкыйлабына кадәрге чор белән чагыштырганда, азрак. Күрәсең, туган туфрактан аерылу, язганнарын бастыра, укучыларга җиткерә алмыйча интегү дә монда билгеле бер роль уйнагандыр.

Әмма Октябрь инкыйлабыннан соң Гаяз Исхакыйның иҗаты, гомумән, идея-эстетик яктан тагын да үсә, камилләшә төшә. Күп илләрдә булу, төрле кешеләр белән аралашу, Аурупаның фикри һәм сәнгати казанышлары белән турыдан-туры танышу аның әсәрләренә уңай йогынты ясаган.

Г.Исхакый мөһаҗирлек елларында роман, хикәя, повесть, драма, комедия, әкият һәм башка жанрларда иҗат итә. Бигрәк тә драмага өстенлек бирә. Бу, мөгаен, чорның, татар язмышының, әдип тормышының кискен борылышларга, конфликт-каршылыкларга бай булуы белән аңлатыладыр.

Әдипнең мөһаҗирлек дәвере иҗаты идея-тематик яктан шактый бай, төрле. Әмма шулай да аның үзәгендә — тарихи вакыйга-хәлләр. «Олуг Мөхәммәд» (1948), «Өйгә таба» (1922), «Дулкын эчендә» (1920), «Җан Баевич» (1923), «Локман Хәким» (1923) һ.б., әйтерсең татар яшәешенең аерым сәхифәләре. Аларда халкыбыз тарихының мөһим күренешләре, кайгышатлыклары, өмет-теләкләре сәнгати яктан калку һәм үтемле гәүдәләнеш тапкан. Бу әсәрләрдә без әдипнең көчле рухын да, уй-хыялларын да, Ватанын сагынып җирсүен дә ачык тоябыз.

## IV

Г.Исхакыйның мөһаҗәрәттә язылган әсәрләре, гәрчә алар өлешчә басылып, бераз таралган булсалар да, илдәге татар укучыларына бары тик 90 нчы елларда гына ирешә башлады. Бу юнәлештә безнең гәзит-журналларыбыз, аеруча «Мирас» мәҗмугасы зур һәм игелекле эшләр башкарды.

***«Локман Хәким»*** гыйбрәтле язмышка ия. Ул 1923–1924 елларда Берлинда иҗат ителә. Кызганыч ки, аның татарча тексты сакланмаган. Русча нөсхәсе генә бар. Кайбер галимнәр бу әсәрнең 1934 елда Шанхайда чыга торган урыс мөһаҗир гәзитләренең берсендә дөнья күрүен искәртәләр. Әсәр бездә тәүге мәртәбә 1990 елда «Идел» журналында И.Нуруллинның кереш сүзе белән Солтан Шәмси тәрҗемәсендә нәшер ителде (№ 6. — 2–7 б.).

Г.Исхакый иҗатын халыкка җиткерүгә һәм өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән профессор Ибраһим Нуруллин «Локман Хәким» әсәрен 1989 елгы сәфәрендә Төркиядән алып кайта. Шунысын да искәртик: бөек әдипнең мирасын туплауда һәм Идел-йортка ирештерүдә әүвәл Кытайда, аннан Төркиядә гомер кичергән Мәхмүт Таһирның (1922–1991) роле искиткеч зур. Г.Исхакыйның башка күп кенә материаллары кебек, «Локман Хәким» дә шушы зат аркылы бүгенге укучыларга иреште.

«Локман Хәким» — һәм стиль-интонациясе, һәм эчтәлеге белән әкияти рухтагы әсәр. Аның башлануына гына игътибар итегез: «Борын-борын заманда яшәгән, ди, җир йөзендә бер халык. Бу халык илендәге җир-суларның, урман-кырларның, таукыяларның исәбен-хисабын белмәгән — тормышы бик бәхетле булган. Елгаларының берсеннән ап-ак сөт аккан, икенчесеннән хуш исле бал, өченчесеннән сары май ага икән...» Алга таба да шушындый стиль белән мәмләкәтнең муллыгы, кавеменең имин тормышы, гармонияле яшәеше сурәтләнә. «Анда, — ди автор, — балалар ата-ана сүзеннән чыкмаган, хатын ирен тыңлаган, ир хатынына кул күтәрмәгән. Олыны — олы, кечене — кече дип танып, һәркайсы үз урынын белгән. Түрә, бәк, хәлфә, остаз кеби дәрәҗәле адәмнәр дә үз вазыйфаларын җиренә җиткереп башкарганнар. Гомумән, анда хан — хан, вәзир — вәзир, акыл иясе хәким булып, һәркайсы үз урынын белгән». Патшалары да, вәзирләре дә гадел булып, 40 ел артка, 40 ел алга карап эш иткәннәр.

Мәмләкәттә бөтен акылны үзендә туплаган акыл иясе-хәким дә яшәгән. Хөкемдарлар да, халык та аның акылына, киңәшләренә таянып көн күргән.

Бервакыт Ходай Тәгалә тарафыннан акыл иясенә бер сер җиткерелә: гаять көчле яңгыр булачак. Ул туктагач, аның суын эчеп, кешеләр акылларын югалтачак... «Хәким моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән нәрсәләр буласын аңлаган, аның күңелен зур борчу вә дәһшәт чолгап алган». Бу хакта патшага һәм вәзиргә дә әйткән, чиста су әзерләп куярга кушкан.

Алдан искәртелгән яңгыр, афәт килә. Су баса. Табигать тынгач, кешеләр, су эчеп, акылларын җуеп, бернәрсә хакында уйламыйча, кәеф-сафа кора башлыйлар. Хәким, патша, акыл иясе алдан ук әзерләп куелган суны эчеп, элеккечә калалар. Ха-

лык, аларның үзеннән аерылып торуын белеп, вәзиргә һәм патшага да тилертә торган суны эчерәләр. Хәким мәгарәгә качып китә, ни-нәрсә булганны язып бара.

Акылын җуйган кешеләр, патша һәм вәзир илне тәмам бөлгенлеккә төшерәләр. Эшләү, киләчәк, үткән турында уйлау бетә. Үтереш, суеш, талау, исереклек, наркотик куллану гадәти күренешкә әйләнә. Шунысы аяныч: бу хәлне кешеләр шулай кирәк, зарури дип кабул итәләр.

Шактый вакыт узгач, янә күк күкрәп, яшен яшьнәп, 7 көн, 7 төн буена көчле яңгыр ява, халык йоклый. Табигать тынгач, халык урамнарга чыга һәм илдәге ачлыкны, җимереклекне, фәкыйрьлекне күреп шакката. Бөтенесе кайгы-хәсрәттә. Кабат акылларына кайткан адәм балалары хәкимне искә төшерәләр, аны эзли башлыйлар. Хәкимне, ниһаять, табалар. Чал чәчле, бөкре карт күргән-кичергәннәрен язып барган була. «Китапны, — ди ул, — бер ел кара, икенче елны күз яшьләре, өченче елны каным белән яздым». Халык карттан гафу үтенә, тынычлап йокыга китә. Әмма шул төндә тәре йөртүчеләр шәһәрне тартып алалар, җимертәләр, күп халык кырыла. Локман хәким дә, хикмәтле китап та онытыла. Күпмедер вакыт узгач, тәре йөртүчеләр куыла, тормыш җанлана башлый. Иске биналарны чистартканда, чүп-чар арасыннан саргаеп беткән бер кәгазь килеп чыга. Ул Локман Хәким язып калдырган киңәш-теләкләрнең бер өлеше була. «Әмма, — ди автор, — аның бик күп хикмәтле сүзләре әле дә билгесез килеш кала». Шуның белән әсәр тәгәлләнә.

Локман Хәким, — акыл иясе, гадел, намуслы, зиһенле кеше буларак, Шәрык, шул исәптән татар дөньясында да элек-электән мәгълүм образ. Күп кенә язма истәлекләрдә бу әкияти каһарман хакында гыйбрәтле кыйссалар сөйләнелә, мөһим факт-мәгълүматлар китерелә. Коръәннең 31 нче сүрәсе юкка гына Локман исеме белән аталмаган. Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки»ендә (1391) бу акыл иясе хакында махсус хикәят бар. Соңгырак дәвер татар чыганакларында да Локман хәким еш кына телгә алына, хәтта аның хикмәтле сүзләрен туплаган махсус язмалар да дөнья күрә. Кыскасы, Г.Исхакый генетик яктан мифологиягә, фольклорга, төрле язма чыганакларга барып тоташкан материал белән Урта гасыр поэтикасына хас ысул, ягъни теге яки бу дәрәҗәдә билгеле сюжет, образлар белән эш итә.

Фәнни әдәбиятта «Локман Хәким» әсәренең Октябрь инкыйлабына, совет чынбарлыгына ишарә рәвешендә язылуын еш телгә алалар. Бу — билгеле бер дәрәҗәдә дөрес. Чөнки Г.Исхакый большевиклар идеологиясе белән килешмәгән, совет җәмгыятенә тискәре, тәнкыйди мөнәсәбәттә торган. Әмма бу әкиятнең эстетик-мәгънәви йөкләмәсе шактый зур, сурәтлә-

ре күп сыйдырышлы. Аны совет чынбарлыгына да, Рәсәйнең татар ханлыкларын яулап алуына да, тарихта булган һәм булачак башка бик күп күренешләргә һәм мәмләкәтләргә дә нисбәт итәргә мөмкин. Халкы нинди, патшасы да шундый. Әсәрдә дә халык үз хөкемдарларының үзенчә фикерләвен, эш итүен таләп итә һәм максатына да ирешә. Акыл, белем, инсаният чоры белән кадерсез төшенчәләргә әйләнә. Стандарт фикерләү, гавами психология һәлакәткә дә китерергә мөмкин.

Җәмгыятьтә нинди генә югалтулар, акылдан язулар булмасын, табигать үз кануннары белән яши. Адәм баласы да аннан үрнәк алырга, аның белән ярашып гомер кичерергә бурычлы.

Әсәрдәге аянычлы вакыйга-хәлләр кешеләрне, кавемнәрне сынау өчен җибәрелгән бер имтихан кебек. Гайре табигыйлек, әкияти вазгыять үзенә күрә бер тамаша, спектакль тудыра. Баксаң, әле адәм балаларының иман-ышанычы, инсанилыгы әллә ни нык түгел икән. Алар әле онытылырга, буыннан-буынга тупланган рухи тәҗрибәне читкә тибәрергә бик мөмкиннәр. Сугыш-түнтәрелешләр, кан коюлар, исереклек, әхлаксызлык — болар барысы да әле җәмгыятьтә яши торган күренешләр.

Кешелекнең акыл ияләре, әдипләре элек-электән гадел, бәхетле җәмгыять турында уйланганнар, бу юнәлештә төрле фаразлар корганнар. Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр әсәрләре — моның күркәм мисаллары. Г.Исхакый да бу традицияләрне дәвам иттерә, җир йөзендәге вәхши күренешләрне кискен тәнкыйтьли, халкы һәм, гомумән, кешелек өчен имин, бәхетле тормыш төзү турында хыяллана. «Локман Хәким» азагында моның өчен зарури булган әхлакый-инсани кагыйдәләр, таләпләр китерелә. Акыл иясенә нисбәт ителгән бу фикерләр түбәндәгедән гыйбарәт:

— Хак Тәгалә биргән кояшның җылысы барыбызга да җитәр.

— Кеше иркен кысма. Изгелегеңне кызганма.

— Туган җирең иркле булса, гомерең тыныч үтәр.

— Яхшы адәм фәрештә булмаган кеби, начар адәм дә шайтан нәселеннән түгел: кем генә булмасын, ул синең туганың — адәм баласы, аны хөрмәт ит.

— Ир-атның бәхете намуслылык вә затлылыктан торыр. Мәмләкәт бәхете хакыйкать вә гаделлектән торыр.

— Гадел падишаһ заманында халык тыныч яшәр.

— Ходайның хөкеме бер булыр. Аны мөнафикъ (икейөзле) бәндәләр төрләндерер.

— Мәмләкәттә тыюлар азрак булган саен, аларны кимрәк бозарлар...

Күрәсез: кешелек акылы, яшәеш тәҗрибәсе, әхлакый иман белән сугарылган бу киңәш-нәсихәтләр һәрчак, һәр кавем өчен инсани кодекс булырлык.

***«Көз»*** повесте Г.Исхакыйның Октябрь инкыйлабыннан соң иҗат ителгән әсәрләре арасында мөһим урынны били. 1923 елда Берлинда язылган, 1938 елда шунда ук басылып чыккан бу повесть Идел-йорт укучыларына, нигездә, «Казан утлары» (1992. — № 2. — 83–114 б.) һәм «Мирас» (1997. — № 11. — 17–28 б.; 1997. — № 12. — 10–23 б.) журналлары аша иреште.

Әсәрдә вакыйгалар якынча 1905–1914 еллар аралыгында Оренбургта, Идел, Дим буйларында бара. Мәскәүдә доктор булып эшләүче Хәлил ял итү һәм балаларына милли тәрбия бирү өчен Идел-йорттагы бер мөселман авылы янында утар сатып ала. Хатыны Нәфисә, ике баласын ияртеп, пароход белән шунда килә. Бер тукталышта алар янына ике баласы белән Гөлсем исемле бер ханым урнаша. Беренчесе шат, кәефле, икенчесе гаять арыган, йончыган. Юлда ике ханым, хатын-кызларга хас булганча, сөйләшеп китәләр, һәр икесе дә үзләренең яшь чакларын, ничек итеп кияүгә чыгуларын хикәяли.

Нәфисә — Оренбургтагы урта хәлле сәүдәгәр кызы. Театрда очраклы рәвештә бер гаскәри табиб белән таныша. Берберсенә гашыйк булалар. Кызның әтисе Нәфисәне башкага кияүгә бирергә тели. Әмма яшьләр үз сүзләрен сүз итәләр: никах укыла, гаилә корыла. Шуннан бирле бәхетле генә яшиләр.

Гөлсем исә бай мирза кызы. Яшьли үк әнисе үлә. Кыз әтисенең сеңлесе тәрбиясендә үсә. Сөйләшү, аралашу, нигездә, урысча. Мул тормыш; аксөякләр, югары дәрәҗәле кешеләр даирәсе. Боларның утарына бер мөселман студенты да килә. Аны Паша кушаматы белән йөртәләр. Кыз белән егет арасында җылы мөнәсәбәт урнаша. Әмма Гөлсемнең Паша белән дуслыгына гаилә хуҗалары каршы. Аны бер «әфисәр»гә димлиләр. Кыз баш тарта. Монда Пашаны гаепле санап, аны утардан куып җибәрәләр. Гөлсем гаять борчыла. Егетне эзләтеп тә карый. Ул укыган Петербург шәһәренә дә бара. Әмма Паша юк. Гөлсемнең әтисе үлеп китә. Кыз шул «әфисәр»гә кияүгә чыга. Әмма ул эчкече була. Дүрт баласының икесе үлә. Хатын үзләренең элеккеге утарына кайтып бара.

Пристаньда һәр ике хатынны да ирләре каршылый. Берсе исерек, икенчесе балкып тора. Баксаң, Нәфисәнең ире Хәлил Гөлсем яратып йөргән Паша икән.

Яшьлектә, тормыш язында очрашкан җирдә янә очрашу. Әмма фасылы үзгә — көз, сары яфраклар, «сары кәфен киенгән көзге урман»; күңелдә моң, сагыш, үкенеч...

Г.Исхакыйның «Көз» повесте — үзенең һәм рухы, һәм әдәби-эстетик табигате белән гаҗәеп әсәр. Ул ничектер бер сим-

фония кебек. Әсәрнең моң-интонациясе, каһарманнарының язмышы синең күңелеңне биләп ала, тетрәндерә.

Кайвакыт Г.Исхакыйның тел-стиленә карата тәнкыйть сүзләре әйтүчеләр дә бар. Имеш, ул ашыгыбрак язган. Язганнарын төзәтеп, эшкәртеп тормаган... Бу дәгъвалар хакмы-нахакмы, — анысы икенче мәсьәлә. Гөнаһына кермим. «Көз» повесте исә тел-стиль ягыннан классик әсәр. Андагы нәфислек, музыкаль аһәң укучыны сокландырырлык. «Көз» И.Тургенев, А.Чехов, И.Бунин әсәрләре югарылыгында язылган.

Повестьта язганнарны җанландыручы, күңелгә ятышлы, текст рухы белән ярашучы сурәтләр күп. Менә көзге караңгылыкта баручы пароход образы. «Ул, — ди автор, — шул төпсез-чиксез караңгылыкны ертып, алга барырга маташа, үләр алдыннан буылган кеше кебек, карлыккан тамаклары берлә бик ямьсезләнеп кычкырта, тагы көпчәкләрен селкетеп поштыр-поштыр йөргән кебек була иде. Ләкин ул никадәр хәрәкәтләнгән булса да, караңгылыкны үтә алмый, никадәр ыңгырашып кычкырса да, җавап ала алмый иде...» Икенче бер урында пароход йөреше болай тасвирлана: «Пароход, бии торган куштан кызның әйләнүе кебек матурлап борылып, пристаньга якынайды».

Әдәби иҗатта вакыт төшенчәсе мөһим роль уйный. (Вакыт һәм пространство мөнәсәбәтләрен еш кына хронотоп дип тә йөртәләр.) «Яшь гомерләр кире кайтмый, сулар үргә акса да» дип җырлый халык. Дөрес, реаль вакыт бер юнәлешле: хәзерге аркылы үткәннән киләчәккә бара. Башыңны ташка бәреп еласаң да, ул үз тәртибен үзгәртми. Әдәбиятта исә вакыт автор кулында көчле чара: ул аны кирегә дә бора, үзгәртә дә ала. Бу яктан «Көз» повесте аеруча кызыклы. Анда хәзерге вакыйгалар хәтер, искә төшерү ярдәмендә элеккеләре белән кушылып, аралашып бара. Мондый алым геройлар язмышын тулырак күрсәтүгә, әсәрнең тәэсир көчен арттыруга булыша. Нәфисәнең һәм Гөлсемнең үткән тормышларын эченә алган хикәяләр ничектер чагыштырмача мөстәкыйльлеккә дә ия. Бу яктан повесть билгеле бер дәрәҗәдә кысалы кыйсса жанрына да якыная. Әмма бу жанрның «Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә» кебек классик ядкәрләрдән үзгә буларак, «Көз» повестенда ике сюжет һәм эчтәлек, һәм идея яссылыгында үзара тыгыз бәйләнешле. Ике хатын язмышының янәшә бирелүе аларны үзара чыгыштырырга, тормышның аерым мәсьәләләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Г.Исхакый — психологик портрет остасы. Бу әсәрендә ул төп каһарманнарының халәте рухиясен, күңел каршылыкларын гаҗәеп матур итеп бирә. Менә шактый гомерләре узып, кабат очрашкан Гөлсем белән Хәлил бер каретада баралар, һәр икесенең дә күңелендә каршылыклы уйлар, ничәмә-ничә еллар эчендә җыелган моң-сагышлар, әйтергә теләгән сүзләр... Әмма сүзне каян, ничек башларга белмичә газапланулар...

Г.Исхакый, күп кенә башка әсәрләрендәге кебек, бу повестенда да хатын-кыз рухын тирәнтен тоеп, аларны хөрмәт белән тасвирлый. Нәфисә һәм Гөлсем кыяфәтләре һәм күңелләре белән матур, күркәм кешеләр. Аларда тою, кичерү, хәтер көчле. Еллар узуга да карамастан, һәр ике хатын да романтик яшьлекләрен онытмыйлар, мәхәббәт хисләре аларның күңел түрендә.

Г.Исхакый милләт, җәмгыять яшәешенең нигезен гаиләдә күрә. Шуңа күрә ул Нәфисәнең имин, бәхетле гаилә тормышын тасвирлауга җитди игътибар бирә. Әдип гомере буе диярлек шәхси ялгызлыкта, буйдак булып гомер кичерә. Әмма аның әсәрләрендә, шул исәптән «Көз» повестенда да авторның, тигез гаилә тормышын сагынып, андый яшәешкә сусап яшәвен ачык тоясың.

Әсәрдә Паша-Хәлил образы да кызыклы бирелгән. Урыс арасында яшәсә дә, аның күңелендә туган халкына, милли яшәешкә омтылыш, хөрмәт бар. «Ир кешенең күңелендә йөгәнләгән ат ятыр» диләр. Хәлилнең беренче мәхәббәтен хәтта хатыны Нәфисә дә белми. Матур, бәхетле гомер кичерүче бу табибның да күңел түрендә элеккеге хисләре сүнмичә яшәгән икән. Аның нәкъ менә Гөлсем белән очрашкан төбәктән утар сатып алуы да күп нәрсә хакында сөйли.

Гөлсем һәм аның гаиләсе хакында уйланып, Нәфисә болай ди: «Ник соң бу болай? Ник болар уртача гына бәхет берлә тора алмаганнар? Ниләре җитешмәгән, икесе дә укыган, икесе дә тәрбия күргән... Икесе дә яшь булган... Ник?» Аларның язмышын үзенеке белән чагыштырып карый.

Нәфисә куйган сорауларга тулы һәм бертөрле генә җавап бирү мөмкин түгел. Адәм балаларының язмышлары, гомер юллары, гомумән, төрле-төрле. Берәүләргә бәхет елмая, икенчеләрен гел кайгы эзәрлекләп йөри. Әмма сәгадәт һәм бәхетсезлекнең кайбер объектив сәбәпләре дә бар.

Гөлсем — милли җирлектән, татар мәнфәгатьләреннән аерылып яшәүче мирза кызы. Күңелендә кан белән килүче иман, милли рух булса да, тиешле шартлар җитмәү аркасында, алар кыз җанында һәм яшәешендә тиешле урын ала алмыйлар. Урыс теле, урыс тәрбиясе, урыс даирәсе аңа тирән эз сала. Ире дә шундый ук мохит җимеше. Өстәвенә ул исереклек чире белән авырый. Гөлсем яшь чагында мәхәббәтен, Пашаны яклап, тиешле гамәлләр кылмый; егетне кимсетү-мыскыллаулардан араламый. Ахыр чиктә шуның җәзасын да ала.

Нәфисә — милли, дини тәрбия алган кыз. Анда ихтыяр көче бар. Дөрес, без аның ата-анасы ризалыгыннан башка кияүгә чыгуын хупламыйбыз. Әмма кызның кешене таный белүе, егетнең әйбәт, тәрбияле ир булуы Нәфисәнең бу бәхәсле гамәлен каплый.

Г.Исхакыйның мөһаҗәрәттә язылган күп кенә әсәрләреннән үзгә буларак, «Көз» повестенда милли тематика артык сиздермичәрәк яктыртыла. Шулай да әсәрдә авторның милләт язмышы, аның хәле турында кичерешләрен, уйлануларын күрү кыен түгел.

Нәфисәнең бәхетле гаилә тормышы, балалар үстерүе аның туган халкы, гореф-гадәтләр белән багланышта торуына да бәйле. Хәлил, гәрчә бик тәҗрибәле врач булса да, доцентлыкка расланмый. «Аны, — ди автор, — мөселман булганга, министр тасдыйк итмәде. Шуңарга шактый борчылды. Бу урыс хезмәтнең кадерен барыбер белми». Гөлсемнең мирзалык, аксөяклек каны сеңгән апасы (тутакай) Пашаны татарлыкта, затсызлыкта гаепли. Аның фикеренчә, «борчак оны берлә балны... бергә бутап булмый».

Әсәрдәге вакыйга-хәлләр, уй-кичерешләр еш кына табигать белән бәйләнештә биреләләр. Әйтерсең табигать һәм адәм балаларының язмышы уртак. Алар бер-берсенә һич тә битараф түгел.

«Көз» повесте, әдипнең кайбер башка әсәрләре кебек, сәхнәләргә, экраннарга, кинофильмнарга соралып тора.

## VI

***«Тәүбә иткән хатын»*** әсәрен Г.Исхакый 1946 елда иҗат итә. Әүвәл автор аны «Исемсез хикәя» дип атаса, 1948 елда әсәргә хәзерге исемен бирә. Төрекчә язылган бу хикәя тәүге мәртәбә Төркиядә нәшер ителүче «Kazan» журналы битләрендә дөнья күрә. Идел-йортта исә аны беренче тапкыр «Шәһри Казан» гәзите бастырып чыгарды (22, 23, 26, 27 февраль, 1991 ел). Төрекчәдән Р.Сабиров тәрҗемә иткән бу хикәя И.Нуруллинның кереш сүзе белән укучыларга тәкъдим ителгән.

Әсәр «мин» — автор исеменнән хикәяләнә. 1939 елда, сугыш алдыннан, «мин» Истанбул урамында бер исерек төрек кызын очрата. Яшь, чибәр. Аның тарихы белән кызыксына. Мәбрүкә — хәлле генә бер гаиләдән. Әтисе үлгән. Кыз начар юлга баскан. Шуның өчен аны әнисе өйдән куып чыгарган. «Мин»нең күңелендә кыз язмышы кызгану хисен уята. Тәмам бозылып беткәнче, «мин» аны баткаклыктан чыгарырга уйлый. Кызның әнисе белән сөйләшә. Мәбрүкәне кичерүен үтенә. Кыз тәүбә кыла. Еллар уза. «Мин» бу вакыйганы оныта яза. Әмма бервакыт ул кызны очрата. Ул бөтенләй үзгәргән, тормышыннан канәгать. Әйбәт кенә кешегә кияүгә чыккан. Ике баласы бар. Яшь хатын «мин»гә рәхмәтләр укый. Хикәя мондый юллар белән тәгалләнә: «Бу минем гомерем буе тормышка ашырырга тырышкан нәрсәнең — моңа мохтаҗ милләттәшләремә ярдәм итәргә кирәклекнең хаклыгына, дөреслегенә ышануымны тагын да көчәйткән иде».

Эчтәлегеннән үк күренгәнчә, хикәя Г.Исхакый иҗаты өчен, гомумән, хас тематика, хатын-кыз язмышы, гаилә тормышы мәсь-

әләләре белән тыгыз бәйләнешле. Авыр хәлгә төшкән хатын-кызлар авторның бәгырен телгәли, аның күңелен аларны бу хәлдән ничек, ни рәвешле чыгару уе борчый. Г.Исхакый фикеренчә, теләсә нинди инсан, тиешле ярдәм, игътибар булганда, тугры, гадел юлга баса ала. Кеше, тәүбә кылып, үз гөнаһларыннан арынырга, рухи яктан үзгәрергә сәләтле. Хикәянең һәм исеме, һәм эчтәлеге нәкъ әнә шул хакта сөйли.

* * *

Г.Исхакыйның мөһаҗәрәттәге иҗаты шактый бай һәм күпкырлы. Биредә исә без аның аерым әсәрләренә тукталып киттек. Алга таба әдипнең берничә китабы, әсәре хакында аерым-аерым махсус сүз алып барылачак. Әмма аларда да бөтенлеккә, тулы, җентекле тикшерүгә дәгъва ителми.

Г.Исхакыйның тормышы, эшчәнлеге хакында соңгы дистә елда шактый гына материаллар дөнья күрде. Аларда мөһим күзәтүләр, кызыклы факт-мәгълүматлар бар. Бу төр гыйльми тикшеренүләрдә, аеруча Ә.Сәхапов монографияләрендә әдип мирасының, аның турында язмаларның гаять бай библиографик исемлеге дә бирелгән.

Г.Исхакый темасы әкренләп уку йортлары программаларына, дәреслекләргә да керә бара. Казан университеты профессоры Р.Ганиева, үзенең шәхси педагогик тәҗрибәсенә нигезләнеп, Исхакый иҗаты хакында махсус программа төзеде (карагыз: Мирас, 1998. — № 5. — 63–78 б.). Анда әдипнең тормыш юлын һәм мирасын өйрәнүнең торышы, Г.Исхакый иҗатының төп этаплары, аерым үзенчәлекләре күрсәтелә. Ахырда библиографик исемлек тә тәкъдим ителә.

1998 елдан Г.Исхакый әсәрләренең күптомлыгы чыга башлады. Бөек әдип мирасын әзерләп, укучыларга тиз арада җиткерү халкыбызны рухи яктан баетуда бәяләп бетергесез эш булыр иде.

*1999*

## Язмышлар дулкынында

*(«Дулкын эчендә» драмасы)*

### I

Тормыш тәкъдир режиссерлыгындагы дәвамлы сериал кебек. Аның һәр мизгелендә туу һәм үлем, шатлык һәм кайгы, кавышу һәм аерылышу, мәхәббәт һәм нәфрәт булып тора. Әмма галиҗәнап Вакытның аерым баскычларында тереклек диалектикасының йә куанычлы, йә фаҗигале яклары өстенлек

ала. Кызганычка каршы, Рәсәй империясенә чылбырланып куелган татар яшәешендә аянычлы сәхифәләр еш кабатланып тора. Башка кавемнәргә килгән кайгы да аңа икеләтә-өчләтә артык төшә. Икенче бөтендөнья сугышында, мәсәлән, татарлар, гәрчә алар оешып яшәгән җирләрдә туплар шартламаса да, иң күп зыян күргән, коточкыч югалтулар кичергән халыкларның берсе булды.

Әдәби әсәр ул — язмышлар, кичерешләр елъязмасы. Ә инде вакытның катлаулы, киеренке борылышларында андыйлар — гыйбрәтле вакыйга-хәлләр гадәттән тыш күп була.

Беренче бөтендөнья орышы, инкыйлаб, илдәшләр (граждан-нар) сугышы —болар бит тарихның исең-акылың китәрлек фаҗигаләре, адәм балаларын сынауның сират күпере кебек хәтәр еллары. Г.Исхакый бу өермәле вакыйга-хәлләрнең үзәгендә кайный, күпчелек гавам омтылган идеаллар өчен көрәшә. Әмма ахыр чиктә чигенергә, Ватанын калдырып китәргә мәҗбүр була: Себер, Кытай, Япония. Озын-озак диңгез юллары... Газаплы һәм мәшәкатьле сәфәрләр, матди кыенлыклар... Татар баласына һич тә якты йөз күрсәтмәгән Аурупа тормышы. Күңелдә әрнү, борчылу... Үз кавеме, Идел-йорт, шәхси язмышы, кешеләр хакында уйланулар... «Дулкын эчендә» пьесасы нәкъ әнә шул чордагы уйлану-кичерешләрнең язмача бер хисабы, сәнгати гәүдәләнеше. Ул — Г.Исхакыйның мөһаҗәрәттә иҗат иткән тәүге әсәрләреннән берсе. Автор аны 1920 елда Парижда төгәлли. Матди кыенлыклар аркасында бу пьеса үз вакытында нәшер ителә алмый. Аны кулъязмада аерым кешеләр генә уку бәхетенә ирешә. (Нәкъ Урта гасырдагыча!) «Дулкын эчендә» Финляндиянең Тампере шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез ярдәмендә бары 1937 елда гына аерым китап рәвешендә Берлинда гарәп хәрефләре белән басылып чыга. Аның керешендә авторның мондый сүзләре бар: *«Большевик җәһәннәменнән котылып чыгып, Аурупада бераз киң сулыш алгач та, беренче язылган бу әсәрем илемездә меңнәрчә булып үткән вакыйгалардан алынган авыр тәэссоратларның җимешедер. Күптән үк басылып, киң укучыларымызны таныштыру, хосусан мөһаҗәрәттә үсеп килә торган яшь буыныбызны туган илендәге кардәшләре, туганнарының башыннан үткәнен күз алдында җанландыру бик кирәк булса да, мәгаттәәссеф (кызганычка каршы. — Х.М.), матди кысынкылык аркасында бу вазыйфаны вакытында үти алмаган идек. Финляндиянең Тампере милләтчеләре безнең бу милли вазыйфамызны үтәргә имкян биргәнгә, һәммәсенә дә зур рәхмәтләремне укып, укучыларга «Дулкын эчендә»не тәкъдим итәм... Варшау,1932 ел».*

Бу әсәр Идел-йортта бары тик 1992 елда гына басылып чыкты (Мирас, 1992. — № 4. — 52–72 б.; № 5. — 52–66 б. Биредә төп чыганак итеп шушы басма алынды).

Г.Исхакый — Октябрь инкыйлабына кадәр үк драма жанрында иҗат иткән әдип. Әмма мөһаҗәрәт чорында ул бу жанрга аеруча өстенлек бирә. 20–40 нчы елларда иҗат ителгән күпчелек әсәрләре («Ике ут арасында», «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд» һ.б.) — шушы шәкелдә. Безнең уебызча, бу жанрны күз уңында тотуның сәбәбе шунда: драма — үзенең синтетик табигате белән авторның уй-ниятләрен үзгәләргә җиткерүдә, укучы-тамашачыны рухи тәрбияләүдә аеруча үтемле шәкел. Мәгълүм булганча, Г.Исхакый — әдип кенә түгел, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче дә. Ул үзенең иҗтимагый-сәяси, милли идеаллары өчен көрәштә сүз сәнгатен аеруча җитди корал, чара дип саный. Бу — бер. Икенчедән, халыкның, илнең һәм, гомумән, дөньяның бу еллардагы тормышы, әйткәнебезчә, кискен вакыйга-хәлләр, төрле сугыш-түнтәрелешләр, фаҗигаләр белән кайнап тора. Болар бар да Г.Исхакыйның драма жанры белән мавыгуына этәргеч ясаганнар булса кирәк.

## II

Пьесадагы вакыйгалар 1915–1919 елларда Казанда бара. Иреннән тол калган Разыя исемле хатын кызы Бану белән гомер кичерә. Тормышлары чыгыштырмача әйбәт: үз йортлары, кибетләре, Галимә исемле хезмәтчеләре бар. Бану гимназиядә укый. Разыя хастаханәдә ятучыларга, яралыларга үз ирке белән ярдәм итеп йөри. Аны үз йортларында фатирда торучы Хәйрулла исемле сәүдәгәргә димлиләр. Хатыны үлеп, ике баласы белән тол калган бу ирнең тәкъдимен Разыя, гәрчә ул аны хөрмәт итсә дә, кабул итми. Баласын тәрбияләү аңа бөтен нәрсәдән өстен. Дөнья сугышы кызганнан-кыза, афәт-югалтулар арткан-арта бара. Хәйрулланы сугышка җибәрәләр. Бераздан ул һәлак була. Бану адвокатлыкка укыган Бәкер исемле егеткә кияүгә чыгып, иренең туган ягына — Кырымга китеп бара. Ялгыз калган Разыя Шәүкәт исемле төрек малаен тәрбияли башлый. Урыс казаклары, бу малайның әнисен, сеңлесен үтереп, аны Рәсәйгә әсир итеп китергән булалар. Кан коюлы сугыш газапларына инкыйлаб зилзиләләре килеп кушыла. Казан кайный. Борчылган, авыру Разыя кызыннан хәбәр булмауга бәргәләнә. Шәүкәтне дә, урысларга әсирлеккә эләгеп, күп кыенлыклар күргән әтисе Фәрит эзләп таба. Шушы вакытта яшь баласы белән Кырымнан Бану кайтып төшә. Аның ирен большевиклар атып үтергәннәр. Соңгы пәрдәдә кызыллар килеп, Разыяның йортын талыйлар, акча, алтын таләп итеп, авыру хатынны, кызы Бануны куркыталар, диварга терәп аткан булып кыланалар. Алар чыгып киткәч, Разыяның хәле авырая. Кызына, Фәриткә васыятьләрен әйтеп, аларның гаилә корырга теләкләрен хуплап, Разыя җан бирә.

Драма төрле-төрле вакыйга-хәлләрдән гыйбарәт. Аларның һәммәсе дә диярлек бер урында — Разыя йортында бара. Бу юкка гына түгел. Автор чор афәтләренең шаукымын, кайтавазын, тормыш агышындагы каршылык-бәрелешләрне аерым гаилә, шәхес язмышында күрсәтергә омтыла. Әгәр дә без әсәрне бөтен тулылыгында күздән кичерсәк, андагы вакыйга-хәлләрнең турыдан-туры да, читләтеп тә Разыя яшәешенә барып тоташуын, дөресрәге, аның бәгырендә кайнавын, зиһене аша узуын күрербез. Бу олы җанлы, тынгысыз зат — драманың төп каһарманы, сюжет-хәрәкәтне әйдәүче көч.

Иреннән тол калган, тормыш авырлыгын үз җилкәсенә салган Разыя безнең күз алдыбызда, иң беренче чиратта, Ана булып килеп баса. Аның күңеле сизгер, һәрнәрсәгә игътибарлы. Разыя күрше-күлән, таныш-белешләре белән генә түгел, ә Шәүкәт, Фәрит кебек сынык язмышлы мөһаҗирләр белән дә инсани мөгамәләдә. Бу хатын үзенең шәхси бәхетен кызының бәхет-киләчәгендә күрә. Шуның өчен күңеленә хуш килгән кешегә кияүгә чыгудан да баш тарта. Әмма, бала күңеле далада, дигәндәй, «мин, әни, синнән аерылмыйм» дип вәгъдәләр биргән Бану, тиз арада кияүгә чыгып, ерак Кырым якларына китеп тә бара. Хәтта «әни, әйдә безнең белән» дип күңел өчен генә булса да әйтми. Әмма ничек кенә булмасын, Разыя кешеләрнең тормыш кануннары белән билгеләнгән хәрәкәт-адымнарын аңларга тырыша. Кызы хакында ул болай ди: «Үзенең мәхәббәте белән исереп, мине дә онытты, ялгызлыгымны да күрмәде, күрә алмады! Рәнҗемим... Валлаһи, рәнҗемим... Рәхәт тор, кызым, рәхәт яшә, кызым...» Соңгы сулышынача аның күңелендә баласы өчен яну, көю, борчылу. Фаҗигагә тарыган Бану да бераздан үзенең ялгышлыгын аңлый, әнисе алдында тәүбә кыла. «Әнием, бәгърем, — ди ул, — рәнҗеттем үзеңне!.. Рәнҗеттем, әнием, бәгърем, бәхил бул! Валлаһи, сине рәнҗетәм дип уйламадым!»

Разыя, кеше, хатын-кыз, ана буларак, янә бер гаҗәеп сыйфатка ия: ул үзенең моң-зарларын, шик-шөбһәләрен теләсә кайда түгеп-чәчеп йөрми, үзе белән үзе сөйләшә, үз күңелендә калдыра. Автор аның эчке каршылыкларын, җан диалектикасын искиткеч осталык белән бирүгә ирешкән.

Г.Исхакый үз иҗатында хатын-кызларны аеруча күңел биреп, хөрмәт-ихтирам белән сурәтли, аларның авыр хәлдә калуларына көенә, шатлык-куанычларына сөенә; хатын-кызда, гаиләдә тереклекнең асылын, милләт яшәешенең нигезен күрә. Шуңа күрә авторның бу җенестәге күп кенә образлары һәм инсани, һәм әхлакый яктан укучыларга үз һәм якын. Разыя да әнә шундый күркәм холыклы каһарманнарның берсе, «Җан Баевич»тагы Сәхипҗамалныңише, кардәше. Ул, нинди генә кыенлыклар булса да, тормышның дәвам итәчәгенә, киләчәккә ышана. Әсәрнең ахыры бик мәгънәле, хәтта өлешчә символик та.

Гомеренең соңгы сулышларын алучы Разыя, үзеннән бигрәк, исәннәр, беренче чиратта, яшьләр турында кайгырта, киңәштеләкләр бирә, кызы белән кияүвенең туен оештырырга куша. Туй исә яшәешнең, буыннар дәвам ителешнең мөһим вакыйгасы, үзенә күрә бер символы да. Буылып йөткергән, кан төкергән Разыяның бу якты дөньядагы соңгы мизгелләрен киенеп, матур булып, музыка тыңлап, туйдагы кебек уздырасы килә. Әмма гомере буе борчылып, күңел тынычлыгы күрмичә яшәгән бу изге затның соңгы шәхси теләге дә гамәлгә ашмыйча, атылган кош кебек, өзелеп кала.

«Дулкын эчендә» драмасында, төп каһарманнан тыш, кызыклы гына башка образлар да бар. Шундыйларның берсе — Маһруй. Ул урта яшьләрдә. Аның өчен кызыксынучанлык, көр күңеллелек, тормышның авырлыкларына бирешмичә яшәргә омтылыш хас. «Дөнья, — ди ул, Разыяга мөрәҗәгать итеп, — барыбызга да бер, аны авыр күтәрсәң — авыр була, җиңелгә борсаң — җиңел була. Соң, әле кайгырып торып, ни чыга дип беләсең? Аллага шөкер... ачысын да күрдек, төчесен дә күрдек, өченче оя алыштырдым, уен түгел! Барысын да кайгырта башласаң, башыңдагы чәчең җитмәс. Тормышны төбеннән күтәрсәң дә, тәүлек егерме дүрт сәгать, өстән үтсәң дә, егерме дүрт сәгать: бүгенге көн минеке! Иртәгесен тагы шул ук кояш!»

Маһруйның бу төр яшәеш фәлсәфәсе белән килешергә дә, килешмәскә дә мөмкин. Әмма бит тормышта мондый мәсләкле кешеләр бар. Г.Исхакый әнә шундый типны җанлы, үзенчәлекле итеп бирүгә ирешкән.

Маһруй — гадәти генә хатын, бөтен күңеле, җаны белән җыр-биюне ярата торган зат. Сәнгати стихия аның канында, рухында. Ул җыр-музыка белән күңелләргә дәрт кертә, тормышка ямь өсти. Аның өчен сәнгать ниндидер зиннәт, өстәмә нәрсә түгел, ә кеше яшәешенең, инсан рухының тереклек рәвеше дә. Маһруй фикеренчә, «бию — китапның китабы». «Ул, күңел ашкынганга чыдый алмаенча, күңелнең уй артыннан баруы; уй чаба, бөтен тән, бөтен барлык аның артыннан тотам, тотам дип чаба; уй сыгыла, бу сыгыла, уй иелә, бу иелә, уй еглый, бу еглый, уй көлә, бу көлә...»

Әсәр тукымасында Галимә образы да мөһим идея-эстетик вазыйфа үти. Ул — Разыя йортында асрау кыз. Беренче пәрдәдә Галимә ачылмаган бөре, эш башкаручы буларак кына күренеп кала. Әмма алга таба без бу кызның шактый зиһенле, җор телле, матур итеп җырлаучы, тормыш, дөнья хәлләре белән кызыксынучы кеше икәнлеген абайлыйбыз. Ул кайгы-афәтләр китерүче сугышка тискәре мөнәсәбәттә. Аның агасы, энесе, җизнәсе солдатта. «Инде, — ди ул, — сабантуенда көрәшергә кеше дә калмаган. Чабыштырырга ат та беткән, барысын казнага алып бетергәннәр...»

Галимәнең патшага карашы да уңай түгел. Бер урында ул болай ди: «Бу падишаһны, каһәрне тиле, диләр иде, дөрест чыкты... Нимес белән сугышкан була бит, хәерче! Бөтен яшь егетләрне әрәм итеп бетерде, авылда бит күзгә алырлык кеше калмаган, бөтен кыз утырып кала инде!»

Пәрдәдән пәрдәгә, сәхифәдән сәхифәгә Галимәнең холкы ачыла, дөньяга карашы киңәя бара. Һәм инде без мондый затларның иртәме-соңмы үз хуҗаларына каршы килүен, аларны «фаш итүен» көтәбез. Әмма күп кенә әсәрләрдән үзгә буларак, «Дулкын эчендә» драмасындагы асрау үз мәсләген үзгәртми: үз хуҗасына тугры кала, хәтта аны кызылларның мыскыл-әрләреннән дә араларга омтыла. Үз чиратында Разыя да Галимәне асрау дип түбәнсетми, аны хөрмәт итә. Үзенең васыять сүзләрен дә ул тикмәгә генә бу кыздан башламый. «Кызым, — ди Разыя, Бануга мөрәҗәгать итеп, — үлсәм-нитсәм, үзе чыкмаса, Галимәне чыгарма!.. Үзе тугры, алты ел сынадым, үзе чыкмаса, үзе теләсә, барлыгың булса, туй итеп, кияүгә бир...» Разыя үзенең иң затлы киемнәрен Галимәгә бирергә куша. Асрауга карап, мондый сүзләрен дә әйтә: «Галимә, бик күп хезмәт иттең, рәхмәт! Мин үлгәч, туташны ташлама... Дөньялар тынычланганчы тор, җәме!»

### III

Әсәр юкка гына «Дулкын эчендә» дип аталмаган. Дулкын — татар сүз сәнгате өчен хас сурәт. Тарихка артык кереп китмичә, Дәрдемәнднең атаклы «Кораб» шигырен искә төшерү дә җитә. Биредә «тулкын» — табигать стихиясенең, язмышның мөһим бер элементы. Икенче яктан, драмадагы вакыйга-хәлләрнең реаль урыны һәм вакыты тарихның, җәмгыятьнең дәрья кебек шаулаган, дулкынланган вакытына туры килә. Бу чорда әйтерсең туфан калыккан, әйтерсең инсаннар бер-берсен этә-төртә Нух көймәсенә чабалар...

Г.Исхакый кешеләрнең, милләтләрнең, илләрнең язмышы, бер тәннең әгъзалары кебек үзара тыгыз бәйләнештә торуын аерым сурәтләр һәм детальләр ярдәмендә калку итеп күрсәтүгә ирешкән. Әсәрдә татар, урыс, төрек, маҗар, поляк кешеләре, картлар, яшьләр, бала-чагалар, ир-атлар, хатын-кызлар, төрле шөгыль һәм катлам вәкилләре катнаша. Болар бар да драма вакыйгаларына иҗтимагый-фәлсәфи яңгыраш бирә, тормыш асылын калкурак күрсәтүгә ярдәм итә.

Америка галиме Кэтрин Р.Култерның китабында (Портреты гомеопатических препаратов: Психофизический анализ избранных конституциональных типов. Т. 2 Пер. с англ. — М.: Атлас, 1996. — С.7) мондый юллар бар: «...История — явление циклическое, она постоянно воспроизводит те же самые

ситуации в изумительно аналогичной последовательности». Тарихта, кешелек яшәешендә тәмам кабатланулар, тулы тәңгәллекләр булмаса да, охшашлыклар, үзара якын вазгыятьләр булып тора.

«Дулкын эчендә» драмасында да андый күренешләр шактый: сугышның кайгы-бәхетсезлек китерүе, тол калу, ятимлек, теләк белән мөмкинлек каршылыгы һ.б. Болар бар да әсәрнең тарихи, инсани офыкларын киңәйтә. «Дулкын эчендә» — гасыр һәм җирлек кысалары белән генә чикләнмәгән, ә төрле чор һәм төрле кавем тамашачыларының күңелен кузгатырлык ядкәр.

Пьесада илләр, милләтләр, социаль катламнар арасындагы каршылыклар шәхесләр язмышында, күңел дөньясында гәүдәләнеш тапканнар. Урыс-төрек сугышы 11 яшьлек Шәүкәтне әнисез, сеңелсез калдырган, этисеннән, Ватаныннан аерган. Кулдан кулга күчеп йөргән бу бала, ниһаять (мөгаен, бәхетенәдер), Разыя йортына эләгә, азмы-күпме инсани шартларда яши башлый. Өй хуҗасы аңа үз баласы кебек карый. Әмма ничек кенә булмасын, фаҗигале вакыйгалар Шәүкәт күңелендә тирән җәрәхәт калдырган. Үзен көчле психик тетрәнүләргә китергән хәлне кеше, гадәттә, бер үк шәкелдә, бердәй сүзләр белән сөйли. Г.Исхакый да бу психологик хосусиятне төрек баласының сөйләмен бирүдә файдалана.

Персонажлар тормышына, аларның гамәл-холыкларына инкыйлаб дулкыннары, кызыллар, большевиклар эшчәнлеге дә көчле йогынты ясаган. Драмада боларга мөнәсәбәтле шактый гына аянычлы күренешләр, фаҗигале мәгълүматлар бар. Хәтта аларда билгеле бер тенденциозлык та күзгә ташлана. Әмма әсәрнең төп кыйммәте кемнәрнеңдер рәхимсезлеген, әхлаксызлыгын фаш итүдә түгел. Хикмәт җәмгыятьнең кырмыска оясы кебек кайнаган мизгелләрендә кешеләрнең инсаниятә ни дәрәҗәдә тугры калуларын, үзләренең ничек, ни рәвешле тотуларын күрсәтүдә. Шәхси язмышлар аркылы кеше психологиясенең, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең мөһим якларын гәүдәләндерүдә исә Г.Исхакый — чын художник. Тагын шунысы да бар: тарихта төрле исемнәр астында төрле көчләр сугышып торган, кан коелган. Ә бит аларның һәммәсе дә адәм балалары! Еш кына бер кавем вәкилләре. Акларга, кызылларга бүленеш, аларның үзара сугышулары — гайре табигый күренеш. Кан кою беркемгә дә бәхет, шатлык китерми. Кешеләр үзләренә бирелгән гомерне иминлектә, үзара аңлашып, сөеп-сөелеп үткәрергә тиешләр. Пьесаның асыл мәгънәсе нәкъ әнә шуннан гыйбарәт.

Мәгълүм булганча, Г.Исхакый большевикларның карашларын кабул итми, аларның хакимиятенә тискәре мөнәсәбәттә тора. Драмада бу сизелеп тора. Автор ышануынча, большевис-

тик режим — вакытлы күренеш. Разыя үлем алдыннан үзенең йортын, бакчасын, кибетен башкаларга васыять итеп калдыра. Билгеле ки, бу төр милекләрнең күпчелеге бераздан ияләреннән тартып алынды. Совет хакимиятенең гомере шактый озын булды.

Драмада төрле кавемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр дә гәүдәләнеш тапкан. Автор фикеренчә, кешеләр теләсә нинди шартларда да үзара аңлаша алалар. Разыя хастаханәдә ятучы полякларга ярдәм итә. Маһруй, Галимә «әстри», ягъни мажар әсире белән аңлашырга тырышалар. Пианинода оста итеп уйнавы белән бу зат татар хатын-кызларының «исләрен китерә».

Татарлар һәм төрекләр — үзара кардәш халык. Әсәрдә аларның дуслыгы, якынлыгы ачык гәүдәләнгән. Шәүкәтнең Разыя йортында урын табуы, Фәрит белән Бануның гаилә коруы, берсенең татар баласы өчен ата, икенчесенең төреккә ана булырга ризалыгы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Бануның баласын күздә тотып, Разыя Фәриткә болай ди: «Бу гөнаһсыз баланың атасы милләт юлында шәһит киткән, аны боектырма! Ата бул...» Ә инде Шәүкәт хакында ул кызына мондый теләкләрен әйтә: «Бу ятимнең анасы халкы өчен корбан булган, аңарга үгилек итмә, анасы кебек йомшак, җылы бул!»

Әсәрдә, гомумән, гаилә мәсьәләсенә җитди игътибар бирелә. Тол калган Разыяның да, Хәйрулланың да, аларның ятим калган балаларының да күңелләре китек. Разыя баласы өчен яши. Аның «үз тормышы юк». Шул хәлен ул төрлечә акларга тырыша. Кәримә белән әңгәмәсендә ул болай ди: «Үзең беләсең, шул балага дип бөтен гомеремне фида иттем. Үстерим, кеше ясыйм, дидем. Үз тормышым булмагач, аның тормышы янына сырылып, аның ирен угыл ясап, балаларын бала ясап торырмын дип уйлаган идем... Инде менә бу болай булды!.. Мин хәзер җеп очымны югалттым...» Бу хәлгә ул үзен гаепли. Хәйрулланың һәлакәтен дә авыр кичерә. «Мин сине, — ди ул,— балам өчен корбан иттем. Сине генә түгел, үземне дә, үземне дә корбан иттем... Бәхил бул! Рәнҗеп ятма!» Разыяның үлем алдыннан Бануга әйткән сүзләре кызы өчен генә түгел, меңәрләгән хатын-кызларга да киңәш, васыять булып яңгырый: «Кеше тугры килсә, кияүгә чык... Бер кайгыны ялгыз күтәргәнче, икәү бүлешерсез...» Кызы белән Фәритнең кушылачагын белгәч, Разыя болай дип тә өсти: «Тормышыгыз минеке кебек китек булмасын. Бер-берегезгә хыянәт итмәгез! Кызым, алдыңа килгән нигъмәтнең кадерен бел, иреңнең гаебен күрмә, сукыр бул! Дөнья булгач була... сукыр бул!»

Разыя язмышында, аның васыятьләрендә авторның да шәхси язмышы, йөрәк сагышлары, бәлкем, билгеле бер дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкандыр?! Г.Исхакый, үзе дә яшьли үк аерылып, кызы Сәгадәт белән очраша-аерылыша яшәгән зат.

Автор, башка күп кенә әсәрләрендәге кебек, «Дулкын эчендә» драмасында да вакыйга-хәлләрне, халыкның гореф-гадәтләре белән теге яки бу дәрәҗәдә бәйләнештә бирә. Әсәр Разыяга яучы килү белән башланып китә. Анда гаилә коруның зарурилыгы һәм җитдилеге, ике якның моңа мөнәсәбәте, йола таләпләрен саклап, оста гына бәян ителә. Икенче пәрдәдәге чәй эчү күренеше каһарманнарның холык-фигыльләрен, үзара мөнәсәбәтләрен яктырту белән тыгыз бәйләнештә бирелгән. Бер персонаж фикеренчә, самовар — «барымызның хәлфәсе, барымызның остазы». Икенче берсе аңа: «Чәй эчмәгән кыз ул татар кызымыни?!» — дип тә өстәп куя. Әсәрдә хәмер эчеп, исереп йөрү юк. «Кызыл солдатлар»ның соңгы пәрдәдә хәтта денатуратка кадәр эчеп, башбаштаклык кылулары гына моннан чыгарма булып тора.

Татар — кунакчыл халык. Бу әхлакый кагыйдәне Разыя да кызына җиткерә. «Кем булса да, — ди ул, — синең ишегеңне ачып, бусагаңны бастымы, мөселман кеше — кунак!» «Кунактан, чәй ясыйммы, дип сорыйлармыни?!»

Әсәрдә дингә ышану, мөселман дине йолаларын үтәү хуплана. Разыя мәрхүм әниләрен сагынган балаларны оҗмах күренешләрен сөйләп юата, үлгәннәр рухына догалар укый. «Коръән укыгач, — ди ул, — күңел тынычланып китә...»

Икенче берәүнең киемен киюне халык җитди үзгәрешкә юрый. Разыя Фәриткә киявенең киемнәрен киертә һәм, озак та үтми, Бәкернең үлгән хәбәре ишетелә. Бану Фәритне беренче күрүдә үк: «Әллә кай төше Бәкер кебек булып китте», — дигән сүзләрне әйтә. Бу — киемгә карап кына түгел, ә киләчәк язмышны күздә тотып әйтелгән сүзләр дә.

Драмадагы җыр-музыка күренешләре, бер яктан, персонажларның холык-фигыльләрен ачуга ярдәм итсә, икенче яктан, Ватаннан аерылган авторның сагышларын, җирсү халәтен дә күзалларга булыша.

Беренче пәрдә елның кыш фасылы белән башлана. Табигать вакытлыча йоклаган. Әмма алда язлар, җәйләр көтә. Бар да уяначак... Мондый пейзаж әсәрдәге вакыйгаларга да ишарә ясый: ул ничек булыр, нинди юнәлештә үсәр? Яучылау нәтиҗәсез бетә. Хәйрулла да борчылудан башы авыртып ята. Разыя да эчке газапларыннан нишләргә белми, туңа, башы авырта. Моңа мөнәсәбәттә тышта да җил улый, буран уйный, «морҗалар сызгыра, тәрәзә капкачлары шакылдый». Өченче пәрдәдә инде яз якынайган. Табигатьтәге уяну тормыш баскан хатын-кызларның да күңелен кузгата. Галимә җырлап җибәрә, «әстри» солдаты белән шаяртып ала. Аңа Маһруй да кушыла. Дүртенче пәрдә авырудан, баласыннан хәбәр килмәүдән тәмам йончыган Разыяны тасвирлау белән башлана. Ана күңеле шомлана, күңелсезлекне сизенә. Аның бу халәтен кышкы суыклык та-

гын да көчәйтә төшә. Кыскасы, Г.Исхакый драмасында пейзаж әсәрнең идея-эстетик аһәңенә, каһарманнарның рухи халәтенә нисбәтән бирелгән.

Драма жанрында сөйләм — төп һәм хәлиткеч чара. Бу закончалыкны автор тирәнтен аңлап эш итә. Ул сөйләмне вазгыять, холык-фигыль белән яраштырып бирергә омтыла. Гармун уйнап, яшьләр биегәндә, Маһруй бөтенләй канатланып китә. Аның сөйләме дә дәртле бию кебек ашкынулы: сүзләр, җөмләләр өзек-өзек; сөйләмдә, мантыйкый бәйләнештән бигрәк, экспрессив бәйләныш өстенлек итә; өндәү, сорау, риторик эндәш, кабатлау, әмер бер-берсен еш алыштырып тора: «Бану, алай түгел, борылганда күбәләк кебек зыр-р әйлән! Шулай, шулай! Зәйнәп, чеметтереп ал, чеметтереп! Бармак очың беләнрәк бас! Нәрсә мужик аты кебек аягыңны лапылдатасың? Шулай... түгел... Нәрсә, уклау йоткан кебек каткансың? Бөтен тәнеңне биет, һәммә әгъзаң биесен! Әй, юк ла. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла, кыз булгансыз! *(Гармунын куеп.)* Йә, уйнагыз әле! Менә ничек. *(Биергә тотына. Бер кат биегәннән соң.)* Йә, Бану, каршыма чык! *(Бану да каршы бии башлый.)* Шулай, шулай, башыңны күтәрә төш! Күкрәгеңне турырак тот, ник йөзеңне әвене янган урыс төсле ясыйсың, күләргә хәзер кебек тот, ата торган чәчәк төсле бул!..»

Хәйрулла — сабыр табигатьле, итагатьле, кешелекле зат. Аның бу сыйфатлары сөйләменең эчтәлегендә һәм яңгырашында чагылыш таба. Фронтка китәр алдыннан ул саубуллашыр өчен Разыя янына керә. Хатынның: «Рәнҗемә инде, Хәйрулла абзый, хаталык бездә», — диюенә ул: «Рәнҗүгә урыны юк», — дип, тыйнак кына җавап бирә.

Әйткәнебезчә, әсәрдә төрле милләт вәкилләре катнаша. Төрек сөйләме, мәсәлән, татар укучысына шактый дәрәҗәдә таныш. Автор Шәүкәтнең тәүге күренүдәге сүзләрен төрекчә китерә. Әмма бераздан аны татарлар белән татарча сөйләттерә башлый. Әтисе белән очрашкач, ул янә төрекчәгә мөрәҗәгать итә. Драмада «әстри» («маҗар») әсире белән сөйләш тә кызыклы бирелә. Галимә аның сөйләменнән хәтта төрки сүзләр дә табып ала.

Г.Исхакыйның бу драмасы да, әдипнең күп кенә башка әсәрләре кебек, теленең байлыгы, җанлылыгы белән сыйфатлана.

* * *

Беренче бөтендөнья сугышы һәм инкыйлаб еллары... Рәсәй тормышының, шул исәптән татар мәгыйшәтенең диңгез кебек кайнаган, адәм балаларының яшәешләре чәбәләнгән, хәтта билгеле бер дәрәҗәдә асты өскә килгән чоры. Бу дәвер меңәрләгән-меңәрләгән сәнгать әсәрләрендә гәүдәләнеш тапкан. Г.Ис-

хакый сугыш һәм инкыйлаб тематикасына татар драматургиясендә беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итә һәм хәзер дә актуальлеген җуймаган, сәнгати яктан тоныкланмаган әсәр тудыра. «Дулкын эчендә» драмасы гыйбрәтле каһарманнары, фаҗигале вакыйгалары, проблемалары белән бүгенге укучыны һәм тамашачыны да дулкынландырырлык. Әмма, кызганыч ки, бу әсәрнең татар сәхнәләрендә үзенә тиешле урынны әле һаман да таба алганы юк. Ә ул моңа тулысы белән лаек.

*1998*

## Уяну һәм асылга кайту

*(«Өйгә таба» повесте)*

Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каумем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

*Дәрдемәнд*

Ватан һәм кавем, ил һәм халык... Адәм балалары өчен бу төшенчәләрнең һәр икесе үтә дә газиз, үтә дә якын. Алар, Сиам игезәкләре кебек, бер-берсе белән үзара тыгыз мөнәсәбәттә. Әмма Вакыт галиҗәнапларының хәлиткеч мизгелләрендә инсан беренчелекне, өстенлекне кавемгә бирә. Ни өчен? Чөнки бу төшенчә Ананың изге сөте, буыннан буынга агучы мөкаддәс кан, нәсел-нәсәб, иман, туган тел, гореф-гадәт белән бәйләнешле. Әгәр дә кавем, халык саклана, яши икән, мәмләкәтне булдырырга, киләчәккә өмет бар. Ә инде Ватан — чагыштырмача үзгәрүчән, тарихи төшенчә. Яһүдләр бик күптәннән илсез-ватансыз калалар. Әмма бу кавем инкыйразга бирешми, яши. Нәтиҗәдә ике мең елдан соң булса да, үзенең Илен-Ватанын коруга ирешә. Кодрәтле хәлифәлекләр таралып, аларның төп халкы — гарәпләр — хәзерге вакытта ике дистәдән артык гарәп илендә гомер кичерә. Гомумән, мәмләкәтләрнең корылуы һәм таралуы, кавемнәрнең җир-мәкан алыштыруы тарихта тулып ята. Иң мөһиме — халыкның инкыйразга бирелмәве, аның үз асылын саклавы.

Евразиянең зур киңлекләрен биләгән безнең төрки әбибабаларыбыз да төрле мәмләкәтләр корганнар, төрле дәүләти фаҗигаләргә дучар булганнар, кайгысын да, шатлыгын да күргәннәр. Әмма шәҗәрәи туганлык, тел, гореф-гадәт, рухи мирас якынлыгы төрле төбәкләргә сибелгән төрки кавемнәрен үзара тартып тора, аларда чагыштырмача рухи бердәмлек тудыра, кар-

дәшлек тойгысын саклый. Шуңа күрә славян, угро-фин, иран-таҗик кавемнәренең бер-берсенә тартылуы кебек, төркиләрнең дә үзара туганлык мөнәсәбәтләрендә торулары табигый һәм мантыйкый күренеш. «Өйгә таба» повесте хакында фикер йөрткәндә дә нәкъ әнә шул хакыйкатьне истә тоту зарури.

## I

Бу рухтагы әсәрне язу оеткысы Г.Исхакый күңеленә илдә вакытта, беренче бөтендөнья сугышының тәүге елларында ук салынган була. Әмма автор бу уй-ниятен 1922 елда гына гамәлгә ашыруга ирешә. Берлинда иҗат ителгән «Өйгә таба» повесте, матди мөмкинлекләр булмау аркасында, шул ук калада 1938 елда гына дөнья күрә*. Гарәп хәрефләре белән язылган бу китап 1992 елда «Мирас» журналы битләрендә (№2. — 45–66 б.; № 3. — 36–56 б.) бүгенге укучыларга җиткерелде.

Әсәрдәге төп вакыйгалар 1915–1916 еллар аралыгына карый. Бу беренче бөтендөнья сугышының кызган чоры. Кавказ фронты. Инглизләр һәм французлар белән бер союзда булган Рәсәй гаскәрләре Төркиягә каршы сугыш хәрәкәтләре алып бара. Әрмәннәр ярдәме белән алар бу мәмләкәтнең төньяк-көнчыгыштагы шактый гына җирләрен, җөмләдән Эрзерум, Трабзон һәм башка калаларны басып ала. Күп кенә тораклар җимерелә, кешеләр кырыла, берничә дистә мең төрек балалары, хатын-кызлары йортсыз-җирсез кала, сукбайлыкка мәҗбүр ителә. Рәсәйнең хәрби җитәкчелеге, көньякка поход ясап, Багдад ягыннан хәрәкәт итүче инглиз гаскәрләре белән очрашуга хәзерләнә башлый. Алга таба исә Төркияне бүлгәләү, Истанбулны, бугазларны тартып алу, Айа Суфия мәчетенең башына хач кую бурычы куела. Моны гамәлгә ашыруда полковник Тимергалиев алаена (полкына) удар көч вазыйфасы йөкләнә. Әмма өлкән яшьтәге тәҗрибәле бу татар командиры, озак уйлану-кичерешләрдән соң, үз гаскәре белән Төркия ягына чыга һәм тугандаш төрек халкын һәм Якын Көнчыгыш төбәген коточкыч һәлакәттән, этносәяси афәттән саклап кала. Әсәр төп каһарманның фронт сызыгын үткән чакта алган ярасыннан үлүе белән тәгалләнә.

«Өйгә таба», гәрчә аны автор традиция нигезендә хикәя (хикәят) дип атаса да, үзенең күләме, төзелеше, табигате белән повесть жанрына туры килә. Аның үзәгендә полковник Тимергалиев образы, аның уй-кичерешләре, эш-гамәлләре. Автор бу каһарманның үткәне, гаиләсе хакында да кыска гына мәгълүмат биреп ала. Кызы Сөембикә дә, гәрчә эпизодик рәвештә

---

* Фуад Туктаров бу китапны төрек теленә тәрҗемә итәргә ниятли. Әмма, үлеме аркасында (19.12.1938), ул бу эшен гамәлгә ашыра алмый.

булса да, әсәрдә катнаша. Полковник күп кенә кешеләр белән очраша, төрле мөнәсәбәтләргә керә. Әсәр үзенең вакыйга-хәлләре, сюжет корылышы, образларны, чынбарлыкны гәүдәләндерүе белән хәтта роман жанрына да якыная төшкән. Шулай да аны повесть дип атау дөресрәк булыр.

«Өйгә таба» — әдәби әсәр. Әмма аның нигезенә мөһим тарихи вакыйгалар, күп кенә реаль факт-мәгълүматлар салынган.

Мәгълүм булганча, Г.Исхакый — әдәби иҗат белән генә шөгыльләнүче коеп куйган әдип кенә түгел, ә җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, сәясәтче һәм көчле публицист та. Ул илдә вакытта да, чит мәмләкәтләрдә яшәгәндә дә һәрчак иҗтимагыйсәяси тормышның үзәгендә кайнады, күренекле кешеләр белән аралашты. Алар арасында М.Горький, Бодуэн де Куртенэ, Й.Акчура, К.Ворошилов, Ю.Пилсудский, А.Керенский һәм башка билгеле затлар бар. Г.Исхакыйның берничә ел Рәсәй башкаласы Петербургта яшәве дә аның иҗтимагый-сәяси һәм интеллектуаль-рухи үсешенә зур йогынты ясады; мәркәзи гәзитләрнең мөхәррире булу язучыга күптөрле мәгълүматлар тупларга мөмкинлек бирде. Болар бар да аның әдип буларак үсешен, фикерләү офыкларының киңәюен, эстетик карашларының үткенәюен тәэмин итте.

Әйткәнебезчә, «Өйгә таба» 1922 елда язып тәмамланган. Димәк, инде автор бу вакытка Кытай, Япония, Чехия, Финляндия, Франция, Германиядә булуга ирешкән, зиһененә гаҗәеп күптөрле мәгълүматлар туплаган. Әдип күңеле ничәмә-ничә уй-кичерешләр өермәсен уздырмаган! «Өйгә таба» да нәкъ әнә шуларның җанлы гәүдәләнеше рәвешендә мәйданга килгән. Аның өчен нечкә психологизм белән сугарылган тирән тарихи тоем хас. Әсәр чынбарлыктагы вакыйга-хәлләрне, чор атмосферасын, сәяси тенденцияләрне күзалларга ярдәм итә, укучының күңел дөньясын кузгата, уйландыра, тарихка, тормышка, үзенә башка күз белән карарга этәрә.

## II

Повестьның төп каһарманы Мирхәйдәр Батыргәрәй углы Тимергалиев — шактый тулы эшләнгән образ. Махсус әйтелмәсә дә, без аның хәлле гаиләдән чыгуын, Оренбург төбәге, Дим буйлары белән бәйләнешле икәнлеген, хәрби белем алуын күзаллыйбыз. Ул «Генераль штаб»та да укыган. Хатыны Нәфисә күптән инде вафат. Сугыш кырында бердәнбер улы батырларча һәлак була. Оренбургта яшәүче кызы, 17–18 яшьлек Сөембикә, сугыш башлангач, медсестралар (шәфкать туташлары) хәзерләү курсларын тәмамлап, үз ирке белән фронтка китә һәм үз-үзен аямыйча, яралыларга ярдәм күрсәтә, милли-рухи яктан да аларның күңелләрен күтәрә.

Тимергалиев урыс, француз, алман телләрен яхшы белә. Татарча да укый-яза, иркен сөйләшә. Динен дә онытмаган. Солдатлар белән мәчеттә намаз укуы да телгә алына. Ул 28 ел буе хәрби хезмәттә. Әсәрдән аның Төркестанны яулап алуда, Порт-Артур сугышларында катнашуы, кыюлыгы, батырлыгы өчен күпсанлы бүләкләргә лаек булуы аңлашыла.

Повестьта шушындый бер эпизод бар: полковник Тимергалиевне Тифлистагы штаб начальнигына чакыралар. Аны «зур мыеклы казачий генерал» каршы ала. Күрешәләр. Баксаң, бу Тимергалиев белән Порт-Артурда бергә хезмәт иткән икән. Алга таба әсәрдә мондый юллар килә: «Тимергали хәтерләде... Әйе, Тимергали ул вакытта ук капитан иде, хәзер дә әле һаман полковник кына. Бу урыс менә ул вакытта малай гына иде, хәзер моның башлыгы булган. Аның күзе алдыннан бөтен Порт-Артур сугышының манзаралары (күренешләре) кичте. Бу, хәзерге генералның урынын ташлап качып, Тимергалине берүзен калдыруын, Тимергалинең бик зур каһарманлык берлә, әллә никадәр гаскәрен югалтып, үзе җәрәхәтләнеп кенә вазгыятьне (хәлне; ситуацияне) саклый алуын, моның өчен үзенең рәхмәт алуын, бу казачийның Георгий медале алуын хәтерләде, күңеленнән бер күңелсез ачу акты».

Бу уңай белән шунысын да искәртү урынлы булыр: татарлар, Рәсәйнең иминлеген саклап, элек тә, совет чорында да фидакарьләрчә көрәшкәннәр. Әмма аларның батырлыгын күрмәмешкә салышу яисә киметеп күрсәтү очраклары тарихта тулып ята. Рейхстагка Җиңү байрагын тәүге кадаучы Гази Заһитовның башка кешеләр белән алыштырылуы — үзе генә дә моның ачык мисалы. Күп кенә талантлы, батыр татар офицерларына генераллык һәм адмираллык юлларының рәсми ябылуын без инде хәзер шактый ачык беләбез.

Тимергалиев — сәләтле, кыю, җаваплы, белемле командир. Әмма татар булганы өчен аңа полковниклык дәрәҗәсенә ирешү дә җинел булмагандыр. Моның өчен икеләтә тырышырга, өчләтә көч түгәргә туры килгәндер. Әсәрдә полковник Тимергалиев таләпчән, кайгыртучан, тәҗрибәле, принципиаль табигатьле җитәкче буларак күзаллана. Аны генераллар да танырга, ихтирам итәргә мәҗбүр. Тимергалиев кул астында ун меңгә якын атлы гаскәр. Алар, нигездә, төрки, мөселман кешеләре. Шактые татар. Полковник үз гаскәре, аның хәзерлеге, рухи халәте белән даими кызыксынып тора.

Өч дистә елга якын хәрби хезмәттә булу Тимергалиев табигатенә башкаручанлык, әмерне кабул итү һәм үтәү кебек сыйфатларны сеңдергән. Әсәрдәге вакыйгаларга кадәр аның шәхесе, милли җаны ничектер томаланып, басылып, йокымсырап торган кебек. Ул командирлык вазыйфасын башкаручы рәсми зат рәвешендә күзаллана. Хәрби антка, Ватанга, әмер-

приказга тугрылык — аның өчен бәхәссез, катгый канун. Г.Исхакыйның ачышы, яңалыгы (ягъни новаторлыгы) шунда: ул Тимергалиев кебек затның милли җаны ничек итеп, нинди шартларда уянуын, актив көчкә әверелүен, вазыйфа иясенең (бу очракта — гаскәр башлыгының) шәхескә әверелүен үтемле, ышандырырлык итеп гәүдәләндерүгә ирешкән. Беренче карашка полковникның Төркия ягына чыгуы илгә, хәрби антка хыянәт рәвешендә кабул ителергә мөмкин. Әмма автор бу хәлиткеч адымның эчке һәм тышкы сәбәпләрен, мантыйк-логикасын әдәби-психологик яктан шундый итеп тасвирлый ки, монда инде үзгә заруият, башкача эш-гамәл күрми башлыйсың, проблеманың нәкъ менә шул рәвешле хәл ителеше белән ризалашырга мәҗбүр буласың.

Башка илләрне һәм җирләрне яулап алу, Рәсәйне киңәйтү, бүтән халыкларны буйсындыру — урыс хакимиятенең гасырдан гасырга килгән традицион сәясәте. Татар мәмләкәтләренең яулап алынуы бу процессны тагын да тизләтте. Бераздан Кавказ, Урта Азия урыс империясенең корбаннарына әйләнделәр.

Тарихта күпсанлы урыс-төрек сугышларының булуы мәгълүм. Бу да, иң беренче чиратта, Рәсәй хакимиятенең империячел сәясәте белән аңлатыла. Чөнки үзен «Өченче Рим», Византиянең варисы дип игълан иткән Мәскәү Кече Азияне, Истанбулны яулап алуны, андагы бугазларны үзенә буйсындыруны изге максат итеп куя. Петр I нең «Васыятьнамә»сендә (1725) акка кара белән болай язылган: «*Русия дәүләтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен аның башкаласы Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга күчерү шарт. Кичекми һәм ялгышмый эш итеп, Истанбулның көнбатыш җирләренә ия булу кирәк. Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньядагы илаһи патша булачак*» (Казан утлары, 1992. — № 1. — 167–168 б.). Петр I дән соң Рәсәй белән төрле патшалар төрлечә идарә итте. Әмма аларның Төркиягә, Истанбулга булган мөнәсәбәте һич тә үзгәрмәде: Әби патша да, император Александр һәм Николай да Петр I нең яшерен васыятенә тугрылыклы калдылар. Беренче бөтендөнья сугышында Рәсәй хакимияте Төркияне бүлгәләүне, Истанбулны буйсындыруны төп максатларыннан берсе итеп куйды. Г.Исхакый да бу сәясәтне яхшы аңлый. Тимергалиев катнашкан югары дәрәҗәдәге хәрби киңәшмә рәисе авызыннан мондый сүзләр яңгырый: «Алдымызда Русиянең иң зур тарихи бурычы тора. Бөек Петр заманасыннан бирелеп тә, үтәлмәгән милли, дини вазыйфасы тора... Төркия тәкъсим ителергә (бүленергә) карар ителде... Яшәсен император, яшәсен аның каһарман гаскәре, саклансын Истанбулда Русиянең ике башлы кара кошлы байрагы! Ялтырасын бөтен дөньяга Айа Суфияның мөкатдәс сали-

бы (хачы)!» Генералның бу сүзләрен «бөтен руслар» кул чабып хуплый. Әмма Тимергалиев тешен кысып булса да түзә, сер бирми.

Татар полковнигы, әкренлек белән булса да, бу сугышның мәгънәсезлеген, халыкларны кыруга, илләрне юк итүгә юнәлтелгәнлеген аңлый башлый. Җимерелгән авыл-калалар, вакытсыз гомере киселгән кешеләр, йортсыз-нисез калып, сукбайлыкка, ачлыкка дучар ителгән төрек балалары, аларны якларга ниятләүчеләрне эт урынына сүгүләр — болар да полковникның күңелен кузгата, вөҗдан-намусын кимерә. Солдатларга диген азык-төлекне урлау, үзләштерү, меңәрләгән инсаннарның бәхетсезлегеннән, кан түгүеннән аерым шәхесләрнең табыш алуы гадәти күренешкә әйләнә. Башкалада сарай, Распутин башбаштаклыклары, мәкер, хыянәт. Тифлис рестораннары һәм салоннары исерек урыс офицерлары, генераллар, фахишәләр белән мыжгып тора. Рәсәйнең союзниклары булган инглиз һәм француз вәкилләре үзләренең мәнфәгатьләре өчен урыс генералларын канлы сугышка өстереп торалар. Шунысы аеруча аяныччы: җирле халыкны, мөселманнарны төрлечә рәнҗетү, куркыту һәр адымда күзәтелә. Рәсәйдә сугышны гаепләү хәрәкәте киң колач ала. Төркиләрдә (автор җыйнама исем буларак та төрек атамасын куллана) Төркиягә каршы сугышны туктатырга чакыру да көчәя. Бу хәл Тимергалиев җитәкчелек иткән полкта да күзәтелә. Гаскәри мулла Ибраһим солдатларның уй-фикерләрен гомумиләштереп, полковникка болай ди: «...Бу эш шәригатьчә гафу ителмәслек зур бер гөнаһ, ... көфер(лек). Милләтчелек ягыннан, шөбһәсез, милли хыянәт. Илемезгә, көнемезгә, тарихымызга каршы хыянәт».

Бу төр күренешләр, вакыйга-хәлләр Тимергалиевнең җанын уяталар, дөньяга, үзенең эш-гамәленә, яшәү мәгънәсенә икенче төрле карарга мәҗбүр итәләр. «Җитте! — ди ул үз-үзенә. — Үткәннәр үтте, кичкәннәр кичте, бүген Мирхәйдәр Тимергалиевнең тормышында бер тыныш куелды, аның юлы борылды. Моңганчыга кадәр барганының тәмам тискәренә борылды. Ул үзенең урыны кая икәнлеген бүген ачык белде, үзенең юлын тапты. Инде сөйлисе, уйлыйсы калмады, инде эшлисе, гамәлгә куясы гына калды. Ул шул юл табуыннан шулкадәр кәефләнгән иде ки, үз-үзен яңа туган биләүсәдәге бала кебек хис итә иде».

Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Алмания һәм Австро-Венгрия ягыннан Рәсәйгә каршы фронтка җибәрелгән чехларның һәм словакларның үзләренә кардәш булган урысларга күпләп әсир төшүе мәгълүм. Бу факт та Тимергалиев аңына билгеле бер йогынты ясый.

Милли җаны кузгалган полковник үзен борчыган мәсьәләләргә тарихтан да җаваплар эзли. Аның фикеренчә, төркиләрнең көчсезләнүендә, таралуында бердәмлек булмау да зур роль

уйнаган. Тимергалиев Аксак Тимернең кодрәтле гаскәри икәнен таный. Әмма ул бу затның үз кардәшләре — төркиләр яшәгән Алтын Урдага һөҗүмен гаепли. Бу уңай белән автор болай яза: «Каһарман Тимер, Идел буена барып, Алтын Урданы җимермәгән булса, бәлки, бу моңлы «Ашказар» көе, еглый, сыкрый торган «Тәфкилеф» көе тумаган булыр иде... Бәлки, ике башлы кара кошның канатлары да бу кадәр озынга, Кавказ тауларына кадәр, Тимернең үзенең кабере яткан алтын Сәмәркандка — Төркестанга кадәр сузылмаган булыр иде. Бәлки, ул хәзерге кебек Дөҗлә (Тигр елгасы), Фәрат (Евфрат) буйларына таба тешләрен ыржайтмаган булыр иде. Истанбулга, бугазларга кадәр ерткыч теше арасында күтәргән тәресен китерергә көчләнмәгән булыр иде...»

Әсәрнең берничә урынында Казан ханлыгы һәлакәтенә үзеннән зур өлеш керткән сатлык җан Шаһгали телгә алына. Тимергалиев үзенең моңа кадәрге эш-гамәлләрендә бу затка охшаш яклар күрә... Алга таба шаһгалилек юлыннан баш тарта.

Полковникның рухи уянуында, күңел каршылыкларын җиңүендә һәм хәлиткеч адым ясавында янә бер мөһим сәбәп бар. Ул да булса — Фәридә. Аның әнисе — татар, әтисе — азәрбайҗан... Зыялы, милли рухлы гаиләдә үсә. 22—23 яшьләрдәге бу гүзәл кыз Петербург университетының әдәбият-тарих факультетында укый. Җырга, моңга гашыйк. Кыз «карт полковникта үзе уйлаган бер төрек каһарманын таба», аңа күңеле төшә. Әчке сизгерлек белән Тимергалиевнең уй-ниятләрен белеп ала, шәфкать туташы булып полковник гаскәрендә армыйталмый эшли, аның рухи таянычына әверелә. Әчке якынлык аларның икесенә дә кыюлык, тәвәккәллек бирә. Бу уңай белән автор болай ди: «Фәридәнең калуы хәл ителде. Куркынычлы качу планнары аңарга полковник булганда һични (түгел) кебек күренде. Тимергалигә дә Фәридә кебек пакь, саф бер фәрештә янында торганда туп та, мылтык та берни түгел кебек хис ителде».

Г.Исхакый хатын-кыз образларын тудыруның остасы. Фәридә алар янында мөхтәрәм урыннарның берсен алып тора. Шуңа күрә дә әсәрнең ахыргы юллары гүзәл кыяфәтле, милли җанлы, актив табигатьле бу кызны тасвирлау белән тәгалләнәдер. Автор Фәридәдә милли бәйсезлек, бәхет өчен көрәшнең ышанычлы каһарманын күрә.

Төрк, мөселман кавемнәрен афәттән саклау юлында Тимергалиев үзен корбан итә. Әмма аның бу фидакарьлеге безнең тормышта һәм әдәбиятта тиешле яңгыраш таба алмады. Милли бәйсезлек тарафдарлары басмачылар, дошманнар дип игълан ителде. Төрле-төрле татбригадалар, интернациональ көчләр оештырылды, аларның эш-гамәлләре макталды, җырларда җырланды...

## III

«Өйгә таба» — тыгыз тукымалы, вакыйга-хәлләргә бай әсәр. Анда публицистик элементлар да, тарихи белешмәләр һәм сәяси мәгълүматлар да шактый. Әмма аларның күпчелеге полковник Тимергалиевнең язмышын сурәтләү, аның эш-гамәле, дөньяга карашы аша бирелә.

Повестьның тәүге өлешенә игътибар итик. Төн уртасы. Тимергалиев һич тә йоклый алмый. Аны уйлар өермәсе чорнап алган. «Баш дулаган тегермән кебек туктамады, әйләнде, яңа фикерләрне, яңа уйларны он ясамакчы булды. Кирәкмәгәннәрен «пуф» иттереп очырмакчы булды. Полковникның күз алдыннан күренә һәм күренми торган әйберләр бер-бер артлы узып тора. Туптан яртылаш өзелгән мәчет манарасы аңа кулсыз җиң кебек күренә. Ату тавышлары яңгырый. Полковник «безнекеләр дошман берлә атышалар» димәкче була. Әмма аның күңеленә «безнекеләр кем соң? Дошман (ягъни төрекләр) кем соң?» дигән сораулар килә. Бераздан Тимергалиев саташулы йокыга китә. Аның күңеленә зәгыйфь кызы, сугышта үлгән улы, вафат булган хатыны килеп баса. Соңгысының кулы мәчет манарасы кебек киселгән... «Аның күз алдында әллә никадәр киселгән куллар, аяклар, мәсхәрә ителгән төрек хатыннары, кызлары үтә... Ул сискәнеп уянды». Күрәсез: бу — күңел диалектикасын, рухи халәтне чын художникларча, Толстой рухында бирү. Әсәрдә мондый урыннар алга таба да еш очрап тора.

Г.Исхакыйның күпчелек әсәрләрендәге кебек, бу повестенда да музыка, сәнгать мөһим идея-эстетик вазыйфа башкара. Адвокат Арысланның кызлары Зәйнәп белән Фәридәнең пианинода уйнап-җырлаулары полковникны тәмам «исертә». «Тимер маршы» исә «үзенең куәте, көче берлә Тимергалинең астын-өскә китерә». «Музыка, — ди автор, — полковник берлә бу гаилә арасындагы пәрдәләрне ачып, арадагы ятлыкларны бетерде». Әдип татар моңнарында халык язмышын тоя.

Адвокат Арысланнар гаиләсе Тимергалиевне әдәби-музыкаль кичәгә чакыра. Анда төрек җырлары, биюләре башкарыла. С.Рәмиевнең «Татар йоклый» шигырен тыңлаганда, полковник үзенә ишарә ясалган кебек тоя. Ә инде Тукайның «Соңгы азан! Моңлы азан... Китте Казан һәм Әстерхан...» юллары Тимергалиевнең болай да тынгысыз күңелен тагын да актара төшә.

Урыс генералларыннан берсе полковник Тимергалиевкә Мәскәүдә чыккан бер татар гәзитен бирә. «Менә карагыз әле әнә шул мәкаләне!.. Сугышка каршы булырга кирәк, әллә ничә җирдән җыелып-җыелып укыган гаскәриләрдән алдылар. Шуны, зинһар, укып, фикереңезне сөйләп, мөмкин булса, тәрҗемә иттереп җибәреңез әле; сездә бит анда тел белә торган әфисәрләр бар». «Бәйрәм корбансыз булмый, корбан бәйрәмсез бул-

мый» дип исемләнгән бу мәкалә әсәр тукымасында, төп каһарманның һәм башка бик күп кешеләрнең язмышында мөһим роль уйный. Бу материал полковникта йөрәк әрнүләре тудыра. Адвокат Арысланның кызы Зәйнәп бу мәкалә хакында болай ди: «Дөрес бит, без бит һәммәмез урыс өмәсенә корбан булучылар... Бөтен халкымыз, бөтен зыялымыз, бөтен гаскәремез урыс өмәсенә йөри». Кызның Одесса университетында белем алучы, социалист идеяләренә теләктәшлек белдерүче абыйсы Ибраһим исә мәкалә белән бик үк риза түгел. «Урыс өмәсе дигән сүз дөрес түгел, — ди ул. — Урысның пролетариаты үзе дә өмәгә йөри. Урысның буржуа өмәсенә дияргә кирәк иде».

Әмма татар гәзитендәге материал күпчелек персонажлар тарафыннан хуплана. Андагы «рус өмәчеләре», «халкымызны кисәр өчен ясалган рус кулындагы балта саплары» кебек төшенчәләр Тимергалиевнең рухи борылышында, солдатларның уянуында катализатор вазыйфасын да башкаралар.

Кызының язмышы турында борчылып, полковник Фәридәгә болай ди: «Яшь кеше бит, белеп булмый, нинди агым артыннан ага торгандыр... Үзем рус өмәсенә бик күп йөрдем. Кызым алай булмасын иде... Углым да шул өмәгә әрәм китте... Менә үзеңез төсле булсын иде».

«Бәйрәм корбансыз булмый...» мәкаләсе, мөгаен, Г.Исхакыйның үзенекедер. Нәкъ шушы чорда аның Мәскәүдә чыга торган «Сүз» гәзитендә (13 декабрь, 1915 — сентябрь, 1916) сугышка каршы язылган мәкаләләре басыла. Шуларның берсе генерал Куропаткин кулына эләгә. Нәтиҗәдә гәзит ябыла, Г.Исхакыйны Мәскәүдә яшәү мөмкинлегеннән мәхрүм итәләр (Акыш Г. Гаяз Исхакый: Идел-Урал милли азатлык хәрәкәтенең бөек юлбашчысы // Казан утлары, 1994. — № 2. — 156 б.).

«Өйгә таба» әсәрендә автор кызыклы гына детальләр, сурәтләр куллана. Башкомандующий зур киңәшмә билгели. Кешеләр җыела. Әмма генерал юк та юк. Бераздан моның сәбәбе ачыклана: баксаң, командующийның Мубсик исемле эте авырып киткән икән. Шуңа доктор чакыртып йөргәннәр. Күрәсең, генерал өчен миллионлаган кешенең язмышына караганда, этенең хәле мөһимрәк.

Полковникның уй-ниятләрен белмәгән капитан Фәхрелисламов, төрекләргә каршы сугышта катнашырга теләмичә, ике атналык ял алырга уйлый. Тимергалиев аның бу адымын куркаклык дип атый, капитанның гамәлен дошманыннан башын комга тыгып котылырга теләгән тәвә кошы белән чагыштыра.

«Өйгә таба» повестенда, әдипнең мөһаҗәраттә язылган кайбер башка әсәрләрендәге кебек, төрек сүзләре, гыйбарәләре очрый (әвәт–әйе, төрән–поезд...). Аерым алынмалар һәм атамалар да төрек телендәгечә бирелә (комитә–комитет, Ләһстан–Польша, Парис–Париж...).

* * *

Г.Исхакыйның бөтен иҗаты, күпкырлы эшчәнлеге иң беренче чиратта татар мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүгә, аны бәхетле, ирекле итүгә юнәлтелгән иде. Әмма шуның белән бергә ул гомере буе төрки халыкларының бердәмлеге, иминлеге, сәгадәтле яшәеше өчен дә көрәште. Төркиягә ихтирамы аның аеруча көчле иде. Үз чиратында төрек халкы да әдипне игътибардан читтә калдырмады: кыен вакытларында үзенә сыендырды. Полковник Тимергалиев соңгы сулышын Төркия туфрагында ала. Г.Исхакый да, үз каһарманы кебек, бу илне үзенең мәңгелек йорты итте.

Әсәрнең «Өйгә таба» дип исемләнүе дә юкка гына түгел. Төрек меңбашы, чикне үтеп, Төркия ягына чыккан тимергалиевчеләргә мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Кардәшләр! Мин сезне һәммәгезне... ана йортка ирешүегез берлә котлыйм! Бөтен тарафтан дошман сарган бу йорт төрек иледер. Бу безнең Ватанымыз булган кебек, сезнең дә туган йортыңыздыр... Безнең берлә бергә, безнең караңгы көннәремезне бүлешергә килгән сез кардәшләремезгә безнең бәхетле көннәремездә дә илемез, йортымыз ачыктыр!..» Әмма автор Төркияне Рәсәй империясеннән килгән төрк-татар кавемнәренең ахыргы тукталышы дип түгел, ә өйгә таба бару юлында туктап алу, хәл җыю урыны итеп кенә карый. Аның максаты — Төркестан, Кырым, Кавказ, Идел-Урал төбәкләрен, Төркия кебек хөр, бәйсез итеп күрү.

Әсәрнең исеме икенче бер символик мәгънәгә дә ия. «Өйгә таба» хәрәкәт итү ул — урын-җир күчеше, гадәти бару-кайту гына түгел. Полковник Тимергалиев шактый гомер кичергәннән, акыл, тәҗрибә туплаганнан соң гына рухи яктан уяна, хакыйкатькә, үзенең тормышында «мөкаддәс кан» һәм «изге сөт» белән кергән милли асылына кайта. Тәүбә кылуы, фидакари гамәле, Җәлилләр кебек елмаеп үлүе белән укучыда хөрмәт, теләктәшлек уята. Шуңа күрә әсәрне «Уяну һәм асылга кайту» дип тә исемләргә мөмкин булыр иде.

*1998*

## Аянычлы һәм гыйбрәтле тамаша

*(«Җан Баевич» комедиясе)*

### I

Күп гасырлык урыс-татар мөнәсәбәтләрендә гыйбрәтле сәхифәләр бихисап. Әгәр дә борынгырак чорда татарлашу, аның телен, гореф-гадәтләрен өйрәнү өстенлек итсә, татар бәйсезлеген җуйгач, моның киресе башлана. Телдән, диннән язу (ягъ-

ни мөртәтләшү) аша урыслашып китү мисаллары тарихыбызда исәпсез-хисапсыз. Юсуповлар, Державин, Аксаков, Карамзин, Куприн һәм башкалар — моның «аяклы дәлиле».

Шунысын онытырга ярамый: чукындыру, урыслаштыру — Рәсәй империясенең гасырлар буена сузылган рәсми сәясәте. Шуңа күрә аны гамәлгә ашыруда мәҗбүри, репрессив, идеологик чаралар, икенче төрле әйткәндә, камчы һәм кәнфит белән «сыйлау» ысулы дәвамлы рәвештә кулланылып килде. Шуның нәтиҗәсендә империячел көчләр, христиан дине белән берлектә, шактый гына уңышларга да ирештеләр. XVI йөзләрдә сан ягыннан үзара тигез булган татар һәм урыс кавемнәре бүгенге көндә бер-берсеннән күп мәртәбәгә аерылалар. Совет чорында, аеруча соңгы берничә дистә елда катнаш никахларның күбәюе урысның сан ягыннан арту процессын тагын да көчәйтте.

Урыслашуда, диннән йөз чөерүдә элек-электән үк аеруча татарның өстен катламы — морзалар активлык күрсәтте. Аларның шактые Рәсәйдә хакимлек итүче төп кавем составына кереп эреде. Бер өлеше, гәрчә ул татар булып калса да, үз кавеменең мәнфәгатьләреннән читләште, аның теленә, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә, тарихына түбәнсетеп карады, «өлкән туган»ны үзенә өлге итте. Урыста «дурной пример заразителен» дигән гыйбарә бар. Күп кенә морзаларның, зыялыларның төп кавемнән аерылып, каста кебек яшәве, урыс тормышын кыйбла итүе, үз милләтенә скептик мөнәсәбәте гавамның аерым вәкилләрендә кызыксыну, алар кебек булырга омтылу теләген дә тудырды. Мондый иҗтимагый-социаль омтылыш кешенең психологиясе өчен дә тәмам чит түгел. Чөнки шактый гына инсаннарның табигатендә теге яки бу дәрәҗәдә мин-минлек, үзен башкалардан өстен яисә аерып кую, тәкәбберлек, һавалану кебек сыйфатлар була. Яралгы, йокымсыраган хәлдәге, карындагы бала рәвешендәге бу төр сыйфатларның билгеле бер шартларда хәрәкәткә килүе, эчке дөньядан тышка чыгуы табигый күренеш.

Иҗатының тәүге сәхифәләрендә үк милләт мәнфәгатьләрен, кавем язмышын үзәккә куйган Г.Исхакый бөтен гомере буе татарны инкыйраз афәтеннән саклау өчен көрәште. Гаять тә мөһим мәүзуг-проблемага язылган «Җан Баевич» драмасы (1923) — шуның ачык бер мисалы. Бу әсәрен ул мөһаҗәрәтнең тәүге елларында Берлинда иҗат итә. Аның беренче басмасы да шул калада 1939 елда дөнья күрә. Идел-йортта исә «Җан Баевич» язылуына 70 еллап вакыт үткәннән соң гына нәшер ителде (Гаяз Исхакый. Зиндан: Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 587–635 б.).

Г.Исхакыйның бу әсәре чит илләрдәге милләттәшләребез арасында әүвәл кулъязма, аннан басма рәвештә киң тарала.

Аерым хәбәрләргә караганда, ул мөһаҗәраттәге татар матбугатында да дөнья күргән булса кирәк. «Җан Баевич» 30 нчы елларда ук Ерак Шәрыкта, Финляндиядә сәхнәләштерелә дә. Мәсәлән, Харбин шәһәрендә аны сәхнәгә күренекле әдип, журналист Хөсәен Габдүш (1901–1944) куя. Ул үзе төп рольне дә башкара. Бу спектакльне 30 нчы елларның урталарында Кытайда, Япониядә булган Г.Исхакый үзе дә карый һәм тамашага, актерларның уенына югары бәя бирә. Аның спектакльдә катнашучылар белән бергәләп төшкән рәсеме дә бар.

«Җан Баевич», гәрчә ул 1923 елда Берлинда төгәлләнсә дә, автор күңелендә бераз элегрәк бөреләнә, оеша башлаган булса кирәк. Чөнки анда әле, аерым детальләрне исәпкә алмаганда, әдипнең чит илдә яшәве, ят вазгыять артык сизелми.

## II

***«Җан Баевич»*** — дүрт пәрдәлек комедия. Әсәрнең эчтәлегеннән андагы вакыйгаларның беренче бөтендөнья сугышы алды елларында Казан шәһәрендә баруы аңлашыла. «Алат юлы», «Каравай авылы», Тукайның «Туган тел»е, балалар мәҗмугасын уку, мәдрәсә сабакларын өйрәнү кебек хосусый деталькүренешләр дә комедиянең вакыт-җирлеген нәкъ шушы чорга һәм урынга нисбәт итү мөмкинчелеген бирәләр. Сугыш бару, инкыйлаб зилзиләләре әсәрдә әле тоемланмый. Комедиянең кыскача сюжеты түбәндәгедән гыйбарәт.

Шакирҗан Миңлебай угылы — авылдан шәһәргә килеп яши башлаган гадәти бер татар кешесе. Ул сәүдә белән шөгыльләнә. Бу затның Сәхипҗамал исемле хатыны, 9–11 яшьләрендәге Халидә исемле кызы, Әнвәр атлы улы бар. Бөтен яктан әйбәт кенә гаилә. Анда милли, дини, инсани вазгыять хөкем сөрә. Милли китап, гәзит-журнал уку гадәттә.

Беренче пәрдәдән соң ике еллап вакыт үткән. Шакирҗанның сәүдә эшләре бик нык алга китә. Ул гадәттән тыш байый. Моны йорт, андагы җиһазлар да ачык күрсәтеп тора. Тормышындагы кискен үзгәреш төп каһарманның күңеленә шайтани уйлар да кертә. Ул гаиләсен, хезмәтчеләрен һәм, гомумән, татар халкын артталыкта, тәрбиясезлектә, наданлыкта, аның сүзләре белән әйткәндә, «необразованныйлык»та гаепли. Үзен, ягъни Шакирҗан Миңлебай улын Җан Баевич, «князь» дип игълан итә. Балалары белән хатынын куып җибәрә, яңа «дуслар», марҗалар таба. Шуларның берсе — «графиня» белән яши дә башлый. Җан Баевичның йорты «заманча» — урысча яшәү, кәефсафа кору, «тәрәкъкыйпәрвәрлек» урынына әверелә. «Князь» һаваланганнан-һавалана бара; байлыгына кызыгып, салпыга салам кыстыручылар күбәя һәм, ахыр чиктә, ул бөлә. Марҗасы акча даулый. «Юк», — дигәч, мондый сүзләр ишетә: «Акчаң

җитәрлек булмагач, ни дип син графиняларга өйләнәсең? Өйләнер идең үзең кебек бер татаркага!» ... Җан Баевич йортына, бурычларын кайтаруны таләп итеп, төрле кешеләр агыла башлыйлар. Алар «князь»не сүгәләр, талыйлар, хәтта кыйныйлар да. Хаим Соломонович дигән бер яһүд, судебный пристав белән килеп, Җан Баевичның әйберләрен юк кына бәягә яздыра. Шунда «князь»нең әти-әнисе килеп керә. Миңлебай абзый улын «мәлгунь»лектә, «илне, көнне мәсхәрә итеп йөрүдә», «оятсыз»лыкта гаепләп сүгә, таягы белән кыйный башлый. Шакирҗан нишләргә белми. Шунда йортка тәртип саклаучылар (бер околоточный, ике городовой) килеп керә. Алар «князь»нең марҗасын кулга алалар. Баксаң, «графиня» дигәннәре «Каравай авылының көтүче Иван кызы» икән. Ул «пивной»да эшләгәндә, хуҗасының беләзеген урлап качкан була.

Әсәр Шакирҗанның тәүбә кылуы, үзен «господин Җан Баевич» диючегә мондый сүзләр әйтүе белән тәгәлләнә: «Мин — Шакирҗан Миңлебай угылы, беләмсең? Мин Шакирҗан Миңлебай угылы, мин синең Җан Баевичыңны күргәнем, ишеткәнем юк. Бу минем мулла кушкан исемем. Мине ничек урыс исеме берлә атыйсың? Ничек син мине мыскыл итәсең? *(Өстәлгә сугып.)* Как ты смеешь! Безнең динне мыскыл итәргә?!»

## III

«Җан Баевич» әсәренең жанрын автор үзе көлке, ягъни комедия дип билгеләгән. Әмма пьесадагы вакыйга-хәлләр нигездә икенче пәрдәдән генә жанр рухына муафыйк рәвештә бирелә башлыйлар. Тәүге сәхифәләр исә гадәти драмага тартым: Сәхипҗамал исемле хатынның балалары белән әңгәмәсе, гаиләнең атаны көтүе табигый. Йорт хуҗасы кайтып кергәч, өйдә шатлык, куаныч. Ата да хатынына, балаларына яратып, игътибар белән карый. Әмма башта ук комедия атамасы белән искәртелгән укучы-тамашачы нәрсәнедер көтә. Ә беренче пәрдәдә көлкеле әйбер юк. Бу исә ике арада каршылык тудыра. Шушындый психологик вазгыять алдагы вакыйга-хәлләр белән кызыксынуны арттыра. Нәрсә булачак? Кем көлке тудырачак? Әсәр исемендәге Җан Баевич кем ул?

Беренче пәрдәдәге Шакирҗан белән башка өлешләрдәге Шакирҗан арасында җир белән күк аермасы кебек. Әйтерсең аны пәри алыштырган: кием-салым, үз-үзен тотыш, сөйләм, интерьер — бөтенләй үзгә. Җан Баевичка әйләнгән Шакирҗан үзенең хатынын, хезмәтчеләрен, кавемдәшләрен «затсыз», «кибәк баш», «утын» дип атый, төрлечә кимсетә. Закирны Захарга, Сәхипҗамалны Софичкага, әтине папага, әнине маманга, хатынны матушкага алыштырып, аларны «тәрәкъкыять» юлына басты-

рырга уйлый. Аның бу төр эш-гамәлләрен күреп, хатыны иренә: «Син әллә гакылдан яздыңмы?» — ди. Аны хәтта өшкертергә дә уйлый. Әмма бөеклек юлына баскан Җан Баевичның үз кырыгы кырык: ул хатынының сүзенә колак та салмый, аның өчен маржалар, «графиня»-«княгиня»лар сүзе генә кыйммәт: «тәрәкъкыйпәрвәр», «аксөяк» булу өчен йөзлек, меңлекләрне, чекларны ыргытып кына тора. «Графиня»ның үтенече белән Җан Баевич гадәттән тыш зур бәягә өч эт сатып ала, аларны өйдә тотарга карар кылына. Чөнки «графларда, князьләрдә» шулай кабул ителгән (хәзер исә күп кешедә эт!). «Һәммәсенең муенына, — ди ул, — җиздән язып, Җан Баевич дип тагасың! Ә бөтен күргән, белгән кеше бу Җан Баевичның эте икән дип белә... Аламыз, һәммәсен алдык». Әмма этләр, эшләпәләр сатып алуга күп акчалар тоткан төп персонаж якташ мулласына мәчет салырга бер тиен дә бирми. Җан Баевич аңа болай ди: «Тагы шул мәсҗед, тагы шул намаз. Тәрәкъкый итәргә кирәк, хәзрәт!.. Образованный булырга кирәк! Ят та тор, ят та тор, имеш? Шул булдымы эш?»

Автор, Җан Баевич-Шакирҗанның асылын, гайре табигыйлеген күрсәтү өчен, төрледән-төрле эпизод-күренешләрне биреп кенә тора. Хезмәтчесенә һәм балаларына кием кидерү, үзе белмәгән килеш асрауны реверанс ясарга өйрәтү, китапка үз исемен кертергә кушу, музыка тыңлау, бокска өйрәнү һ.б. — әнә шундыйлардан.

Сорау туа: ни өчен соң милли җанлы, ипле табигатьле Шакирҗан ярым маңкорт, һавалы Җан Баевичка әверелә? Байлыкны моның төп сәбәпчесе итеп күрсәтергә мөмкин. Әмма хатыны Сәхипҗамал да шундый шартларда яши. Ә бит ул үзгәрмәгән: милли рухлы, итагатьле, ярдәмчел, кайгыртучан зат булып калган. Гомумән, бу образ үзенә карата укучы-тамашачыда хөрмәт уята. Димәк, Шакирҗанның үзгәреше байлыкта гына түгел. Биредә психологик фактор, шәхеснең үзенчәлеге дә мөһим роль уйный. Чөнки бердәй яисә охшаш шартларда кешеләр еш кына төрлечә хәрәкәт итә: берәүләр ашыга, кабалана, борчыла, икенчеләре тынып кала...

Дөнья сүз сәнгатендә, шул исәптән татар фольклорында һәм язма әдәбиятында әверелү-метаморфоза күренешләре, «Мең дә бер кичә»дәге кебек «халиф на час» булып алу очраклары шактый күп. Мондый шартлы алым әдипнең уй-ниятен тулырак гәүдәләндерергә, образ-сурәтләрнең тәэсир көчен арттырырга ярдәм итә.

Дөнья һәм милли эстетик казанышларыннан хәбәрдар булган Г.Исхакый Шакирҗанны юкка гына Җан Баевичка әйләндерми. Бу — гадәти исем алыштыру, көлкеле тамаша гына түгел, ә кешенең милли асылын, инсанлыгын сынаучы, кавем язмышы хакында уйландыручы үзенә күрә җитди бер имти-

хан да. Җан Баевич маҗаралары ничектер кысалы кыйсса, спектакль эчендә спектакль кебек, әйтерсең алар саташу, мираж, төш, исереклек халәте шикелле. Биредә гадәти манктыйктан бигрәк, сәнгати логика өстенлек итә. Төп персонажның үзгәреше, үз-үзен тотышы, эш-гамәлләре укучы-тамашачыда бәхәс тудырмый — барысы да аклана. Әсәр ахырында Җан Баевичның кабат Шакирҗан Миңлебаевич исеменә кайтуы да табигый, төштән, шартлы дөньядан реаль тормышка кайту рәвешендә кабул ителә.

Г.Исхакый әсәре — гадәти көлке генә түгел, ә сатирик рухлы комедия. Автор Җан Баевичның, аның даирәсендәге марҗа-графиняларның, Галәветдиннәрнең кешеләргә, җәмгыятькә, милләткә зарарлы булуларын фаш итә. Милли-тарихи агышка, халыкның яшәеш-язмышына бәйләп караганда, әсәр жанры трагикомедия рәвешен дә ала. Ни өчен? Чөнки милләтеннән баш тарткан, диненнән язган мөртәтләр безнең тарихыбызда, аеруча Октябрьдән соңгы чорда гаять күп. Аларның шактые алдында Җан Баевич хәтта тоныкланып та кала. Әле ул ни әйтсәң дә, «киртәгә сикермәгән» (ягъни диненнән язмаган), исеменең бер өлешен саклап калган, үзен татар аксөякләре, Мамай нәселе белән бәйләүдән баш тартмый, ахырда, тәүбә кылып, үзенең асыл хәленә кайта. Ә бит безнең тормышыбызда тәмам урыслашкан, татар теле, ислам дине белән бөтенләйгә бәйләнешен, алыш-бирешен өзгән кешеләр никадәр! Бу инде комедия генә түгел, ә коточкыч фаҗига-трагедия дә.

Тормышта еш кына бер хәл күзәтелә: үзенең милли йөзен, гореф-гадәтләрен, иманын югалткан, башка этник мохиткә күчкән кеше, матди, социаль яктан уңышларга ирешкән очракта да, кагыйдә буларак рухи бәхеткә, җан тынычлыгына ирешә алмый. Аның күңеленә нәсел шәҗәрәсе, әби-бабалары аңлы-аңсыз рәвештә аваз салып, зиһенен борчылуда, каршылыкта тота. Шуны басар өчен андый зат үзенең элеккеге милләтенә, кавемдәшләренә зыянлы гамәлләр дә кылырга мөмкин.

«Җан Баевич» әсәре үз кавеменнән, гореф-гадәтләреннән аерылуның әйбәт кенә шәхесләрне дә инсани һәм әхлакый яктан бозуын, милләтне эчке яктан җимерүен гыйбрәтле күренешләр аркылы ачык күрсәтә. Башка күп кенә әсәрләрендәге кебек, бу комедиясендә дә автор инкыйразны булдырмауда, милли яшәешне саклауда хатын-кызларга зур өмет баглый. Шакирҗанның хатыны Сәхипҗамал (исеме генә дә нинди: Матурлык иясе!) үзенең тереклек мәгънәсен ире, балалары белән исән-имин, милли рухта яшәүдә күрә. Чит-ят, әхлаксыз гадәтләрне, эшләрне аның җаны кабул итми. Балалары, гаиләсе хакына ул үзенә хыянәт иткән ирен дә кичерә, аны бәладән йолып ала.

«*Ш а к и р җ а н.* Сәхипҗамал, синме?.. Коткар мине бу бәладән, коткар!..

*С ә х и п җ а м а л.* Менә, кием-салымыңны алып килдем... Бик күп саташтың, җитәр инде! Әйдә, киен дә өйгә кайтамыз!

*Б а л а л а р.* Әйдә, әти, өйгә кайтамыз!.. Әйдәгез! Әйдәгез...

*Ш а к и р җ а н.* ...Шул шайтанга алданып, никадәр дәүләт бетердем, никадәр дәүләт!.. Мин бит тәрәкъкыйпәрвәр булдым дип белдем!.. Мин бит тарихка керәм дип белдем!..

*С ә х и п җ а м а л.* Ярар инде! Баш сау булса, мал табылыр. Әйдә тизрәк өйгә!

*Ш а к и р җ а н.* Тагы толчокта иске кибетемне алырмын. Тагы иске-москы берлә сату итә башлармын. Бик яхшы торырмыз әле!»

Бу өзек үзе генә дә Сәхипҗамалның киң күңелле, айнык акыллы, ипле, зирәк зат булуын күрсәтеп тора. Аның өчен баш саулыгы мөһим. Чөнки Сәхипҗамал иренең уңганлыгын, тырышлыгын белә. Балаларында да этиләренә хөрмәт-мәхәббәт хисләре көчле. (Монда, әлбәттә, әниләренең дә роле зур.) Кыскасы, бу гаиләнең киләчәктә дә әүвәлге кебек матур, тату торуына шик юк. Бары халкыбызның Сәхипҗамаллары гына исән-имин булсын!

Әсәрдә үзләренең холык-табигатьләре, идея-эстетик вазыйфалары белән күңелгә сеңеп калырлык башка персонажлар да бар. Шакирҗанның әнисе, аналарга хас булганча, улын кызгана, аны этисенең әр-сугуларыннан араларга омтыла. Миңлебай карт исә шактый кызу табигатьле зат. Ул, Шакирҗанның кыланышларын белеп, аны таяк белән акылга утыртудан да тартынмый. Хаим Соломонович — хәйләкәр, йомшак сугып, катыга утырта торган зат. Галәветдинне Г.Исхакый беренче сәхифәдә үк «имансыз яшь мулла» дип сыйфатлый. Әсәрдәге вакыйгаларда аның үз-үзен тотышы автор биргән тасвирламага туры килеп тора. Бу икейөзле зат акча өчен теләсә нәрсә эшләргә әзер. Аның Җан Баевичны мактап әйткән сүзләре — мәдех стихиясенә бирелеп китүнең классик үрнәге. «Сез, — ди ул, — тарихымызның кояшы, милләтемезнең ае, киң киләчәгемезнең Тимер казык йолдызы... Сез, господин Җан Баевич, үзеңезнең шушы эшеңез берлә... бөтен дөньяга, дүрт йөз миллионлы мөселман галәменә үрнәк булдыңыз... Табигатьтә магнетизм куәте бар... Марс йолдызы берлә Зөһрә йолдызы шул магнетизм куәте берлә берсенә берсе бағлангандыр... Менә сез дә күктәге Марс йолдызы, господин Җан Баевич! Милләт, менә, Зөһрә йолдызы. Зөһрә йолдызы Марска гашыйк булган кебек, милләт тә сезгә гашыйк!..»

Әсәрнең сюжет-композициясе авторның уй-ниятләрен мөмкин кадәр тулы гәүдәләндерерлек, персонажларның асылын, холык-табигатен тиешле күләмдә ачарлык итеп корылган.

Беренче пәрдә төп вакыйга-хәлләр барачак мәйдан, нигез ролен уйный. Биредә әле каршылык юк. Икенче пәрдә Шакирҗанның «тәрәкъкыять» юлына басуы белән башланып китә. Беренче пәрдәдән соң үткән ике еллап вакыт, күрәсең, үз эшен эшләгән: йорт-җирләр бөтенләй икенче, кыйммәтле җиһазлар; «киез итек, тәвәккәл бүрек» кигән, биленә «билбау» ураган Шакирҗан инде бөтенләй икенче рәвеш алган. «Аның, — ди автор, — өстендә фрак, муен бавы ачык кызылдан, жилет яшел төстә. Аягына ак туфли берлә сары гетр кигән». Ул хезмәтчеләрен төрле кыңгыраулар белән генә чакырып тора. Болар — Шакирҗанның эштә уңганлыгына, тырышлыгына да дәлил. Матди, тышкы үзгәрешкә нисбәтән ул үзен дә үзгәртүне кирәк дип саный. Шушында инде әсәрнең конфликты башлана. Тәрәкъкыять төшенчәсен ялгыш аңлау, исем алыштыру, гаилә тарату, башка гакылсыз гамәлләр — болар бар да тормыш кануннары, милли яшәеш кодексы белән каршылыкка керә. Иң аянычы һәм көлкелесе шул: төп персонаж үзенең нинди хәлгә төшкәнен үзе аңламый, бөеклек шаукымы аның зиһенен томалаган. Бөлү-банкротлык дүртенче пәрдәдә Җан Баевичны җиргә төшерә. «Графиня»ның кемлеге ачыклану төп персонажны тәмам айныта. Марҗага карап, ул болай ди: «Син графиня түгелмени?.. Тфү, ялганчы! Ни дип син мине, господин Җан Баевичны... (Миңлебайга карап.) Юк, юк!.. Шакирҗан Миңлебай угылын алдадың?» Марҗа үзенең көтүче кызы икәнлеген танығач, Шакирҗан мондый сүзләрне әйтә: «Соң, син ни дип графиня булган булып йөрисең?» «Графиня» аңа болай дип җавап бирә: «Соң, син ни дип князь булган булып йөрисең? Син дә бит авыл мужигы». Шакирҗанның тәүбә итүе, хатыны-балалары белән чыгып китүе вакыйгаларның чишелешен, конфликтның хәл ителүен билгеле.

Персонажларның сөйләме аларның холык-фигыльләренә, психологик халәтләренә, иҗтимагый-социаль вазыйфаларына нисбәтле бирелгән. «Графиня», үзенең асылын яшерү өчен, купшы, стандарт сүзләрне күп куллана. Ул башкаларны, аеруча татарларны түбәнсетергә тырыша, үзен, икейөзлеләнеп, әллә кем итеп күрсәтергә омтыла. Шакирҗаннан Җан Баевичка әверелгән төп персонажның да сөйләмендә тупас, башкаларны рәнҗетү сүзләре арта. Бурычын ала алмыйча, тәмам гаҗиз булган приказчик Шакирҗанның «затсыз, необразованный!» дигән репликасына «Төкерәм мин синең образованный дип кылануыңа!» сүзләрен әйтә.

Комедиянең телендә шивә, аерым социаль катлам, чор өчен хас булган сүз-гыйбарәләр дә очрый: киртә сикерү (диннән язу; гакыл зәгыйфьләнү), околоточный (тәртип саклаучы), мадмуазель, бозга язмаганны сөйләү һ.б.

* * *

Октябрьдән соң илдәге аерым әдипләр, милләтпәрвәрләрне фаш итеп, алардан көлеп, әсәрләр яздылар. Г.Исхакый исә үз кавеменнән аерылучыларны, мөртәтләрне тәнкыйть уты астына алды. Ул тудырган Җан Баевич — татар тормышына хас булган бер тип. Андыйлар Г.Исхакыйга кадәр дә, аның дәверендә дә, бүтән мәгыйшәттә дә булган. Совет чорында исә Җан Баевичлар гаять күбәйде. Автор үз комедиясен әйтерсең шул киләчәкне күздә тотып иҗат иткән. Милләт язмышын, инсаниятне, әхлакны үзәккә куйган бу әсәр хәзерге көнгә дә аваздаш. Шуңа күрә аны укучыларга ирештерү, сәхнәләштереп, тамашачыларга җиткерү — мөһим һәм изге бурыч.

Г.Исхакый комедиясендә кеше һәм милләт, шәхес һәм әхлак, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре дә гәүдәләнеш тапкан. Җан Баевич — дөнья әдәбиятындагы күп кенә классик типлар белән янәшә торырлык образ.

*1998*

## Яшәү мәгънәсенең асыл гәүдәләнеше

*(«Олуг Мөхәммәд» драмасы)*

### I

Инсаннарның, бигрәк тә иҗат ияләренең гомер юлында алар яшәешенең асылын фокустагы кебек бергә туплаган эш-гамәлләр була. Алар бу затларның кемлеген, эшчәнлекләренең мәгънәсен, иҗтимагый-тарихи кыйммәтен ачык күрсәтеп торалар. «Олуг Мөхәммәд» драмасы да Гаяз Исхакыйның гомер юлында нәкъ әнә шундый роль уйный.

Мәгълүм ки, бу бөек шәхесне әдип буларак «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре танытты (1903). Анда авторның күңел дөньясы, милләт язмышы, тормыш, кешеләр турында уйланулары, чынбарлыкка мөнәсәбәте сәнгати һәм публицистик агымнарның кушылуы, синтезы рәвешендә гәүдәләнеш тапты. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» Г.Исхакыйның һәм үзе, һәм күп кенә татар зыялылары өчен мөһим бер программа, таяныч, этәрелеш ноктасы булып хезмәт итте.

XX гасырның шаулы, фаҗигале һәм гыйбрәтле еллары, Рәсәй һәм совет җирлегенең кырыс шартлары, мөһаҗирлек шулпасы, әлбәттә, яшь әдипнең «Ике йөз елдан соң инкыйраз»дагы романтик уйлануларына, чагыштырмача тонык иҗтимагый-социаль карашларына шактый гына үзгәреш-төзәтмәләр кертте.

Әмма Г.Исхакый яшьлек хыялларына — милләткә хезмәт итү, аны хөр, бәхетле итү идеалларына соңгы сулышынача тугрылыклы калды. Биредә ирексездән Тукайның «Үз-үземә» исемле шигыре хәтергә килә:

...Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.
Татар бәхте өчен мин җан атармын,
Татар бит мин, үзем дә чын татармын...

Г.Исхакый татарның Тукай хыялланган «җанлылык вактын», «бәхетен» азатлык, дәүләтчелек төшенчәләре белән тыгыз мөнәсәбәттә карый. Идел-Урал мәмләкәтен төзү аның Октябрьдән соңгы, аеруча 30 нчы еллардагы эшчәнлегендә төп кыйблага, иманга әверелә. Шунысы мөһим: Г.Исхакыйның фәнни-публицистик язмаларындагы Идел-Урал идеясе аның 40 нчы еллардагы әдәби иҗатында билгеле бер эволюция кичерә, Идел-йорттагы татарларны һәм бу төбәктәге кайбер башка халыкларны үз эченә алган Казан дәүләте рәвешен ала. «Олуг Мөхәммәд» драмасында да шул караш өстенлек итә.

20 нче елларда төзелгән Советлар Берлеге бер-ике дистә ел эчендә шактый ныгый, көчәя, дөньяның хәлиткеч факторына әверелә. Шуңа да карамастан, Г.Исхакый аның таралачагына, империя составындагы кавемнәрнең, шул исәптән татарларның бәйсезлек алачагына ышанып яши. Әдип фикеренчә, якынлашып килүче дөнья сугышы бу процессны тизләтәчәк. «Бүгенге вазгыять (хәл) вә безнең вазыйфамыз» исемле мәкаләсендә (Яңа милли юл. — Берлин, 1935. — № 6. — 1–6 б.) ул нәкъ әнә шул фикерне алга сөрә. *«Бу сугышта,* — ди автор, — *СССРдагы «гайре табигый режим» җимереләчәк, андагы аерым кисәкләрне берсенә берсен баглаган бөтен сәяси, иҗтимагый җебләр сүтеләчәк вә киң Русиядә һәр шәһәр, һәр авыл үз башына калып, анаршы (анархия. — Х.М.) башланачакдыр... Рус халкының җимерелү дәвере, төрек (төрк. — Х.М.) халкының төзелү, корылу дәверенә очраячак...»*

Мәгълүм ки, икенче бөтендөнья сугышыннан Советлар Берлеге җиңүче булып чыкты. Ул таралу-җимерелү түгел, күп кенә илләрне һәм кавемнәрне үз йогынтысы астына алды. Мондый вазгыятьтә СССРдагы халыкларның хөрлеккә, бәйсезлеккә ирешүләре бөтенләй мөмкин булмаган хәлгә әверелде. Хәзер инде шушындый шартларда калган Г.Исхакыйның хәлен күз алдына китерегез! Өстәвенә — картлык, хасталык, мөһаҗирлек, фәкыйрьлек, Истанбул кебек берничә миллион халыклы шәһәрдә ялгызлык. Әмма төрмә-сөргеннәрдә дә, куылу-эзәрлекләүләрдә дә сынмаган Исхакый һаман Исхакый булып, көчле рухлы, кыйблалы милләтпәрвәр булып кала. 1947–1948 елларда язылган «Олуг Мөхәммәд» — шуның гүзәл бер гәүдәләнеше, ышандырырлык дәлиле.

Бу драма — Г.Исхакыйның ярты гасырга сузылган күпкырлы иҗат юлындагы күләмле соңгы әсәре, бай тәҗрибә туплаган 70 яшьлек әдипнең килер буыннарга мәгънәви васыяте, бәйсезлеккә ирешүнең, гадел милли дәүләт төзүнең, имин тормыш коруның сәнгати бер программасы, хыялый бер үрнәге. «Олуг Мөхәммәд» өчен, гәрчә ул бәрелеш-каршылыкларны үз эченә алган драма жанрында язылса да, гомумән, олпатлык, эпик масштаблылык, салмаклык, фикри һәм психологик зирәклек хас. Бу яктан ул ничектер «Шаһнамә», «Котадгу белек», «Искәндәрнамә», «Идегәй» кебек классик ядкәрләрдән килә торган рухи традицияләр белән кушылып, керешеп китә. Аларның бит һәммәсендә ил язмышы, хөкемдар һәм гавам, имин җәмгыять мәсьәләләре! Г.Исхакый исә боларга милләт язмышы проблемасын да китереп куша, аны үзәккә куя.

«Олуг Мөхәммәд» үз вакытында нәшер ителмичә, кулъязмада кала. Ул бары тик 90 нчы еллар башында гына басылып чыкты (Мирас, 1991. — № 1. — 27–51 б.; 1992. — № 1. — 39–66 б. Гарәп язуындагы бу текстны матбугатка әзерләүчеләр — Лена Гайнанова һәм Һәнүз Мәхмүтов).

Күз алдына китерегез: автор, янып-көеп, илһамланып, рухи газап һәм шатлыклар кичереп, әдәби әсәр тудыра. Әмма аны бастыру, әдип теләгән кешеләр белән очраштыру мөмкинчелеге юк. Бу бит коточкыч фаҗига! Әмма автор, алдан ук шуны белсә дә, фидакарьләрчә эшли, иҗат итә. Димәк, аның күңелендә алга, киләчәккә ышаныч, өмет, үз хезмәтенең милләт яшәешендәге заруриятен тирәнтен аңлау, төшенү хисе яши. Тагын шунысы да бар: әдип үз әсәре белән шәхси идеалларына җавап бирерлек бер дөнья, үзе хуҗа булган сәнгати бер җиһан тудырган. Хыялый бу дөнья кыен шартларда психологик һәм рухи яктан әдип күңеленә, әлбәттә, билгеле бер канәгатьләнү, юаныч та биргәндер.

## II

Теләсә нинди язма, әдәби әсәр очраклы рәвештә генә язылмый. Ул авторның үзе тарафыннан тоемланган яисә җәмгыять тарафыннан җиткерелгән ихтыяҗга рухи җавап рәвешендә туа. Әдип үз язмасы белән нәрсәне дә булса расларга яисә кире кагарга, күңел дөньясындагы уй-кичерешләрне башкаларга җиткерергә омтыла.

Үз халкыннан, туган җиреннән читтә яшәп, ерак Истанбулда гомер кичергән Г.Исхакыйның «Олуг Мөхәммәд» драмасын 40 нчы елларның урталарында иҗат итүе дә һич тә очраклы түгел. Нәкъ менә шушы чорда Советлар Берлеге хакимияте татарларга карата болай да рәхимсез сәясәтен тагын да катыландыра: Кырым татарлары гомер бакый яшәгән җирләрен-

нән сөреләә. Идел-йорттагы милләттәшләребез коточкыч салымнарга дучар ителә, сугыш кырларында империя мәнфәгатьләре өчен көрәшеп, берничәшәр йөз мең татар башын сала. Шушы елларда татарларны тарихыннан, рухи мирасыннан аерып, маңкорт итү юнәлешендә дә СССР хакимияте һәм аның җирле иярченнәре зур эшләр башкара. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 ел 25 август карары («Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»), Татарстан партия Өлкә комитетының сугыштан соңгы елларда кабул ителгән күп кенә документлары («Тел, әдәбият һәм тарих институтының эшчәнлеге», «Урта мәктәпләрнең 8 нче сыйныфы өчен татар әдәбияты дәреслеге турында», «Татарстан АССР тарихыннан очерклар» һ.б.) — моның ачык билгесе. Боларга СССР Фәннәр академиясе тарафыннан Казан татарларының килеп чыгышына багышланган махсус сессия (1946 елның апреле) карарлары да килеп кушыла. Рәсми хакимиятнең һәм оешмаларның милләтебез тарихына һәм мәдәниятенә мөнәсәбәтле документларында һәм материалларында иң каһәрләнгән өлкә, әлбәттә, татарларның мөстәкыйль яшәгән дәвере, төгәлрәк әйткәндә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорлары, аларның хөкемдарлары иде. Урыс халкы белән булган һәм булмаган дуслыкны күрсәтү иң төп таләпләрнең берсе итеп куелды. Ә шул чорда урысның күп кенә китапларында, аеруча дәреслекләрдә татарлар төрлечә хурланды, аларның тарихы бозып тасвирланды. Явыз Иван һәм аның ишләре каһарманнар кебек күрсәтелде.

Г.Исхакыйның тарихи үткәнгә, аның дә нәкъ менә киеренке чорына — Алтын Урда таралу, Казан ханлыгы төзелү дәверенә мөрәҗәгать итүендә шактый тирән һәм символик мәгънә ята. Бу еллардагы тарихи вакыйгалар, Олуг Мәхәммәд шәхесе авторга ретроспектив ысул белән эш итәргә, үткәнне сурәтләү аша киләчәккә караш ташларга мөмкинлек тудыра.

Г.Исхакый юкка гына үз әсәрен тарихи драма дип атамаган. Чөнки аның нигезенә урыс елъязмаларында, төрле тарихи хезмәтләрдә (мәсәлән: Соловьев С.М. История России с древнейших времен; Вельяминов-Зернов В.В. Исследования о Касимовских царях и царевичах һ.б.) гәүдәләнгән реаль вакыйгалар ята. Автор Алтын Урда һәм татар ханлыкларына мөнәсәбәтле бу төр чыганаклар белән таныш була. Аның күңеленә аеруча М.Г.Худяковның «Очерки по истории Казанского ханства» (Казань, 1923. — С.304) исемле китабы хуш килә. Г.Исхакыйның бу хезмәтне нәкъ менә 1945 елда төрекчәгә тәрҗемә итүе дә күп нәрсә хакында сөйли.

«Олуг Мәхәммәд» авторының Ризаэддин Фәхреддинне һәм галим, һәм шәхес буларак хөрмәтләве күпләргә мәгълүм. Ул аны бер мәкаләсендә (Яңа милли юл, 1936. — № 7–8. — 2–

6 б.) «бөек милли хезмәтчебез», «мәдәни истикълялемезнең (азатлыгыбызның) яшәве өчен кирәкле зәминне (җирлекне) әзерләүче» дип атый.

Г.Исхакый үз драмасы сюжетына төп материал итеп Р.Фәхреддиннең «Олуг Мөхәммәд хан» язмасын ала («Шура» журналының 1908 елгы санында басылган бу мәкаләне түбәндәге китаптан да табарга мөмкин: Ризаэддин Фәхреддин. Казан ханнары. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. — 38–51 б.). Моның шулай икәнлеген текстлардагы вакыйгаларның, төп факт-мәгълүматларның уртаклыгы, охшашлыгыраслый.

Әмма «Олуг Мөхәммәд», гәрчә ул «тарихи»... дип аталса да, гыйльми хезмәт түгел, ә әдәби әсәр. Шуңа күрә анда авторның иҗат фантазиясе катнашуы, тарихи вакыйгаларның теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртелүе, төрле характердагы өстәмәләрнең кертелүе табигый хәл. Чөнки әдәби әсәр кануннары вакыйга-хәлләрне җанландыруны, кешеләштерүне таләп итә. Шунсыз ул эстетик яктан үз укучысына һәм тамашачыга тәэсир ясый алмаячак. Драманың дүртенче пәрдәсендә зур урынны бүләк багу (бирнә карау) күренеше алып тора. Олуг Мөхәммәднең улы Ягъкуб Казан түрәләреннән берсенең кызына өйләнә. Шул уңай белән хан сараена шәһәрнең күп кенә аксөяк хатыннары — бикәләр җыйнала. Ә бит боларның берсе дә тарихи чыганакларда юк. Әсәрне укыганда исә бу уйланма күренешнең һәм мәгънәви, һәм эстетик яктан зарурилыгы һич тә бәхәс тудырмый. Беренчедән, ул халыктагы, хан сараендагы гореф-гадәтләрне күрсәтүгә булыша. Биредә персонажларның тапкыр теләкләре аеруча кызыклы. Мәсәлән, бер хатын яшьләргә Коръән бүләк итә. Шул уңай белән андагы бикәләр болай диләр: «Сансыз көннәр, исәпсез төннәр шул Коръән Шәрифнең хөкемнәрен йөртергә насыйп итсен!» Икенче бер хатынның ефәк тышлы тун бүләк итүе «авыру, кайгылары онытылсын, тормышы җылы, күңеле тыныч булсын!» теләге белән хуплана. Икенчедән, бүләк багу күренеше ил анасы, ягъни хан хатыны Гөлбикәнең, аның гаиләсенең холык-фигылен аңларга, бикәләр әңгәмәсе аркылы ил-көн хәлләренә күз ташларга, яшәешнең әхлакый нигезләре хакында сүз кузгатырга мөмкинлек бирә. Өченчедән, бүләкләр карау күренеше төп каһарманның үз гаиләсендә мөхтәрәм ата булуын, гавамның аңа уңай мөнәсәбәтен төшенүгә дә ярдәм итә.

Чыңгыз оныкларыннан берсе булган Олуг Мөхәммәд (1404–1446) — Алтын Урда мәмләкәтенең соңгы ханнарыннан берсе. Ул Сарай тәхетенә якынча 1419 елда утыра. 1437 елда тәхетне Кече Мөхәммәдкә калдырырга мәҗбүр була. Берничә ай Кырымда булганнан соң, 3 мең кешесе белән бергә Ока елгасы буендагы Белёв шәһәренә килә. Әмма кайчандыр үзе тәхеткә утырткан Мәскәү князе Василий Икенче Олуг Мө-

хәммәдкә каршы 40 меңлек гаскәр җибәрә. Татар ханының мәсьәләне тыныч юл белән хәл итәргә тырышуына карамастан, сугыш башлана. Олуг Мөхәммәднең бер меңлек гаскәре Мәскәүнең 40 меңлек гаскәрен җиңүгә ирешә. Берничә мең кеше әсирлеккә төшә, калганнары кырыла, качып китә. Олуг Мөхәммәд Казан шәһәренә килә. Җирле хакимият һәм халык аны тәхеткә күтәрә.

1445 елда Олуг Мөхәммәд Мәскәүнең күпсанлы гаскәрен җиңеп, князь Василий Икенчене әсирлеккә ала. Урыс патшасы үзен ярлыкауны, хаталарын кичерүне сорый. Олуг Мөхәммәд аны янә Мәскәү тәхетенә утыртырга карар кыла.

Дөрес, кайбер авторлар Казан дәүләтенә нигез салынуны башкачарак та аңлаталар. Имеш, бу ханлыкның тәүге хөкемдары — Олуг Мөхәммәд түгел, ә аның улы Мәхмүд. Имеш, Олуг Мөхәммәд Казанны көч белән яулап алган... Әмма болар — хосусый карашлар. Драмада төп каһарманның биреләше гомуми планда тарихи вакыйгалар һәм фактлар белән яраша.

## III

«Олуг Мөхәммәд» — биш пәрдәлек әсәр. Беренче пәрдә үз эчендә чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия булган өч, икенчесе ике күренешкә бүленгән. Төп эчтәлекләренә карап, пәрдәләрне түбәндәгечә исемләргә мөмкин булыр иде: I–II — яшәү белән үлем арасында; борынгы Болгар җиренә килү; III — Казан дәүләтенең дөньяга аваз бирүе; IV — туйлар булганда, ил-кавем яшәр; V — җиңү һәм ярлыкау (яисә көчле рухлылар гафу да итә).

Драманың бу рәвешле корылуында тирән фәлсәфи мәгънә бар. Кеше, кавем, нинди генә кыен шартларда калса да, үткәненә тугрылык, киләчәккә өмет-ышанычы бар икән, ул яши, максатына ирешә. Әсәрнең тәүге өлешенә игътибар итик: салкын кыш, тиз вакытта юкка чыгарлык боз ныгытмалар, сан ягыннан 40 мәртәбә куәтле дошман камалышы, үтенеч-теләкләрнең һәммәсенә каршы җавап... Мондый вазгыять эш-гамәлдә, персонажларның күңелендә эчке бер тынгысызлык, давыл алдындагы кебек киеренке халәт тудыра. Әмма Олуг Мөхәммәд һәм аның даирәсе вакыт агышының карлыгач канаты кебек киеренке мизгелендә үзләренең шәхси, хосусый язмышларыннан бигрәк, гасырлар тирәнлегеннән килүче төрки-татар кавеменең, дәүләтчелегенең үлем-калым, яшәү-яшәмәү мәсьәләсенең хәл ителүен күрәләр. «*Бүген,* — ди хан, — *Чыңгыз дәүләтенең шобагасы салына, ул йә бетәчәк, йә әүвәлгесе кебек олуг ханлык булачак. Башым китсә китсен, Чыңгызның мирасы — илемез сау калсын!*»

Байракны төшерүне таләп иткән урыс илчесенә Олуг Мөхәммәд болай дип җавап бирә: *«Бу байрак безнең олуг бабамыз Чыңгыз ханның илемезгә багышланган мөкаддәс байрагыдыр. Бу байракны без иңдерә алмыймыз. Тәңредән башка аны иңдерәчәк куәт юктыр, без бетәрмез, — байрак иңмәс!»* Вакыт агышы һәм тарих алдында үзләренә нинди бөек һәм изге вазыйфа йөкләнүен тирәнтен төшенү Олуг Мөхәммәд кешеләренә рухи дәрт, эчке бер куәт, иҗтимагый-әхлакый иман-ышаныч бирә.

Алга таба килгән вакыйга-хәлләрнең дә эчке бер мантыйгы (логикасы), инсани-әхлакый мәгънәсе бар. Олуг Мөхәммәд дошманын җиңә. Әмма ул тантанага бирелми, сугышның һәр ике як өчен дә зур корбаннар китерүен һәм, гомумән, фаҗигале икәнлеген яхшы аңлый; иң әүвәл шәһид булганнарны, аларның якыннарын искә төшерә, әсирләр турында да кайгырта. *«Кичә,* — ди хан, — *алар (ягъни әсирләр) дошман гаскәре иде, бүген Алланың бәхетсез бәндәләре генә. Шәфкать берлә эш күреңез».*

Олуг Мөхәммәд дошманын җиңде. Аңа биредә калып, үз хакимиятен Мәскәү төбәгендә дә урнаштырырга мөмкин иде. Әмма ул башкача эшли. *«...Бу җир,* — ди хан, — *безнең илемез түгел — бөтен тирә-юнь дошман халык... Алланың әмере берлә үз илемезгә, бабаларымызның төп иленә — Болгар йортына китәчәкмез. Илемез, дәүләтемез мәңге яшәсен дип тагы әле бик күп эшләр эшләргә тиешмез, шул изге байрагымызны мәңгегә илемездә сакланачак хәлдә дәүләтемезне көчләндерергә тиешмез...»*

Автор фикеренчә, Казан, — бер яктан, элеккеге Болгар мәмләкәтенең дәвамчысы. Икенче яктан, ул — Алтын Урда дәүләтенең мәркәзи төбәкләреннән берсе, төрки-татар кавеменең мөһим үзәге. Олуг Мөхәммәднең башка җиргә түгел, нәкъ менә Казанга юнәлүе әнә шул факторлар белән аңлатыла.

Урыс гаскәрен пыран-заран китергән татар ханы Идел-Чулман төбәген сугышып алуны гайре табигый гамәл дип саный. «Казан бит урыс каласы түгел, үз шәһәремез, — ди Олуг Мөхәммәд. — Үзара сугыша-сугыша дөнья йөзен тоткан Бату дәүләтеннән (халыкка күрсәтеп) менә нәрсә калды, Чыңгыз балалары урыс-дошманга сыгынуга кадәр түбән төштеләр. Әгәр Казан кабул итмәсә, күтәрелеп, сахрага китәмез, казах буламыз. Илдәшләр арасы сугышларга мин сәбәп тә була алмыйм, бу сугышларда башлык та була алмыйм».

Драмада төп каһарманның Казан ханы булып китүе бик мәгънәле сурәтләнгән. Урыс һөҗүмнәреннән даими иза чиккән шәһәр кешеләре исеменнән аларның хөкемдары Галимбәк, руханилар башлыгы Сәед, илнең аксакалы һәм «кара халык» вәкиле Олуг Мөхәммәдне Казан тәхетенә үзләре чакыралар,

мәмләкәтнең яшәешен, иминлеген алар шушы кодрәтле затның идарәчелегендә күрәләр. Әсәрнең үзәк каһарманы халыкның үтенечен гаять зур җаваплылык белән кабул итә. «*Ил,* — ди ул, — *барымызның да уртак малы. Дошманнарымызга дошманлык безне бүген ничек берләштерсә, арамызда дуслык, кардәшлек тә шулай ук берләштерсен... Адәм баласымын, хатам да булыр, минем яңлышлыкларымны күрсәтегез, тугрылык берлә ил эшләрен башкарырга барыгыз да ярдәм итегез». Олуг Мөхәммәднең хан булуын илдәге чуваш, чирмеш вәкилләре дә хуплый.*

Бу затның Казан тәхетенә утыруы олы иҗтимагый-сәяси янгырашка ия. Бердән, ул — Чыңгыз нәселеннән. (Бу шарт исә Урта гасыр төрки-татар сәясәте өчен зарури.) Икенчедән, Олуг Мөхәммәд — Алтын Урда белән 17 ел идарә иткән хан. Өченчедән, ул — Казан тәхетенә халык үтенече белән килгән хөкемдар. Төп каһарманның Идел-Чулман төбәгендә идарә итә башлавы моңа кадәр «Алтын Урда дәүләтенең бер өлеше булган» Казанга бөтенләй яңа вазыйфалар йөкли, сыйфади үзгәрешләр кертә. Кайчандыр Болгар рухи казанышларына нигезләнеп үскән Сарай мәмләкәте инде төрк-татар халкы яшәешендә үзенең тарихи миссиясен үти алмый башлый. Аның вазыйфалары Казанга күчәргә тиеш. Бу уңай белән Олуг Мөхәммәд әйткән сүзләр бик урынлы: «*Уемыз,* — *ди ул,* — *тынычсызлык көннәрендә аерылган, таралган илләремезне бергә җыеп, бабаларымыз вакытындагы кебек көчле бер дәүләт кору, халкымызны Тәңренең биргән нигъмәтләрендән файдаландырып, балаларымызга көчле, куәтле бер дәүләт мирас итеп калдырудадыр. Илемезнең мул ага торган Идел, Ак Идел, Чулман су юлларыны алыш-биреш көймәләре өчен һәрвакыт ачык тотып, юлларымызның тынычлыгын саклау, күрше халыклар берлә дә алыш-бирешне күңел тынычлыгында йөртүдер. Сарай киң илемезнең тынычлыгын саклауны, юлларымызның каравылчылыгын үти алмас хәлгә килде. Илемезнең һәр почмагына урыс агыла башлады. Хәзер без төп тупрагымызны саклар өчен, Чыңгыз байрагыны Казанда күтәреп, монда дошманнарга каршы кала корамыз. Казан каласы безнең кулымызда чакта һичбер урыс-дошман Идел суын үтә алмаячак. Безнең аркамыздагы илләремез, — Себер, Урал, Чыгтай йорты (ягъни Урта Азия) анасының кочагындагы бала кебек рәхәт итәчәк. Бу кала — Казан каласы — бабаларымызның бөтен илләрен, безнең мөселман халкымызны, ислам динемезне, безнең гыйлемемезне, һөнәремезне, сатып-алуымызны саклаучы, нәүбәтче булып торачак, бу кала изге кала булачактыр...*»

Әмма, кызганыч ки, Казан бу сәяси-тарихи вазыйфасын бер гасыр эчендә генә үти алды. 1552 елда аның егылуы күп кенә

төрк-мөселман дәүләтләренең инкыйразына, төрк-татар кавеменең аянычлы хәлгә төшүенә, Евразиянең иксез-чиксез мәйданнарын биләгән урыс-христиан империясе төзелүгә китерде.

«Олуг Мөхәммәд» драмасы дәүләт, аның эчке корылышы, тышкы мөнәсәбәтләре мәсьәләләрен сәнгати гәүдәләндерүгә дә зур урын бирә. Хөкемдарның гаделлеге, халкы турында ата кебек кайгыртучы зат булуы — ил иминлеген булдыруның төп шарты. Дәрвиш Әбүлмөхсин, ханга мөрәҗәгать итеп, болай ди: «...Балык баштан чери. Шаһзадәләрнең, вәзирләрнең, бәкләрнең тугры юлдан язмавын кара». Ханның кятибе, ягъни язу-сызу эшләрен башкаручы, укымышлы Мирза Гали моңа вәзир һәм түрәләр тугрылыгын, «халык берлә хөкүмәт... берлеген» өсти. Ике арада хәбәрдарлык булу, даими киңәш-табыш кору аеруча лязем.

Баш каһарман фикеренчә, «корал илне, суны дошманнан сакларга гына ярый. Дәүләт корыр өчен белем кирәк, бер-береңә ышаныч кирәк, халык арасында дуслык кирәк, халыкның төрле катлаулары арасында күңел бавы кирәк. Ул шигырь берлә, тарих берлә ясала».

Мәгълүм булганча, Казан мәмләкәтендә татарлардан тыш башка дин вә кавем әһелләре, җөмләдән чуашлар, чирмешләр, мукшылар һәм башкалар да яши. Аларга нинди мөнәсәбәттә торырга? *«Безнең шәригатемездә,* — ди Олуг Мөхәммәд, — *көчләп дингә керту тугры булмаса кирәк»*. Хан карашынча, аларга «үз йолаларында, үз диннәрендә торуларына ирек бирү» зарури. Шуның белән бергә хөкемдар ислам динен аңлатуга, димләүгә дә каршы түгел.

Дүртенче пәрдәдә Олуг Мөхәммәд янына чуваш аксакалларының вәкиле керә. *«Безнең илгә,* — ди ул, — *урыс явы керде... , мал-туарны талады, ирләр хатыннарны әсир алды, ... авыл(лар)га ут салды... халыкның кача белгәне урманга качты... Бөтен чуваш иле хан хәзрәттән ярдәм үтенә»*. Үз кул астындагы халыкларның илен-йортын сакларга сүз биргән хан «урыс явын» кууны үзенең «бурычы» дип саный.

Тышкы сәясәттә Олуг Мөхәммәд алыш-биреш кылып, үзара тыныч яшәү карашын алга сөрә. Биредә, әлбәттә, иң мөһиме — «урыс иле» белән мөнәсәбәтләр кору. Бу бер үк вакытта драманың эчке конфликтын, вакыйга-хәлләр үстерелешенең төп сәбәпчесен, этәргеч көчен дә тәшкил итә. Әсәрнең Олуг Мөхәммәд һәм Василий гаскәрләренең үзара сугышы белән башлануы, мондый күренешнең янә кабатлануы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Драмада катнашучы персонажлар тарафыннан һәм урыс, һәм татар адресына әйтелгән каты-каты сүзләр, бәхәсле фикерләр дә бар. Мәсәлән, урыс илчесе Василий Сабакин болай ди: «Безнең урыс йорты... татар яуларыннан бик зур авырлык-

лар чикте, шәһәрләремез таралды, малымыз-туарымыз алынып, иленезгә озатылды, ирләремез, хатыннарымыз әсир ителде». Сәед Җәлил авызыннан мондый сүзләр яңгырый: «Бабаларымыз «Урыс атаң булса, билеңдә балтаң булсын!» дигәннәр...» «Шул урыс иле мөселманлыкка чыкса, безнең илемез генә түгел, Кырымы да, Сарае да бер тынычлыкка кавышыр иде...»

Драмада мондый мисалларны тагын да китерергә мөмкин. Әмма әсәрнең төп каһарманы татар-урыс мөнәсәбәтләренә җитди карый. Аның фикеренчә, ике арада төрле сугышлар, каршылыклар була килгән. *«Моны без генә дөньяга чыгармадык, адәм баласы яши башлаганнан бирле бу эш шулай килә,* — ди Олуг Мөхәммәд. — *Безнең татар иленә урысларның зыян-зарары азмы?.. Безнең хатыннарымыз-кызларымызны алып китеп, монастырьларга китермәделәрме? Болар һәммәсе дә үткәндәге эшләр. Без — ике якымыз да шуларны онытып, ике күрше ир булып, бер-беремезгә яу җибәрмәенчә, тынычлыкта яши алмыймызмы?! Минем теләгем менә шул!»* Дөрес, бу сүзләр әсәрнең беренче өлешендә — Олуг Мөхәммәдкә кыен вакытта әйтелгән. Әмма Казан ханы, Мәскәү гаскәрен җиңеп, князь Василийны әсир иткәч тә, үзенең тәүге теләк-ниятләренә тугры кала. Урыс кенәзе, үз хаталарын танып, гафу үтенгәч, Олуг Мөхәммәд, янә олы җанлылык, рухи җегәрлек күрсәтеп, аны кичерә, хәтта Василий Икенчегә Мәскәү тәхетен дә яңадан кайтара.

«Һичбер вакыт хәзерге көчеңә таянып, дустыңа, дошманыңа золым итәргә ярамый. Көч-куәт бүген бар, иртәгә юк, болар барысы да Тәңренең кулында» — менә ханның сәяси-инсани принцибы. Драманың бетеме дә символик. *«Бу сәгатьтән башлап,* — ди Олуг Мөхәммәд, — *Мәскәү князьлеге берлә Казан ханлыгы арасында сугыш бетте, килешү булды. ...Мәскәү князе вә аның боярлары — безнең кунагымыздыр... Халыкка белдерегез..., халык өч көн, өч кич бәйрәм итсен!..»*

Моннан соңгы гасырларда нәрсәләр булганлыгы, Мәскәү патшаларының татарларга нинди «сый-хөрмәт» күрсәтүләре һәркемгә диярлек, шул исәптән авторның үзенә дә көн кебек ачык. Әмма Г.Исхакый киләчәкне күздә тотып эш итә. Урыс белән татар үзара аңлашып, күршеләрдәй килешеп, бер-берсен хөрмәт итеп яшәргә тиеш — бу милләтпәрвәр әдипнең мөкатдәс идеалы.

Үзенең мәшһүр «Китмибез» шигырендә Тукай: «Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!» — дип язган иде. Бу шигарь (лозунг) — күпләрнең, шул исәптән Г.Исхакыйның да изге теләге. Әмма бу идеалга әдип әкренләп җитди генә үзгәреш тә кертә. «Олуг Мөхәммәд» авторы татар илен, «хөр Идел-йортны» «хөр Русия» составында түгел, ә аның белән янәшәдә, тигез итеп күрәсе килә.

Әсәрнең исеме җисеменә туры килә. Аның үзәгендә — Олуг Мөхәммәд. Барлык вакыйга-хәлләр турыдан-туры да, читләтеп тә төп каһарман белән бәйләнешле. Авторның уй-ниятен гамәлгә ашыруда, идея йөкләмәсен сәнгати гәүдәләндерүдә дә Олуг Мөхәммәдкә төп авырлык төшә. Әсәрне укыгач, аның чын мәгънәсендә олуглыгы, олпатлыгы ачык күзаллана.

Олуг Мөхәммәд — тарихи шәхес. Аның бирелешендә дә чынбарлыкка тугрылык, реалистик башлангыч өстенлек итә. Әмма бу хөкемдар — Урта гасыр кешесе, мөһим иҗтимагый-социаль һәм эстетик идеалларны гәүдәләндерүче зат. Шуңа күрә Г.Исхакый Олуг Мөхәммәднең сәнгати сурәтен тудыруда билгеле бер дәрәҗәдә дастани башлангычка, аерым эш-гамәлләрне, сыйфатларны өлешчә калкуландыруга да юл куя. Мәсәлән, төп каһарман безнең күз алдыбызга акыллы, зирәк, мәрхәмәтле, кешеләргә игътибарлы, ягъни инсаннарга хас булган уңай сыйфатларны үзенә туплаган камил зат рәвешендә килеп баса.

Олуг Мөхәммәд — нәсел-нәсәбе белән дә гадәти инсан түгел. Шәҗәрәсе белән ул Чыңгызга барып тоташа. Әсәрдә Олуг Мөхәммәд дүрт улның, ике кызның атасы, берничә оныкның бабасы итеп бирелә. Шунысы мөһим: ул әмер биреп утыручы хөкемдар гына түгел. Эшнең авырын, бүрәнәнең юан башын Олуг Мөхәммәд үзе ала, улларына, якыннарына да ташлама ясамый. Беренче сугышта ул киявен югалта, кызы ятим кала. Уллары һәрчак көрәшнең, сугышның алгы сафында. Хөкемдарның мондый гамәле аңа түрәләрнең, гавамның хөрмәт-ышанычын арттыра.

Олуг Мөхәммәд — төрле хәлләрне башыннан кичергән тәҗрибәле зат. Ул шуңа күрә уйлап, киңәшеп эш итүне, кабаланмауны яхшы күрә. Тәхет-хакимиятнең дә, гавам мөнәсәбәтенең дә вакытлы, үзгәрүчән булуын Олуг Мөхәммәд яхшы аңлый. Казанда хан булгач, аңа күпләгән котлаулар килә. Бу уңай белән кятибе (секретаре) Мирза Гали болай ди: «Бөтен ил сөенеч эчендә, хан хәзрәтләре». Аңа җавап рәвешендә Олуг Мөхәммәд мондый сүзләрне әйтә: «Сөенеч эчендә, дисең! Безне, падишаһ балаларын, бөтен ил, бөтен халык безнең өчен үләргә хәзер, дип тәрбия итәләр, һәрбер кылган эшемезне халык сөенеп каршы алды, диләр. Мин җанымны, балам-чагамны коткарыр өчен Сарай шәһәреннән качканда, халыкның ничек сөенеч эчендә булуын үз күзем белән күрдем. *Көчең, куәтең булса, халык баш ия* (ассызык безнеке. — *Х.М.*). Эшләреңә ялганнан сөенеч күрсәтә, аз гына төштеңме, сине мәсхәрә итү аңа берни тормый». Бу юлларда хәзер «социаль психология» дип йөртелгән фәннең мөһим бер күренеше дә гәүдәләнеш тапкан.

Драмада Олуг Мөхәммәд һәм князь Василий образлары,

хөкемдар һәм шәхес буларак, өлешчә чагыштырма планда да биреләләр. Халыкта «аш белән атканга таш белән ату» гыйбарәсе бар. Олуг Мөхәммәд әсир төшкән урыс кешеләрен, князь Василийны, ягъни таш белән атучыларны аш белән сыйларга әмер бирә. Мондый адым аның әхлакый инанычы белән табигый керешеп китә. Чөнки Олуг Мөхәммәд өчен кешеләргә, авыр хәлдә калучыларга ярдәм итү — үзенә күрә бер инсани кагыйдә, норма. Әсәрдә князь Василий вәгъдәсез, хәйләкәр зат буларак күзаллана. Дөрес, әсирлеккә төшкәч, ул кылган явызлыклары, шайтани гамәлләре өчен гафу үтенә, тәүбә кыла, яңадан туган кебек эш итә. Әмма аның ихласи булуына инде күңел шикләнә. Чөнки бер алдаган кешегә янә ялганлау психологик һәм әхлакый яктан һич кыенлык тудырмый.

Драмадагы башка персонажлар да төп каһарманны ачуда, чынбарлыкны сәнгати гәүдәләндерүдә, авторның уй-ниятен гамәлгә ашыруда билгеле бер вазыйфа башкаралар. Гөлбикә, Галимбәк, Сәед Җәлил, Әбүлмөхсин һ.б. — әнә шундыйлардан. Болар арасында Әбүлмөхсин үзенчәлекле урын алып тора. Ул — дәрвиш, шагыйрь, туры сүзле зат. Сәләмә киемле бу кешенең күңелендә ил, кавем гаме. Шуңа күрә дә хан аны хөрмәт итә, бу инсанның киңәшләренә колак сала. Казанның элеккеге хөкемдары Галимбәк борынгы гадәт-йолаларны, рухи тәҗрибәне дәвам итәргә омтылучы, имин тормышны яклаучы сабыр, зирәк зат буларак күзаллана.

Г.Исхакый шул дәвер чынбарлыгын гәүдәләндерүдә этнографик күренешләрдән, тарихи детальләрдән уңышлы гына файдалана. Бүләк багу, бәйрәм күренешләре, сарай җиһазлары, музыка уйнау, җыр һ.б. Шунысын да искәртик: Алтын Урда һәм аннан соңгы татар мәмләкәтләрендә хан сараенда музыкантлар, җырчылар тоту күп кенә тарихи чыганаклар белән раслана.

«Олуг Мөхәммәд» — үзенә күрә авторның сәнгати бер васыяте. Шуңа күрә Г.Исхакый аның тел-стиль камиллегенә, каһарманнарның холык-фигыле белән сөйләмнәренең ярашуына җитди игътибар итә. Олуг Мөхәммәд сөйләме өчен салмаклык, фикри тирәнлек хас. «Бикәләр» исә, хатын-кыз табигатенә тапкыр рәвештә, төрле темаларга сөйләшергә яраталар.

Әсәрдә психологик һәм сюжет вазгыятенә туры килешле кызыклы гына сурәтләр, чагыштырулар бар. Бер персонаж урыс гаскәрләре камалышында калучыларны «капкынга төшкән бүре» белән тиңли. Борынгы Болгарның төрле кавемнәрне туплаудагы роле җилем белән чагыштырыла.

Г.Исхакый — туган тел мохитеннән аерылып, шактый гына чит-ят төбәкләрдә яшәгән әдип. Аның кырыгынчы еллардагы, ягъни «Олуг Мөхәммәд» иҗат ителгән чордагы тормышы Төркия белән бәйле. Шуңа күрә драманың тел-стилендә өлешчә шул дәвердәге төрек теле тәэсире дә сизелә. Мәсәлән: кыла-

выз (юл күрсәтүче, җитәкче), командан (гаскәр башлыгы, командир), «кызны өйләндерү» (кызны кияүгә бирү) һ.б. Казан аксакалларыннан берсе, Олуг Мөхәммәдне тәбрикләп, болай ди:«... Салымымы бар, олау чабумы бар, гаскәр бирүме — болар барысы да илгә каршы, ханга каршы бурычымыз». Биредәге «каршы» сүзе татар телендәге мәгънәдә түгел, ә төрекчә төшенчәдә килгән (ягъни хуплау).

«Олуг Мөхәммәд» — татар әдәбиятында Урта гасыр кешеләрен һәм чынбарлыгын гәүдәләндергән тәүге тарихи драмаларның берсе. Алга таба бу башлангыч драматургиядә һәм прозада Н.Фәттах, Т.Миңнуллин, М.Хәбибуллин, Җ.Рәхимов, Р.Батулла һәм башка авторлар тарафыннан дәвам иттерелде. Аларда Г.Исхакый традицияләренә теге яки бу дәрәҗәдә аваздашлык сизелеп тора. Мәсәлән, М.Хәбибуллинның Кубрат ханы үзенең эпиклыгы, олпатлыгы, зирәк акылы, ил, кавем мәнфәгатьләрен үзәккә куюы, алга карап, перспектив юнәлештә фикерләве белән типологик яктан Олуг Мөхәммәдкә охшаш.

Г.Исхакыйның оптимистик рухлы татар кавеменең тарихи язмышын һәм яшәеш программасын үз эченә алган драмасы соң булса да басылып чыкты. Әмма аны аерып, китап рәвешендә нәшер итү дә зарури. «Олуг Мөхәммәд» — сәхнә әсәре. Аны тиз көндә тамашачыларга ирештерү — әдип рухы алдында безнең әхлакый һәм инсани бурычыбыз.

XVI йөзнең күренекле әдибе Шәрифи үзенең «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңүе») әсәрендә (1550) милләтпәрвәрлек, ватанпәрвәрлек хисләрен белдереп, Казанның гүзәллеге, борын-борыннан ханнар шәһәре, татар пайтәхете булуы хакында шигъри юллар язган иде. Бер урында ул үзен: «Шәрифи, китмә бу йирдин, син — Казанның «сахибе» (хуҗасы)», — дип игълан итә. Бу уй-хисләрне үз драмасы белән Г.Исхакый да янә бер мәртәбә раслый һәм Идел-йортны торгызу, яшәтү хакындагы мөкатдәс идеалларын килер буыннар белән уртаклаша.

* * *

«Олуг Мөхәммәд» — гаять тирән мәгънәле, иҗтимагыйсәяси рухлы әсәр. Биредә без аның хакындагы аерым фикеркүзәтүләребезне генә бәян иттек. Бу драма турында Әхмәт Сәхаповның «Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты» (Казан: Мирас, 1997), Флүн Мусинның «Гаяз Исхакый» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1998) монографияләрендә, соңгы елларда басылган мәктәп дәреслекләрендә кызыклы гына күзәтүләр, факт-мәгълүматлар бар. Кызыксынган укучылар аларга да мөрәҗәгать итә алалар.

*1998*

## Гаяз Исхакыйның Мөселман Көнчыгышына сәяхәте

Тормышта, гәрчә бик сирәк булса да, шундый затлар очрый: аларның шәхси яшәеше, эш-гамәле, әйткән һәм язган сүзе гаиләсе, туган-тумачалары, якыннары өчен генә түгел, ә, гомумән, киң җәмәгатьчелек, милләтләр һәм илләр, тарих өчен билгеле бер әһәмияткә, мәгънәви яңгырашка ия була. Гаяз Исхакый да шундый инсаннарның берсе. Аның тормышы, язганнары терекләкнең күп кенә мәсьәләләрен ачыкларга, тарихны тулырак һәм җентеклерәк күзалларга ярдәм итә, бүгенге һәм киләчәк яшәеш өчен гыйбрәтле сабак булып тора. Без ничектер соңгы вакытта битарафлыкка, әби-бабаларыбыз даими искәртеп килгән гафиллеккә (ваемсызлыкка) күнегеп беттек. Мондый шартларда исә Тукай, Исхакый кебек бөекләребез белән танышу, алар белән киңәш-табыш итешү гафләт йокысыннан уянырга, бүгенге хәлебезне, барыр юлыбызны төшенергә булышыр иде.

Г.Исхакый — үзенең «...Инкыйраз»ы, күпсанлы чәчмә, драма әсәрләре, публицистикасы белән татарның күңел түрендә, әдәбиятында яшьли үк мөхтәрәм урынны алган әдип. Иленнән, халкыннан аерылгач та, ул үзенең милләти һәм дини иманына тугры калды. Мөһаҗирлектәге иҗаты, эшчәнлеге — моның ачык дәлиле. Кызганыч ки, әдипнең Октябрьдән соңгы тормышы, язмалары әле һаман да бүгенге укучыга тиешенчә җиткерелмәгән. А.Пушкин, Л.Толстой, А.Чехов, С.Есенин кебек әдипләрнең хәтта атнасы, көне ачыкланган тормыш һәм иҗат хроникалары бар. Ә Г.Исхакый гомеренең без хәтта аерым елларын да белмибез. Мөһаҗирлектәге язмаларының да әле күпчелеге һаман да таралып, сибелеп ята бирә. Шундыйларның берсе — һәм милли-тарихи, һәм иҗтимагый-сәяси, һәм әдәби-публицистик яктан мөһиме — «Ислам мәмләкәтләрендә» дип исемләнгән язмасы. Автор аны үзе «Юл истәлекләре» дип атаган. Әмма ул үзенең эчтәлеге, төзелеше белән сәяхәтнамә (сәфәрнамә) жанрына туры килә. Аның да төп үзәген сәфәр, авторның сәяхәт вакытында күргән-ишеткәннәре, тәэсирләре, уйкичерешләре тәшкил итә.

«Ислам мәмләкәтләрендә» язмасы шактый күләмле. Ул Берлинда гарәп хәрефләре белән нәшер ителүче «Яңа милли юл» журналының 1932 елгы 2—8, 10, 12 һәм 1933 елгы 1, 3, 5, 7, 8, 9, 10, 12 нче саннарында дөнья күргән. Аннан соңгы вакытта бу язманың башка урыннарда басылуы миңа мәгълүм түгел. Безнең аерым доклад-чыгышларны, мәкалә-язмаларны исәпкә алмаганда, бу сәяхәтнамә әле фәнни әйләнешкә дә кертелмәгән.

Г.Исхакый кебек җиһанны гизгән, дөньяның төрле кыйтгаларында, күп төбәкләрендә булган, яшәгән татар әдибе, бәлкем,

гомумән, татар кешесе, мөгаен, юктыр, булса да — бармак белән генә санарлыктыр. Әлбәттә, «...Инкыйраз» авторы үз ихтыяры белән генә сәяхәт кылмаган. Аны еш кына бу адымга тормыш шартлары, сәяси вазгыять мәҗбүр иткән. Әмма күп кенә чыганаклар, факт-мәгълүматлар Г.Исхакыйның холкы-табигате белән гаять кызыксынучан, хәрәкәтчән булуын күрсәтеп торалар. Миңа 1964–1967 елларда, Сарман якларында эшләгәндә, берничә мәртәбә Теләнче Тамак авылында булырга туры килгән иде. Биредә Октябрь инкыйлабына кадәр татарның мәгълүм сәүдәгәрләре — Хәлфиннәр яши. Аларның ташпулатлары хәзер дә исне-акылны җибәрерлек. (Мин белгәндә, бу биналарда ярдәмче мәктәп эшли иде.) Февраль инкыйлабы алдыннан Г.Исхакый берничә атна Хәлфиннәрдә яшәп ала, иҗат итә. Теләнче Тамактагы кайбер кешеләр «шыпырт кына» сөйләвенчә (кызганыч, шул мәгълүматларны вакытында теркәп калдыра алмаганмын), «...Инкыйраз» авторы еш кына табигатькә чыккан, урман-тауларга, күрше авылларга йөргән, күп кенә кешеләр белән очрашкан, гәпләшкән. Финляндиядәге милләттәшләребез дә Г.Исхакыйның йөрергә, сәяхәт кылырга, кешеләр белән аралашырга яратуын кат-кат искәрткәннәр иде. Әдипнең гаять кызыксынучан табигатьле булуы аның әсәрләрендә дә, шул исәптән сәяхәтнамәсендә дә чагылыш тапкан.

«Ислам мәмләкәтләрендә» язмасының нигезен Г.Исхакыйның мөселман Көнчыгышына, җөмләдән Фәләстин, Мисыр, Сүрия, Иордания, Ливан һәм кайбер башка илләргә сәфәре тәшкил итә*. «...Инкыйраз» авторының бу төбәккә килүендә төп сәбәп — Кодеста (Иерусалимда) уздырылган Бөтендөнья мөселманнарының корылтаенда катнашу. Халыкара җәмәгатьчелектә киң яңгыраш тапкан бу җитди чара 1931 елның 6–17 декабрендә 12 көн буена бара. Корылтай эшендә мөселман дөньясының күренекле әһелләре (дәүләт эшлеклеләре, руханилар, эшмәкәрләр, галимнәр...), төрле мәзһәб һәм фирка тарафдарлары, гаять күпсанлы журналистлар катнаша. Идел-Урал мөселманнары вәкиле буларак Г.Исхакый да алар арасында**. Сәгыйд Шамил бәк исә — кавказлылар делегаты. Бу зат — «...Инкыйраз» авторының дусты, фикердәше. Мәшһүр галим, рухани Муса Бигинең дә Кодес чараларында булуы, ватандашлары белән аралашуы мәгълүм.

---

* Г.Исхакый Ерак Шәрыктан Аурупага барышлый, 1919 елның декабрендә, пароход белән Сүәеш каналы аша үткән була.

** Мәгълүм ки, Бөтендөнья мөселманнарының бер корылтае 1926 елда Мәккәдә була. Анда мөфти Ризаэддин Фәхреддиннең Рәсәй мөселманнары вәкиле рәвешендә катнашуы, гарәп телендә чыгыш ясавы, конгресснын вице-президенты (рәис урынбасары) итеп сайлануы билгеле. Биредә бу мөхтәрәм затны Согыд Гарәбстаны короле дә кабул итә.

Корылтай мөселман дөньясының, илләр, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрнең мөһим мәсьәләләрен тикшерә, җитди генә карарлар кабул итә. Алар арасында исламият байлыкларын саклау һәм үстерү, Хиҗаз тимер юлын мөселманнар кулына алу, Кодеста халыкара ислам университеты (дарелфөнүне) ачу һәм башка чаралар да бар.

Корылтай Фәләстин мөфтие Хаҗи Әмин Хөсәйни җитәкчелегендәге 25 кешелек Үзәк Башкарма комитет сайлый. Аның составына Советлар Берлеге мөселманнары вәкиле сыйфатында Г.Исхакый да кертелә. Бу юкка гына түгел. Чөнки «...Инкыйраз» авторы күренекле әдип һәм журналист кына түгел, тәҗрибәле җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче дә. Аның проблемалы язмалары, җитди чыгышлары Аурупада гына түгел, гарәп дөньясында, мөселман матбугатында да еш күренеп тора. Бу — бер. Икенчедән, Г.Исхакый — корылтай эшендә иң актив катнашучыларның берсе. «Яңа милли юл» журналында басылган бер хәбәрдә (1932. — № 2) мондый юллар бар: «Ислам корылтаенда Идел-Урал вәкиле Гаяз Исхакый берлә Кафкас вәкиле Сәгыйд Шамил бәйләрнең катнашулары бик зур нәтиҗәләр бирде. Алар корылтайда аерым бер урын тоттылар. Үзләренең самимилекләре берлә вак-төяк мәсьәләләр өстендә торганнарны коралсызландырдылар. Алар большевик (большевизм) һәм исламның бер-беренә булган мөнәсәбәтен уртага куюлары берлә корылтайның дикъкатен җәлеп иттеләр. Кирәк корылтайда булсын, кирәк ислам матбугатында булсын, бик зур хөрмәт казандылар» (20 б.). Г.Исхакыйның тырышлыгы нәтиҗәсендә корылтай «Большевизмның Русия мөселманнарына җәбер-золымы хакында» махсус резолюция дә кабул итә. Ул Женевадагы «Милләтләр җәмгыяте»нә, башка халыкара оешмаларга, дөнья матбугатына һәм иң мөһиме — мөселман илләренең җитәкчеләренә ирештерелә. Корылтай көннәрен искә төшереп, Г.Исхакый бер язмасында болай ди: *«Мәсҗеде Аксада (Кодестагы мәшһүр мәчет. — Х.М.) мигъраҗ кичәсендә намаздан соң мин Русия мөселманнарының большевикларга каршы диннәре, милләтләре өчен сугышта шәһид булган угыллары, кызлары өчен бер фатиха укуны үтенгәч, 10 мең мөселман күз яше эчендә фатиха укыганнары вә мине — Русия мөселманнары угылын — меңнәрчә авыздан чыккан тәкбир берлә сәламләделәр» (Яңа милли юл, 1932. — № 1).*

Г.Исхакый Варшавадан Берлинга, аннан Италиягә юнәлә һәм биредән пароход белән Урта (Ак) диңгез аркылы Якын Көнчыгышка килә. Фәләстингә ул 1931 елның 30 ноябрендә аяк баса. Бирედә ул корылтайда катнаша, изге-тарихи урыннарны карый; Иорданиягә дә барып чыга. Поезд белән Каһирәгә килә. Бирედә төрле очрашулар үткәрә, конференциядә лекцияләр, чыгышлар ясый. Г.Исхакыйның инициативасы бе-

лән һәм аның турыдан-туры катнашында Русия мөселманнарының авыр хәле, аларга ярдәм итү турында Мисыр руханилар башлыгы — Шәйхел-Әзһәрнең Ислам дөньясына мөрәҗәгате әзерләнеп таратыла. Бу уңай белән Г.Исхакый үзе менә нәрсә ди: *«Рамазан гаете мөнәсәбәте берлә Мисырның Шәйхел-исламы бөтен ислам дөньясын большевикларга каршы тартышка чакырып мөрәҗәгать итте. Ул большевикларның мөселманнарга күрсәткән золымнарына каршы протест итте. Бу безнең мондагы хәрәкәтләребез җимеше иде. Без үзебезнең бу кыска вакыт эчендәге эшләребез берлә большевикның алган пәрдәсен алып ыргыттык, аның империализм сәясәтен аңлаттык. Бүген монда большевикларга дуст бер фикер юк. Гарәп дөньясында бүген большевик яклы булып язучы бер гәзит мөхәррире калмады». (Яңа милли юл, 1932. — № 3. — 4 б.)*

Мисырдан Г.Исхакый янә Фәләстингә килә, аннан Сүриягә юнәлә. Дәмәшкътан Бәйрутка килә һәм 1933 елның 8 мартында пароход белән Италиягә юл тота. Сәяхәтнамәсенең ахырында автор Русия мөселманнарының эше берлә әле Румага керергә мәҗбүр булачагын искәртә. Г.Исхакый Римгә килү генә түгел, хәтта Рим папасына Русия мөселманнарының авыр хәлен бәян иткән мөрәҗәгать тә тапшыра. Шунысы мөһим: югары дәрәҗәдәге бу зиярәт көчле халыкара яңгыраш ала. «Яңа милли юл»ның 1932 елгы 10 нчы санында мондый бер хәбәр бар: «Папа хәзрәтләренең рәсми гәзитенең 17 нче апрель (1932 ел) санында Русия мөселманнарының хәле хакында большевикларны тәнкыйть итеп, бер озын мәкалә нәшер ителде. Бу мәкаләне бик күп италиян һәм башка милләт гәзитләре күчереп басты». Бу төр мәгълүматлар Советлар Берлегенә дә ирешә. «Мәскәүдә чыга торган татарча «Коммунист» гәзитендә Сәгыйдуллин дигән бер егет, бу турыда бер озын мәкалә язып, Гаяз әфәндене «Ул ничек оялмыйча, папага кадәр барган?» — дип ачуланды һәм аңа «милләтче», «динче» дип бик каты тамга басты». «Тифлистә чыга торган «Заря Востока» гәзите бу уңай берлә... Гаяз Исхакыйны «авантюрист» дип атый (11–12 б.).

«...Инкыйраз» авторының корылтайга, Шәрыкка сәяхәте, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, өч ай ярымга сузыла. Алтынчы дистәне ваклап барган Г.Исхакыйның шушы вакыт эчендәге сәфәре, кылган эш-гамәлләре чын мәгънәсендә сокланырлык. (Өстәвенә әле ул берничә көн авырып та ята.) Ә бит бу могтәбәр зат үз шәхесе өчен түгел, ә милләт, киң җәмәгатьчелек, инсаният мәнфәгатьләре өчен йөри, алар өчен тырыша, янакөя. Көндәлек эшләрдән, төрле очрашу-әңгәмәләрдән, лекциячыгышлардан тыш, Г.Исхакый сәфәр вакытында шактый гына мәкаләләр яза, «Яңа милли юл»да гарәп һәм, гомумән, дөнья матбугатында күп кенә материалларын бастыра. Аның үзе ха-

кында да гарәп, төрек, урыс, француз, әрмән, инглиз, алман телләрендә төрле мәгълүматлар нәшер ителеп тора. Мәсәлән, французларның католик рухлы «I Echo de Paris» гәзитендә (1932. — № 29) Г.Исхакыйның корылтайдагы эшчәнлеге яктыртыла һәм гарәп җәмәгатьчелегенә карата аерым тәнкыйть фикерләре әйтелә. Бу мәкалә «гарәп дөньясында шактый шаушуга сәбәп» була, шуңа мөнәсәбәттә күптөрле язмалар дөнья күрә (Яңа милли юл, 1932. — № 4. — 1–2 б.). Кыскасы, бу төр факт-мәгълүматлар Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеген әле тагын да ныграк өйрәнү мөмкинлеген ачык күрсәтеп тора.

Тарихтан узган гасырның 30 нчы елларында ислам дөньясында һәм халыкара җәмәгатьчелектә Русия мөселманнарының хокукларын яклау хәрәкәте хакында безгә теге яки бу дәрәҗәдә мәгълүм иде. Баксаң, бу эшнең башында безнең бөек милләттәшебез Г.Исхакый торган икән. Тагын шунысы да бар: халыкара җәмәгатьчелек басымы астында Мәскәү ислам диненә карата булган сәясәтен төрле юллар белән акларга тырыша. Әмма барып чыкмый. Мәгълүм ки, Кремль «СССРда ислам диненә ireклек, ислам диненә бертөрле дә кысу юк» дигән ялган кәгазьгә кул куйдыртып, бөтен дөньяга тарату максаты белән Риза хәзрәтне Мәскәүгә чакырта. Мөфти исә, мондый ялган кәгазьгә кул куюдан баш тартып: «Ялган сөйләү безнең динемездә юк», — дип җавап бирә һәм Кремльнең динебезгә азатлык бирүен таләп итә. [К.Казанлы. Төрк-татар халкының бөек мөфтие Риза Фәхреддин // Азат Ватан (Мюнхен), 1952. — № 1. — 14 б.]

* * *

Күп кенә әдип-журналистлар кебек, Г.Исхакый да даими рәвештә дип әйтерлек куен дәфтәре алып бара, аңа үзе кирәк дип тапкан эш-гамәлләрен, тәэсирләрен, факт-мәгълүматларны, мөһим детальләрне теркәп бара. «Ислам мәмләкәтләрендә» әсәре дә шундый материалларга нигезләнеп туган. Аннан тыш Г.Исхакый еш кына үзе барасы җирнең (илнең, халыкның, шәһәрнең...) тарихын, үзенчәлекләрен дә алдан ук билгеле бер дәрәҗәдә өйрәнә торган була. Мәсәлән, ул 1933–1935 елларда өч елга якын Японияда, Кытайда була. Әмма бу сәфәргә чыкканчы ук инде Г.Исхакый «Яңа милли юл» журналында «Ерак Шәрык» исемендә мәкаләләр сериясен бастыра. Кыскасы, «Ислам мәмләкәтләрендә» сәяхәтнамәсенең дә фактик нигезе шактый нык, саллы. Автор аның тәүге өлешен Мисырда яза, ә калган өлешен Варшавада төгәлли.

Әйткәнебезчә, Г. Исхакый үз язмасын «Юл истәлекләре» дип атаган. Татар әдәбиятында сәяхәтнамә жанрында әсәрләр

язуның озын тарихы бар. Исмәгыйль Бикмөхәммәд углы, Гали Чокрый, Заһир Бигиев, Фатих Кәрими һәм башкаларның язмалары күпчелек татар укучыларына мәгълүм.

Сәяхәтнамәнең ниндилеге, иң беренче чиратта, авторга, аның позициясенә, талантына, сәфәр максатына бәйле. Сәяхәт вакытында күргән, ишеткән, кичергән нәрсәләр күп була. Ә менә аларны сайлап алу, урнаштыру, бәяләү авторның күңел күзенә, эчке тоемына, рухи тәҗрибәсенә, гомумән, шәхесенә бәйле. «Ислам мәмләкәтләрендә» язмасын укыганда, Г.Исхакыйның эрудициясе, тарихтан һәм сәясәттән яхшы хәбәрдарлыгы, оригиналь фикерләве, тугрылыгы, югары зәвыгы, тәнкыйди карашы ачык сизелеп тора. Ялган, буш әйберләргә аның мөнәсәбәте тискәре. Дәмәшкъта вакытта Г.Исхакый атаклы Өмәвия мәчетенә җомга намазына бара. Әмма ул биредәге вәгазьдән канәгатьсез кала. *«Хотбәсе,* — ди автор, — *искереп беткән бер хотбә; хәзерге әхваль берлә һичбер мөнәсәбәте, бәйләнеше юк»*. Каһирәнең атаклы милли театрындагы «Ләйлә вә Мәҗнүн» спектакле дә Г.Исхакыйда ризасызлык уята. Аның фикеренчә, артистлар уйнау, күрсәтү урынына, сүз сөйләү, сөйләм белән мавыгалар. Бу исә театрның «ибтидаилыгын» («башлангычын», «тәҗрибәсезлеген») күрсәтә. *«Мин,* — ди Г.Исхакый, — *Мисырның театрлары әле безнең татар театрыннан бик күп түбән икән, дигән фикер берлә театрдан чыктым һәм безнең милли труппалар киләчәктә Мисырда нинди зур уңышлар ясый алачакларын уйлап, өйгә борылдым»*.

Якын Көнчыгыш — яһүди, христиан, ислам диннәренең асыл Ватаны, дөнья мәдәниятенең мөһим бер мәркәзе. Г.Исхакыйның бу мәсьәләләргә, мәдәни-тарихи кыйммәтләргә нык игътибар итүе нәкъ әнә шуның белән дә аңлатыла. Авторның «Мәсҗеде Акса», «Әл-Әзһәр», «Къийамә» (Воскресение чиркәве. — *Х.М.*) һәм башка корылмалар, изге урыннар хакындагы мәгълүматлары гаять кызыклы. Әмма шулай да Г.Исхакый тарих, борынгы истәлекләр белән бик мавыкмый. Алар автор өчен, иң беренче чиратта, бүгенгене аңлау, мөһим сәяси мәсьәләләрне төшенү, милли язмышны ачыклау өчен кирәк. Мәсәлән, Византия дәверендә үк төзелгән борынгы бер чиркәүне караганда, Г.Исхакый һәм аның юлдашларының (шул исәптән Муса Бигинең дә) Тула шәһәрендә коелган кыңгырауларга күзләре төшә. Бераздан биредәге биналарның да урыс акчасына төзелүе ачыклана. *«Аларда,* — ди автор, — *безнең халкыбызның да маңгай тирләре белән эшләнгән миллионнарның әрәм булып ятуына ачындык»*.

Кодеста вакытта Г.Исхакый шәһәрне әйләндереп алган «нык», «биек» «койма»га игътибар итә. Кирпечтән корылган бу ныгытманы карар өчен «иң аздан дүрт сәгать вакыт» кирәк. Аны XVI йөздә идарә иткән госманлы солтаны Сөләйман

Кануни төзеткән. «*Бу кoйманы кору өчен,* — ди автор, — *миллионнар-миллионнар акча түгелгән. Аны еллар буе унегермешәр мең кеше эшләгән*». Бу урында Г.Исхакый бик тә мәгънәле, бик тә символик сорау куя: «*Ни өчен төрекнең иң зур падишаһы — мөселманлыкның көчле хәлифәсе — моны эшләткән? Ул вакытта бу көчне, бу материалны, бу акчаны төрек халкының үз файдасына куя алачак бер урын юк идеме? Бар иде! Ул төреклек өчен дә, мөселманлык өчен дә Кодестан кырык мәртәбә әһәмиятле бер урын — Идел буенда урыска каршы корган төрк-татар милләтенең Казан каласы, мөселман өммәтенең христианлыкка каршы корган Казан ханлыгы иде. Ул шул көннәрдә Иван Грозный берлә үзенең барлыгын, иреген саклар өчен канлы сугышта иде... Ул үзенең көче берлә генә урыс агымын, христианлык ташкынын туктата алмавын күргәч, үзенең мәсҗедләрендә исеменә хотбә укыла торган хәлифәсенә — Сөләйман Канунига дин исеменнән ислам байрагын сакларга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән иде... Сөләйман: «Мин, бөтен мөселманнарның хәлифәсе, җир йөзенең солтаны, диңгезләрнең патшасы... Мин андый вак, Казан кебек эшләр берлә вакланыйммы? Минем алдымда зур эшләр тора: Кодесны зур койма белән әйләндерәсе, Крит (атавын) камасы, Венаны мохасарә итәсе бар. Китегез, башны әйләндереп йөрмәгез, мине ваксытмагыз», — дип, Казанның күз яше эчендә булган илчеләрен кире борып җибәргән иде.*

*Аңа инде дүрт йөз елга якын вакыт үтте. Сөләйман Кануниның меңнәрчә-меңнәрчә төрекләрнең канын түгеп, еллар буе сугыштан соң алган Крит атавы бүген Юнанстанның (Грециянең. — Х.М.) яхшы зәйтүн үстерә торган губернасы булды. Кодесның әйләнәсенә миллионнарга төшереп эшләткән кальга (крепость. — Х.М.) арыган каргаларның куныл каркылдый торган җиргә әверелде... Казан нишләде? ...Төрк илләренең сакчысы үтерелде. Урыс ташкыны Казанны гына түгел, бөтен Идел буен басты. Себерне алды, Кырымны таптады. Төркияне Кара диңгезнең бу ягыннан куды... Төркиянең берлеген парчаландырды...*»

Г.Исхакый бу сәяхәтнамәсендә һәм, гомумән, мөһаҗирлек чоры язмаларында төрки, ислам бердәмлеге тарафдары буларак чыгыш ясый, үзара аңлашу, килешү җитмәүнең аянычлы нәтиҗәләргә китерүен искәртә. Бу яктан аның бабизм турындагы фикер-күзәтүләре шактый гыйбрәтле. Автор укучы алдына: «Баблар, Баһауллалар вә башкалар аңлап-аңламыйча ислам дошманнарына корал булмадылармы?» — дигән җитди сорау куя. Бу искәртүнең шактый урынлы һәм җитди икәнлеген тарих кына түгел, соңгы заман чынбарлыгы да раслап тора.

Г.Исхакый, гәрчә ул төрк, мөселман бердәмлеге тарафдары булса да, беркайчан да үзенең татарлыгын, туган Ватанын, Идел-Урал төбәген онытмады. Миллилек аның рухына, канына сеңгән, татар мәнфәгате, татар хөрлеге аның яшәү кыйбласына әверелгән. Сәфәр вакытында Г.Исхакый төрле милләт, төрле катлам, төрле дәрәҗәдәге кешеләр белән очраша, аралаша, үзенең ихтирами, тәнкыйди хисләрен дә бәян итә. Әмма аның өчен иң якыны — үзенең милләттәшләре, ватандашлары. Кая барса да, ул, иң беренче чиратта, алар белән очрашырга, аралашырга омтыла. Каһирәдә яшәүче Хәмзә Таһирбәк, Фәләстиндә гомер кичерүче Габдулла Тимур, Дәмәшкъта төпләнеп калган Миңлелбанат һ.б. — әнә шундыйлардан. (Аларның кайберләре хакында Г.Исхакый «Яңа милли юл»да аерым материаллар да урнаштыра. Мәсәлән, 1932 елгы 10 нчы санда Хәмзә Таһирбәкнең рәсеме бар.) Сәяхәтнамә авторы үз язмасында милләттәшләре турында кызыклы тасвирлар, сюжетлар бирә. Менә Бөгелмә өязеннән чыккан Миңлелбанат «абыстай». Ул инде 38 ел чит-ят җирләрдә. Аның бөтен килеш-килбәтендә, өендә татарлык. «Үзе сөйли, үзе көлә, үзе җылый». «Үз илең түгел шул, куркып кына торабыз», — дип тә куя. Авторның «чәй эчүне онытмаган икәнсез, чәегез бик һәйбәт» диюенә, «абыстай» «онытаммы соң, онытмадым» дип җавап бирә. Шушы уңай белән Г.Исхакый бу сүзләрне яза: «38 ел буе төрек, гарәп мәдәнияте эчендә юарланган бу абыстай(ның) ник утта янмас, суда батмас татар булып калуы мине бик тирән уйларга төшерә иде».

Сәяхәтнамәдә милләттәшләребезнең кайда да югалып, төшеп калмавы, белеме, зирәклеге, тырышлыгы аркасында гарәп дөньясында да җаваплы эшләр башкаруына кат-кат басым ясала. Мәсәлән, Спас өязе Салман авылы хәзрәтенең улы Габдулла әүвәл Җаек-Уральскида, аннан Мисыр мәдрәсәләрендә укый. Бераздан Фәләстиндә дарелмөгаллимне (укытучылар институтын) тәгәлли. Алга таба Лондонда югары белем ала. Хәзер Фәләстиндә укыта; спортчы, җәмәгать эшлеклесе. «Кыяфәте, гадәте берлә, — ди Г.Исхакый, — тәмамән безнең тирәнең мишәре булса да, ана теле ачык Чистай шивәсе булса да, хәзерге көндә гарәп мәдрәсәләрендә гарәпчә әдәбият вә фәсахәт (риторика. — *Х.М.*) дәресләрен өйрәтә...» Мондый милләттәшләребезнең уңганлыгын, эшчәнлеген күреп, сәяхәтнамә авторы үкенеч тә белдереп куя һәм «Өйгә таба» повестенда һәм кайбер башка язмаларында яратып кулланган «өмә», «өмәче» детальләрен дә телгә ала (ягъни, башка илгә, халыкка хезмәт итү). Габдулла әфәнде кебекләрне күздә тотып, Г.Исхакый болай ди: «Безнең Идел буе егетләре кемнәргә өмәгә йөрмиләр. Үз илең булмагач, үз халкың үз ихтыярында булмагач, шулай итеп мәгънәви чегән булып каласың, күрәсең».

Юлъязма авторына Идел-Урал үз милләте өчен нигез, таяныч ноктасы, чагыштыруның төп объекты рәвешендә. Г.Исхакый декабрь башындагы Кодес табигатен «бездәге август ахыры һавасы» белән тиңли. Мисыр җәмигында бер вәгазьче, хатыннарны яманлап, нәсыйхәт сөйли. Г.Исхакый аның сүзләрен әбисе Мәхфүзә һәм әнисенең авыл хатыннарына сөйләгәннәре белән чагыштыра да, кәефе төшә. Аңа вәгазьче тарафыннан мәрхүм әби-әниләренең хатирәләре мыскыл ителә кебек тоела. Бер урында автор үзен «Чистай мишәре» дип тә атый.

Колониаль изелү, чукындыру сәясәте Рәсәйнең күпләгән мөселманнарын башка ислам илләренә күчәргә мәҗбүр иткән. Сәяхәтнамәдә аларның ачы язмышлары хакында дулкынландырырлык юллар бар. Мәгълүм булганча, хәзерге күп кенә гарәп илләре узган гасырның башларына кадәр Госманлы империясе составына керәләр. Милли яктан бигрәк, дини уртаклык хисе көчле була. Бу аеруча мөһаҗир мөселманнарда нык чагыла. Гарәпләр бәйсезлек өчен көрәшкә күтәрелгәч, бирегә күчеп килгән татарлар, чиркәсләр аеруча кыен хәлдә кала. *«Дөнья сугышы вакытында гарәпләр, инглизләр яклы булып, төрекләргә каршы сугыш ачкач, безнекеләр дә төрек саналып, йортлары-җирләре таланып, маллары алынып, бик күбесе үтерелеп, калганнары... лагерьга ябылган була...»* — ди бу хакта Г.Исхакый. Мәккә шәһәрендә яшәүче татарларның башлыгы булган, дингә чын күңелдән бирелгән, туры сүзле, горур табигатьле Гомәр карт язмышы күңелләрне тетрәндерерлек. Төрек-гарәп конфликтында динне барыннан да өстен куйганы өчен ул мал-мөлкәтеннән мәхрүм ителә, үзе, гаиләсе төрмәгә ябыла.

Юлъязма авторы Шәрык татар мәдәни бәйләнешләрына да игътибар итә. Аның фикеренчә, Октябрь инкыйлабына кадәр Якын Көнчыгыштагы уку йортларында (аеруча «Әл-Әзһәр»дә, Бәйрутта) күпләгән татар егетләре белем ала. Мәсәлән, Муса Биги, Петербург имамы Лотфулла Исхакый, «Галия» мөдәррисе Зияэддин Камали, Закир Кадыйри, Габделбарый Баттал Мисырда, Нияз Максудый, Габдулла Сөләйман, Кәмал Локман һ.б. Бәйрутта укый. Шулар аркылы татар дөньясына Шәрык казанышлары, өлешчә Аурупа фикерләре дә керә. Үз чиратында татарлар да гарәпләргә аерым рухи кыйммәтләрне җиткерәләр.

Г.Исхакыйның «Юл истәлекләре»ндә тарихи-иҗтимагый, мәдәни, сәяси яктан башка төр мөһим факт-мәгълүматлар да бар. Автор Шәрыкның кайбер музейларын, күренекле шәхесләрен телгә ала, аерым гореф-гадәтләргә, милли үзенчәлекләргә дә туктала. Мәсәлән, мисырлылар сүздә «зурлыкны-арттыруны бик яраталар». Моның сәбәбе аларның олы тарихы, зур-зур пирамидаларга ия булуы белән дә аңлатыла икән.

Якын Көнчыгыш — яһүдиләрнең дә асыл ватаны. Дөньяның төрле почмакларына сибелгән бу халык узган гасырның 20–30 нчы елларында кабат бирегә кайта башлый: йортлар сала, сәүдә итә... Сәяхәтнамәдә дә бу хакта шактый мәгълүматлар бар. Авторга ун ел элек салына башлаган 40 мең халыклы Тель-Авив шәһәре авыл төсле генә күренә. *«Ул,* — ди автор, — *Казанның Яңа Бистәсе төсле дә булып күренә, Бишбалта кебек тә булгалап куя».* (Әгәр дә Г.Исхакый бүгенге Израильне, Тель-Авивларны күрсә, нәрсә дияр иде икән?!) Автор Сүриядә 35 мең чамасы чиркәс, 100 меңгә якын әрмән яшәгәнен искәртә. Алар төрек, гарәп телләрен белсәләр дә, үз телләрендә дә гәзитләр чыгаралар. Бер әрмән гәзите Г.Исхакыйның күп кенә чыгышларын бастырып чыгара. Бер үк дәүләт — Госманлы мәмләкәте составында яшәү нәтиҗәсендә күпләгән гарәпләр һәм башка кавемнәр дә, нигездә, төрек телен белә. Аерым гарәп дәүләтләре төзелгәч тә әле төрек теле тормышта киң кулланылышын дәвам итә. Г.Исхакый да күбрәк шул телдә, аерым очракларда французча сөйли, аралаша.

«...Инкыйраз» авторы гомере буе диярлек күзәтү-тикшерүләр астында яши. Сәяхәтнамәдә дә бу берничә урында сизелә. Мәсәлән, пароходка утырыр алдыннан да ул җентекле тикшерүгә дучар була. *«Кырык төрле сөальләр берлә башымны катырдылар. Соңыннан үзләренең гизле (яшерен. — Х.М.) бүлмәләренә кереп бик озак тоткач кына... виза сукты-лар»,* — ди автор. Кунакханәдә яшәгәндә дә «полис»лар аның «хәлен белеп» тора.

«Ислам мәмләкәтләрендә» язмасы — төрле башлангычларны үз эченә алган ядкәр. Анда бәян итү-хикәяләү дә, тасвир-сурәтләү дә, аналитик фикерләү дә, публицистик башлангыч та бар. Мәсәлән, Г.Исхакыйның Каһирәдә сөйләгән лекция тексты тирән эчтәлеге белән генә түгел, ә форма-шәкеле ягыннан да ораторлык-публицистик стильнең күркәм бер үрнәге. Язмада табигать күренешләре дә (мәсәлән, «Үле диңгез»не тасвирлау, тауларны, бакчаларны сурәтләү) бар. Текстка табигый рәвештә диалог-бәхәс тә, төрле уйлану-чигенешләр дә кереп китә. Боларның һәммәсен автор образы, аның көчле ихтыяры бербөтен итеп тота.

Корылтайның үзе хакында Г.Исхакыйның янә берничә язмасы бар. Мөгаен, шуңа күрәдер автор үз сәяхәтнамәсендә корылтайның үзенә чагыштырмача азрак урын бирә.

«Ислам мәмләкәтләрендә» язмасының тел-стилендә аерым кытыршылыклар (бер үк сүзләрне кабатлау; гарәп, төрек алынмаларын күбрәк куллану, хәтта аерым юлларын шул телләрдә китерү һ.б.) очрый. Бу авторның күп һәм ашыгыбрак язуы, текстның, күрәсең, кайчак редакцияләнмичә генә басылуы белән дә аңлатыла. Техник хаталар да бар.

Сәяхәтнамә татар укучысына адресланган һәм ул тел-стиле, эчтәлеге белән укучыны җәлеп итәрлек.

Тагын бер моментны искәртү зарури: сәяхәтнамә «Яңа милли юл»да басылган. Яңа мәгълүматлар бу журналның татар укучылары арасында гына түгел, башка төбәкләрдә дә билгеле бер дәрәҗәдә таралуын күрсәтәләр. Андагы аерым язмалар гарәп, төрек, француз, алман, поляк, урыс телләренә дә күчереп басылган. Мәсәлән, Г.Исхакыйның «Яңа милли юл»дагы (1932. — № 4. — 1–6 б.) «Ислам дөньясы һәм большевиклар» исемле мәкаләсе, Габдулла Тимур тарафыннан гарәпчәгә тәрҗемә ителеп, Кодеста чыга торган «Әл-җәмигату-л-гарәбия»-дә (дүрт санында) һәм янә берничә гәзиттә дөнья күрә.

«Ислам мәмләкәтләрендә» юлъязмасының, бер яктан, тарихны, элеккеге тормышны, мәдәниятне танып белү ягыннан татар өчен генә түгел, башка халыклар өчен дә әһәмияте зур. Икенче яктан, бу ядкәр — әдипнең тормышын, күпкырлы эшчәнлеген өйрәнүдә дә кыйммәтле чыганак. Аны укыганда, Гаяз Исхакыйның шәхесе тагын да олылана, тулылана, җанлана төшә.

* * *

Әйткәнебезчә, «Ислам мәмләкәтләрендә» сәяхәтнамәсе гарәп графикасында элеккеге язылыш кагыйдәләре белән басылган. Аны хәзерге язуга күчергәндә, нигездә, бу үзенчәлекләр сакланды. Аерым үзгәрешләр, кагыйдә буларак, хосусый характерда гына. Тиешле шәрех-аңлатмалар җәяләр эчендә бирелде. Аерым сүзләрнең, атамаларның язылышында, аңлатылышында кайбер төгәлсезлекләрнең китүе дә табигый. Болар өчен укучыдан алдан ук гафу үтенәбез.

*2003*

## Ислам мәмләкәтләрендә*

*Гаяз Исхакый*

30 нчы ноябрьнең (ягъни 1931 елның) иртәсендә, минем юлга чыгуымның сигезенче көнендә, Яффа шәһәре күренде: матур гына, зур гына бер мөселман, гарәп шәһәре. Пароход лиманга (портка) янәшә (туктый) алмады, диңгез эчендә тимер (якорь) салды. Ул да булмады, бөтен тарафтан акча алыштыручы, әфлисун сатучы, христианнарның тәреләрен, яһүди-

* «Яңа милли юл» (Берлин). — 1932. — 2–8, 10, 12 нче саннар; 1933. — 1, 3, 5, 7, 8, 9, 10, 12 нче саннар.

ләрнең арзи (алтын) мөкаддәс ташын, мөселманнарның тәсбихен сата торган төрле милләтнең төрле телендә дүрт-биш сүз мыгырдый торган сатучылар пароходны чолгап алды. Төрле телдә кычкырыш, бакырыш китте. Пароход өсте берничә минутка чегән табуры төсен алды. Без, Яффада чыгучылар, полисәләрне (полицейскийларны) көтәргә тотындык. Бер-ике сәгать вакыт кичкәч кенә, полисәләр керде. Болар барысы да инглизләр; араларында гарәп юк иде. Алар берлә бергә, бик күп иттереп, төрле яһүди җәмгыятьләрнең каршы алучылары, әллә никадәр хаммаллар (йөк ташучылар) пароходны тутырды. Яһүдиләр үз кешеләренә әйберләрен бирделәр. Безне каршы алучы күренми иде.

Мин, бер хаммалга әйберләремне тапшырып, паспорт карарга киттем. Ләкин анда сыйныфлап караганга, миңа бик озак көтәргә тугры килде. Мең бәла берлә паспортымны эшләтеп бетергәч, каек берлә гүмрүккә (таможняга) киттем. Анда чанталарның (сумкаларның) исән-сау икәнен күреп сөенергә өлгермәдем, «карантинга!» диделәр вә бик күп кеше көтә торган бер җиргә тыктылар. Мин безнең белән бергә килгән юлчыларның һичбер көтмичә, карантинга китүләрен күрү берлә, шул хәлдән файдаланырга теләп, гүмрүктәге кеченә полисәләр берлә орыша, талаша доктор ишегенә кадәр килдем. Андагы сакчы мине җибәрми, төрле сүзләр берлә алдаштыра, башкаларны берсе артыннан берсе җибәрә генә иде. Мин, тагын талашып, докторның алдына килеп бастым. Монда ни өчендер юлчыларны доктордан каратып үткәрү дигән бер юл тотылган һәм бу да докторның исем-фамилияне, паспортны язып алу рәвешенә сугылган. Доктор нә исәнлекне сорый, нә карый. Бу полисәнең яшерен тикшерүчеме, әллә башка берәр кирәге бармы — белмәдем. Ләкин моның исәнлек-саулык берлә һичбер мөнәсәбәте юк иде.

Доктор миңа күзен акайтып карады, читтән килеп торган яһүдиләрне каравында дәвам итте, алар да бер-бер артлы кереп, эшләрен бетереп чыгалар иде. Мин дә докторның алдына паспортымны тутырып: «Минем кизүем (чиратым)», — дидем. Паспортымны алды. Карашырга, маташтырырга тотынды. Миннән элек үткәннәргә моны эшләмәгән иде. Мин: «Полис карады, зәхмәт итмәгез», — дидем. Нәрсәдер инглизчә мыгырдады. «Французча сөйлим», — дидем. Авырсынып кына әлләниләр язарга тотынды. Әллә нинди мәгънәсез сораулар бирде. Аның мөгамәләне авырайту юлын тотканы күренеп тора иде. Шул арада булмады, бер чалмалы, бер фәсле ике мөселман килеп керделәр дә: «Монда Гаяз Исхакый бәк юкмы?» — дип, төрекчә сорадылар. Мин дә үземне таныттым. Күрештек. «Без мөфти тарафыннан сезне каршы алырга чыктык. Бер сәгатьтән бирле эзлибез. Таба алмыйбыз», — диделәр. Доктор да язганнарын оныт-

ты. Бик тиз генә паспортны бирде. «Боерың, боерың! — дип, төрекчәгә күчте. — Юлыгыз мөбарәк булсын, фәлән!» — диде. Минем берлә бергә килгән юлчылар да бердән минем корылтайга килүче икәнемне аңлап алдылар. Мин пароходта килгәндә «ни булыр, ни булмас», дип үземне Мисырга баручы мөхәррир дип кенә таныткан идем. Һәм алар берлә сионизм Кодес (Г.Исхакый бу атаманы Коддес рәвешендә яза. Иерусалим) мәсьәләләре турында бик күп сөйләшкән, дөресрәге, аларны сөйләткән идем. Шуның өчен минем бердән мөхәррирлегемнән вәкил булып чыгуым алар өчен көтелмичәрәк килеп чыкты, аптыратты. Ләкин минем үземнең моны уйлап торырга вакытым да, теләгем дә юк иде. Мине гүмрүктән (таможнядан) җил кебек, чанталарымны да ачтырмыйча алып чыгып, безне көтеп торган автомобильгә утыртып, шәһәргә алып киттеләр.

Мин каршы алучыларга: «Мин Яффада берәр көн калып, Кодеска барам. Мине бер үтәлгә (отельгә) иңдерегез», — дисәм дә, тыңлаучы булмады. Бер мөселманның өенә китерделәр. Анда бик күп көтүчеләр мине «әһлән вә сәһлән» (хуш килдегез, рәхим итегез!) дип каршы алдылар. Бу Яффаның мәшһүр бер ишаннарының балаларыннан әл-Лачаниның (әл-Лаҗаниның) өе икән. Анда пароходның беренче сыйныфында күргән бер азәрине таптым. Ул Зыяэддин Табатаи исемендә, Иранның иске назирәләреннән (түрәләреннән) һәм Качар фамилиясе берлә тартышучылардан, соңыннан Ризаҗан Пәһләви шаһ булгач, мәмләкәтеннән куылган бер Иран олугларыннан икән. Сөйләштек, таныштык. Чәйдән соң: «Боерың!» — диделәр. «Кая барабыз, миңа бер үтәлгә төшәргә кирәк. Мин монда бер көн калам», — дидем. Мөфти Хаҗи Әмин әл-Хөсәйнинең хәзерге хезмәт иптәшләреннән булган, элеккеге Әрдүн (Ордүн, Иордан) хөкүмәтенең назире, Төркия гаскәрендә орду (хәрби) мөфтисе булган әш-шәйх Мозаффар: «Хәзер Кодеска барыйк, автомобильләр хәзер. Аннан соң монда килеп булыр, ара якын», — диде. Мин дә, бәлки, шулай дөрестер, — дип разый булдым. Автомобильләр берлә Кодеска юнәлдек.

Яффа — алтмыш меңле мөселман шәһәре. Сәүдәле, бай шәһәр. Аның күршесендә яһүдләр үзләренә Тел-Абиб исемендә бер шәһәр салганнар һәм аны ун ел эчендә кырык меңле бер шәһәргә җиткезгәннәр. Безнең юлыбыз бу ике шәһәрнең арасыннан китә иде. Гарәп шәһәре искедән салынган — иске ысул биналар, яһүдләр шәһәре соңгы ысулда салынган Аурупа шәһәрләре төсен бирә иде. Юлыбыз ялт иткән асфальт. Тирәюньне әфлисун бакчалары тоткан. Бер-ике атнадан әфлисун өлгерә торган чак булганга, бөтен агачлар яшелле-сарылы әфлисуннар берлә бизәнгәннәр. Һава бездәге август ахыры һавалары. Табигать таулы, ташлы. Бу таулык, ташлык арасындагы бакчалар адәм баласының бик күп тырышуы аркасында

гына үсә алганнар. Юлның яхшылыгын күреп: «Моны инглизләр эшләдеме?» — дидем. «Юк, төрекләрдән калма (калган). Элек тә бар иде. Сугыш вакытында төрекләр шул хәлгә куйдылар», — диделәр. Юлда автомобильләр, өсләренә капчыклар йөкләнгән ишәкләр, төяләрне (дөяләрне), арбаларга җигелгән үгезләрне очратырга, куып җитеп, үтеп китәргә тугры килә иде. Боларны алып баручы юлчыларның күбесе башларына безнең кәләпүш күк бер нәрсә, йә бер иске фәс кигән, өсләренә тубыкларына кадәр төшереп кигән бер ситса күлмәк кигән яланаяклы гарәпләр иде. Хатыннарның күпчелеге һичнәрсә берлә йөзләрен капламаган, башларын, сачләрен яулык берлә бәйләп, өсләренә бер кара капут (кием; җилән) кигәннәр иде. Аларның муеннарына бик күп зиннәтләр тагылган кебек, яланаякларына да, тубыктан аз гына югары, беләзекләр киелгән иде. Йөзләре-битләре матурлыктан шактый озак (ерак), өс-башлары шактый керле иде.

Без сәгать ярымнар чамасы юлда калып, тауларны бер менеп, бер төшеп, алтмыш километрлык араны үтеп, Кодес Шәрифкә килеп җиттек. Монда мине бер отельгә төшерделәр. Фәләстин мөселманнарның баш мөфтисе корылтай җыюда зур хезмәт күрсәткән Хаҗи Әмин Хөсәйни отельгә килеп зиярәт итте. Мин дә, җыенып, киенеп, мондагы мөселманнарның милли идарәләре булган җәмгыятел-исламда мөфтине зиярәт иттем. Анда корылтайны хәзерләү һәйәтенең (комиссиясенең) бик күп әгъзалары берлә таныштым. Аларның бик күбесе төрекчә сөйләшә һәм төрек вакытында зур-зур мәэмүриятләрдә (рәсми урыннарда) булган кешеләр иде. Шунда ук Нәкышбәнди (XIV йөздә Урта Азиядә яшәгән атаклы суфый) ханәкасенең (йортының) шәехе Ягъкуб әфәнде берлә дә таныштым. Ул гарәпләшкән бер төркестанлы булса да, симасын (төс-кыяфәтен) һәм телен югалтмаган, мосафирчылыгын да саклаган иде. Аның берлә бергәләп, Мәсҗеде Аксаны (Иерусалимдагы бик борынгы, атаклы мәчет), Хәрәме Шәрифне карарга киттек. Хәрәме Шәриф — мөселманнар өчен бер мөкаддәс җир. Ул дүрт почмаклы биек бер таш койма берлә әйләндереп алынган. Аның эче — мөселманнар өчен мөкаддәс булган 17 дисәтинә зурлыгында бер мәйдан. Мәйдан уртасында сигез почмаклы иттереп салынган Җәмигъ әс-сахра (Коббәт әс-сахра) исемендә бер җәмигъ (мәчет) бар. Бу җәмигъ бу көндә дә Мәлик бине Мәрван (VIII гасыр) тарафыннан салынган рәвешендә саклана. Җәмигъның исеме аның эчендәге зур коббә (гарәпчәсе: әс-сахра) ташыннан килә икән. Ул таш Ибраһим галәйһиссәлам заманында өстендә корбан чала торган бер таш булган. Вакыт үтә-үтә ул таш, тарихлашып, бик күп дин әһеленә мөкаддәсләшкән. Исламның беренче вакытларында мөселманнарның кыйблалары да менә шул Хәрәме Шәрифкә,

шул ташка таба булган. Мигъраҗ кичәсендә Мөхәммәд галәйһиссәлам, Мәсҗед әл-Хәрәмдан Мәсҗед әл-Аксага килеп, намаз укып, мигъраҗга ашканда, шул таш өстеннән ашкан. Менә шуңа күрә бу таш Ислам дөньясында зур мөкаддәс ташлардан санала.

Христианнарда бу тарихи таш өстендә Хәзрәте Гайсә утырганмы, Хәзрәти Мәрьям ятканмы дигән бер хикәя сөйлиләр. Алар өчен дә бу җир мөкаддәс. Яһүдиләр өчен дә ул бер изге таш. Әһле салиб (тәре йөртүчеләр) Кодесны алган чакта, алар бу ташны бер тимер рәшәткә берлә әйләндереп алганнар да аның өстен бер пәрдә берлә каплаганнар. Солтан Сәлахеддин әһле салибне куып чыгарып, Кодес шәһәрен мөселманнар кулына кайтаргач та, рәшәткәне сүттермәгән. Ул хәзер дә шул хәлендә тора. Бүген олуг бәйрәмнәрдә аның эчендә хатыннар намаз укыйлар. Мәсҗед бик матур иттереп эшләтелгән. Аның бизәкләре бик күп. Тәрәзәләре искиткеч матур. Зиннәтләрнең соңгырак дәвердәгеләре төрек солтаннары тарафыннан ясалган. Диварларга бик күп аяте хәдисләр язылган. Боларны солтан Габделхәмид алтынлаткан. Монда төрекләрнең бу мөкаддәс җирләргә иткән хезмәтләрен адым саен очратып торасың. Җәмигъның төрле төстәге пыялалардан эшләнгән бик матур тәрәзләренең бик тарихилары Мәлик бине Мәрван һәм солтан Сәлахеддиннән калган булса да, аларның да күбесе төрек солтаннары тарафыннан төзәттерелгәннәр. Бу җәмигъ Истанбулдагы Айа Суфия һәм Солтан Әхмәд (мәчетләре) кебек зур җәмигълардан түгел. Ләкин ул тарихи, мөкаддәс һәм бик иске бина булганга, бик кыйммәтле бер җәмигъ. Соңгы елларда мөфти Әмин әл-Хөсәйни, мөселманнардан, бигрәк тә Һиндстаннан бик күп акча җыеп, аның соңгы җир тетрәүләрдә какшаган баганаларын алыштырган. Җимерелергә торган җирләрен төзәттергән. Бозылган зиннәтләрен тутырган. Бу эштә Кодес мөселманнарына төрек мигъмарларыннан (архитекторларыннан) Кәмал бәкнең зур хезмәте тигән. Кутаһия (Төркиядәге шәһәр) һәм Барсадан (Кече Азиядәге кала) китерелгән төрек осталары бу эшләрне эшләү берлә калмаганнар, алар шундый ташларны ясарга, шуларны эшләргә Кодес мөселманнарын да өйрәтеп киткәннәр.

Кодестагы икенче изге җәмигъ — Мәсҗед әл-Акса дип атала торган зур бер җәмигъ. Ул Хәрәмнең бер почмагында тора. Аны хәзрәте Гомәр килеп салган. Ул җәмигъ кечерәк булганга, хәзер аның янына кушып бер зур мәсҗед салганнар. Хәзрәте Гомәрнең мәсҗеде анда бер кечкенә бүлмә генә булып калган. Монда зур бәйрәм намазлары укыла. Анда ун-унбишләп мең кеше сыярлык урын бар. Бу җәмигъны да төзәтеп яталар. Бу мәсҗедләрне карап йөргәндә, аны күрсәтеп йөрүчеләр: «Бу җирдә Ибраһим галәйһиссәлам намаз укыган, бу

җирдә Исмәгыйль, бу җирдә Муса, бу җирдә фәлән пәйгамбәр намаз укыган», — дип, аерым-аерым урыннарны күрсәтәләр. Бу сүзләр караучыларда «әллә бер вакытларны бу пәйгамбәрләр шунда җыелып, бер корылтай ясаганнармы икән?» дигән бер фикер калдыра.

Хәрәме Шәрифнең бер борылышында, ике дивар арасында, яһүдиләрнең дә бер мөкаддәс җирләре бар. Аңа мөселманнар Боракел-шәриф диләр. Аурупада ул Еглау дивары дип мәгъруф. Диварларының берсендә яһүди язуы берлә язылган берничә ташлар бар. Бу ташлар Сөләйман сараеның, яһүди дәүләтенең иң куәтле чагыннан калган ташлар, имеш. Ул дивар мөселман вакыфлары уртасында. Ләкин бик иске дәверләрдән бирле монда яһүдиләрнең килеп гыйбадәт итүләренә, бигрәк тә аларның иске тарихларын сагынып, «Тәүрат» укып еглауларына мөселман падишаһлары һәрвакыт рөхсәт итә торган булганнар; дөнья сугышыннан соң инглизләр Фәләстиндә яһүдиләргә бер «милли йорт» ясарга сүз биреп, монда меңнәрчә сионистлар күчеп килеп, бу җирләрне яһүдиләштерергә башлагач та, бу хәл шул рәвештә барган. Ләкин яһүдиләр акрын-акрын аны үз кулларына кертергә, башта пәрдәләр берлә, бара-бара такта коймалар берлә аерырга, ахырдан аңа бер синагог (гыйбадәтханә) төсе бирергә тели башлаганнар. Ләкин моңа каршы бер Кодес мөселманнары гына түгел, бөтендөнья мөселманнары каршы төшкәннәр. 1930 елда бу мәсьәлә, бик зур тавышлардан соң, мөселманнар файдасына хәл ителде. Андагы пәрдәләр, коймалар сүтелде. Бу җирләрнең мөселманнарныкы булуы мәхкәмә (хөкем; суд) тарафыннан тәсдыйк ителде (расланды). Ләкин моннан соң да мөселманнар яһүдиләрнең бу җиргә килеп гыйбадәт итүләренә каршылык кылмаганнар. Без карап йөргәндә дә, берничә яһүди Тәүрат укып торалар һәм берничә яһүди хатыны, йөзләрен ташка сөртеп, үкереп-үкереп еглыйлар иде. Бу җирдән ерак түгел ике инглиз полисе, ул-бу чыкмасын өчен, карап торалар. (Бу юллардан соң Җәмигъ әс-сахра мәчетенең рәсеме бирелгән.) Моннан башка мөкаддәс җирләрнең иң зурысы христиан дөньясының изге саналган Къийамә (Воскресение. — *Г.И.*) чиркәве. Ул бер тарихи бина. Ул Бизанс (Византия) падишаһларыннан Константин дәверендә Елина тарафыннан салынган, эчендә бик күп баганалы, бераз Айа Суфия җәмигына охшаган бер чиркәү. Монда, христианнарның ышануынча, Гайсә галәйһиссәлам күмелгән. Шундагы бер җирне аның кабере дип күрсәтәләр. Ул җир чиркәү эчендә, ләкин бер төрбә рәвешендә. Өстенә бик күп кандилләр (люстралар; яктырткычлар) асылган. Анда һәрбер мәзһәбнең аеры-аеры кандилләре бар икән. Бу кандилләр мәзһәб кенә түгел, милләт аермасы берлә дә аерылганга охшый. Бу төрбәне саклау эше христиан гарәпләре кулында икән. Чир-

кәүнең эче берничәгә бүленгән. Бер зур гына җире — католикларныкы, берсе — румнарныкы, бер почмагы — әрмәннәрнеке, берсе — гарәпләрнеке. Һәм алар аерым-аерым гыйбадәт кылалар, бу җирләрне аерым-аерым саклыйлар. Аның кыңгыраулары да бүленгән. Монда бернәрсә күзгә ташлана: саннары ул чаклы күп булмаган румнар берлә әрмәннәрнең чиркәүдәге урыннары башкаларныкына караганда бик күп зур. Моның сәбәбе шул икән: элек заманнарда мондагы урын өчен бик зур низаглар, канлы сугышлар булган. Шул эшләрдә хәкем (хөкем чыгаручы) булып төрек хөкүмәте эшкә катыша торган булган. Румнар, әрмәннәр һәм христиан гарәпләр Төркия тәбгасе (буйсынуында) булганга, ул аларны яклый төшә торган булган икән. Шуңар күрә аларның урыннары да зуррак икән. Чиркәү бик искергән, дивар ташлары купкалаган. Бер җир тетрәүдә аның бер зур гөмбәзе җимерелеп тә төшкән. Тагын бер шундый тетрәү булса, аның бөтенләй җимерелүе дә бик якын. Без шундагы папаслардан (поплардан) аның ни өчен төзәтелмәвен сорадык. Алар «төзәтү өчен бөтен мәзһәбләр бер фикергә килергә кирәк. Ә һәрбер мәзһәб үзенә зур эшне алырга тели. Шуңар күрә шулай кала бирә: төрекләр заманында яхшырак иде. Алар мөселман булганга, безнең арадагы низагларны битараф хәл итә алалар иде, төзәтергә кирәк булганда, солтаннар безнең бер фикергә килүебезне көтмичәрәк төзәттерә иделәр. «Бүгенге хәкем булырга тиешле инглизләр үзләре дә христиан булганга, аларны бер мәзһәб тә кабул итми», — диделәр. Ләкин озын моназарәләрдән (бәхәсләрдән) соң инглизләр дә төрек солтаннарының юлын тотканнар. Җир тетрәүдән соң җимерелгән гөмбәзне төзәттерергә керешкәннәр. Бу чиркәүдә христианнар өчен бик күп мөкаддәс булган әйберләр бар. Ләкин минем исемне җибәргән нәрсә мәрмәрдән ясалган Хәзрәти Мәрьямнең бер һәйкәле булды. Христиан падишаһлары аңа шулчаклы күп энҗе, гәүһәр һәм алтын зиннәтләр бүләк иткәннәр, аларны тагарга түгел, янына куярга да урын калмаган.

Бу чиркәү янында «Гомәр җәмигы» дигән бер кечкенә мәсҗед бар. Бу бик тирән мәгънәле бер тарихи мәсҗед икән. Ислам гаскәре Кодесны алгач, Гомәр (585–644 елларда яши. Икенче хәлиф) шәһәрне зиярәткә (карарга) килгән. Ул Къийамә чиркәвен караган һәм аны христианнар малы булып калырга тиеш дип кулыннан кәгазь биргән. Папаслар берлә сөйләшкәндә, намаз вакыты җиткән. Гомәр намаз укырга теләгәч, папаслар, бер палас китереп: «Йә, мөселманнарның хәлифәсе, шунда намаз укы. Бу Алла йорты!»— дигәннәр. Гомәр: «Мин монда намаз укысам, киләчәктә мөселманнар, монда хәлифә намаз укыды дип, чиркәүне сезнең кулыгыздан алу ихтималлары бар. Андый, минем сүземне боза торган бер эш киләчәк-

тә булмасын өчен, монда намаз укуым муафикъ түгел», — дип, чиркәү янындагы бер буш җирдә намаз укыган. Соңра мөселманнар бу җиргә бер мәсҗед салганнар. Ул Хәзрәте Гомәрнең акыллылыгын һәм тугрылыгын күрсәтә торган һаман бер җанлы дәлил булып тора. «Къийамә» чиркәвенең ачкычы әле дә Гомәр тапшырган бер мөселман гаиләсендә тора икән. Бүгенге көндә дә шул гаилә чиркәүне ачып яба икән. Инглизләр Кодесны алгач, бу ачкыч мәсьәләсе тагы күтәрелгән. Христиан дөньясының бер мөкаддәс чиркәвенең ачкычы бер мөселман кулында тору монасиб түгел, дигәннәр. Алырга теләгәннәр. Ләкин ачкычның кем кулында булуы турында тагын бик зур низаг чыккан. Һәр мәзһәб ачкычны үзенә алырга теләгән. Шуңа күрә ул мәсьәлә тагын искечә калдырылган. Чиркәү эчендә, чиркәүнең вакыфларына тимәү турында Гомәрнең кулы берлә язылган кәгазь дә саклана икән.

Кодеста болардан башка да бик күп изге җирләр бар. Тик болары шуларның иң зурлары гына. Монда урысларның чиркәүләре, үтәлләре (кунак йортлары) һәм вакыфлары да бар. Ялгыз вакыфларының гына бүгенге килере ике йөз мең алтын сум икән. Монда хәзерге көндә дүрт йөзләп монах һәм кайта алмыйча калган бераз урыс шуны ашап яталар. Элек монда һәр ел егерме мең урыс зиярәтчесе (паломнигы) килә торган. Алар монда миллионнарча акча калдыра торган булганнар. Русия мөселманнарыннан монда югарыда сөйләнгән Нәкышбәнди завиясе (почмагы; тәкиясе) генә бар. Аның да вакыфы (фонды) күп түгел. Ул Русиядән килгән мөселманнарга мосафирханәлек хезмәтен итә килә. Анда унбиш-егермегә якын хаҗга килеп, кайта алмыйча калган һәм Русиядән качып чыккан төркестанлылар яшәп торалар. Аларның кечкенә кәсепләре дә бар. Күбесе пычак кайраучылыкны үзләренә һөнәр итеп алганнар. Алар мине туганнары кебек каршы алдылар. Корылтайдагы эшебезне зур дикъкать берлә тәгъкыйб итәләр (күзәтәләр).

Корылтай ябылуның икенче көнендә без мондагы мөстәкыйль бер мәмләкәт саналган Шәркый Эрдүнгә (Шәркул–Ордун–Трансиордания) барырга йөрибез. Анда берничә мең мөһаҗирләр яшиләр. Аларның кайберләрен без корылтайда күрдек, кайберләре үзләре килеп күрештеләр. Бу мәмләкәт христиан тарихында бик мәшһүр Эрдүн (Иордан. — *Г.И.*) елгасының көнчыгышында кечкенә бер җир. Ул төрекләр вакытында бер мөтәсаррифлык (вилаят; төбәк) кенә булган. Хәзер ярым мөстәкыйль бер мәмләкәт булып, Мәккәи Мөкәррәмә шәрифе әмир Хөсәеннең зур баласы әмир Габдуллага бирелгән. Дүрт йөз мең чамасы халкы булып, күпчелеге гарәп. Аның ярты миллион инглиз лирасы килере бар. Зур шәһәре Гамман. Бу мәмләкәтнең иң зур байлыгы — Лут күле (Җансыз диңгез). Бу күлдә бик күптөрле, һөнәр сәнәгатендә кирәкле булган тоз-

лар, мәгъдәннәр чыга. Төрекләр заманында бу күл шулай буш яткан. Хәзер бер инглиз компаниясе аны эшләтә башлаган. Күл буена кечкенә-кечкенә фабрикалар, лабораторияләр салдырган. Мәгъдәннәрне, тозларны чыгарырга тотынган. Шундук (шунда ук) коену җирләре эшләнгән. Без барган чакта декабрьнең яртылары булса да, әле читтән килгән бик күп кешеләр коену киемнәрендә су буенда чабышып, уйнап йөриләр иде. Суы да җылы иде. Ләкин суның гаҗәп бер төсе һәм һичбер су тавышына охшамаган бер тавышы бар. Яр буена дулкынның бәрелүеннән бик күп ак күбекләр җыелган. Күлнең өстендә һичбер кош-корт юк. Эчендә дә балык, бака кебек һичбер җан иясе дә яшәми. Ләкин үзенең суы коену өчен бик файдалы, имеш. Коену киемнәребез булмаганга, без коена алмадык. Йөзебезне, кулыбызны юдык. Авызыбызны чайкадык. Ләкин тәмсез тәме авыздан сәгатьләр буе китмәде. Күл бик бай булса да, әле инглизләр дә аның бөтен байлыгын файдалана башламаганнар икән.

Вакытында автомобильчебез (шоферыбыз) килмәгәнгә, вакыт та тар булганга, без Гамманга кадәр бара алмадык. Көнебезне Кодес тирәсендәге тарихи һәм изге саналган җирләрне карарга сарыф иттек. Беренче иттереп Хәлил әр-Рахман дигән бер шәһәргә киттек. Ул Кодестан утыз чакрымнар ераклыкта бер авыл. Халкы мөселман. Бу шәһәрне Ибраһим галәйһиссәлам хатыны Сараны күмәр өчен сатып алган һәм соңыннан Ибраһим пәйгамбәрнең якын нәселен зираты булган урын янына корылган. Тарихта да, Коръәндә дә Ибраһим галәйһиссәламнең кушымта аты «Хәлил әр-Рахман» булганга, бу шәһәргә дә шул исем бирелгән. Бу зиратлыкта Ибраһим галәйһиссәлам үзе, хатыны Сара, улы Исхак, аның улы Ягъкуб, аның улы Йосыф торган кебек, бер хикәя-легенда гына түгел, чынлап та зиратлар. Аларның өстенә бер зур мәсҗед салынган, зиратлар, тимер бармаклар берлә әйләндерелгән көенчә, мәсҗед эчендә калганнар. Зиратлар зур бер таш өстенә эшләнгән булганнар. Ташларның астын тарих эзләүче җәмгыятьләр казып яталар икән. Безне аларның эченә кертмәделәр. Мәсҗед зур. Төрле җирдә карилар (укучылар) Коръән укып утыралар. Мәсҗедне күрсәтеп йөртүчеләр аның тарихи якларын сөйләп аңлаталар. Ләкин бу мәсҗеднең янында әллә никадәр теләнчеләр җыелган. Һичбер ирек бирмичә теләнәләр. Күрсәтеп йөрүче дә тарихи яклардан күбрәк әкият тарафынарак сүзне бора, янындагы кешенең кем булганын тикшермәстән, үзе белгән бөтен әүлияларны шунда җыелган итеп күрсәтергә тырыша. Тарихны белгән кешегә бу бик начар тәэсир калдыра. Мәсҗед эчендәге төрле хәерчеләр: «Укыган вирдемне (догамны) синең хисапка, Хәзрәте Ибраһимга багышладым. Аның кебек бала-чагаң күп булсын. Укыган ясин шәрифне Хәзрәте

Йосыфка багышлыйм. Бала-чагаң аның кебек матур булсын, падишаһ булсын», — кебек вак сату-алулар бик эчне пошыра, һичбер төрле иттереп дикъкатьне теләгән нәрсәгә борырга ирек бирмиләр. Бигрәк тә Муса әфәнде (Муса Биги) берлә безнең икебезнең башларыбыздагы бүрекләр бөтен хәерченең күз алдына, сугыштан элек сирәк кенә килеп зиярәт итә торган татар байларын хәтерләтте һәм безне Әхмәд бай [Хөсәенов (1837–1906) — атаклы татар сәүдәгәре берлә Хәсән Акчурин (1855–1916) — татарның эре фабриканты] дип хисапланды булырга кирәк. Алар безнең бөтен ягыбызны сырып алып, әлләниләр сөйләнүдән туктамадылар. Шуның өчен мәсҗед һәм зияратларны туйганчы карап булмады. Тиздән чыгып качтык. Бу урын мөселманнарга изге бер җир булган кебек, ул яһүдиләр өчен дә мөкаддәс һәм зиярәт итә торган урыннары. Ләкин алар үзләренең олугларына хөрмәтсезлек булмасын өчен мәсҗедкә чыга торган баскычларның берничәсеннән югары үтмиләр, пәйгамбәрләрнең туфрагы яткан җиргә аяклары берлә басудан сакланалар икән. Шуңарга баскычка менә торган җирләр яһүдиләрнең йөзләрен сөрүдән (сөртүдән) ялтырап беткәннәр. Соңгы гарәп-яһүди кычкырышы вакытында мондагы яһүдиләргә ярдәм килмәгәнгә, бик күп яһүд өйләре җимерелгән, үзләре качканнар. Синагоглары буш калган. Бүген анда бер яһүди тормый икән.

Хәлил әр-Рахманнан соң без Бәйтүләхмгә (Вифлеемгә) киттек. Бу җир — Хәзрәте Гайсәнең туган урыны. Хәзрәте Мәрьям корсаклы булгач, монастырьдан куганнар. Аны хөрмәтсез итәргә теләгәннәр. Шул яшь хатынны саклау өчен, Йосыф исемендә бер яхшы кеше Хәзрәти Мәрьямгә өйләнгән. Үзе хөрмәтле карт булганга, үзенең исеме берлә Хәзрәти Мәрьямне саклаган. Бала туар вакыт җиткәч, андый-мондый тавыш чыкмасын дип, Мәрьямне ишәккә атландырып, аулак бер җир эзләргә дип чыгып киткән. Уйлаган җиргә барып җитә алмаган. Юлда юлаучы туктый торган бер җирдә Хәзрәте Гайсә дөньяга килгән. Менә бу җир — шул урын. Ул җирдә Константинның (Византия императорының) хатыны Елина тарафыннан зур бер чиркәү салынган. Ул бик матур иттереп эшләнгән һәм мозаик берлә бизәлгән. Моңа инде мең ярым ел вакыт үткән булса да, әле мозаик эшләренең бик күбесе сакланган. Боларны күргәндә, Бизаж (Византия) мәдәниятенең никадәр тирән булганын күз алдына китерәсең. Хәзрәте Гайсә туганның соңында, аны юганнар. Ул җир бер чокырлы таш. Ул да чиркәү эчендә калдырылган. Аннан соң бала йоклатырга бишек булмаганга, аны печән-салам ашый торган тагаракка салганнар. Ул җир дә хәзер изгеләнгән һәм аерым итеп тотып алынган. Гайсә туган вакытта күк йөзендә бик зур галәмәтләр булган. Йолдызлар аңа сәҗдә иткәннәр һәм җиргә иңгәннәр, имеш.

Йолдыз төшкән җир дип тагын бер җирне аерып куйганнар. Анда алтыннан бер йолдыз сурәте дә ясаганнар. Уртасындагы тишектән йолдыз җиргә сеңеп киткән, имеш. Әлбәттә, боларның бик күбесе арттырылган. Ләкин Гайсәнең шунда тууы мәгълүм бернәрсә. Шуңар күрә бу җир христиан дөньясы өчен бик зур хөрмәтле урын. Аның бөтен тирәсенә бик күп монастырьлар салынган. Чиркәүнең эче, Кодестагы күк, төрле мәзһәбләргә бүлеп бирелгән. Бу мәзһәбләр дә бер-берсенә каршы дошман бер вазгыять алганнар.

Безгә чиркәүне бер әрмән побы күрсәтеп йөр(де). Сөйли, тарихны да яхшы белә. Ул безгә әллә нинди кирәкмәгән тәреләрне күрсәтеп, башыбызны әйләндермәде. Тарихи якларына дикъкать итте. Шуңарга без бу поптан бик рази калдык. Чиркәүнең тирә-юнен карап йөргәндә, монастырьларның беренең ишегенә язылган бер кәгазь безне гаҗәпкә калдырды. Анда «Хатыннарга керергә мәмнүгъ (тыелган)» дип язылган. Моның сәбәбен белер өчен, ишекне кагып, сорамакчы булдык. Ләкин ишектән берәү дә чыкмады. Әрмән побы сәясәт ясады булырга кирәк, моның мәгънәсен безгә аңлатмады. Аннан чиркәүнең башына чыгарга булдык. Безгә кечкенәрәк монахлар юлбашчылык иттеләр. Уңайсыз гына баскычтан үрли башладык. Бераз менгәч тә бер зур чиркәү кыңгыравы юлыбызны каплады. Ни күзебез берлә күрик: кыңгырауга урысчалап фәлән-фәлән тарафыннан, фәлән елда Тула шәһәрендә эшләнгән, дип язылган. Юл күрсәтүче: «Бу баш үзе дә урыслар тарафыннан эшләнгән. Мондагы рум монастыре бөтенләй урыс акчасына яши иде. Хәзер Русиядән килүче киселгәч, акча да бетте. Румнар (греклар) бик ярлыланды», — диде. Юлда очраган кыңгырауларның барысының да Русиядә эшләнгән булганы күренә иде. Башына менеп җитеп, шәһәрне карадык. Урыс акчасына эшләнгән зур-зур биналарны югарыдан сәер иттек (күзәттек). Аларда безнең халкыбызның да маңгай тирләре берлә эшләнгән миллионнарның әрәм булып ятуына ачындык.

Акрын гына төшә башладык. Кыңгырау янына килгәч, Муса әфәнде:«Кагып карыйкмы әллә? Бу бит безнең халыкның акчасына эшләнгән», — диде. Мин дә шул әрәм акчаның җылаганын ишетәсем килеп китте. Монахка сөйләдек. Ул: «Юк, ярамый. Аны зур бәйрәмнәрдә генә кагалар», — диде. Карыйсы җирләрен карап бетердек. Чиркәү бик искергән, сәләмәләнгән булганга, «ник төзәтмисез?» дип, тагын сорадык. Чиркәү төрле мәзһәб арасында бүленгән. Төзәтү өчен бер фикергә килергә кирәк. Шуны булдыра алмыйбыз, диделәр. Бу ислам дөньясына каршы эшләрдә берләшә белгән христиан дөньясының үзенең бик зур изге урыннарын саклауда берләшә алмавына гаҗәпкә калып, чиркәүдән чыктык та бу шәһәрдәге мәсҗедне карарга киттек. Мөселманнар аз булганга булырга

кирәк, монда мәсҗедләре зур да, бай да түгел; тарихи кыйммәте дә юк иде.

Урамга чыксак, бер төркестан түбәтәйле әфәнденең бер кибеттә сату-алу иткәнен күрдек. Чыннан да бу кеше фирганәле Габделкәрим исемендә бер үзбәк булып чыкты. Большевиклардан качып чыгып, элек Әфганстанга, аннан акрын-акрын Кодеска кадәр килеп чыккан. Хәзер Бәйтүләхмдә кечкенә генә бер кибет ачып, христианнарның шәмнәрен, вак-төяк изге китапларын, хәтта тәреләрен сатып сәүдә итә икән. Безне туганнарын күргән кебек каршы алды. Хәзер (бик тиз) кибетне ябып, өенә чәй эчәргә алып керде. Бу әфәнде инде монда бер гарәп хатынына өйләнеп, үзенең гаилә нигезен дә корган һәм ике баласы да булган икән. Ике-өч яшьлек зур кызы үзбәкнең бөтен төсләрен алып чыккан. Ләкин теле, «баба»дан (әтидән) башкасы, гарәпчә. Үз иленнән хат-хәбәр булмауга бик зарланды. Без дә белгән мәгълүматны биреп аерылдык.

Кодеска кайтып, анда күрергә өлгермәгән җирләрне караштык. Монда безнең өчен иң кызыгы Кодес каласын урап алган койма иде. Бу койма шулкадәр нык, шулкадәр биек итеп салынган, инде дүрт йөз ел үткән булса да, әле бер кирпече дә төшмәгән иде. Койманы Сөләйман Кануни (XVI йөздә идарә иткән госманлы солтаны) эшләткән. Бу җирләр аның атасы Явыз Сәлим вакытында Төркиягә кушылган булган. Сөләйман Кануни, Кодесны зиярәт иткәннең соңында, халыктан: «Сезгә бүләк бирергә телим. Сез нәрсәгә мохтаҗсыз?» — дип сораган. Ул вакытларда шәһәрне бәдәвиләр (күчмә гарәпләр) килеп басып, талап торганга, халык шулардан котылыр өчен: «Безгә бер койма кор. Бәдәвиләр үтәрлек булмасын», — дигәннәр. Сөләйман Кануни шул койманы кордырган. Шуннан соң Кодес халкы тынычланган. Без койманы әйләнеп чыгарга теләдек. Ләкин моның өчен иң аздан дүрт сәгать вакыт күбрәк кирәк икән. Без койманың төрле капкаларын карап, каравыл ясалган җирләренә чыгып, тирә-юньне күздән кичердек. Койманың тарихы, максаты һәм шуңа сарыф ителгән көч хакында төшендек. Аның салынуына, көн исәбе берлә, миллионнарча эшче көне киткән. Аның өчен шөбһәсез миллионнар-миллионнар акча түгелгән. Аны еллар буе ун-егермешәр мең кеше эшләгән. Хәзерге көндәге биш Анкараны корырлык материал киткән. Төрекнең ул вакыттагы иң зур мөһәндисләре (инженерлары) моның өчен баш ваткан. Ни өчен төрекнең иң зур падишаһы — мөселманлыкның көчле хәлифәсе — моны эшләткән? Ул вакытта бу көчне, бу материалны, бу акчаны төрек халкының үз файдасына куя алачак бер урын юк идеме? Бар иде. Ул төреклек өчен дә, мөселманлык өчен дә Кодестан кырык мәртәбә әһәмиятле бер урын — Идел буенда урыска каршы корган төрк-татар милләтенең Казан каласы, мөселман

өммәтенең христианлыкка каршы корган Казан ханлыгы иде. Ул шул көннәрдә Иван Грозный берлә үзенең барлыгын, ирегән саклар өчен канлы сугышта иде. Ул шул илнең ислам мәдәнияте астында яшәве өчен мең төрле корбан берлә үзен сакларга тырыша иде. Ул үзенең көче берлә генә урыс агымын, христианлык ташкынын туктата алмаганын күргәч, үзенең мәсҗедләрендә исеменә хөтбә укыла торган хәлифәсенә — Сөләйман Канунига дин исеменнән ислам байрагын сакларга ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән иде. Ул урыслыкка каршы гасырлар буе чик саклаучы булып килгән, төрк илләренең сакчысы булган Казанны бергәләшеп саклашырга үзенең олуг агасы итеп аңа ялварган иде, ялынган иде. Аз гына көч бирә күр, урысларга каршы ике генә сүз сөйли күр, дип күз яшен түккән иде. Сөләйман: «Мин, бөтен мөселманнарым хәлифәсе, җир йөзенең солтаны, диңгезләрнең падишасы, әмирләрнең әмире. Мин андый вак, Казан кебек эшләр берлә вакланыйммы? Минем алдымда зур эшләр тора: Кодесны зур койма берлә әйләндерәсе, Крит атасын (атавын) камасы, Венаны мохасарә итәсе (камап аласы) бар. Китегез, башны әйләндереп йөрмәгез, мине ваксытмагыз», — дип, Казанның күз яше эчендә булган илчеләрен кире борып җибәргән иде.

Аңа инде дүрт йөз елга якын вакыт үтте. Сөләйман Кануниның меңнәрчә-меңнәрчә төрекләрнең канын түгеп, еллар буе сугыштан соң алган Крит атасы бүген Юнанстанның (Грециянең) яхшы зәйтүн үстерә торган бер губернасы булды. Кодесның әйләнәсенә миллионнарга төшереп эшләткән кальга (крепость) арыган каргаларның кунып каркылдый торган җиргә әйләнде. Вена шәһәре... бар да билгеле. Казан нишләде?.. Ул урыс агымына үзе генә каршы тора алмады, төрк илләренең сакчысы үтерелде. Урыс ташкыны Казанны гына түгел, бөтен Идел буен басты. Себерне алды, Кырымны таптады, Төркияне Кара диңгезнең бу ягыннан куды. Төркестанны басты, Балканны аякландырып, Төркиянең берлеген парчаландырды (җимерде), Төркиянең бөтен барлыгын бер сорау тамгасы астына алды...

Сөләйман Кануни Иван Грозный кадәр булмыйча, аның бер командиры чаклы гына бер милләтче булган булса иде һәм Казанга кечкенә генә бер ярдәм кулын сузган булса иде, Төркия башына бәла булган бер урыс империясе кайдан чыгар, кайдан куәт алыр иде дә, Сөләйман Кануни корган Госманлы империясен кем җимерер иде? Нинди юл берлә ул төрк мәдәниятенең бишеге булган Төркестанны таптар иде? Бу сорауларның җаваплары төрк дөньясы өчен бигүк ямьле хатирәләрне ачмаганга һәм төрк (бу сүзнең бу рәвешле язылышы «төрки» мәгънәсен белдерә. — *Х.М.*) кабиләләре арасындагы мөнәсәбәтнең табигый булмаганын күрсәткәнгә күрә, алар турында сүзне бу урында озайтмыйча, Кодес сәфәрен тәмамлыйк.

* * *

Фәләстин дөньяның иң зур диннәреннән булган исламият, христианлык һәм яһүдилекнең өчесенә дә мөкаддәс җир саналганга, анда булганнарны, анда күргәннәрне, анда ишеткәннәрне язып бетерергә һәм аларны мәҗмуга мәкаләсенә сыйдырырга һичбер төрле имкян (мөмкинлек) юк. Аларны, вакыты килгәндә, үземнең көн дә язып килгән хатирә дәфтәремне бастырырга кадәр калдырып торып, укучыны Мисырга таба алып китәргә мәҗбүрмен. Фәләстиннән Мисырга иң кыска булган юл — тимер юл. Кантарә дигән җирдә Суэш (Сүәеш) каналы аша чыгып, Мисыр туфрагына керелә. Бу канал Кызыл диңгез берлә Ак диңгезне (Урта диңгезне) берләштереп, Африка берлә Азияне бер-берсеннән аера. Бу канал буенда инглиз гаскәре Мисыр өчен бик каты сугышканга һәм төрек гаскәре җиңелеп чигү аркасында, Мисырны гына түгел, Фәләстин, Сүрияне дә ташлап чыгарга мәҗбүр булганга, бу җирләр яңа төрек тарихы өчен дә мөһим урыннар.

Мин бу каналны беренче мәртәбә 1919 елның декабрендә Владивостоктан Триестка килешли үткән идем. Ул вакытта канал буенда ныгытылган җирләр дә күренеп торганга, Исмәгыйлия дигән шәһәр янында төрек әсирләренең дә лагерьлары күзгә ташланып торганга, шул хакта хатирә дәфтәремә озын гына язган идем. Хәзер дә шуңа арттырылачак нәрсә күп юк. Ләкин ул вакытта миңа төрек гаскәре лагере дип күрсәтелгән җирдә берничә татар гаиләсе дә әсир булып яткан икән. Алар бервакытны: «Ислам динен саклыйбыз», — дип, мөкаддәс Мәккә һәм Мәдинәгә Идел буеннан күчеп килгән мөһаҗирләр булганнар икән. Дөнья сугышы вакытында гарәпләр инглизләр яклы булып, төрекләргә каршы сугыш ачкач, безнекеләр дә төрек саналып, йортлары-җирләре таланып, маллары алынып, бик күбесе үтерелеп, калганнары шул лагерьга ябылган булган икән. Аларның кайберләре лагерьдан лагерьга күчерелеп йөрткәндә, үлеп беткәннәр. Кайберләре Фәләстин, Сүрия һәм Төркия эченә таралып киткәннәр.

Мин аларны соңгы озын сәфәремдә эзләп таптым. Аларның туктамастан аккан күз яше эчендә башларыннан үткәннәрен сөйләгәннәрен сәгатьләр буе тыңлап тордым. Инглиз хәтере өчен гарәби — төрек дип, урыс хәтере өчен төреге — татар дип, һәрбер уңгае килгәндә һәр яктан кыйнала торган бу милләттәшләремнең кара бәхетенә мин дә эчемнән еглап утырдым һәм шул кара язмышның сәбәпләрен эзләдем. Бу эшкә инде шактый күп вакыт үткәнгә, шул мәсьәләләрнең эчендә булган гарәпләрдән дә аның сәбәбен сорадым. Алар:

— Бу диннәрен сакларга дип, Хиҗазга күчеп килгән сезнең татарларга каршы һичбер дошманлыгыбыз юк. Сугыш ва-

кытында эшләр шулай китәчәк иде. Ләкин алар гарәп гыйсъянын (фетнәсен) һичбер төрле аңламадылар. Хәлифәгә каршы баш күтәрәсез, мөселманлыкның мөкаддәс җирләрен кяферләр кулына бирергә телисез, без шуны күрер өчен кяфер җиреннән ислам туфрагына күчеп килдекмени? Кайтыгыз бу яңлыш фикердән. Юкса кяфер буласыз, әстәгъфируллаһ (Ходай кичерсен!), әстәгъфируллаһ, дип сөйләделәр дә тордылар һәм безнең гади халыкка да тәэсир иттеләр. Мәккә шәһәрендә боларның башлыклары булган, татар шәкертләренә дә бик күп ярдәмдә булынган бай татар сәүдәгәре Гомәр карт бар иде. Ул гарәпләр арасында хөрмәтле бер мөселман иде. Шәриф Хөсәен аны үзенә чакырып: «Син татарларның хөрмәтле агасы, без сине татарларның консулы ясыйк. Син бөтен татарлар исеменнән миңа бәйгать (сүз; вәгъдә; ант) бир», — дигән. Гомәр карт та кып-кызыл чөгендер кебек булып: «Бу җир — Мәккәи Мөкәррәмә. Дине исламның туган урыны. Син — пәйгамбәрнең балаларыннан бер кеше. Мин дә динне саклар өчен кяфер йортыннан килгән мөһаҗир. Син ничек оялмыйча шул изге җирдә минем хәлифәгә (Госманлы солтаны бер үк вакытта хәлифә дә исәпләнгән) биргән антымны бозып, кяферләр эше артыннан йөрүчеләргә ант итәргә кушасың? Син ничек пәйгамбәрдән оялмыйсың? Син мине консуллык берлә кыздырмакчы буласыңмы? Бөтен гарәп туфрагын гына түгел, бөтен Госманлы падишаһлыгын бирсәләр дә, мин иманымны сындырмыйм һәм антымны бозмыйм. Мин ялганчылык эшләргә теләсәм, аны урыс йортында эшләгән булыр идем. Син эш моның берлә генә кала, дип уйлыйсыңмы? Бөтен Ислам дөньясы сиңа ләгънәт укыячак», — дип, әмир Хөсәенне нәсыйхәтләргә тотынган. (Бу биттә Мисырдагы Җәмигъ әл-Әзһәр мәчетенең рәсеме бирелгән.) Табигый, Гомәр картның бу сүзләре инглизләргә дә ишетелгән. Үзе, балалары һәм аның милләттәшләре дә төрекче хисап ителеп, маллары алынып, үзләре төрмәгә һәм лагерьларга ябылган, диделәр.

17–18 нче гасырларда кырым татарларының фидакарьлеге берлә генә дәүләтлекләрен саклаган госманлы төрекләренең боларны «пис (шапшак) татар, хунхор (явыз; канечкеч) татар, монгол» дип, кызыл һәм кара урысларның хәтере өчен боларга һәртөрле авырлыклар ясауларының сәбәпләрен дә бик күп эзләдем. Бер төрек дипломаты (болай диде. — *Х.М.*) (Аның сүзләрен Г.Исхакый төрекчә китерә. Без аны татарчага якынайтып бирәбез. — *Х.М.*):

— Әфәндем, без, руслар, хосусан большевиклар белән дуст яшәү мәҗбүриятендәбез. Бу — бер дәүләт мәсьәләседер. Моның өчен русларны, хосусан большевикларны көчәндермәвебез ляземдер. Хәзерге әхвальгә багыгыз: сезнең татарлар бирегә килеп, «әфәндем, руслар безгә бу фәналыкны (зыянны)

эшләде, ул фәналыкны кылды. Мәктәбебезне япты, җирләребезне алды» дип кычкыра башладылар. Шикаять, гел шикаять. Валлаһ (Алла өчен. — *Х.М.*), руслардан риза дигән бер кешене очратмадым. Болар безнең садә күңелләребезгә тәэсир итәләр. Биредә төрекчелек... кеби агымнар (карашлар) уяндырдылар. Дөресен әйткәндә, бу төр карашлар безнең күңелне болгаталар. Боларны эшләүчеләрнең һәммәсе — сезнең татарлар. Монда килеп, оста итеп язалар, «төрекчелек, төрекчелек» дип кычкыралар. Шул көннәрдә рус дусларымнан берсе бер китап күрсәтте. Бер әрмәни тарафыннан русча язылган бу китап сезнең татарларның анда үз мәмләкәтләрендә төрекчелекне таратуыгызны, төрекчелек өчен большевиклар белән дошманлык итүегез хакында яза. Коммунистлар партиясенә язылсалар да, төрекчелекне таратырга телиләр. «Сез безгә дуслыкны бәхәс итәсез. Чынлыкта исә сезнең арадагы кардәшләр ни эшлиләр», — диде. Французча тәрҗемә ителгән берничә юл укыды. Борчылуымнан ни эшләргә белмәдем. «Хәзер безнең эшләребезгә зыян китергән иптәшләрне мин безнеке дия аламмы? Әлбәттә, әйтмәм. Мин боларның мәмләкәтендә «төрк, төрк» дип кычкыруларына ярдәм итәрменме? Табигый, итмәм. Тыңлатмасам, ярар, кит, диярмен, куармын», — диде.

Мин моның да фикерен һәм аның фикерен йөрткән эгоизмын(?) аңладым. Ләкин изге урыннарны мөселманнар кулында сакларга теләгән Гомәр картның гарәплек ноктасыннан мөселманлыкка никадәр гөнаһ булганын һәм коммунист фиркасына язылса да, төрекчелек сәясәтен йөртергә теләгән татар коммунистының урыс һәвәсенә китмәвенең төрекчелек ягыннан нинди зур гөнаһ булганын аңламадым. Вазгыятьләребез Гомәр карт берлә Шәриф Хөсәен вазгыяте кебек булганга, сүзне кыска кисәргә мәҗбүр булдым. Бу татсыз вакыйгалардан татар укучысының үзенең дә төрле тәмсез мәгънәләр чыгару ихтималы юк түгел. Ләкин бу мәгънәләр таякны икенче якка бору төсен алмасыннар иде һәм без дә диндәш һәм кардәшләребезнең бу хәрәкәтләренә шулай җүләрләрчә җавап бирмәсәк иде. Чөнки болар да вакытлы һәм киләчәк эшләр.

Тимер юл Фәләстиндә һәм Мисырда да шактый былчырак. Вагоннар уңайсыз. Гүмрүк (таможня) мөгамәләсе дә Европадагы кебек түгел. Мисырның паспортларны карый торган полисе (полицейский):

— Каһирәдә кайсы отельгә төшәсең? — дип, җанымны алды. Мин, Каһирәгә беренче баруым булганга, һичбер отельнең исемен һәм адресын белми идем. Шуңа ачык җавап бирә алмагач, паспортымны алып калды да, аны отельгә урнашкач, полис мәркәзеннән барып алырга кушты.

Мисырга төнлә берлә сәгать унберләрдә генә барып кергәнгә, табигый, шәһәрне һичбер төрле күрә алмадым. Андагы

отельләрне дә белмәгәнгә, юлда туры килгән берсенә индем (туктадым). Ул пакь мәхәлләләренең берсендәге бер яхшы француз отеле булып чыкты. Мисырда минем мөэтәмәрдән (корылтайдан) бик күп гарәп танышларым булса да, элек үзебезнең татарларны эзләргә киттем. Сугыштан элек Русия берлә мөселман дөньясы арасында табигый мөнәсәбәт булганда, монда безнең Идел буеннан килгән укучыларыбызның саны бик күп була иде. Алар Мисырның милли-мәдәни агымнарында катышалар, илебездәге тәҗрибәләрен Мисырга китерәләр һәм Мисырда алган мәгълүматларын Идел буена алып кайтып тараталар иде. Соңгы гасыр башларындагы милли хәрәкәтләребездә зур урын алган галимнәребездән Муса Биги, Петербур имамы мәрхүм Лотфулла Исхакый, «Галия» мөдәррисе Зыяэддин әл-Камали, мөхәррирләребездән Закир әл-Кадыйри, Габделбарый Баттал әфәнделәр Мисырда елларча укып һәм укытып, өйрәнеп һәм өйрәтеп, илебезгә кайтып хезмәт иткән кешеләр иде. Болардан башка да әллә никадәр мөдәррис, мөхәррир, галим һәм имамнар хәзерләнеп кайткан һәм шулар аркылы Мисырның сәяси агымнары берлә бергә аның гыйльми тормышы да безнең Идел буена китерелеп, мал ителгән иде. Гарәпчәдән бик күп китаплар безнең телебезгә тәрҗемә ителгән иде. Безнең кичергән дәверебез табигый булса иде, гыйлемгә сусавын калдырыр (кандырыр) өчен бөтендөнья дарелфөнүннәренә (университетларына) тарала торган татар яшьләре бүген Мисыр дарелфөнүннәрендә дә йөзләп-йөзләп саналган булыр иде. Ләкин СССРдан чыгу кяферләргә тәмугтан котылу дәрәҗәсенә китерелгәнгә, Мисырга соңгы унөч ел эчендә бер генә дә татар яше килә алмаган иде. Анда булганнары да сугыштан элек чыгып, дөнья өстеннән үткән туфаннан монда сакланып кала алган кешеләр генә иде. Мондыйлардан уфалы бер яшь галимебезнең монда икәнлеген мин ара-сыра идарәгә язган хатларыннан белә идем һәм шуның аркылы башкаларны да таба алырмын дип уйлый идем. Шуңар күрә беренче иттереп аны эзләргә киттем.

Автомобиль берлә озын юллар үтеп, тар һәм киң урамнар кичеп, Әзһәр (Әл-Әзһәр мәчете һәм университеты күздә тотыла) янында булган бер бинаның алдына килеп туктадык. Бу минем якташым Хәмзә Таһир бәк хезмәт итә торган көтепханә иде. (Бирелдә Шәйх әл-җәмигъ әл-Әзһәр Мөхәммәд әл-Әхмәди әз-Зөһуринең рәсеме бирелгән. Мондый аңлатма да бар: «Узган Рамазан бәйрәмендә большевикларның ислам диненә иткән золымнарына каршы протест ясаган кеше». — *Х.М.*) Эш вакыты булганга, ул үзе дә монда иде. Ул минем Кодестан язган хатымны ала алмаган булса да, Мисыр гәзитләрендә минем хакта язылган мәкаләләрне укып, минем Мисырга да килеп чыгуымны көтеп тора икән. Килеп-киткән бөтен татарның

Мисырда берданбер өзелеп калган милләттәшен эзләп табучыларны бик күп мәртәбәләр күргәнгә, минем дә эзләп киләчәгемне белеп тора икән. 17 яшендә Дим буен ташлап китеп, 18 ел гарәп дөньясында укыган һәм кайнаган бу татар егете, кичә генә Уфадан чыккан кебек, саф татарча сүзләр берлә мине каршы алды. Әйләнә-тирәдәге кешеләрне, алдагы эшләрне онытып, ил-йорт хатирәләренә чумдык. Көтепханәнең ябылганын көтмичә үк чыгып киттек.

Без Мисырның ислам тарихында зур роль уйнаган «Әзһәре җәмигъи» янында идек. Минем танышларымнан бик күп кеше бу җәмигъдә укыган булганга, мин аны мөмкин кадәр тизрәк күрергә тели идем. Кечкенә генә мәйданны чыгып, җәмигъка якынлаштык. Ул тыштан караганда гарәп өслүбендә салынган җәмигъларның берсе иде. Аяк капларын (киемнәрен) салып, эченә керәбез. Тирәсенә җәелгән калын намазлыкларда шәкердләр дәрес хәзерләп утыралар. Кайберләре намаз укый. Җәмигъның үз ишегенә килеп җиттек. Анда безне капучы (сакчы; каравылчы) туктатты: «Хәзер дәрес вакыты. Керергә рөхсәт юк», — диде. Хәмзә Таһир бәк мине ислам корылтаена килгән мөсафир дип танытып, аерым рөхсәт алды.

Мәсҗед кояш батышыннан кояш чыгышына каршы иттереп, озайтылып салынган. (Бирелә Кодес шәриф мөфтисе Мөхәммәд Әмин әл-Хөсәйни рәсеме түбәндәге язу белән бирелгән: «Большевикларның Русиядәге яшәүче мөселманнарга иткән золымнарына каршы Милләтләр Лигасына мөрәҗәгать иткән кеше». — *Х.М.*)

Буена караганда, ике-өч мәртәбә киң, түшәме бик күп баганалар берлә тоттырылган. Аларның саны өч-дүрт йөз кадәр бар икән. Аларның кайберләре янында мөдәррисләре тәбәнәк кенә бер көрсигә аякларын бөкләп утырып, тирә-юньнәрендә идәнгә утырган шәкердләргә дәрес әйтәләр. Берсенең янында — кырык-илле, икенчесенең янында — унбиш-егерме. Шәкердләрнең барысы да уку яшендәге яшьләр. Дәресләр иртән сәгать сигездән кичке алтыга кадәр дәвам итә, өйлә намазы вакытында ике сәгать туктап торыла икән. Мондагы мөдәррисләр, төрек җәмигъларындагы кебек, бугаз ярылганчы кычкырырга мәҗбүр булмаганга, мәсҗед эче сүз ишетелмәслек бер тавыш берлә тулмаган. Мөдәрриснең сүзен шәкерд бик җиңеллек берлә ишетә. Аларның берсенең сүзе икенчесен борчымый. Ун-егерме мең шәкерде бар дип сөйләнгән «Әзһәр»нең эчендә бары 400–450 шәкерднең генә болай дәрес тыңлап утыруы минем хушыма китмәде.

— Башка шәкердләр кайда? — дип сорадым.

— Хәзер монда яңа тәртипләр куелды. Җәмигъда хәзер илаһия берлә фикъһе (мөселман юриспруденциясе) шөгъбәсе (факультеты, бүлеге) генә калды. Башка фәннәр яңа биналарга күчтеләр, — диделәр.

Аннан чыгып, «Әзһәр» күршесендәге анда укучы төрк шәкердләренең тора торган җирләренә киттек. Ул берничә катлы зур өй икән. Эчендә алтмышлап аерым бүлмәләр бар. Моннан башка тагы «Әзһәр» йортының эчендә төрк шәкердләре өчен егермеләп бүлмә бар. Моны «Рәвакыл-әтрак» («Төркләр бинасы») дип атыйлар. Монда бөтен төрк илләреннән килгән укучыларга буш бүлмәләр бирәләр. Элеккеге заманнарда аның вакыфы аерым йөртелә торган һәм елда йөз мең Мисыр лирасы кадәр килере булган. Бу акчадан шәкердләргә һәм мөдәррисләргә магашлар (хезмәт хакы) бирелгән. Соңгы кризислар аның килерен азайткан. Соңыннан «Әзһәр» вакыфларыннан «рәвак»ларга бүленүе бетерелеп, бөтен мали (милек) эшләре үзәкләштерелгән. Бөтен шәкердләргә бертөрле ярдәм бирелә башлаган. Элек һәрбер шәкердкә аена биш лира биргән булганнар; хәзер җиде лира бирәләр икән. «Әзһәр» янында бу төрк бүлегеннән башка, Һиндстан, Җавә (Ява утравы), Хиҗаз, Әфган һәм башка кебек мөселман халыкларының аерым-аерым бүлекләре һәм аерым-аерым оешмалары, вакыфлары бар. Аларның үзләренең башлыклары (шәйхләре) бар. Төрк бүлеменең башлыгы — шәйх Габделхәмид Таһир исемендә бер чиркәс. Аның ярдәмчесе Шәмседдин әфәнде — Анатолий төрекләреннән. Бу «рәвак»ларның идарәләре бер мәркәзгә табигъ (буйсынулы). «Әзһәр»дә барысы 300 гә якын мөдәррис бар. Аларның магашлары аена унике Мисыр лирасыннан алып, илле лирага кадәр икән. Бөтен «Әзһәр»нең вакыфының еллык килере бер миллион Мисыр лирасына якын. «Әзһәр»нең бөтен укыту эшләренең идарәсе башында торучы «Шәйхел-Әзһәр» исемендә йөртелеп, ул шул ук вакытта Мисырның «Шәйхел-исламы» урынын ала һәм Мисыр голәмасының иң бөекләреннән сайланып куела. Бу урында бүген шәйх Әхмәд Мөхәммәд әз-Заваһиди хәзрәтләре тора. Бөтен зур дини фәтвалар, фәрманнар аның имзасы берлә чыга. Узган Рамазан бәйрәмендә большевикларның ислам диненә каршы иткән золымларына каршы игълан ителгән протест та шул бөек затның имзасы берлә чыкты.

Шәкердләрнең тора торган җирләрен карап бетергәч, «Әзһәр»нең көтепханәсенә кердек. Аның укыла торган бүлеме булган кебек, музә (музей) — иске кыйммәтле әсәрләр саклана торган бүлеме дә бар икән. Анда барлыгы сиксән мең җилд (том) иске китап саклана. Алар эчендә бик иске заманнардан калган, бик матур иттереп мәгълүм хаттатлар (күчерүчеләр; каллиграфлар) тарафыннан язылган бик күп фәрманнар да бар икән. Шул ук көтепханәнең бер бүлмәсенә Мисырның унтугызынчы гасырдагы зур галимнәреннән Мөхәммәд Габдәнең көтепханәсе китереп урнаштырылган.

Бүгенге көндә «Әзһәр»нең төрле факультетларында төрле яктан җыелган йөзгә якын төрек шәкердләре укып яталар.

Алар арасында берничә төркестанлы булса да, безнең Идел буеннан һәм Кырымнан берәү дә юк. Күпчелек — кафкаслылар. Әгәр укырга ихласы һәм дөньяның ачысын-төчесен татырга теләгән яшьләребез булып, Әзһәргә барып чыксалар, Әзһәрнең ишекләре һәм вакыфлары алар өчен һәрвакыт ачык. (Бу урында Әзһәрдәге дәрес вакытын чагылдырган рәсем урнаштырылган. — *Х.М.*) Тик элгәреге күк, анда кереп укымыйча, ашап яту гына бетерелгән. Һәр шәкерд имтихан тотарга тиеш. Бирә алмаган шәкердләр мәдрәсәдән куылалар.

Әзһәрне карап бетергәч, ашап-эчеп, Мисырдан килгән корылтай әгъзаларын күрер өчен, «Җәмгыяте шөббанел-мөслимин»гә («Мөселман яшьләре җәмгыяте»нә. — *Х.М.*) киттек. Бу җәмгыять — мөселман яшьләрен бер тәрбиядә һәм рухта үстерер өчен соң елларда гына оештырылган һәм бик күп мөселман мәмләкәтләрендә үзенең шөгъбәләрен ачып өлгергән бер мөселман җәмгыяте. Ул бөтен дөньядан килгән мөселманнарның бер-берсе берлә күрешә, таныша торган һәм бер-берсенең дәрдләрен (проблемаларын) аңлаша торган бер мөселман мөәссәсе (оешмасы). Анда мине күптәнге таныш һәм туган-кардәш кебек каршы алдылар һәм Русия мөселманнарының хәле хакында биреләчәк беренче конферансның (лекциянең; докладның) үзләрендә бирелүен сорадылар.

Мисырда сәясәттә, мәдәният һәм фикер таратуда киң бер иркенчелек бар. Бу хөррияттән файдаланып, аның сәясиләре төрле-төрле фиркалар (партияләр) ясаганнар. Алар шул фиркалар янында халыкны туплап, үзләренең сәяси һәм мәдәни фикерләрен тормышка тәтбикъ итәргә (ашырырга) тырышалар.

Төрле фиркаларның максатка барып җитәр өчен иң кыска юл дип ышанган юллары бер-берсенекеннән башка-башка булганга, табигый, алар бер-берсе берлә кычкырышалар, талашалар. Бөтен дөньядагы хөрриятле мәмләкәтләрдә булган кебек, монда да кайбер вакытларны кызышып китеп, бер-берсен гаепләшәләр, талашалар. Алар, үзләренең матбугатларында Мисырның мәсьәләләрен төрле төстә күрсәтеп, укучыларны да үзара талаштыралар.

Мисыр халкы, һәрбер иске (текстта — һәрбересе) мәмләкәт халкы кебек бик тиз күперенеп, кызып китә торган халык булганга, бу кычкырышлар күп вакытларда канлы вакыйгалар да тудыралар, зур-зур мәхкәмәләргә (судларга) сәбәп булалар. Ләкин боларның берсен дә безнең Русиядә күрергә өйрәнгән меңләп-меңләп тотулар (кулга алулар), йөзәрләп-йөзәрләп сөргенгә җибәрүләр һәм атуларның берсе булмый. Тавыш-туыш бераз дәвам итә дә, тормыш тагын үзенең табигый юлына төшә...

Без Мисырга барганда да мондый фирка кычкырышларының бик кызу барып яткан чагы иде. Ләкин без монда, Мисыр

зур бер мөселман мәмләкәте дип, үзебезнең кайгы-хәсрәтләребезне сөйләргә һәм белдерергә килгәнгә, үзебезнең эшебезне фиркачылыктан читтә тора торган «Җәмгыяте шөббанелмөслимин»нән башладык. Бу җәмгыять — Мисырда гына түгел, бөтен гарәп дөньясында ислам мәдәниятен саклау нигезенә корылган һәм мөселман яшьләрен бертөрле тәрбиягә алыштырыр өчен корылган бер оешма. Аның шөгъбәләре (бүлекләре), Гыйрак, Фәләстин һәм Сүриядә булган кебек, Һиндстан һәм Җавада (Явада) шактый көчле тармаклары бар. Ислам дөньясында Мисыр бүген мәдәният ягыннан да һәм байлык ягыннан да беренче урында торганга, Каһирәдәге «Җәмгыять...» мәркәзлек урынын тота. Ул шул исемдә төрле җирләрдә клублар ача, оешмалар кора һәм шул ук исемдә зур бер мәҗмуга чыгара. Бу мәркәзнең идарәсе танылган кешеләр кулында. Аның башында Мисыр Милләт мәҗлесе әгъзасы, Мостафа Кәмал паша оештырган фирканың лидеры Габделхәмид Сәгыйдбәк тора. Ул — үзенең яшьлегеннән алып бу көнгә кадәр ислам дөньясының һәр почмагындагы милли-дини тартышларга катнашып килгән кеше. Ул Тарабулус (Триполи шәһәре) сугышларында мәрхүм Әнвәр паша һәм Гази Мостафа Кәмал пашалар берлә бергә Тарабулусны коткарыр өчен сугышка катышкан; Балкан сугышлары башлангач та, ул бердәнбер мөстәкыйль мөселман падишаһлыгына — Госманлы императорлыгына каршы христиан дөньясының берләшеп һөҗүм иткәнен күреп, үзенең мөселманлык вазыйфасын үтәргә — мөселман гаскәре берлә бер сафка булырга ашыккан кеше. Ул Балкан сугышында безнең илдән күңелле (ирекле; доброволец) булып килгән Гариф Кәримиләр берлә бергә сугышка кереп яраланган.

Габделхәмид Сәгыйдбәк дөнья сугышы вакытында Төркиянең тагын бөтен яктан көчле дошманнар берлә чолганып алынганын күргәч тә, аның ислам мәхәббәте кузгалып, өченче мәртәбә күңелле булып сугышка катышкан һәм Мисырны кулында тоткан инглизгә каршы корал берлә көрәшкән һәм таралырга торган гарәп әфкяре гомумиясен (иҗтимагый карашларын; җәмгыятен) хәлифәт тирәсендә берләштерергә хезмәт иткән (Госманлы солтаннары бер үк вакытта хәлифә дә хисапланган): Сийур могаһәдәсе (биредә Сьерра-Леоне килешүе күздә тотыла булса кирәк. — *Х.М.*) берлә Төркия бетереләчәк булгач башланган Гази Мостафа Кәмал пашаның (ягъни Ататөркнең) истикъляль (азатлык) сугышлары вакытында Италиядә торып, Төркия файдасына бик күп матди-мәгънәви хезмәт иткән. Ул үзе зур бер бай кешенең баласы булганга, бу эшләрнең барысын да үзе өчен һичбер файда күзәтми эшләгән. Исламият юлында күп һәм бик күп мал сарыф иткән бу кеше бүгенге көндә дә һәрбер мөселман өлкәсе өчен дөньяның бер

читеннән икенче читенә китәргә хәзер тора. Шуның өчен дә «Шөббанел-мөслимин» җәмгыяте — Мисырның иң җанлы бер мөселман оешмасы.

«Шөббанел-мөслимин» җәмгыяте хәзерге көндә Төркия төрек очаклары ролен уйный. Аның рәисе дә Төркиядә соңгы 15 ел эчендә Хәмдалла Собхибәк торган урында тора. Бу җәмгыятьнең бинасы һәрвакыт төрле җирләрдән килгән мөселман мосафирлары берлә тулы. Мин анда корылтайда очрашкан Гыйрак һәм Югославия вәкилләрен тагын бер тапкыр күрдем. Шунда ук Америкада ислам динен таратучы һәм шул юлда гомерен фида иткән һәм 20000 кадәр Америка караларын (негрларын) мөселман иткән Америка мөфтисе — кара гарәп, сәйд сани (икенче сәйд) Мәҗид Мөхәммәд әфәндене очраттым. Мин анда ислам мәдәниятенә сусап килгән Кытай мөселманнарын да күрдем. Бик күп гарәп өлкәләренең җәмәгать эшчеләре, Һиндстан мөселманнарының олугларыннан Шәүкәт Гали һәм аның иптәшләрен һ.б. таптым.

Анда безнең эшебезне тәмам кардәшчә каршы алдылар. Минем конферансым (чыгышым; лекциям) шимбә көнгә билгеләнде. Чакыру кәгазьләре таратылды, гәзитләрдә игълан ителде.

Җомга килеп җитте. Мин Мисырның зур җәмигъларыннан (мәчетләреннән) берсендә намаз кылырга уйладым. Хәмзә Таһирбәк миңа тагын ярдәмгә килде. Мисырда җәмигълар бик күп. Аларның мәшһүрләре: Сәйдна Хөсәйн, Сәйдәи Зәйнәб, Имам Шафи, Рәфагъи, Гомәр бине Гас, Җәмигыл-Әзһәр җәмигълары һ.б. Сәйдна Хөсәйн җәмигында Хәзрәте Хөсәйннең зиярәты бар. Анда аның башы күмелгән. Сәйдәи Зәйнәб — Рәсүлнең Зәйнәб исемле кызы хөрмәтенә салынган һәм Мисырның зур, мөбарәк җәмигъларыннан. Гомәр бине Гас җәмигы — Мисырда беренче салынган мөселман мәсҗеде. Рәфагъи җәмигы иң зур һәм бүгенге көндә Мисырның иң могтәбәр җәмигъларыннан.

Халык бик күп була торган җәмигъ булганга, мин Рәфагъига барырга булдым. Бик артта калмыйм дип, сәгать 11 ләрдә үк җәмигъның эченә кереп утырдым. Мин килгәндә, мәсҗеднең эчендә берничә җирендә Коръән укып утыручы берничә кешедән башка берәү дә юк иде. Мәсҗед бик зур, ишекләре төрле урамнарга ачыла. Моңар күрә урам тавышы ишетелеп тора иде. Сәгать уникенче ярты булды. Зур ишекләр янына барып, мөәзиннәре, карилары (кариәләре; Коръән укучылары) бик сузып, урамга таба кычкырып, төрле догалар укырга тотындылар. Бу догалар халыкны чакыру, гыйбадәт кылырга өндәү булсалар да, озак түгел иде. Төрле тавышлар берлә 15 минут сузылган бу чакырудан соң, халык мәсҗедкә җыела башлады. Бер җирдә бер хафиз (Коръәнне яттан укучы) бик матур тавыш

берлә Коръән укырга кереште. Ул бик сузып-сузып, төрле тоннарга күчеп укый иде. Аны гарәпләр бик ихлас берлә, бик зур күңел рәхәтлеге берлә тыңлар иде. Кайбер вакытларда катышып бер сүз дә әйтәләр һәм салаватлар да кушалар иде.

Менә мөәзин дә кычкыра башлады. Ул бер озын мәкам (көй, тавыш; моң) берлә без белгән азанны укыды. Ләкин ул аны шундый озын иттереп, тавышларын төрләндереп, уйнатып, бер төшереп, бер күтәреп укый иде, — безнең кебек читтән килгәннәргә аның сүзләре артыннан барып җитүе дә һәм аңлавы да бик авыр иде. Кари азан әйткәндә дә үзенең укуыннан туктамады. Азан тәмам булды. Мәсҗед тулды. Арттан берәү «ас-салават» дип кычкырды. Халык гөрләп калкып, намазга кереште.

Монда төрле мәзһәб кешеләре булганга, намаз уку бертөрле генә түгел иде. Кайберләре кыямда (намазның аягүрә үтәлә торган өлешендә) кулларын җибәреп торалар; кайберләре рөкүгъка (намазның иелеп тору, тезләргә таяну өлешендә) киткәндә, тагын бер тапкыр колак кагалар; кайберләре безнең кебек укыйлар иде. Ләкин барысы да ике рәкәгать кенә укыдылар. Намаз бетте. Хатиб мөнбәргә чыкты. Мөәзин азан укыды, арттагы мөәзиннәр аны кабатладылар. Хотбә (вәгазь) безнең хотбә китапларындагы гади бер хотбә иде. Суык кына, тонык кына укыды. Хотбәдә ләкин холәфаи рашидин (биредә «тәүге хәлифәләр» күздә тотыла), хәлифә һәм үзләренең падишаһларына һич төпле дога юк иде.

Безнең муллаларның, урыс хөкүмәте бик каты тыя торып, хәлифәләргә дога кылулары һәм кайбер фетнәле мәхәлләләрдә имамнарның бу доганы яшерен генә укулары күз алдыма килде дә бу мөселман илендә тулы хөррият эчендә моның эшләнмәве кызык тоелды.

Намаз бетте. Халык гөр итеп купты. Бер өлеше ишекләргә, икенче өлеше мәсҗед уртасына утырган вагыйз (вәгазь укучы) янына җыелды; өченче бер өлеше михраб янына җыелып, яңа бер имамга оеп, өйлә намазы укый башладылар. Болар Мисыр шәһәренең җомга намазы өчен шартлары тулмаган дип өйлә намазы укучы суган суфыйлар икән.

Мин, бер вагыйз янына барып утырып, аның вәгазен тыңларга хәзерләндем. Вагыйз: «Әр-риҗалу кавамун галяин-ниса», — дип башлады (ир — хатыннарга баш! — *Г.И.*) һәм шул фикерне балландырып, татландырып сөйләргә кереште. Ул ирләрнең хатыннарга баш булуы өчен кирәк булган бик күп дәлилләр китерде. Хатыннарның хыянәтләреннән, хәйләләреннән бәхәс китте. Кечкенә вакытта мин үземнең әбием Мәхфузә остазбикәнең һәм әнинең авыл хатыннарына сөйләгән бу дәлилләрне, мисальләрне (кинаяле хикәятләрне, мисалларны) бик күп тыңлаган идем һәм аларның ул хатыннарга ничек тәэ-

сир иткәнен дә күргән идем. Ул вакытта алар миндә бер дә начар тәэсир калдырмаганнар һәм минем һичбер хисемне мыскыл итмәгәннәр иде. Ләкин бер Мисыр вагыйзының моны җентекләп-җентекләп сөйләве миндә бик ямьсез тәэсир калдырды. Ул мәрхүм әби-әниләрнең хатирәләре мыскыл ителә кебек тоелды.

Җәмигътан чыгып, аннан бик ерак булмаган Мөхәммәд Гали паша* җәмигын карарга киттем. Мисырның бүгенге сөлялэсенең (династиясенең; нәселенең) башы тарафыннан бина ителгән бу җәмигъ Мисырның иске кальгасында һәм Мисырның иң биек җирендә, тәмам төрек стилендә салынган. Тыштан караганда, Истанбулдагы Валидә җәмигына охшаган кебек күренә. Ләкин эченнән бик зур һәм бик бай бер җәмигъ. Бик күп акча сарыф итеп эшләтелгәне һәрбер җиреннән күренеп тора. Намаз беткәнгә монда да вагыйзлар сүзләрендә дәвам итәләр иде. Мин дә берсе янына килеп чүктем. Вәгазь Кәүсәр суының тәмлелеге, татлылыгы һәм файдалыгы хакында иде. Бераз тыңладым. Ләкин монда да дәрдемә дәрман булачак бер сүз ишетә алмадым.

Минем җәмигъләрдагы вәгазьләрне бик күп ишеткәнем бар. Алар, шөбһәсез, халык өчен бик кирәкле нәрсәләр һәм халыкка бик зур тәэсир дә ясый алалар. Төркия вагыйзлары үзләренең вәгазьләре берлә төрек гаскәрен кыздырып, утка-суга кертә алалар. Бик күп шәһәрләрне алдыралар. Бик көчле дошманнарны тар-мар иттерә алалар. Һәм җәмигътагы халыкны электрикланган хәлгә китерә алалар: көннең актуаль мәсьәләләренең хәлендә файдалы йә зарарлы роль уйный алалар. Ләкин мондагы вагыйзлар бик вак мәсьәләләр берлә шөгыльләнәләр һәм халыкка да бик аз тәэсир итә беләләр.

Кич берлә бер театрга барырга ният иттем. Мисырның Милли театрында «Ләйлә вә Мәҗнүн» уйналганга, шунда киттем. Театр бинасы бик бай һәм матур. Бөтенләй гарәп ысулында салынган бер бина. Каралуы, саклануы да яхшы. Мондый театр бездә дә һәм Төркиядә дә юк. Мин яхшы ишетер һәм күрер өчен урынны алдагы сафлардан алдым. Алданрак барып, килүче халыкны сәйр иттем (күзәттем). Килүчеләр пакь киенгән һәм үз-үзләрен тота белә торган кешеләр иде. Хатыннар ложаларда гына күренә. Түбәндә юк дәрәҗәсендә аз иде. Пәрдә күтәрелде... Декорационнар яхшы эшләнгән, киемнәр гарәп ысулында. Ләкин уйнаучыларның күбесе үзләрен сәхнәдә тота белмиләр иде. Алар йә утырышып торалар, йә кулларын салындырып, кая барырга белмичә, үзләренең монда ни өчен

---

* Мөхәммәд Гали (1769–1849) 1805 елда Мисырда хакимиятне үз кулына ала. Илдә күптөрле реформалар үткәрә. Аның бу өлкәдәге гамәлләрен еш кына Петр I эшчәнлеге белән тиңлиләр *(Х.М.)*.

кергәннәрен аңламыйча, аптырап, сәхнә буе йөриләр иде. Драматик моментлар хәрәкәт һәм уен берлә җанландыра (бу сүз «җанларла» дип ялгыш язылган. — *Х.М.*) алмыйлар иде. Аларның осталыгы декламационда, сүздә генә иде. Җанландырып күрсәтеләчәк күренешләр озын монолог төсенә керә, бик нечкә минутлар сүз берлә буылалар (бүленәләр) иде. Әсәрдә музыка бер дә катыштырылмаган иде. Ул шуның өчен әллә нинди корыган, коргаксыган хис калдыра иде. Уйнаучылардан Мәҗнүн ролен уйнаучы Хөсәйн Рийаз берлә Ләйлә ролен уйнаучы Фатма Рөшди (Фатыйма Рәшиди?) ханымнар чын мәгънәсе берлә артистлар иде. Аларның икесе дә Аурупаның һәр театрында уйнарлык көчкә һәм осталыкка малик (ия) кешеләр иде. Ләкин режиссер бик зәгыйфь булганга, аларның тырышуы гына кирәкле нәтиҗәне бирә алмый иде. Хөсәйн Риийаз куәт ягыннан бик зур бер артист булса да, аның гәүдәсе Мәҗнүн роленә туры килми иде. Ашый да, эчә дә һәм йоклый да алмый торган мәңгелек гашыйк, үзенең яндырган гыйшкын сөйләгәндә, көйдергән дәрден җырлаганда, бераз ябыграк, зәгыйфьрәк күренергә кирәк иде. Ләкин Хөсәйн Риийаз фил кадәр зур, җуан һәм тупас гәүдәле бер кеше иде.

Мин моннан соң да Мисырның шактый зур театрларында булдым. Боларның барысында да бер кимчелек бар: ул да — күрсәтелә торган тормышның авыр минутларын уйнап, җанландырып күрсәтү урынына — сөйләп аңлату ысулы (ысулын куллану). Гарәп теленең бик эшләнгән һәм бик бай булуы бу монолог-декламацион юлына керергә зур ярдәм итсә һәм гарәп караучысы моннан бер ләззәт тапса да, — бу юл театрның ибтидаилигын (башлангычын, тәҗрибәсезлеген) күрсәтә. Бу сәгать берләргә кадәр сузылган монотон уеннары мине ялыктырсалар да, гарәпләр үзләре аны рәхәтләнеп тыңладылар. Мин, Мисырның театрлары әле безнең татар театрыннан бик күп түбән икән, дигән фикер берлә театрдан чыктым һәм безнең милли труппалар киләчәктә Мисырда нинди зур уңышлар ясый алачакларын уйлап, өйгә таба борылдым.

26 нчы декабрь кичәсендә «Шөббанел-мөслимин» җәмгыятенең залында минем беренче конферансым (лекциям; чыгышым) булды. Мин төрекчә сөйләдем. Җәмгыятьнең идарә әгъзаларыннан Мөхеддин әл-Хатиб бәк аны гарәпчәгә тәрҗемә итте. Ләкин тыңлаучыларның өчтән бере төрекчәне аңлыйлар иде. Мәсьәләгә кереп китеп, фикернең нинди юлда барганын аңлап алган үткенрәк кешеләр минем гарәпчәне махсус күбрәк катыштырып сөйләгән төрекчәмнән дә күп фикерне аңлап киләләр иде. Сүз башлану берлә бөтен зал тып-тын булып калды. Һәрбер кеше җанлы бер дикъкатькә әверелде.

Мин элек Русиядә яшәгән мөселманнарның утырган урыннарын санап, аерым-аерым төрек өлкәләренең кайсы елларда

урыс кул астына керүләрен аңлаттым. Патша дәверендәге сәяси-мәдәни хәлләрен күздән кичереп, большевик дәверенә кердем. Русиядәге 30 миллион мөселманның большевик дәверендә өч яктан — мөселманлык, төркчелек һәм истикъляльчелек (азатлык) ягыннан — башка СССР тәбгаләреннән (кавемнәреннән) өч мәртәбә артык золымга мәгъруз калуларын (дучар ителүләрен) сөйләп, мисаллар китердем. Исламият Русия мөселманнары арасына моннан мең сәнә (ел) элек кергән бер дини тәгълимат булганга һәм алар исламиятне саклар өчен һәрвакыт христиан урыслар берлә сугышып килгәнгә, ул монда халыкның канына һәм җанына сеңгән бер милли дин төсен алган. Шуның өчен мөселманнар һичбер төрле итеп алласызлык һәм динсезлеккә корылган коммунизм әсасен (тәгълиматын) кабул итә алмадылар, урысларның рухларындагы башбаштаклык (анархия) бу коммунизм әсасларын кабул итәргә никадәр киң мәйдан ачса, исламиятнең әхлак-мораль дисциплины мөселманнарга ул фикерне кабул итәргә шулкадәр манигъ (киртә) булды. Шуның өчен һәрбер динне үзенә дошман итеп игълан иткән большевиклык исламиятне ике кат дошман итеп таныды. Ул аның берлә христианлык һәм яһүдилеккә караганда әллә ничә өлеш артык көч берлә тартышырга кереште.

Русия мөселманнарының йөздән сиксән бише — төркләр. Калган кыйсеме төрк мәдәниятенә мәгъруз калган чиркәсләр. (Шәрыкта бөтен Кафкас таулары «Чиркәс» исемендә йөриләр.) Русия милләт уларак һәрвакыт төрек милләте берлә тартышып килде. Элек ул 300 ел кадәр төркләрнең кул астында яшәде. (Алтын Урда һәм Казан дәверләре.) Соңыннан алар төркләрне җиңеп, үз кул астына алдылар һәм төрек милләтен бер милләт уларак бетерергә керештеләр. Урысларның бу хәрәкәте бер каршы хәрәкәт уятты. Төрек милләтендә бер милли уяну туды. 20 нче гасыр төрек милләтенең милли уянуының иң көчле бер дәвере иде. Милләтсез бер коммунизм җәмгыяте, «яратам» дип мәйданга чыккан большевик үзенең бу эшендә иң элек төрек милләтчелегенә бәрелде. Ул аны һичбер төрле әзәйтә алмаганга, ул аңа каршы иң каты дошманлык вазгыятен алды. Шуңа күрә төрк милләтчелеге коммунизмның иң зур дошманы булып танылды.

Большевикларның максатлары — бөтен дөнья күләмендә бер иҗтимагый революцион (революция) ясап, бер совет дәүләте дөньяга китерү. Аларның бөтен пропагандалары, тышкы сәясәтләре менә шушы максатны күздә тота. Алар чит илләрдә дә менә шул фикерне кабул итәчәк һәм итә алачак гонсырлар (элементлар; чыганаклар) эзлиләр. СССРның эчендә яшәүче милләтләр һәм шулар эчендә төркләр дә, большевик дәүләтеннән аерылып чыгып, үзбашларына ирекле бер дәүләт ко-

рырга тырышалар. Алар Русиядәге хәзерге большевизм патшалыгын, урыс милләтенең идарә итү ягыннан бонкрот булуы дип карап, аның кулыннан котылырга тырышалар. Төрек милләтенең аерым өлкәләре булган Төркестан, Кафкас, Кырым һәм Идел-Урал мөстәкыйль булырга тиеш. Большевик идарәсе бу милли истикъляль дәгъвасын күреп, бу яктан да төркләрне үзенең биәман (куркынычлы) дошманы итеп карый һәм аларга каршы җәбер-золымны арттыра. Большевизм хосусый милекне танымаганга, ул бөтен Русия халкының милкен дәүләтләштергән кебек, мөселманнарның да милкен талый. Ул бөтен русиялеләрнең гаиләсен бозган кебек, мөселманнарның гаиләсен дә бозарга тырыша. Шуңа күрә бүген Русиядә яши торган 30 миллионлы мөселманлык үзенең хәятен саклар өчен бик авыр тартыш алып килә. Үзеннән бик күп мәртәбә көчле булган дошман берлә хәят-матәм (яшәү-үлем) дәгъвасын алып бара.

Ул үзенең истикъляль җәбһәсендә (мәйданында; фронтында) аның кебек Русиядән аерылып мөстәкыйль булырга тырышучы Украина, Гөрҗи (Грузия), белорус һәм фин кавемнәре берлә берләшеп, бер «Прометей» җәбһәсе берлә (берлектә) тартыш алып бара. Төрк җәбһәсенә килгәндә, Русиядә яшәүче төрек милләте, төрле кабилә исемнәре берлә йөрсә дә, үзенең мәдәнияте һәм тарихы бер булганын һәм шулай ук дошманның уртак бер дошман булганын бик тирән хис итә. Ул бергә бара һәм бер-берсенә ярдәм итә. Русия читендә булган әфган, иран, кытай һәм анатол төркләренең бүген бу авыр хәлгә сәийрчинә (күзәтүче) булып торуларын күреп бик кайгырса да, вакыты килгәндә, кардәш кардәшне таныр фикере берлә ул үзенең өмиден югалтмый һәм киләчәгенә зур бер ышану берлә карый. Исламият җәбһәсенә килгәндә, безнең эшләребез бик фаҗигале. Ислам дөньясында бүгенге көндә һичбер уртак мөәссәсә (нигез) юк. Бүген һичбер ислам дәүләте, кечкенә генә рәвештә булса да, ислам сәясәтен йөртә алмый, алар чит илдәге дин кардәшләрен химая (таяныч) итә алмыйлар һәм итмиләр. Большевикларның христиан диненә каршы золымнарына каршы, папа хәзрәтләре башта булган хәлдә, бөтен христиан дөньясы аякка калыкты. Яһүди динен кысуга каршы бөтен Аурупа һәм Америка яһүдиләре тавыш куптарды. Ләкин 30 миллион мөселман аларга караганда өч-дүрт мәртәбә артыграк золымга мәгъруз калса да, һичбер мөселман мөәссәсе, һичбер мөселман патшасы, һичбер мөселман дәүләте аларны химая итү турында бер авыз сүз сөйләмәде. Шуның өчен мин үземнең кардәшләремә шул 30 миллион мөселманның аһ-зарын ишеттерергә ислам мәдәниятенең бүгенге мәркәзе булган Мисыр мөселман дәүләтеннән мәгънәви ярдәм сорарга килдем. 30 миллионлы мөселманның тарихта охшашы күрелмәгән авыр хәлен сезнең мөселманлык вөҗданыгызга әманәт иттем.

Мин шул сүзләр берлә конферансымны бетердем. Менә бердән кыямәт купты. Сүз сораучыларның исәбе-хисабы булмады. Бөтен зал беравыздан әйткән кебек: «Безнең илебездә әллә никадәр качак урыслар, әрмәннәр ярдәм күрәләр дә (күрсәләр дә), без ни өчен Русия мөселманнарына ярдәм итмибез. Ник аларга каршы эшләнгән бу җәбер-золымны бетерергә тырышмыйбыз?! — ди иде. Бик күп кеше мине әйләндереп алып, башка җирләрдә дә конферанс бирүемне сорадылар, гәзитләрдә туктамастан бу турыда мәгълүматны киңәйтергә тырышалар иде. Икенче көнне Мисырның бик күп гәзитләрендә бу конферанс басылып чыкты.

Икенче көнне мин гарәп хариси музәханәсенә (гарәп милли мәдәнияте музеена) киттем. Гарәп мәдәниятенең бер күргәзмәсе урынын тотачак бу музәханә бик күп кыйммәтле әсәрләрне җыйган икән. Ләкин гарәпләр үзләренең милләтчелекләрендә без төрекләргә охшамыйлар. Алар бик куе милләтчеләр-шовинистлар. Шуның өчен боларга кирәк музәханәдә шактый күп фарсы, һинд һәм төрек әйберләре гарәп эше кебек күрсәтелгән һәм гарәп музәханәсенә ислам мәдәнияте музәханәсе төсе бирелгән иде. Ләкин ничек булса да, бу әсәрләрнең җыелып саклануы, югалмавы яхшы.

Мин яхшы ук авыр уйларга керергә мәҗбүр булган бер хасталык берлә 3–4 көн ятакта калырга тиеш булдым. Инде Сәгыйд Шамил дә килгәнгә, безгә Мисырдагы рәсми эшләребезгә керешергә вакыт бик җиткән иде. Шуның өчен Габделхәмид Сәгыйдбәк аркылы Шәйхел-Әзһәргә телефон иттереп бер рандеву (очрашу) алдык. Шулай ук Мисырның иң зур фиркаларыннан булган Вафид башлыгы Нәлхас (Нәхас, Нилхас) пашадан да бер көн билгеләттек. Шул ук көннәрдә «Шөббанел-мөслимин» җәмгыяте дә безнең хөрмәтебезгә бер чәй зияфәте (мәҗлесе) ясады. Мисырга килүебезгә бик аз гына вакыт үтүгә карамастан, инде аның эчке тормышына кереп бара идек. Мөселманлыкның зур хадимләреннән Габделгазиз Сәгалби хәзрәтләре берлә Габделхәмид Сәгыйдбәкләр безне Мисырның гыйлем, әдәбият һәм сәясәт фиркаларының клубларын зиярәт итү берлә мәшгуль булсак, кичләрен әле бер галимнең, әле бер сәясинең, әле бер мөхәррирнең өенә чакырулы була идек.

Шул көннәрнең берендә Вафид фиркасының башлыгы һәм иске Садрәгъзам Нәлхас пашаны да зиярәт иттек. Бу фирка — мәрхүм Зәгълүл паша фиркасы. Ул соңгы 10 ел эчендә Мисыр сәясәтендә зур роль уйнаган бер фирка булганга, аның рәисе булган Нәлхас пашаны да үзләренең матбугатлары әррәис дип кенә йөртәләр. Алар үзләренең клубларын «Бәйтелөммә» («Диндәшләр йорты») дип атыйлар. Мәрхүм Зәгълүл пашаның хатынын да Өммүл-мисрийун (мисырлыларның ана-

сы) дип йөртәләр. Бу сүзләр халыкның күңеленнән чыгып бирелгән исемнәрме, әллә фирка матбугатының пропагандасы берлә генә туганмы — моны читтән килгәннәргә кыска вакытта гына аңлату җиңел түгел. Ләкин мисырлылар иске тарихлы бер милләт булганга һәм тарихларында да дөньяның мәшһүр әсәрләре зур әһрамлар (пирамидалар) булганга, алар сүздә дә зурлыкны-арттыруны бик яраталар. Монда бер кешене икенче берсенә танышканда да шагыйрь булса — «сәйд әш-шөгара» (шагыйрьләр патшасы), мөхәррир булса — «әмирел-әдиба» (әдипләрнең әмире), галим булса — «әфзалел-фазла» (фазыйлларның фазыйле — галимнәрнең-галиме), доктор булса — «хәкимел-хөкәма» дип тәкъдим итәләр. Башка эшләрдә дә шулай зур итүне, күтәрүне бер дә онытмыйлар. Әлеге югарыдагы исемнәрдә дә шундый берәр нәрсә бардыр.

Нәлхас пашаны күрер өчен без Вафидның клубына килдек. «Бәйтел-өммә» — бер зур сарай. Эченә кердек. Безне әллә никадәр андагы әгъзалар каршы алдылар. Зур бер хөрмәт берлә рәис бүлмәсенә керттеләр. Зур-зур салоннарны үттек. Аларның барысы да бик бай иттереп җиһазланганнар иде. Бу клуб Эстония рәис җөмһүренең (премьер-министрының) сараеннан зуррак та һәм баерак та иде. Монда каһвәләребезне эчкәннән соң, Нәлхас пашаның үз өенә алып киттеләр. Бусы да бер зур кунак, бер сарай иде. Безне монда да каршы алып, «әр-рәис»нең кабинетына керттеләр. Без кергәч, анда хазыйр булганнар (катнашканнар) барысы да аякка калыкты. Нәлхас паша үзе дә урыныннан торды. Түргә утырттылар. Габделгазиз Сәгалби безне тәкъдим итте һәм сөйләшүләр башланды. Вафидның шигаре (лозунгысы) бу вакытка кадәр Әл-Мисру лил-мисриййун (Мисыр — мисырлыларның) булганга, ул гарәпчелек һәм мөселманчылык сәясәтеннән бераз ераграк тора. Мисыр сәясәтендә зур роль уйный торган христиан гарәпләрен куркытмас өчен, ул мөселманлык эшендә бик сак хәрәкәт итә иде. Без монда мөселманлык эше берлә килгәнгә, аларны мөселманлык сәясәтен тәгъкыйб итүчеләр кебек сөйли идек. Корылтайдагы әгъзаларның хезмәтләре өчен рәхмәтләр укыдык. Нәлхас паша безне бик тиз аңлады. Үзе бик үткен кешегә охшый. Сүзгә бик оста. Ул сөйләгәндә, тыңлаучылар тәмам эреп китәләр иде. Ул Аурупаның иксез-чиксез либерализм фикерен үзенә бөтенләй сеңдергән. Аурупаның империализмы турында озын-озын сөйли иде. Хәрәкәтләре берлә ул җәнүб (көньяк) мәмләкәтләрендә бик күп очрый торган кызу бер пропагандачы кебек иде.

Каһвәләребезне эчеп, күрешеп чыктык. Паша безне ишеккә чаклы озата килде. Ишек янында әллә никадәр фотографлар рәсемнәребезне алдылар. Зур дәфтәргә имзаларыбызны куеп чыктык. Без, моннан туп-туры «Шөббанел-мөслимин» җәм-

гыятенә барып, Габделхәмид Сәгыйдбәк берлә бергә, «Җәмигыл-Әзһәр» шәехен зиярәт өчен, Диния мөдириятенә киттек. Мөхәммәд әл-Әхмәди әз-Заваһири хәзрәтләре безне бик зур кадер-хөрмәт берлә кабул итте. Матур йөзле, үткен күзле, алтмыш яшьләрендә бер галим. Аның симасы (йөзе, кыяфәте) тамырларында төрек каны акканын күрсәтә. Сүзләре бик акыллы һәм төпле иде. Ул бик оста иттереп безгә бик күп сөальләр бирде. Шәйхел-Әзһәр хәзрәтләренә, мөселман дәүләте булган Мисырның Диния мөдириятенең рәисе сыйфаты берлә СССР-да яшәгән мөселманнарның дин ягыннан җәберләнүләре хакында сөйләп, ислам дөньясының шул зур мөәссәсенең (оешмасының) ярдәм итүен сорадык. Ул безгә: «Мисыр дәүләте мөселман дәүләте, Мисырның патшасы Мәлик Фуад ихласлы бер мөселман. Мин кулымнан килгән кадәр исламияткә хезмәт итүче бер мөселманчы. Русиядәге мөселманнарның җәберләнүләреннән бик мөтәәссир булдым (кайгырдым). Мин моны бөтен дәүләт адәмнәренә белдерәчәкмен. Без рәсми бер мөәссәсә булмаганга, Русия мөселманнарын химая итүне дә (яклауны да) рәсми бер юлга куяр өчен сез безгә бер рәсми гариза языгыз, кулыгыздагы вәсикаларны (дәлилләрне; материалларны) күрсәтегез», — диде. Без дә шулай итәргә булдык. Габделхәмид Сәгыйдбәк, бу эшне бөтенләй Аурупа ысулына куяр өчен, бер махсус комиссия ясауның мөнасиб икәнлеген сөйләде. Без дә аны муафикъ таптык. Шәйхел-Әзһәр дә бу хакта уйлашырга булды. Моннан соң да бик озын сөйләшеп утырдык. Шәйхел-Әзһәр миндә бик зур тәэсир калдырды. Ул мөселман галимнәре арасында бик сирәк очрый торган акыллы, тәрәкъкыйпәрвәр (прогресс яклы) бер галим; бик оста бер Шәрык дипломаты, киң күрешле бер ислам сәясие һәм фикре берлә чын мөселманчы. Без халкыбызның эше шундый төпле бер кешенең кулына элэгүенә сөенә-сөенә чыктык.

Инде безнең бурычыбыз, Шәйхел-Әзһәр сораган рәвештә, бер меморандум язып бирү, — большевик хөкүмәтенең исламиятне керчеләвен (кысуын) объектив дәлилләр берлә күрсәтү иде. Мин Кодес корылтаена барыр алдыннан мондый бик күп дәлилләрне җыйган идем: большевикларның «Алласызлар җәмгыяте» чыгарган мәҗмугалар, большевик хөкүмәтенең диннәр (текстта «дәлилләр» дип ялгыш басылган) хакындагы декретлары, большевик гәзитләреннән алынган мәсҗедләрне ябу, голяманы хокуксыз калдыру, имамнарны сөрү хакында большевикларның үз куллары берлә язылган мәкаләләре, әмерләре һәм хәбәрләре. Ләкин болар урысча һәм татарча басылган китап, гәзит һәм мәҗмугалардан алынган булганга, аларны гарәпчәгә тәрҗемә итү кирәк иде.

Сәгыйдбәк берлә меморандумның ана хатларын(төп текстын) карар астына алдык (үзебезнең җаваплылыкка алдык).

Икенче көнне мин шуның төп маддәләрен төрекчә яздым. Хәмзә Таһирбәк һәм берничә чиркәсләр берлә ясаган бер хосусый мәҗлестә аны укып чыктык. Меморандум фәнни язылган һәм маддәләр (статьялар, пунктлар) яхшы тәртип ителгән, дип табылды. Ләкин мөкаддимәне (керешне) гарәп ысулы өчен кыска һәм коры таптылар. Бу кыйсемне язу Сәгыйдбәк берлә чиркәсләргә тапшырылды.

Эшнең иң авыры хәзер большевикларның декрет-фәрман, мәкалә һәм хәбәрләрен гарәпчәгә тәрҗемә итү иде. Боларның урыс телендә булганнарына Русиядә укыган берничә христиан гарәпне табып булса да, татарчалары өчен Хәмзә Таһирбәктән башка кешебез юк иде. Шуңар күрә бу зур йөкне аңа йөкләдек һәм бер кочак китап, мәҗмуга, гәзит биреп, шуларда минем тарафымнан күрсәтелгән урыннарның гарәпчәгә күчерелүен үтендек. Хәмзәбәк, көн-төн утырып, шуларны хәзерли. Кафкаслы аркадашларыбыз да мөкаддимәне өлгерттеләр. Без меморандумны, матбагада (машинкада) бастырып, Шәйхел-Әзһәргә тәкъдим иттек. Шәйхел-Әзһәр бөтен эшне рәсми юлга куйды. Берничә голәма һәм мәэмүрдән (чиновниктан) ясалган бер һәйят (комиссия) алдында ул безнең кәгазьләребезне алды. Безнең биргән вәсикаларыбыз берәм-берәм номерлап язылды. Боларның Совет хөкүмәте вәсикалары булганлыгын исбат итү безнең өстебезгә йөкләнде.

Мондагы мәэмүрләр Совет системасын бер дә белмиләр. Анда матбугатның коммунист фиркасының диктатурасы астында гына булганын, һәрбер басылган китап коммунист цензурына табигъ (буйсынулы) икәнлеген, Совет илендә Аурупадагы мәгънәдә һичбер төрле матбугат, җәмгыять, сүз хөррияте юклыгын аңламыйлар. «Алласыз»ларның мәҗмугаларына килгәндә, алар: «Хәзер дөньяда мондый җәмгыятьләр бик күп. Алар Аурупаның бик күп мәмләкәтләрендә бар. Вөҗдан хөррияте булгач, әлбәттә, динсезләр җәмгыяте дә була ала. Андагы мөселманнар тотсыннар да аларга каршы динлеләр җәмгыяте ачсыннар һәм динлеләр мәҗмугасы чыгарсыннар», — диләр. Без Совет хөкүмәтенең «Дин-әфьюн!» дип башланган дин хакындагы декретын укыйбыз. Динсезләр җәмгыятьләренең Совет хөкүмәтенең әмере берлә эшләнгәне хакында коммунист фиркасының съезд карарларын күрсәтәбез. Динлеләр җәмгыяте ясарга канун буенча имкян (рөхсәт) юклыгын, бөтен матбага һәм кәгазь хөкүмәт кулында булганга, дини бер мәҗмуга түгел, бер догалык бастырырга да мөмкин булмаганын сөйләп, бик күп фактлар китерәбез. Большевикларның үзләреннән алынган бик күп дәлилләр берлә дәгъвабызны исбат итәбез. Без, шулай итеп, беренче маддәбездә күрсәтелгән Совет хөкүмәтенең диннәргә мөсагадә (мөмкинлек) итмәгәнен исбат итә алдык. Бу бетү берлә тагын икенче бер сөаль бирелә: «Сез

ислам динен башка диннәргә караганда артык кысалар, дигәнсез. Моңа дәлилләр кая? Безнең белүебезгә караганда, Совет илендә дин һәм милләт аермалары бетерелгән. Анда тигезлек, анда бер динне кыссалар, башкаларны да шулай ук кысалар. Кысмасалар — барысына да бертөсле мөгамәлә итәләр». Без тагы большевик мәҗмуга һәм гәзитләреннән тәрҗемә итәргә тотынабыз. Мөселманнарның артык җәберләнүләрен күрсәткән цифрлар берлә берничә мисал китерәбез. Аларга большевикларның үзләре язып, үзләре баскан мәҗмугаларны һәм гәзитләрне күрсәтәләр. Алар бу мәҗмуга берлә бу гәзитләрнең наширләре һәм мөхәррирләре кем икәнлеген, аларның нинди матбагада басылганлыкларына кадәр тикшерәләр, язалар. Без боларның барысының да коммунист фиркасы — Совет хөкүмәте тарафыннан эшләнгәнлеген исбат итә алабыз.

Сәгатьләр буе утырып, без әле бары ике маддәгә генә дәлилләр куя алдык. Безнең меморандумда 12 маддә булганга, мәҗлес дәвам итә. Сөаль өстенә сөаль бирелә. Без зур бер имтиханга тотылган кешеләр хәленә куелабыз. Кайвакыт ачуыбыз да килә. Ләкин дәгъвабызны исбат итәргә кирәк булганга, без дәлил өстенә дәлил вәсика бирә барабыз. Дүрт-биш сәгать сөргән мәҗлес барыбызны да арыта; Әзһәр голәмасы да безнең меморандумдагы маддәләрнең тугрылыгына иманын куәтләндерә. Шуны күреп, мин большевикларның исламны кысуларын күрсәткән, төрле мәҗмугалардан алган фотограф рәсемнәрен чыгарам. Монда клубка әверелгән мәсҗеднең манарасына эленгән кызыл байрак та бар; сыраханәгә чәверелгән (әйләндерелгән) мәсҗед ишеге өстенә асылган Ленин һәм Троцкий рәсемнәре дә бар. Монда динсезләрнең гает көннәрендә музик берлә ясаган демонстрацияләре дә бар. Монда татар кызларын дуңгыз асрарга өйрәткән курста алынган рәсемнәр дә бар. Шулар янына динсезләрнең берничә җырлары кушыла. Голәмаларга болар барысы да бик зур тәэсир ясый. Алар бер-берсенең күзенә карашып «Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ, безнең андагы дин кардәшләребез Әндәлусиядәге (Андалузия. — *ред. иск.*) мөселманнарның күргәннәреннән зуррак золымнарга мәгъруз калганнар (дучар булганнар) икән. (Урта гасырларда Пиреней ярымутравында — Әндәлусиядә мөселман дәүләтләре яши. Әмма алар ахыр чиктә христианнар тарафыннан рәхимсез рәвештә юкка чыгарыла. — *Х.М.*) «Боларга ярдәм итү — дини фарыз!» — диләр. Безгә карап: «Безнең сездән бу кадәр җентекләп сорашуыбызга кәефегез китмәсен. Безнең чыгарган карарыбыз объектив дәлилләргә корылган булырга тиеш. Мөселман голәмасы турында таралган кайбер ифтираларга (гайбәт-ялаларга) урын калмасын дибез», — диләр. Алар шул хакта мәҗлес җыеп, карар бирәчәкләрен вәгъдә иттеләр. Без бөтен вәсәкаларны калдырдык. Алар бу вә-

сәкаларның (материалларның; дәлилләрнең) урысча булганнарын үзләре тәрҗемә иттереп карамакчы булдылар. Аларның урысча белә торган берничә христиан гарәпләре бар икән. (Боларның элек Казан семинарияләрендә укыган гарәпләр икәнлеге соңыннан мәгълүм булды.) Татарчаларының тәрҗемәсе өчен без тагын Хәмзә Таһирбәкне күрсәттек. Без өстебездән бер зур йөк төшкән кебек, өебезгә юнәлдек.

Без Шәйхел-Әзһәр туплаячак мәҗлеснең карарын көтәргә тотындык. Ләкин көннәр үтте. Карар чыкмады. Мәсьәләнең нинди юл алганлыгы да мәгълүм булмады. Без матбугатта һәм җәмгыятьләрдә үз эшебезне дәвам иттек. Хөкүмәт фиркаларының клубларын һәм лидерларын зиярәт иттек. Алардан мәгънәви ярдәм сорадык. Мисырдагы бөтен гарәп гәзитләрен зиярәт итеп, аларга мәгълүмат бирдек һәм язуларын үтендек. Шуның аркасында Русия мөселманнары хакында берәр гәзит йә мәҗмугада берәр мәкалә чыкмаган һәм җәмгыятьләрдә бу турыда сүз сөйләмәгән бер көн калмады. Мисырның бөтен әфкяре гомумиясендә (иҗтимагый фикерендә; җәмәгатьчелегендә) большевизм-исламият мәсьәләсе иң актуаль бер мәсьәлә хәлен алды. Бу француз һәм инглиз гәзитләренә дә күчте.

Без Шәйхел-Әзһәрнең карарын көтүебездә дәвам иттек. Ләкин шул шау-шу һәм шул матбугат кампаниясе Совет хөкүмәтен дә куркытты. Совет хөкүмәте исеменнән бер кеше килеп: «Мин сездән мамык алыр идем», — дип, Мисыр хөкүмәтенә мөрәҗәгать итте. Мисыр — мамык мәмләкәте. Аның иң зур байлыгы — мамык. Ләкин соңгы кризә (кризис) Мисырның мамыгына бик каты тәэсир иткән. Урта хисап берлә 15–18 Мисыр лирасы торган мамыкның бәһасе сугыш башлангач 40 лирага кадәр күтәрелгән. Бу эштән Мисыр һичбер күрелмәгән рәвештә баеган. Бу, табигый, мамык кырларының да көннәнкөн артуына сәбәп булган. Сугыштан соң мамык бәһасе үзенең табигый бәһасенә кадәр иңгән. Соңгы ике елдагы кризәдә аның бәһасе 3 лирага кадәр төшкән. Шуңа күрә Мисырның бик күп мамыгы сатылмыйча, амбарларда ябылып калган. Менә шундый вакытта мамык алырга килүче кем булса да, аның Мисыр өчен бик кадерле кунак булуында шөбһә юк. Большевиклар мисырлыларның бу нечкә җирләреннән файдаланырга уйлыйлар. Алар мамык базарлыгына керешеп, бәһа-фәләндә килешкәч: «Алуын алачакбыз. Ләкин сезнең мәмләкәттә большевикларга каршы бик каты пропаганда бара. Сез шуны туктатмасагыз, безнең хөкүмәт сездән мамык алырга разый булмас. Сез бу Русия мөселманнары исеменнән сүз сөйләүчеләрне куыгыз!» — дип әйтәчәкләр иде. Бу большевик кешесе Мисырга килү берлә, хакыйкатән, безнең пропагандада бераз суыклык башланды кебек күренде. Ул хөкүмәт даирәләренә килде, китте. Сатулашты. Ләкин Мисыр хөкүмәтенең мөселман-

лыгы аның мәнфәгатьчелегеннән өстен чыкты. Мисыр матбугаты тагын үз юлына төште. Рамазан бәйрәмендә Шәйхел-Әзһәрнең протесты чыкты. Шул ук бәйрәмдә Кодес мөфтие әл-Хаҗи Әмин әл-Хөсәйни дә Мәсҗеде аксада Русия мөселманнарының котылуы хакында дога кылып, андагы большевизм золымына каршы протест итте. Шул ук бәйрәмдә Русия мөселманнарының дини хакларын химая кылу хакында Милләтләр җәмгыятенә мөрәҗәгать күндерелде. Бөтен гарәп матбугаты тагын безнең Русия мөселманнарының эше берлә дулады. Без дә үзебезнең дини бурычыбызны үти алганыбызга шатландык. Беренче мәртәбә үз диндәшләребездән мәгънәви ярдәм күреп, сөенеп бәйрәм иттек.

Рамазан бәйрәмнәренә кадәр кулларына барып керерлек иттереп, без бөтен дөньяның мөселман падишаларына Русия мөселманнарының вөҗдани хөрриятләрен саклау хакында аерым мөрәҗәгатьләр күндергән идек*. СССРдагы мөселманнарның хәлләрен күрсәтә торган бик күп материаллар да боларга кушып җибәрелгән. Алардан мөселманлык ярдәме үтенелгән иде. Без бу эшкә киң мөселманлык ноктасыннан караганга, мәйдандагы мөселман падишаларының танылганнарының берсен дә читтә калдырмадык. Мисыр мәлиге — Фуад, Хиҗаз мәлиге — Ибне әс-Согуд, Гыйрак короле — Әмир Фәйсал, Әфган әмире — Надир шаһ, Иран шаһы — Риза хан, Фас солтаны — Мәүләви Хәсән, Ямән имамы — Имам Яхъя хәзрәтләренең барысына да аерым-аерым мөрәҗәгать иттек. Падишаларга әйтелгән мөрәҗәгатьләр аерым кешеләргә язылган хатлар кебек булмаганга, боларны да ригая итәргә (олыларга) кирәк иде. Бу безнең кебек халык хезмәте артыннан йөреп, вакытын гарәп халкы арасында сарыф иткән кешеләргә сарайларның гореф-гадәтләрен белү-өйрәнү бик җиңел түгел иде. Шуңарга без сарай мәрасимен (йолаларын) өйрәнгән таныш-белешләрдән бу мөселман падишаларының исемнәрен, ләкабләрен (кушамат-титулларын) өйрәндек. Мөрәҗәгатьнең ни төсле булуы хакында без фикер ясадык.

Төрекчә язылган мәктүпне гарәпчәгә тәрҗемә иттереп, оста язучыдан матур иттереп яздырырга вә һичбер ноктасына кара тамызмыйча матур, пакь көенчә күндерергә кирәк иде. Чиркәс кардәшләребездән бер рәссам, күз нурын түгеп, безнең мөрәҗәгатьләребезне бик матур итеп язды. Бу зәхмәтле эш шактый күп вакыт алды. Алай да кайбер җирләрендә хаталар ясаштыргаладык. Мәсәлән, без Иран шаһы Риза хан Пәһләви хәзрәтләренә язылачак мөрәҗәгатькә «Әббәдаллаһу дәүләтәһу» («Аллаһ аның дәүләтен мәңгелек итсә иде») дигән бер гыйбарә язганбыз. Вәхаләнки (чынлыкта) Иран сарай гадәте буенча... «Хәлләдаллаһу

* Бу мөрәҗәгатьнең гарәп телендә язылган асылының кечерәйтелгән фотографиясе "Яңа милли юл"ның 8 нче санында басылып чыкты *(Г.И.)*.

гомрәһу» («Аллаһ аның гомерен озын итсә иде») дип язарга кирәк икән. Инде боларны җибәрү ысулы калды. Падишаһларга мөрәҗәгатьләрне почта берлә күндерү гадәт түгел. Үзебез барырга вакытыбыз-имкянебез (мөмкинлегебез) юк. Шуңар күрә без Мисырда илчеләре булган мөселман дәүләтләренең илчеләренә барып күндерүләрен үтенергә, юкларына аерым пакетларда һава почталары берлә күндерергә карар иттек. Моны юлга чыгарыр өчен Мисырдагы Иран, Әфган, Хиҗаз һәм Гыйрак сәфирләренә (илчеләренә) кабул вакытларын сорап, мөрәҗәгать иттек. Сәфирләрнең барысы да безгә аерым-аерым көннәр билгеләделәр. Без аларны аерым-аерым барып зиярәт иттек. Аерым-аерым СССРдагы мөселманнарның хәлләрен аңлатып, дәүләтләренең, падишаһларының мөселманлык бурычын үтәүләрен сорадык. Бу кабул итүләр кайберләрендә икешәр-өчәр сәгать сөрде, озын-озын конферанс төсен алды. Сәфирләрнең иксез-чиксез сөальләренә җаваплар бирергә мәҗбүр булдык. Мондагы мөселман сәфирләре ике-өч ай Мисыр матбугатында дәвам иткән Русия мөселманнарының ачы хәлләрен укып, ишетеп торганга, боларның һәммәсендә дә безнең эшебезне белүчеләрне, безнең Русия мөселманнары берлә кызыксынучыларны күрдек. Аларның бик күбесендә үзебезнең мәгънәви ярдәмчеләребезне таптык. Аларның барысы да үзләренең падишаларына безнең мөрәҗәгатебезне күндерәчәкләрен һәм үзләре тарафыннан язылуы кирәкле булган мәгълүматны бирәчәкләрен вәгъдә иттеләр. Мисыр мәлиге Фуад хәзрәтләренә үзебез илтеп тапшырдык.

Бу мөрәҗәгатьләрнең күндерелүе хакында вакытында Аурупа матбугатында бик күп язылды. Бу мөрәҗәгатьләрнең күбесе бәйрәм көнне барып җитәчәк булганга, без аларның тәэсирләрен көтә идек. Беренче Гыйрак падишаһы Әмир Фәйсалдан хәбәр килде. Әмир хәзрәтләре бик зур дикъкать берлә мөрәҗәгатебезне укыганын һәм кулыннан килгән кадәр мөселманлык бурычын үтәргә хәзер булганын белдерә иде. Аралар ерак булганга, башкаларның җаваплары бераз кичексәләр дә, шул төстә иделәр. Бәйрәм бүләкләре арасында Сүрия мөфтисенең Русия мөселманнарының котылуын теләп, җәмигъда дога кылдыруы вә Сүрия мөселманнарының бу хакта «Җәмгыяте әкъваль»га («Милләтләр лигасы»на) мөрәҗәгать итүләре(н) белдерә иде. Мисыр гәзитләренең бәйрәм номерларының барысы да Шәйхел-Әзһәрнең протесты берлә тулы иде. Һәрбер гәзиттә шул хакта мәкаләләр язылган иде. Вафид гәзитләреннән «Кәүкәбеш-Шәрык»та («Шәрык йолдызы»нда) гарәпнең зур язучыларыннан Гыйас Мәхмүд әфәнде генә шундый зур уртак мөселманлык мәсьәләсендә, фиркачылыктан аерыла алмыйча, Шәйхел-Әзһәрне «ник Тарабулус (Триполи) мөселманнарын химая итми (якламый)» дигән төстә тәнкыйтьле бер мәкалә язды. Бу мәкалә безнең кәефебезне бик бозганга,

без икәүләп Вафид гәзитләрен зиярәткә киттек. Мин «Әл-Җиһад» берлә «Әл-Бәлаг»ка бардым; Сәгыйдбәк «Кәүкәбеш-Шәрык»ка китте. Икенче көнне Вафиднең бөтен гәзитләрендә Шәйхел-Әзһәрнең ислам галәменә мөрәҗәгате хакында озын мәкаләләр язылган һәм Мисыр халкы диндәшләре булган Русия мөселманнарына ярдәмгә чакырылган иде. Бигрәк тә «Әл-Җиһад»та язылган мәкалә бик кыйммәтле иде. Мисырда француз дуслыгы фикерен алып баручы «Әл-Әһрам» гәзитендә зур бер мәкалә бар иде. Башка кечерәк гәзит вә мәҗмугаларның һәммәсе дә аңа зур урын биргәннәр иде. Хәтта көлке журналлар да безне Шәйхел-Әзһәр берлә бергә төшереп, үзләренчә мәсьәләгә катышканнар иде.

Гарәп матбугатының бу кадәр кайнарлык берлә мөзакәрә иткән (тикшерелгән) мәсьәләнең Аурупа матбугатына да күчүе бик табигый иде. Мисырның французча, инглизчә һәм итальянча чыккан гәзитләреннән башка, аларның Аурупа ажанслары (агентлары; вәкилләре) тарафыннан таратылуы кирәк иде. Вена һәм Женева ажансларының бу хакта телеграфлар күндерүләрен белсәк тә, инглиз, француз, итальян һәм Америка матбугатының мондый эш эшләүләрен тоя алмадык. Шул юлда безгә ярдәм итәр өчен, Мисыр матбугат әһеленә дә мөрәҗәгать иттек. Ләкин ни өчендер инглиз берлә француз ажанслары безне химая итү хакында Шәйхел-Әзһәрнең ислам дөньясына иткән мөрәҗәгатен таратмадылар. Алар бу эштә үзләренә бер зарарлы нокта күрделәрме? Әллә большевиклар берлә дуслык ясауны мөселман дөньясыннан артык күрделәрме? Аңлый алмадык. Ләкин без бөтен гарәп дөньясындагы хәрәкәтебездә инглизләр берлә французларның һәм алар артыннан бара торган христиан гарәп матбугатының ярым галякасызлыгы (бәйләнешсезлеге; тотнаксызлыгы), ярым дошманлыгы берлә каршылаштык. Инглиз тарафдарлыгы берлә танылган «Әл-Мокаттам» (Каһирә тирәсендәге тау исеменә мөнәсәбәттә бирелгән гәзит атамасы) берлә французларга бик якын торган «Әл-Әһрам» гәзитләре бик озакка кадәр безнең дәгъвабызга сәхифәләрен ябык тоттылар. Мисырдагы әфкяре гомумия (җәмәгатьчелек) җиңеп китеп, безнең большевикларга каршы эшләребез бик зурайгач һәм безнең кем булуыбыз Америкадан килгән боксердан һәм Италиядән килгән биючедән мәгъруф (билгеле) булып өлгергәч кенә, алар безнең эшләребез хакында мәкаләләр язарга керештеләр. Большевиклар тарафыннан уйдырылган «мөселман» корылтаен инглизләр ясатты, аның эшләрен инглизләр йөретте, дигән сүзне һичбер тәнкыйтьсез кабул иткән төрек матбугатына монда уйларлык шактый гына материал бар. Ләкин уйлап торганча, большевик уйдырып биргәнне кабул итәргә өйрәнгән кешеләргә «Аңлаганга — сүри (печән җыя торган чыбык) — сәнәк тә саз (музыка коралы),

аңламаганга — дәвал (барабан) — думбра да аз» мәкаленнән башка җавап юк.

Шәйхел-Әзһәрнең ислам дөньясына мөрәҗәгате яңа бер мәйдан ачты: гарәп матбугатында шул хакта яңа бер фикер туды. Ул да: Мисырның тарихи җәмигъларының берсендә зур бер дини мәҗлес ясап, шунда Русия мөселманнарының хәлләрен тагын бер мәртәбә күздән кичереп, Русия мөселманнарына ярдәмне гамәли бер юлга кую һәм Мисырда Русия мөселманнарының эше берлә шөгыльләнә торган бер даими оешма мәйданга китерү иде. Без шул эш берлә шөгыльләнә беләчәк төрле даирәнең олуглары берлә күрешергә-сөйләшергә тотындык. Ләкин Мисырда фиркачылык бик тирән җирләшкәнгә, бик күп хөрмәтле кешеләр үзләренең бу эшкә катышулары өчен икенче бер фирканың олугларыннан фәлән-фәләннең катышмавын шарт иткәнгә, без бик авыр вазгыятькә төштек. Без бик күп вакыт һәм көчебезне сарыф итсәк тә, әле шундый бер мәҗлесне ясап булу-булмау хакында шөбһәдә калдык. Читтән генә булса да, безгә каршы кайбер интригалар барын күреп, бу эшне мисырлыларның үзләренә тапшырдык.

Минем монда торуым бик озаеп киткәнгә, илемдә-йортымда бик күп эшләрем булганга, мондагы дус-иш һәм фикердәшләрдән шул хәрәкәтне алып баруны үтенеп, юлга хәзерләндем. Мин Фәләстин аша Сүриягә кереп, Бәйрутта пароходка утырып, Италия юлы берлә Аурупага кайтачак идем. Аркадашым Сәгыйд Шамилбәк мондагы эшләрне бер изге нәтиҗәгә ирештерергә тырышачак иде. Мисырда таныган-белгәнем бик күбәйгән иде. Алар берлә күрешеп, юлга чыгачак булдым. Юлым, Кантарада Сүәеш каналын үтеп, Фәләстингә керәчәк иде. Моның өчен тагын бер инглиз визасы кирәк булды. Юлым бик озын булып, бик күп мәмләкәтләрне үтәргә туры килгәнгә, визалар да бик масрафлы (кыйбат) иде. Гәзитчеләргә визаны буш бирү гадәт хәленә килгәнгә, берничә мәмләкәттән башкасында, мин һәрвакыт визаны бушлай ала килә идем. Инглиз консулына да паспортымны суздым: «Мөхәррир, бушлай виза», — дидем. Мәэмүр (чиновник) күзләрен акайтып, төрекчә паспортымны әйләндереп-әйләндереп карады да: «Виза биреп-бирмәвебезне белер өчен иртәгә килегез, бушлай булу ихтималы юк!» — диде. Күпме торачагын сорадым. Җиде доллар чамасы бер цифрны әйтте. Кодес-Шәрифкә барып, безнең анда сайлап калдырган... «Башкарма һәйәте»нең ни хәлдә барганын күрәсем килгәнгә, Яффа күршендә яһүдиләрнең яңа салган Тел-Абиб шәһәрен һәм Хәйфада илдәшем Габдулла Тимерне зиярәт итәсем килгәнгә, икенче көнне теләр-теләмәс тау чаклы акча биреп, инглиз визасын алдым. Озатырга Мисырдагы дусларымнан, ислам галәменең Мисырдагы мәшһүр хадимнәреннән бик күп кеше чыккан иде. Самими күрешүләрдән соң мин юлыма юнәлдем.

* * *

Мин хәзер тагын Фәләстингә барып, аннан Сүриягә чыгып, Бәйрутта пароходка утырып, Тагуктан Италия юлы берлә Аурупага кайтачак идем. Искәндәрия-Яффа йә Искәндәрия-Хәйфа юлы пароход берлә бик бәһале, бик озын булганга, мин тимер юл берлә генә китәргә мәҗбүр булдым. Монда Фәләстин берлә Мисырны баглый торган бер генә тимер юл булганга, килгән юлымнан киттем. Сүәеш каналы аша чыгып, Кантарада инглиз-Мисырның уртак гүмрүген (таможнясын) үтәргә кирәк иде. Бу араларда монда инглиз лирасы төшү-очсызлану дәвере булганга, аңа багланган Фәләстин һәм Мисыр лиралары да төшеп килә һәм шуның аркасында алтын бәһасе күтәрелә иде. Төрле җиңелдән мал табарга өйрәнгәннәрнең кулында алтын спекуляция малы булып килә иде. Кәгазь акча төшкәнне белмәгән халыктан алтынны җыеп алып, чит илләргә сату итүчеләргә киң юл ачылган иде. Ләкин Мисыр хөкүмәте алтын алуны хәзинәнең генә (бу очракта — банкларның) хакы итеп игълан иткәнгә, Мисырдан алтын чыгаруны тыйганга, алтынны чыгарыр өчен болар качак юлларына керешкәннәр иде. Шуның өчен гүмрүктә тикшерүләр бик нык була дип, гәзитләрдә укыганга, минем алтыным-фәләнем булмаса да, гәзит һәм мәҗмугаларым бик күп булганга, боларны актаруларыннан шактый курка идем. Гүмрүккә керү берлә мин әйберләрне караучыга: «Ислам корылтае башкарма әгъзасы» дип язылган картамны тоттырдым. Ул шуны укыр-укымас олырагына китеп күрсәтте. Ул әфәнде, үзе килеп, тәфәззуллу (рәхим итегез!) дип, һичбер карамыйча, чемоданнарыма «рөхсәт» кәгазьләрен ябыштырып, паспорт мөгамәләмне дә җиңеләйтер өчен, минем берлә бер мәэмүрне (хезмәткәрне) дә күндерде. Аннан минем паспортымны күз ачып йомганчы эшләп бирделәр. Мин беренче юлчы булып вагонда урын алдым. Мөселман һәм мөселман җәмгыятьләренең әгъзасы булганым өчен бик күп вакытлар төрле мыскыллар, хөрмәтсезлекләр күрергә өйрәнгән миңа мөселманлыкның болай шәрәфле-хөрмәтле булуы бераз гаҗәбрәк тоелды. Без Мисыр мәэмүренең миңа шәхесем өчен түгел, мөселман корылтаеның әгъзасы булуым өчен кылган хөрмәтенә чын күңелемнән сөендем. «Мөселман»лыкның әле кыйммәте югалмаган җирләр дә барлыгын, мөселман җәмәгать хадименә хөрмәт итәргә кирәк дигән игътикадның (ышанычның) яшәгән урынның бар икәнен күреп, мөселманлык хиссиямә һавалык та керде.

Китәргә әле бик күп вакыт булганга, гүмрүккә тагын бер кереп, шул кешенең йөзен танып калыйм дип, бер карадым. Юлыбыз моннан соң бик тыныч үтте. Тик вагоннар бик тар булганга, йокларга имкян (мөмкин) булмады. Яффага иртүк

килеп җитсәм дә, отель табу бик җиңел булмады. Җуынып, киенеп, бер автомобиль яллап, Кодеска киттем. Максадым: безнең корылтайның сайлап калдырган башкарманың эшләрен һәм нинди карарларының вөҗүдкә чыгарылганын күз берлә күрү һәм ул әгъзалар берлә контактка килү иде. Башкарманың рәисе мөфти Әмин әл-Хөсәйни хәзрәтләрен мәҗлестә очраттым. Аның берлә озын-озын сөйләшкәннән соң, Ләҗнәту тәнфизиянең (Башкарма комитетның) башкармасын карарга киттек. Сәркатиб итеп сайланган әгъзаи сабикъ (элеккеге) Иран баш вәзире Зыяэддин Табтабаш бәк әле Аурупадан килеп җитмәгән булганга, Кодесның олуг мөфтисе Әмин әл-Хөсәйни башкарманың рәисе сыйфаты берлә бюроны идарә итә иде. Корылтай беткәнгә озын бер вакыт үтмәгән булса да, бюро да инде тәмам юлга куелган бер хәлдә иде. Бик күп кизүдәге эшләр тәртипкә куелып өлгергән, карарларны эшкә ашыруга керешелгән иде. Без күргәндә, бюрода эшләр кайнап тора иде. Бер тарафта — корылтайда сөйләнгән нотыклар тәртипкә куелып, бер хисап төсендә нәшер ителергә хәзерләнә. Икенче якта кабул ителгән карарлар төрле ислам халыкларының телләренә тәрҗемә ителә. Өченче тарафта мөселман эшләре берлә галякалы (бәйләнешле) Аурупа дәүләтләренә һәм җәмгыяте әкъвамга (халыкара җәмәгатьчелеккә) күндерер өчен, алар Аурупа телләренә тәрҗемә ителеп, рәсми бер вәсика (документ) хәленә сугыла иде. Шулай ук корылтайга катышкан мөселман милләтләр хакындагы материаллар җыелып, мөселман дөньясының бөтен тормышын өйрәнәчәк үзебез эшләгән яңа бер институтның нигезе корыла иде. Корылтайның эчке һәм тышкы дошманнары тарафыннан «Ләҗнәту тәнфизия»нең эш эшли алмаячагы хакында таратылган төрле мәгънәсез сүзләрнең ялган икәнлеген күзем берлә күреп сөендем. Шул эшне эшли алган Фәләстин олуг мөфтисе Әмин әл-Хөсәйнинең гайрәт һәм уңганлыгы алдында башны идем.

Кодеста шактый күп танышларым булса да, аларның барысы берлә дә күрешергә вакытым юк иде. Шуңа «Әл-җәмигату әлгәрабийә» идарәсен зиярәт итеп, безгә бик зур ярдәм иткән Мөниф бәк әл-Хөсәйнигә рәхмәт укып, дуст-ишкә гәзит аша бер тәшәккер хаты язып, юлыма китәчәк булдым. Хәйфа шәһәренә бергә дәгъвәтле (чакырулы) шәйх Ягъкуб әфәндене зиярәт итеп, аның тәмле чәен эчәргә киттем. Анда тагы бик күп таныш-белешне очраттым. Аларның сораулары берлә бер көн Кодеста калырга мәҗбүр булдым. Кичне шәйх Ягъкуб әфәнде өендә Бохара пылавы, Казан чәе янында уздырып, үзара сөйләштек, дәрдләштек.

Икенче көнне Яффага кайтыр-кайтмас, яһүдиләрнең бөтен дөньяга мактанган шәһәрләре Тел-Абибны (Тель-Авивны) зиярәткә киттем. Бу шәһәр Яффаның күршесендә генә. Ике шәһәр арасында бер тар гына юл үтә. Кайбер җирләрен әфлисун

бакчалары аера. Мин бу шәһәр хакында бик күп ишеткәнгә, аны мактау берлә пароходта вакытта колакларым тонганга, мин Париж, Берлин кебек булмаса да, Прага, Варшау, Дрезден йә Анкара кебек бер шәһәрне күрергә хәзерләнгән идем. Юлны яхшы белмәгәнгә, бер арбачы алдым һәм Тел-Абибның мәркәзенә илтергә куштым. Яффадан чыктык кебек булдык. Яффаныкына караганда урамнары киңрәк, бер авыл дисәң — авыл түгел, бер бистә кебек. Авыл Казанның Яңа Бистәсе төсле дә булып күренә, Бишбалта кебек тә булгалап куя. Кайбер җирләре зур шәһәрләр тирәсендәге җәйләү (дача) җирләре төсле дә булып ала иде. Арбачыга акрын барырга кушкан булсам да, 10–15 минуттан соң арбачы торды: «Килдек», — диде. Мин ачуланыбрак: «Кая килдек? Мин сиңа шәһәрнең уртасына илт, — дидем. — Син мине кырыендагы дачаларга туктатасың!» — дидем. Ул моны шәһәрнең уртасы булганын, әнә почтаханә, әнә кибетләр, әнә каһвәләр (каһвәханәләр) булганын күрсәтә башлады. Мин тирә-юньгә карадым. Чынлап та, шул нәрсәләрне күрдем. Аттан төштем. Ләкин арбачыга ышанмаганга, бер очраган яһүдтән шәһәрнең мәркәзен сорадым. Мондагы яһүдләрнең 80 проценты урысча белгәнгә, ул миңа урысча җавап бирде. Ул берничә урамнарның исемнәрен сөйләп, кулы берлә күрсәтте. Шәһәрнең иң зур ресторанныннан «Казино»ны бик мактады. Мин акрын гына иң олуг урам буйлап киттем. Күзем һаман зур-зур өйләр, зур магазиннар, мәктәпләр һәм театрлар эзли иде. Ләкин күзгә бәрелгән биналарның йөз дә туксаны бер йә ике катлы урамга өч-дүрт тәрәзәсе берлә караган өйләр генә иде. Һәрбер өйнең аскы каты бер кибет төсенә куелган һәм аларга яһүдчә вывескалар язылып, аларда нәрсәләр сатылганы белдерелгән иде. Тик бу кибетләрнең барысы да кечкенә өяз шәһәрендәге кибетләр кебек кенә иде. Тәрәзәләргә куелган товарлар да Аурупада модасы чыгып беткән маллар иде. Ләкин аларның күбесе иске кибет иде. Зур урамны йөреп чыктым. Мин яңлыш китермәделәр микән дип шөбһәләнеп, тагы бер яһүд хатыныннан сораштым. Дөрес икән. Яһүдләрнең Сөләйман пәйгамбәр сарае ватылганнан бирле беренче итеп корган бер шәһәрләрендә йөрим икән. Йөри торгач, Тел-Абиб өчен махсус эшләнгән вокзалга килеп чыктым. Тагын киттем. Ләкин һичбер яңа мәһабәт бай бер шәһәрне таба алмадым. Шәһәр читенә килеп чыктым. Анда өелгән бина, бина эшләре өчен китерелгән тимер-томыр, асфальт, таш, агачларны очраттым. Ләкин анда һичбер хәрәкәт күренми, нә боларны ташучы бар, нә алучы бар (ягъни «юк» мәгънәсендә). Барысы да өелгән дә куелган. Берсенең янында бер каравылчыны күреп: «Болар нәрсә?» — дип сораштым. — «Болар Америкадан килгән, бина салыр өчен хәзерләнгән материаллар иде, хәзер менә шулай череп яталар», — диде. «Ник соң биналар салмый-

лар?» — дидем. Каравылчы шуңа миңа гөнаһлы иттереп карап: «Акча кая?» — диде. Яңа биналар салынып-салынмавына дикъкать итәргә тотындым. Аурупа шәһәрләрендәге кебек зур биналарның салынуына очрамадым. Шәһәр читендә берничә ике-өч бүлмәле өйләрнең эшләнеп ятканын һәм кайбер җирләрдә үткән ел башланып та бетми калган бинаны бетерергә маташуларын күрдем.

Ике сәгать буе җәяү йөреп арыганга, ашарга кирәргә булдым. Иң зур ресторан дигән «Казино»ны сорап таптым. Ул диңгез өстенә салынган, Истанбул Бугазы эчендәге йөзләп-меңләп ясалган рестораннарның берсе кебек бер ресторан икән. Мин кергәндә, аш вакыты булса да, бер генә мосафир бар иде. Миннән соң ике егет берлә бер кыз керделәр. Мин, әҗнәби сәйях (чит ил сәяхәтчесе) төсе бирер өчен, французча сөйләргә тотындым. Бик мактый торган Фәләстин шәрабы берлә аш сорадым. Аларның иң мактаган балыкларын бирергә куштым. Аштан соң каһвә сорап, гарсунга (гарсон; официантка) чәйлек бирдем дә, шәһәрнең зур, мәшһүр җирләрен сорашырга тотындым. Мин һаман әле үземне адашып, Тел-Абиб дигән пайтәхет тирәсендәге бистәләрдә генә йөримме дигән шөбһәдә идем. Гарсун, бик рәхәтләнеп, мин кичкән урамнарны, мин күргән биналарны сөйләде. Ашап чыккач, килгән юлымнан киттем. Былчырак урамнар эчендәге кечкенә, фәкыйрь яһүд өйләре арасына килеп кердем. Анда борылдым, монда борылдым — 10–15 минут үтмәде — тагын Яффага килеп чыктым.

Әле вакытым күп булганга, Яффа шәһәрен карарга керештем. Бу шәһәр бик иске булганга, монда гаҗәп урамнар бар. Андый тар урамнар хәзер Мисырда да, Истанбулда да, Римда да калмаган. Шул урамнарның берсенә кереп, берсеннән чыгып йөргәндә, бер җирдән ачык госманлы шивәсендә бер нотыкмы сөйләнгәнен, конферансмы бирелгәнен ишеттем. Тирәюньгә карандым: бу тавыш бакча эченә салынган, тәрәзәләре ачык бер бинаның эченнән килә икән. Монда төрекләрнең бер мәктәбеме, клубымы бар, күрәсең, дип, капканы ачып кердем. Тавыш ишетелгән бинаның ишеген ачып, акрын гына өйгә аяк бастым. Караңгы гына бер өйгә урындыклар куелган. Бер тарафта егерме-утыз хатын утырган, бер тарафта — шулкадәр үк ирләр. Өйнең түрендә кара киенгән бер кеше көрсигә (бу очракта — трибунага) чыккан да, сандугач кебек төрекчә сөйли. Минем керүем бераз гаҗәбрәк тоелды, күрәсең, һәркем берберсенә каранды. Мин бер буш урындыкка утырдым. Тышта калган күзем ярты караңгылыкка өйрәнеп өлгергәч, мин үземне хачлы (тәреле) бер өйдә икәнемне аңладым. Сөйләүче дә: «Менә хәзер Мәтинең (Матвейның) Инҗилнең фәләненче аятен укыйбыз», — диде. Иске госманлы шивәсендә берничә юллык Инҗилнең бер аятен укыды, ул Хәзрәте Гайсәнең авы-

руларны терелтүе хакында иде. Шуны аңлатырга кереште. Сөйләгән сүзләре, мохакәмә (фикер) йөртүе, Хәзрәте Гайсәнең могҗизаларын фән ягыннан тәфсир итәргә тырышуы — бу кешенең Аурупа тәрбиясе күргән икәнен күрсәтә иде. Озын мисаллар берлә Хәзрәте Гайсәнең биредән алган саз берлә бер сукырның күзен ачканын сөйләгәннән соң: «Монда ачучы куәт ул саз да йә аның эчендәге матдәләр дә түгел иде, авыруның үзенең әхвале рухиясендә иде. Ул Хәзрәте Гайсәне күрсәм, аңардан дога алсам, күзем ачылачак, дип, иман әйтеп куйган иде. Аның күзен саз ачмады, менә шул иман ачты», — диде.

Мин озын (озак) торырга вакытым булмаганга, акрын гына торып чыктым. Минем артымнан бер кеше дә чыкты. Ул шул чиркәү сымак өйнең сакчысы, имеш. Сораштым. Бу төрекчә Инҗил укучылар әрмәниләр, имеш. Болар әрмәни телен белмәгәнгә, бөтен гыйбадәтләрен төрекчә кылалар икән. Үзләре христианлыкның реформатор бер мәзһәбенә ияргән булганга вә телләре, гадәтләре берлә әрмәничә сөйли торган әрмәннәргә башка булганга, аларга катышмыйча, аерым бер тормыш берлә яшиләр икән. Мине төркияле дип уйлаганга: «Төркиядә хәлләр ничек?» — дип сорады. «Яхшы, сез ник кайтмыйсыз?» — дидем. «Анда бит хәзер әрмәннәрне яратмыйлар», — диде. Мин: «Анкараның үзендә сезнең кебек төрекчә сөйли торган әрмәннәр аерым бер мәхәллә булып яшиләр. Фәкать алар католик мәзһәбендә. Аларга һичкем бер сүз әйткән юк. Сезгә дә шулай булачак. Монда төрле чит халык арасында яшәгәнче, дин аерым булса да, үзеңнең ана телендә сөйләгән төрекләр берлә яшәү җиңелрәк, күңеллерәк булыр», — дидем. Ул: «Шулай инде. Ләкин бит төрекләр берлә әрмәннәр арасында бу хәлләр булып үтте... Без дә монда калдык», — диде, үзе дә аптырап куйды.

Әрмәни попларның тәлкыйни (ышандыруы) буенча, үзен әрмәни дип уйлый торган бер төрек углы төрекнең, әрмәннәрнең милли эшләренә өмәче булып йөреп, иленнән адашып, халкыннан аерылып калган бу кан кардәшнең авыр хәленә чын күңелдән кайгырдым, кызгандым. Ләкин моның берлә минем арада ялганнан оештырылган бик биек коймалар халыкның бу ике углының аңлашуына манигъ (киртә) булганга, эчемнән «Кемләргә безнекеләр корал булмадылар, нинди агымнарга безнең төрекләр өмәче булмадылар!» дип, төрк халкының үткәнен, хәзерге хәлен һәм киләчәген төшенә-төшенә отелемә юнәлдем.

Икенче көнне шәйх Ягъкуб әфәнде берлә Хәйфага киттем. Акрын гына йөри торган тимер юлы берлә дүрт-биш сәгать юлда калып, Хәйфа шәһәренә килеп җиттек. Вокзалда безне илдәшебез Габдулла әфәнде Тимур һәм бер төркем йирле гарәб җәмәгать хезмәтчеләре каршы алды. Безне алдан хәзер-

ләп куелган Габдессәлам әфәнде исемендәге бер яшь сәүдәгәрнең өенә мосафир иттеләр. Габдулла әфәнде хакында мин Кодес-Мисыр сәяхәтләремдә бик күп ишеткән, аның берлә инде берничә мәртәбә хатлашкан булсам да, бу вакытка кадәр күрешергә насыйп булмаган иде. Ул да мине ишеткән, минем хакымда укыган, гарәп гәзит-журналларында рәсемнәремне күргән булса да, Русиядә вакытта очрата алмаган икән. Ул безнең тәмам якташ: күрше авылдан булып чыкты. Спас өязе, Салман авылы хәзрәтенең углы булган бу зат элгәреге тәхсилне (укуны) Уральск шәһәрендә кылып, сугыштан элек Мисырга килгән вә андагы дини мәдрәсәләрдә тәхсилен дәвам иттергәндә, сугыш башланып китеп, иленнән өзелеп калган икән. Ул Фәләстиндәге югары баскыч дарелмөгаллимне (укытучылар институтын) бетереп, Фәләстиндә мөгаллим булып йирләшкән. Эзчелек өйрәнеп, Фәләстиндә беренче эзче (следопыт) оешмасын тудырган. Тәхсилен тәмамлар өчен Лондонга барып, андагы тәрбия вә эзчелек институтыннан шәһадәтнамә алган. Кыяфәте, гадәте берлә тәмамән безнең тирәнең мишәре булса да, ана теле ачык Чистай шивәсе булса да, хәзерге көндә гарәп мәдрәсәләрендә гарәп егетләренә гарәпчә әдәбият вә фәсахәт (сәнгатьле уку һәм сөйләү; риторика) дәресләрен өйрәтә вә Фәләстиннең зур бер өлешендә эзчеләрнең командалыгын ясый. Үзе вакытның кадерен белә торган бер зат булганга, безнең кыска вакытыбызны тулы үткәрер өчен көненә бер программ да ясап куйган. Өй хуҗалары берлә танышып, аш ашар-ашамас, программ буенча йөрергә тотындык.

Беренче иттереп Хәйфаның өстендә хаким булып торган вә Хәйфаның җәйге эссе көннәрендә тын ала, хәл җыя торган җәелге булган «Әл-Кәрмәл» тавына киттек. Берничә йөз метр югарылыкка бер зур тау бөтен Хәйфага вә аның лиманына (портына) хаким бер хәлдә булганга, төрекләр заманында монда шәһәрне саклый торган кальга булган. Бу йир диңгездән бик югары булып, урман берлә капланганга, җәй көннәрне һавасы могтәдил (уртача) булганга, бу йир бөтен ерак кешеләрнең җәйләүлекләре булган. Тауның өстеннән диңгезгә вә тирә-юньгә киң манзара ачыла. Монда бик күп җәйлек өйләргә башка, тирә-юньнән килгән мосафир өчен отельләр, пансионнар да бик күп. Ләкин бу матур йирне соңгы елларда яһүдләр баса башлаганнар. Бөтен әтрафны (тирә-юньне) югарыдан карап, озын итеп йөреп, өйгә кич кенә кайттык. Кичке аштан соң безнең берлә күрешергә бөтен шәһәрнең олуглары килде. Боларның барысы да гарәп булса да, бик күбесе төрекчәне бик яхшы сөйли иде. Зыялыларының күпчелеге төрек мәктәпләрендә укыганнар иде. Эчләрендә һичбер төрек дошманлыгы күренми иде. Безне зиярәт итүчеләрнең арасында бик күбесе тәрәккыйпәрвәр сәүдәгәрләр иде. Бик күбесе үзенең дөньяга

карашы, тирә-юнен аңлавы берлә безнең сугыштан элеккеге тәрәккыйпәрвәр сәүдәгәрләребезгә бик охшаган иде. Безнең яшь сәүдәгәрләр кебек, болар да бик җанлы, бик тырыш вә бик иманлы иде. Икенче көнге күрешүләр вә шәһәр берлә танышуларымда мин моның сәбәбен аңламадым. Хәйфа сату-алу өчен бик мөһим урын булганга, монда шактый күп яһүд сатучысы килеп тулган вә гарәп яшьләрен дә алар берлә ярышу хисен уяткан. Болар яһүд сәүдәгәрләре берлә ярышыр өчен сәүдә юлына бил баглап керешкәннәр. Хосусан боларның бу эштә хәлфәләре булган зыялы сәүдәгәр Габдеррәшид Ибраһим әфәнде — искитәрлек бер кеше. Бу зат бөтен Фәләстиндә «Гарәп банкы» ачучыларның беренчеләреннән. Ул Хәйфадагы гарәп банкының мөдире вә андагы мөселманнарның бөтен икътисади вә мәдәни оешмаларының әгъзасыдыр. Ачык фикерле, халкын сөюче бу зат үзенең икътисади төшенчәсе берлә безнең Мәскәү сәүдәгәрләрен хәтерләтә. Бик хәммиятле (сизгер; зирәк) бер зат булганга, ватаны Фәләстинне яһүдиләргә каптырмас өчен, икътисади бик зур тартыш алып бара. Гарәпнең мал көчен бергә җыеп, аны гарәп файдасына кулланырга тырыша. Гарәп сәүдәгәренә, гарәп авыл халкына кирәк вакытта бурычка акча бирү берлә, гарәпне сату-алу базарына яһүдигә бирелмәслек хәлгә китерергә җан-тәннән хезмәт итә. Кич буе бик озын сүзләр сөйләшеп, вакытны кичердек. Кызыгы шул: бу Фәләстин гарәпләренең яшьләре бик күбесе безнең Салман авылы Габдулла әфәнденең шәкертләре булган кебек, боларның картлары да миңа, Чистай мишәренә, үзләренең уртак мөселманлык йөген тартышучы бер кеше дип карыйлар; тәмамән кардәшчә мөгамәлә итәләр; һичбер яшермичә, кайгылары-шатлыклары берлә бүлешәләр иде. Мин дә үземне Казанда, Мәскәүдә, Истанбулда үзебезнең халкыбызның арасында кебек хис итә идем.

Икенче көнне, иртүк торып, «Әл-Кәрмәл» гәзитенең мөхәррирен зиярәткә киттек. Бу гәзит Фәләстиндә чыга торган гарәп гәзитләренең иң элгәреседер. Мөхәррире, — христиан гарәп булса да, эше-көче берлә чын мәгънәсендә хәммиятле бер гарәп. Безне күктән төшкән кадерле кунак кебек каршы алды. Каһвә берлә сыйлап кына калмыйча, чәй дә ясатты. Ул мине гәзитләрдә укып таныганга, бик озын сөальле мөзакәрәләргә керешге. Гәзите өчен миннән бер интервью да алды. Бу гарәп хезмәтчесе үзе христиан булса да, Хәзрәте Мөхәммәд галәйһиссәламне бик зур хөрмәт итә вә Коръәнне гарәп даһасының (дөньясының) зур әсәре дип карый. Сөйләгәндә, дәлил итеп, Коръәннән бик күп аятьләр китерә. Гарәпләрнең хәзерге көндәге хәлгә төшүләренең сәбәбен Хәзрәте Мөхәммәд галәйһиссәламнең тәгълиматын тотмауларыннан дип тәфсир итә. Безнең тарафтагы мөселманнарның хәлләрен бик тәфсилле итте-

реп сораша. Гарәп теленең никадәр таралуын белергә тырыша. Андагы мәдрәсәләрдә гарәпчә уку-укытуны сөйләгәндә, балалар кебек чын күңелдән шатлана. Бу да үзләренең Фәләстин өчен вә гарәп йорты өчен тартышуларында мине бер юлдаш иттереп карый иде. Күрешеп чыкканда, калтыраган, тәэсирләнгән тавыш берлә: «Карлы-бозлы Идел буйларында, меңләр чакрымлык Урал тауларында сезнең кебек безгә якын калебле затларның йитешүе гарәпнең олуг даһисе Хәзрәте Мөхәммәднең онытылмас Коръәненең йимешләредер. Бу безнең гарәп даһиебызның могҗизасы!» — диде. Күрешеп аерылыштык.

Аннан соң Габдулла Тимур әфәнденең гарәпчә укыта торган мәктәбен зиярәт иттек. Мөгаллимнәр берлә күрештек. Боларның күпчелеге төрекчә сөйли, аңлый торган затлар иде. Сыйныфларны карарга киттек. Зур сыйныфта мөдир мине балаларга зур сүзләр берлә танытты: «Халкының кяферләр тарафыннан җәберләнүен безгә аңлатырга килгән. Сез дә шундый зур гая (олуг теләк, максат) артыннан йөрүче булырга тырышыгыз!» — диде. Габдулла әфәнде бер сыйныфта балалардан Коръән укытты. Бер Идел буе төрк-татарының пәйгамбәрләрнең туган йире булган Фәләстиндә гарәп балаларына Коръән өйрәтүе тагын гаҗәп төсле булып китте. Безнең Идел буе егетләре кемнәргә өмәгә йөрмиләр (ягъни хезмәт итмиләр). Үз илең булмагач, үз халкың үз ихтыярында булмагач, шулай итеп, мәгънәви чегән булып каласың, күрәсең.

Туп-туры «Мәҗлесе исламия»гә киттек. Бу мәҗлес — мондагы Хәйфа мөселманнарының милли-сәяси мәркәзләре. Ишек янына килеп җиткәч, тар гына баскычтан берсе арты берсе төшеп, менеп килә торган бик күп гарәп хатыннарына очрап, аларның төшкәннәрен көттек. Ул арада тагы берничә чаршаулы (бөркәүле) ханымнар килеп чыкты. Бу юлы без, бераз нәзакәтсезлек булса да, ханымнарны көтмичә, икенче катка менеп киттек. Бер киң генә салонга кердек. Анда безне җәмәгате исламиянең рәисе берлә берничә әгъза каршы алды. Монда килгән хатыннарның ник күплеген сорадым: «Бу бина безнең үз бинабыз. Икенче тарафта бер могаянәханәбез бар: фәкыйрьләргә бушлай, хәллеләргә бик очыз (очсыз) (алтын акча берлә 12 тиен). Күбрәк мосафирлары һәрвакыт ханымнар булганга, юлда сезгә күтәргә туры килгәндер, диделәр. Озак та үтмәде, могаянәханәнең яшь докторы Рөшди Тәмими әфәнде дә килеп, безнең берлә күреште. Бераз сөйләшкәннән соң, аны карарга чыктык. Аның көтү бүлмәсендә әллә никадәр мөселман хатыннарын очраттык. Доктор бер елда алты мең хаста килеп-киткәнен вә боларның зур бер өлеше хатыннар булганын сөйләде. Шунда ук бер мөселман акушерка берлә дә таныштырды. «Мөселман хатыннары бу ханә ачылганга кадәр тыйбби (медицина) ярдәмсез иделәр. Шуны игътибарга

алып, «Җәмгыяте исламия» үз хисабына моны ачты вә, хатыннарга җиңеллек булсын өчен, бер мөселман акушерка да булды. Ләкин хатын докторыбыз әлегә юк. Сезнең тарафта хатын-кыз докторлар күп, диләр. Безгә килсәләр, бик зур хезмәт итәрләр иде», — диде. «Җәмгыяте исламия» рәисе: «Хәзер менә алдыбызда бер хастаханә ачу мәсьәләсе тора, ләкин бинабыз җитәрлек түгел; шуның өстенә тагы бер кат төзеп, хастаханә ачачакбыз. Сез икенче килгәндә, хастаханәбез дә булачактыр. Безнең мөселман хатыннары ирләргә күренүдән тартыналар. Безгә сезнең доктор ханымнардан берәрсен җибәрегез», — диде. «Җәмгыяте исламия»дә каһвә эчеп, аның шул елларда гына салдырган мәсҗеден карарга киттек. Бу мәсҗеднең урыны элек бер әүлияның зияраты (кабере) булган. Бу тарафны яһүдиләр баса башлагач, шәһәрнең уртасында калган бу зиярат йиренә «Җәмгыяте исламия» ике катлы зур бер мәсҗед салдырган. Аның астакы (астагы) катына кибетләр эшләнгән. Өсте мәсҗед ясалган. Зур-кечкенә кибетләрнең саны гына 26. Урын тәмам базар уртасында булганга, бөтен кибетләр тулган. Болар китергән меңнәрчә лиралык файдага «Җәмгыяте исламия» берничә мәктәп, могаянәханә тәрбия итә вә киләчәк биналарына да акча җыя бара. Җәмигъ бик зур, бик якты, бик яхшы. Без аннан «Шөббанелмөслимин» («Мөселман яшьләре») җәмгыятенә киттек. Бу җәмгыятьнең бөтен ислам мәмләкәтләрендә барлыгын, яшьлекне мөселман рухында тәрбия итәргә хезмәт итүче бу оешманың һәр йирдә зур рәгъбәт (кызыксыну) күргәнен үткән мәкаләләремдә язган идем. Мондагысының төзелүендә, тәрбия ителүендә безнең илдәшебез бик зур хезмәт иткәнгә, миңа бусы тагы якынрак күренде. «Шөббанел-мөслимин» дә үзенең бинасында йирләшкән. Бу да күптән түгел генә йирле хәммиятлеләрнең һиммәте (тырышлыгы) берлә салынган ике катлы бер таш йорт. Бу да элгәре бер шәйхнең төрбәсе булган. Моның да асткы катында кибетләр. Өсте «Мәҗлеснең идарәсе»ндәге төрле-төрле бүлмәләр, салоннар. Диварлар бик күп эзчеләрнең рәсемнәре берлә бизәлгән. Салоннары хәзерге җәмгыятьнең үсүенә җитәрлек булмаганга, бинаның бер ачык тарафына салон ясарга хәзерләнәләр вә шуның өчен кирәкле салу материалларын китертеп яталар. Җәмгыятьнең эшләрен, көтепханәләрен карап, гарәп банкын күрергә китәбез. Анда безне банкның мөдире Габдеррәшид Ибраһим әфәнде каршы ала.

Көн буе шулай мөселман оешмаларын күреп йөреп, өйлә ашыны махсус хәзерләнгән Габдулла әфәнденең бер шәкердендә ашыйбыз. Мәҗлестә шәһәрнең бөтен олуг хазыйр булды (катнашты). Мин боларга: «Бөтен эшләрегезне икътисади нигезгә корырга сезне кем өйрәтте?» — дип, бер сөаль бирдем.

Казан татарындагы бу табигатьнең монда, гарәп илендә, пәйгамбәрләр чыгара торган Фәләстиндә, кайдан килүен белсәм, килеп җавап көтәм. Арадан берсе: «Яһүди мөһаҗирләре!» — дип җавап бирә. Башкалары да бу җавапны гөблиләр (җөплиләр; куәтлиләр). Димәк, яһүдиләрнең Фәләстинне үз кулларына алырга теләүләре йирнең хәзерге хуҗалары — гарәпләрдә үзен-үзе саклау хисен уяткан. Яһүди коралы икътисад берлә ул да коралланырга керешкән. Димәк, сионизм гарәпләр өчен файдалы бер камчы да булып чыккан.

Программа буенча аштан соң Гакка шәһәрен күрергә дип, автомобиль берлә киттек. Бу ике шәһәрнең арасы 30–40 чакрым гына икән. Гакка шәһәре Хәйфа кебек үк диңгез кырыена корылган бер шәһәр. Ләкин мондагы култык пароходлар туктарга тагы да уңгайрак булганга, гасырлар буе әлеге шәһәр бу тирәнең порты булып килгән. Төрекләр дәверендә бу бер кальга булып торган. Шәһәрнең тирә-юне бик зур биек таш койма берлә әйләндерелгән. Кальганың эчендә зур гөнаһлы усалларны саклар өчен бер төрмәсе дә булган. Солтан Габделхәмид дәверендә салына башлап, тәмам ителгән. Хиҗаз тимер юлы менә шул Гакка шәһәреннән башланып китеп, Мәдинә шәһәренә барып кергән. Бу тимер юл солтан Габделхәмиднең планы, ислам галәменең иганәсе вә төрек мөһәндисләре (инженерлары), осталары һәм эшчеләренең кул көче берлә эшләнгән бердәнбер ислам вакыф тимер юлыдыр. Ул вакытларда хаҗиларның күпчелеге Гакка шәһәренә пароходлар берлә килә торган булганнар да, шунда тимер юлга утырып, рәхәт-рәхәт өч көн эчендә хаҗга барып җитә торган булганнар. Сугыш вакытында бу юл шактый бозылган. Хәзерге көндә бу юл Хиҗаз, Шәркыл-Әрдән, Фәләстин, Сүрия дәүләтләре арасында бүленгән вә бик күп җирләре харап ителеп, эшкә яраксыз ителгән вә уртак мөселман вакыфлыгыннан чыккан. Мөэтәмер (корылтай) бу тимер юлыны элгәреге кебек ислам вакыфы итеп калдырыр өчен карарлар алды. Әмир Сәгыйд Әл-Җәзаиринең риясате (рәислеге) җитәкчелегендә шуның берлә шөгыльләнергә махсус бер комиссия дә аерган иде. Менә хәзер без шул тимер юл башланган Гакка шәһәрендә. Шәһәр хәзер ташландык хәлендә, сүнгән. Сату-алу һәммәсе Хәйфага күчкән. Хаҗилар килү беткән, төрек вәлиләреннән (мэрларыннан) Әхмәд паша исемендә бер зат тарафыннан салдырылган иске бер зур җәмигъ (мәчет) та бар икән. Аның әтрафы мәдрәсәләр һәм шәкердләргә хөҗрәләр берлә әйләндерелгән. Әле дә булса шул мәдрәсәләрдә гарәп егетләре дәрес укыйлар вә мәрхүм төрек пашасы калдырган вакыфыннан (фондыннан) бушлай бүлмәдән башка, айга 60 грошлар (алтын берлә — 4,5 сум) ярдәм дә алып торалар икән. Гарәп шәкерте безгә ярдәмнең азлыгыннан зарланды. Мин дә моның сәбәбе сугыштан соң гарәп дөньясы арасы-

на кергән ходуд (чик) мәсьәләләре икәнен сөйләп торуның лозумен (кирәклеген) тапмадым.

Бу шәһәрнең хәзерге көндә минем өчен иң кызыклы булган җире монда бәһаиләрнең башы булган Бәһаулла зияраты вә аның янына салынган бәһаи мосафирханәләре иде. Шуңарга бу мәсҗед тирәсендә без озак туктамыйча, шәһәрдән бераз читтә булган бәһаиләр мәркәзенә киттек.

Мәгълүм ки, 19 нчы гасырның соңгы яртысында ислам дөньясында яңа бер мәзһәб дөньяга туа. Бу мәзһәбкә баби мәзһәбе дисәләр дә, күп вакытта шул сүзне аурупалаштырып «бабизм» дип тә йөртәләр. Бу исем мәзһәбнең чын башы Сәйд Гали Мөхәммәд әш-Ширази дигән иранлы бер галимнең «баб» дигән кушымта исеменнән алгандыр. Сәйд Гали Мөхәммәд әш-Ширазиның мәзһәбе Иранда бәд (начар, бозык) мәзһәб булып кабул ителгән вә мәзһәб башлыгы төрмәгә ябылган вә ахырдан аттырылып үтерелгән. Аның башлаган мәзһәбен 1260 һиҗридә (милади белән 1844 тә) Тәһран шәһәрендә туган Бәһаулла, үзләренчә әйтсәк, Хәзрәте Бәһаулла дәвам иттергән. Ул шуңа мәзһәб төсе биреп, аның гадәтләрен вә җолаларын эшләткәндер. Бу мәзһәбнең төп фикере: дөньяда булган бөтен диннәрне берләштерү һәм һәрбер дин әһеленә үзенчә гыйбадәт итү юлларын тәэмин итүдер*.

Хәзрәте Баб та, Бәһаулла да ислам дөньясыннан чыккан кешеләр булганга, алар үз мәзһәбләренең нигезе итеп исламиятне алганнар. Аларда намаз да, ураза да бар. Ләкин намаз көнгә өчкә генә вә руза да бер айдан унтугыз көнгә иңдерелгән (киметелгән). Үзләренең догалары да бар. Үзләренең бер китаплары да бар. Ләкин бу китап үзе дә Коръән Шәрифнең бозынтысы (бозылган варианты) гынадыр. Менә шул Хәзрәте Бәһаулла Иранда үзенең мәзһәбен тарата башлагач, Иран хөкүмәте аны мәмләкәттән куган. Бәһаулла Төркиягә сыгынган. Солтан Габделмәҗид (? Габделхәмид. — *Х.М.*) үзенә хөрмәт күрсәткән вә аның утырыр җире итеп Гакка шәһәрен билгеләгән. Хәзрәте Бәһаулла 1309 елда (милади белән 1892 дә) үлгәнгәчә Гаккада калган; үзенең мәзһәбен шуннан тараткан. 19 нчы гасырда ислам дөньясында дини нигездә ислахать (реформа) ясау вә дини юлда эзләнүләр бик актуаль эшләр булганын без үзебезнең илдәшләребез Габденнасыйр әл-Курсави һәм Шиһабеддин әл-Мәрҗаниләрнең хәрәкәтләре берлә танышканда ук белә идек. Бу хәрәкәтләр ул вакытларда ислам дөньясының башка йирләрендә дә булган. Җамаледдин әл-Әфгани, мисырлы Мөхәммәд Габдәләрнең эшләре берлә дә безгә мәгълүм

---

* 19 нчы гасырда Сарытау сатучысы Курамшин дигән бер кеше дә шундый бер мәзһәб корам дип йөргән вә үзенчә бер китап та язып чыгарган иде *(Г.И.)*.

иде. Баб, Бәһаууллаларның хәрәкәтләрен дә без ислам дөньясындагы тормышның шул сөальләренә җавап төсендә эшләнгән бер хәрәкәт дип карый алабыз. Ләкин ничек кенә булмасын, бу мәзһәб вакытында ислам дөньясына бик күп фетнәләр чыгарган, ахырдан Иран һәм Һиндстанда шактый күп таралган булып, Бәһаулла үзенә бик күп мөридләр җыя алган иде. Аның берлә генә калмыйча, бу хәрәкәт Аурупа һәм Америкага күчеп, «бабизм» төсендә анда да үзенә уртаклар таба белгән, имеш.

Безнең күрергә теләгәнебез менә шул мәзһәб башлыгы Хәзрәте Бәһаулланың зияраты. Бу зиярат — ислам дөньясында күрелмәгән рәвештә гаять бай иттереп эшләтелгән бер төрбә. Төрбә генә түгел — зур бер сарай. Идәннәре бик кыйммәтле паласлар берлә өртелгән (түшәлгән), диварлары бик күп матур язулар берлә бизәкләнгән. Кабер тирәсенә матур шәмнәр тезелгән. Кабернең тирә-юненә бик күп гөлләр, чәчәкләрдән зур бер чәчәк бакчасы эшләнгән. Болар һәммәсе дә Шәрык ысулында түгел, Аурупача иттереп һәм дә бик күп акча сарыф иттереп эшләтелгән. Шуларның әтрафы бик пөхтә иттереп эшләтелгән зур бер бакча берлә әйләндерелгән. Икенче тарафта берничә катлы зур бер таш өй. Өй генә түгел — бер сарай. Шул сарайның бер тарафында Хәзрәте Бәһаулланың кызларыкияүләре яши икән. Икенче тарафы — мөридләр өчен мосафирханәгә әверелгән. Хәзрәте Бәһаулланың утырган урыны да бу мосафирханә эчендә калдырылган. Мосафирханә бик пакь, бик пөхтә. Аурупа шәһәрләренең икенче дәрәҗә отельләре төсендә. Ятак бүлмәләре аерым, язу бүлмәләре аерым, ашау бүлмәләре аерым, хаммамнары (юыну урыннары) аерым, көтепханәләре аерым. Шуңарга башка, бәһаилеккә каратып язылган бөтен телдәге китаплар, гәзитләр һәм мәҗмугаларны эченә алган картотекалы бер көтепханәсе дә бар.

Монда әллә ничә йөз җилдлек (томлык) төрле телдә бабизм хакында язылган китаплар саклана. Алар тарафыннан чыгарылган рисаләләр, китаплар өстәл өстендә укучыга хәзер тора. Мосафирханәдә бик күп бүлмә бар. Бу бүлмәләр һәрвакыт бәһаи мәзһәб мөридләре өчен бушлай ачык. Анда килгән мосафирларга ашау-эчү дә бушлай икән. Безгә боларны бер Иран азәрисе (азәрбайҗаны) күрсәтеп йөрде. Үзе азәри шивәсендә төрекчә бик һәйбәт сөйли. Тәбризи (Тәбриз шәһәренең) бер бәһаие икән. Хәзрәте Бәһаулланың үзе утырган бүлмәсен дә махсус күрсәтте. Анда аякларыбыздан салып кердек. Аның кул язуларын, китапларын күрсәтте. Болар һәммәсе дә бик тәмиз (чиста, пөхтә) иттерелеп, сакланып киләләр.

— Боларны кемнәр карый? — дип сорадым.

— Бәндәгез һәм дә монда бәһаи мәзһәбле бер япун конты (гаррафы) (изге заты; диндары) бар. Ул! — диде.

Моны идарәгә (идарә итәргә) бик күп акча кирәк булуын

күздә тотып, моның вакыфы булып-булмавын һәм мәсарифларының (чыгымнарының) кайдан чыгарылуларын сорадым.

— Мөридләребезнең ярдәменнән. Хәзрәте Бәһауллланың зияратыны саклау һәрбер мөриднең бурычыдыр! — диде. Бу сарайдан чыгып килгәндә, карт кына өч ямьсез инглиз хатынына очрадык. Алар берлә япун кыяфәтле бер кеше сөйләшеп тора иде. Азәри: «Болар Америкадан килгән. Хәзрәти Бәһаулланың мөридләре», — диде. Япунда чәчәк мәракалысы, имеш. Ләкин мондый елларда мондый зур бер нәрсәнең мөридләрнең ярдәме берлә генә торуына ышанып бетә алмаганга, «акча кайдан алалар?» дигән сөалемә җавап таба алмадым. «Мөтәвәвәллисе (дәвамчысы) кем?» — дидем.

— Хәзрәте Бәһаулладан соң аның угылы Гыйас әфәнде калган иде. Хәзер Шәүкый әфәнде исемендә кызының углыдыр, Хәйфада яши, — диде.

Минем юлдашларым:

— Гыйяс әфәнде исламият берлә галякасыны (бәйләнешен) кисмәгән бер зат иде. Һәр җомга көнне мәсҗедкә җомгага килә, фәкыйрь-фөкарага ярдәм итә иде. Хәзерге Шәүкый әфәнде Аурупада укыган, исламият берлә галякасын кискән бер гәнеҗ (егет), — диделәр. Шул бәһаиләр хакындагы бөтен күрәсе йирләрне күреп бетерер өчен, Әл-Кирмәл тавының итәгенә эшләтелгән Хәзрәте Бабның зияратына киттек. Бусы да бик зур бер бакча эченә салынган, бер гыйбадәтханә кебек бина. Бик күп Иран халилары (паласлары) берлә сөрелгән (бизәлгән) зиннәтле бер бүлмәнең уртасына Бабның ләхеде куелган. Монда да шәмнәр. Ләкин байлыкта болар беренчесеннән дә баерак. Бер бүлмәдә Бәһаулланың кием-салымнары, язулары саклана икән. Диварларда фарсыча-төрекчә-гарәпчә бик матур язу берлә язылган ләүхәләр (элмә такталар) тагылган. Бу язулар Иранның 19 нчы гасырдагы мәшһүр хәттаты (каллиграфы) «Миске Каләм»нең язулары икән. Моның тирәсендә бик зур гөл бакчасы. Күрәсең, бабилар гөлне бик сөяләр. Шәүкый әфәндегә дә кереп, зиярәт итәчәк булдык. Ләкин өйдә тугры китерә алмадык.

Монда күргәннәрем дә бик зур акча берлә эшләтелгән, бик күп акча берлә дәвам иттерелә торган эшләр икәне күренеп тора. Ләкин акча килә торган юллар бер дә күренми иде. Мөридләр дисәләр дә, мөридләр исемендә беркемгә дә очрамый идек. Гарәпләр арасында боларның мөридләре юк. Иранда бар, имеш тә, Һиндстанда бик күп, имеш. Һиндстанда Исмәгыйлия мәзһәбенең башлыгы саелган (хөрмәтле), Лондонның мәгъруф бер һиндлы принцы Ага хан, ди, боларның мәзһәбенең бер шәхсияте (әгъзасы), имеш. Америкада Чикаго шәһәрендә бабиларның алты ишекле, алты мәзһәбкә гыйбадәт өчен салынган бер гыйбадәтханәләре бар, имеш. Боларның кайсылары дөрестер — белеп булмады. Ләкин, каян акча алалар? дигән сөалемә җавапны белә алмадым.

Шәһәргә кайткач, шуларның хәлләрен сораша-сораша сугыш вакытында боларның арасында зур инглиз хәфияләре (яшерен оешма вәкилләре, агентлары) яшәгәнлеген вә төрекләр тарафыннан тотылганыны сөйләделәр. Бу минем сөалемә дәрхаль (шунда ук) яңа сөальләр кушты. Минем хәзер генә кереп йөргән биналарым, зияратларым, аллы-гөлле бакчаларым ислам дөньясының дошманнары тарафыннан исламиятне бозарга, аерырга корылган микроб лаборатурлары (лабораторияләре) түгел идеме? 19 нчы гасырдагы ислам дөньясының уяну дәверендәге эзләнү хисене ислам дөньясы үзенә файдалыга бора белмәсә дә, ислам дөньясыны таратырга теләүчеләр аның бер көч булуына соңгы йомрыкны (йодрыкны) орырга теләүчеләр, шул хисеннән файдаланып, сонгый (ясалма) рәвештә шул хәрәкәтне үстермәделәрме? Баблар, Бәһауллалар вә башкалар аңлап-аңламыйча ислам дошманнарының кулына корал булмадылармы? Бабизм 19 нчы гасырның «аля лявиринс» (? буталчык) бер хәрәкәте генә булмадымы? Бу сөальләр минем башымны биләп алып, җавап эзләргә тотындылар. Сөаль артыннан сөаль китеп, шунда күрсәтеп йөргән гаҗәм (иран) тәрбияле азәринең кыяфәте алдыма килеп басты. Аны моннан элек тә бер җирдә күргән кебек булдым. Фикер йөри-йөри мине Берлиндагы бер гаҗәм ашханәсенә илтеп җиткерде. Шунда аш ашаганда, күршебездәге урысча, алманча, төрекчә, әрмәнчә, фарсыча сөйләшә торган егетләр берлә уртак бернәрсәсе бар кебек тоелды. Әйе, шуларга охшаган, ләкин бу бераз картрак. Мөгамәләләре, кыланышлары да шәрыкчарак. Тегеләр — яшьләр. Тегеләр — модерн. 19 нчы гасырның дин ислахяте фикере берлә йөрелмиләр. Болар, 20 нче гасырда куәт алган милләтчелек фикеренең көчәюеннән файдаланып, милләтләрнең капитализмның пәнҗәсеннән (тырнагыннан) коткару гына түгел, бөтендөнья милләтләрен берләштерү гаясенә хезмәт итәләр.

Шул тулы «Шәркый азатлыгы»н дөньяга чыгарыр өчен, рус большевизмының кассасыннан файдаланып, руслыктан бизар булган (йөдәгән) милләтләрнең милләтчелек җәряннарын (хәрәкәтен) кырырга хезмәт итәләр. Ленинны фарсычага, төрекчәгә тәрҗемә итәләр. Большевизмны чәчәкләндереп, балландырып Шәрыкка кертергә, таратырга, Шәрыкта уянган милләтләрнең милләтчелекләрене рус истилясына (басып алуына; изүенә) каршы киләчәк бер куәтеннән чыгарырга хезмәт итәләр. 19 нчы гасырның бабилары берлә 20 нче гасырның ленинчылары икесе дә бер юлга хезмәт итмиме? Бу хәрәкәтләрнең сугарыла торган чишмәләре аерым-аерым булса да, болардан чит халыклар, чит җәряннарның көткән нәтиҗәләре бер түгелме? Бу сөальләр мине Фәләстиннән киткәнче борчыды. Әле дә борчый. Җавапны әле дә таба алмадым. Бәлки, киләчәк бирер.

* * *

Фәләстин белән Сүрия арасында иң кыска юл — автомобиль юлыдыр. Ике арада тимер юл булса да, бик борылып-урап йөргәнгә, вакытны кызганмаган юлчылар автомобильне ихтыяр итәләр. Мин дә шул соңгысын ихтыяр иттем. Ләкин автомобильчеләргә бер генә юлчы йөртү эшләренә килмәгәнгә, алар юлдаш эзләп, йөдәп беттеләр. Мисыр төрәне (поезды) килеп, мин төрәнгә утырырга булгач кына, төрән бәһасенә ялгызымны гына алып китәргә булдылар.

Ике сәгатьтән соң Табәрия исемендәге зур күл башына утырган, шул исемдәге шәһәргә килеп җиттек. Монда минем ямчым (шоферым) яңа юлчы эзләргә кереште. Зур күл буена салынган бу шәһәрнең тирәсе Фәләстиннең байлары, бигрәк тә әҗнәбиләрнең (чит ил кешеләренең) җәйлекләре икән. Шәһәр кечкенә булса да, күл буенда матур-матур биналар бик күп. Ямчы ике сәгать эзләсә дә, бер юлчы да таба алмады. Мин тагын ялгызым гына киттем. Озак бармадык, Фәләстин-Сүрия чигенә җиттек. Монда инглиз түрәсе минем паспортыма үзенең тамгасын басты. Тагын утырып киттем. Биш-ун чакрымнан без күпердән чыктык. Бу күпернең исеме «Җәрбәнате Ягъкуб» («Ягъкуб кызларының күпере») икән. Аның икенче ягында, бер капка янында туктадык. Ямчы, минем паспортымны алып, бер өйгә керде. Берничә минуттан соң аннан бер яшь француз чыгып, минем нинди гәзиттә язуымны, нәрсә өйрәнү өчен Сүриягә килүемне, кайсы отельдә торачагымны сорады. Җавап бирдем. Визам җирендә булганга, җиңеллек берлә ходудны (чикне) үтеп киттек.

Вакыт бик кич булмаса да, һава бик суынды. Бик каты суык җил исәргә тотынды. Ямчы, башы гына түгел, итәкләре дә кар белән капланган бик биек Җәбәлүш-шәйх (икенче исеме — Хермон) тавын күрсәтте:

— Кар яуган, суык шуннан килә! — диде. Французларның гүмрүкләре (таможнялары) Канитарә дигән шәһәрдә икән. Сәгать дүртләрдә шунда килеп җитеп, гүмрүк алдына туктадык. Безнең әйберләребезне карарга тотындылар. Минем чемоданнарга сыймаган бик күп гәзит төргәкләрем дә бар иде. Гүмрүк түрәсе бер чиркәс: «Болар нәрсә?» — дип сорады. «Гәзитләр», — дидем. Шуларны караганда, берсендә минем рәсемемне күреп, астына язылган язудан минем мөэтәмәр (корылтай) әгъзасы булуымны белде һәм караудан туктап: «Боерыгыз, боерыгыз! Мин сезне танымадым», — дип, ачарга хәзерләнгән чемоданнарымны ачтырмады.

Бу Канитарә шәһәре күпләп чиркәс мөһаҗирләре тора торган шәһәр икән. Минем карап йөрергә вакытым булмады. Шамга баручы өч юлчы табылып, китеп бардык. Җәбәлүш-шәйхнең

суыгы монда тагын артты. Бик туңып, кояш баеган чакларда Шамга барып кердек. Өмәвиләрнең пайтәхете булган һәм ислам тарихында бик зур роль уйнаган Шам-шәриф (Дәмәшкъ) менә инде шул үзе.

Отельгә төшеп, җирләшеп, ашарга чыктым. Аннан соң мөһаҗирләр мәхәлләсен сорап, шул тарафларда булырга тиеш булган үзебезнең Идел буе иптәшләребезне эзләргә киттем. Мин аларның берсенең дә адресын белми һәм үзләрен дә танымый идем. Ләкин алай итеп, болай итеп, табуыма-тануыма канәгатем бар иде. Мөһаҗирлек мәхәлләсенә барып җитсәм дә, кич бик суык булганга, бөтен кибетләр һәм каһвәханәләр ябылган иде. Урамда һичбер йөрүче юк иде. Очраган кешеләрдән сораштыргаласам да, барысы да, суыктан качып, өйләренә ашыкканга, бертөрле дә мәгънәле җавап ала алмадым. Өйгә борылып киттем. Гарәпләрдән таныганнарым булса да, аларны эзләргә вакыт соң булганга, бүлмәмә кайтып яттым. Төн буе җил улаганга, минем бүлмәмнең тәрәзәләре дә, шалдыр-шолдыр килеп, йокы тынычлыгымны бүлделәр. Суык җил дә юрганымның астына кадәр кереп уятты. Иртүк торып, үземнең чәй машинамны тишеп, чәй эчкәч кенә кеше төсенә кереп, шәһәргә чыгып киттем. Һичбер көтелмәгәндә урамда мөэтәмәрдә Сүрия әгъзасы булган адвокат Шәфыйк Сөләйман бәкне очраттым. Ул миңа шәһәрне күрсәтергә, барачак кешеләр һәм җирләремне өйрәтергә булды. Беренче иттереп Әмир Сәгыйд әл-Җәзаирне зиярәт иттек. Ләкин Әмир өендә юк иде. Без Өмәви җәмигын (мәчетен) карарга кердек. Бу — Шамның иң иске, иң тарихи бер җәмигы. Ул христианлыктан элек бина ителгән бер мәҗүси гыйбадәтханәсе икән. Шамны христианнар алгач, аны чиркәүгә, мөселманнар алгач, җәмигъка әверелдергәннәр. Инде 1250 еллар чамасы мәсҗед булып тора. Өмәви хәлифәләрнең тарихы берлә бик баглы булганга вә алар заманында җәмигъка әверелгәнгә, ул Өмәви җәмигы дип йөртеләдер. Дүрт почмаклы итеп эшләтелгән, дүрт якта дүрт капкасы бар. Бу җәмигъ үзе капкаларын япкач, шәһәр эчендә бер кала булып кала аладыр. Бик күп сугыш вакытларында, эчке баш күтәрүләрдә ул шул калалык хәлен алып килгән. Йортның тирә-юнендә шәкердләр өчен бик күп хөҗрәләр бар. Болар иске заманнан бирле үк укучыларның тора торган урыннары булып килгән. Җәмигъ үзе безнең мәсҗедләрнең хилафына (киресенә) — гаребтән шәрыкка таба озын иттереп эшләтелгән. Михрабы урта бер җирендә. Җәмигъ эчендә челтәр берлә тотылып алынган зур бер кабер бар. Моны «Хәзрәте Яхъя» кабере дип йөриләр. Бу никадәр дөрестер — анысын белә алмадым. Җәмигътан Гарәп көтепханәсенә һәм Гарәп музәханәсенә кердек. Боларның икесе дә төрекләр дәверендә эшләнгән мөәссәсләр (корылмалар). Гарәпләр аларны зур гайрәт сарыф итеп алып

баралар вә тарихи әсәрләрне чит халыкларның урлауларыннан коткарып калдырырга тырышалар. Музәдәге Мисырның мәгъруф пашаларыннан берсе тарафыннан һәдия ителгән иске акчалар коллекционы бик кыйммәтле асаре гатикадандыр (борынгы әсәрдер). Болар эчендә бөтен өмәви вә габбаси хәлифәләренең акчалары мәүҗүддер (бардыр). Иң иске ислам акчасы бу музәдә Габделмәлик бин Мәрван акчасы. Тарихи һиҗри берлә 79 (милади белән — 698) ел дип язылган. Шунда ук Һулакуның (Чыңгыз нәселеннән килгән хөкемдар) бер бакыр акчасы да саклана. Тарихи бу тарафларны Һулакуның алу тарихы, диделәр (654–663 һиҗри) (ягъни 1256–1265 еллар). Ләкин акчаны алып, дикъкать берлә карый алмадым. Янымда зурайта торган пыялам да юк иде. Монда бик күп тарихи, мәдәни әсәрләрне зиярәт итеп, Шәфыйк бәк берлә каһвә эчеп аерылдык. Мин тагын мөһаҗирләр мәхәлләсенә илдәшләремне эзләргә киттем.

Мөһаҗир мәхәлләсе элек Шамның кырыенда бер таулык кына булган бу җирләр солтан Габделхәмид вакытында чиркәс, арнауд, бошнак (боснияле) һәм татар мөһаҗирләренә бушлый бирелгән булган. Һавасы бик яхшы булганга, бик тиз бу җирләр үсеп китеп, зур, бай бер мәхәллә булып өлгергән. Хәзер бу җир Шамның иң аристократ бер җире. Мин тауның югарыларына кадәр чыгып, өстеннән бер карадым. Шәһәр тәмамән аяк астында кебек калды. Төрле тарафларны карап, мәхәллә эченә төштем. Һәрбер кибет вә каһвәханәгә кереп, татар мөһаҗирләрен сорашырга тотындым. Йөри торгач, бер икмәкче кибетеннән: «Әнә шунда!» — дип күрсәттеләр. Миңа кушып җибәрелгән икмәкче малай берлә бер өйнең капкасына килеп туктадык. Кактык. Аннан тәрекчә: «Кем вар?» — дигән бер хатын тавышы ишетелде. Мин: «Казаннан килгән бер юлчы, монда Казанлы мөһаҗирләр тора дип ишеттем», — диюемә өйдән: «Аннә, һәмшәһрең (ватандашың, якташың) килде!» — дигән бер кыз тавышы ишетелде. Миңа: «Хәзер, хәзер, аннә чаршафны гына (пәрдәне; киемне) кия», — диде. Ишек ачылды. Өйгә кердем. Карт кына бер хатын: «Боер, боер!» — дип, мине ак өенә кертте. Пөхтә бер бүлмә. Казандагы кебек пыялалы шкафка бик күп чынаяклар, чәйнекләр тезелгән. Казан ысулы мендәрләр өелгән... Бер урта татар гаиләсенең өе. «Кем буласыз соң?» — диде. Мин дә әйттем. Абыстай үзе Бөгелмә өязе, Каратан (Каратай ?) авылыннан Хәсәнулла дигән бер абзыйның Миңлелбанат исемле кызы икән. Атасы Шамда үлеп калгач, үзен мондагы илдәшләре Хәсән исемендә харбутлы (Хорватиядән) бер төреккә кияүгә биргәннәр. Инде аңа утыз еллап вакыт үткән. Абыстайның угыллары җиткән. Кызлары кияүгә чыккан. Бер кызы Шамны төрек гаскәре ташлап чыкканда булган патырдида (? ыгы-зыгыда, сугышта. — *Х.М.*) үтерелеп таш-

ланган. Абыстай шуларны берәм-берәм аңлатырга тотынды. Үзе сөйли, үзе көлә, үзе җылый иде. «Кызым Хәдичә (кечкенә кызы) бүген төш күргән. Иртә белән: «Сиңа, әни, бер шатлыклы хәбәр килә», — дигән иде. Инде дөрес чыкты. Туганымны күргән кебек булдым. Әй, сөйли-сөйли оныттым. Кызым, Хәдичә, самоварны куй!» — диде. Аның артыннан: «Куйдым, аннә, куйдым!» — дигән җавап килде. «Килүеңә рәхмәт, туганымны күргән кебек булдым. Безнең авыл менә шундый, мондый...», — дип сөйләргә тотынды. Сөйләгән саен абыстайның телендә аннан-моннан йоккан госманлычалыклары бетә бара. Чистайны сөйли башлаганда, инде ул тәмамән Каратан авылының Миңлелбанат абыстай булып калган иде. Сугыштан элек кенә абыстай илгә дә кайтып, кардәш кабиләсен күреп килгән икән. Хәзер дә бик күрәсе килә. Ләкин хат язса — хатка җавап юк. Хәбәр күндерсә — җавап юк. Урыс бик баскан икән, дип кенә ишеткәли икән.

— Бездә бит урыс көчләп чукындыра, дип сөйлиләр иде. Мәрхүм эти дә шуннан куркып, ислам йортына һиҗрәт иткән иде. Әллә шул көннәр килдеме? — диде.

Мин дә андагы хәлләрне аңлаттым.

Абыстай:

— Ай мескеннәр! Ай мескеннәр! — дип куя. Күзеннән тәгәрәгән яшьләрен яулык очы белән сөртә иде. Чәй килде. Чынаяклар, чәйнекләр тәмамән Казанча булуга башка, чәй дә чын чәй иде. Чәй янына куйган вареньесы да безнеңчә кайнатылган иде. Чәйне татып карагач: «Сез әле, абыстай, чәй эчүне онытмаган икәнсез, чәегез бик һәйбәт!» — дидем. «Онытаммы соң, онытмадым. Менә, илемнән аерылып, 38 ел яшим, Аллага шөкер, телләренә дә, гадәтләренә дә өйрәнмәдем. Бөтен бала-чагама чәй эчәргә өйрәттем, онытаммы соң — онытмадым!..» — диде. 38 ел буена төрек, гарәп мәдәнияте эчендә юарланган бу абыстай, ник утка янмас, суга батмас татар булып калуы мине бик тирән уйларга төшерә иде. Вә татар гонсырының (кавеменең) никадәр куәтле икәненә алдымда тагы бер җанлы шаһиты күрсәтеп тора иде.

— Халык артыннан йөрисең икән, рәхмәт, Алла әҗереңне бирсен! Туган илемне күргән кебек булдым, сезгә дә туган илләрне күрергә язсын иде, куыгыз инде шул кяферләрне! — диде дә тагын күзеннән аккан яшьләрне корытырга тотынды. Үзенең кардәш кабиләсен, таныш-белешләрен бик күп сорашты. Чынаяк өстенә чынаякны ясады, мин дә эчтем, ул да эчте. Аш ашарга калырга чакырды. «Рәхмәт, абыстай, вакытым тар бит, тагы башка илдәшләрне дә күрергә телим», — дидем.

— Ярый алай булса, ярый. Рәхмәт килүеңә, әйдә алай булса! — дип, мине алып, башка илдәшләрне күрергә урамга алып чыкты. Юлда үзе бер туктамыйча сөйли иде.

— Төрекләр ташлап чыкканда, монда бик көчләделәр бит.

Кызымны ике вагон арасына кысып үтерделәр. Төрек, диделәр дә, үтерделәр... Изгелекнең кадерен белмәделәр, монда бит җәннәт иде, җәннәт! Хәзер генә кяфер басты. Кызымны үтерделәр шул, Аллаһ җәзаларын бирсен. Үз илең түгел шул, куркып кына торабыз, — диде. Сүзене ишетмиләрме дип, тирә-юненә каранды.

Менә бер өйнең алдына килеп туктадык. Абыстай ишеккә шакыды. Аннан килгән тавышка татарчалатып: «Мин, мин, кунак китердем, ач тизрәк, туган илебездән килүче, Аллаһ мосафиры!» — диде. Ишек ачылды, өйгә кердек. Мине ак бүлмәләренә керттеләр. Бусы да тәмамән Казанча иттереп җыелган иде. Бу өй Уфаның Гыйззеддин Хаҗи гаиләсенең өе икән. Хаҗи әфәнде үзе вафат иткәнгә, абыстай угылы, кызы белән яши. Казанның мәшһүр Җиһан остазбикәсенең кызы икән. Без танышып өлгерә алмадык, угылы Әхмәд Сәгыйд әфәнде дә кайтып җитте. Ул да монда әүкафта (вакыфлар идарәсендә) мохасәбәче (тикшерүче) булып хезмәт итә. Элгәре болар Мәдинәдә яшәгәннәр, аннан төрекләр куылгач, Шамга күчеп килгәннәр. Угылы Русиядә булган, Төркиядә булган. Аңлы, тәрбияле бер егет. Бик күп уртак таныш-белешләр дә чыкты. Сөйләшеп торганда, Әхмәд Сәгыйд әфәнде: «Үзебезгә генә пешерелгән ашыбыз бар, гаеп итмәссез», — диде. Бергәләп аш ашадык. Шулпасы тәмамән безнең Казанның лапшалы шурпасы иде. Аштан соң якташ миңа шәһәрне күрсәтергә булды. Абыстайлар белән күрешеп, чыгып киттем. Кичкә кадәр шәһәрне карап йөрдек. Хәмидия чаршусында (базарында) сату итүче Нури әфәнде дигән бер кеше бар икән. Бу әфәнде безнең чистайлы икән. Аның белән күрештек, ләкин үзе бик озын фалиҗ (паралич) белән хәстә ятканга, рәтләп сөйләшә алмадык. Аннан соң төркестанлы мөһаҗирләрдән Әхрам җәмигының имамы Салих вә Мөхәммәд Гали Ясәвиләрне зиярәт итеп чыктык. Болар монда тәкиядә шәйх булып, мәктәп ачып, балалар укытып торалар икән. Үзләре Төркестан мәсьәләләре вә бөтен Русия мөселманнарының эшләре белән бик якыннан таныш булып торалар икән. Мине Бохара пылавы ашарга бик чакырдылар, сүз бирә алмадым. Сәгыйд әфәнде шәһәрнең зур җаддәләрене (олы юлларын; проспектларын), җәмигъларын күрсәтте. Өмәви җәмигысыннан соң иң мәшһүр җәмигъ солтан Явыз Сәлимнең җәмигысы икән. Моның вакыфлары бик күп, янында шәкертләр торыр өчен ясалган хөҗрәләр дә бик күп икән. Аларны хәзер бераз яңа юлга куйганнар. Хөҗрәләрнең бер бүлеген төзәтеп, тыйббия (медицина) шәкертләре өчен лаборатор ясаганнар. Бер тарафына хәстәләр карый торган йир ясаганнар. Бер кыйсемендә һаман әле укучылар тора. Мондагы шәкертләрдән бүлмә өчен, ягу-яктырту өчен акча алынмауга башка боларга ашау-эчү дә бирелә. Укучылар тәмамән үз эшләре

белән генә мәшгуль була алалар икән. Бу масрафлар (чыгымнар) һәммәсе дә мәрхүм солтан Явыз Сәлимнең вакыфыннан капланып килә икән. Җамигъның бер тарафында бакчалык. Шуның эчендә кечкенә генә бер каберлек. Монда соңгы солтан Вәхидеддин дәфен ителгән (җирләнгән). Һәм дә күптән түгел генә вафат иткән Зиннәт солтан да шунда күмелгән. Зияратлары тәмиз (чиста), пөхтә иттерелеп тора. Мәсҗед эченә кердек. Аның идәненә җәелгән паласлар — һәммәсе төрек эше. Гомумән, Шамда төрек асаре бик күп. Төрекләрнең тәэсире дә монда бик зур. Һәркем төрекчә сөйли. Һәркем төрекләрне сагынып кайгыра. Зур кышлалар (казармалар, өйләр) монда солтан Габделхәмиднең дәверендә эшләтелгән. Вокзал башында солтан Габделхәмиднең туграсы (матур итеп язылган исеме) әле дә ялтырап ята. Урамнарның исемнәре: Җәмал паша, Әнвәр паша; чаршулары (базарлары): Хәмдия чаршусы, Мидхәд паша чаршусы... вә һәказа (шул рәвешле). Бер мәйдан Хиҗаз тимер юлы ачылуының ядкәре итеп эшләтелгән. Бер багана һәйкәлнең янына Хәрәме Шәриф сурәте ясалып куелган. Багананың дүрт тарафына бу тимер юл солтан Габделхәмид дәверендә фәлән тарихта эшләтелде дип, төрекчә язылган язулар бар. Боларның икесе төрекләр куылгач, әллә нинди бер кара буяу белән буялган булган. Инде аннан бирле шактый вакыт үткәнгә, ул кара буяу үзеннән-үзе уңып, сүзләре тәмамән чыккан.

Шул иске гыйбарәләр дә яңадан мәйданга чыккан. Хәзерге көндә Сүрия төрекләрдән аерылып тора башлавына 14 ел булганга, ул вакыттагы өмидләрнең барысы да сулып беткәнгә, бу язуларны карарга, буярга теләүче беркем дә табылмаган. Вә моннан соңра да аның табылуы бик ерактыр. Төрек идарәсе дәвере монда инде буллыклы (мул), бәхетле чак булып калган. Сагынып сөйли торган бер дәвергә әйләнгән.

Кичне мин чиркәсләр белән үткәрдем. Сүриядә болар 35 мең чамасы — һәммәсе солтаннар вакытында монда утырганнар, барысы да төрекчә сөйли. Ләкин исламияткә бәйләнышлары төрекләрдән куәтле. Болар йирләрене урыс алгач, Төркиягә ислам йорты дип мөһаҗәрәт иткәннәр вә һәрвакыт Төркияне исламият мәркәзе итеп күреп килгәннәр. Араларында сарай берлә багланышлы шактый күп шәхсиятләре һәрвакыт булып килгән. Чиркәс пашаларының һичбер вакытта да Төркиядә саны аз булмаган. Соңгы Төркия инкыйлабының ялгыз милләтчелек юлыннан китәргә теләвене гомум чиркәсләр аңлап та бетермиләр, кабул да итә алмыйлар. Шуңа күрә Төркия берлә чиркәслек арасында элгәреге замандагы дуслык шактый зәгыйфьләнгән. Истикъляль (бәйсезлек) сугышы вакытында кайбер чиркәс башлыкларының мәгънәсез хәрәкәтләре бу мөнәсәбәтне тагын авырайткан. Ләкин аларның Сүриядәге гарәп-

ләр берлә дә мөнәсәбәтләре шәптән түгел. Французлар бу чиркәсләрне жандармлыкта һәм дә чик саклаучылыкта кулланалар. Гарәпләр чиркәсләрнең хәятене кичерер өчен мәҗбүрият берлә алган шул вазыйфаларыны үзләренә дошманлык дип карыйлар. Үзләре йирле-йортлы булганга, иленнән-йортыннан аерылган бу чиркәсләрнең тамак туйдыру өчен бер эш эшләргә мәҗбүр икәнлекләрене аңлап бетермиләр, аңларга да теләмиләр. Шуның өчен араларында һәрвакыт аңлашылмаулар булып тора. Мин күрешкән чиркәс зыялылары [берсе Сүриядә чиркәс мәбгусе (депутаты) Әмин бәк, берсе «Мазәҗ» исемендәге чиркәс гәзите баш мөхәррире, зур бер мәктәпнең мөдире. — *Г.И.*] бу мәсьәләләрне бик яхшы аңлыйлар. Үзләре халыкларыны бик сөючеләр булганга, шул авыр вазгыятьтән чыгарга да юллар эзлиләр. Төрекләргә каршы да, гарәпләргә каршы да чиркәс халкының дошман булырга һичбер сәбәбе булмавыны вә бу ике халыкка чиркәсләр һаман дус икәнлекләрене бик күп дәлилләр берлә исбат итәләр, кулларыннан килгән кадәр аңлашылмауны бетерергә тырышалар. Боларның халыклары эчендә исламият бик тирән урын тотканга, болар ислам сәясәте берлә бик мәшгульләр. Безнең мөэтәмәрдәге (корылтайдагы) эшләребезне, Мисырдагы чыгышларыбызны бик якыннан тәгъкыйб итеп (күзәтеп) барганнар вә шулардан зур өмидле эшләр көтәләр. Боларның күбесенең Кафкас һиҗрәтенә инде 50–60 ел үткән булса да, яшьләр Кафкасны һичбер күрмәгән булсалар да, Ватан хәмияте (тойгысы) үзләрендә бик куәтле, һәммәсе диярлек беренче имкянда (мөмкинлектә) кайтырга торалар. Бик күп яшьләр Ватаннарын коткарыр өчен җаннарын фида итәргә хәзер торалар. Шуңар күрә Шимали Кафкас истикъляль хәрәкәтенә зур әһәмият бирәләр, аны тәмамән үз эшләре итеп карыйлар, кулларыннан килгән бар көч берлә шул хәрәкәтне куәтләндерергә телиләр. Үзләренең бөтен дөнья чиркәсләре берлә багланышлары шактый куәтле. Араларындагы вак-төяк аңлашылмаулардан өстә дә тора белә торган башлыклары чыкса, шөбһәсез, болар Кафкас мәсьәләсендә зур бер роль уйный беләчәкләр.

Икенче көнне җомга булганга, мин Өмәвия җәмигында җомга намазы укырга киттем. Җәмигъ бик зур булса да, халык шыгрым тулы. Ләкин җомга намазы һич тә Өмәвия җәмигысына мөнасиб (туры килешле, лаек) түгел иде. Хотбәсе искереп беткән бер хотбә; хәзерге әхваль берлә һичбер мөнәсәбәте, багланышы юк. Безнең илдәге надан авыл муллаларының хотбәсе кеби бер нәрсә. Шуңарга кәефем бик китте. Җомганың фарызыны (тиешлесен) бетергәч тә, бер гөруһ (төркем) халык тагын имамга оеп, бер нәрсә укырга тотынды. Мин моңарга аптырап калдым. Ул ихтиятыз-зоһр (өйлә) намазы икән. Җомгадан соң әмир Габделкадыйр әл-Җәзаиринең музәханәсене карадык. Бу музәне әмир Сәгыйд [әмир Габделкадыйр-

ның хәфиде (онытгы. — *Г.И.*)] ясаган вә мөмкин кадәр бабасына гайд (мөнәсәбәтле) бөтен коралларыны, бөтен киемнәрене, бөтен вәсикаларны (материалларны; мәгълүматларны) тупларга тырышкан. Җәзаир (Алжир) — француз сугышыннан берничә Аурупа рәссамнарының рәсемнәре берлә дә диварларыны зиннәтләгән. Музәгә бик күп көч, бик күп акча сарыф ителгән. Музәнең, шөбһәсез, кыйммәте дә бик зур. Ләкин музәханәнең каралуы, саклануы бик мөселманча куелган: теләгән кеше кереп карый ала, теләгән каракка кыйммәтле тарихи нәрсәләрне урлау да бер дә авыр түгел.

Аннан соң әмир хәзрәтләре Шамны күрсәтергә булды. Автомобиленә утырып, шәһәр гизентесе ясарга чыктык. Беренче уларак Мөхеддин әл-Гарәбине зиярәт иттек (Ибне Гарәби — 1165–1240 елларда яшәгән мәшһүр философ, суфый. Ул аеруча үзенең «вәхдәтел-вөҗүд» — «яшәешнең берлеге һәм бердәмлеге» турындагы карашлары белән тарихка кереп калган. Ибне Гарәбине еш кына «бөек шәех», «Әфләтүн угылы» дип тә йөртәләр. Ризаэддин Фәхреддиннең бу зат хакында махсус монографиясе дә бар. — *Х.М.*). Бу ислам галименең зияраты монда мөкаддәс хисап ителә. Башына зур бер җәмигъ та бина ителгән. Шул җәмигъның йортында Җәзаир каһарманы Әмир Габделкадыйр хәзрәтләре дә дәфен ителгән (күмелгән). Дөнья сугышыннан соң гарәп илләрендә башланган каргашалык (ыгы-зыгы; буталыш) эчендә шәһид ителгән әмир Сәгыйднең борадәренең дә (туганының да) зияраты шунда икән. Бу зат хакында мин бу сәфәремдә бик күп ишеткән идем, бу ике борадәрнең төрек-гарәп арасы ачылмасын (бозылмасын) өчен никадәр зур каһарманлык берлә чалышулары (хезмәт итүләре) хакында берничә тарихи вәсыйкалар да күреп, икесенә дә зур хөрмәт биләгән идем. Шул ике бөек ислам шәһиденең рухына Коръән укыдык. Аннан соң әмирнең шәһәр читендәге гареб стилендә салынган күшегене (сараен) карарга киттек. Бу күшек хакыйкатән (чыннан да) бик матур, бик стильле иттереп эшләнгән.

Мин Шамда Русия мөселманнары хакында бер конферанс (лекция) бирәчәк булган идем. Ләкин мондагы дусларның сорашу-белешүләреннән мондый конферанска французларның мөсагадә (булышлык) итмәүләре беленде. Гизле (яшерен) бер мәҗлестә конферанс бирү хатрәле (тыелган) булганга, мин дә ваз кичәргә булдым. Шул бушлыкны тутырыр өчен әмир Сәгыйд хәзрәтләре, шәһәрнең олугларыны, хәмиятлеләрене чакырып, бер аш мәҗлесе ясады. Без дә 3–4 сәгать шунда сөйләштек. Вакытым аз калганга, иртәгә китәргә тиеш идем. Шуның өчен Шамдагы дуст-ишләр берлә күрешеп аерылдым вә икенче көнне Бәйрутка киттем.

Бәйрут — безнең соңгы еллардагы Уяну дәверебездә шактый зур роль уйнаган бер шәһәр. Безнең Уяну дәверендә мәк-

тәпкә омтылучы, Аурупа гыйлемене тәхсыйльгә (өйрәнергә) тырышучы бик күп яшьләребез мәйданга атылган иде. Боларның зур бер кыйсеме мәдрәсә шәкертләре булганга, рус мәктәпләренә кереп укырга яшьләре үткән була иде. Руслар үзләре дә боларга дуст карамаганга, Русиядә боларның гыйлем вә фәнгә сусауларыны бастырырлык бер мәктәп тә юк иде. Шуларның зур бер кыйсеме Төркиягә китә. Истанбулның дарелмөгаллимендә (педагогия уку йортында), дарелфөнүнендә (университетында) үзләренең эзләгәннәрене табып, гыйльми хәзерлекләрене арттырып, илгә кайталар иде. Бер кыйсеме Бәйрутта Америка миссионерлары тарафыннан ачылган Бәйрут көллиясенә (колледжына) кадәр китәләр вә аннан инглизчәгә өйрәнеп, тәкиянең шәкертләре арасына керәләр, инглиз теле аша Аурупа мәдәниятләрен өйрәнәләр иде. Мондый яшьләребезнең саны сугышка кадәр күбәйгәннән күбәя бара, аннан, тәхсыйлене бетереп, илгә кайткан яшь зыялыларыбызның саны ел саен арта бара иде. Болар арасында безнең мәктәп, мәдрәсә ислахында (реформасында) зур роль уйнаган Нияз Максуди, казый Габдулла Сөләйман, петрол мөһәндисе (нефть инженеры) Кәмал Локман кеби бөтен милләт тарафыннан танылган затлар юк түгел иде.

Моңарга башка, Бәйрутның мөфтисе безнең мәктүб берлә мөрәҗәгатебезне эшкә ашырып, Русия мөселманнарының большевик идарәсендәге авыр хәлләре берлә халыкны таныштырып, Рамазан гаетендә зур хотбә сөйләп, безнең туганнарның бу золымнан котылуы өчен дога да кылган иде. Моңарга рәхмәт уку да минем вазыйфам иде. Шуның өчен Бәйрут минем өчен күреләчәк бер йир иде. Мөэтәмәрдә күрешкән, танышкан бик күп гарәп җәмәгать хадимнәре дә монда яшәгәнгә, мин боларны эзләргә булдым. Мөэтәмәр тарафыннан китабәт һәйәтенә (секретариатка; редакцион комиссиягә) сайланган Рияз әс-Сәлах бәкне эзләп таптым. Гарәпләрнең милли мөҗадәләсене (мәсьәләләрен; каршылыкларын) тәмамән каураган (өйрәнгән) бу зат үзе яшь, үзе эшчән, үзе тәмиз (саф) калебле булганга, шөбһәсез, киләчәктә зур роль уйнаячак бер шәхсияттер.

Аннан соң Тарабулус (Триполи) мөҗаһәдәләреннән (дин өчен тырышучыларыннан), иске төрек забитларыннан (аксөякләреннән, түрәләреннән) Бәшир әс-Сәһдави берлә күрештем. Аның берлә Бәйрутны карарга вә дустларны эзләргә тотындык. Олуг мөфтине зиярәт иттек. Мин халкыбыз исеменнән тәшәккер иттем. Мөфти — аңлы, киң карашлы бер зат. Гарәп гәзитләреннән «Ән-нидан» (тавыш; чакыру), «Әл-Бәлаг» (матур сөйләм; риторика) гәзитләрене дә зиярәт итсәк тә, идарәдә адәм гакыллы бер мөхәррирне дә очрата алмадык. Өйләдән соң «Әш-Шәрык» гәзитенең мөхәррире, мөэтәмәр әгъзасы Гуни

әфәндене урамда очраттым. Аларның идарәханәләренә киттек. Гәзитләре басыла торган матбагада бер әрмәни гәзите дә басыла икән. Гуни әфәнде мине бер әрмәни мөхәррире берлә дә таныштырды. Моның берлә сүзгә керешеп киттек.

Әрмәни мөхәррире:

— Без сезнең мөэтәмәрдәге (корылтайдагы) бөтен эшләрегезне тәгъкыйб итеп (күзәтеп) килдек. Бөтен рапорларыгызны (язмаларыгызны), бөтен нотыкларыгызны гәзитебездә нәшер иттек. Безнең арабызда бик күп кафкасияле әрмәни булганга, бик зур дикъкать берлә андагы мөселманнарның авыр хәлләрене тәгъкыйб иттек. Безнең Русиядәге халкыбыз сезнең берлә бергә; без дә Русиянең парчалануын телибез, сез дә шуны телисез, — диде. Сүриядә йөз меңгә якын әрмәни яшәгәнне аңлатты. Мин моннан чыгып, Бәйрут көллиясене карарга киттем. Ләкин вакыт соң булганга, башка биналарны кереп карап йөрергә мөмкинлек булмады. Шәһәрнең төрле йирләрене гизеп, үзебезнең мондагы бердәнбер илдәшебез, монда мөгаллимлек итүче ханымны эзләргә киттем. Адресым начар булдымы, никадәр кыдырсам да (теләсәм дә) таба алмадым. Рияз әс-Сәлах бәк берлә күрешеп, Русия мөселманнары хакында бер конферанс укырга теләдем. Ләкин француз полисеннән (полициясеннән) мөсагадә (ризалык; ярдәм) алу мөмкин булмаячагыннан ваз кичәргә мәҗбүр булдым. Хосусый күрешүләрдә, зыяфәтләрдәге (очрашулардагы) фикер алышулар берлә генә канәгатьләнергә мәҗбүр булдым. Китү көнем дә җитте. Мин, билетларымны алып, Берлинга телеграмм бирергә киттем. Төрекчә язган телеграмманы алмас өчен мәэмүрләр (хезмәткәрләр) япмадыкларыны (эшләмәгәннәрен) калдырмадылар. Ахырда «Төрекчә Аурупада аңлашылмас, сүзләр бозылыр», — диделәр. Телеграммны алмадылар. Мин мөдиренә чыгып шикаять иттем.

Ул:

— Бу сезнең мәнфәгатегезгә, сүзләр бозылыр дип куркабыз, фәлән, — диде.

— Минем мәнфәгатем гаиб улмадан (юкка чыгудан) курыкмагыз, бән разыем (ризамын), бән Аурупаның бөтен шәһәрләрендә төрекчә телеграфлашырым, нәдән сездә төрекчә мәмнугъ (тыела), — дидем.

— Хәер (юк), әфәндем, мәмнугъ дәгел, фәкать төрекчә аңлашылмаз ки! — диде.

Әсрарле (тырыша торгач), телеграммамны төрекчә бирдем. Монда төрек тәэсирене бетерү өчен эшләнгән бер сәясәт булырга кирәк. Төрек консуллары, төрек бәкләренең бондый кечкенә эшләргә дикъкатьләрене җәлеп итәргә, әлбәттә, вакытлары юк...

Вапурга (пароходка) киттем. Паспорт контроле башланды. Кырык төрле сөальләр берлә башымны катырдылар. Соңын-

нан үзләренең гизле (яшерен) бүлмәләренә кертеп, бик озак тоткач кына «вапурга утырырга ярый» дип, виза суктылар. Отельдә вакытымда ике мәртәбә полис килеп, паспортымны язып-сызып, сорап киткән иде.

8 нче март төнлә вапурыбыз калыкты (кузгалды). Мин өч ай ярымлык мөэтәмәр (корылтай) сәфәремнән өйгә таба борылдым. Шул ук Русия мөселманнарының эше берлә әле Румага (Римгә) керергә мәҗбүр булсам да, анда да хәрәкәтләрдә булынсам да, алар ислам дөньясына гаид булмаганга (карамаганга), хатирәләремне шунда бетерәм.

# Гаяз Исхакый публицистикасы

*(«Яңа милли юл» битләреннән)*

## Азатлык көрәшенең мөнбәре

«Яңа милли юл» дөньяның караңгы вә чуалчык юлларында бик күпләренә милли юлын күрсәтә торган Тимер Казык йолдызы булып килә алгандыр».

*Гаяз Исхакый*

Инкыйлабтан соң чит илләрдә чыккан татарча гәзит-журналлар арасында «Яңа милли юл» мөхтәрәм урынны алып тора. Ансыз татарның мәдәниятен, милли-азатлык көрәшен һәм, гомумән, тарихын тиешенчә күзаллап та, бәяләп тә булмый. Ул халкыбызның энциклопедиясе, көрәш елъязмасы кебек. Нәкъ менә шуңа күрә дә татар мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүче чит мәмләкәт галимнәре «Яңа милли юл»га еш мөрәҗәгать итәләр, аны, ышанычлы чыганак буларак, бик теләп файдаланалар. Бездә дә соңгы вакытта аннан аерым материаллар укучыларга тәкъдим ителә башлады. Әмма әле, кызганыч ки, укучыларның гына түгел, күпчелек татар белгечләренең дә «Яңа милли юл» хакында күзаллаулары бик тонык. Шуны күздә тотып, без бу мәкаләдә журнал хакында аерым белешмәләр бирергә, кайбер фикерләр әйтергә җөрьәт итәбез.

«Яңа милли юл» мәшһүр әдип, публицист, җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый исеме белән тыгыз бәйләнешле. Ул бу журналны нигезләүче, аның баш мөхәррире һәм төп авторларыннан берсе. Дөрес, мәҗмуганың 1–19 саннарында журналның «мәсьүл редакторы К.Русак» диелгән. Бу — Гаяз Исхакыйның йә үз кушаматы яисә рәсми якны күздә тотып куелган башка берәр зат. Чөнки журналны оештыручының һәм тәүге санnарыннан ук аны җитәкләүченең Гаяз Исхакый булуы шөбһәсез. Мәҗмуганы чыгаруга шулай ук баш мөхәррирнең «Учительская школа»дан ук якын дусларыннан берсе булган Гомәр Тәңреколый да (Терегулов) үзеннән зур өлеш кертә.

Мәгълүм булганча, Гаяз Исхакый 1927–1939 елларда нигездә Варшава, Берлин калаларында яши. Ерак Шәрыкка да шул чорда, ягъни 1933–1936 елларда сәяхәт кыла. Бу еллар — эмиграциядәге милли-азатлык һәм сәяси хәрәкәтнең көчәеп, тагын да оешып киткән дәвере. 1928 елның 28 июнендә Варшавада Гаяз Исхакый инициативасы белән Идел-Урал комитеты корыла. Ике елдан соң, ягъни 1930 елда Польша башкаласында Идел-Урал, Төркестан, Азәрбайҗан, Кырым, Төньяк Кавказ, Украина, Белоруссия, Грузия, Карелия вәкилләрен үз эченә алган «Прометей» исемле милли-азатлык хәрәкәте оешмасы төзелә. Аның да үзәгендә Гаяз Исхакый тора.

Бөек әдип фикеренчә, хәзерге заманда матбугатсыз халык телсез, вәхши халык кебек. Иҗтимагый-сәяси көрәштә вакыт-

лы матбугатның ролен шәхси тәҗрибәсендә тирәнтен аңлаган Гаяз Исхакый 1928 елгы Варшава корылтаенда гәзит-журналлар чыгару бурычын бөтен кискенлеге белән куя. Бер төркем милләттәшләренең матди һәм рухи ярдәме белән ул үзе «Милли юл» мәҗмугасын чыгаруга керешә. Аның беренче саны 1928 елның 23 декабрендә, ә икенчесе 1929 елның 15 гыйнварында дөнья күрә. Журнал 1930 елга кадәр айга ике мәртәбә «Милли юл» исеме белән чыга, инде алга таба ул «Яңа милли юл» атамасын ала һәм, кагыйдә буларак, айлык мәҗмугага әверелә. 11 еллап вакыт эчендә журналның барлыгы 136 саны дөнья күрә, шуның берничәсе — куш саннар. (1929. — № 20–21, № 22–23; 1933. — № 8–9; 1935. — № 9–10; 1938. — № 8–9...) Текстлар — гарәп графикасында. Тышлык битләрдә латин хәрефләрендәге сүзләр, атамалар һәм белешмә характерындагы немецча текстлар да күзгә ташлана. Мәҗмуганың теле татарча. Әмма кырымтатар, төрек һәм кайбер башка төрки телләрдә бирелгән өзекләр, текстлар да бар. Журналның форматы — 24х16,5 см. Күләме — 15 көнгә бер чыкканда — 16 шар бит (куш саннары — 26 битлек), айлык саннары 1930–1932 елларда — 26, ә алга таба, кагыйдә буларак, 32 битлек. Арада 38, 42 битлек саннар да очрый. Мәҗмуга юка тышлыкта.

Журнал, нигездә, Берлинда (Штеглиц, Миквельштрассе, 14) нәшер кылына. Аның 1929 елгы 20–21 нче куш санында мондый белдерү бар:

«*Мәҗмугамызның башкарма йортын (идарәханәсен) Берлиндан күчерергә туры килде. Әлегә төпле бер башкарма йорт табылганга кадәр «Милли юл» өчен йибәреләчәк акча, хат, мәкалә вә башкаларны түбәндәге адреска йибәреп торуларын бөтен укучыларымыздан үтенәмез*». (Биредә Гаяз Исхакыйның Польшадагы адресы күрсәтелә.) «К.Русак» исеменең Гаяз Исхакый атамасы белән алышынуы, күрәсең, матди һәм кайбер башка факторлар белән бәйле булса кирәк. Мәҗмуганың 1929–1930 еллардагы берничә саны Варшавадагы иске адрес белән дөнья күрә. Ә инде журналның 1930 елның ноябреннән алып ахырга, ягъни 1939 елның октябренә кадәр чыккан саннары Берлинда (Шарлоттенбург, 1. Постфакт № 8) нәшер ителә. Монда гарәп хәрефләре белән китаплар, гәзит-журналлар чыгаручы «Виктория» дигән махсус нәшрият булуы мәгълүм. Гаяз Исхакыйның «Дулкын эчендә» исемле биш пәрдәлек пьесасы да шунда нәшер ителә (1938). Биредә кайбер башка төрки халыкларның да китаплары, аерым гәзит-журналлары чыгуы билгеле. (Бу елларда Берлинда мөселман мәчете дә эшли.)

Журналның матди хәле шактый кыен була. Ул, нигездә, чит

илләрдәге милләттәшләребез ярдәме хисабына яши һәм шуңа да аны Гаяз Исхакый «Милләт баласы» дип атый. Мәҗмуганың 1930 елгы 11 санында мондый белдерү бар:

«*Финляндиянең хәмиятле (игелекле. — Х.М.) милләтчеләре тарафыннан мәҗмугамызның дәвамына, үсүенә ярдәм өчен җыйнап җибәрелгән ике йөз доллар акчаларын алдык. Бик зур юклык эчендә бөтен мәшәкатьләргә чумып алып барган мәҗмугамызның ихтыяҗы бик зурдыр. Аның дәвамы, үсүе берничә фидакарьнең генә җилкәсенә йөкләнергә тиеш түгелдер. Шуны аңлап, үзләренең милли бурычларын үти белгән Финляндиянең хәмиятле милләтчеләренә рәхмәтләремезне белдерәмез вә башка йирләргә таралган милли даирәләремезнең дә болардан үрнәк алуларын өмет итеп каламыз* («Милли юл» башкармасы)».

Журналның 94 нче (1935. — № 12) санында да мәҗмуганың ярдәмгә мохтаҗ булуы искәртелә: «*Бик күп авырлыклар берлә үзенең юлын какшатмыйча алып килә торган мәҗмугамызга матди вә мәгънәви ярдәмдә булу — һәр милләтдәшнең вазыйфасыдыр*». Кайбер саннар хәтта мәҗмуга хезмәткәрләренең үз көчләре белән үз машиналарында да җыела. Бер санда журналның соңга калып чыгуы әйтелә дә ахырда болай языла: «*Мәҗмугамызның бу саны көчемез берлә тугдырган үз машинамызда тезелеп, укучыларымызга тәкъдим итéләдер*» (1936. — № 9). Матди як ничек кенә кыен булмасын, журналның хакы әбүнәчеләр (подписчиклар) өчен әллә ни артык куелмый: бер елга — 3,5, алты айга — 2 доллар.

Мәҗмугадагы материалларның авторлар даирәсе шактый киң һәм төрле. Алар, нигездә, эмиграция нәтиҗәсендә дөньяның төрле почмакларына, аеруча Кытайга, Япониягә, Төркиягә, Финляндиягә, Алманиягә, Ләһстанга (Польшага), Румыниягә сибелгән татарлар. Авторлар арасында без Сания Гыйффәт, Закир Кадыйри, Хөсәен Габдүш, Хәсән Хәмидулла, Ләбиб Каран кебек билгеле каләм әһелләрен дә, Финляндиянең Вәли Әхмәд Хәким шикелле мәшһүр имамын да, Ерак Шәрык милли хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе, «Милли байрак» гәзитенең мөхәррире Рокыя Мөхәммәдишне, Тампере татарларының мәдәни тормышын оештыручы Мәхрусә Вафаны һәм башкаларны очратабыз. Журнал эшен оештыруга, рәсми хакимият оешмалары белән мөнәсәбәтләрен коруга мәшһүр галим Рәшит Рәхмәти Арат та шактый ярдәм күрсәтә. Мәҗмугада «Котлы Мөхәммәд», «Чыңгыз», «Бикбулат», «Лотфулла угылы», «М. Уфа» кебек исемнәр белән басылган мәкаләләр дә байтак. Болар, нигездә, баш мөхәррирләрнең тәхәллүсләре.

Журналдагы шактый күпсанлы материал Гаяз Исхакыйның үзе тарафыннан язылган, һәр санда диярлек баш мөхәррирнең

берәр, хәтта икешәр мәкаләсе очрый. Алар, нигездә, күләмле, саллы, баш мәкалә рәвешендә бирелгән. Аерым материаллар да, гәрчә аларның авторлары конкрет күрсәтелмәсә дә яисә кушаматлар белән бирелсә дә, Гаяз Исхакый каләменә карый. Моны бу мәкаләләрнең тел-стиле, фикерләү рәвеше ачык күрсәтеп тора. Кыскасы, «Яңа милли юл» журналын Гаяз Исхакыйның милли-азатлык өчен көрәш мөнбәре, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни эшчәнлегенең елъязмасы дип тә атарга мөмкин.

* * *

Ә соң мәҗмуганың идея-тематикасы, эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт? Әйткәнебезчә, 11 еллап вакыт эчендә журналның 136 саны дөнья күрә. Бу — якынча 4 мең бит дигән сүз. Шуңа күрә бу кадәр зур күләмле һәм төрле характердагы, эчтәлектәге материаллар хакында тәфсилле фикер йөртү бу очракта мөмкин дә түгел. Сүз бары тик журналның төп юнәлеше, үзәк тематикасы, төп рубрикалары, кайбер бүтән мөһимрәк яклары хакында гына барырга мөмкин.

«Милли юл»... «Яңа милли юл»... Бу атамалар үзләре үк мәҗмуганың төп юнәлешен күрсәтеп торалар. Милли тарих, халык язмышы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге — менә журналның гомуми тематикасы. Мәҗмуга — милли тормыш агышын, аңа мөнәсәбәтле вакыйга-хәлләрне гадәти теркәүче, гәүдәләндерүче генә түгел, ә милләтнең алга барыр юлын билгеләүче, яктыртучы, оештыручы көч тә. Журнал исеменең «Милли юл»дан «Яңа милли юл»га әйләнүе дә очраклы түгел. Яңа вазгыять, яңа халыкара шартлар төрки-татар язмышына яңачарак якын килүне, аның барыр юлын ачыграк, максатны конкретрак куюны таләп итә. Төп максат — милләтләрнең азатлыгы, тигезлеге өчен көрәш, һәр халыкның үзенең бәйсез дәүләтен төзү. Журналның 1933 ел 10 санында Спинозаның мондый сүзләре теркәлгән: «Ирек — бер көч димәктер. Бу көч һәр халыкның үзен-үзе үстерү көче; боңа һәрбер мәхлук та (җан иясе дә. — *Х.М.*) табигате илә омтыла». Мәҗмуга битләрендә һәм төркестанлыларның, һәм украинлыларның, һәм кавказлыларның, һәм күп кенә башка халыкларның азатлык, бәйсезлек өчен көрәше эзлекле рәвештә яклана; барың да хөр булганда гына мөстәкыйль дәүләтчелеккә ирешү мөмкинлеге күрсәтелә. Мәҗмуганың тышлыгында еш кына «Ирекле ил уен таратучы журнал» дигән сүзләр очрый. Бу — гадәти лозунг кына түгел, ә текстларның эчтәлеге, рухы белән ярашкан төп идея дә.

«Яңа милли юл» журналының һәр санында диярлек тышлыкта түбәндәге сүзләр язылган: *«Идел-Уралның истикъляленә хезмәт итүче, илнең һәм халыкның матди вә мәгънәви бар-*

*лыгы һәм аның киләчәге тугрындагы фикерләрне эченә алган һәрбер язма өчен мәҗмуга битләре һәркемгә ачык».* Журналда Идел-Урал, «Идегәй» дастанындагы кебек, татар дәүләте, Идел-йорт рәвешендә күзаллана, аның бәйсезлек яулап алуы, мөстәкыйль тормыш коруы бөтен эшчәнлекнең, көрәшнең асыл максаты итеп күрсәтелә. Әмма әле чынбарлык башка: Идел-Урал, татар халкы Мәскәү хакимияте, Сталин режимы астында. Бу хәл журналның тышлык рәсеме белән дә искәртелә: Идел-Урал харитасы (картасы), ә ул зинданда — читлек эчендә. «Яңа милли юл» сүзләрендәге «л» хәрефенең озын сызыклары нәкъ әнә шундый символик мәгънә тудыруга ярдәм итәләр дә.

Шулай итеп, мәҗмугадагы материалларның сайланышы, урнаштырылышы, идея-тематикасы, иң беренче чиратта, халкыбызның барыр юлы, бүгенгесе һәм үткәне, милли бәйсезлек, мөстәкыйльлек өчен көрәше белән бәйле.

Журналның һәр санында диярлек агымдагы халыкара хәлләргә күзәтү бирелә һәм шул контекстта төрк-татар язмышы карала. Бу төр мәкаләләргә (алар, нигездә, баш мөхәррир тарафыннан язылган) киң колач, фикер тирәнлеге, көчле публицистик аһәң хас.

Мәскәү хакимияте, аның кул астындагы матбугат органнары дөнья җәмәгатьчелегенә илдәге объектив хәл, аеруча милләтләр язмышы хакында берьяклы хәбәр бирү белән генә чикләнә. Әмма шуңа да карамастан «Яңа милли юл», бар булган рәсми, басма (бигрәк тә төрки җөмһүриятләрдәге) мәгълүматларны җентекле тикшереп, СССРдагы әхвәл, төрки-татарларның хәле турында даими рәвештә материаллар биреп килә. Аларда совет хакимиятенең урыслаштыру сәясәте, халыкның диненә, тарихи хәтеренә каршы көрәше, эзәрлекләү эш-гамәлләре кискен тәнкыйтьләнә. *«Дин вә милләт,* — диелә бер мәкаләдә, — *халкымызның большевиклар дәверенә кадәр иң мөкатдәс дип белгән рухи барлыгы иде, һәм шуның берлә ул үзен 300 елдан артык саклады,киләчәккә өмидне өзмичә яши иде. Бүген дин вә милләт большевикларның иң курыккан каршылыгы булып тора» (1935. — № 2. — 2 б.).* Шул ук санда без «совет статистикасының ышанычсыз» булуы (11 б.), уку йортларында «урыс тарихы»ның гына өйрәнелүе (15 б.) һәм башка шундый тәнкыйди фикерләр белән дә очрашабыз.

Журнал төрки-татар халкының күренекле уллары хакында да материаллар биреп бара. Мәсәлән, мәҗмуганың 1933 елгы дүртенче саны Исмәгыйль Гаспралының, Габдулла Тукайның үлемнәренә 20, «Тәрҗеман»ның чыга башлавына 50 ел тулуга багышланган. Гаять тирән эчтәлекле, сурәтләргә, мәгълүматларга бай сан! Журналның 1936 елгы июль — август саннары (№ 7–8) тулысы белән Риза Фәхреддин хакында. Шулай ук

«Яңа милли юл»да Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Габдерәшид Ибраһим, Йосыф Акчура, Фуад Туктар һәм татарның башка олуг затлары турында да мәгълүматлар шактый. Шунысы мөһим: аларның эшчәнлеге заманга, милли үсеш перспективасына нисбәтән карала. Мәсәлән, Мәрҗанинең тууы халкыбыз өчен кояш чыгу белән чагыштырыла. *«Аның милли-дини ачык фикерле төшенчәләре,* — диелә бер мәкаләдә, — *бүген мең бер төрле авырлык эчендә яши торган халкымызга золымның чиген белмәгән дошманга каршылык күрсәтү өчен кирәкле булган гамәлләрнең берседер... Мәрҗани хәзрәтнең соңгысыз (үлмәс) хезмәтләрендән илһам алып, аның безгә калдырып киткән милли-дини иманыннан куәт алып, бүгенге көндәге һичбер нәрсәдән өрекмичә, башка дин вә милләт кардәшләремез берлә бергә үземезнең милли вә сәяси корытылышымызны таләп итәбез» (1936. — № 12. — 3 б.)*. Ризаэддин Фәхреддиннең тарихи ролен билгеләп, Гаяз Исхакый болай яза: *«Риза хәзрәт безнең Идел-Урал дәүләтенең мөстәкыйль яшәве өчен кирәк булган иң зур гамәлләрнең берсе булган мәдәни истикъляллемезне ныгыткан вә безнең киләчәк мөстәкыйль дәүләтемезнең төп баганаларын вакыт-заманның какшатуыннан, урыс-улакның җимерү-ватуындан сакларлык хәлгә китерергә иҗтиһад иткәндер»* (1936. — № 7–8. — 4 б.).

«Яңа милли юл» халык тарихындагы, мәдәниятендәге истәлекле вакыйгаларны даими рәвештә яктыртып тора. Мәсәлән, журналның 1938 елгы өченче саны тулысы белән «Милләт мәҗлесенең егерме еллыгына багышлап» чыгарылган. Анда 1917–1918 елгы тарихи вакыйгаларга анализ ясала, Милләт мәҗлесенең халык язмышындагы, барыр юлындагы әһәмияте күрсәтелә. Билгеле булганча, бу юбилей уңае белән 1938 елда Варшавада Бөтендөнья төрки-татар корылтае уздырыла. Журналның бу санында юбилей хакында бай материаллар урнаштырылган. Алар арасында Гаяз Исхакыйның Варшава радиосыннан алтынчы февральдә ясаган чыгыш тексты да бар.

Мәҗмугадагы бер өлеш мәкаләләр чит мәмләкәтләрдәге татарлар, аларның иҗтимагый вә мәдәни хәлләре хакында. Бу юнәлештә аеруча Финляндиядә һәм Ерак Шәрыкта яшәүче милләттәшләребезнең тормышы киң яктыртыла. Мәсәлән, бер хәбәрдә (1937. — № 4. — 9–11 б.) 1937 елның 22 гыйнварында Нагоя каласында яңа мәчет вә мәктәп ачылу тантанасы хакында сүз бара. Шунысы кызыклы: күпсанлы милләттәшләребез һәм Япония рәсми кешеләре катнашкан бу кичә татар телендә уздырыла. Аерым якташларыбыз япон телендә дә сөйлиләр. Бу истәлекле вакыйганы Япония матбугаты да игътибардан читтә калдырмый.

Журналда әдәби материалларга да урын бирелгән. Анда без фольклор, классик шигърият үрнәкләре белән очрашабыз. Күпчелек әдәби текстлар Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Мансур Арысланбәк һәм кайбер башка мөһаҗир татарларга нисбәтле. Күләмле әдәби әсәрләр күзгә ташланмый. Мәҗмуга шулай ук татарларның һәм, гомумән, төрки халыкларның мәдәният тарихына мөнәсәбәтле мөһим язма истәлекләр хакында да мәгълүматлар биреп бара. («Олуг Мөхәммәд ханның солтан Морадга язган мәктүбе», «Ибне Баттутаның Алтын Урда хакында биргән мәгълүматы» һ.б.)

Тугандаш төркестанлылар, кырымлылар, төрекләр һәм башка халыкларның тормышын яктырту — журналның даими рубрикасы. Еш кына аларның чит мәмләкәтләрдә чыккан вакытлы матбугатына күзәтүләр бирелә. Мәсәлән, кырымтатар телендәге «Әмәл» журналына (Ул Румыниянең Күстәнҗә каласында айга бер мәртәбә чыга. Әүвәл гарәп хәрефләре белән, 1939 елдан — латинча), «Истикъляль» гәзитенә (милли Азәрбайҗан истикъляль фикерен таратучы, айга өч тапкыр латин хәрефләре берлә Берлинда чыга), Франциядәге айлык «Яшь Төркестан» журналына һ.б. басмаларга күзәтүләр ясый.

Билгеле булганча, 1935 елның 1 ноябреннән Мукден каласында «Милли байрак» исемле атналык татарча гәзит чыга башлый (гарәп графикасындагы бу басма 1945 елның урталарына кадәр нәшер кылына. Барлыгы 440 саны дөнья күрә)*. Аны оештыручы, нигезләүче дә — Гаяз Исхакый. «Милли байрак» һәм «Яңа милли юл» үзләренең мәсләкләре, рухлары белән үзара бик якын. Шуңа күрә алар бер-берсенә еш урын бирешеп торалар. Мәсәлән, «Яңа милли юл»да (1935. — № 12) «Милли байрак»ның беренче санына җентекле күзәтү урнаштырылган, Гаяз Исхакый тарафыннан язылган «Максадымыз», мөхәррир Рокыя Мөхәммәдиш һәм кайбер башка авторларның мәкаләләре дә шактый тулы бирелгән. Мәҗмугада татарча чыккан бүтән гәзит-журналларга да күзәтүләр очрый. «Яңа милли юл» (аны, кыскалык өчен, еш кына «Милли юл» дип тә йөртәләр), чит мәмләкәтләрдәге татар матбугатын, иҗтимагый хәрәкәтен рухи яктан җитәкләүче көч буларак гәзит-журналларга үзенең киңәш-тәкъдимнәрен дә белдерә, аларның уңай башлангычларын хуплый. Мәсәлән, Мукденда 1935 елның декабреннән башлап «Шәкердләр таңы» исемле «төрек-татар шәкердләренә ана телен онытдырмау вә аны тәрәкъкый итдерүче айлык мәҗмуга» нәшер кылына. «Яңа милли юл» бу журналны ике еллыгы белән котлый, аның шәкертләрне, балалар-

* Миңнегулов Х. Бер ана йортының балалары... «Милли байрак» гәзитенең беренче саны турында // Татарстан яшьләре. — 1990. — 27 декабрь.

ны милли рухта тәрбияләүгә өлеш кертүен билгеләп үтә (1938. — № 2. — 27 б.).

«Яңа милли юл» чит ил галимнәренең төрки-татарга мөнәсәбәтле хезмәтләрен дә үз укучыларына тәкъдим итеп бара. Менә журналның 1937 елгы беренче саны. Анда алман галиме Г.Менденың «Русия төркиләренең милли көрәшләре» исемле немец телендәге хезмәтенә кыскача күзәтү ясала һәм ахырда мондый фикер әйтелә: ул «милли агымызның үсүен вә милли көрәшемезнең төрле дәверләрен тасвир итеп, милли таләпләремезнең нидән гыйбарәт булуын аңлаткан гыйльми бер китап...». Бу хезмәт «алманча белгән һәр кешенең өстәлендә булырга тиеш».

Мәҗмугада татарча, төркичә яңа чыккан китаплар хакында күпләгән мәгълүматлар табарга мөмкин. Мәсәлән, Финляндиядә Сания Гыйффәтнең «Тормыш көзгесе» исемле 4 пәрдәлек драма әсәре басылды. Анда илдәге халыкның авыр язмышы күрсәтелә (1937. — № 7); Мукденда «Төрек-татар әлифбасы» дөнья күрде (1935. — № 12) һ.б.

Журналда, гәрчә күп булмаса да, аерым сурәтләр, фоторәсемнәр һәм төрле иллюстратив материаллар да бар. Мәсәлән, Нагояда төзелгән татар мәчете; Милләт мәҗлесенең 20 еллыгыннан фоторепортаж; Варшавадагы Тукай кичәсе; Ризаэддин Фәхреддин хатларының күчермәләре һ.б. Мәҗмуга тышлыгында еш кына күренекле каләм әһелләренең рәсемнәре урын алган: Габдулла Тукай (1931. — № 4), Йосыф Акчура (1935. — № 6), Исмәгыйль Гаспралы (1931. — № 6), Кырым халык шагыйре Мөхәммәд Ниязи бәк (1931. — № 11), Муса Акъегетзадә (1931. — № 11), Габдерәшид Ибраһим (1931. — № 12), Ризаэддин Фәхреддин (1936. — № 6) һ.б. Ә 1931 елгы дүртенче санын Сөембикә манарасы бизәп тора.

Журналның 1931 елгы җиденче-тугызынчы саннарының тышлыгында күрер күзгә бик күркәм сурәтләр бар. Аларның берсе «Ләһстанда татар атлы гаскәре» (1660 ел) дип исемләнгән. Анда атка атланган бер яшь, чибәр татар гаскәрие тора. Икенчесе — «Наполеонның татар гвардиясе». Өченчесе — «Татар сугышчысы» (XIV йөз), һәр өч сурәт тә «Ләһстан мөселманнарының милли музәханәләрендән алынган».

Мәҗмуганың тышлыгы хакында сүз барганда янә бер хосусияткә игътибар итү зарури. Аның күп саннарында яшәеш, милләт, бәйсезлек, көрәш, бердәмлек, белем турында гыйбрәтле сүзләр, афористик фикерләр теркәлгән. Эпиграф ролендәге бу текстлар журналның эчтәлеге, рухы, төп юнәлеше белән ярашып, керешеп торалар, билгеле бер дәрәҗәдә мәҗмуганың «визитка» вазыйфасын да үтиләр. Мәсәлән, Милләт мәҗлесенең 20 еллыгына багышланган махсус санның тышлыгында Г.Ту-

кайның «Өмид» шигыреннән «Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә» дип башланган дүрт юлы язылган. Тышлыктагы өземтәләрнең шактый өлеше Р.Фәхреддингә, Ш.Мәрҗанигә, К.Насыйрига, Й.Акчурага, Г.Тукайга мөнәсәбәтле. Ә инде кайберләренең авторлары күрсәтелмәгән.

Журналның теле, нигездә, — инкыйлабка кадәрге татар язма теле. Совет чорында безнең телебезгә күпләп кергән урыс сүзләре мәҗмуга текстларында сирәк очрый. Ә инде гарәп-фарсы алынмалары, киресенчә, күп. Төрек теленең йогынтысы көчле. Көнбатыш Европа телләреннән турыдан-туры яисә төрек аркылы кергән сүзләр дә күзгә ташлана (обжиктиф — объектив, култур — культура, паник — паника, групп — группа, программ — программа, комитә — комитет һ.б.). Хәзер безнең телебездә элек актив кулланылып, аннан «иске» дип читтә калдырылган сүзләрне, гыйбарәләрне кабат әйләнешкә кертү бара. Бу процесста «Яңа милли юл» һәм, гомумән, чит мәмләкәтләрдәге вакытлы матбугат, басма сүз теленә мөрәҗәгать итү зыян итмәс иде. Тагын шунысы бар: авторлар, аеруча Гаяз Исхакый, гәрчә алар Идел-йорттан читтә яшәсәләр дә, татар теленең шивәләреннән шактый мул файдаланалар... Үкенеч ки, СССР–Германия пакты һәм икенче бөтендөнья сугышы башлану нәтиҗәсендә милләт өчен игелекле эшләр алып барган «Яңа милли юл» журналы 1939 елда эшен туктатырга мәҗбүр була. Аның хезмәткәрләре төрле якларга тарала. Баш мөхәррире Төркиягә күчеп китә.

* * *

«Яңа милли юл» рәсми рәвештә «сәяси, әдәби, гыйльми, икътисади, милли мәҗмуга» дип йөртелгән. Аның эчтәлеген, идея-тематикасын кыскача гына күзәтү дә бу сүзләрнең чынбарлыкка туры килүен ачык күрсәтеп тора. Журнал ябыла. Әмма ул башкарган эшләр, ул салышкан милли-азатлык юлы өзелеп калмады. Гаяз Исхакыйның үзе, аның көрәштәшләре, варислары тарафыннан дәвам иттерелде һәм иттерелә. Алар арасында Гали Акыш, Тимербәк Дәүләтшин, Надир Дәүләт, Рифат Тәби кебек чит илләрдәге милләттәшләребезне дә, Идел-йорттагы күпсанлы иҗтимагый-сәяси эшлеклеләрне һәм аерым каләм әһелләрен дә күрсәтергә мөмкин.

«Яңа милли юл» үз чорының, читтәге милләттәшләрнең мәнфәгатьләрен генә түгел, ә бөтен татар халкын, аның киләчәген күздә тотып эшләде. Мәҗмуганың баш мөхәррире 1938 елда болай дип язган иде: «...Милли юл»ның эшләрен, үзе ышанып күтәргән милли байрагының вакытлы булу-булмавын киләчәгемез күрсәтәчәк вә киләчәк буынымыз гына аның хез-

мәтләренә дә, эшләренә дә бәһане бирә беләчәкдер» (1938. — № 1. — 1 б.). Хәзерге югарылыктан «Яңа милли юл» алып барган эшнең бөеклеге, тарихи әһәмияте ныграк та, ачыграк та күренә. Империяләр җимерелә, халыкларның ирек, милли-бәйсезлек өчен көрәше дәвам итә. Бу — табигый канун. Аны бернинди көч тә туктата алмый.

Гаяз Исхакый, аның фикердәшләре хыялланган, үз эшчәнлекләренең асыл максаты итеп куйган азатлык, бәйсезлек татар халкы тормышында бүген гамәли төс ала бара.

1992 елда халкыбызның бөтендөнья корылтае булды. Милли мәҗлес сайланды. Идел-Урал халыкларының конфедерациясен төзү дә янәдән көн тәртибенә килеп басты.

«Яңа милли юл»ның 1932 елгы икенче санында титул биттә мондый юллар бар: «Бер милләтне юк иткән нәрсә — милләтнең үз-үзенә булган ышанычының югалуыдыр». Гаяз Исхакый һәм аның көрәштәшләре бу яктан безгә үрнәк булып торырлык. Алар нинди генә кыен хәлләрдә калсалар да, киләчәккә өмет-ышанычларын саклаганнар, милли-азатлык көрәшен дәвам иткәннәр, милләт каршындагы үзләренең изге бурычларын булдыра алган кадәр үтәгәннәр. Үләренә өч көн кала Гаяз Исхакый үзенең ышанычлы ярдәмчесе Гали Акышка: «*Мин төрк-татар халкының иреге өчен бөтен гомрем буена көрәштем... Тәңре сезләргә Ватаныбыз Идел-Урал азатлыгын күрергә насыйп итсен*», — дигән сүзләрне әйтеп калдыра.

«Яңа милли юл», — бер яктан, тарихны, милли-азатлык хәрәкәтен өйрәнүдә мөһим чыганак. Икенче яктан, журналдагы күп кенә фикерләр, аның юнәлеше бүгенге иҗтимагый, сәяси һәм мәдәни хәрәкәткә, милли тәрбиягә аваздаш. Шуңа күрә аны ныграк өйрәнү, андагы материалларны укучыларга мөмкин кадәр тизрәк, тулырак җиткерү зарури. Җөмһүриятебезнең Милли китапханәсендә «Яңа милли юл» журналының һәм, гомумән, чит мәмләкәтләрдә басылган татарча гәзит-журналларны, китапларны туплау, булдыру һәм алардагы материалларның библиографиясен төзү шарт. Әрмәннәр, грузиннар, таҗиклар һәм элеккеге СССРдагы кайбер башка халыклар моны инде күптән эшләде.

*1992*

## «Яңа милли юл» журналы тышлыгындагы кайбер эпиграфлар

«Ил ул — халыкның үтмешендән калган, бу көнгесенә корылган, киләчәге өчен сакланган бер барлыкның учагы».

*(1932 . — № 3)*

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары...

*Габдулла Тукай (1932. — № 5)*

«Таланган халык, изелгән ил синең ярдәмеңне көтә. Илнең ирке өчен көрәшүчеләр сафына кер. Аларның эшләрен ныгыт!»

*(1932. — № 7)*

Алга, туган, алга! Җиңгәнгәчә,
Ил юлында тиңсез тартышка!
Бергә, туган, бергә! Үлгәнгәчә
Ирек өчен изге тартышта!

Ирек сөйгән батыр бабайларның
Сөякләре әле чермәгән.
Күңелләрне яккан ирек уты
Йөрәкләрдә әле сүнмәгән!

Ил юлында канлы тартыш өчен
Алган кылыч мәңге ташланмас.
Иркен алган изге туган илнең
Коллык көне тагын башланмас!

*(«Ирек җыры» дип исемләнгән бу текст журналның 1932 елгы 7–10 саннарында строфалап бүлеп-бүлеп бирелгән.)*

«Илсез халык юк; халыксыз ил юк. Ил берлә халык берләшеп, аерылмаслык бер бөтенлек ясаганда гына тормышны корып була. Онытма: син кем? Синең илең кайда?!»

*(1932. — № 11)*

«Халкың бүгенге коллыкда калмаячагына, аның күтәреләчәгенә һәм ямьле киләчәгенә ышан да, бу — син тырышкан чакта гына була алачак итеп эшлә. Онытма: эшнең булып-булмавында син дә мәсьүл!»

*(1932. — № 12)*

«Милли берлек һәм милли парлак мәсьәләләре — болар һичбер вакыт икенче урынга калдырыла торган мәсьәләләр түгел».

*Гыйсмәт паша (1933. — № 2)*

Авыру, азабдагы ул илләрнең
Сөякләре сыкрый, сызлана;
Йөз еллардан бирле ирек юлын
Йөрәкләре капшый, эзләнә.

*Сания Гыйффәт (1933. — № 3)*

«Тарихны тормыш яза. Син дә үз өлешеңне яздырырга онытма!»

*(1933. — № 5)*

«Илле ел элгәре башланган «телдә, фикердә, эштә берлек!»нең мәгънәсе бүгенге көндә «сәясәттә берлек!» димәктер».

*Гаяз Исхакый (1933. — № 6)*

«Узган кире кайтмый. Югалган һәрбер көн киләчәктә бер бушлык тудырачак».

*(1933. — № 7)*

«Бер милләтнең көче бер үк теләккә, бер үк юл берлә баруда!»

*(1933. — № 8–9)*

«Кеше өчен иң гүзәл юаныч моталәга, иң яхшы иптәш — китаплар».

*Ш.Сами (1937. — № 1)*

«Бәгъзе бер көтелмәгән кебек нәрсәләргә гаҗәп итеп вә ис китеп торулар дөнья китабыны күрмәү сәбәбендәндер. Дөнья китабыны моталәга кылучылар өчен дөньяда булган эшләрнең һәрбере гади вә табигый хадисәләрдәндер (вакыйга-хәлләрдәндер. — *Х.М.*)».

*Ризаэддин Фәхреддин (1937. — № 6)*

«Хакыйкатькә мөстәнәд булган (нигезләнгән. — *Х.М.*) фикер шулкадәр куәтледер ки, миллионнарча акчаның, йөз меңнәрчә гаскәрнең, туп вә мылтыкларның көче йитмәгән нәрсәләргә аның көче йитә. Фикерсез миллионнарча кешенең хәйран булган мәсьәләсен фикерле бер кеше хәл итә, фикерсез миллионнарча кешене фикерле бер кеше җиңеп, аларны башка юлга кертә. Шуның өчен дә һәркем ул гали фикерне тәгъзыйм вә аңа хөрмәт итә».

*Ризаэддин Фәхреддин (1937. — № 9)*

«Төрки барның күрке бар дигәндәй, мин үзем саф төрки телен яратам».

*Каюм Насыйри (1937. — № 10)*

«Бу дөньяга килеп тереклек кыйлудан максуд ни нәрсә, — аны белдермәк кирәк. Тәрбиянең башы — ошбудыр».

*Каюм Насыйри (1937. — № 11)*

Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә,
Син дә, вөждан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.
Юк, түбән калмас бу җан: фитърәтдә гали[1] булган ул,
Кисмәк өстендә — кара кош иттифакый[2] кунган ул.

*Габдулла Тукай (1938. — № 3)*

## 10 нчы елымыз*

*Гаяз Исхакый*

Бу санымыз берлә «Милли юл» үзенең унынчы яшенә аяк басадыр. Вә артында калдырган тукыз еллык эш йөге берлә бергә киләчәк елгы милли хезмәтенә керәдер. Бүген без тукыз ел эчендәге «Милли юл»ның эшләрен тикшерергә, аның шул кыска гомерендәге хезмәтләрендән хисап бирергә теләмимез, аның эшләгән эшләре, милли тормышымызда калдырган эзләре хакында сүз сөйләүнең әле вакыты да түгел, урыны да түгел. Аның күтәргән милли байрагы бүгенге мөһаҗәрәтемезнең (күчкән кешеләребезнең) вакытлы мәсьәләсе генә булмаенча, бөтен Идел-Урал төрек-татарының киләчәге мәсьәләсе булганга, аңа кыйммәт бирергә, бәһа бирергә бүгенге мөһаҗәрәтемез тулы көенчә сәлахийатдар (әзер; компетентлы) да түгел. «Милли юл»ның эшләрен, аның үзе ышанып күтәргән милли байрагының вакытлы булу-булмавын киләчәгемез күрсәтәчәк вә киләчәк буынымыз гына аның хезмәтләренә дә, эшләренә дә бәһане бирә беләчәкдер. Без, «Милли юл»ны тудыручылар, дәвам итдерүчеләр, «Милли юл»ның фикерен киң катлавымызга таратырга тиеш диеп ышанучылар, үземезнең көчемез, куәтемез ирек биргән кадәр шул юлга тукыз ел хезмәт иткән кеби, унынчы елында да шул милли эшкә җигеләмез. 11 нче, 12 нче елларымызны да күздә тотып, шуны дәвам итдерүне дә милли бурыч санап, һәрбер авырлык алдында вазыйфамызның башында булырга хәзер торамыз. «Милли юл» мәҗмугасы чыгарыла башлаганда, без милли эшемезнең киң планыны корып, мөһаҗәрәтемезне үзенең мәгънәви тормышында тирә-юнендән мөстәгъни (хаҗәтсез; бәйсез) итүне, мөһаҗәрәтемез өчен кирәкле булган мәгънәви азыкларны тәэмин итүне күздә тоткан, киң рәвешдә милли нәшрият эшемезне алып баруны төшенгән идек. Ләкин мөһаҗәрәтемезнең җәгърафый якдан бик таркау булуы, рәсмән (рәсми рәвештә) оешмаган хәлдәлеге, иске мөһа-

---

* Яңа милли юл. — 1938. — № 1 (118). — 1–5 б.

[1] Фитърәтдә гали — тугмыштан олы.

[2] Иттифакый — очраклы гына.

җирлек ганганәсе (гадәте, традициясе) вә андан калган һичбер матди-мәгънәви мирасларның булмавы безгә үземезнең эш планымызны теләгәнемез рәвешдә киң итеп алып барырга мөсагадә итмәде (мөмкинлек бирмәде). Без милли вазыйфамызның форсаты кадәресен генә барлы-юклы көчемез берлә үтәп, милли хезмәтемезнең важибларын (бурычларын), соннәтиләрен (традицияләрен), мөстәҗибләрен (үтенечләрен) канәгатьләндерүне барысын да киләчәк форсатка калдырып килергә мәҗбүр булдык. Бу эшләрдәге кимчелекләремез, йитешсезлекләремез «Милли юл»ның яшәеш шәраитындан (шартларыннан) килеп чыккан обжиктиф (объектив) манигълар (киртәләр) булганга, киләчәк буынымыз «Милли юл» хакында фикерен йөреткәндә, әлбәттә, бу юксыллыкларымызны күзендән ерак тотмас.

«Милли юл» үзенең милли эшләре өчен, тел, тарих, культура, дин ягындан кардәш берәр мәмләкәтдә оя була алмады, истикъляльләрен кулда иткән кандашларымыз арасында арка таяначак бер агым таба алмады* . Бөтен эшен, бөтен авырлыгын үз өстенә генә йөкләде. Зиһният ягындан да (фикри яктан да), техник ягындан да тәмамән башка Аурупа өлкәләренә сыгынырга мәҗбүр ителүемез бу йитешсезлекләремездә бик зур роль уйнады. Шуңарга күрә бүген кулда ителгән бөтен барлыкларымыз барысы да үземезнең көчемез, үземезнең Идел-Урал төрк-татарларының матди-мәгънәви ярдәмләре берлә генә вөҗүдкә килгәндер. Үзенең тукыз еллык авыр юлын үтешендә «Милли юл» фәкать үзенең илдәшләренә генә мәдъюн (бурычлы) калгандыр. «Милли юл» милләтнең генә баласыдыр. Дөньяның дүрт тарафына таралган илдәшләремезнең мөһаҗәрәт тормышы-тартышында бик авыр вазгыятьләрдә яшәгән милләтдәшләремезнең вакыт (вакты) форсат булып, «Милли юл»га матди-мәгънәви ярдәмгә йитешүе үзе үк «Милли юл»ның мөһаҗәрәтемез алдында кыйммәтене күрсәтә торган вакыйгадыр. «Милли юл» байрагының халкымызның күңеленә үз икәнлеген исбат итә торган җанлы бер дәлилдер. Халкымызның үзенең үзлеген сакларга, үзенең барлыгын, берлеген нинди авырлык эчендә югалтмаска тырышуыны күрсәтә торган, үзенең теләген гәүдәләндерергә омтыла торган бер көч икәнене исбат итә торган сөенечле бер вакыйгадыр. «Милли юл» үзе дә язулары вә фикере берлә, шөбһәсез, халкымызның аерым-аерым шәхесләренең, групп(а)ларының җил кайдан килсә, шунда таба оча торган бер тузан халендән чыгып, милли гәүдәләнүенә сәбәп булгандыр. Дөньяның караңгы вә чуалчык юлларында бик күпләренә милли юлын күрсәтә торган Тимер

---

* Монда, әлбәттә, иң беренче чиратта Төркия күз уңында тотыла (*Х.М.*).

казык йолдызы булып килә алгандыр. Җәгърафый таркау, мәгънән (мәгънәви) оешмаган милләт балаларымызда оешу, берләшү фикеренең үсүенә, киңәюенә, тирәнәюенә сәбәп булгандыр вә бөтен мөһаҗәрәтемезнең милли байрак әтрафында тупланып, милли хәрәкәтемезнең еллар үткән саен үсә килеп, гәүдәләнеп, бер милли байрак булып җитеп, сәяси бер кыйммәткә хаиз (ия) булуына ярдәм иткәндер. Тукыз елда сәяси бер көч итеп хәзерләп җиткергәндер.

Телсез кешенең фикерен, уен аңлап булмаган кеби, матбугатсыз халык та үзенең теләген, омтылышын беркемгә дә аңлата алмыйдыр. Үзе никадәр үзлегенә баглы халык булса да, милли матбугаты булмаган халык тирә-юнендән хөрмәт күрә алмаенча, өченче, дүртенче дәрәҗәдә вәхши халыклар исәбенә индереләдер вә аның берлә беркем дә хисаплашуны кирәкле тапмыйдыр. «Милли юл» мөһаҗәрәтемезнең тәрҗеман әфкяре дә (биредә «фикри яктан аралашу чарасы» мәгънәсендә) булып, Идел-Урал төрек-татарыны телсез, җансызлык дәрәҗәсенә түбән төшерүдән саклады. Аның ана теле булып, халкымызның дәрдене, кайгусыны, омтылышыны ана телендә сөйләде, уйлады, үзенең уе, фикере берлә күршеләрен, дустларын, дошманларын хисаплашырга мәҗбүр итде. Безнең Идел-Урал төрк-татарының милли мәсьәләсен дөньяның сәяси базарына чыгарды вә анда аңарга бәһа куйдырды. Бүгенге көндә «Милли юл» үзенең унынчы яшенә аяк басканда, без Аурупаның төрле мәмләкәтләренә, Якын Шәрыкка, Ерак Шәрыкка таралган меңләрчә-меңләрчә милләтдәшләремезне мәгънәви йебләр берлә берберсенә багланган итеп вә бер милли кыйблага таба хәрәкәт итә торган оешкан бер мәдәни көч итеп күрәмез. Һәрбер йирдә аны сәяси бер барлык булып җиткән хәлдә, сәясәт дөньясында очратамыз. Аның омтылышы-теләгенең дөньяның бик күп тарафларына ингыйкясына (чагылышына) шаһид буламыз. Боларның барысында да азмы-күпме «Милли юл» хезмәтенең эзен сизеп, Идел-Урал төрк-татарының сикълэт изафисенең (биредә «дәрәҗәсенең») көндән-көн үсә баруыны күрәмез. Аркамыздан килә торган «Милли байрак» кеби гәзитемезнең туусындан, дәвам итүендән, үсүендән сөенеп, безнең бу хәрәкәтемезнең йимешле икәнене эшемез, көчемезнең кысырга китмәвенә тагы бер мәртәбә ышанып, эшемезгә дәвам итәмез.

«Милли юл»ның кызыл урыс баскынлыгында яшәргә мәҗбүр булган илемездә никадәр тәэсир ясавын күрер өчен андагы бик күп чын коммунистларның да истикъляль (бәйсезлек) юлына кереп китүләре, истикъляльче булып хөкемләргә бирелүләре, буржуа милләтче булып, үлемгә хөкем ителүләрен күздән кичерү җитәдер. Болар «Милли юл» күтәргән истикъляль байрагының никадәр җанлы, никадәр җазиб (үзенә тарта тор-

ган) икәнлеген күрсәтә торган дәлилләрдер. Большевик хөкүмәтенең еллар буе туктамаенча үзенең коммунист фиркасене милләтче гонсырлардан (элементлардан) әрчергә мәҗбүр булды; бу — милли хәрәкәтнең никадәр киң катлавымызны каплап алуын күрсәтә торган эшләрдер. Большевиклыкның зәгыйфьлеге арткан саен, бу милли хәрәкәтемез куәтләнә барачакдыр. Советларның золымы, җәбере арткан саен, халкымыз истикъляльдән башка котылу юлы юклыгына ышанычын, иманын ныгытачакдыр. Мәҗмугамыз унынчы яшькә аяк баскан көнләремез, тарихи дошманымыз руслыкның башбашдаклык эчендә чәйкәлгән (чайкалган) кызыл русчылыкның чыкмаз тыкрыкга кереп, кая барачагын белмәенчә аптырап калып, кай тарафдан йомрык (йодрык) килә диеб паник(а) эчендә яшәгән көнләренә тәсадеф итәдер (туры киләдер). Бу безгә алган юлымыздан бер карыш та тайпылмаенча, милли кыйбламыздан адашмаенча, эшемез, көчемезне тагы артдырырга, байрагымыз этрафында туплануымыз, берләшүемезне тагы куәтләндерергә мәҗбүр итәдер. Без дә, элекке юлдан язмаенча барырга бисмилла әйтеп, яңа елга керәмез. Милли максадымыз бу елда бөтен милләттәшләремезнең иманлыларын милли байрагымыз этрафына туплап, сәяси куәтемезне артдыру, хәрәкәтемезне тагы да активлашдырудыр. Большевик җимерелү берлә өстемезгә йөкләнәчәк милли вазыйфаларымызга хәзерләнүдер. Бу хәзерләнүемездә без һаман иске юлымыздан барачакмыз, искедә булган кеби, Идел-Уралның истикъляленә кавышуын төп максад итеп куеп, бу хәрәкәтемезне, элекдә булган кеби, киләчәкдә дә төрк культур берлеге даирәсендә алып барачакмыз. Вә һәрбер төрк өлкәләренә кардәшчә карап, төрк өлкәләренең берсенең зарарына булган агымлар берлә мөнәсәбәтдә булышудан озакда (еракта) калачакмыз. Эчемездән, тышымыздан төрк берлеген саклаячакмыз. Уртак дошманымыз — баскынчы руслыкга каршы кортылыш тартышы алып барганда, безнең кеби руслардан җәберләнгән, көчләнгән вә бүген истикъляльләре, кортылулары өчен тартыш ачкан прометей (бу очракта «тоткын» мәгънәсендә) милләтләрнең милли дәгъваларына хөрмәт итеп, алар берлә җәбһә (көрәш; фронт) берлеген сакларга тырышачакмыз. Боларның да һичберсенең зарарына хәрәкәт итмәячәкмез. Без озын гасырлар урыслар берлә тартышып, җан чикешеп килгән Идел-Урал төркләре — озын тарихымызда урысларның даимән алдауларына очраганга, урысларның һәрвакыт биргән сүзләрен бозуларына шаһид булганга, аларның һичбер агымлары, фиркаләре берлә сәяси тәмасәдә (мөнәсәбәттә) булынмыймыз, сәяси мөҗадәләмездә (бәхәсебездә) алар берлә сафдаш булудан качачакмыз. Вә аларның һичбер группа(а)ларына ышанмаенча, үз милли эшемезне үз башымызга гына эшләргә тыры-

шачакмыз. Соңгы вакытларда мөһаҗәрәтдәге русларның төрле агымлары, фиркаләре үзләренең көчсезлекләрен күреп, безнең төрек кабиләләренең әле берсенә, әле берсенә сарылып, якынлашкан булып, алдашу юлына керергә теләүләрен хис иткәнен күреп торганга, бөтен милләттәшләремезнең бу эшкә дикъкатен җәлеп итеп, һәрбер йирдә төрле төскә буялган руслардан еракда торуларын тәүсыя итәмез (киңәш итәбез).

Бу эш елымыз — мәҗмугамызның унынчы елы — халкымызга, илемезгә котылу китерә торган бәхетле ел булса иде дип, бөек Тәңремезгә ялварып, милли вазыйфамызга дәвам итәмез*.

### Мөфти Ризаэддин хәзрәт**

*Гаяз Исхакый*

Мәҗмугамызның бу нөсхәләрен мәрхүм мөфтиемез Ризаэддин хәзрәткә багышлап чыгарамыз.

Ризаэддин хәзрәт үзенең илле еллык хезмәтене һәрвакыт ачык итеп алып барганга вә аның бик күп әсәрләре калганга, аның хакында тулы мәгълүмат бирү бер дә уңайсыз булмаска тиешдер. Ләкин мөһаҗәрәтемезнең илемез берлә ачыкдан-ачык мәдәни мөнәсәбәт йөртүенә большевик хөкүмәтенең манигъ (каршы) булуы безнең бу мәдәни эшемезне тулы көенчә алып барырга киртә булып киләдер вә безне бары мөһаҗәрәтдә (эмиграциядә) табуы мөмкин булган мәрхүмнең әсәрләре, язулары вә мәктүпләре (хатлары) берлә генә кифаяләнергә (чикләнергә; канәгатьләнергә) мәҗбүр итәдер. Бу гайре табигыйлек мәрхүм хәзрәтемезгә каршы булган милли вазыйфамызның яртыйорты гына үти алынуына, шул бөек милли хезмәтчемезне бөтен зурлыгы, олуглыгы, тиңлеге, тирәнлеге берлә милләтемез алдында тулы көенчә күрсәтә алмавымызга сәбәп буладыр. Болар бөтен мөһаҗәрәтемез өчен уртак манигъләр булып, «Милли юл»ның үз көче берлә генә аны үтәп китәрлек имкяне (мөмкинлеге) булмаганга, кирәк мәрхүм хәзрәтнең дустлары, кирәк милли кыйммәтләремезне тулы итеп күрәсе килгән милләтдәшләремез шул мәҗбүри ноксанларымыз (кимчелекләребез) өчен безне гафу итәрләр дип өмид итәмез.

«Милли юл» кулында булган имкян, урталыкда булынган әхвалнең мөсагадәсе (ярдәме) даирәсендә бөтен мөһаҗәрәтемез өчен фарыз кифая булган шул милли фарызны үтәргә, бонең берлә бөтен мөһаҗәрәтемезне зур бер милли гөнаһдан коткарырга тырышды, ләкин эшләгән эшемез берлә Риза хәз-

---

* Мәкалә ахырына «Милли юл» идарәсе» дип куелган. Әмма ул баш мөхәррир Гаяз Исхакыйның үзе тарафыннан язылган.

** Яңа милли юл. — 1936. — № 7–8 (101). — 2–6 б.

рәт хакында аңлатыласы, белдереләсе, языласы нәрсәләр тәмамән тутырылды дигән фикердә түгелмез. Билгакес (киресенчә), кулымыздагы материалның азлыгы, рәсми мәгълуматымызның җитешмәслеге бик күп кирәкле нокталарның (нөктәләрнең—фикерләрнең) ачылмаенча калуына да сәбәп булды. Бәлки, мәрхүм хакында кайбер мәгълүмат тулы көенчә бирелмәү берлә генә калмыйча, хаталар да кереп киткәндер. Боларны төзәтүләр, боларның ачык булмаганларын ачык итеп язуларны киләчәккә калдырамыз вә мәкаләләремездә очраган хаталәрны белгәнләрдән тәсхих итүләрен (төзәтүләрен) үтенәмез. Эшемез зур бер милли вазыйфаны үтәү булганга, бөтен тәсхихләрны «Милли юл»ның киләчәк нөсхәләрендә нәшер итәргә тырышачакмыз. Фәкать бу тәсхихләр, мәрхүм мөфти хәзрәтемезнең тәрҗемәи хәле, эшләгән эшләренең тарихы, әсәрләренең язылышы, басылышы якынлары, әкърибалары (туганнары) мохите тирәсендә булырга тиешдер. Мәҗмугамызга иштиракь иткән (катнашкан) мөхәррирләрнең карашлары берлә мөназарә (бәхәс) төсендә булмаска тиешдер. Мәрхүм мөфти Ризаэддин хәзрәт безнең Уяну дәверемезнең бик зур бер симасы (шәхесе) булганга вә аның эшләгән эшләрен яктырту сәяси фикерләр башкалыгына карамаенча, аның дәвердәшләренең уртак вазыйфаларыдыр. Бу олуг милли хезмәтчемезгә хөрмәтен шул бөек вазыйфамызның җитдилегене игътибарда тотып, бөтен язучыларымыздан вак-төяк шәхси капризларга бирелмәенчә, минем фәлән сүзем калмасын, минем фәлән җөмләмнең фәлән сүзе юл башында булсын, фәлән йирдә кечкенә өтере генә куелмасын, нокта төртелсен кеби вак-төяк шартлар берлә җитди эшне ваксытмауларын вә табигый көенә генә уртак эшкә ярдәм итүләрен риҗа итәмез (үтенәбез).

Кайбер матбугадагы җитешсезлекләр мәкаләләремезнең йирләшдерелүендә үземез теләгәнчә итеп идарә итәргә имкян бирмидер, бондый ноксанларымыз милләтемезнең матди фәкыйрьлеге берлә баглы эшләрдер. Каләм тибрәтүчеләрнең шуларны игътибарга алып хәрәкәт итүләрен, мәрхүм мөфти Ризаэддин хәзрәтнең үз йөзен үз төсендә күрсәтергә, танытырга кирәкле булган нокталарына (урыннарына, фикерләренә) гына әһәмият биреп, вак-төяк җитешсезлекләремезне бармак аша карап, мөгамәлә итүләрен риҗа итәмез.

* * *

Мәрхүм Ризаэддин хәзрәт, безнең Идел буе төркенең (төркиенең) фикри хәрәкәтене бер тарафдан Курсавилар, Мәрҗанилар, Габделкаюм Насыйрилар берлә, икенче яктан, Идел-Урал истикъляле (бәйсезлеге) агымы берлә баглаучы бер тарихи

шәхсыятьдер. Аның кыйммәте безнең үткәнләремезне белер өчен генә түгел, киләчәгемездәге барачак юлымызны, кыйбламызны тәгъйин итәр (ачыклар) өчен дә бик зурдыр. Риза хәзрәт мәрхүмнең истикъляль тарафдары булуы, шәхсыятене хөрмәтләндерә торган бер эш булса, аның шул сәяси истикъляллене таяндыра торган мәдәни истикъллемез өчен гомерене сарыф итүе, милли мәдәниятемезне нygыту, тазарту өчен илле ел бер уйдан эшләве шул истикъляльнең (азатлыкның) яшәве өчен кирәкле зәминне (җирлекне) хәзерләве һичбер язып бетермәслек бер милли хезмәтдер.

Безнең Идел-Урал дәүләте төзүемез вә безнең Идел-Урал истикълялен вөҗүдкә чыгаруымызның шартлары искедәге Каратау (Черногория) мәмләкәте, хәзерге Албания мәмләкәтенең истикъляллендәге шартларга тәмамән башкадыр. Идел-Уралда мөстәкыйль милли дәүләт ясар өчен аны үзбашына яшәтә беләчәк матди вә мәгънәви вазгыяте тәэмин ителгән булырга тиешдер. Идел-Уралда әллә ничә гасырлар зур-зур төрк дәүләтләренең мөстәкыйль яшәве (Хәзәр, Болгар, Алтын Урда, Казан, Әстерхан ханлыклары) үзендән-үзе бонда мөстәкыйль бер дәүләт төзелешкә һәр бакымдан (карашдан) имкян (мөмкинлек) зурлыгыны күрсәтә торган дәлилләрдер. Руслар алганның соңында дүрт йөз ел эчендә кыйлган җәбер-золымлары берлә Идел-Урал төрк-татарының мәдәниятен җимерә алмадылар. Халыкның фикерендә үзен-үзе тәмамән башка бер мәдәният баласы, башка бер халык итеп күрүен аз гына да кимемтә алмаулары үзендән-үзе Идел-Уралда мөстәкыйль төрк мәдәниятенең яшәп килүенә аяклы дәлилдер. Мәрхүм Риза хәзрәт гомере буенча менә шул мәдәниятемезнең истикъляллене сакларга тырышкандыр. Гомере буенча аның мәдәниятенең бүленмәгән бер өлеше булган мөселманчылыкны черетүдән саклар өчен Идел буе мөселманының динчелегенә ябышкан ишанлык, мөтәгассыйблык (фанатизм) кеби төрле-төрле паразитлардан пакьләргә тырышкандыр. Озын тарихлы милли мәдәниятемез үз эчендә генә кысылып калып, буылып китеп, һавасызлыкдан корымасын, коргаксымасын өчен, ул безнең төрк мәдәниятенең төбен, тамырын саклап, аны гареб мәдәнияте белән ашлау кирәклегене аңлап, шуны билфигыль (чынлыкта) татбикъ итәргә (бәйләргә, яраклаштырырга) керешкәндер. Шул эшдә бик зур үрнәк булып, Аурупа мәдәниятенең кәләпүшле, калфаклы көенчә милләтемез эченә сугылуына сәбәпче булгандыр. Боларның икесе берлә дә милли мәдәниятемезне сипләп, аның үсүе куввәтене, аның җилгә-давылга каршы таяну көчене нygытырга хезмәт иткәндер. Боның берлә Риза хәзрәт безнең Идел-Урал дәүләтенең мөстәкыйль яшәве өчен кирәк булган иң зур гамәлләрдән берсе булган мәдәни истикълялле-

мезне ныгыткан вә безнең киләчәк мөстәкыйль дәүләтемезнең төп баганаларын вакыт-заманның какшатуыннан урыс улакның (чапкынының; баскынының) җимерү-ватуыннан саклар-лык хәлгә китерергә иҗтиһад иткәндер. Мәрхүм Риза хәзрәтнең хезмәте ялгыз безнең өчен, Идел буе төрке өчен генә түгелдер. Бөтен төрк илләренең сәламәтлеге, бөтен төрк кабиләләре уртак мәдәниятләренең мөхафәзәсе (сакланышы) өчен кирәкле булган бер хезмәтдер. Бу юлда мәрхүм Риза хәзрәт фикри төшенчәсе, эше берлә төркчә булган кеби, калдырган мирас ягыннан да уртак төрекчелекнең мәгънәвиятене яратучы сакчысыдыр.

Идел елгасы безнең төрек илләре берлә рус илене җәгърафый бүлүче бер чик кенә түгелдер. Идел елгасы төрек мәдәнияте берлә рус мәдәниятен бер-берсендән аера торган мәгънәви бер чикдер. Идел буе төреге үз илен — Идел-Уралны гына рус һөҗүмендән саклаучы бер төрк-татар гаскәре генә түгелдер. Ул уртак төрек мәдәниятен рус мәдәниятенең һөҗүмендән саклаучы төрек мәдәниятенең сакчысыдыр. Казан, Әстерхан ханлары мөстәкыйль чакда бөтен төрк илләре Төркестан, Кырым, Кафкас, Сибирия, Госманлы императорлыгы русларның һөҗүмендән генә түгел, үзләренең милли мәдәниятләре дә тулы мәгънәсендә мөхафәзә астында (саклауда) булгандыр. Руслар төрекләрнең чикләре Идел елгасыны кичеп чыкканның соңында гына Сибирия, Кырым, Кафкас, Төркестан, Төркия мәмләкәтләренә һөҗүмгә күчкәнләр. Бондан соң гына бөтен төрк илләрен генә түгел, уртак төрк мәдәниятен дә хәтарәле вазгыятькә (куркыныч хәлгә) сукканлардыр. Бөтен төрк илләренең сәяси истикъляльләре (бәйсезлекләре), төрк мәдәниятенең үзенең үзлегене тулы көенчә саклый белүе кәнәдә (чынлыкта) Идел буе төркенең сәяси истикъялене алуына, уртак төрк мәдәниятен Идел буе төркенең кылычы берлә саклавына баглыдыр. Шуның өчен Риза хәзрәтнең Идел буе төркенең мәдәниятен ныгытырга чалышуы хәтарәле урындагы бер кальганы (крепостьне, каланы) ныгытырга тырышуы кеби бер эшдер. Аның калдырган мәгънәви азыклары киләчәк гаскәремезнең мәгънәви ачлык вә сусавыны кандырыр (басар) өчен ясаган хәзерлекләредер. Дошманга каршы торганда мәкавәмәт итәр (каршы торыр) өчен биргән кораллырыдыр. Менә шул ноктадан чыгып, мәрхүм мөфтиемез Риза хәзрәт гомерендә бер мәртәбә дә дошманга каршы утлы корал кулланмаган булса да, руслар тарафындан сугыш сафы башында шәһид ителгән мәрхүм мөфти Чәләби Җиһан кеби үк төрек милләтенең мөхтәрәм мөҗаһидыдыр (көрәшчеседер). Безнең милли тормышымызны коруда бик зур хезмәт иткән Исмәгыйль бәк Гаспралы, Йосыф Акчура, Каюм Насыйри кеби безнең милли йортымыз-

ны корышучы, төзешүче милли мөһәндисемездер (инженерыбыздыр). Мәрхүм Чәләби Җиһанның Истанбул дарелфөнүн таләбәсе (студенты) булып фәсле булуы, Йосыф Акчураның Париж дарелфөнүн шәкерде булып, башында шапкасы булуы, Габделкаюм Насыйриның ил җимеше булып, башында камчат бүрек булуы, авыл мәдрәсәсендә генә тәхсыйль (уку) күргән Риза хәзрәтнең башында чалма булуы боларны бер-берсендән аера торган нәрсәләр түгелдер. Боларның эчләре, рухлары, омтылышларының берлеге, кыйблаларының бер тарафдалыгы боларны бер милли көч иткәндер, бер милли көч итеп безгә танытканлыр. Киләчәк тарихымызга да болар бер милли юлның юлчылары, бер милли кыйбланың (кабиләнең) имамлары булып, бер йорт төзүнең мөһәндисләре булып, безнең милли тарихымызга керәчәкләрдер вә безнең яшьлегемезгә (яшьләребезгә) үрнәк булып китәчәкләрдер. Боларның барысы да безнең киләчәгемездә милли газизләремез булып әйләнәчәкләрдер.

Мөфти Риза хәзрәтнең аермасы шундадыр ки, ул бу дәрәҗәгә, монтазам (рәтле; тәртипле) мәктәп күрә алмаенча, үз тырышлыгы, үз казынуы берлә генә ирешкәндер. Үз-үзен идарә итә белүе берлә генә дөньяның җилле-давыллы җирләрендә, кызыл руслыкның иксез-чиксез вәхши золым-җәбере алдында башын югарыда тота алып, соңгы сулышына кадәр үзенең иман иткән милли сафы башында калгандыр. Бу мәдәни җәсарәте (батырлыгы, кыюлыгы) берлә чит халыкларны хәйрәткә (гаҗәпкә) калдырып, безнең Идел-Урал төркенең мәгънәви кыйммәтен тагын күтәргәндер. Төрек балаларында төрклек горурымызны охшап, милли вазыйфасыны тулы көенчә үтәгән милли каһарманымыз булып Аллаһның рәхмәтенә кавышкандыр.

## Бер ана йортының балалары

Инде менә ничә гасыр буе тарих татар халкына карата рәхимсезлек күрсәтә: аның теле, дине, гореф-гадәте кысыла, ул үз җирендә килмешәккә әйләндерелә. Түзеп тормаслык шартлар халкыбызның күп кенә улларын һәм кызларын дүңгәләк кебек каңгырып йөрергә, Идел-Урал буйларын ташларга мәҗбүр итә. Ирекле көннән беркем дә туган йортын, дус-ишләрен, таныш-белешләрен калдырып, чит җирләргә, үзгә мәмләкәтләргә китеп бармый. Аны бу адымга аянычлы хәлләр, гадәттән тыш шартлар мәҗбүр итә.

Октябрьдән соң халкыбызның бер өлеше Ерак Шәрык илләрендә торып кала. Мәсәлән, 20—40 нчы елларда Маньчжуриянең Харбин, Хайлар калаларында меңәрләгән татар кеше-

сенең яшәве мәгълүм. Шулай ук Корея, Япония мәмләкәтләрендә дә күп кенә милләттәшләребез гомер кичерә.

Ерак Шәрыктагы татарлар мәктәп-мәчетләр ачалар, төрле мәдәни җәмгыятьләр төзиләр, концерт-спектакльләр оештыралар. 1922–1924 елларда, мәсәлән, Харбинда ислам диненең кабул ителүенә 1000 ел тулу уңае белән бик гүзәл бер мәчет бинасы төзелә.

Кытай, Япония якларындагы милләттәшләребез үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү йөзеннән татар телендә, гарәп графикасында күпсанлы китаплар, төрле гәзит-мәҗмугалар да бастыралар. Биредә «Ерак Шәрык» (Харбин), «Яңа япун мөхбире» (Токио), «Шәрык авазы» (Тянцзинь), «Шәкердләр таңы» (Мукден) журналларының, «Чаткы», «Бәйрәм нуры» гәзитләренең чыгуы билгеле. Болар арасында «Милли байрак» гәзите игътибарга лаек. Ул 1935–1945 елларда Мукденда чыга. Барлыгы 440 сан. Бу атналык гәзитне чыгаруда Хөсәен Габдүш, Әхмәтшаһ Гыйззәтулла, Хәбибрахман Болгари, Ибраһим вә Рокыя Дәүләткилде, Мансур Арсланбәк һ.б. актив катнаша. «Милли байрак»ны оештыручы, аның рухи җитәкчесе, төп авторларыннан берсе Гаяз Исхакый була. Аның мәкаләләре милләтне саклау, халкыбызның яшәеше, киләчәге өчен көрәш идеясе белән сугарылган. «Милли байрак» Ерак Шәрыкта гына түгел, милләттәшләребез яшәгән башка мәмләкәтләрдә дә таралыш таба.

Бу атналык гәзит моннан 55 ел элек, ягъни 1935 елның 1 ноябрендә чыга башлый. Кызганыч, безгә ул сан белән танышу хәзергә мөмкин булмады. Әмма Г.Исхакый җитәкчелегендә Берлинда 1929–1939 елларда чыккан «Яңа милли юл» журналының 1935 ел, 12 нче санында (94) «Милли байрак»ның тәүге номерына җентекле күзәтү ясала (28–32 битләр), аерым материаллар күчереп тә басыла. Шулардан кайберләрен, теге яки бу күләмдә кыскартып, бүгенге укучыларга тәкъдим итәбез. Текстларның язылышы нигездә үзгәрешсез бирелә.

*1990*

* * *

Ерак Шәрыкка чыгып, бондагы дүрт мәмләкәткә таралып яшәргә мәҗбүр булган безнең мөһаҗирләремез Идел буе, Урал итәкләре бондан мең биш йөз элекдән бирле безнең бабаларымызның ана йорты булып килгәндер, безнең бабаларымыз шул озын тарихда бонда зур императорлыклар, ханлыклар корып, үзләренә бик күп халыкларны ияртеп яшәгәнләрдер. Бу мәмләкәтләрнең исемнәре төрле вакытта төрле исемдә йөрсә дә, мәмләкәтемездәге зур Идел һичбер вакыт исемене дә, агуыны

да үзгәртмәгәндер. Урал тавы да, төрле сәяси эшләргә карап, үзенең төсене, табигатене, байлыгыны алышдырмагандыр. Боларның икесе дә безнең бабайларның таулары, сулары булып калгандыр. Вә бүгендә дә болар вә боларның тирә-юньләре безнең халкымызның җиредер. Идел дә, Урал да безнекедер. Идел-Урал — ана туфрагымыздыр. Безнең киң илемездә, безнең бабайларга башка төрле фин халыклары да бергә-бергә яшәп килсәләр дә, бу илнең күпчелеге, илнең хуҗасы һәрвакыт безнең бабайлар — төрк-татарлар булып килгәннәр. Бу көндә Идел-Уралның зур елгалары, киң кырлары, бай урманнары, зур тауларының яшәүчесенең күпчелеге безнең төрек-татар халкыдыр. Уналтынчы гасырдан башлап безнең илемезгә рус мөһаҗирләре көчләп утыртылган булса да, илемезнең мәдәнияте, тормыш ысулы һаман үзенең иске Шәрык төсене югалтмагандыр вә төрек теле, төрек гадәте соңгы елларга кадәр хаким бер мәдәният булып килгәндер. Тамырлары Монголия сәхраларына, Төркестан, Сибирия йәйләүләренә, Кафкас, Кырым, Кечек Асиянең бай туфракларына кадәр сузылган бу меңәр еллык төрк мәдәнияте великорусның берничә гасыр бер юлдан җимерү, вату һөҗүмендән үзенә алып калгандыр вә бүгенге көндә дә илемезгә хаким булган кызыл руслар, коммунистларның милләтемезне җимерү һөҗүмләрендә үзлегене, төрк-татарлыгыны саклап килгәндер вә киләчәк җил-давылда да үзен сакларлык куәткә маликдыр. Үзенең шәрыклы төрк-татар мәдәниятене, телене, әдәбиятыны, гореф-гадәтене тагын озын гасырлар саклап киләчәкдер...

Ерак Шәрыкның дүрт мәмләкәтенә сибелгән, киң илемезнең төрле почмакларына озакларга ыргытылган без, мөһаҗирләр, менә шул озын тарихлы, бик тирән мәдәниятле олуг төрк-татар милләтенең балаларымыз. Төп йортымыздан, илемез, суымыздан дошман большевик кувәте берлә чит илгә чыгарылып ташланган шул җанлы олуг бер милли тәннең җанлы бер кисәгемез, җанлы бер әгъзасымыз. Большевик дулкыныннан төрле илләргә сибелгән илдәшләремез кебек без дә үземезнең йортымызга, илемезгә җандан, тәндән баглымыз, үземезнең мәдәниятемезгә, динемезгә тешемез, тырнагымыз берлә ябышканмыз.

Шул авыр хәлдә дә үземезнең мең еллык мәдәниятемезне, динемезне, дөньяга карашымызны, әхлакымызны сакларга тырышамыз, шул бабалардан бабага килгән милли мирасымызны саклап, киләчәк буынымызга, балаларымызга сау-сәламәт табшырырга тырышамыз вә тырышачакмыз.

Үзен-үзе саклау һәрбер адәм, кешенең хакы булган кебек, үзенең милләтене, милли мәдәниятене саклау да һәрбер милләтнең мөкатдәс вазыйфасыдыр...

*(Гаяз Исхакый. «Максадымыз»)*

* * *

...Кара рус милли бәйрәмемезне бетерергә, динемезне юк итәргә теше-тырнагы берлә өч йөз ел буена тырышып килде. Ләкин нәтиҗәдә милләт бетмәде, һаман шул ук төрк булып калды. Асылып-киселгән, йортсыз-йирсез калдырылган халык җәрәхәтләнгән тәнендә әллә кайдан көч, тәхкыйрь ителгән күңелендә иман табты. Бу көч һаман шул гаилә эчендә сакланды. Бу ныклык халкымызның Зөләйхаларында, әкият сөйләүче карчыкларында, сабак абыстайларында табылды. Болар һичбер золымга карамый, кара көчкә сугыш ачды. Бу бичара башындагы аналарның: «Җылама, әнә урыс килә», — дип, җылый торган баласын куркытуда милли барлыкның нигезен саклауның беренче ташы салынды. Милләтемезнең бүгенгә кадәр бертуктаусыз һөҗүм иткәндә дә югалмый килүенең сәбәбе аналарымызның вазыйфаларын үтәүләрендә булды... Чит тормышның безгә ят булган агымлары яшь буынымызны әле бер якка, әле икенче якка сөйри башлады. Шуны күреп, милләтемезнең киләчәген кочакларында тоткан аналарымызны тарих «мин монда» дип вазыйфа башына чакыра, илдән читтә дә илсөяр кызлар, җегетләр йитешдерүен көтә.

*(Рокыя Мөхәммәди. «Аналарымызның милли бурычы»)*

* * *

Мөһаҗирлекдә яшәвемез никадәрле аяныч булса да, милләтемезнең киләчәгенә ышануымыз аркасында күпчелек арасында югалмый, һаман да үземезнең барлыгымызны саклап яшәтергә бөтен көчен сарыф иткән мөхтәрәм юлбашчымыз Гаяз әфәнде Исхакый җәнаплары Ерак Шәрыкка килеп чыгуы берлә теләкләремез җанланды.

*(Әхмәдшаһ Гыйззәтулла. «Безнең теләгемез»)*

## Гаяз Исхакыйның көрәштәш дусты

1992 елның 19 июне. Казан шәһәренең мәһабәт Опера һәм балет театры бинасы. Зал халык белән шыгрым тулы. Бөтендөнья татар конгрессы бара. Менә доклад өчен сүз Татарстан Җөмһүрияте Президентына бирелә. «Татарлар, — ди ул, — иң кыен елларда да хакыйкатьнең тантанасына ышандылар... Дәүләтчелекне торгызу иҗтимагый аңда беркайчан да үлмәде. Ул әкиятләрдә, риваятьләрдә, җырларда яшәде, аның хакында шагыйрьләр, сәясәтчеләр сөйләде һәм язды. Монда мин Рәшит Ибраһимов, Муса Бигиев, Риза Фәхреддинов, Фатих Кәрими һәм Садрый Максуди кебек мәшһүр исемнәрне искә төшерәм. Бу шәхесләр дәүләтчелекне торгызуның бердәнбер дөрес юлын

күрсәттеләр дип әйтеп булмый, билгеле. Ләкин алар азатлык көрәшенә шактый зур өлеш керттеләр. Бу мәсьәләне хәл итүдә Гаяз Исхакый, Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Фуад Туктаров, Мирсәет Солтангалиев кебек социал-демократлар да үз юлларын тәкъдим иттеләр». Дөньяның төрле төбәкләреннән килгән күпсанлы милләттәшләребез, кунаклар Президентның бу сүзләрен аеруча алкышлап кабул иттеләр. Татарстан җитәкчесенең дәрәҗәле корылтай мөнбәреннән сөйләгән нотыгы турыдан-туры Татарстан радиосы һәм телевидениесе аша да яңгырады.

Бу тарихи күренешнең шаһиты буларак, мин уйга калдым: бу дөнья дигәнне һич аңлап бетерерлек түгел, әле бер төрле була, әле — икенче төрле. Әле бит моннан берничә ел элек кенә Президент санаган исемнәрнең күпчелеген олуг корылтайларда түгел, юньләп кеше укымый торган мәкалә-хезмәтләрдә дә телгә алырга ярамый иде. Алган вакытта да бары тискәре планда гына. Инде менә хәзер заманалар янә үзгәреп бара: элеккеге кумирлар урынына яңалары килә, онытылган исемнәр кайтарыла яисә таныш атамалар яңача бәяләнә. Фуад Туктар да (Туктаров та) — әнә шундый шәхесләрнең берсе. Ул XX гасырның тәүге ике дистә елында татар иҗтимагый, сәяси, мәдәни тормышының үзәгендә кайный, көчле характеры, тирән белеме, үткен каләме, милләтпәрвәрлеге белән зур абруй-авторитет казана. Әмма Мәскәү хакимияте белән килешмәү, иманына тугрылык, язмыш аны эмиграциягә этәрә: Самара, Уфа, Екатеринбург, Кызылъяр (Петропавловск), Себер аркылы үтеп, Харбинга килеп җитә. Г.Исхакый белән берлектә су юлы белән Көнбатыш Европага юнәлә. Ниһаять, 1920 елның апрель аенда Парижга килеп җитә. Биредә Милләт мәҗлесенең солых һәйәте әгъзасы сыйфатында (бу комиссиягә шулай ук С.Максуди, Г.Исхакый да керә) ике еллап Версаль сөйләшүләрендә катнаша. Аннан Берлинда яши. Көнбатыш Европада яшәү чорында ул юриспруденция, язу һәм башка эшләр белән шөгыльләнә, көченнән килгәнчә, милләт язмышы, аның киләчәге турында кайгырта. Ф.Туктарның, мәсәлән, Берлинда оештырылган «Туран җәмгыяте», «Яшьләр берлеге» оешмаларында актив катнашуы, яшьләр өчен лекция-докладлар сөйләве, милли тәрбия чаралары үткәрүе мәгълүм. Бу тынгысыз зат Парижда һәм Берлинда яшәү дәверендә француз һәм алман телләрен өйрәнә, Көнбатыш Европаның рухи казанышлары белән ныклап кызыксына.

Матди кыенлыклар, төрле сәбәпләр (шул исәптән «Туран җәмгыяте»ндә эшләр катлаулану) аркасында Ф.Туктар, Европада биш еллап яшәгәч, 1925 елда Төркиягә күчеп китә. Биредә аны илнең мәгариф вәкилләре һәм милләттәшләре дә чакырган була. Ф.Туктар, бераз Истанбулда яшәгәч, Анкарага килеп, «Хөкүмәт көтепханәсе»ндә мөдир сыйфатында эшли

башлый. Вазыйфасын күңел биреп башкара. Аның эш урыны милләттәшләренең үзенә күрә бер җыелу мәркәзе рәвешен ала.

1938 елның 12 октябрендә Гаяз Исхакыйга язган бер хатында ул киләчәккә өметен белдерә, «Кырык еллык милли мөҗадәлә» (бәхәс, тартыш. — *Х.М.*) исемле истәлекләр китабы язачагын, дустының 1922 елда иҗат ителеп, 1938 елда Берлинда басылган «Өйгә таба» әсәрен төрекчәгә тәрҗемә итәргә нияте барлыгын искәртә. Әмма 58 нче яшендә, ягъни 1938 елның 19 декабрендә Анкара каласында ул кинәт үлеп китә.

* * *

Гаяз Исхакыйның укучыларга тәкъдим ителә торган бу мәкаләсе Фуад Туктарның үлеме уңае белән 1939 елның башларында язылган һәм февраль — март айларында дөнья күргән. Анда мәрхүмнең Октябрь инкыйлабына кадәрге тормышы һәм эшчәнлеге шактый тулы яктыртыла.

Архив материаллары күрсәтүенчә, Фуад Туктар «1880 елның 5 феврале»ндә туа (Мирас, 1992. — 12 нче сан. — 74 б.).

Мәкаләдән күренгәнчә, Фуад Туктарның балачагы һәм яшьлеге Мораса авылы һәм Чистай каласы белән бәйләнешле. Ул татар руханилары, зыялылары мохитендә тәрбияләнә. Традицион Шәрык белемен ала. 1901–1904 елларда Казандагы «Учительская школа»да укый. Аны уңышлы тәмамлап, иҗтимагый, сәяси, журналистик эшенә керешә. Аеруча Икенче Дәүләт Думасы эшендә актив катнаша, «Мөселман фракциясе» төзи. Хакимият оешмалары тарафыннан төрлечә эзәрлекләнә, кулга да алына. Реакция елларында бераз вакыт актив сәясәттән читләшеп тә торырга мәҗбүр була. 1910 елларда, гимназиягә имтихан тапшырып, Казан университетының юридик факультетына укырга керә. Казан, Петербург һәм Мәскәү калаларындагы татар һәм рус матбугатында актив язышуын, эшләвен дәвам итә. «Мөселман депутатлары» исемле китап та нәшер кыла. Матди якны күздә тотып, университетта укучы рус студентларына имтиханнар бирүдә дә булыша. Университетны тәмамлагач, адвокат булып эшли. Инкыйлаб елларында инде ул Казанда «Мөселман комитеты» («Казан мөселман шурасы»), «Мөселман фракциясе» рәисе, «Корылтай» гәзитенең баш мөхәррире. «Учредительное собрание»га депутат итеп сайлана; Мәскәү, Казан корылтайларын актив оештыручы; Милләт мәҗлесенең тышкы эшләр комиссиясе әгъзасы һ.б.

Мәгълүм булганча, Гаяз Исхакый — татар әдәбиятының, иҗтимагый фикеренең, милли-азатлык хәрәкәтенең мәшһүр вәкилләренең берсе, инкыйлабтан соң мөһаҗир татарларның

юлбашчысы. Шуңа күрә аның уй-фикерләре, мөнәсәбәте, бәясе, игътибары үзе зур нәрсә. Бу мәкаләне дә нәкъ әнә шул ноктадан карау шарт. Аның өстәвенә Гаяз Исхакый һәм Фуад Туктар бер-берсен бик яхшы белгәннәр. Аларның якташлар булуы, «Учительская школа»да бергә укулары, «Тәрәкъкый», «Хөррият», «Таң йолдызы», «Тавыш», «Дума», «Ил», «Сүз», «Маяк» (ул гражданнар сугышы елларында Кызылъяр шәһәрендә нәшер кылына) һәм башка гәзит-мәҗмугаларны бергәләп чыгарулары, иҗтимагый-сәяси көрәштә янәшә барулары бу ике әһелнең үзара нинди мөнәсәбәттә торуларын ачык сөйли.

Гаяз Исхакый мәкаләсе кеше вафат булганнан соң сөйләнә, языла торган мактау рухындагы мәрсия әсәре түгел. Аның өчен аналитик фикерләү, тәнкыйди караш, үткәндәге вакыйга-хәлләргә объектив мөнәсәбәт, шәхес язмышын тарихи чынбарлык белән тыгыз мөнәсәбәттә карау хас. «Учительская школа»дагы уку елларын искә алып, мәкалә авторы болай ди: *«Ул вакыттагы безнең карашда, халкымызның бу кадәр артка калуына сәбәп: мөфтинең үз вазыйфасын үти алмавы, мәктәп-мәдрәсәләрнең исляхына бил баглап көрәшмәве булганга, без мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов урыныннан төшерелсә, әллә никадәр дөнья үзгәрәчәк дип ышана идек».* Тарих тәҗрибәсе туплаган, 30 нчы еллардагы Гаяз Исхакый өчен, әлбәттә, ул вакыттагы мондый ышануның гаять берьяклы икәнлеге көн кебек ачык.

Гаяз Исхакый, Фуад Туктар эшчәнлегенә нисбәтән татар халкының тарихы, иҗтимагый-сәяси хәрәкәте, азатлык өчен көрәше хакында күптөрле мәгълүматлар бирә. Гадәттә, татар вакытлы матбугат тарихын 1905 елгы инкыйлабтан гына башлыйлар. Чынлыкта исә ул «Тәрҗеман»нан (1883), «Тәрәкъкый» (1901), «Хөррият» (1902) гәзитләреннән үк килә. Мәкаләдә Чистай татар мәдәни үзәге, «Учительская школа»да шәкертләр хәрәкәте, татар гәзит-журналларының тарихы, цензура һәм татар матбугаты арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр, Бодуэн де Куртенэ, В.Д.Смирнов һәм башкалар хакында да мөһим күзәтүләр, гыйбрәтле белешмәләр бар.

Истәлек мәкаләдә Г.Исхакый Фуад Туктарның 1913 елда Архангел сөргененә язган хатыннан бер өзек китерә: «... *яшьлегемез (яшьләребез. — Х.М.) башсыз калды. Без бонда Казанда бер-беремез берлә кычкырышып, талашып, берлегемезне югалтдык... Кайт да хәрәкәтнең башына кич! Эш күп, вазыйфа зур».* Бу юллар Тукайның Гаяз Исхакыйга мөрәҗәгать итеп язылган «Мөхәрриргә» шигырен искә төшерә:

...Кайт әле монда, Ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!..
Җанлырак тормыш та бетте, җанлырак бер эт тә юк,

Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.
Алты ел торды чупансыз, аерылышты яшь көтү;
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя...*

Һәм Фуад Туктар хаты, һәм Тукай шигыре 1913 елның башларында язылган. Димәк, алар арасындагы аваздашлык, охшашлык шул чор Казан тормышындагы вазгыять, гомуми рухи халәт белән билгеләнгән.

Мәкалә Фуад Туктарның гына түгел, ә Гаяз Исхакыйның үз шәхесен, эшчәнлеген аңлауда һәм өйрәнүдә дә мөһим чыганак. Анда без әдипнең фикерләү рәвеше, эволюциясе, укуы, журналистлык эшчәнлеге хакында да мөһим белешмәләр таба алабыз. Мәсәлән, «Учительская школа»ны тәмамлап, яшь әдип Оренбургка «Хөсәения» мәдрәсәсенә эшкә киткән. Безгә киләчәктә Гаяз Исхакыйның тормыш һәм иҗат хроникасын язу зарури.

Мәкаләдә бүгенге көнебез өчен дә гыйбрәтле, аваздаш яклар күп. Шуларның иң мөһимнәре: милли-азатлык хәрәкәтендә таркаулык; «милли берлекне бозучы көчләрнең» «читтән» яңаданяңа ярдәмнәр алып торуы; сайлаулар вакытында оешканлык җитмәү һ.б. 1917 елда Гаяз Исхакый Фуад Туктарны Мәскәүгә эшкә чакыра. Шунда Фуад әфәнде: «Казанның эченә кереп эшләргә кирәк... Казан тыштан ялтыраса да, эчтән калтырый», — дип баш тарта. Аның бу сүзләре хәзерге көн өчен дә актуаль.

Гаяз Исхакыйның Фуад Туктар хакындагы мәкаләсе, чыганак буларак, чит илләрдә инде күптәннән файдаланыла (Т.Дәүләтшин, Гайшә Рорлих, Надир Дәүләт һ.б.).

Кызганыч ки, безнең тарихчыларыбыз, иҗтимагый фән ияләре әле һаман да татар милли-азатлык хәрәкәтен һәм, гомумән, татар тарихын өйрәнүдә сүлпәнлек күрсәтәләр, электән билгеле һәм яңа табылган материалларны тиешенчә анализлау җитми; инерция нигезендә һаман да бер үк балык башын чәйнәү, билгеле «хакыйкатьләрне» кабатлау, шәрехләү өстенлек итә. Минем фикеремчә, безгә Йосыф Акчура, Садрый Максуди, Гаяз Исхакый, Габдулла Баттал, Фуад Туктар кебек әһелләрнең тормышларын һәм эшчәнлекләрен хәзердән үк ныклап, махсус өйрәнергә кирәк. Аларның мәкалә-хезмәтләрен, әсәрләрен, китапларын барлау, туплап бастыру зарури. Истәлекләр, өстәмә материаллар җыйнау да әһәмиятле. Бу әһелләрнең туган, яшәгән җирләрендә музейлар ачу, истәлек такталары кую да тәрбияви яктан файдалы булачак. Күптән түгел Казан шәһәр Советы президиумында М.Солтангалиев исемендәге фонд булдыру турында сүз чыккач, бер төркем җаваплы кешеләр: «Кем соң ул Солтангалиев, ул нәрсә белән шөгыльләнгән?» —

* Тукай Г. Әсәрләр: Дүрт томда. 2 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. — 288 б.

дип, махсус белешмә таләп итәләр (Казанские ведомости, 1992. — 4 июля). Мондый хәбәрдарсызлыкта депутатлар гына түгел, без — галимнәр дә — өлешчә гаепле. Димәк, без андый тарихи затларны тиешенчә өйрәнеп, тиешенчә пропагандаламыйбыз. Күрәсең, моны бездән заман, халык көтә.

Әйткәнебезчә, Гаяз Исхакыйның Фуад Туктар хакындагы мәкаләсе «Яңа милли юл» журналының 1939 ел, февраль санында [№2 (129)] басылган. Язма ахырында «бетмәде» дип куелган. Кызганыч ки, кулыбызда журналның алдагы саннары юк. Журнал исә әле яңадан 7 сан чыга. [Соңгысы — 8–9 (136), сентябрь, 1939 ел.] Күрәсең, мәкаләнең алдагы өлешендә Фуад Туктарның эмиграция алды көннәре, читтәге тормышы тасвирланадыр. Мөмкинлек булса, бу хакта, Аллаһ боерса, өстәмә рәвештә хәбәр итәчәкбез...

*1992*

* * *

Шөкер Ходайга, Г.Исхакыйның Фуад Туктар хакындагы мәкаләсенең дәвамы басылган «Яңа милли юл» журналының 1939 елгы 3нче саны, (дөресрәге — күчермәсе) бераз соңгарып булса да, кулыбызга керде*. Биредәге текстны да «солых һәйәте әгъзасы Фуад бәк Туктар» мәкаләсенең дәвамы рәвешендә бүгенге укучыларга тәкъдим итәбез. Г.Исхакый язмасының икенче өлеше дә факт-мәгълүматларга шактый бай.

Мәкаләдән без илдәге 1918–1919 ел сәяси вакыйгаларын да, «Милли идарә»нең соңгы дәвер эшчәнлеген дә, аерым татар зыялыларының эмиграциягә ничек, ни рәвешле китүләрен дә, мөһаҗәрәттәге татар яшәешен дә билгеле бер дәрәҗәдә күзаллыйбыз.

Г.Исхакый үз язмасының бу өлешендә дә төп игътибарын Ф.Туктарга, аның тормышына, эшчәнлегенә юнәлтә. Мәкаләдән күренгәнчә, бу зат үзенә хас үҗәтлеген, активлыгын, тырышлыгын һәм иң мөһиме — милләтпәрвәрлеген Көнбатыш Европада һәм Төркиядә яшәү елларында да саклап кала. Татарлыкка тугрылык Ф.Туктарга шактый гына кыенлыклар да китерә. Төркиягә күчеп килгән милләттәшләренең төп өлеше «мин — Шималь төреге», «мин — Казан төреге» дип йөргәндә, бу затның «мин — татар, Идел буе татары» дип әйтүе үзе үк күп нәрсә хакында сөйли. Г.Исхакый мөһаҗир Фуад Тук-

---

* Мин Хельсинкидагы «Ислам җәмгыяте»нең чакыруы белән 2000 елның җәендә кызым Гөлназ белән янә Финляндиядә булган идем. Шул сәфәр вакытында, башка материаллар белән бергә, «Яңа милли юл»ның бу санына да тап булдым. (Моның өчен Хельсинкида яшәүче милләттәшебез Кадрия туташ Низамеддингә рәхмәтлемен.)

тарның чит илләрдәге тормышын, халәтен төньяктан көньякка күчереп утыртылган, «тамыр җибәрергә, үсеп китәргә мохит таба алмаган» ят бер агач белән чагыштыра. «Киләчәк йир юклыгы, — ди мәкалә авторы, — аны тагы шул мохиткә баш иярргә, тәкъдиргә буйсынырга мәҗбүр итә...» Бу аянычлы халәттән чыгу өчен, Фуад Туктар өйләнеп, гаилә корып та карый. Әмма анда да аны бәхетсезлек, күңел газаплары көтә.

Мәгълүм ки, Фуад Туктар — мәдрәсәдә укыган, мәшһүр «Учительская школа»ны, атаклы Казан университетын тәмамлаган, барничә телне белгән, бай сәяси һәм публицистик тәҗрибәгә ия булган талантлы зат. Әгәр дә мөмкинлек булса, ул үз илендә җаваплы югары урыннарда, министр дәрәҗәләрендә эшләр иде. Әмма бәхет аңа аркасы белән борылган. Вактөяк эшләр, дөнья мәшәкатьләре, китапханәчелек шөгыле бу олуг инсанны изә, чиргә сабыштыра. Аның 1880 елда Чирмешән, Чистай якларыннан башланган гомер юлы, Казан, Мәскәү, Питер, Самара, Уфа, Себер, Харбин, Һинд океаны, Париж, Берлин, Истанбуллар аша үтеп, Анкарада өзелеп кала.

Г.Исхакый — дуслыкка бик талымлы зат. Фикердәш, мәсләктәш булу, тугрылык — аның өчен иң мөһиме. Ф.Туктарны бөек әдип чын мәгънәсендә үзенең көрәштәш дусты дип саный. Алар, шул исәптән Гомәр Тәңреколый да, 40 елга якын үзара аралашып, милләт мәнфәгатьләре өчен көрәшеп яшәгәннәр. «Яңа милли юл»ның 1939 елгы 4 нче санында Г.Исхакый, Фуад Туктар һәм Гомәр Тәңреколыйның 1924 елда Берлинда төшкән фотолары бар. Бер елдан соң Анкарада төшкән фоторәсемдә дә алар бергә. (Бу сурәт «Мәгърифәт» гәзитендә дә дөнья күрде. — 7.11.1998.) Яшәү урыннары үзгәреп, төрлесе төрле җирдә гомер кичергән вакытта да, алар бер-берсенең хәлен белеп тора. Гомәр бәк Тәңреколыйның югалу хәбәрен ишеткәч, мәсәлән, Г.Исхакый бик борчыла, Төркиядәге танышларына бер-бер артлы хатлар яза. Һәм бераздан бу затның 1938 елның 29 августында Истанбул тирәсендәге бер бистәдә вафат булуы ачыклана. Дүрт ай эчендә Г.Исхакый үзенең иң якын дусларын — Фуад белән Гомәрне югалта. Бу, әлбәттә, бөек әдип өчен олы кайгы һәм көчле тетрәнү. Әмма Г.Исхакый шушындый авыр вакытта да, үзендә көч табып, Гомәр Тәңреколый һәм Фуад Туктар хакында гаять тирән эчтәлекле мәкаләләр язып бастыра (Яңа милли юл, 1939. — 2–4 саннар), аларның тормыш юлларын, шәхси сыйфатларын, кылган гамәлләрен, тарихи рольләрен чордашларына, килер буыннарга җиткереп калдыра, мәрсияви һәйкәлләрен ясый. Бу — чын дуслыкның, инсанилыкның, әхлаклылыкның күркәм үрнәге.

Г.Исхакый мәкаләсенең ахыргы абзацларына гына игътибар итик. Аларда никадәр шигърият, никадәр тирән мәгънә,

никадәр иман-ышаныч! Бөек әдип фикеренчә, *«Фуад берлә бергә безнең Идел буеның соңгы утыз ел эчендә һәрвакыт милли тормышта беренче сафта булган бер милли мөҗәһиде вафат итте»*. Ул халык, милләт өчен көрәштә «һичбер көч алдында баш имәгән, дөньяның җилендә, давылында, буранында имән агачы кеби баш та селкетмәгән бер хаклык каһарманы» иде. Мәкалә авторы үз язмасын мәрхүм эшчәнлегенең тарихи әһәмиятен, килер буыннарга үрнәк булачагын искәртү белән төгәлли. *«Фуад,* — ди ул — *милләтне сөюдә, үзен-үзе тәрбия итә белүдә, халкы өчен үзен корбан итә белүдә үрнәк булып калачак. Бик күп яшь фуадчыклар аның тәрҗемәи хәленнән үзенең рухына куәт алып, аның шәкерде булачактыр. Хаклык югалмаган кеби, хаклык корбаны да онытылмыйдыр»*. Бу юлларны Фуад Туктарга гына түгел, Г.Исхакыйның үзенә карата да әйтергә мөмкин.

*2003*

## Солых һәйәте әгъзасы Фуад бәк Туктар вафат*

*Гаяз Исхакый*

1938 ел, 19 декабрьдә вафат иткән Фуад—Казан вилаяте, Чистай өязендә Мораса авылының** Фәсах Хаҗи исемендәге мәшһүр бер галимнең угылыдыр. Фәсах Хаҗи үзе Төркиядә, Гарәбстанда булынган (булган), дөнья күргән, аз-маз русча да белеп, тирә-юньдәге рус боярлары берлә дә танышлык тотып килгән, вакытының тәрәкъкыйпәрвәр (алга баруны яклавы, прогресс тарафдары) галимнәрендәндер. Фуадның анасы Чистай шәһәренең мәшһүр тәрәкъкыйпәрвәр сәүдәгәрләре Зариф, Гариф Бәдамшаһларның туган туталары, Сираҗеддин Бәдамшаһның кызыдыр.

Фуадның балалыгы бердәнбер угылы Фуадка бик зур өмидләр баглаган, картаеп килгән Фәсах Хаҗиның Морасадагы зур көтебханәле өе берлә Чистайның милли тормыш улый (кайнап, мул булып) торган, бөтен тирә-юньдән килә торган тәрәкъкыйпәрвәр муллалар, сәүдәгәрләрнең туктап чәй эчмәенчә, «милләт кайгыртмаенча» китми торган Бәдамшаһларның шәһәр өйләре арасында үткәндер.

Шул кечкенә вакытында кечкенә Фуад әтисенең итәгенә утырып барып, күрше боярларда да рус мөхәррире Островскийның зур көтебханәсен дә күргән (Островскийның бер кардәше

---

* Яңа милли юл. — 1939. — № 2 (130). — 6–17 б.; № 3 (131). — 16–25 б.

** Хәзер бу авыл Чирмешән районына керә.

шул тирәдә алпавыт булып яши иде вә аңарда ни өчендер Островскийның көтебханәсе тупланган иде); андагы әллә ни-кадәр төрле зур-кечкенә русларның рәсемнәрен-портретларын да кызыксынып караган. Чистайда ул мәшһүр ишан Закир хәзрәтнең кулын да үбеп, «Аллаһы Тәгалә гыйльме нәфигъ (файдалы, игелекле) бирсен» дигән догалар берлә башын да сыйпаткан иде. Шул ук Чистай бабае Сирай карт берлә авылдан шәһәргә, шәһәрдән авылга барганда, икенде намазы казага (бурыч булып; үтәлмичә) калмасын дип, кырда кар берлә тәһарәт алып, кар өстенә басып, карга сәҗдә кылып, намаз да укыган. Сукыр карыйдан шул өйдә ул Мисыр мәкамен (көен, моңын) дә өйрәнгән иде. «Тәрҗеман» гәзите чыга башлагач та, аны чыгаручы мөселманлыкны бозарга теләүче миссионер икән диеп ышанып, шул «бозучы»ны дөнья йөзеннән юк итәр өчен фидиягә (корбанга, сәдакага) килгән актык атны сатып, Бакчасарайга сәяхәт итеп, Исмәгыйль бәкне күреп, озын (озак) сөйләшкәннең соңында Исмәгыйль бәкне пәйгамбәр дәрәҗәсендә зур күреп, гомерен ысулы җәдидче пропагандасына сарыфы иткән Гыйльман ахундның (Фатих Кәрими, Гариф Кәрими бәкләрнең аталары) утлы сүзләрен дә ишеткән; әллә нинди мөселман учительләрен дә күреп, алар берлә агаларының «милләт» өчен киңәшләшүләрен дә бик күп тыңлаган. Урыс падишаһының мөселманларны чукындырырга теләүләре хакындагы куркынычлы хәбәрләрне авыздан-авызга сөйләгәндә, ата-анасының, кардәш-кабиләсенең эч (чын) күңелдән янып, шул авырлыклардан чыгарга юл эзләүләрен дә бик күп күргән. Бала-чаганы коткарыр өчен «Хәлифә падишаһ йортына» китүче сәүдәгәрләрне, муллаларны, авыл халыкларын азан әйтеп, күз яшьләрен сөртә-сөртә озатуны да шунда ук күргән иде.

Атасы Фәсах Хаҗи Фуад бик яшь вакытда үлеп киткәч, шул ук бабасы аны Чистай мәдрәсәсенә дә йирләшдергән. Ул бонда үткен шәкерд булып китеп, бик тиз дамелла берлә (Нәҗиб дамелла Әмирхан — Фатих Әмирханның атасы берлә бертуган агасы) дә якынлашып алып, нәху (синтаксис), сарыф (морфология), мантыйк (логика), гакаид (иман), фикъһегә (мөселманнарның хокук белеме) башка, аның көтебханәсендән алып, ул бик күп төрекчә, гарәбчә яңы китаблар укый. Бәдамшаһларның йортларында «Тәрҗеман»ны бер дә укып кына калмаенча, Төркиядән монтазам (тәртипле, эзлекле) килә торган мәҗмугалар, Әхмәд Мидхәт әфәнденең* китабларын моталәга итә (укый, өйрәнә), аның «Мөдафәга»ларын (яклау чыгышларын) укып, Чистайда мәшһүр миссионер Яфим попда (бу Яфим поп Казандагы Яфим попка башкадыр) — исламиятнең ма-

* Мидхәт Ә. — 1844–1913 елларда яшәгән мәшһүр төрек язучысы.

нигъ тәрәкъкый (алга баруга каршы), исбат итәргә мөназарәгә (бәхәскә) дә бара. Шулар эчендә русча, дошман теле булса да, кирәкле бер корал икәнен үзе дә сизеп алып, русча мәктәбкә дә йөри; русчаны аңларлык, сөйләрлек өйрәнә.

Менә шулай итеп тәрәкъкыйпәрвәр шәкерд булып Фуад Туктар 1901 елда Чистай мәдрәсәсен хәтме көтеп итә (тәмамлый). Бер авылда мулла, мөгаллим булып, йә шул ук Чистай мәдрәсәсендә һәм хәлфә, һәм мөкаррәр (беркетелгән) булып яшәргә имкян (мөмкинлек) Фуад ул вакытның программы (программасы) буенча дәресен тәмам итеп, бер тәрәкъкыйпәрвәр (прогрессив) мулла, мөдәррис булып торырлык әзерләнеп җиткән булса да, аналары, мәхәлләләре Хаҗи хәзрәтнең михрабына үзен имам итәргә бик теләсәләр дә, Фуад бу белем берлә канәгать итә алмый. Боның берлә генә озакка китә алмассың дип, дөнья гыйлемләрен өйрәнергә, аның өчен русча мәктәпкә керергә дип төшенә.

Ул вакытта бердәнбер бондый (мондый) яше үткән егетләргә кереб укырга мөсагыйд (мөмкин) булган Казанның «Учительская школа»сына керә. Бонда керүенә, бәлки, минем дә бераз тәэсирем булгандыр. Мин ул елны школаның соңгы сыйныфына күчеп, җәйне уздырырга авылга кайтканда, Фуадны Чистай мәдрәсәсендә беренче мәртәбә очратып, укуга дәвам итү хакында димләвемне хәтерлим.

Казанда школадагы Фуад үзенең сыйныф иптәшләре Шакир Мөхәммәдъяр, Габдерахман Дәүләтшаһ, Габдерәүф Ниязбай, Габдерахман Фәхреддиннәрдән (Риза казыйның углы) мөрәккәб (җыелган, катышкан) мәдрәсә шәкердләре арасында бик тиз безнең Гомәр Тәңреколый, Хөсәен Ямаш, мин дә бераздан Гомәркол Әхмәдләр идарәсендәге милли түгәрәккә кердек. Шул түгәрәкнең монтазам (оешкан) җыелышларында, пәрәмәч чәйләрендә хазыйр булып (катнашып), безнең «шәкердлек» җәмгыятемезгә дә әгъза булып китәләр. Фуад болар арасында иң эшлекле, иң ышанычлысы була. Ләкин бик динле булып, школада һичбер намазны калдырмаенча, рузәне бер дә бозмаенча тотып килгәнгә, рус тәрбиясендәге ибдәшләре арасында үзенә «фанатик» (мөтәгассыйб) дип карап килсәләр дә, русча дәресләрендә бик тырышып укып, бик тиз хөрмәт казана вә сыйныфның беренче шәкердләре арасына күчә.

Ул вакытдагы безнең карашка, халкымызның бу кадәр артка калуына сәбәп: мөфтинең үз вазыйфасын үти алмавы, мәктәп-мәдрәсәләрнең исляхына (үзгәрешенә, реформасына) бил баглап керешмәве булганга, без мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов урыныннан төшерелсә, әллә никадәр дөнья үзгәрәчәк дип ышана идек. Шуның өчен аны төшерергә бик зур бер план корып, бөтен Идел буеның зурраграк мөселман шәһәрләренә:

«Мөфти Солтанов истигъфа итде (хезмәтеннән азат ителде), аның урынына мөфти сайлау милләтнең үз эшедер». Шуңарга күрә Казанга язылган мәктүбләрдә: Уфада; Уфага язылганнарына: Оренбургда; Оренбургка язылганнарына: Әстерханда шул хосусда махсус мәҗлес тупланып, фәлән кешеләрне намзәдә (кандидат) итеп күрсәтделәр, сез дә үз шәһәреңездә шундый мәҗлес эшләңез, дип, берничә йөз милләт кайгыртучыларга хатлар күндердек. Боларның һәммәсе Казанда язылса да, төрле шәһәргә төрле өслүбдә яздык вә төрле шәһәргә төрле нокталардан күндердек. Шул мәктүбләрнең асылын мин язсам да, күчереп язучысы, яздыртучысы Фуад, боларны күндерүдә дә Фуад бик зур хезмәт куйган иде.

Бу Фуадның беренче сәяси адымы булды. Ләкин бу адым бик уңышлы чыкды вә безнең яшьләрне актив сәясәтчелеккә алып керде. Бондан соң яшерен чыккан «Тәрәкъкый» гәзите вә төрле кагыйдәләрне дә бу «түгәрәк» йә басуда, йә таратуда, йә язуда эшләп килде вә Фуад болар арасында беренче иде.

Мин, школаны тәмам итеп, Оренбург «Хөсәения» мәктәбенә мөгаллим булып китдем. Школадагы («Учительская школа» күздә тотыла) «Шәкердлек җәмгыяте»нең башында Хөсәен Ямаш калса да, бәлфигыль (чынлыкта) боның идарәсе Фуад кулына күчде. Фуадның кардәшләре русча укуына ярдәм итмәгәнгә, ул бик фәкыйрь хосусый дәресләр берлә тамагын туйдырырга мәҗбүр иде. Алай да Фуад шул оешманы 1904 елга кадәр алып килешде.

Япун-рус сугышы башланып, эшләр тирәнәеп киткәч, без тагы ныграк эшкә керешдек. «Шәкердлек җәмгыяте»нә сәяси төс бирдек, аңарга программ төзедек, исемен «Хөррият» дип кушдык. Шул исемдә яшереп мәҗмуга чыгарырга тотындык. Фуад бу эшләрнең эчендә булып килде һәм дә иң мәсъүлиятле (җаваплы) эшләрне алып барды. Бу вакытда инде Фуад школаны укып бетергән булса да, мөгаллим фәлән булып, дөнья көтәр өчен бер эшкә кермәде. 1905 ел ихтиляльның (революциясенең; фетнәсенең) гарәфәсендә (иртәсендә, алдында) бик күп эшләде; әллә никадәр шәкердләр түгәрәге корды, яздысызды. 1905 елның Октябрь көнләрендә Казанны иске хөкүмәт идарәсендән алу гаскәренә, милиция төсендә катышып, башкалар берлә бергә кораллы көенчә тәүкыйф ителде (кулга алынды). Ләкин бу эшкә берничә йөз кеше катнашкан булганга, Фуад да бондан зарарсыз көенчә котылды.

1905 елның пароход өстендәге «Мәкәрҗә съезды»на инде без Фуад берлә бергә оешкан бер көч булып, аерым программ берлә катышамыз: «Мөселман иттифакы» җәмгыятене мәдәни бер җәмгыять төсен алып, аны бөтен милләт балаларын берләшдерә беләчәк сәяси программсыз итүне тәкъдим итә-

мез: «Кадет фиркасе»нең программын «Мөселман иттифакы» програмы итеп кабул итүгә каршы чыгамыз. Фуад бу көннәрдә минем янымда яшь көчнең беренче дәрәҗәдәге эшчесе булып бик зур тартыш алып бара.

Төрекчә (төркичә) беренче гәзит «Казан мөхбире»н мөсагадә (рөхсәт) алынгач та, Казанның бөтен зыялы көчләрен, шулар арасында мине дә мәсьүл мөхәррир Сәйдгәрәй Алкинның өенә дәгъват итәләр (чакыралар); бонда гәзитне кору, алып бару, яшәтү мөзакәрә иteлә (фикер алышына, сөйләшенә). Мәҗлеснең күпчелеге милли зыялы көчләремез булгангамы, «Казан мөхбире»нең Сәйдгәрәй Алкин гәзите төсендә түгел, Казанның милли зыялыларының уртак гәзите рәвешенә куелуын алга сөрәмез. Вә шул хакта Алкинны канәгатьләндерү вазыйфасын Йосыф бәк Акчурага йөклимез. Ләкин икенче мәҗлесдә Йосыф бәкнең гәзите инде Алкинның идарәсе астында калса да, үзенең сәркатиблек вазыйфасын алуы мәгълүм була, «Казан мөхбире» хосусый бер гәзит төсен ала.

Безнең гөруһ (төркем, партия) әүвәлге айларда гәзитнең эченә кермәенчә генә язучы эшенә катышсак та, гәзитнең мәсләге безгә мөнасиб булмаганы көндән-көн күрелеп, без үз гәзитемезне корырга башлыймыз. «Таң» исемендәге гәзиткә рөхсәт сорыймыз. Ул вакытлар гәзиткә рөхсәт бирү-бирмәү өч айлык мөддәт (вакыт) бирлә чикле булганга, безнең «Таң» гәзитемезгә ниндидер кечкенә генә бер сылтау берлә рөхсәт бирмәүне өч айдан соң гына безгә белдерәләр. Без «Таң йолдызы» гәзитенә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәмез вә 1906 елның апрель аенда гына рөхсәт аламыз. Мин инде бу вакытда качып йөрүчемен. Гәзитнең нашире итеп Фуад Туктарны күрсәтәмез. Һәм дә ул хакыйкатән (чынлыкта) «Таң йолдызы»ның рәсми нашире булып язу эшләрендә бик зур урынны тотып, гәзит ябылганча аны алып баруда зур роль уйный. Мин Казандан куылгач, гәзитнең билфигыль (чынлыкта) баш мөхәррирлеге вазыйфасын да үти. Бу араларда инде безнең үз тәшкилятемез (оешмабыз) «Таңчы» исемендә Идел-Уралның һәрбер шәһәрендә корылып җитеп, яшерен рәвештә дә пропаганда алынып барыла иде вә Фуад Туктар бу эшләрнең барысында мөһим рольләрне уйный иде. (Шушы ук биттә Фуад Туктарның кара белән каймаланган фоторәсеме бирелгән. Аның астында мондый юллар бар: «Идел-Урал Милләт мәҗлесенең солых һәйәте әгъзасы мәрхүм Фуад бәк Туктар». — *Х.М.*)

Икенче Думага сайлау көннәрендә без берничә йирдән үземезнең намзәдләремезне (кандидатураларыбызны) куярга карар бирдек. Болар эчендә Чистай өязендән берсе мин, икенчесе Фуад күрсәтелгән иде. Сайлау алдыннан мине хөкүмәт, тәүкыйф итеп (кулга алып), сайлау хакыннан мәхрүм итә тор-

ган 129 нчы маддә (статья) берлә гаепләп, мәхкәмәгә (хөкемгә) бирде. Фуад олыс (волость) сайлавында үткән булса да, өяз (вилаять) сайлауларына формаль сылтаулар табып катыштырылмады. Казан вилаятендән без беремез дә үтә алмадык. Ләкин Самара, Сембер, Уфа кеби вилаятьләрдән безнең тарафлардан берничә кеше үткәнгә, без Петербургка Фуадны фиркамызның вәкиле итеп күндердек, анда «Таңчылар фракциясе» корырга тәшәббес итдек (карар кылдык, ниятләдек). Безнең әгъзаларымыз «Мөселман трудовая группасы» исемендә тукыз кешедән мөрәккәб (төзелгән) бер оешма корды. Тарихчы Һади Атласи, Гариф Бәдамшаһларның башлыклары астында Бодуэн де Куртенэның* чит милләтләрнең мәбгусләрендән (депутатларыннан) оештырылган федералистлар гөруһына кушылды. Фуад Туктарның билфигыль алып баруы астында Петербургда «Дума» исемендә бер гәзит тә нәшер итә башлады. Безнең Казанда нәшер итә башлаган «Тавыш» гәзитемездә дә язудан Фуад һич туктамады.

1907 елның 4 июлендә Столыпинның Икенче Думаны куып, сайлау хокукларын киметүе фәрманындан соң Фуадның идарә иткән «Дума» гәзите капанды (чыгудан туктады). Төзелгән фракциямез җимерелде. «Тавыш» гәзите дә хөкүмәт тарафындан ябылып, мин кулга алындым. «Таң мәҗмугасы» гәзитемезнең беренче нөсхәсе үк хөкүмәт тарафындан җыелып алынып, безгә легаль эшләргә имкян (мөмкинлек) бик тарайды. «Дума» ябылып, гәзит тә хөкемгә бирелеп, Фуад качып Казанга кайтканда бик арган, эш эшләүнең авырлыгындан, халкымызның мәгълүм дисциплинага өйрәнә алмавындан бик йончыган иде.

Озак үтмәде, безнең яшерен оешмаларымыз да берсе артыннан берсе хөкүмәт тарафыннан тотылды. Уфа, Оренбург, Казан шәһәрләрендә корган яшерен матбагаларымыз табылып, бик күп ибдәшләремез төрмәгә ябылып, мәхкәмәгә (судка) бирелде. Кулга эләкмәгәннәре качарга, посарга мәҗбүр булды; пропаганда эшемез тәмамән диер дәрәҗәдә туктады. Фуад посды... Мин сөргендә... Сөргендән качып, Петербург, Финляндия, Төркиядә яшәп үткәргән алты-йиде ел эчендә Фуад яңадан уку юлына керде: зур мәшәкать берлә гимназия имтиханын тотды. Казан дарелфөнүненең (университетының) хокук шөгъ-

---

* «Ләһле (поляк. — *Х.М.*) профессор мөстәкыйль Ләһстанда Академия әгъзасы булып сайланып, Варшауда вафат итде». Бодуэн де Куртенэ (1845–1929) 1875–1883 елларда Казан университетында да профессор булып эшли. Мәшһүр лингвист җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Азчылык милләтләрне яклап, чыгышлар ясый. Шуның өчен 1915 елда патша төрмәсендә дә утырып ала. Гаяз Исхакый Бодуэн де Куртенэ белән Россиядә вакытта да, Польшада яшәгәндә дә очрашкан булырга мөмкин.

бәсенә (бүлегенә, факультетына) керде. Казанда төрле исемдә чыга торган мәҗмугаларда язу язып килде. («Мөгаллим», «Сөембикә», «Аң» мәҗмугалары.) Рус матбугатына мәкаләләр бирүчән булды. Ләкин акчасы бер дә булмаганга, хәятын алып бару өчен шәкердләр укытды. Гимназия шәһадәтнамәсен алырга теләүчеләрне хәзерләде. Дарелфөнүн бетерүче рус студентларына, курсисткаларына имтиханнарына кирәкле булган әдәбиятдан, тарихдан, икътисадияттан тәхрирләр (сочинение) язып биреп, акча казанды..., дөньясын көтде.

Бу вакытлар Русиядә реакциянең көчле бер дәвере булганга, ачыкдан сәяси бер эш дә эшләү мөмкин түгел иде. Фуад сәясәтдән тартылган (читләшкән) төсдә яши иде. Фәкать Думадагы фракциямез тирәсендәге тәҗрибәләренә таянып, «Мөселман депутатлары» исемендә рәсемле, каты тәнкыйдле бер китап кына нәшер иткән иде.

1913 елның апрель аенда мин, Архангел вилаятендәге икенче кат сөргенемне тәмамлап, илгә кайтырга торган көнләремдә, Фуадтан алган мәктүбләремнең берсендә ул: «Инде качып йөрү хәятындан чыгарга кирәк, яшьлегемез («яшьләремез» мәгънәсендә) башсыз калды. Без бонда, Казанда, бер-беремез берлә кычкырышып, талашып, берлегемезне югалтдык... Кайт да хәрәкәтнең башына кич! Эш күп, вазыйфа зур. Сөйләшергә, дәрдләшергә җыелган төерләр бик күп», — дип язган иде. Минем Петербург, Мәскәү, Нижний аша пароход берлә Казанга төшмәенчә, Чистайга таба китә торган юлыма Фуад, Гомәр, Габдерахман, тагы берничә иске ипдәшләр каршы чыкканлар, минем берлә бергә үк Чистайга кадәр озата киткәнләр иде. Бонда Фуад: «Менә әле синең кайтуың берлә генә без әле бергәләшдек, инде артык бер-беремез берлә күрешми идек. Эт булдык», — дип сүзгә башлады. Башкалары да шулай икәнлекне аңлатып, иске вакытларымызны яңадан ябышдыру лязөмлегене алга сөреп, бер җәбһә (юнәлеш, фронт) берлә эшләүне тәкъдим итделәр вә минем башлыгым астында гына җыела беләчәкләрен сөйләделәр. Мин сөргендән генә Казанның бик чуалганын күреп торганга, форсат килгәнче әдәбият берлә генә мәшгуль булырга карар итеп куйган идем. Шуның өчен беренче сөйләшүләрдә үк яңадан сәяси сәхнәгә атылырга теләгем юклыкны белдердем. Ләкин моңганга (моңа кадәр) бер-берсе берлә кычкырышып, талашып йөргән бу иске ибдәшләр, бер җәбһә булып, минем бу фикеремә һөҗүм итделәр; бу — милли сафдан дезертирлык (хезмәтдән качу) була дип, фикерләрен аңлатырга керешделәр. Чистайга җиткәнче, унбиш сәгатьләр дәвамында сөйләшеп, киңәшләшеп бардык. Мине әүвәлге фикеремдән ваз кичереп, матбугатны яңа юлга борачак бер гәзит чыгару фикерен алга сөрделәр. Нәтиҗәдә без тагы Казанда һәм дә Мәкәрҗәдә

күрешеп, Петербургда «Ил» гәзите чыгарырга карар бирдек. Фуад Туктар бу юлы тагы гәзитнең даими мөхәррирләрендән булып, идарә мөдире төсендә Петербургка күчеп килде. «Ил» гәзите мәйданга чыгып, милли эшенә башлады.

Дөнья сугышы башланган җәендә мин гасаби (көчле, нык) авырып, Балтыйк диңгезе буенда, хәзерге Эстониянең Гонгинбург дигән диңгез коену (куены) йиренә килгән идем. Фуад да гәзитнең идарәсен башкаручы булып, идарәдә калган иде. Сугыш игълан ителү көнләре бу курортда бик зур паника (курку) тудырса да, миндә үземдә әллә нигә әле курку юк иде. Ләкин Фуад хатларында: «Петербургны алманлар тиздән алалар, тизрәк кайт! Тагы икегә бүленеп каламыз», — дип, ашыкдырып яза иде. Мин кайтканда, Фуад бүген-иртәгә Кронштадка һөҗүмне көтеп тора иде. Хәтта бер төнне: «Керделәр, алманлар керделәр!» — дип, безне йокыларымыздан уятып, тәрәзә төбенә зур шәһәр урамының тавышын тыңларга басдырган да иде. Без барымыз да, әлбәттә, Русиянең җиңелү тарафында идек; үземезгә тулы мәгънәсендә Русия берлә сугыша торган алманларның иттифакъчысы (союзнигы) кеби карый идек. Халкымыз да шул фикердә булганга, шул фикерне гәзитемез аша да дәвам итдерергә тели идек. Ләкин Петербургда гаскәри цензор куелып, безнең гәзитемезгә цензор уларак мәшһүр төрк дошманы Смирнов* билгеләнгәнгә, бу фикеремезне эшкә ашыру бик авыр иде. Сугыш башлангандагы беренче санымызның бөтен җыйган материалын цензор кызыл кара берлә сызып җибәрде дә безгә хөкүмәтнең рәсми телеграммаларын басуның мәҗбүри икәнлеген дә сөйләп күндерде. Без икенче кат материал җыеп, икенче мәртәбә санымызны тутырдык; цензорымыз бусының да яртысын бозды, сызды вә бик күп рус хөкүмәтенең ялган хәбәрләрен басырга кушып җибәрде. Моңганча Казан, Оренбург гәзитләренә караганда сәрбәстрәк (ирекләрәк) алынып килә торган «Ил»не элекке юлдан алып бару мөмкин түгеллеге беленде, рус хөкүмәтенең рәсми ялганларын нәшер итеп тору безнең милли вазыйфамызның тышында булуы игътибарга алынып, һәйәт идарәмез «Ил»не Мәскәүгә күчерергә карар бирде вә киләчәк нөсхәмезне шул көнләрдә генә вафат хәбәре килгән мәрхүм Исмәгыйль бәккә генә багышлап чыгарып, Мәскәүдә йирләшеп беткәнче бер-ике ай өзелеп тора булачагы игълан ителде.

«Ил» Мәскәүгә күчде, «Ил» берлә бергә Фуад бәк дә күчде. «Ил» Мәскәүдә берничә ай эшләгәннән соңында Кафкасда аҗар мөселманнарына каршы рус хөкүмәте рус гаскәренең кылган

---

* Смирнов В.Д. (1846–1922) — урыс тюркологы, Петербург университеты профессоры.

золымнарын тәфсыйльле итеп язуы өчен Кафкас вали гомумиясенең (губернаторының) соравы буенча ябылды. Вә миңа гәзит чыгарырга манигъ ителде (тыелды). «Сүз» гәзитенә башка кешеләр исеменә мөсагадә (рөхсәт) алу да айлар буе сөрде (сузды). Фуад бәк мәшәкатьләрдә бергә булды. «Сүз» гәзите урынлашып бетеп, елдан артык дәвам итеп, киң хөрмәт казанып йитде. Ләкин лашман хезмәтенә төркестанлыларны җыю эшендә Җизак шәһәрендә булган урысларның йирле төрекнең (төркинең) канын дәрьялар кеби агызуы хакында мөфәссал (җентекле) язып килүе өчен Төркестан вали гомумы (губернаторы) Куропаткинның таләбе үзәгенә (буенча) «Сүз» дә ябылды. «Ил сүзе» гәзитемезгә алдан ук рөхсәт алынган булса да, безгә «дустча» итеп, Мәскәүне ташлап китәргә куштылар. Вә башка гәзиткә һичбер төрле катышырга хакымыз юклыкны белдерделәр.

Мин Уфага «хәл җыярга» китдем, Фуад Казанга дүнде. Алты-йиде ай гәзитсез калдык. «Сүз»нең ябылуы суына төшкәч, «Ил сүзе»н башладык. Ләкин бик зәгыйфь көенчә генә, байракны төшермәс өчен эшләгәнгә, Фуадны инде Казандан алып килмәдек. Ул да шул вакытларда үзенең дарелфөнүнендән соңгы имтиханнарын бетереп, дәгъва вәкиле мөгавинәте (ярдәмчесе) булып, адвокатлык эшенә керешде.

1917 ел Февраль ихтиляле Фуадны Казанда адвокат мөгавинәтлеге урынында каршылады. Март ахырларындагы Казанны зиярәтемдә (килүемдә) мин Фуадны инде «Мөселман комитәсе»нең (комитетының) рәисе итеп табдым. Ләкин Казан милли берлек нигезендә оешып бетә алмаган иде. «Мөселман социалист» исеме берлә чыккан, киләчәк коммунистлар (Мулланур Вахитов, Шәһид Әхмәдиев вә башкалар) Казанның бер милли байрак әтрафында туплануына төрлечә киртә салалар. Казанның иске җәмәгать хадимләре дә Фуадка «килмешәк» диебрәк карап, аның авторитетын танымыйлар, нәтиҗәдә башбаштаклыкның дәвамына сәбәп булалар иде.

Мәскәү мөселманнары ул вакытта «Ил» өчен аерым матбага корып, милли матбугатыбызны киң рәвешдә яшәтер өчен зур мадди ярдәмләр эшләп ятканга, Фуадны Мәскәүгә күчәргә, «Ил»не алып барышырга чакырдым. Фуад катгый рәдд итмәсә дә (кире какмаса да): «Элгәрге вакытда Казан матбугаты каты цензор астында тотылганда, Мәскәү, Петербургда рус матбугаты өчен йомшаграк куелган вазгыятьдән файдалануымызда хаклы идек; хәзер ул әхваль үзгәрде, Казанның эченә кереп эшләргә кирәк! Тагы, Казан тышдан ялтыраса да, эчдән калтырый... Мин дә китсәм, эш башында кем калачак?» — диде вә шул фикеренә садыйк (тугры) калып, Казанда йирләнде. Казанда «Мөселман комитәсе»нең (ахырдан «Казан мөселман шу-

расы» исемен алды) рәисе, Казан бәләдиясенең (шәһәренең) «Мөселман фракциясе»нең рәисе, «Корылтай» гәзитенең баш мөхәррире булып эшкә чумды. Беренче Мәскәү, икенче Казан корылтайларына Казан исемендән иштиракь итде (катнашты).

Ләкин Казанда милли берлекне бозучы көчләр руслар тарафындан яңадан-яңа ярдәмләр алып торганга, Фуадның бу дәвердәге милли хезмәте бик зәхмәтле кичде. Ике тарафның һөҗүме арасында үзе дә ул вакытның милли берлек байрактары (байрак йөртүчесе; юлбашчысы) мәркәзе «Мөселман шурасы»на мөнәсәбәтне катгый куя алмады.

«Учредительное собрание»га сайлау вакытларында да Казан бер генә листә (блок, исемлек) берлә чыга алмады. Фуад милли листәнең башында булып, «Учредительное собрание»га әгъза булып үтсә дә, листәдәге башка әгъзалары Казанны тәмсил итәрлек (гәүдәләндерерлек) булмаганга, иттифакый (очраклы) рәвешдә дулкын өстенә чыккан шәхесләр генә иде. «Учредительное собрание»ның беренче вә соңгынчы мәҗлесендә Фуад милли груп (группа) берлә «төрк-татар фракциясе»н корышучылардан берсе булды.

Ул вакытның Милләтләр комиссары булган Сталинның «Мөселман комиссариатын» корышуга чакыруын бу фракциянең катгый рәдд итүендә дә (кире кагуында да) Фуадның роле булмады түгел. Безнең Идел буе депутатларының зур күпчелеге (Галимҗан Ибраһимов, Мулланур Вахитов, провокатор Манатовлар вә башкалар) ул вакытта Уфада утырышларын дәвам итдерә торган Милләт мәҗлесе берлә бер фикердә, бер хателхәрәкәдә (бер юнәлештә; бердәм) булынды, большевик режимын катгыян танымады, алар берлә һичбер эшдә уртак эшләүне кабул итмәде. «Корылтай»да бик каты итдереп антибольшевик пропагандасын алып килде. Вә һәр вакытда Фуад большевикларның, аларның коткысы берлә хәрәкәт итә торган хулиганларның һөҗүмләренә мәгъруз булып (тоеп; көрәшеп) яшәде. (Алга таба журналның өченче санындагы текст бирелә. — *Х.М.*)

1918 ел, 12 апрельдә Казанның милли гаскәре таратылып, милли комитәләре (комитетлары) ябылып, милли матбугаты бетерелгәч тә, Фуад, вакытында кача белүе аркасында гына, башын саклап кала алды. Август аенда (1918 ел) чех гаскәре Казанны алганның беренче атнасында мин большевик җәбһәсен (фронтын) ярып, Мәскәүдән качып килүемдә Фуадны Казанда таптым. Инде Самарада «Учредительное собрание» әгъзаларының комитәсе корылган, большевикка каршы безнең илемездә дә милли мөҗадәлә (бәхәс; көрәш) яңадан башланган, Фуад вә аның иптәшләре «Алтай» гәзитен чыгара башлаганлар иде. Уфа да шул көннәрдә большевиклардан арчылып, боль-

шевиклар тарафыннан куылган, таланган Милли идарәдә яңадан эшкә башлаган иде. Бәләбәйгә тупланган 11 мең татар, башкорд гаскәрен, Казанда большевиктан кулга төшкән корал берлә коралландырып, Казанны сакларга китерү хакында сөйләшер өчен Уфадан ике татар забиты (офицеры) (берсе мәрхүм полковник Әкрам Биглицев иде. Икенчесе... әлегә исәндер дип исемен зикер итмим) килгәннәр иде. Аларның Казандагы көрешүләре уңышлы чыкмаганга, Самарага барачак иделәр вә безнең дә тиз бергә баруыбызны үтенә иделәр. Самарадан «Учредительное собрание» әгъзасы Гомәр Тәңреколыйдан (Гомәр Терегуловтан): «Төрк-татар вәкилләренең Самарада туплануы матлубдыр (заруридыр), Казан депутатларын мөмкин кадәр тиз Самарага алып килегез!» — дигән телеграмм да бар иде.

Казанда берәр атнага калып, без Фуад берлә Самарага киттек. Фуад «Учредительное собрание»ның комитәсендә эшләргә башлады. Мин Милләт мәҗлесенең Русия хөкүмәте янына күндерелгән «илчелек һәйәте»нең әгъзасы сыйфаты берлә Самарада бюромны ачтым. Самарадан комитә алдында Бәләбәйдәге коралсыз көенчә бет ашатып ята торган унбер мең татар, башкорд егетләрен, Казанда алынган корал берлә коралландырып, аерым татар, башкорд гаскәре төсендә Казанны сакларга күндерелүе хакында тагы тәшәббестә (фикерендә; ниятендә) булдык. Руслар безнең татар, башкорд гаскәреннән курыктылармы, Казанны саклауның әһәмиятен сизмәделәрме? — Безнең таләпләребезне кабул итмәделәр. Ачык итеп рәдд итәргә (каршы килергә) курыкканга, якын көндә тупланачак «Учредительное собрание» әгъзалары берлә милли тәшкилият (оешма) вәкилләреннән мөрәккәб (тупланган) киңәш мәҗлесенең карарына багладылар. (Бу мәҗлес җыелганчы, җитәрлек сакчысы булмаганга, Казанны большевиклар алдылар.)

Без таләбебез буенча, Милләт мәҗлесебез тарафыннан кабул ителгән милли-мәдәни мохтариятебез һәм дә Идел-Урал мохтар (ирекле) җөмһүрияте ясау фикеребезне кабул итүләре хакында бер карар ясап, шуны рәсми гәзитәләрендә «Учредительное собрание» әгъзаларының декларационы (декларациясе) тарызында (рәвешендә) игълан иттеләр. Бу декларационның үткәрелүендә Фуадның бик күп хезмәте тукынды (төгелде).

Самарага хосусый кешеләр тарафыннан китерелгән татарча хәрефләрне сатып алып, бер гәзит чыгарырга тиеш иттек. Ләкин шул көннәрдә Казанда бик каты сугышлар булып, большевиклар Сембер, Самара өстенә дә йөрегәнгә, без үзебезнең киләчәк мәркәзебез булачак Уфага таба хәрәкәт иттек. Фуад Самарада иң озак калып, иң соңгы төрән (поезд) берлә чыкты һәм дә үзе берлә бергә теге хәрефләрне дә капчыкка гына тутырып булса да алып чыгарга онытмады.

Уфадагы «Дәүләт киңәш мәҗлесе»нә Идел-Урал төрк-татарларының Милли идарәсе, казак-кыргызларның Алаш урдуларының, башкорд гаскәренең вәкилләре дә чакырылган булганга, «Учредительное собрание» әгъзалары арасында Төркестанның да берничә мәбгусы (депутаты; делегаты) да булганга, Уфада төрк кабиләләренең, Кафкас, Кырымнан башкасының, һәммәсенең мөмәссилләре (вәкилләре) хазыйр (катнаша) иде. Без дә бонда милли матлабларымызда (таләпләребездә) беравыздан хәрәкәт итәр өчен «Төрк-татар фракциясе» исемендә бер фракция дә кордык. Вә килгән кунак казак-кыргыз, Төркестан вәкилләрен Уфа Милли идарәсе аерым бер мәдрәсәдә йирләшдереп, Уфада утырган мөддәтләрендә (вакытларында) аларны кунак итте. Бондан файдаланып без, һәрбер мәсьәлә өстендә утырышлар ясап, ай буе дәвам иткән киңәш вакытында Идел-Урал, Себер, казак-кыргыз, Төркестан төркләрен бер сәяси мәүҗүдият (бөтенлек) төсендә оештырып өлгердек. Бонда да Фуадның роле һич кечкенә түгел иде.

Самара алынып, Уфага большевик гаскәрләре якынлаша башлагач, без Милли идарә берлә һәм дә «Яңа мувәкъкать» (вакытлы) хөкүмәт берлә Себергә күчеп киткәндә, Фуад бәк тә бергә булды. Ләкин «Учредительное собрание» әгъзаларының даими тупланыш шәһәрләре итеп ни өчендер «Себер хөкүмәте» яшәгән Омск шәһәре тәгъәйен ителмәенчә (билгеләнмичә) Екатеринбург билгеләнгәнгә, башка «Учредительное собрание» әгъзалары берлә Фуад та Кызылъярга бездән бер-ике ай соң килде. Аның Самарадан алып чыккан хәрефләре берлә «Учредительное собрание» хәзинәсеннән Гомәр берлә икесенең мәсьүлиятенә алынган акчалары берлә «Маяк» гәзитен чыгарырга тотындык. (Ул 1919 елның апреленә кадәр чыга.)

Бу вакытта 1918 елның 11 ноябрендә Аурупадагы мөтарәкә (вакытлы килешү) дә игълан ителде. Без алманнарның җиңелүләренә ышанмаганга, бу эшне Аурупа дәүләтләренең бергәләшеп бөтен сугыш бүлекләкләрен (чыгымнарын) Русия өстенә күтәртеп, шуларны капатыр (каплар) өчен Русияне бүлү башлануының башы дип аңладык.

Шул Русияне бүлешүдә үзебезнең халкыбызның сәяси «ризыкы» хуҗасыз калмасын өчен, Аурупага солых мәҗлесләренә катышырга вәкилләр күндерүне кичектерелми торган бер милли эш итеп карадык. Бу фикер андагы бөтен милләтчеләребезнең уртак фикере булганга, мин «Маяк»ның беренче санында ук Милләт мәҗлесенә сайлаган солых һәйәтенең (комиссиясенең) бер әгъзасы сыйфаты берлә милләткә мөрәҗәгать итеп, өзелеп калган солых һәйәтенең ике әгъзасы йиренә тагы яңа әгъзалар сайлауны, большевик талап калган солых һәйәтенең хәзинәсе йиренә яңадан акча җыеп бирүне үтенеп мөрәҗәгать

иттем. Үзебез Милли идарәнең мәҗлесләрендә киңәшләшеп, шул әгъзаларны сайлар өчен, гомумән, эшләребез хакында милләткә хисап бирер өчен большевик кулына төшмәгән милли идарәләребезнең вәкилләрен тупларга карар иттек. Акча җыю өчен кайбер шәһәрләргә аерым вәкилләр дә күндердек. Үзара киңәшләшеп, бу эшләрнең булып чыгуы бик озакка калыр дип уйлап, Милләт мәҗлесенең «төркче фракциясе»нең әгъзалары тупланып, фракция исеменнән минем яныма әгъза итеп Гомәр Тәңреколыйны сайладылар. Себердән акча җыеп баруны да миңа йөкләп, минем «киңәш мәҗлесе»н көтүемне мәслихәт күреп, безгә юлга чыгарга мөнасиб күрделәр.

Мәрхүм Гомәр (ул 1938 елның 29 августында Истанбул тирәсендәге Бакыр исемле бистә хастаханәсендә вафат була. — *Х.М.*) минем берлә акча җыешып, шау-шу күтәреп барудан курыкты. Ул үз башына алдан хәрәкәт итте. Мине Иркутскида көтәргә булды. Мин, өстемә төшкән вазыйфаны үтәп, Иркутскида Гомәрне алып, Харбинга килеп чыктым (апрель, 1919). Кызылъярдагы киңәш мәҗлесе солых һәйәтенә әгъза итеп берничә кешене сайлады. Ләкин аларның, бер-берсе берлә аңлашып, хәрәкәтләре озынга сузылды. Яңа сайланганнардан күбесе барырга разый да булмады.

Фуад 1919 елның август ахырында гына Харбинга килеп чыкты. Аңганча (аңа кадәр) без Гомәр берлә Япуниягә барып, Аурупага чыгар өчен юл визалары эстәсәк тә, дүрт ай эчендә һичбер йирдән мөсагадә (ярдәм; булышлык; мөмкинлек) ала алмаенча, кире Харбинга кайткан идек. Безнең «Учредительное собрание» әгъзасы Чайковскийга Париска (Парижга) виза сорап күндерелгән телеграммабыз Садрый әфәнде Максудиның кулына төшеп, ул безгә французлардан виза күндерткән булса да, безгә бу виза килеп җитә алмады. Без чех гаскәрләре берлә бергә өчәүләп — Гомәр, Фуад, мин — солых һәйәте сыйфаты берлә Аурупага чыгарга юл таптык.

Ләкин Гомәр ул вакытларда Читага милли мәсьәләләр хакында күрешер өчен күндерелгән булганга һәм дә безгә билгеләнгән пароход киткәнчә килеп җитмәгәнгә, аңарга киләчәк пароходта барырга әйтеп, урынын, йирен билгеләп, Аурупага сәяхәткә чыктык. Фуад берлә бергә 56 көн чех солдатлары арасында калып, Прагага килеп җиттек. Анда «Азәрбайҗан һәйәте»нең башында иске танышыбыз Галимәрдан бәк Тупчыбашевның Парижда булуыннан хәбәр алып, аңарга безгә Франсага (Франциягә) виза күндерү хакында мөрәҗәгать иттек. Мәктүбебезгә җавап Садрый бәк Максудидан килеп чыкты. Безнең күптән югалткан Садрый бәгебез Финляндия ашасыннан (аркылы) Парижга килеп чыккан икән. Без Фуад берлә 1920 елның апрель аенда Парижга килеп җиттек. Без-

не Садрый бәк каршы алды. Гомәрдән һичбер хәбәр булмады. Без өч кеше Идел-Урал төрк-татары Милләт мәҗлесенең солых һәйәте исемендә эшкә керештек. Илебездә минем мөрәҗәгатемә каршы большевик кул астына төшмәгән милләттәшләребез бик юмартларча милли ярдәмдә булынганнар вә ярты миллионнан артык акча туплаганнар иде. Боларның минем берлә килгәннәрен мин Иркутски, Харбинның зур сәүдәгәрләренә мал (товар) алып, валютага күчерергә үтендем. Алар да кабул иттеләр. Ләкин хисапка килгәндә тукыз айдан соң кыйммәтләре тәмамән бетәр дәрәҗәгә иңгән Себер акчаларын кәгазь көенчә кире тоттырдылар. Себердән Фуад та шундый кәгазьләр күтәреп кенә килгән иде. Шуңарга Парижга килгәндә кулыбыздагы акчабыз бик аз иде. Алай да Финляндия төрк-татарлары һәм дә Америкадагы Заһидулла бәк Агиш һәм Харбинның мәрхүм Гыйнаят ахунның тырышып аз-маз ярдәмнәре аркасында солых һәйәтебезне Франсада ике ел яшәтә алдык... Садрый бәк — рәис, мин — хәзинәдар, Фуад кятиб иде. [Мондагы эшләребезне язып тору мәүзугның харичына (темабыздан читкә) чыгу булганга, аларны үтеп китәм.] Ләкин Фуадка тәгалыклы (бәйләнешле) булганга, бер вакыйганы язып китүне лязем табам.

Көннәрнең берендә кайдадыр бер милли эш хакында мәктүб алдык. Садрый бәк миңа килде дә, без кичке ашны бергә ашап, Фуадның французчаны өйрәнер өчен кергән кичке курстан чыгуын көтәр өчен, сәгатендә мәктәпнең янына бардык. Распай җаддәсендәге (урамындагы) бер мәктәп бинасыннан Фуадыбыз башын иеп кенә чыкты. Әгәр без эндәшмәсәк, ул безне күрмәенчә үтеп тә китәчәк иде... Күрештек. Садрый бәк: «Мелла Фуад, кәефең йирендә түгел кеби, ни булды?» — диде. Фуад та: «Ни булды!.. Ни булсын... элгәре, төнне көнгә кушып, мәдрәсәдә укыдым, галим булдым. Аны тәмам иткән идем... Бу хәзер эшкә ярамый, яңа гыйлем өйрәнергә кирәк, диделәр. Әлифбадан русчага керештем; «Учительская школа»ны бетердем. Бондан ни була, бик кечкенә, диделәр. Гимназия шәһадәтнамәсен алыр өчен өч ел тырыштым, ул да булды. Дарелфөнүнгә (Казан университеты күздә тотыла) кердем, аны да бетердем. Адвокат булып җиттем. Инде хәзинәм тулды дип, эшкә керешкән идем... Илебездән куып җибәрделәр, инде бонда ул белгәннәрем дә эшкә ярамый. Французча белергә кирәк. Инде менә өченче мәртәбә әлифбадан башлап укырга керәм. Баш күтәрерлек йир бармы?!» — диде.

Ләкин Фуадның әле укуы боның берлә генә бетмәде. Ул мескен французчаны шактый әлдә (алда) иткәч, аның берлә генә эш тәэмин итә алмады. Алманиягә күчте. Анда да әлифбадан башлап, алманча өйрәнде. Анда да казык кага алмады

(ягъни төпләнеп кала алмады), Төркиягә күчте. Анда да әлифбадан булмаса да, госманлычаны да өйрәнергә мәҗбүр булды. Шулай берсе арты берсе килеп торган ачлы-туклы өйрәнүләр берлә бергә милли эшләрне эшләү эчендә Фуадның тормышы үтеп китте...

Алманиядә ул үзен вөҗдани канәгатьләндерерлек яңа бер милли эш тапты. Ул да: төрк клубындагы бөтен төрк кабиләсеннән җыелган яшьләрне тәрбия итү иде. Шул эшне бер программ юлында эшләр өчен, без бөтен төрк кабиләләренең бераз тәҗрибәләрен туплап, «Туран җәмгыяте» төзедек вә боның идарәсенә икебез дә кердек. Атнаның бер көнендә боның гомуми җыелышларын ясап, мәгърузәләр (лекция, докладлар) укый идек; сәяси, әдәби, гыйльми мәүзугларда мөнакашәләр (бәхәс-диспутлар) ясый идек. Фуад бәк боның һичбер мәҗлесен калдырмаенча, һичбер мәсьәләдә моназарәгә (әңгәмә-бәхәскә) катышмаенча калмаучы бер фәгъгал (эшлекле; актив) әгъзасы иде. Үзе дә әллә ничә төрле мәүзугларга мәгърузәләр ясап кына калмаенча, аерым-аерым группалар берлә дә аерым утырышлар ясап, фикри тәрбияне алып бара иде. Вә бонда чын мәгънәсендә госманлы, азәри, төркестан, Идел-Урал төрк яшьлегендән берберсен телендә аңлашырлык, фикердә берләшкән яңа бер гонсыр (матдә, тупланыш) ясарга тырыша идек вә шактый муаффәкъ та була идек (максатка да ирешә идек). Госманлы төрек яшьлегенә (яшьләренә) данес (танец, бию), каһвә, хатын-кыз берлә чуалудан башка, фикри бер хәят барлыгын билфигыль (гамәлдә) күрсәтеп, аның замимиләрен җитди юлга салынып китәргә ярдәмдә булына идек.

Боңарга башка ул вакытлар безнең Идел-Ураллы укучы яшьләребезнең дә саны Берлинда гына да кырыктан артык иде. Аларны да милли бер рухта тәрбия итәр өчен бер җәмгыять төзеп, монтазам (эзлекле, тәртипле) рәвештә чалышу (эшләү) лязем иде. «Яшьләр береге» (берлеге) исемендә ун елдан артык яшәгән бу җәмгыятьнең низамнамәсе (уставы) Фуад бәк тарафыннан эшләнгән иде. Җәмгыятьнең дә атнаның бер көнендә (шимбә көн) мәҗлесләре җыела. Шунда Фуад бәк бик күп вакытта башкаручы ролен алып бара иде.

Ләкин безнең төрк яшьләре арасында чалышмамыз (эшләребез; эшләвебез) төрк дошманы — большевикларның — эчен бик пошыра иде. Аларның үз хисапларына алманча Маркс әсәрләрен укый белә торган большевик ясар өчен китергән Төркестан, Азәрбайҗан укучылары «Туран»ның мәҗлесләренә сөя-сөя киләләр. Бондагы хөр милләтчелек фикере берлә ашланып, большевик сафсатасыннан озаклашалар (ерагаялар) иде. Бу шәкердләрнең большевиклар тарафыннан куелган караучысы Галимҗан Идрисинең боларны «Туран» мәҗлесләренә

барудан тыю тәдбирләре (теләк-ниятләре) нәтиҗәсез кала иде. Ахырдан большевик Сефартинның киңәше берлә большевикларның «Пансион сух» дигән мәркәзләрендә берничә большевик ялчылары киңәшләшеп, Совет акчасына укый торган азәри, төркестанлы шәкердләргә катгый әмер биреп, «Туран»ның бер мәҗлесен бастырдылар вә бик зур скандал (гауга) ясап, мәҗлесне тараттылар. Мәҗлеснең рәисе мин, «һәйәте идарә» әгъзасы Фуад бәк «Туран»нан истигъфа иттек (киттек; эшне калдырдык). «Туран» җәмгыяте икенче идарә сайласа да, эшкә керешеп китә алмады, «Туран» сүнде, большевикларның теләкләре дә булды.

Фуадны рухан (рухи яктан) Берлинда баглый торган бернәрсә калмады, ул Төркиягә күчәргә карар бирде. Бу вакытларда Төркиядә культур сахәсендә (өлкәсендә; мәйданында) төркчелек рухында инкишафлар (эш-гамәлләр) күтәлә иде. Төркиянең мәгариф вәкиле дә төрекче Хәмдалла Сөбхи бәк иде. Шуңарга безгә һәммәбезгә анда барып кулдан килгән кадәр хезмәт итү милли вазыйфа кеби тоела иде. Төркиядәге дустлардан чакырулар да ала идек. 1925 елда беренче уларак Фуад Төркиягә китте. Истанбулда озак калмаенча, Анкарага хәрәкәт итте. Берничә ай вакыт үткәч, ул мәгариф вәкаләте тарафыннан «Хөкүмәт көтепханәсе»нә мөдир итеп тәгъйин ителде (билгеләнде). Мәгашы (хезмәт хакы) күп булмаса да, Фуадның эше күңеленә ошый торган гыйльми, тәрбияви хезмәт иде.

Ләкин көтепханә дигән мөәссәсә (оешма; учреждение) хосусый, вакыф көтепханәләреннән җыеп китерелгән, һичбер тәртипкә салынмаган китап өемләреннән гыйбарәт иде. Фуад бәк боларны юлга салырга тотынды: шкафлар ясатты, китапларны сайлатты, дәфтәр (каталог) ясатты. Шул китаплар өемен көтепханә төсенә кертте. Көтепханә укучыларга китап бирә торган булса да, укучылар бик аз иде. Күбрәк китапны алучылар төрле мәгариф мәэмүрләре (хезмәткәрләре) иде. Алар да, дөрестән әйткәндә, кирәкле китапны алып, үзләренә кирәкле материал эзләмиләр иде. Дәрәҗәсенә күрә Фуад бәккә кәгазь язып, мәсәлән: «Гыйльме хайванаттан (зоологиядән) аюның нәүгълары (төрләре) кайда яшәүләре хакында дүрт битлек мәгълүмат хәзерләп куегыз! Дәреслек өчен кирәк.— «Урта мәктәпләр мөдире Фәлән». Яисә: «Французча китапларда тырнак буясының (буявының) насыйл (ничек) ябылмасы хакында мәгълүмат хәзер итеңез! — Мөдир бәкнең рәфыйкасына (хатынына) лязем, фиһристләрен (эчтәлеген, исемлеген), китапларын хәзерләңез!» — Мәгъбүс (депутат) фәлән кеби сораулар иде. Фуад бондый кәгазьләрне алыр-алмас сигараны ягып, бераз уйлап тора иде дә, гомерлек томаулы борынын сөртеп, үзе тәр-

типкә куйган шкаф янына килеп баса иде. Шуннан бер французча, бер төрекчә, бер гарәпчә китаплар чыгарып, сораган мәгълүматларны туплый иде.

Атнага, ун көнгә бер мәртәбә берәр укучы шәкерд кереп, берәр гыйльми китап та сорый иде. Фуад андый кадерле мосафирның янына барып: «Ни өчен, нәрсә эзләнәсең, сине кызыкдырган мәсьәлә кайсысы?— дип сорашып, егет берлә танышып, аңарга кирәкле китапны табып бирә. «Әле бетмәде, тагы һәйбәт китаплар бар, укыгач килерсең», — дип җибәрә. Икенче мәртәбә китапларны китергәч, Фуад, көтепханә мөдирлегеннән шәһадәтнамә алырга өйрәтүче мөгаллим төсле булып, укыганмы, юкмы дип, егетне имтиханга тота иде. Шуңарга бондыйларның укыганнары яңа-яңа китаплар алып, Фуад бәктән аңламаганнарын сорап, аның шәкердләре булып китәләр иде. Болай гына, фасон өчен генә китап алганнары өченче кат китапханәгә únграмыйлар (килмиләр) иде. Фуад шкафларның арасында үзенә бер өстәл куеп, ул өстәлнең бер почмагына һичбер сүнми торган бер машинаның (плитә, керосинка) өстенә чайданын (чәйнеген) утырткан бер урын да корган иде. Бонда һәрвакыт кайнар чәй булганга, мәэмүрләр (хезмәткәрләр) чыккан чагында кай көннәрдә бонда Идел буе төркләреннән Йосыфдан (Акчура) башлап, Әюбкә кадәр зиярәтчеләр (килүчеләр) тулган була иде. Төркиянең бөтен хәлләре, эшләре дә сөйләнә, уйлана иде.

Ләкин 25 ел бер буйдан халык хезмәтендә булынган, халкын таныган, халкының кирәген күргән Фуадка ул вакыттагы Төркиядә башланган бүрек салдырыб инкыйлаб ясау, мең дә өч йөз ел хаким булынган кануннарны ике сәгатьтә ташлап, ике сәгатьтә Исвичрә (Швейцария) канунын кабул итеп, «алга атлау» эшләре Фуадны канәгатьләндермәде. Аның табигый тәнкыйтьче куәтен эшкә ашыруга имкян (мөмкинлек) булмавы аны изә, мохиткә каршы көчсезлек аны өмидсезләндерә иде.

Фуад үзенең 25 еллык җәмәгать хезмәтен төркчелеккә корганга, ул вакытта дүрт-биш безнең мөһаҗирнең Анкарада йирләшүенә каршы большевикларның сатып алган бәндәләре тарафыннан күтәрелгән кампаниягa каршы төрек зыялысының галякасыз (бәйләнешсез, битараф) калуы Фуадка бик авыр тоела иде. Ул, шуңарга протест кеби итеп: «Фуад бәк, сез кайдан?» — сөаленә һичбер вакыт шималь (төньяк) төрекләреннән, фәлән кеби җавап бирмәенчә: «Мин татар, Идел буе татары», — дип куя иде. Иптәшләренең: «Ник алай диясең! Шималь төрке, фәлән диең», — тәнбиһләренә (шелтәләренә): «Ник? Ул бит барыбер минем берлә эше беткәч тә, «биш татар» дип сөйләячәк», — дип җавап бирә иде. Фуадның милли инкыйлабчы, төрекче, русафоб, антибольшевик рухына ул вакыттагы

Төркиядә хаким булган, большевикларны күккә күтәрү, рус марҗасының юмартлыгыннан руслыкны зур күрү зиһнияте дә, әлбәттә, тәмам ят иде. Шуңарга Фуад бонда шимальдән күчерелеп китерелеп, җәнүб (көньяк) тупрагына утыртылган ят бер агач кеби тамыр җибәрергә, үсеп китәргә мохит таба алмавы канәгатендә иде. Китәчәк йир юклыгы аны тагы шул мохиткә баш иярге, тәкъдиргә буйсынырга мәҗбүр итә иде. Үзенең шул вазгыятенең фәҗәгатеннән (аянычлы хәленнән) Фуад шәхси тормышка бирелү юлында чыкмакчы булды. Ул, өйләнеп, гаилә корып, «мещан» булып торам дигән фикергә килде. Көтепханәдә үзенең кул астында хезмәт итүче бер тол хатын берлә өйләнде. Хатынның баглыкдагы бер йирендә өй корырга тотынды. Көн, төн эшләде, бурычка батты, өй корды. Инде балалы-чагалы булып яшәргә генә калды... дигәндә, хатыны өеннән куып чыгарды. Фуад өстеннән ялган төһмәтләр (ялалар, гаепләр) ясап, көтепханәдән чыгуына да сәбәп булды. Фуад бу хатынның йорты өчен булган бурычларын еллар буе түләде, мәхкәмә (хөкем; суд) берлә генә хатыннан аерыла алды. Үзе дә урынсыз калды. Бераздан хокук мәктәбенең көтепханә мөдире булып, урынга йирләште. Монда Фуад үзен үзенең вазыйфасы эчендә хис итеп җан тарытты, хатынының бурычларын түләп бетерде. Шәкердләргә китап биргәндә, аларның мокаррирләре (аңлатучы; репетитор) булып, аларга аңламаган мәсьәләләрен аңлатучан булды. Кызыксынучы яшьләргә фикъһенең (хокукның) төрле мәүзугъларына мәгърузәләр (доклад-рефератлар) ясады, шәкердләрнең имтиханга хәзерлекләренә ярдәм итте, үзен сөйдерде. Бераз күңеле күтәрелеп, икенче кат өйләнде. Ләкин тузанлы китап эчендә еллар буе эшләү Фуадның утыз ел арган организмына авыр килде. Фуадта үпкә хәстәлеге (чехотка) башланды. Яшь шәкердләр берлә бондый йогышлы авыруның даими катнашта булуы шәкердләр өчен куркулы булганга, Фуад хезмәттән чыгарылды. Берничә мәртәбә төрле санаторийумларга (санаторийларга) барып дәваланса да, аның гомер буе шәхси тартыш, милли тартыш, сәяси тартыш, кабиләви тартыш берлә йончыган җисеме бу эчтән кимерелгән зәһәрле авыруга мөкавәмәт (каршы килә; каршылык) итә алмады...

Фуад Анкарада 19 декабрь, 1938 елында вафат итте һәм дә Анкарада күмелде. Фуад берлә бергә безнең Идел буеның соңгы утыз ел эчендә һәрвакыт милли тартышта беренче сафта булган бер милли мөҗаһиде вафат итте. Фуад берлә бергә безнең милли тартышымыбызның халык файдасы өчен үзен һәрбер авырлыкка катарга (атарга), чыдарга тиеш дип ышанган вә гомере буе шул икътикадка (ышанычка; принципка) садыйк (тугры; дус) калган бер идеалисты йиргә күмелде. Фуад

берлә бергә хаклык өчен тартышу мөкатдәс инсани бер вазыйфадыр дип ышанып, хаклыкка каршы (ягъни хаклык өчен) һичбер көч алдында баш имәгән, дөньяның җилендә, давылында, буранында имән агачы кеби баш та селкетмәгән бер хаклык каһарманы югалды. Ул туган иленнән, яшәгән тупрагыннан, эчкән суыннан озакларда (еракларда) кардәшләре арасында ят булып яшәп, гариб (чит) булып вафат булды.

Ләкин аның эшләгән эшләре, кылган корбаннары, бүген тәкъдир ителмәсә дә, онытылмаячакдыр. Фуад милләтне сөюдә, үзенүзе тәрбия итә белүдә, халкы өчен үзен корбан итә белүдә үрнәк булып калачак. Бик күп яшь фуадчыклар аның тәрҗемәи халеннән үзенең рухына куәт алып, аның шәкерде булачактыр. Хаклык югалмаган кеби, хаклык корбаны да онытылмыйдыр.

## Таныш проблемалар, таныш бәхәсләр

Реаль тормышта мәсьәлә хәл ителми икән, рухи дөньяда ул һәрвакыт бәхәс чыганагы булып тора. Милли мөнәсәбәтләр хакындагы сүзләрнең гаять күп һәм озын гомерле булулары да нәкъ әнә шуның белән аңлатыла. Империя яшәгән җирдә милли мәсьәлә хәл ителми: киресенчә, тагын да катлаулана, чәбәләнә төшә. Империяне саклау (ягъни милләтләрнең тигезсезлеген саклау) өчен әллә нинди теорияләр уйлап табыла, сафсаталар корыла. Югыйсә бит милли мәсьәләне хәл итүнең юлы бик гади һәм табигый: һәр милләткә үзенчә һәм мөстәкыйль яшәргә мөмкинлек бирү. Әмма, кызганыч ки, гасырлар буе империячел рухта тәрбияләнгән кешеләрнең күпчелеге шушы аксиоматик хакыйкатьне аңламыйлар, дөресрәге, аңларга да теләмиләр; аның өчен чечен, татар, осетин, абхаз, гагаузның рус, грузин, молдаван кебек тигез, мөстәкыйль яшәргә омтылышы гайре табигый күренә.

Ни өчен рус, христиан булмаган халыклар да 1917 елгы инкыйлабка тартылдылар? Моның, әлбәттә, сәбәпләре күп. Әмма алар арасында большевикларның милли бәйсезлек һәм дин иреге мәсьәләләрен үзәккә куюлары мөһим рольне уйнады. Тик көткән милли азатлыкны Октябрь бирмәде. Халыклар бер империя эскәнҗәсеннән икенчесенә, тагын да катырагына эләктеләр. Җөмһүриятләрнең союздаш, автономияле формалары элек бердәй яисә үзара якын милләтләр арасында да тигезсезлек китереп чыгарды. Милли үзлекне, милли телләрне юкка чыгару, «бердәм совет халкы» төшенчәсе астында урыслаштыру совет хакимият органнарының рәсми һәм катгый сәясәтенә әверелде.

Милли бәйсезлек байрагына чын күңеленнән инанган күп кенә кешеләр большевиклар хакимиятенең асылын тиз аңлап алдылар һәм, чит мәмләкәтләргә китеп, истикъляль (азатлык) өчен көрәшләрен дәвам иттеләр. Болар арасында «татар әдәбиятының таҗлы бер хаканы» (Әхмәт Ләбиб Каран әйтүенчә) Гаяз Исхакый да бар иде. Ул тиз арада СССР империясендәге бәйле халыкларның мөһаҗәрәттәге юлбашчыларыннан берсенә әверелде. Варшавада корылган «Прометей» оешмасы да аның инициативасы белән төзелә. Украина, Төркестан, Идел-Урал, Кырым, Кавказ һәм башка төбәк вәкилләрен үз эченә алган бу интернациональ блокның төп максаты изелгән милләтләрнең иреге, бәйсезлеге өчен көрәш була. «Прометей» яңа халыкара шартларда төрле сәяси һәм мәдәни чаралар үткәрә, төрле телләрдә гәзит-журналлар («Әмәл», «Азад Төркестан», «Яңа милли юл», «Милли байрак» һ.б.) чыгара, китаплар нәшер кыла, милли бәйсезлеккә ирешүнең юлларын билгели.

Мөһаҗәрәттәге күпсанлы руслар да тик ятмый. Аларның да төрле оешмалар төзүе, матбугат органнары булдыруы мәгълүм. Рус гәзит-журналларында Русия, аның киләчәге хакында гаять күптөрле фикерләр бар. Әмма күпчелек авторлар нәкъ бүгенге рус «демократлары» һәм милли манкортлар кебек Русия, Совет империясен бүленмәс һәм бердәм итеп карыйлар, милли проблемаларны, рус булмаган халыкларның ирке мәсьәләсен күрмәмешкә салышалар яисә аларны ясалма, вакытлы күренеш дип кенә уйлыйлар. Шуның нәтиҗәсендә «великорус» һәм «истикъляльче» әһелләр арасында даими көрәш бара. Аның да үзәгендә Гаяз Исхакый тора. Ул даими рәвештә мөһаҗәрәттәге рус матбугаты белән дә танышып бара, рус эмигрантлары белән дә очраша. Хәтта аның берничә мәртәбә Керенский белән дә очрашып бәхәсләшүе мәгълүм.

Гаяз Исхакый, гомумән, рус мөһаҗир идеологларына, авторларына тәнкыйди мөнәсәбәттә тора, аларның империячел, шовинистик фикерләүләрен фаш итә. Әмма әдипнең сәяси зирәклеге шунда: ул үз оппонентларын тәнкыйтьләү белән генә чикләнми, аларның хезмәтләрендә милли-азатлык көрәшенә файда китерерлек якларны да күрергә омтыла, икенче төрле әйткәндә, үзләренең коралларын үзләренә юнәлтә. Әдипнең рус мөхәррире Постников мәкаләсенә тукталуы да — нәкъ әнә шуның бер гәүдәләнеше. Әлбәттә, рус авторының бу язмасы башка максатларны да күздә тоткандыр. Әмма аның мөһаҗәрәт матбугатында «сепаратизм» хакындагы күп кенә фикерләре объектив һәм Гаяз Исхакый инануына аваздаш яңгырый. Тәҗрибәле рус авторының «истикъляль хәрәкәтен» ясалма күренеш дип түгел, ә «җитди бер хәрәкәт» дип тануы сәяси яктан аеруча мөһим. Заманында Ленин һәм большевиклар су-

гышта патша хөкүмәтенең җиңелүен теләп, шул шартларда властьны кулга алу программасын эшләгәннәр иде. Мөһаҗәрәттәге истикъляльчеләр дә совет хакимиятенең җиңелүен телиләр һәм бары шул шартларда гына милләтләрнең ирек, бәйсезлек алачагына ышаналар.

Постников мәкаләсе болай бетә: «Киләчәкдәге Русия ихтиляле (большевиклар егылганда) милләтләрнең хокукын тану, Русиядә милли мәсьәләләрне хәл кылу шигаре астында дәвам итәчәкдер». Рус авторы һәм татар әдибе язмасындагы мондый юллар пәйгамбәр сүзләре кебек яңгырый. СССР империясе җимерелде, Русия һәм аерым җөмһүриятләрдә милли-азатлык көрәше дәвам итә.

Гаяз Исхакыйның «Рус мөһаҗир матбугатында миллият мәсьәләсе» (Яңа милли юл. — Берлин, 1938. — № 1 (118). — 17–18 б.) моннан 54 ел элек язылган. Әмма андагы фикерләрнең, проблемаларның күпчелеге бүгенге көн өчен дә актуаль, аваздаш. Анда гыйбрәт алырлык нәрсәләр күп. Бу язманың сәяси көрәш тарихын, үткән юлны танып-белү ягыннан да әһәмияте бар. Рус эмигрант матбугатында да безгә мөнәсәбәтле яклар бар икән. Парижда француз телендә чыккан «Прометей» журналы да үзен өйрәнүгә ымсындырып тора. Безгә Гаяз Исхакыйның иҗат мирасындагы һәрнәрсәне өйрәнү шарт. Бу яктан да мәкалә, тарихи бер факт буларак, игътибарга лаек.

Әйткәнебезчә, соңгы 2–3 елда СССРда милли-азатлык көрәше көчәеп, моңа мөнәсәбәтле күп кенә мәсьәләләр гамәли төс алды. Бу процесста мөһаҗәрәттәге истикъляль хәрәкәте дә зур роль уйнады. Чөнки ул, илдә каты идеологик режим чорында, милли-азатлык көрәшен дәвам итте, аны үстереп, баетып, Ватандагы яңа көрәшчеләр буынына эстафета рәвешендә тапшырды.

*1992*

## Рус мөһаҗир матбугатында миллият мәсьәлә(се)*

*Гаяз Исхакый*

Мөһаҗәрәтдәге (эмиграциядәге) рус матбугатының үзара сүз көрәштерүендән уза алмаенча, Русиядә хөкем сөрә торган большевикларны куып җибәрүчеләр булса, Русия идарәсенең нинди агымларга, нинди кешеләргә күчәргә тиешлеге хакында моназарәләр (сүз көрәштерүләр, бәхәсләр) берлә генә мәшгуль булуларын, киләчәк Русиянең төзелеше-корылышының чын мәсьәләләрен күздән кичерергә дә вакытлары юклыгын күп-

* Яңа милли юл. — 1938. — № 1 (118). — 17–19 б.

тән күреп киләләр. Аларның матбугатларының битләрендә Русиянең яртысындан артыгын тәшкил иткән рус булмаган халыкларның мәсьәләләре куелмавын да шуңарга табигый итеп карап, тәгъкыйб итеп (күзәтеп) киләмез. Ләкин соңгы вакытларда ниндидер без аңламаган сәбәпләрдән ак русларның матбугаты, ара-сыра булса да, Русиядәге милләтләр мәсьәләсенә кагыла башлады. Парисда (Парижда) май аенда булып үткән Украина мөхәррире Славенскийның (Славянскийның) «СССР-да милли мәсьәлә» мәүзугындагы (темасындагы) мәгърузәсенә (докладына; чыгышына; проектына) Парисдагы Кафкас–Украина–Төркестан дустлыгы җәмгыятенең кайбер даирәләре мәгърузәне тыңларга дип махсус рәвешдә Керенскийны(ң) үзен һәм дә яһүди гәзите «Последние новости» даирәсене дәгъвәт иткәнләр (чакырганнар) вә аларга каратып, махсус нотык да сөйләгәнләр иде.

Бу истикъляльчеләрнең (бәйсезлек өчен көрәшүчеләрнең) ул вакытдагы мөрәҗәгатьләренә Керенский үзенең мәҗмугасының (журналының) 28 нче санында (23 май) «Сепаратистларда» мәүзугында бер мәкалә язып, җавап биргән вә бу әфәнделәргә бик югарыдан карап, великоруслар исемендән үзенең аңлашу шартларыны имля иткән (куйган) иде. Бу шартларның беренче маддәсе (пункты, статьясы) — великорусларның кораллы баскычы көченә каршы истикъляльчеләрнең корал көче кулланмаулары; икенчесе — великорусларның империализм сәясәтләренә каршы булган көчләр берлә истикъляльчеләрнең мөнәсәбәткә кермәүләре... Кыскасы гына, истикъляльчеләрнең истикъляль дәгъвасындан ваз кичүләре... Украина–Кафкас–Төркестан дустлыгы җәмгыятенең кайбер әгъзаларының мәгънәсез хәрәкәтләренең нәтиҗәсендән яуган бу чыгыш бөтен «Прометей»* җәбһәсендә (берлегендә; блогында) зур бер наразыйлык (ризасызлык) хисе уяткан вә бу мәгънәсез мөнәсәбәтнең киселүе өчен тәдбирләр (чаралар; фикерләр) алынган иде. Керенскийның мәкаләсе дә җавапсыз калдырылган иде. Инде менә тагы шул ук иске с.р.ларның (эсерларның? — *Х.М.*) мәҗмугасында Постников исемендәге бер карт мөхәррир «Сепаратистлар матбугаты» исемендә мәҗмуганың 114 нче номрасында (номерында) озын гына бер мәкалә нәшер итәдер. Постников Прагадагы «Архив русской революции»сенең мөдирләрендән булынганга вә бу мөәссәсә (оешма) бөтен мөһаҗәрәт матбугатын туп-

---

* 1930 елда Ләһстан башкаласы Варшавада Украина, Белоруссия, Идел-Урал, Кырым, Төньяк Кавказ, Төркестан, Грузия, Азәрбайҗан һәм кайбер төбәкләрнең мөһаҗәрәттәге вәкилләре «Прометей» исемле оешма (блок, фронт) төзиләр. Бу берлекнең төп максаты — милләтләрнең бәйсезлеге, азатлыгы өчен көрәш.

ларга иҗтиһад иткәнгә (тырышканга, омтылганда), истикъляльчеләрнең матбугатлары берлә мөхәррир аз-чук (азмы-күпме) танышдыр. Боларның русча чыкмаганларының мәгънәсен, мөндәриҗәсен (эчтәлеген) тәгъкыйб итә алмаса да, боларның төсләрен еллар буе күреп киләдер. Болар арасында ара-сыйра чыккан мөнакашәләрнең (бәхәсләрнең, тартышуларның) русчалы (рус телендәге) Шимали Кафкасия, «Вольное казачество» мәҗмугаларына ингыйкяс иткәнләрендән (чагылганнарыннан) аз-чук мәгълүмат да алып килгәнлеге күренәдер.

Постников мәкаләсене истикъляльче милләтләрнең матбугаты хакында мәгълүмат бирүдән башлыйдыр. Вә бөтен «Прометей» милләтләренең мәҗмуга, гәзитләрен берәм-берәм санап, аз-маз характерларын сөйләп, русча укучысыны тәнвир итәдер (таныштырадыр; агартадыр). Бондан соң боларның эшләре, максадлары хакында фикер йөртергә кичәдер (күчәдер). Постников мәҗмугаларымызның күбесенең исемләрен яңлыш язса да, биргән мәгълүматлары хакыйкатькә шактый якындыр. Фикерләренә килгәндә, бу да рус мөхәррире өчен тәкъдир итмәслек (бәя бирмәслек) түгелдер. Постников Керенский кеби югарыдан карап фикер йөртмидер. Булган эшләрне бар көенчә кабул итеп, үз ноктасындан шуларга кыйммәт куярга телидер. Шул мәсьәләне үзенчә русча хәл итәргә, аңлашырга тырышадыр. Постниковның фикеренчә, Русиядә яшәүче милләтләр арасында сепаратизм (истикъляль агымы) мәсьәләсе сонгый (ясалма) рәвешдә кабартылган уен гына түгелдер, җитди бер хәрәкәтдер. Истикъляльчеләр мөһаҗәрәтдә 28 елдан бирле монтазам (эзлекле, тәртипле) рәвешдә чалышып (көрәшеп, хәрәкәт итеп) киләләр. Ун елга якын зур бер сәбат (ныклык; даимилек) берлә үзләренең истикъляль фикерләренең тәрҗемане әфкяре («гәүдәләндерүче», «чагылдыручы»; «тылмачы» мәгънәләрендә. — *Х.М.*) матбугатларын дәвам итдерәләр. Бу истикъляльче (азатлык, бәйсезлек өчен көрәшүче) милләтләрнең [Украина, Гөрҗи (Грузия), Әрмәни, Азәри, Шимали Кафкас, Төркестан, Идел-Урал, Кырым, калмыклар, казачиларның] үз араларында идеоложи (идеологик) аңлашмалары да бардыр. Боларның барысы да великорус халкына дошманлыкда берләшәләр, истикъляльчелек фикерләрендән һичбер тәнзилять (ташлама, чигенү) ясауга разый булмаулары берлә фикри берлектә алып баралар. Боларның берлекләренең тәрҗемане әфкяре булып Парижда французча «Прометей» мәҗмугасы чыгарыладыр. Истикъляльчеләр Аурупаның төрле дәүләтләрендә үзләренә ярдәмчеләр дә табып алганлар, болар Русия империясенең дошманлары арасындан үзләренә арка таянaчак, истикъляльләренә ярдәм итәчәк көч табуны һичбер гөнаһка саймыйлар (санамыйлар). Төрле дәүләтләрнең СССРга каршы төр-

ле сәясәтләрендән истифадә итәргә (файдаланырга) генә тырышалар. Истикъляльчеләр СССР берлә аларга (ягъни Совет дәүләтенә) хилаф (каршы) булган дәүләтләрнең иртә-кич сугышка керешүләренә ышаналар вә шул сугышларга зур өмид баглыйлар вә ачыкдан-ачык үзләренең халыкларының большевиклар берлә сугышучы, үзләренең милләтләренең котылышына сәбәп булучы дәүләтләр берлә бергә булачакларын игълан итәләр.

Истикъляльчеләрнең рус культурасына караулары да дустча түгелдер. Кайберләре мәҗмугаларын русча чыгаралар да, руслыкга дошманлыкларын яшерүне һичбер кирәкле тапмыйлар вә һәрбер җай килгәндә урыс сәясәтен генә түгел, рус культурын да тәнкыйть итәләр. Русиядә яшәүче милләтләр арасында сепаратизм хәрәкәте җитдидер. Аның күтәргән истикъляль дәгъвасы катгыйдыр, шуңарга 1917 елгы Русия ихтиляле (революциясе; фетнәсе) авыл халкын йир берлә тәэмин шигаре (байрагы; лозунгысы) астында башланган булса, киләчәкдәге Русия ихтиляле (большевик егылганда) милләтләрнең хокукын тану, Русиядә милли мәсьәләләрне хәл кылу шигаре астында дәвам итәчәкдер.

## «Милли сафлары... гранит ташы кеби»

Финляндия хакында сүз чыктымы, безнең җавапларыбыз, компьютерга салынгандай, әзер һәм стандарт иде: бу ил элек «безнең җир», ягъни Россия составында булган. Октябрь инкыйлабы, Ленин үзе аңа мөстәкыйльлек биргән. Әмма Финляндиянең буржуаз хөкүмәте моның кадерен белмәгән: реакцион, бераздан фашистик сәясәт уздырган, СССРга, аеруча «революция бишеге» Ленинградка, куркыныч тудырган, безнең Уралга кадәрге җирләрне яулап алырга омтылган. Шуның нәтиҗәсендә 1939 елгы кышкы «фин сугышы» башланган һәм ул Кызыл Армиянең «данлы җиңүе» белән төгәлләнгән. Гаделлек тантана итеп, СССР үзенең «элеккеге» җирләрен кире кайтарып алган...

Совет мәктәбе, пропаганда чаралары ярдәмендә Финляндия хакында формалашкан мондый стереотип традицион күзаллау бездә озак еллар яшәде һәм, кызганыч ки, әле хәзер дә шактый дәрәҗәдә яшәвен дәвам итә. Әмма соңгы берничә елда күп кенә аксиоматик карашлар, күнегелгән күзаллаулар тарихи фактлар, чынбарлыктагы вакыйгалар белән янәдән чагыштырыла башлады һәм нәтиҗәдә безнең шактый гына инанган нәрсәләребезнең хакыйкатьтән ерак яисә берьяклы булуы күренде. Финнар белән дә эш шулай торган икән.

Тарихи тәҗрибә шуны раслый: бер генә империя дә үз кулы астындагы халыкларга үзе теләп ирек бирми, һәр милләт, һәр халык аны яулап, көрәшеп ала. «Үзәк» исә, башка чарасы калмагач, тешен шыгырдатып булса да, бу хәлгә ризалык бирергә мәҗбүр була. Финляндия-Россия мөнәсәбәтләре дә нәкъ әнә шул тарихи тәҗрибәнең бер мисалы. Финнар азатлыкны үзләре яулап алалар. Россия, Мәскәү хакимияте моны булдырмас өчен әллә нинди чаралар куллана, интригалар оештыра. Финнарның Россиядән башка (ике ай, бер ел... да) яши алмаячаклары хакында фикерләр таратыла. (Хәзер дә еш ишетелә торган таныш сүзләр.) Әмма Финляндия халкы үзенең бәйсезлеген саклау юлында Суоми җирендәге «гранит ташы кеби» нык тора.

3 миллион ярым халыклы кечерәк кенә ил СССР кебек гигант империягә сугыш куркынычы тудырамы соң инде?! Бу — әкият! Чынлыкта исә 1939 елгы (дөресрәге, 30.XI.1939–12.III.1940) «фин сугышы»ның башлану сәбәпләре, нигездә, Мәскәү сәясәтенә бәйле булган. Билгеле ки, нәкъ шушы вакытларда Латвия, Литва, Эстония, Көнбатыш Украина, Бессарабия, Көнбатыш Белоруссия, «халыкка каршы» режимыннан «азат ителеп», «ирекле» рәвештә СССРга кушыла. Финляндия өчен дә шундый язмыш хәзерләнгән була. Дәвамлы хәзерлек, җитди репетицияләр узган махсус отрядлар О.Куусинен җитәкчелегендә тантаналы рәвештә Һельсинкига керергә тиеш була. Әмма фин халкының үз бәйсезлеген яклап, бердәм рәвештә көрәшкә күтәрелүе Мәскәү хакимиятенең тиз җиңүгә корылган планнарын җимерә, «данлы» Кызыл Армия төртелеп кала. Бары күпләгән резервистларны чакыру ярдәмендә дүрт айдан соң гына СССР бу сугышта өлешчә үз максатына ирешә. Финляндия җиңелеп, бер өлеш җирләрен югалтса да, үзенең мөстәкыйльлеген саклап кала. Бу кирәксез сугыш һәр ике якка да бик кыйбатка төшә: берничә йөз мең кеше һәлак була: һәм Финляндиягә, һәм СССРга матди яктан күп зыян килә. Кайберәүләр «фин сугышы» СССР өчен Бөек Ватан сугышына хәзерлекнең «генераль репетициясе» дә булды, дип әйтәләр. Әмма мондый фикердә, минем уемча, кешелексезлек моменты бар. Чөнки ул Финляндия–СССР арасындагы сугышны аклауга, зарури күренеш итеп күрсәтүгә корылган.

Ленинградтан 30–40 чакрым көнбатышта кечерәк кенә Сестрорецк каласы бар. Анда авыруларны дәвалау өчен яхшы гына реабилитация үзәге урнашкан. 1989–1990 елларда миңа шунда кызым авырган чакта берничә мәртәбә булырга туры килде. Мин шул тирәдәге кешеләр белән очраштым, кайбер элеккеге «ятрак» корылмаларны карап йөрдем. Баксаң, элек чик шул тирәдән узган икән. Шундагы халык та аны «фин

җире» дип йөртә. Ә инде Россия составындагы хәзерге Выборг — ул да элеккеге, ягъни 1939 елгы сугышка кадәрге фин шәһәре Виипури. Анда күп кенә суомилыларның асыл ватаннары, ата-аналарының, әби-бабаларының зияратлары...

Без хәзер генә белеп бара торган күп кенә хакыйкатьләр кайбер милләттәшләргә электән үк мәгълүм булган икән. Гаяз Исхакыйның «Финляндиядә» мәкаләсе — шуның ачык мисалы.

Бөек әдипнең Октябрь инкыйлабына кадәр дә, аннан соң да Финляндиягә кат-кат килүе, бу илдәге милләттәшләребез белән тыгыз мөнәсәбәттә торуы хакында инде мин матбугатта язып чыккан идем. Биредә бары шуны гына әйтәм: халыкара иҗтимагый-сәяси тормышның үзәгендә кайнаган Гаяз Исхакый Суомины яхшы белгән. Әмма бу мәкаләсендә ул илнең тарихи, этнографик, икътисади, мәдәни якларына бик кереп тормый, аны барыннан да элек мәсьәләнең сәяси ягы кызыксындыра.

Автор Финляндия дәүләтенең үз азатлыгы, бәйсезлеге өчен авыр көрәш алып баруын, Мәскәү хакимиятенең финнарга каршы корган интригаларын яктырта. Мәкалә 1937 елда язылган. Әмма анда инде без 1939 елда кабыначак «фин сугышы»ның чаткыларын, төп сәбәпләрен дә ачык күрәбез.

Милләтләр ирекле, бәйсез яшәргә тиеш. Бары шунда гына кеше чагыштырмача бәхеткә ирешә ала. Бу фикер — Гаяз Исхакыйның иманы, көрәш кредосы. Ул ляһләрнең (полякларның), финнарның ирек алуын чын күңелдән котлый.

Бөек әдип, нәрсә хакында гына язмасын, аның фикере үз халкының, төркиләрнең язмышы, азатлык өчен көрәше белән бәйле. Бу мәкаләдә дә ул ачык күренә. Ни өчен финнар үз ирекләрен саклап кала алдылар? Чөнки алар милләт мәнфәгатьләрен, бердәмлекне үзәккә куеп эш иттеләр, милли рухта тәрбияләнгән гаскәр булдырдылар. Авторның элеккеге Россия империясе җирлегендә төзелгән яисә корылып килгән Азәрбайҗан, Төньяк Кавказ, Идел-Урал дәүләтләренең җиңелү сәбәпләре хакында куйган риторик сораулары бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый.

Гаяз Исхакый Мәскәү хакимиятенең милли сәясәтен кискен фаш итә, аның алдауга, сафсатага корылуын һәр мәкаләсендә диярлек күрсәтә.

Мәскәү сәясәтенең бер үзенчәлеге шунда: ул, башка халыкларны үзенә бәйле тотар өчен, еш кына турыдан-туры түгел, ә милли мәнфәгатьләрен саткан кешеләр ярдәмендә, алар күләгәсе астында эш итә. Казан ханлыгы чорыннан, Шаһгалиләрдән килә торган бу алым хәзер дә Балтыйк, Днестр буйларында, Кавказда һәм кайбер башка төбәкләрдә кулланыла. Баб-

рак Кармаль, Нәҗибулла, элеккеге социалистик системаның күп кенә сәяси әһелләре дә Мәскәү катнашында хакимияткә килеп киткән кешеләр. Сталин режимы хәтта Коминтерн кебек халыкара оешмаларны да максатларына җигә. Бу алым Финляндиягә каршы да оста кулланыла. Чыгышы белән финлы Отто Куусиненның (1881–1964) Коминтерн лидерларыннан берсе булуы да күп нәрсә хакында сөйли.

Гаяз Исхакыйның чит мәмләкәтләрдәге милләттәшләребезгә карашы да гыйбрәтле. Ул аларның иртәме-соңмы туган җирләренә кайтасыларына ышана. Ирекле, азат Идел-Урал җөмһүриятен төзү өчен бөек әдип үз милләттәшләрен алдан ук рухи яктан тәрбияләргә, хәзерләргә омтыла, Финляндия язмышы мисалында үз укучыларына гыйбрәтле сабак бирергә тырыша.

Гаяз Исхакыйның «Финляндиядә» дигән мәкаләсе — безнең өчен дә, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «тарихи дәрес».

*1993*

## Финляндиядә*

*Гаяз Исхакый*

Русиягә буйсынырга мәҗбүр булган милләтләрнең истикъляльләре (азатлыклары, бәйсезлекләре), милли хокуклары өчен тартышуларында ляһләрдән (поляклардан) соң финнар киләләр. Ләһләрнең истикъляль тартышлары күзләрне камаштырырлык бик күп тарихи вакыйгалар берлә бөтен дөньяның хөррият сөйгәннәренең дикъкатене җәлеп итеп килеп, Ләһстан истикъляль мәсьәләсен инсани бер мәсьәлә төсенә куя белгән булса, финнарның үз милли хокукларын саклауда сәбатлелекләре (ныклыклары, тотрыклы булулары) милли хокукларын русның аяк астына таптатмас өчен милли сафлары башында мәмләкәтләрендәге гранит ташы кеби алган вазгыятьләрендә (хәлләрендә) кыймылдамаенча тора белүләре кеч-кенә бу милләткә каршы дөньяның киң катлавында хөрмәт җирләштергәндер. Бу халыкның җирен, суын, илен сакларлык үсеп җиткәнлеге канәгатен дуст-дошманда иман хәленә китергәндер. Киң дөньяның бу ике халыкка шул күз берлә каравы дөнья сугышының нәтиҗәсендә милли дәүләтләр корырга бу ике милләткә дә зур ярдәм иткәндер. Боларның астан-өстән генә корылган милли дәүләтләре дә бик тиз көн эчендә бәйнәлмиләл сахәдә (халыкара мәйданда) танылып, һичбер

* Яңа милли юл. — 1937. — № 4 (109). — 1–6 б.

тышкы мәшәкатьсез Аурупаның дәүләтләре арасына кереп китә алгандыр.

Финляндия җәгъръафый вазгыяте берлә Русиянең басуы, таптавына бик уңай бер өлкә булганга, Русиянең сугыштан калган вак-төяк Балтыйк флоты да Финляндиянең бөтен зур шәһәрләрен үзенең тубы астында тота белгәнгә, 1918 еллардагы истикъляль сугышлары финнар өчен бик авыр булгандыр. Хосусан ул вакытларда финнар арасында коммунизм фикере керә башлаганга, рус империализмын ташучы рус большевиклыгының, фин коммунистына ярдәм сылтавы берлә, Финляндиягә бик күпләп кызыл рус гаскәрен күндереп, сугышка катышырга имкян (мөмкинлек) бирү истикъляль эшен бик читенләштергәндер. Шул вазгыять ул вакыттагы фин хөкүмәтенең башы Свинхувудны* Алман дәүләтенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткәндер. Алманиянең вакытында ирешүе кызыл русларның котларын очырып, аларны көтү кеби качырырга мәҗбүр иткән. Алманиядә гаскәри тәрбия күргән вә җаны-тәне берлә һәрбер төрле фидакярлегенә хәзер финнарның милли гаскәрләренә русларны себереп ыргытуны җиңелләткәндер. Совет Русиясе дә теләр-теләмәс Финляндиянең истикъляlen танырга мәҗбүр булган бу көнгә инде 17–18 ел вакыт үтеп киткәндер.

Шул дәвердә рус большевигы һәртөрле форсаттан файдаланып, Финляндиянең эчендә төрле-төрле интригалар ясавында дәвам итсә дә, фин халкы үзенең истикъляlen саклап килеп, үзенең аерым дәүләтлек вазгыятен көннән-көн куәтләндерә килгәндер. Финнарның элгәрегә караганда әллә ничә мәртәбә баюлары Финляндиянең кирәк Балтыйк дәүләтләре тезмәсендә, кирәк Скандинавия дәүләтләре зөмрәсендә (төркемендә) зур бер икътисади, сәяси гамил (фактор, дәрәҗәле көч) булып өлгерүе фәкать вакытында истикъляльләрен алып калуларының җимешедер. Финляндиянең бүгенге көндә яши торган милли тормышының байлыгы, аның икътисад, мәдәният ягыннан көннән-көн үсүе милли истикъляль казанунын халыклар өчен никадәр зур бәхет, никадәр зур бәрәкәт икәнен күрсәтә торган аяклы дәлилдер. Хосусан 3 миллион ярымлы кечкенә фин халкының бүгенге бай-мул тормыш Совет эчендә калырга мәҗбүр булган 35 миллионлы төрк (төрки) халкының ач-ялангач, ертык-портык тормышы берлә чагыштырылса, милләтләр өчен истикъляльнең никадәр зур байлык икәнлеге күзне камаштырырлык итеп күренеп

---

* Свинхувуд Пер Эвенд (1861–1944) — Финляндиянең күренекле дәүләт вә сәяси эшлеклесе. Милли азатлык хәрәкәтендә катнашканы өчен Россия дәүләте аны 1914 елда Себергә сөргенгә дә җибәрә. Свинхувуд — Финляндиянең тәүге премьер-министры. 1931–1937 елларда — илнең президенты.

китәдер. Финнарның истикъляль тартышулары гына түгел, аларның корган дәүләтләрен саклый белүләрендә дә безгә дәрес булырга бик күп гыйбрәтле вакыйгалар тулыдыр.

Финляндия берлә бер чактарак истикъялен игълан иткән безнең кардәшләремез Азәрбайҗан төрекләренә, Шимали кафкаслыларга ни өчен истикъляльләрен бүгенгә кадәр алып килергә насыйп булмады, финнарга, алардан да кечкенә эстоннарга бүгенгә кадәр мөстәкыйль дәүләтчелекләрен саклап килергә мөмкин булды? Бу мәсьәлә дә, әлбәттә, җәгъpафый вазгыятьнең аермасы, бигрәк тә русларны бик кызыктыра торган Баку, Грозныйдагы нефть коеларының байлыгы бик зур роль уйнагандыр: рус большевигын бөтен көче-куәте берлә Кафкасны кулда итәргә тырыштыргандыр. Ләкин шул бай мәмләкәтемезне саклау өчен, шуны үз кулымызда калдырыр өчен, без төркләр, гомумән, азәри төркләре, Шимали Кафкас мөселманнары хосусан үзләренә йөкләнгән милли бурычны финнар кадәр үти белделәрме? Финнар истикъляль тартышуларына Алманиядә үгрәнгән йәгирләрене (егерьләрене, гаскәриләрене) оеткы итеп, күңелле (ирекле) бер милли гаскәр мәйданга китерделәр. Вә бу күңелле гаскәргә фин халкының, Финляндия шведының (Суоминың 6–7 процент халкын шведлар тәшкил итә) бай катлавы, аңлы катлавы тәмамән катышты. Бу гаскәрне йөз меңгә кадәр җиткереп, шуның куәте берлә истикъляльне алганның соңында да таралып китмәделәр, әле тәһлекә (һәлакәт, куркыныч) бетмәгәнне аңлап, болар дәүләтнең һәрбер зәгыйфь ноктасында нәүбәт сакладылар, каравылда тордылар, һәрбер кирәкле милли тартышка бил баглап, кул сызганып хәзер булдылар. Гаскәри бер милләтнең баласы булган азәри төрке берлә дөньяны шаккатыргыч Шәйх Шамил вакыйгаларын яшәткән Шимали кафкаслы диндәшләремез ни диеп шундый бер милли гаскәр мәйданга китерә алмадылар? Ни диеп азәри кардәшләремезнең бер-ике елда тугдырган яшь гаскәрләре Кафкасны истиля итәр (басып алыр) өчен килә торган рус гаскәренең кулларына бәйләгән айлы-йолдызлы чүпрәкләренә алданып, тарихи дошманны дуст диеп уйладылар? Ни диеп Шимали Кафкас мөселманының үз көче берлә тугдырган гаскәре бүген, Деникин ягына чыгып, кызыл руслар берлә сугышты. Икенче көнне, кызыл руслар тарафына күчеп, ак руслар берлә кырылышты? Ник бу шәйх Шамил угылларының гаскәре рус дошманының төрле төстәгесеннән бай илен, суын, җирен сакларга бил баглап, саф башында гына калмады? Безнең бу сөальләремезгә кафкаслы кардәшләремез ник Идел-Уралның Бессарабия җәбһәсенә (фронтына) тупланган 35–40 меңлек гаскәре Кырымга Севастополь большевиклары һөҗүм иткәндә, Кырымлы кардәшләренә ярдәмгә ашыкмады? Ник Украина истикъляльчеләрен

Киевтан куып чыгарыр өчен Зәки Вәлиди «башкорт гаскәре» берлә большевикларга ярдәмгә ашыкты? Ник Юденич гаскәреннән Петербургны саклап калу өчен шул ук «батыр» 25 меңлек татар-башкорт яшьлеге (яшьләре) ярдәм итте диярлек. Бу сөальләрнең, бәлки, барысына да бердән җавап бирергә кирәктер. Тугрысы, бу сөальләргә хәзер тормыш үзе җавабын бирде. Безнең 35 миллион төрк халкының бүгенге көндә большевик зинданында ертык-портык яшәргә мәҗбүр булуы үзеннән-үзе шул хаталарымыз, шул гөнаһларымызның нәтиҗәсе түгелме? Фин милләтчесе, финның аңлы бүлеге милли гаскәрне ясау берлә генә калмады, аны милли рухта тәрбия итеп, аны милли кирәк өчен генә куллана торган аңлы бер милләт коралы хәленә китерә алды. Ул аны Юденичка да өмәгә (биредә «ярдәмгә» мәгънәсендә) җибәрмәде. Ул аны тел бистәсе кызылларның алдауларына, ялганнарына да бирелеп китүдән өстен итә алды. Ул, истикълялен алып, хөкүмәт мөәссәсәләренең (учреждениеләренең) башына үзенең милли байрагын күтәргәч тә, сугыш бетте, дип ашыгып өенә чапмады. Күптән күрмәдем, сагындым, диеп, бала-чагасы, хатынының кочагына атылмады. Ул саф башында калды. Милли байракның каравылчысы булып, иске бабалары кеби гранит ташы булып баскан истикъляль сафында калды.

Шул милли фин гаскәре, инде Финляндия искикъляль алуына 18 ел үтеп киткән булса да, бүген дә таралып китмәгән. Советларның матур сүзләренә, күршеләрен йоклатыр өчен сөйли торган солыхчылык хәрәкәтен тикшереп, җаннары, каннары берлә илләрен, истикъляль аркасында кулда иткән байлыкларын сакларга хәзер торалар. Финляндиядә икътисади кризис вакытында Коминтерн, Финляндиянең читкә сата торган агач эшләрен туктатыр өчен бик күп миллионнар акча түгеп, агач эшчеләре арасында тугыз ай эш ташлау дәвам иттерде вә эшсезлек, бушлык нәтиҗәсендә бозылган фин эшчесеннән милләтсез сатлык кешеләрне табып алып, фин коммунизмын көчләндерде. Тыштан ала алмаган Финляндияне эчтән черетергә, зәгыйфьләндерергә кереште. Финляндиянең милли вөҗданы буңар чыдый алмады. Лаппуа (Лаппи — илнең төньяк өлешендәге өлкә. — Х.М.) дигән җирнең авыл халыклары күтәрелеп, гаскәри тәртип алып, Һельсинкига хәрәкәт иттеләр. Хөкүмәттән коммунист фиркасен таратуны, коммунист пропагандасын бетерүне таләп иттеләр*. Финляндиянең кортылыш гаскәре Лаппуа тарафына кичте (күчте). Коммунизм пропагандасы Финляндиядә бетерелде. Әүвәлге — Финляндияне

* Совет фәнендә бу хәрәкәт тискәре бәяләнеп, «фашистик» эпитеты белән аталды. (Большая Советская Энциклопедия, 1977. — Т. 27. — С. 1342.)

коткаручы — Свинхувуд рәисе җөмһүр (җөмһүрият башлыгы) итеп сайланылды. Бу тынычлык эчендә Финляндия тагын баеды, тагын куәтләнде. Милли истикъляль агымы хаким вазгыять алды. Аның эчтән, тыштан көчлеләнүе Советларны куркытырга башлады. Алманиядәге коммунизмга каршы көрәш тә фин милләтчеләренә зур бер мәгънәви көч биреп, фин халкында германофиллек хисен куәтләндерде. Шул нисбәттә рус большевик дошманлыгы зурайды, киңәйде.

Коминтерн Финляндиянең үзен-үзе саклау хәрәкәтенә икенче төрле мәгънәләр биреп, аңар фашист исеме тагып, Финляндия берлә Алмания арасында большевикларга каршы гаскәри иттифак (союз, берләшү) булган диеп, сугыштан куркытып, финнар эченә интрига кертте. Сугыш фин тупрагында булачак төсле күрсәтеп, фин чигендә төрле хәрби хәзерлекләр ясаган кеби кыланды. Большевик матбугатында Коминтернның пропагандасында Финляндиягә каршы зур дошманлык планы алып барды. Икенче яктан, Финляндиянең идарәсе йөзләгән милләтчеләрнең кулыннан чыгып, халык җәбһәсе (фронты) рәвешендә чиле-пешле бер идарәгә тапшырылса, Мәскәүнең Финляндиягә каршы булмаячагы кеби тәтиләр күрсәтеп, кызыктырып килде. Финнар берлә шведлар арасындагы милли аерманы да интриганың эченә катыштырып, нәтиҗәдә бу елгы рәисе җөмһүр сайлауларында Финляндияне тугдыручы, Финляндияне мөстәкыйль бер дәүләт итеп яшәтүче буржуа фиркаләре (партияләре) дәүләтнең анахтында (сенатында) аерылыштылар. Һичбере үз башына дәүләт машинасын алып барырлык күпчелек җыя алмаенча, Финляндия социал-демократларының теләге буенча хәрәкәт итәргә мәҗбүр булдылар. Нәтиҗәдә Финляндиянең истикъляль казануында вә аның бүгенге байлыгын, муллыгын, тынычлыгын тугдыруда бик зур роль уйнаган сабикъ (элеккеге) рәисе җөмһүр Свинхувуд фиркасе җиңелде вә үзе рәисе җөмһүрлеккә сайлана алмады. Либераллар, социал-демократлар, авыл халкы (Лаппуага башкасы) фиркаләре үз кандидатларын үткәрделәр вә Финляндиядә Франциядәге халык җәбһәсе хөкүмәте кеби бер хөкүмәт кордылар. Бу хөкүмәтнең иң көчле сул канаты кыйбласын Мәскәү итенгән социал-демокартлар булганга, табигый буларак, Финляндиянең эчке вә тышкы эшләрендә үзгәрешләр булыначактыр. Фәкать Финляндиянең истикълялен алышучы, аны бүгенгә кадәр саклаучы милләтчеләрнең гаскәрләре һәрвакыт милли вазыйфаларын үтәргә хәзер булганга, финнарның руслар кулында уенчык булып, Испаниядәге кеби илдәшләр сугышына мәйдан бирмәячәкләрдер. Фин милләтенең күпчелеге дә истикъляльнең биргән бәрәкәтенә, байлыгына чыдый алмавыннан килгән бу уенның ачылы-төчеле җимешләрен аз-маз татып калып, элекке сәламәтлек, тынычлык юлына кайтачактыр.

Менә шул 18–19 ел эчендә истикъллялен алып, дәүләтен халыкчылык нигезендә корып өлгергән Финляндиядә безнең Идел-Урал мөһаҗирлегенең бер кыйсме яшәп киләдер, һәм дә уллыкча монтазам (тәртипле, тотрыклы) бер милли тормыш төзеп, милли, мәдәни барлыгымызны саклауга тырышып киләдер. Мондагы милләтчеләремез мөстәкыйль Финляндиянең тууын, үсүен, баюын, тазаруын үз күзе берлә күреп килгәнгә, мондагы гыйбрәтләр, мондагы тарихи дәресләрдән болар файдалана алалармы вә киләчәктә илемездә эшкә яраклык, туган илемезгә фин мәдәниятеннән, фин истикъляль тартышында финнарның дәүләтләрен саклый белүләреннән тәҗрибәләр хәзерли белделәрме? Беләләрме? Монда инде шактый гына зур яшьлегемез (яшьләребез) өлгергәнгә, болар милли истикъллялемезне бина итүдә эшкә яраклы милли материал хәленә килә алдылармы? Бу сөальләрне җентекләүне киләсе мәкаләгә калдырамыз.

## Гаяз Исхакый бәк Тампереда*

*Мәхрүсә Вафа*

> Үткәнебезнең мәшһүр шәхесе Гаяз Исхакыйның тормышына, иҗатына кагылышлы яңа сәхифәләр ачыла тора. Мәхрүсә Вафаның бу ике мәкаләсе — шуның бер мисалы.
>
> *Х.Миңнегулов*
> *1998*

Гыйнвар башында (1937 елның) мөхтәрәм юлбашчымыз вә әдибемез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабларын Финляндиядә тәшриф итделәр (хөрмәт күрсәттеләр). Элек Һельсинкида байтак торыб, кунак булып, анда яшәүче төрк-татарларга һәм Һельсинки «Прометә» клубы әгъзаларына кыйммәтле конферанслар (лекцияләр) биргәннең соңында, Тамперега килде. Истасионда (вокзалда, станциядә) Тампере төрк-татарлары тарафындан каршы алынып, барыбыз да Гаяз әфәндене күреп, чиксез шатландык. Аның Ерак Шәрыкда вакытда хәстәләнүе барымызны да тирән уйда калдырган иде. Хәзер арамызда һаман шад һәм сәламәт Гаяз әфәндене күрү бөтенләй күңелемезне күтәреп җибәрде. Гаяз әфәнде берничә көн барыбызда да кунак булгач, Тампере мәктәбенең зур залында өч сәгать сөргән безнең өчен бик кыйммәтле һәм гыйбрәтле бер конферанс бирде. Мәктәб-

* Яңа милли юл. — 1937. — № 3 (108). — 20–22 б.

неӊ залы бөтен милләтдәшләр — ире-хатыны, олысы-кечкенәсе берлә тәмам тулган иде. Мәҗлес мөгаллимебез Гыйбадулла әфәнде тарафыннан ачылганнан соӊында, Гаяз әфәнде, сүзгә башлап, безгә, гомумән, Ерак Шәрык һәм андагы илдәшләребез, аларныӊ эшләгән эшләре, тырышлыклары, фидакарьлекләре хакында гаять тәфсыйльле сурәтдә мәгълүмат бирде. Бөек Нийуппун (Япун?) вә Манжуку (Маньчжурия?) дәүләтләре берлә якындан таныштырды. Безнеӊ Финляндиядә яшәүче төрк-татарларны бик тәэсирле сүзләр берлә эшкә берләшүгә чакырды. Халык тарафыннан бөек бер галака (кызыксыну; мавыгу) берлә тыӊланган бу әһәмиятле конферанс мәҗлесдә хозур булучыларныӊ (катнашучыларныӊ) бик озын кул чабулары вә рәхмәтләре берлә тәмам булды. Соӊрадан мөгаллимебез Гыйбадулла әфәнде халык исемендән Гаяз әфәндегә җандан рәхмәтләр укып, аӊа озын гомер вә сәламәтлек теләп, мәҗлесне ябды. Сәгать сигезенчене яртыда башланган мәҗлес унберләрдә генә бетеп, җыелган халык да өйләренә таралдылар.

## Тампереда милли кичә

*Мәхрүсә Вафа*

Февральнеӊ җидесендә (1937 елныӊ. — *Х.М.*) Финляндиянеӊ Тампере шәһәрендә «Тампере төркләре берлеге»неӊ тәшәббесе (инициативасы) берлә хөрмәтле Гаяз әфәнденеӊ шәрәфенә бер милли кичә тәртиб ителде. Бу кичәдә мөхтәрәм әдибемезнеӊ «Зөләйха» дигән дүрт пәрдәле драмасы сәхнәгә куелды. Кичәдә ике йөздән артык кеше хазир булып (катнашып), Финляндиянеӊ башка шәһәрләрендә яшәүче милләтдәшләребездән дә байтак кеше килгәнләр иде. Гаяз әфәнденеӊ бу милли кичәдә безнеӊ арабызда булуы барыбызныӊ да рухын күтәреп, кичәмезгә аерым бер гүзәллек бирде. Һельсинкида эшләнгән милли кичәгә иштиракъ итүче (катнашучы) яшь милләтдәшләремез дә режиссерлары берлә берлектә хосусый (махсус) бер вагон алып, кичәгә килделәр вә безне ифрат шатландырдылар. Кичә мөгаллимебез Гыйбадулла әфәнде Мортазаныӊ йокыларын калдырып тырышуы һәм оста режиссерлыгы, уйнаучыларныӊ да рольләрен бик тырышып өйрәнүләре вә оста уйнаулары аркасында тәкъдир иделәчәк кадәр яхшы вә күӊелле чыкды. Кичәне «Тампере төркләре берлеге»неӊ хөрмәтле рәисе Гомәр әфәнде Салый килгән кунакларга, биләасса (бигрәк тә) үзенеӊ килүе берлә кичәмезне шәрәфләндергән бөек җитәкчебез Гаяз әфәнде «Хуш килдегез!» сүзләре берлә ачкач, яшьләр тарафыннан төзелгән оркестрда милли көйләребез уйналды. Соӊра сәхнә ачылып, кичә башланды. Беренче кыйсем (бүлек) балалар кыйсеме булып, Тампере төрк-

татар мәктәбендә укучы яшь шәкердләр тарафындан төзелгән хорда милли көйләребез җырланды вә мәктәп шәкердләре төрле гүзәл шигырьләр укыдылар. Мөгаллимебез тарафындан бик яхшы хәзерләнгән бу балалар караучыларда тирән тәэсир калдырыб, бик озак алкышландылар. Балалар бүлеге тәмам булгач, кичәнең театр кыйсеме башланды.

«Зөләйха» байтак авыр бер әсәре булса да, безнең аурупалылар шикелле һичбер сәнгать мәктәбе күрмәгән уенга иштиракъ итүче (катнашучы) яшьләребез бөтенесе бик зур осталык берлә алыб бардылар. «Зөләйха» ролен уйнаучы Хәдичә туташ Ходайбирде, Гыймади карт ролендә Гайса әфәнде Хәкимҗан, Петр ролен уйнаучы Лотфулла әфәнде Байбулат бигрәк оста уйнаулары берлә халыкның дикъкатен җәлеп итделәр.

Театр кыйсеме беткәч, хөрмәтле әдибемез Гаяз әфәндегә «Зөләйха» шикелле безнең өчен соң дәрәҗәдә гыйбрәтле вә кыйммәтле бер әсәрне яратып (иҗат итеп), безгә бүгенге шикелле кичәләрне күрергә насыйб иткәне өчен чиксез күб рәхмәтләр укылып, уйнаучылар исемендән чәчәк тәкъдим ителде һәм мәҗлесдә хазир булучылар бар да аякга калкып, Гаяз әфәнденең шәрәфенә өч мәртәбә «Яшә!» дип кычкырдылар.

Соңра Гаяз әфәнде сәхнәгә чыгып, гаять әһәмиятле бер нотык сөйләп, бондый милли кичәләрнең еш-еш эшләнеп торуы тиеш икәнлеген һәм аның безгә файдаларын, әһәмиятен аңлатды вә уйнаучыларга һәм башкаручыларга самими рәхмәтләрен укып, үзенең бу кичәдән мәмнүн (канәгать) калганлыгын белдерде вә бик озак алкышланды.

Бондан соңра Һельсинкидан килгән кунаклардан Вәли Әхмәд хәзрәт Хәким, Ибраһим Гарифулла, Гайса әфәнде Бәшәр (Бәшир ?) сүз алып, үзләренең бу кичәдән мәмнүн (шат) булуларын, рәхмәт вә тәкъдирләрен (хуплауларын) белдерделәр. Соңрадан мөгаллимебез Гыйбадулла әфәнде, сәхнәгә чыгып, бондай кичәләр эшләнгән вакытда китабсызлыкның барыбыз өчен дә никадәр мөшкел, никадәр уңайсыз бер хәл икәнлеген аңлап, бу кичәнең хатирәсе улмак үзрә Гаяз әфәнденең язылып да басылмаган әсәрләрендән берсенең басылып чыгуы өчен кичәдә хазир булганлардан ихтыярый акча җыюны тәклиф итде (үтенде). Бу барыбыз өчен дә файдалы тәклиф хазирун (катнашучылар) тарафындан шадлык берлә кабул ителде вә шунда ук бу хәерле эш өчен 4400 фин маркасы акча җыелды. Шуның берлә кичәнең рәсми кыйсеме тәмам булыб, халык да бик мәмнүн булып, өйләренә тарала башладылар.

Һельсинкидан килгән яшьләр «Тампере төркләре берлеге» тарафындан чәйгә чакырылган булганга күрә, вакыт кич дә булса (кич булса да. — *Х.М.*), яшьләр хөрмәтле Гаяз әфәнде дә араларында булган хәлдә соңга калдылар. Яшьләр чәй янында

төрле файдалы фикерләр алышыб, бик күңелле итдереп сөйләшеп утырганның соңында, алтыда башлаган кичә төнен икедә генә тәмам булды.

Тампереда эшләнгән милли кичәдә хөрмәтле әдибемез Гаяз әфәнденең басылмаган әсәрләрендән «Дулкынлар эчендә» исемле драмасын басдыру өчен һиммәтдә булынучы (катнашкан) ханым вә әфәнделәрнең исемләре:

*1. Гыймад Җәмаледдин*
*2. Гомәр Салый*
*3. Лотфулла Җәмаледдин гаиләсендән*
*4. Зиннәт Вафа*
*5. Ногман Насыйбулла*
*6. Гафур Билаледдин*
*7. Фатих Закир*
*8. Сәмигулла Вафа*
*9. Габдерәхим яшьләре*
*10. Зөләйха ханым Салый*
*11. Әнвәр Җәмаледдин*
*12. Рокыя туташ Сәлах*
*13. Бәнат ханым Хәмидулла*
*14. Корбан Гали*

## Гаяз Исхакый фаразлары

Сәгыйть Рәмиевкә язган хатында Габдулла Тукай болай дигән: «*Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит*». Бөек шагыйрьнең бу сүзләре XX йөзнең беренче яртысында иҗат иткән Галимҗан Ибраһимов, Садрый Максуди, Фатих Әмирхан, Фатих Сәйфи-Казанлы, Афзал Таһиров һәм күп кенә башка каләм әһелләренең эшчәнлегенә дә кагыла. Чөнки заман аеруча милли-азатлык хәрәкәте күңелендә милли тойгы булган һәр намуслы әдипнең төрле тармакларда эшләвен таләп итте.

Тукай сүзләрен бигрәк тә Гаяз Исхакыйга карата куллану уңышлы булыр иде.

Гаяз Исхакый эшчәнлегенең бер үзенчәлеге янә шунда: ул халык тормышында туып, бөреләнеп кенә килгән мәсьәләләрне алдан ук тотып ала, үстерә, вакытны үткән, хәзерге, киләчәк яссылыгында карый белә; аның әсәрләрендә, куелган проблемаларга нисбәтле рәвештә, тормыш агышының ышандырырлык җанлы картинасы тудырыла. Ләкин әдип моның белән

генә чикләнми, үзенең уй-ниятләрен гамәлгә ашыру өчен диңгез кебек шаулы тормышта актив көрәш тә алып бара: гәзит-журналлар («Таң йолдызы», «Ил», «Сүз», «Төрк йорды», «Яңа милли юл», «Милли байрак» һ.б.) чыгара, төрле оешмалар төзи (мәсәлән, «Прометей»), корылтайлар уздыра, күпсанлы очрашулар үткәрә. Бетмәс-төкәнмәс энергияле, талантлы бу шәхес, кайда гына булмасын һәм ни генә эшләмәсен, көрәшнең алгы сафында тора һәм вакыйга-хәлләргә көчле йогынты ясый. Аның идеалы — һәр халыкның азат, иркен яшәве. Нәкъ менә шуңа күрә дә ул татарның гына түгел, ә чит илләрдә яшәүче Төркестан, Кавказ, Кырым, Украина милли-азатлык хәрәкәте вәкилләренең дә танылган юлбашчысына әверелә. Моны 1937 елда әдип иҗатының 40 еллыгына багышлап Харбин, Мукден, Токио, Таллинн, Тампере, Берлин, Варшава һәм башка шәһәрләрдә уздырылган юбилей кичәләре дә раслап тора.

Шунысы гыйбрәтле: Гаяз Исхакыйны милли-азатлык көрәшеннән зиндан-сөргеннәр дә, эмиграция дә, төрле эзәрлекләүләр, ялалар да — берсе дә туктата алмады, ул үз идеалына тугры калды, үз халкына бәйсезлек киләсенә инанган килеш вафат булды.

Иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышта вакытлы матбугатның роле зур булуын тирәнтен аңлап, Гаяз Исхакый гомере буе публицистиканы үзенең даими юлдашы итте. Аның гаҗәеп күптөрле темаларга язылган мәкаләләренә актуальлек, масштаблык, логикалылык һәм тел-стиль үтемлелеге хас. Бер генә мисал: ул дөньяның 30 нчы еллардагы сәяси халәтен дулкынлы бер диңгез, илләрне кораб, ә мәмләкәт башлыкларын капитаннар белән тиңли. Нәтиҗәдә бу сурәт-картина укучыга нык тәэсир итә.

1935 елда язылган **«Бүгенге вазгыять вә безнең вазыйфамыз»** мәкаләсендә Гаяз Исхакый шул чордагы дөнья тормышының тотрыксызлыгын, галәм сугышының котылгысызлыгын күрсәтә. *«Бәхетсезлеккә каршы,* — ди автор, — *хәзерге көннәрдә фәүкылгадә вакыйганы бөтен дөнья халкы сугышдан көтә, милләтләрнең берсенә-берсе каршы килеп, берсе икенчесенең мең еллар буе тудырган мәдәниятен, байлыгын җимерүдә яхшылыкка таба үзгәрешен көтә».* Сәяси, икътисади, халыкара каршылыкларны сугыш ярдәмендә генә хәл итәргә омтылыш — «агулы», «хата» фикер. Ул гомумкешелек мәдәнияте, әхлагы өчен «зарарлы». Әмма «бу сугышны тотып калачак, аңарга киртә булып торачак хәзерге көндә һичбер матди-мәгънәви көч юкдыр. Иртә-кич бу сугыш башланачакдыр» һәм ул дөнья өчен афәт булачактыр. Гаяз Исхакый өчен бу сугышта СССРның катнашуы бәхәссез. (Гадәттә, бездә бу фикерне Р.Зоргега бәйләп карыйлар.) Мәкалә

авторы язуынча, бу бөтендөнья сугышы «кан вә күз яше эчендә» яңа бер чынбарлык, «яңа бер барлык» тудырачак.

Гаяз Исхакыйны шушындый афәтле вакыт агышында барыннан да элек төрк-татар язмышы борчый. Автор фикеренчә, аның милләттәшләре дә СССР белән берлектә бу сугышка тартылачак, димәк, алар да «ватылу-кырылуларга» дучар булачак.

Гаяз Исхакый, дөнья сугышы нәтиҗәсендә СССР хакимияте җимерелеп, анда анархия башланачак, ди. Шул шартларда исә төрки халыкларга мөстәкыйльлек алу мөмкинлеге туачак. Әлбәттә, чынбарлык бу мәсьәләдә әдип фаразының вакыт ягыннан туры килмәвен күрсәтте. Сугыш нәтиҗәсендә Мәскәү үз хакимиятен СССРда гына түгел, ә дөнья күләмендә дә көчәйтүгә ирешә. Әмма, тарих раславынча, империяләр озак яши алмый. СССР, Россия империяләре таралып бара, мөстәкыйль җөмһүриятләр төзелә. Димәк, Гаяз Исхакый әйткәннәр, бераз соңрак булса да, дөрескә чыга.

Мәкалә авторы вазгыятькә анализ ясап кына калмый, алга таба милли бәйсезлек юлында ничек хәрәкәт итү турында да уйлана. Биредә ул дөрес сәясәт уздыруның, акыллы җитәкчелекнең, милли тәрбия эшенең зарурилыгын күрсәтә. Гаяз Исхакый фикеренчә, иң мөһиме — бердәмлек. *«Милли байракны хөрмәтсезләндерергә, милли көчнең берлеген бозарга тырышу,* — ди ул, — *милли хыянәтдер»*.

Язмада төрки халыкларның сәяси тарихы, бурычлары, дөнья вакыйгалары хакында башка мөһим фикерләр дә бар. Мәкаләдә, гәрчә ул моннан ярты гасыр элек язылса да, бүгенге иҗтимагый, сәяси тормышка аваздаш моментлар күп. Классик әдип фаразларының күпчелеге бүген гамәлгә ашты.

*1992*

## Бүгенге вазгыять вә безнең вазыйфамыз*

*Гаяз Исхакый*

Соңгы ел дөньяның сәяси мәвазнәсе (тотрыклылыгы) бетүнең бөтен күзле-күзсезгә күренгән елы булды. Сугышдан соң көчләп, көчләндереп эшләтелгән тынычлык бетде. Үзендән-үзе, дәүләтләрнең бер-берсе берлә аңлашып, уртак мәнфәгатьләр тирәсендә тупланулары тәмамлана алмады. Вә дөнья сәясәте тулкынлы бер диңгез төсен алды. Бонда төрле олуг дәүләтләрнең сәяси капитанлары үзләренең халыкларының ваз-

* Яңа милли юл. — 1935. — № 8 (91). — 1–6 б.

гыятьләренә, үзләренең осталыкларына карап — дәүләт корабларын, әле бер тулкынны, әле бер тулкынны үтеп, идарә итеп килсәләр дә, һичбер зур кораб әле тынычлык ярына килеп, тимер (ягъни якорь) сала алганы юк. Вә һичбер зур дәүләт үзенең киләчәк өч-биш елының да тынычлыгын тәэмин итә алганы юк.

Дөньяда «солых», «тынычлык» өчен әллә никадәр зур-зур күләмдә, дөньяви үлчәүдә сигорт (страховой, яклаучы) компанияләре (җәмгыяте әкьвам ляһи мөхәкәмәсе*, башкалар. — *Г.И.*) ясалган булса да, боларның берсенә дә, беркем дә ышанмаганга, милләтен, ватанын сөйгән һичбер сәяси бу ел тыныч йоклый алмады. Олуг сәясәт диңгезенең тулкынлыгыннан куркып, дәүләт кимәләрен үзләренең милли ярларына бик каты бәйләп тота торган кечкенә дәүләтләр тыныч кеби күренсәләр дә, аларның да дәүләт тормышлары төрле зур дәүләтләрнең икътисади-сәяси вазгыятьләре берлә баглы булмаганга (булганга), аларның да дәүләт ирләре үзләрен тыныч итеп хис итә алмыйлар. Бу рухани тынычсызлык вә бу иртәгегә ышанычсызлык, бөтен дөньяның сату-алу эшләренә бик начар тәэсир ясап, дөньяның икътисади тормышын чыгырыннан чыгарадыр. Һөнәр сәнагатьле (промышленностьлы) мәмләкәтләрдә фабрика-заводларының туктавына, эшсезлекнең күбәюенә сәбәп була вә дәүләтләр эчендә тормышындан наразый (риза булмаган) куәтле эшсезләр гонсырыны (катламын) тудырып, күп милләтләрнең иҗтимагый хәлләрен хәтәр(ә)ле (куркынычлы) бер вазгыятькә куядыр вә боларның барысы бергә җыелып, халыкның күпчелегендә шул вазгыятьнең дәвамына ышанычсызлык йирләшдереп, киләчәген юлга куярлык фәүкылгадә (гадәттән тыш) вакыйганы көтү хиссиятен бөтен эшдә хаким бер хәлгә китерәдер. Бу фәүкылгадәлек урта гасырларда булса, христиан дөньясында хәзрәт Гайсаның иңүе, ислам дөньясында хәзрәт Мәһди (шигый мәзһәбендәге 12 нче имам) чыгуы берлә гәүдәләнеп, халыкны гыйбадәтханәләргә туплар вә халыкның фикеренә зарарсыз тынычландыручы бер агым бирер иде. Бәхетсезлеккә каршы, хәзерге көннәрдә фәүкылгадә вакыйганы бөтен дөнья халкы сугышдан көтә, милләтләрнең берсенә-берсе каршы килеп, миллионлап-миллионлап берсенберсе үтерүендә, берсе икенчесенең мең еллар буе тудырган мәдәниятен, байлыгын җимерүдә яхшылыкка таба үзгәрешен көтә. Бөтен дөнья халкы шул фикер берлә агуланып өлгергәнгә, бу фикер никадәр хата булса да — адәм баласы өчен аның уртак мәдәнияте, уртак әхлакы өчен зарарлы булса да, бу фи-

* «Халыкларның (милләтләрнең) мәнфәгатен яклаучы хөкем органнары» мәгънәсендә.

кер хәзер дөньяда зур бер тормыш гамиле (хәрәкәткә китерүче көче) факторы булып, хикмәтен көндән-көн зурайта, көндән-көн куәтләндерә барадыр. Тиз көндән бу әхвале рухия дөньяның кайсыбер почмагында булса да, сугышның якынлашуына вә шул сугышның киңәюенә сәбәп булачак, дөнья халкы шул авыр бәла-казаны башлангычында коткаручы бер көч итеп, зур бер шадлык берлә каршы алачаклар. Бу сугышны тотып калачак, аңарга киртә булып торачак хәзерге көндә һичбер мадди-мәгънәви көч юкдыр. Иртә-кич бу сугыш башланачакдыр. Дөнья сугышындагы бөтенлекләрне, ватылу-кырылуларны, балалар уены дәрәҗәсенә төшереп, дөнья йөзен кан берлә каплаячакдыр. Бу дөньяның бер очында патлаган (кабынган) сугыш ялкыны бик тиз икенче очына сикереп, дөньяның асты өскә киләчәкдер. Бу сугышдан дөньяның бөтен иҗтимагый вә сәяси хасталыкларына дару көткәнләр өмидләрендә алданганларын бик тиз күрәчәкләр. Дөньяда дәвамлы бер тынычлык көткәнләр дә инкисары хыялга (буш хыялга; күңел төшенкелегенә) уграячаклар (дучар булачаклар). Фәкать бу сугыш каср (чикләнгән, кыска; хата) булмаячак, ул күпчелекнең теләгәнене тугдырмаса да, ул кан вә күз яше эчендә яңа бер мәүҗүдият (чынбарлык, халәт), яңа бер барлык тумаенча калмаячактыр. Бу киләчәк. Сугыш, эзләнгән сәяси хаклыкны бирә алмаса да, яңа-яңа барлыклар тудырачак, һәм дә дөньяның киләчәк корылышына кирәкле булган яңа гәүдәләнүләр мәйданга китерәчәклегендә һич шөбһә юкдыр. Бу булачак сугышда — дөньяның зур өлешенә җәелгән, без төрк халыклары читдә кала алмаган кеби, боның тудырачак яңа барлыкларына да без галякасыз (бәйләнешсез) кала алмыйбыз. Кирәк сугышның, кирәк аның нәтиҗәсендә туачак яңа барлыкларның безнең милли барлыгымыз өчен әһәмияте фәүкылгадә зур. Бу киләчәк сугышда төрк милләте үземез башлаучы йә туктатучы, зур бер гамил (фактор, көчле сәбәп) була алмасак да, боның нәтиҗәсе берлә иң зур багланган бер милләт булачакмыз.

Сугыш дөньяның кай йирендә генә башланмасын — ул сугышка иске Русия, бүгенге СССР мөхәкъкак (чыннан да, һичшиксез) катышачакдыр вә аның катышуы берлә хили (күп) таләп ителгән эшләр Русия туфрагының сәламәтлеге йә түгеллеге берлә генә калмаенча, Русиядә 15, 16 елдан бирле көчләндереп йирләшдерелгән коммунизм режимының калу вә бетерелү мәсьәләсе дә тормыш имтиханына куелачакдыр. Вә бу гайре табигый режим һич шөбһәсез тормыш имтиханын бирә алмыйча җимереләчәкдер. СССРның бөтен тәшкилияте (корылышы, барлыгы) хосусый милек бетерелеп, сату-алу хөкүмәт кулына алынганга вә Русиядә яшәүче милләтләрнең иҗтимагый тормышы да, игенчелеге, хайван асравы, сату-алуы, фабри-

ка-заводы мәркәзләшдерелеп (үзәкләштерелеп) хөкүмәт кулына җыелганга, совет хөкүмәтенең җимерелүе берлә бергә бөтен СССРдагы вилаяте мөәссәсәләр (оешмалар, төзелешләр) җимереләчәк, ашау-эчүнең таралуы туктаячакдыр. Иске замандагы Иран падишаһларының сарае алыну, шаһ кулга төшү берлә бөтен дәүләт машинасы сүтелгән кеби, СССРның да аерым кисәкләрен берсенә-берсен баглаган бөтен сәяси, иҗтимагый җебләр сүтеләчәк вә киң Русиядә, һәр шәһәр, һәр авыл үз башына калып, анаршы (анархия) башланачакдыр. Великорус халкы үзе хәзерге көндә кырыкга бүленү, аңлашылмау дәверендә торганга, СССРның киң вилаятьләрендә ата угылын, ана кызын белми торган бер хәл хаким булачакдыр. Менә шул вазгыять туганда, безнең төрк халкы, русларның шул милли авырулары берлә авырып китеп, төрк илләре дә бер тимарханә (авырулар йорты; психик авырулар йорты) хален генә алачакмы? Әллә төрк халыкларын да үзенең коручы дәүләтчелек хасыяте (сыйфаты) җиңеп китеп, ул үзен-үзе саклар өчен үз илене, үз йортыны корырга тотыначакмы? Бу сөальгә тугры җавап бирә белсәк — без киләчәгемез өчен тәдбир (чара, гамәл) алуларның юлыны ачкан булачакмыз. Әгәр без бу сөальгә җавап бирә алмасак яисә яңлыш җавап бирсәк, без халкымызның киләчәк берничә гасырлык тормышын яңлыш бер юлга борган булачакмыз. Моңарга җавапны бирү өчен, иң әүвәл төрк милләтенең хәзерге елларда нинди дәверен яшәвене күздән кичерергә тиешмез. Төрк милләте хәзерге елларда үзенең сүтелү-җимерелү дәверендәме? Әллә ул дәверне ватып яңадан төзү, төзелү, корылу дәверенә аяк басканмы?

XIX гасыр һич шөбһәсез төрк милләте өчен бер инкыйраз (бетүгә йөз тоту) дәвере иде. Бу гасырда Төркестан истикъляллен (бәйсезлеген) югалтды. Кафкас төркләре мәмләкәтләрене югалтдылар. Төркия үзенең куввәтене, кыйммәтене югалтды. XIX вә XX гасырның башлары төрек милләте өчен, аның милли хиссияте, милли шәрәфе төшүенең, аның йире, йортының башкалар кулына китүенең ачы еллары булды. Ләкин бу җимерелү дәвере тәмамән (бөтенләй) беткәч, яңадан туу хасыятенең тагы мәйданга чыгу көнләре дә шул ук XX гасырның башларында ук башланды. Аурупада төркләрне Аурупа туфрагыннан тәмамән куарга дип язып-сызып ятканда, дөнья сугышы нәтиҗәсе Аурупада: Кырымда мөстәкыйль бер төрк дәүләте мәйданга чыкды; Идел-Уралда бик куәтле уларак гаскәрле дәүләтчелек хәрәкәте башланды. Төркияне бүлүне гая иткән (теләгән) Аурупа дәүләтләре Кафкасда туган төрк-азәрбайҗан мәмләкәте — Шимал Кафкас дәүләтен танырга мәҗбүр булдылар. Төркестанда истикъляль алу хәрәкәте бик киң халык катлавыны сибләп, еллар буе дәвам иткән большевик-

Төркестан сугышлары төсен алды. 14 еллык сугышдан соң бир(е)телеп, аягы-кулы киселеп чыккан Төркия төреге бөтен олуг дәүләтләргә каршы сугыш ачып, үзенең хак хәятыны танытды; үз туфрагында үз ирегене үз халкына алып калуга муафыйк булды. Ниһаять, Шәркый Төркестан, Кытай хөкүмәтенә каршы баш күтәреп, өч еллык сугышны дәвам итдерде. Боларның һәммәсе дә йирле төрк халкының үз көче берлә генә эшләнде вә боларның һич берсенә һич дуст милләт йә бер дәүләт ярдәм итмәде. Нәтиҗәдә боларның күпчелеге большевик хөкүмәтенә каршы тора алмаенча, җиңелеп, үзенең истикъляль байрагыны индерергә мәҗбүр булса да, төрек халкы боның берлә үзенең корылыш дәверенә кергәнене бөтен дөньяга каршы исбат итде. Большевиклар хуҗа булган һәрбер төрк өлкәләрендә, Төркестан, Кафкас, Кырым, Идел-Урал төрк халкының, русларның коммунизмын кабул итмәве вә даимән тартышу хәлендә торуы берлә чит халыкларга, төрк милләтенең великорус башбаштаклыгы авыруына кагылмаганын ачык күрсәтде. Димәк, рус халкының җимерелү дәвере төрк халкының төзелү, корылу дәверенә очраячак, киләчәкдә СССРның җимерелгәндән яңа милли дәүләтләр корырга төрк халыклары рухан хәзер булачаклар вә алар русларның башбаштаклыгындан илен, йортын саклап калырга керешәчәк вә тырышачакдыр. Менә төрк халкының шөгурсыз (аңсыз, тоюсыз) инстинктын идарә итә алачак вә аны тугры юлга куя беләчәк милли куввәтләр табылачакмы? Төрк халкы шул вакытында үзендән-үзе бер Тимурын, бер Мостафа Кәмалын яратачакмы? Боларга җавабны да без үземезнең соңгы еллардагы кыска тарихыбыздан ала алабыз. Большевикларның милли хәрәкәтемезне җиңүе, бездә шуның сәбәпләрен тикшерү хисен уятды вә шуны тикшерә-тикшерә без Кафкаслы, Кырымлы, Төркестанлы, Идел-Ураллысы, төрле сахәләрдә (мәйданнарда, буш урыннарда) эзләсәк дә, бер нәтиҗәгә ки(л)дек. Ул да безнең милли берлегемез, безнең төрк берлегемезнең реаль бер хәлгә килеп, өлгереп җиткән булмавы. Бу сабакдан дәрес алып, без мөһаҗәрәтдәге төрк кабиләләре берләшдек, кыйбламызны берләшдердек. Һәммәбез истикъляль байрагына сарылдык. Милли бер саф корып, бер-беремезгә ярдәмләшергә сүз бирешдек. Большевикларның илемездә Кафкаслыны Кырымлыдан, Төркестанлыны Идел-Ураллыдан аерырга тырышуы вә милли хирыслыгымызны (теләгебезне) кисәкләргә маташуы, ике мең еллык бер телемезне бүлгәләргә керешүе, анда да реакция төсендә берлеккә омтылуны бик куввәтләндерде, аны күрерлек дәрәҗәдә үсдерде. Имкян (мөмкинлек) булу берлә ул анда да реаль бер хәлгә әйләнәчәкдер. Милли бер барлык булып, мәйданга атылачакдыр. Шуңарга күрә киләчәк канлы сугышның нәтиҗәсендә большевик

режимы җимерелү берлә башланган бушлыкда Төркестан, Кафкас, Кырым, Идел-Уралда яшәүче төрк халыклары үзләренең илләрене корырга, үзләренең дәүләтләрене төзергә керешәчәкләрдер. Боны төзүдә төрк тарихындагы бөтен дәүләтчелек хасыятьләрен мәйданга атачаклардыр. Ләкин СССРда яшәүче милләттәшләремезнең яшь буыны большевиклар тарафыннан сонгый (ясалма) рәвешдә милләтчелек, төркчелек агымларыннан еракда тотылганга, араларында милли агымдан кайбер адашучылар булыр диеп, аларга ярдәмче булачак егетләремез, кызларымызны без монда табарга тиешмез. Милләтемез өчен яшәү юлы ялгыз шул истикъляльчелек кенә икәнлеген вә аны алу ялгыз берлек аша гына үтәргә мөмкинлеген бөтен мөһаҗәрәтемездәге милләттәшләремезгә сеңдерергә тиешмез. Шуның өчен безнең мөһаҗәрәтемез кайда булса, шунда халкымызны бер җепкә туплап, бер милли байрак янына җыярга теләвемез милләтемезнең сәламәтлеге өчен беренче шартдыр. Шул милли берлекдән читкә китү — милли вазыйфамызны үтәмәү икәнебезне белергә, белдерергә тиешдер. Бу безнең милли берлегемезгә балта чабучылар аңлапмы, аңламыйчамы, милли җинаять эшләгәнләрен киң халык катлавына аңлатырга тиешмез. Мөһаҗәрәтдә булган төрк-татар балалары кайда булсак да, шул милли вазыйфаны үти алсак, киләчәк канлы сугышдан без үземезнең милли барлыгымызны саклап алып чыгачакбыз вә халкымызның тормышын үз илемездә, үз йортымызда, үземезнең тарихымыз юлында милли ганганәмез (мирасыбыз, буыннан буынга күчкән барлыгыбыз) төсендә кора беләчәкмез. Әгәр без вакытның мөһимлеген аңлап, мөһаҗирлек форсатымыздан файдаланып, бу милли берлекне яшәтә алмасак, безнең агай-энеләремезнең меңләп, йөз меңләп түккән канлары әрәмгә китәчәкдер. Шуның өчен бүген һәрбер төрк-татар баласына үзенең милли байрагы тирәсенә тупланып, берлек күрсәтү фарыздыр. Шуның өчен — милли байракны хөрмәтсезләндерергә, милли көчнең берлеген бозарга тырышу — большевик тегермәненә су китерүдер, милли хыянәтдер.

## Милләтпәрвәрләр һәм шаһгалиләр

Октябрь инкыйлабыннан соң мөһаҗәрәткә (эмиграциягә) киткән милләттәшләребез 1552 елгы кара көнне Хәтер көне, Матәм көне рәвешендә билгеләп үткәннәр. Мондый чараларның 1920–1930 елларда Польшада, Финляндиядә, Эстониядә, Ерак Шәрык мәмләкәтләрендә һәм кайбер башка илләрдә уздырылуы мәгълүм. Димәк, хәзерге Матәм көнен үткәрүнең озынозак тарихы бар.

Гаяз Исхакый тарафыннан укучыларга тәкъдим ителә торган «Казан китүгә 383 ел үтде» мәкаләсе — нәкъ әнә шул чордагы рухи тормышның бер ядкәре. Ул бөек әдипнең Ерак Шәрык сәфәрендә Мукден каласында 1935 елда язылган. (Бу шәһәрдә нәкъ шушы елда мәшһүр «Милли Байрак» гәзите чыга башлый. Аны Г.Исхакый нигезли.) Мәкалә Берлинда гарәп хәрефләре белән нәшер ителүче «Яңа милли юл» журналының 1935 ел, 11 (93) нче санында дөнья күрә.

Г.Исхакый 1552 елдан соңгы татар тормышының гаять авыр, катлаулы, каршылыклы булуын искәртә. Аның фикеренчә, халкыбызның Олуг Мөхәммәдләр, Сөембикәләр белән бәйләнешле агымы, зур югалтулар белән булса да, телебез, динебез, мәдәниятебез өчен көрәшен дәвам иттерә, мөстәкыйльлеккә ирешү иманын саклап килә. Ә Шаһгали варислары — моның капма-каршысы, колониаль сәясәтне уздыручыларның ялчылары, милли берлекне, көя кебек кимереп, эчтән җимерүчеләр.

Мәкалә Исхакыйга хас булган публицистик кайнарлык, полемик рух белән язылган. Шуңа күрә анда аерым бәхәсле фикерләрнең, кискенрәк әйтелгән юлларның очравы табигый.

*2000*

## Казан китүгә 383 ел үтде*

*Гаяз Исхакый*

Бу ел унбишенче октябрьдә Казанның русларга китүенә 383 ел тулды. Бу 383 ел эчендә Казанның төп халкы — төрк-татарларының өч кенә елы да тынычлыкда үтмәгәндер. Өч кенә аен да халкымыз үзе теләгәнчә, үзе аңлаганча рәхәт итеп тора алмагандыр. Бу 383 елның тарихын тикшерсәк, безнең төрк-татарларның канлы яше өзелмәенчә дәвам иткәнен вә ара-сыйра шул күз яше катып китеп, милләтнең тешен кысып, куәтен җыеп, шул дошман золымыннан кортылырга (котылырга) атылганын күрәмез. Халкымызның өмидле көнләр үткәргәнен, искиткеч батырлыклар берлә дошманның үзендән әллә ничә мәртәбә көчле куәтен җимергән шаһид буламыз. Мона (менә) Казан кортыла, мона милләт үз йортына үзе хуҗа була дигән уйга киләмез, бу өмидемез безне сөемле җәллиясе (балкышы) берлә сөяргә өлгерми, әллә кайдан бер ямьсез тавыш ишеткән кеби булып сискәнеп китәмез. Әллә нинди бер мирзаның, әллә нинди бер мелланың берсенә бик диндар булган булып, алып барган эшемездә дин ягындан яңлыш тапкан бу-

* Яңа милли юл. — 1935. — № 11 (93). — 1–5 б.

лып маташуын, берсенеӊ бик гакыллы булган булып, алып барган милли тартышымызда кылны кырыкка ярып, кимчелекләр эзләп, эчебезгә икеләнү салганын вә икесенеӊ дә милли халкымызны көчсезләндерергә, икеләндерергә тырышып ятканларына шаһид буламыз. Элек боларныӊ аӊлы-аӊсыз эшләре милләтнеӊ кайнаган милли рухы астында эреп китәчәк, милли теләге алдында берни боза алмаячак, дип үтеп китәмез. Ләкин эчемездә йөрүче бу кара көчләрнеӊ һәрбер йиргә коткы салганын, аларныӊ коткыларындан һәрбер милли почмагымызда көчләр туып, безнеӊ милли тәнемезне кимергәненә очрыймыз вә бик күп вакытда тышдан милли берлегемез сакланган төсдә булса да, дошман куәте берлә актыкгы бәрелешү килгәндә, эчдән көя ашаган милли сафымызныӊ ертылганын, сүтелгәнен вә дошманга каршы кирәк вакытда көч күрсәтә алмаенча җиӊелгәнемезне күрәмез. Тарихымызныӊ бу сәхифәләре халкымызныӊ бөтен күтәрешләрендә өзелмәенчә сузылып килә. Безнеӊ милләткә тагын яӊы-яӊы (яӊадан-яӊа) канлы яшьләр тудырып килә. Шул 383 ел буенда бик күп мәртәбә булып үткән тартышларда дошманларымыз — руслар үзләре эчемезгә кереп, шундый бер зыянчы сатлык кешеләр агымы ясап торуларына шаһид буламыз. Дошман куәтенеӊ эчемезгә кереп, халкымызны бозуларына вә шул бозылганнарныӊ хәятлары аркасында халкымызныӊ тагын кара көнләр үткәрергә мәҗбүр булуына шаһид буламыз. Безнеӊ берлә мөнәсәбәтләре башланган көндән игътибарән руслар безгә каршы булган бөтен сәясәтләрен арамыздан үзләре чыгарган хаинләр (хыянәтчеләр, сатлык җаннар), шул зыянчылар ашасындан гына йөртеп килгәнләр һәм шулардан башка һичбер юл да эзләмәгәнләр. Шуӊар күрә безнеӊ Казан ханлыгы дәверендән башлап бүгенгә кадәр милли барлыгымыз өчен тартышымызны тикшереп карасак, бөтен хәрәкәтемездә руслар тарафыннан хәзерләнгән бу дошман агымына очрыймыз.

Боӊа каршы ләкин халкымызныӊ динен, милләтен саклап, халкымызныӊ иленә, суына хуҗа итеп, үз мәдәниятен саклап, мөстәкыйль бер халык, мөстәкыйль бер ил итеп яшәтүне максад итеп киӊ халык катлавын күздә тоткан саф агым яшәп киләдер. Олуг Мөхәммәд вә Сөембикәләр — бу агымныӊ нигез салучылары. Шул озын дәвердә милләтемезне саклап калырга тырышучы, илемезне коткарырга җан атучы дини-милли көрәшчеләремез — боларныӊ туп-тугры варислары, шәкердләре. Дүрт-биш йөз еллык тарихымыздагы, тышкы сафымыздагы бөтен көрәшләр бу агым тарафыннан алынып барылган. Илемез руска киткәч милли-дини хакымызны саклар өчен тугдырылган милли кальгаларымыз (ныгытмаларыбыз) — мәсҗедләремез, мәдрәсәләремез — болар тарафыннан эшләнел-

гән, милли гадәт-горефемез, тарихи көнемез, моңымыз, телемез болар тарафыннан сакланып килгән, халкымызның милли иманы үзенең кортылуына өмиде, милләтнең шул иманлы угыллары, кызларының кайнар йөрәгендән сугарылып килгән. Шул изге куәтләрнең фидакарьлеге, халкының файдасы өчен үзен-үзе онытып, белгән юлында эшләве аркасында, руслар 383 еллык золым дәверләрендә милләтемезне руслашдыра алмаганлар, бетерә алмаганлар. Шуларның балаларының тырышлыгы аркасында гына бүгенге көндә милләтемез, милли барлыгымызга каршы җәһәннәм зобаниларының гөрзисе (чукмары) берлә коралланган большевикларга каршы да милли барлыгымызны саклап киләмез. Милләтемезнең вә илемезнең котылырга иманын яшәтеп, илемез, суымыз, йортымызны коткару тартышын алып барамыз. Шуларның матди, мәгънәви көче берлә генә халкымызны сәламәтлек яр якасына чыгарырга хәзерләнәмез.

Бу саф иманлы халык куәтенә каршы үзенең халкын хур (хар, түбән) күрүче, русларны зур күрүче, милләтенең йөрәк тибүен аңламаучы, үзенең бик кечкенә шәхси мәнфәгатен милләтенең тарихи мәнфәгатендән алда тотучы, зәгыйфь иманлы мескен бәндәләр яисә тәмамән руслар тарафыннан тотылучы имансыз, сатлык хаинләр, асылда, халык эчендә күренмәслек дәрәҗәдә аз булган рус ялчылары гонсыры (элементлары, төркеме) бар. Боларның дәү этиләре Шаһгалидер. 383 ел эчендә халкымызның һәрбер тартылышында тугрыдан-тугры русларга сатылып эш иткән хаинләр — милли тартышларымыз вакытында эчке сафымызны эчдән кимерүче, җимерүчеләрдер. Шул агымның көчләре тугрыдан-тугры Шаһгалинең варисларыдыр.

1905 нче елдан соң, матбугат, җәмгыятьләр хөрриятендән файдаланып, милләтемез, үзенең милли нигезен кору өчен илемезнең төрле почмагында, төрле төсдә милли оешмалар, җәмгыятьләр тугдырып, бил баглап эшкә керешде. Яңа милли бинаны салу вә яшәтү өчен кирәкле булган яңы осталар җитешдерә торган «Хөсәения», «Мөхәммәдия», «Буби»лар кеби бай мәктәпләр корды. Шул көнләрдә өстемездән русларга чагучылар «Буби»ларның мөдәррисләрен төрмәләргә ябдыручылар, сөргенләргә җибәртүчеләр, мәктәпләрен каплатучылар (ябучылар) шулай ук Шаһгалинең эшләрен дәвам итдерүчеләрдер.

Илемездә большевикларның милләтемезне, динемезне җимерер өчен корган планына хезмәт итүче Сәедгалиефләр, Баймбитофлар, Атнагулофлар, Нәзир Түрәколофлар, Гадерәшит Ибраһимофлар — шул ук Шаһгалинең бүгенге гаскәриләредер, шул ук хыянәтне эшләүче фасикъләрдыр (бозыклардыр, иман-

сызлардыр). Мөһаҗәрәтдәге тормышымызны да күздән кичергәндә гайни манзара (шул ук күренеш) тәкрарланадыр (кабатланадыр). Кирәк Аурупада, Төркиядә булсын, кирәк Ерак Шәрыкда булсын, милләтемезнең кичергән көнләре әйтеп бетермәслек авыр чакларда милләтемезнең саф, пакь балалары урысның урысы кызыл урыска каршы биәман (рәхимсез) бер тартыш алып барадыр. Милләтен, илен шул золымдан коткарыр өчен бик зур фидакарьлек күрсәтеп, бик якында туачак форсатда милләтен берләшкән бер милли көч ясарга милли берлек тугдырырга тырышадыр. Мәҗмугалар чыгара, оешмалар ясый, илемезне читләргә танытадыр. Руслардан сатылып алынган, руслар тарафыннан бик күп акча берлә тотылган Шаһгали балалары бонда да йә ачыкдан-ачык большевиклар берлә берләшеп яисә, эчемезгә көя булып кереп, эчдән кимереп, милли берлек сафымызны җимерергә тырышадыр, бик үлчәүле милли көчемезне кирәкмәгән эшләр берлә вакытын сарыф итдереп, иң мөһим булган милли эшемездән читкә алырга маташадыр. Милләтләргә ризык өләшү көнендә без Идел-Ураллыларны тагын милли байрагы янына җыелмаган итдерергә тырышалар. Бу хыянәтдә бу сатлык гонсыр 4–5 кешедән артмаса да, һичбер нәрсәдән оялмаенча, урыс берлә дә берләшәдер, коммунист берлә дә үзләшәдер. Динле дә булган буладыр. Урысның агынамы, кызылынамы хезмәтендә иренмидер, милли сафны бозуда дәвам итәдер. Олуг Мөхәммәд, Сөембикә варислары үзләренең куәтләрен милләтнең саф балаларындан алганга, аларның алган юллары милләтен сөйгән һәрбер кеше өчен бердәнбер тугры юл булганга, алар мәгънән (мәгънәви яктан) бик куәтледерләр. Икътисадән (икътисади яктан) мөһаҗир халкымызга гына таянган, маддәтән (матди яктан) аның көче бик санаулыдыр.

Шаһгали балалары үзләренең көчләрен ак, кызыл, кара руслардан алганга вә милләтнең сатлык чүп-чарына таянып эш иткәнгә, аларның мәгънәви бер тиенлек кыйммәтләре юкдыр. Халык алдында бер тиен бакыр акчалык хөрмәтләре юкдыр. Фәкать алар мадди яктан дөньяның алтыдан берсен биләгән руслыкка — бүген кызыл руслыкка таянганга — мадди имкянләре (мөмкинлекләре) бик киңдер. Төрк-татар милләтенең зарарына итәр өчен кирәкле акчалары бик күптер. Димәк, бүгенге көндәге халкымызның дөньяның төрле почмагына таралган милли тартышын бондан элекке ханлар заманасындагы милли истикъляль (азатлык) тартышы берлә чагышдырсак, гайни (ачык) бер манзараның тәкрарлануын күрәмез. Төрк-татар милләтенең өзелгән барлыгын, берлеген сакларга теләүче Олуг Мөхәммәд, Сөембикә балалары милли байраклары әтрафына (тирәсенә) тупланышып, үз илләрен, үз йортларын, үз

мәдәниятләрен, үз динләрен вәхши русның чабатасы астындан алырга телиләр. Шуның өчен сафны ныгытырга, халыкны берләшдерергә тырыша-тырмашалар.

Шаһгали балалары руслар берлә бер саф булып, төрк-татарның милли байрагына һөҗүмдә рус балтасына тугрыдан-тугры саб булалар. Кайберләре ачыкдан халыкка каршы чыгарга куркып, милли сафны эчдән җимерергә, төрк-татарның милли байрагын көчсезләндерергә хезмәт итәләр. Рус файдасы өчен милләтенең хакын корбан итәләр. Бүгенге көндә безнең илемезне кызыл руслар истиля итеп (басып алып) алган булганга, чит илләрдә аларның мадди көчләре бик зур булганга, безгә милләтчеләргә — Олуг Мөхәммәд, Сөембикә варисларына, аларга каршы мадди якдан уникенең берсе булмаганда, милли тартышны алып бару бик авыр. Хосусан безнең беренче сафда баручы көрәшчеләремезгә каршыдан килгән дошманның сөңгесенә, кылычына, угына каршы килү, шул авырлыклар эчендә милли байракны төшермәү бик читендер. Ләкин хаклыкга хак ярдәмче дигәнчә, 383 ел бер буйдан дәвам иткән бу канлы, яшьле сугышда бик күп дәрәҗәмездән куәтле дошман көче безнең сафдашларымызны меңләп-миллионлап үтерсә дә, безнең милли иманымызны кыл кадәре дә киметә алмаганга, милли байрагымызны бер карышка да иңдерә алмаганга, бүген дә бер эш эшли алмаячакдыр. Кылган бөтен мадди мәсарифлары (чыгымнары), сатлыкларымызны сатып алулары исраф кына булып калачакдыр. 383 ел эчендә русларның бөтен зәхмәтләре, мәшәкатьләре бушка киткән кеби, хәзер мөһаҗәрәтдәге руслар, русчыларның да бөтен мәшәкатьләре бушка китәчәкдер вә төрк-татар милләте 383 ел үзенең кортылышына югалтмаган иманын хәзер генә югалтмаячакдыр. Эчемездәге хаинләр кирәк эчдән, кирәк тышдан никадәр тартышсалар да, СССР бүленгән көндә сабикы (элеккеге) Русиянең тупрагы варисларына таратылган көндә без, Олуг Мөхәммәднең, Сөембикәнең угыллары, кызлары Идел-Урал байрагы астында үземезнең бабайларның мирасын алырга хәзер булачакмыз вә бу безнең хакымыз — кануни тарихи хакымыз булганга, Идел-Уралны алачакмыз, халкымызны коткарачакмыз. 383 ел элек төшерелгән милли байрагымызны Сөембикә манарасына асачакмыз. Русларның бу озын сөргән золымнарын вә төрле-төрле Шаһгали балаларының хыянәтләрен милләтнең ләгънәте берлә тарих битенә атачакмыз.

*Мукден*

Корылтай. Милли мәҗлес. Нәзарәт. Милли идарә... Хәзерге көндә еш яңгыраучы бу сүзләр һәм төшенчәләр күпләр тарафыннан ничектер яңа, соңгы еллар күренеше рәвешендә кабул ителә. Әмма бу — тарихи хәтерсезлегебез һәм озак еллык рәсми сәясәт аркасында туган ялгыш күзаллау. Чынлыкта исә «корылтай», «милли мәҗлес» (Милләт мәҗлесе) кебек сүзләр — татар халкының милли азатлык көрәше белән бәйләнешле күптәнге атамалар. Алар 1917 елгы инкыйлаб дәверендә аеруча активлашып киткән.

Мәгълүм булганча, Мәскәүнең атаклы Әсәдуллаев йортында 1917 елның 1 маенда Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае ачыла. 900 вәкил катнашкан бу җыелышта Муса Бигиев, Гаяз Исхакый, Зәки Вәлиди, Закир Кадыйри һәм башка күренекле әһелләр милли һәм дини хәрәкәтнең, дәүләтчелекнең мөһим мәсьәләләре буенча докладлар ясыйлар. Корылтай алга таба башкарылырга тиешле эш-гамәлләрнең төп юнәлешләрен билгели, 12 кешелек җитәкче мәркәз сайлый.

1917 елда янә берничә корылтай була. Шундыйларның берсендә — Казанда үткәрелгән корылтайда — 22 июль көнне эчке Русия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни автономиясе хакында документ кабул ителә һәм тиз арада Милләт мәҗлесен оештыру, сайлау бурычы куела.

Катлаулы, каршылыклы һәм гаять җитди эш-гамәлләрнең нәтиҗәсе буларак, 95 (96) кешелек Милләт мәҗлесе оеша, һәм ул Уфада 1917 елның 22 ноябреннән 1918 елның 11 гыйнварена кадәр утырышларын уздыра. 51 көн буена барган бу мөһим сессиядә Идел-Урал җөмһүриятен төзү, милли идарә, мәдәният, мәгариф, милек, хәрби көчләр, тышкы сәясәт һәм мөстәкыйль дәүләтчелек өчен зарури булган бик әһәмиятле башка документлар раслана, карарлар кабул ителә. Аларны гамәлгә ашыру юнәлешендә җитди генә адымнар ясала. Әмма, кызганычка каршы, Русия хакимияте Милләт мәҗлесен танымый, бераздан аны куып тарата, әгъзаларын эзәрлекләүләр, кулга алулар башлана. Милли хәрәкәтнең Садрый Максуди, Гаяз Исхакый, Закир Кадыйри, Габдулла Баттал, Муса Бигиев һәм кайбер башка җитәкчеләре, идеологлары чит мәмләкәтләргә китәргә мәҗбүр булалар; анда Идел-Урал җөмһүрияте, Милләт мәҗлесе идеясе өчен көрәш дәвам иттерелә. Читтәге күпчелек милләттәшләребезнең өендә хәзер дә Идел-Урал җөмһүриятенең төсле картасы булу, алар арасында Идел, Урал исемле кешеләрнең очравы үзләре үк күп нәрсә хакында сөйли.

Гаяз Исхакый (Иделле) — югарыда әйтелгән мөселман, төрк-татар корылтайларының, Милләт мәҗлесенең танылган вәки-

ле. Мәскәүдәге беренче корылтай, нигездә, аның җитәкчелегендә оеша. Яшьләрнең, эшче, гаскәри делегатларның аны, «ура!» кычкырып, зал аша күтәреп, президиумга илтүләре мәгълүм. Гаяз Исхакыйның Мәскәү мөселманнары исеменнән корылтайда ясаган ялкынлы чыгышы* көчле алкышлар белән каршы алына.

Идел-Урал идеясенә, милли бәйсезлек байрагына Гаяз Исхакый эмиграциядә дә тугры кала, төгәлрәк әйткәндә, төрк-татарларның рухи остазына, юлбашчысына әйләнә. Үзенең күпсанлы публицистик язмаларында, әдәби әсәрләрендә ул Мәскәү хакимиятенең руслаштыру сәясәтен кискен тәнкыйтьли. Советлар империясендәге рус булмаган халыкларның иртәме-соңмы бәйсезлек алачагына тирән ышаныч белдереп, үз укучыларын милли азатлык көрәшенә рухи яктан әзерли.

1938 елның башларында чит илләрдәге милләттәшләребез Милләт мәҗлесе төзелүнең 20 еллыгын зур сәяси, мәдәни чара рәвешендә билгеләп үтәләр. Мондый истәлекле көннәрнең Япониядә, Кытайда, Финляндиядә, Төркиядә, Германиядә, Эстониядә һәм татарлар яши торган башка төбәкләрдә уздырылуы мәгълүм. Илдә исә 1937–1938 еллар — бик күпләрне, шул исәптән татар зыялыларын, милли җанлы кешеләрне йөзәрләп-йөзәрләп кыру, үтерү еллары.

Польша (Ләһстан) — икенче бөтендөнья сугышына кадәр эмигрант татарларның төп мәркәзе. Гаяз Исхакый да күп вакытын шунда үткәрә. 20 еллык юбилейның халыкара төп бәйрәме Варшавада уздырылуы да нәкъ әнә шуның белән аңлатыла. (Ул 1938 елның 4–6 февраль көннәрендә була.) Биредә төрле мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребез, элеккеге Милләт мәҗлесенең, Милли идарәнең кайбер әгъзалары белән берлектә Кавказ, Кырым, Төркестан, Украина милли азатлык хәрәкәте вәкилләре дә катнаша. Берничә йөз кешелек бу чараларны уздыруга Польша рәсми властьлары, профессорлары, зыялылары нык ярдәм итә. Польшадагы җирле татарлар да бу эштән читтә калмый. 20 еллык юбилей уңае белән чит ил матбугатында күпсанлы материаллар дөнья күрә.

Милләт мәҗлесенең истәлек көннәрен оештыру, үткәрү эшләре белән Гаяз Исхакый турыдан-туры үзе җитәкчелек итә, төп авырлыкны үзенә ала. Аның бу уңай белән махсус мәкаләләр язуы, докладлар, чыгышлар ясавы, рәсми һәм рәсми булмаган төрле очрашулар уздыруы мәгълүм. Үз мөхәррирлегендә Берлинда чыга торган «Яңа милли юл» журналы-

---

* «Безнең юлымыз» дип исемләнгән бу чыгыш «Мирас» журналының 1992 елгы 7 санында басылды.

ның бер санын (1938, № 3) ул махсус шушы вакыйгага багышлый.

Укучыларга без Гаяз Исхакыйның Милләт мәҗлесенең 20 еллыгы уңае белән язылган ике мәкаләсен һәм радиодан чыгышын тәкъдим итәбез. Аларда Милләт мәҗлесенең тарихы, төп идеяләре, юбилей тантаналары яктыртыла, һәм тематикалары, һәм эчтәлекләре белән үзара якын, хәтта өлешчә керешеп тә китәләр*.

Гаяз Исхакыйның гыйльми-публицистик фикерләвенә караш-мөнәсәбәтләрнең ачыклыгы, һәрнәрсәне тарихи контекстта яктырту хас. Ул нәрсә хакында язса да, үз милләтенең улгы булып кала, күренеш-вакыйгаларны, эш-гамәлләрне шул ноктадан торып карый, тикшерә, бәяли. Милли идеал, милләт язмышы аның бөтен әдәби иҗатын һәм публицистикасын үтәли ярып бара. Әмма бу һич тә милли чикләнгәнлек түгел, ә гомумкешелек идеаллары белән сугарылган гуманистик инану. Гаяз Исхакый бер милләтнең икенче милләткә буйсынып яшәвен гайре табигый күренеш дип саный, һәр халыкның — ул зурмы, кечкенәме үзенчә иркле яшәргә хаклы булуын яклый, милләтләр арасында тигез хокуклылык өчен көрәшә. Нәкъ менә шуңа күрә дә аны милләттәшләре генә түгел, ә поляклар, украиннар, азәрбайҗаннар, төркестанлылар да гаять зурлаганнар, хөрмәт иткәннәр. 1937 елда әдипнең 40 еллык иҗат бәйрәме уздырыла. Аның материаллары белән танышу Гаяз Исхакыйның чын мәгънәсендә халыкара олуг лидер булуын янә бер мәртәбә раслый.

Гаяз Исхакый өчен тарих — иң мөхтәрәм остаз, тормыш дәреслеге, гыйбрәт чыганагы. Аның фикеренчә, милләтнең бөтенлеген бары тик тарихны, элеккеге гореф-гадәтләрне, традицияләрне өйрәнеп, белеп, шуларга таянып кына саклап һәм баетып була. Әдип өчен үткән, хәзерге, киләчәк кебек вакыт категорияләре үзара тыгыз бәйләнешле күренешләр. Шуңа күрә ул алар белән иркен эш итә: чагыштыра, капма-каршы куя, янәшә китерә...

Гаяз Исхакыйның бу мәкаләләре — үткән юлыбызны өйрәнү, аңлау өчен мөһим материал, ышанычлы чыганак. Аның ярдәмендә без тарихның киеренке көннәрен, татар тормышындагы катлаулы һәм каршылыклы вазгыятьне шактый дәрәҗәдә күзаллыйбыз. Бу язмалардагы фикер-күзәтүләрнең кайбер башка халыклар өчен дә билгеле бер әһәмияте бар. Чөнки

* Шунысын да искәртик: Г.Исхакыйның Милләт мәҗлесе хакындагы язмалары болар белән генә чикләнми. «Беренче Милләт мәҗлесенең 15 еллыгы» исемле күләмле мәкаләсе (Яңа милли юл. — 1933. — 1, 2, 3 ... саннар) — шуның күркәм бер мисалы.

сәясәтнең, мәдәниятнең, милли азатлык хәрәкәтенең үзәгендә кайнаган, тәҗрибәле, талантлы каләм остасы тарафыннан язылган. Аларда без көчле логика, үтемле фикерләү белән очрашабыз. Әдипнең карашлары кемгәдер ошарга, ошамаска мөмкин. Әмма аларны, мөһим тарихи факт буларак, урап китеп булмый.

Гаяз Исхакый мәкаләләрендәге күп кенә фикер-күзәтүләр, факт-мәгълүматлар бүгенге иҗтимагый, сәяси, мәдәни тормышка да аваздаш. Мәсәлән, татар халкының килеп чыгышын билгеләгәндә, кайберәүләр болгар компоненты белән генә чикләнәләр, үзләренә дәлил итеп кайчак Гаяз Исхакыйга да сылтама ясыйлар. Әмма әдип «Болгар», «Болгар иле» төшенчәләрен киң мәгънәдә ала һәм аларны төрк-татар, «Алтын Урда» атамаларына синоним рәвештә дә куллана. (Шунысын да искәртик, автор «төрек» сүзенә еш кына «төрки» мәгънәсен сала.) Авторның халкыбыз тарихында һәм, гомумән, яшәешендә диннең гаять зур роль уйнавын искәртүе дә мөһим.

Гаяз Исхакыйның милли хәрәкәттә бердәмлекне яклавы, милли гаскәри көчләргә ныклы игътибары, Русия белән мөнәсәбәтләр турындагы карашлары, сәясәттә күптөрле факторларны исәпкә алуы, киләчәккә ныклы ышанычы һәм кайбер башка фикерләре бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырыйлар.

Беренче Милләт мәҗлесенең карарлары, документлары, нигездә, Идел-Урал җөмһүриятен күздә тотып төзелгән. Хәзер исә чынбарлык башкачарак.

Гаяз Исхакый Милләт мәҗлесе төзелүне халкыбызның азатлык өчен көрәш тарихында зур вакыйга, тормышында мөһим бер борылыш дәвере дип билгели. Исхакыйлар даирәсендәге шагыйрә Сания Гыйффәт тә халыкның ул көннәрдәге күтәренке рухи халәтен:

— Әй канатланды, сөенде, чик-чама юк иркенә,
Әнкәсен күргән баладай ач теләкләр җилкенә, —

дип тасвирлый.

Гаяз Исхакыйның сүзләре пәйгамбәр сүзләре кебек булды. Бездәге рәсми хакимият органнары, аларның күпләгән хезмәтче тарихчылары Милләт мәҗлесен никадәр генә хурлап, мыскыллап оныттырырга тырышсалар да, максатларына тулысынча ирешә алмадылар. Милләт мәҗлесе, корылтай атамалары, җәмгыятьне үзгәртеп коруга нисбәтән янә күтәрелеп чыктылар, һәм бу табигый дә. Бу сүзләр ирек, милләт бәйсезлеге кебек изге, табигый сыйфатларны, яшәеш кануннары белән диалектик бәйләнешле төшенчәләрне белдерәләр.

*1992*

## Милләт мәҗлесенең 20 еллыгы*

*Гаяз Исхакый*

Мохтарият һәйәте (биредә Идел-Урал штатын төзү комиссиясе күздә тотыла. — *Х.М.*) Уфага йирләшеп, үзенең эш аппаратын коргач та, милли-мәдәни мохтариятне гәүдәләндереп, аны канунлаштырыр өчен Эчке Русия вә Себер төрк-татарларының Милләт мәҗлесен туплауны лязем күреп, Милләт мәҗлесенә сайлау низамнамәсен (регламентын; уставын) хәзерләп, сайлаулар игълан итте. Вә сайланган милләт вәкилләрен 20 ноябрьдә (иске стиль берлә. — *Г.И.*) Уфада хазыйр булырга (килеп җитәргә; булырга) чакырды. Үзе Милләт мәҗлесенә кертеләчәк вә аның каравына тәкъдим ителәчәк мәсьәләләрне хәзерләү берлә мәшгуль булды. 20 ноябрь, 1917 елда милләт вәкилләренең күбесе Уфага килеп җитсә дә, Милләт мәҗлесенең утырышлары өчен билгеләнгән бинаның төзәтелүе тәмам булмаганга, мәҗлес 22 ноябрьдә (4 декабрьдә. — *Г.И.*) генә ачыла. Мохтарият һәйәтенең хисабына күрә, вәкилләрнең саны йөз дә унлап чамасында булырга тиеш булса да, кайбер ерак йирләр вәкил күндерә алмаганга, кайбер вилаятьләр бөтен тулы хакларыннан файдаланып, саннары кадәр вәкил күндермәгәнгә, мәҗлес 96 вәкил берлә генә ачылды. Мәҗлеснең ахыргы көне 24 гыйнвар (яңа стиль берлә. — *Г.И.*) 1918 елга кадәр бер-ике артып, бер-ике кимеп, шул күпчелек берлә дәвам итте. Мәҗлеснең беренче утырышлары рәсми ачылуга, риясәт (рәислек; җитәкчелек) сайлауга багышланды. Рәислеккә мохтарият һәйәтенең рәисе Садрый бәк Максуди, могавинлеккә (ярдәмче, урынбасар итеп) Ибне Ямин (Әмин) әфәнде Әхтәм (1877–1920 еллардан соң юрист, сәясәтче), кятиблеккә (секретарьлыкка) Галим әфәнде Акчура (Галимҗан Кәлимулла углы, 1895–1933; сәясәтче, шагыйрь. Ул 1920–1926 елларда Харәзм, Бохара җөмһүриятләренең җитәкчесе дә була) сайландылар. Боларга берничә кятиб могавинләр бирелде. Мохтарият һәйәтенең мәгърузәсеннән (докладыннан) соң, Милләт мәҗлесе, кануне әсаси (төп закон; конституция), мәгариф, диния, малия (милек) исемнәрендә комиссионлар (комиссияләр) аерып (аерым-аерым) эшкә кереште. Милләт мәҗлесенең әгъзалары үзләренең милли мәсьәләләргә караулары ягыннан берничә фиркага бүленде. Идел буе төрк-татарын зур төрек милләтенең бер өлеше генә, аның мәдәниятен зур төрек мәдәниятенең бер парчасы гына дип төшенгәннәр төркче фракционына

---

* Яңа милли юл. — 1937. — № 12 (117). — 11–16 б.; 1938. — № 1(118). — 5–11 б.

язылдылар. Зыялыларымызның күпчелеге, мөнәүвәр (күренекле) галимнәремез, сәүдәгәрләремез бер фракционда иделәр. Рус агымларының тәэсирендә булынганлар, гаскәриләр, яшь укыганлар үзләренә татарчы фракционы ясарга теләсәләр дә, ахырдан ул сүздән куркып, тупракчы фракционы төзеделәр. Милләт вәкилләре арасында җиде-сигез коммунист фракциясенең әгъзалары булса да, алар да үзләренә аерым фракцион ясамаенча, тупракчыларның эченә кушылдылар вә аларны үз фикерләре тирәсендә әйләндерергә маташтылар. Мәҗлеснең беренче көннәрендә үк «ислам берлеге» фракционы кору хакында бер гаскәри имам тарафыннан тәклиф (тәкъдим) ясалган булса да, бу фракционга язылучы булмаганга, Милләт мәҗлесендә боның тарафдары бер кешедән үтмәгәнгә, «ислам берлеге» фракционы вөҗүдкә чыга алмады. Мәҗлеснең вәкилләре төркче, тупракчы фракционлары арасында бүленеп, эшне алып бардылар. Төркче фракционның әгъзалары иллedән югары, тупракчыларның саны 35—36 тирәсендә иде.

Риясәт әгъзалары рухан (рухи яктан) йә аңа, йә боңа тарафдар булсалар да, рәсмән (рәсми рәвештә) үзләрен фракционлардан читтә тоталар иде. Мәҗлеснең беренче утырышлары, мәҗлесләрне милләтнең шәрәф хиссиятенә монасиб рәвештә тәртипле алып бару өчен мәҗлеснең эчке низамнамәсен кабул итте вә милли дисциплинны (дисциплинаны) бик тиз бөтен әгъзалар тарафыннан хөрмәт иттерде. Әүвәлге көннәрендә эшләрнең иң зурысы комиссионларда һәм дә фракционларда үтте. Милләт мәҗлесенең гомуми утырышлары сирәк кенә булды. Ләкин шул берничә мәҗлестә үк большевик әгъзалары Совет хөкүмәтенә Милләт мәҗлесенең ачылуын белдереп вә аны котлап бер телеграф чикүне (телеграмма сугуны) тәкъдим итте. Татар большевикларының вәкиле Шәһид Әхмәдиев: «Иске заманларда бондый зур мәҗлесләрдә падишаһларга котлап садыйкы тәбәгалек (тугрылыклы хезмәт итү, верноподданство) телеграммы йибәрелә иде, хәзер дә Совет хөкүмәтенә садыйкы тәбәгалекне белдереп, телеграмм бирү кирәк», — диде. Бу мәсьәлә мөзакәрәләргә (фикер алышуларга; бәхәскә) сәбәп булды. Күп кешеләр сүз сөйләп, күпчелек: «Без үзебезнең милли-мәдәни мохтариятемезне игълан иткән халыкның вәкилләре, үземезне-үземез фәкать милләтемез алдында гына мәсьүл (җаваплы) тотамыз вә һичбер төрле рус хөкүмәтенең безнең эчке эшләремезгә катышырга хакын танымыйбыз, без үз милләтемезнең генә садыйкы тәбәкасымыз (буйсынуында)», — диделәр. Телеграмм тәклифен рәд итделәр (кире кактылар). Шулай итеп, Милләт мәҗлесе совет режимының барлыгын рәсмән белмәмешкә салынып кичде. Ләкин эш боның белән генә тәмам булмады. Берничә көннән соң Мәркәз

Милли Шурадан Советларның ул вакыттагы милләтләр комиссары Сталинның Мәркәз Шурага мөрәҗәгать итеп, төрк-татар шөгъбәсене кулларына алуны тәклиф итүне, телеграф берлә белдереп, җавап сөрелде. Милләт мәҗлесе тагы «без үземезнең милли эшләремезнең төзелешен, милли хокукымызның саклануын Учредительное собраниегә тәкъдим итәр өчен ляихә (проект) хәзерләп ятамыз, Дәүләт Учредительное собраниесе карарыннан элек һичбер совет комиссарлыгы берлә мөнәсәбәткә кермимемез», — дип җавап кайтарды. Боңарга каршы Мәркәз Шурадан бондагы бөтен мәсьәләләрне аңлатыр өчен Мәркәз Шура әгъзасы Солтан бәк Мамли күндерелде [Колчак тарафыннан Милли идарә таратылгач, Алаш Урда гаскәренә хезмәткә кергән бу милләтче забитымыз (офицерыбыз; хезмәттәшебез) 1919 елда Семидә (Семипалат каласында. — *Х.М.*) большевиклар тарафыннан үтерелде. — *Г.И.*]. Аны тыңламаенча, катгый карар алмавыгызны үтенәмез, дигән телеграмм килде. Мәркәз Милли Шура берлә Милләт мәҗлесе арасындагы бу телеграммалар Милләт мәҗлесендәге большевик вәкилләренең Петербургка рус большевикларына мөрәҗәгать итеп, Милләт мәҗлесенә совет комиссарлыгы ашасындан тәзйикъ (басым, кысу) ясатырга теләүләрен вә безнең саф (текстта — сарыф) милли эшләремезгә русларны катыштыруга маташуларын мәйданга чыгарды. Милләтчеләр берлә татар большевикларының арасыны бик каты ачды. Берничә көннән соң Мәркәз Шураның әгъзасы Солтан бәк Мамли әфәнде килгәч тә, Милләт мәҗлесе ябык мәҗлес ясап, Солтан бәк әфәнденең үзен вә тулы мәгърузәсен тыңлады. Бик озын мөнакашәләр (фикер алышу-бәхәсләр) ачды. Ләкин милләт вәкилләренең зур күпчелеге Совет хөкүмәте берлә мөнәсәбәткә кермәү тарафында булганга, Милләт мәҗлесе иске карарында калды. Милләт мәҗлесенең әгъзасы булып та, Уфадан Учредительное собраниегә дә әгъза булып барачак Гомәр әфәнде Тәңреколыйга (Гомәр Терегулов) үзенең ноктаи нәзаре (карашы) берлә Мәркәз Шураны да һәм дә Учредительное собраниене дә таныштыруны риҗа итте (үтенде) вә кизүдәге эшенә дәвам итте.

Милләт мәҗлесе бик тиз көнләр эчендә төрк-татар тормышының мәркәзи вазгыятен алды. Күрше халыкларның төрле-төрле мәдәни оешмалары берлә генә калмаенча, төрле сәяси агымлары да химая сорап (ярдәм сорап) мөрәҗәгать иттеләр. Мариларның вәкилләре килеп: «Без татар халкы берлә бергә меңләрчә еллар буе дуст яшәдек. Бүгенге большевик-татар тартышында да без сезнең берлә бергәмез», — дип килеп, садакать бәйгате (тугрылык анты) бирделәр. Төрле урыс җәмгыятьләре, урыс агымлары, хәтта православный дине мөәссә-

сәләре (оешмалары): «Безне химаягезгә (яклавыгызга; ярдәмегезгә) алыгыз», — дип, катлы-катлы мөрәҗәгатьләрдә булындылар. Безнең үз халкымыз Милләт мәҗлесенең ачылуын дәвамән бер бәйрәм кеби каршылады. Театрлар, мәҗлесләр, банкетлар берлә вәкилләрне хөрмәтләү һичбер өзелмәде.

Милләт мәҗлесенең ачык мәҗлесләрен йөзләр-йөзләр тыңлаучы басты, Уфадагы татар алае (гаскәре; полкы) Милләт мәҗлесенең химаясенә риҗадә булынды вә бик зур рәсми кәчид ясап, Милләт мәҗлесенә садыйк калачагына ант итеп, Милләт мәҗлесе исеменнән татар алаена байрак бирелде. Бу көн Уфада зур бер бәйрәм ясалып, милләтчеләрне сөендерсә, большевикларны кыздырды. Бу татар алаена байрак бирүемез үзләренә каршы бер хәрәкәт кеби каршыланды. Шул көннәрдә Милләт мәҗлесенең хөрмәтене үстерә торган икенче бер вакыйга да булып үтте. Милләт мәҗлесенә башкордларны катышдырмас өчен Зәки Вәлиди ибдәше провокатор Шәриф Манатовлар Оренбургда үзләренә махсус «башкорд корылтае» чакырганлар иде. Үзләренә күрә берәр төрле планлар да ясаганлар иде. Милләт мәҗлесенә башкорд илләренең вәкилләре килгән булса да, аерым бер нәрсәнең Оренбургда булып ятуы безнең милли шәрәфемезгә зарар итәчәк иде, Учредительное собраниеда милли таләпләремезнең кыйммәтене төшерәчәк һәм дә милли дошманларымызның эчке эшләремезгә катышуларына сылтау булачак дип уйлап, Милләт мәҗлесе Оренбургка ике әгъзасыны вәкил итеп күндерде. Милли берлегемезне бозмауга димләргә кушты. Нәтиҗәдә Оренбургдагы «башкорд корылтае»: «Без кардәшләремез татарлар, мишәрләр, нугайлар, типтәрләрдән аерылырга теләгәнемез юк, безне алдап китерделәр», — дип, зур тавыш күтәреп, Зәки Вәлиди, Шәриф Манатовларның үзләрен генә калдырып, мәҗлесләрен ташлап чыкдылар. Уфадагы Милләт мәҗлесенә вәкил сайлап күндереп, бергә булачакларын белдерделәр. Шулай итеп, Милләт мәҗлесе канунан да, әхлакан да Идел-Урал төрк-татарының тулы мөмәссиле (вәкиле) төсен алды. Шул мәгънәви кувәт берлә бил баглап, җиң сызганып эшләрне дәвам итте. Ләкин вакытлар бик чуалчык булганга, демагожига (демагогиягә) урын бик булганга, бер мәсьәлә хәл ителеп бетә алмый, икенчесе туа, икенчесе юлга салынып өлгерми, өченчесе, дүртенчесе нәүбәткә куела. Аның артыннан әллә никадәр вагы-эресе ишекне шакый, нәүбәт билгели (текстта — бикли. — Х.М.) иде. Шулар арасындагы мөһимләренең берсе дә милли тәшкилиятемездә динне милләттән аеру-аермау мәсьәләсе аерым урын тоткан иде. Безнең Идел-Урал төрк-татарының милли үзлегене, барлыкыны саклауда динемез исламиятнең руслардан башка булуы иске заманларда бик зур роль уйнаганы кеби, безнең милли мәдәниятемезнең гәүдәләнүендә дә

бик тирән эз калдырып зур тәэсир ясаган вә киләчәктәге барышымызда да үзенең ролене бетермәгән иде. Шуңарга милләтчеләремезнең күпчелеге милли мәсьәләләремезне дини мөәссәсәләремез (оешмаларыбыз) берлә бергә йөретү, милли мәдәниятне динемез берлә бергә алып бару тарафында иделәр. Шул нигездән чыгып мохтарият һәйәте Диния нәзарәте янына Уфага берләшкән вә Милләт мәҗлесе дә шул сәбәптән Уфага чакырылган иде. Ләкин русларның дини мөәссәсәләре хөкүмәт берлә багланып, чар (патша) хөкүмәтенең хезмәтчеләре булып җитеп, халыктан аерылганын күреп, рус зыялысы динне хөкүмәттән аеруны кирәкле таба вә шул фикерне алга сөрә иде. Безнең динемез, дин әһелемез һәрвакыт рус хөкүмәтеннән золым-җәбер күреп килгәнгә, үзенең көчене, кувәтене халыктан гына алганга, бездә милләтне диннән аеруның сәбәпчесе юк иде. Ләкин безнең ул вакыттагы кайбер яшьләремез урысларда булган, булуы матлуб (ихтимал; тиешле) нәрсәләрне тәнкыйтьсез һәммәсене үз халкына кертүне фазыйләт (әйбәт; кирәкле) дип йөргәнгә, яшьләр арасында динне милләттән аеру да бер мөһим мәсьәлә кеби йирләшкән иде. Татар большевиклары боны программаларының башына ук язып куйганнар, һәрбер йирдә шул хакта сөйлиләр, пропаганда ясыйлар иде. Бу таләпләрендә алар урысларның кызылларыннан гына түгел, безнең үзлегемезгә, барлыгымызга дошман бөтен рус даирәләреннән ярдәм күргәнгә, бу таләпләренә вакытның чыгарган бер тәрәкъкыйсы кеби итеп карыйлар, бу тәлкыйнне (ышануларын; фикерне) халкымыз арасында таратырга маташалар вә сайрак кешеләрне кандыралар (ышандыралар) да иде. Бу гына түгел, руханиларның үзләре арасында да динне милләттән аеру, хосусан милли тәшкилиятләрне дини тәшкилиятләрдән аеру фикере юк түгел иде. Ләкин боларның сәбәпләре яшьләрнекенә карaганда тәмамән башка иде. Руханиларның бу фикердәгеләре халкымыздан чыга торган бик күп акчаларның «милләт юлына» дип бирелүене күпсенәләр. Шул акчалар «дин юлына» бирелсә, үзләре тирәсендә калачагын уйлап, милләтчелекне динчелеккә каршы бер көндәш, бер рәкыйб (конкурент) кеби карыйлар вә алардан ераграк булырга телиләр иде. Мәгаттәәссеф (үкенеч ки), ул заманымызның мөфтисе Галимҗан хәзрәт Баруди үзе дә милләтне диннән аеру тарафында иде. Шуның өчен кануне әсаси комиссионында бу мәсьәлә бик зур мөзакәрәләргә (бәхәсләргә) сәбәп булса да, күпчелек берлек тарафында булганга, анда динне милләттән аермау нигезе кабул ителгән иде. Шул мәсьәлә Милләт мәҗлесенең утырышында каралыр алдыннан аеручылар арасында төрле-төрле хәрәкәтләр, хәзерлекләр хис ителергә башланды вә шулар дәвам иткәндә, без динне милләттән аеручы бу ике группның (төркемнең) берлектә җыелышлар

ясауларын вә мәрхүм мөфти хәзрәтнең шул хакта большевикларның башлыклары Галимҗан Ибраһимовлар берлә дә киңәшләшүләрен вә бергә тавыш бирү хасларын эзләшүләрен әйттек. Мәсьәләне төркче фракционында бик озын итеп мөзакәрә итештек вә бер авыздан динне милләттән аермау нигезен кабул итеп, Милләт мәҗлесендә шул мәсьәләнең тизлек берлә мөзакәрәсен таләп итеп, аерылучыларга зур бер сугыш ачтык. Мәсьәлә бик кызу вә бик тирәннән мөзакәрә ителгәнгә, без милләтчеләр һәммәмез бик каты иттереп большевиклыкка һөҗүм иткәнгә, голяманың аерылучы канаты да аптырауда калды. Аерылуны фәкать большевизанлар (большевиклар) гына химая итеп (яклап; канаты астына алып), мәйданга чыкты. Сүз арасында бик күп куркынычлы яклар да күренеп калганга, әфкяре гомумия (җәмәгатьчелек фикере) тәмамән берләшү ягына борылды. Мөфти хәзрәт үзе дә үзенең әтрафындагы голямаларыннан да ялгыз калачагын күреп, сүзгә катышмады. Күпчелек ничек мәгъкуль күрсә, шулай разыймын, диде. Төркчеләр берлә бергә тупракчы фракционның да бик күп әгъзалары тавыш биреп, милли тәшкилиятемезне милли-дини итеп бергә алып бару вә шул рухта милләтне тәрбия итү кабул ителде. Шул нигездә бөтен милли идарәләремез төзелде. Бу мәсьәлә голямаларның кайберләре вә куе милләтчеләр арасында мөфти Галимҗан хәзрәткә каршы суыклык уятса да, эшнең дәвамына манигъ (киртә; тоткарлык) булмады...*

Милләт мәҗлесенең беренче эше Русиянең төрле тарафларына таралган милләт балаларын, кабилә, ыруг аермасына карамаенча, бер милли йепкә тезеп, бер милли барлык хәленә китерү вә аны сәяси бер мәүҗүдият (яшәеш) итеп оештыруны канунилаштыру иде. Бу эш тә Милләт мәҗлесенең кануни әсасе (канун нигезләре) комиссионына (комиссиясенә) тапшырылган иде. Милләт мәҗлесенең юрист әгъзаларыннан сайланып алынган бу комиссионның эше бик нечкә, вазыйфасы бик авыр иде. Русларга каршы үзен мөселман дип йөри торган, үз арада төрле кабилә исемнәре: башкорт, мишәр, типтәр, татар, нугай дип атала торган, иске тарихларда «төрки», «болгар» дип йөртелә торган бу таркау төрк балаларының һәммәсенә дә уртак бер исем табарга кирәк вә боларның төп илләренә дә уртак бер ат куярга кирәк иде. Озын-озын тикшерелгәннең соңында, Аурупа галимнәренең халкымызга каршы кул-

---

* Г.Исхакыйның Милләт мәҗлесе турындагы язмалары безнең аңлатмалар белән «Мирас» журналының 1993 ел, 2 нче санында дөнья күргән иде. Әмма ул вакытта, «Яңа милли юл»ның 1937 ел, 12 нче саны кулыбызда булмау аркасында, Г.Исхакый мәкаләсенең тәүге өлеше басылмады. Бирелә исә «Милләт мәҗлесенең 20 еллыгы» язмасы тулы килеш бирелә *(Х.М.)*.

ланып килгән «төрк-татар» исеме кабул ителде. Илемезгә «Алтын Урда», «Болгар иле» кеби исемнәрне бирү тарих ягыннан тугры булачак булса да, беренчесе күршеләремезне куркытачак булганга, икенчесене, безнең илемез Болгар йортыннан күптән Балканнарга күчкән мөһаҗирләремез славяннар берлә катышып, үзләренә «болгар» исемен таккан вә шул исем астында дәүләт тә корган булганга, һәрбер кабиләне берләштерә торган илемездәге иң зур елгамыз Идел берлә илемездә иң бай, иң мәгълүм тавымыз Уралны куштык та Идел-Урал дигән исемне кабул иттек. Шулай итеп, бөтен таркау халкымызны, кабилә-ыруг аеруына карамаенча, рәсмән (рәсми рәвештә) Идел-Урал төрк-татары дип йөретергә булдык. Милләт мәҗлесе дә шуны муафыйк табып, тәсдыйк итде (раслады). Комиссионның икенче авыр вазыйфасы: милләтемезнең шул теләгәне, Милләт мәҗлесенең шул карарларын дәүләт мәҗлесе мөәссәсеннән (оешмасыннан) кабул иттереп, милли хокукымызны дәүләтнең* кануни әсасенә керттерү иде. Шуның өчен бу карарларымыз, теләкләремезне кануни рәвешкә сугу лязем иде. Комиссион да шуны бик дикъкать берлә эшләп, милли аерымлыгымыз, милли барлыгымызның нигезләре булган телемез, динемез, йоламызның дәүләт мөәссәсләрендә гадлия идарә (юстиция идарәсе), гаскәрилек, мәгариф хаклары ничек сакланачагы, маддә-маддә (пунктлап) тәсбит ителгән (күрсәтелгән) иде. Тормышта булачак һәрбер үзгәрешләр дә — милли барлыгымыз, үзлегемезнең саклануы күз уңында тотылган иде. Идел-Урал төрк-татарының милли-мәдәни үсүе бер төстә, бер рәвештә алып барылуы, киләчәгендә бер гаяга (максатка) таба хәрәкәт иттерелүен хәзерләү вазыйфасы мәгариф комиссионына тапшырылган иде. Алар да балаларымызны тәрбия, тәхсил иттерү (укыту) эшләрен карап, мәктәп-мәдрәсәләремезнең ана хатларын (нигез кагыйдәләрен) эшләгәннәр вә яшьлегемезнең бала бакчасыннан алып дарелфөнүннәргә (университетларга) кадәр ана телемездә тәхсилләре (укулары) өчен кирәкле булган бөтен шәраитны (шартларны) күздән кичереп, бер йепкә тезгәннәр иде. Нахия (район), вилаять (өлкә) мәгариф шөгъбәләре (бүлекләре) ясап, мәгариф эшләремезнең бөтен идарәсен Мәгариф нәзарәтенә (идарәсенә) йөкләгәнләр иде. Диния комиссионы дини оешмаларымызның, нигезене мәхәлләремезгә корып, мәхәллә имамлыгы, нахия казыйлыгы, вилаять мөхтәсиблеге (дин оешмасы) баскычларыннан кичереп, Диния нәзарәте берлә тәмамлаган иде, мәсҗедләр, дини мәдрәсәләр, зияратларның карау-каралу

* Учредительное собрание тупланачак һәм дә үзенең дәүләти вазыйфасы берлә урнаша беләчәк дип ышана идек (*Г.И.*).

эшләрен бер низамга (тәртипкә) салган иде. Малия (мөлкәт) комиссионы мөлкәтнең шул мөсарыфларын (чыгымнарын) ябар өчен акча табу юлларын тикшереп, һәрбер милләт әгъзасына милли салым салуны кабул иткән вә шуның өстенә, Идел-Урал төрк-татарының санына мөнасиб (туры килешле) рәвештә, уртак дәүләт хәзинәсеннән урыслар вә башка милләтләр берлә бертигез төстә акчаны алуны кушып, шул мөгъзәм (зур) милли тәшкилиятнең барышын тәэмин итәрлек мәнбәгъләрен (чыганакларын) булдырган иде. Шул салымнарны җыюны көнһда (асылда, ахыр чиктә) милли вилаятьләрдәге малия шөгъбәләренә йөкләтеп, милли хәзинәне идарә итүне малия нәзарәтенә тапшырган иде. Кануни әсасе комиссионы бу өч нәзарәтне берләштереп, боларга Милли идарә исемене бирде вә башларына Милли идарә рәисе исемендә бер рәис сайлауны да кирәкле тапты. Милләт мәҗлесе дә моны кабул итте. Шулай итеп, Идел-Урал төрк-татарының милли-мәдәни барлыгы вә аның дәвамы өчен кирәкле булган һәрбер мөәссәсә (оешма) мәйданга китерелгән булып чыкты.

Инде илемез Идел-Уралның, йир-суымызның үз кулымызда калуы, аның саклануы алга килеп басты. Шул мөнәсәбәт берлә шул вакыттагы һәрбер шәһәремездә төзелгән татар алайларын (полкларын) Милли идарәгә табигъ итү-итмәү (буйсындыру-буйсындырмау) мәсьәләсе бик кызу мөзакәрә (бәхәс) ителде. Татар алайлары ул вакытта бөтен Идел буе шәһәрләрендә төзелеп җиткән иде. Илемездә тынычлыкны саклауда зур роль уйнап килә иде. Боларның идарәләре Казанда корылган Гаскәри шураның карамагында булып килсә дә, идарәдә мәркәзият (үзәкләшү) тәмамланып бетмәгән иде. Боңарга башка татар алайларында үземезнең забитларымыз (офицерларыбыз) җитешерлек булмаганга, әллә никадәр урыс әфисәрләре йирләшкән иде. Болар татар алае төзелүнең төп сәбәбе булган руслыктан аерылуны кабул итмәгәнгә, төрлечә комачаулык ясауда иделәр. Гаскәрләремезне үзләренең сәяси карашларына карап йә коммунистларга таба, йә монархистларга таба өстерәргә маташалар иде. Мәркәз гаскәри шураның әгъзалары да тәҗрибә күрмәгән яшь забитлар булганга, боларның да нык итеп куйган сәяси карашлары йирләшеп бетмәгәнгә, сүздә большевик берлә большевик галиәдарларының (башлыкларының) тартышуларыннан битараф калуны алга сөрсәләр дә, эштә татар гаскәре эчендә большевик пропагандасына каршы һичбер хәрәкәт итмиләр иде. Шуның өчен кавийи (көчле) милләтчелек нигезенә корыла торган Милли идарә берлә Гаскәри шура арасында уртак бер тел табу авыр иде. Гаскәри шураның әгъзалары да гаскәри эшләрнең Милли идарә тирәсендә мәркәзләшүенә каршы киләләр иде. Шул караш үзгәрешләре кануни

əсаси комиссионында да, Миллəт мəҗлесенең җыелышларында да гаскəри тəшкилиятемезне Милли идарəдəн аеру, аны Идел-Урал мохтар (бəйсез) җөмһүрияте һəйəте (комитеты) берлə багълау фикерене куəтлəндерде. Гаскəри шурамыз Идел-Урал җөмһүрияте төзү һəйəте берлə бергə барырга дигəн карар кабул итте. Бу ике мөəссискə (органга) бергəлəп тиздəн Идел-Урал җөмһүриятене йирлəштерү вазыйфасы йөклəнде. Миллəт мəҗлесе милли алайларны миллəт куəтенең бер парчасы (кисəге) итеп карап, аларның төзелешендə, яшəешендə милли-мəдəни хосусиятлəремезнең саклануы хакында аерым маддəлəр кабул итте вə мəгънəн (асылда) Милли идарəгə багълап, контроль астына алырга булды. Инде бу телəклəр, бу карарларның дəүлəт тарафыннан тəсдыйк ителүе калган иде. Миллəт мəҗлесе бу хактагы милли вазыйфаны дəүлəт Учредительное собраниесындагы миллəттəш əгъзаларыннан көтə иде. Аларга ярдəм өчен, эшне даимəн тəгъкыйб итəр (күзəтер) өчен һəм дə Мəркəз хөкүмəт берлə даими мөнəсəбəттə булыр өчен, Мəркəз хөкүмəт янында бер илчелəр һəйəте коруны да кирəкле тапкан иде. Шуның берлə Миллəт мəҗлесенең беренче сессиясенең эшлəре тəмам була язган иде. Лəкин ул вакытларда Русия сугыштан чыккан төсле булса да, əле билфигыль (асылда) сугыш дəвам итеп торганга, Русиянең килəчəге бəйнəлмилəл (халыкара) бер мəсьəлə хəленə төшəчəге күренеп торганга, Миллəт мəҗлесе Русия берлə башка дəүлəтлəр арасында булачак солых могаһəдəлəрен (килешүлəрен) русларга гына тапшырмас өчен, Идел-Урал төрк-татары исеменнəн сүз сөйлəрлек солых һəйəте сайлауны лязем тапты. Миллəт мəҗлесе бу тəкъдимне мөнасиб күреп, чит иллəр берлə миллəт исеменнəн мөзакəрəлəрен (фикерлəрен) йөртер өчен бер низамнамə (закон) кабул итеп, һəйəтне өч əгъзадан мөрəккəб итəргə (төзергə) карар итте. Шуның берлə мөзакəрə ителəчəк мəсьəлəлəр тəмам булды.

Егерме ел үткəннең соңында күңелдəн генə язып үтелə торган бу эшлəрнең эшлəнүе, əлбəттə, язылган кеби җиңел кичмəде. Боларның мөзакəрəсе өчен төне-көне эшлəү эчендə үткəн 51 көнне тулы көенчə сарыф итəргə кирəк булды. 95, 96 кешедəн мөрəккəб (оешкан) əгъзаларның иртəдəн кичкə кадəр Миллəт мəҗлесендə булынулары лязем булды. Хосусан, мəсьүлиятне (аеруча җаваплы эшне) алып баручы күпчелек булган төркче фиркасенең 47—49 əгъзасына көнне төнгə катып, башка эшлəрне генə түгел, күп вакытта ашау-эчүне дə онытып эшлəргə тугры килде. Хосусан, комиссионнарда эшлəр эшлəнеп бетеп, Миллəт мəҗлесенə бирелгəч, күз ачарга да имкян (мөмкинлек) калмады. Төркче фиркасе фирка төсендə төзелеп өлгереп йиткəнгə, ул һəрбер ляихəне (проектны) үзенең фрак-

цион мәҗлесеннән әүвәл карауны гадәт итеп алды вә һәрбер ляихәне фракцион мәҗлесендә мөзакәрә итеп, кабул ителәчәкләрен кабул итәргә, төзәтү кертеләчәкләренә төзәтүләр хәзерләргә, ляихәне яклап йә каршы чыгып, сүзләр сөйләргә хатыйплар (чыгыш ясаучылар) тәгаен итеп (билгеләп), мәҗлескә хәзер көенчә чыгарга тырышты. Шуның өчен Милләт мәҗлесенең тупланышыннан ике сәгать-сәгать ярым элек һәр көнне төркче фракционы тупланды. Мөзакәрәләр озын дәвам итеп, кайбер көннәрне Милләт мәҗлесе ачылуының кичегүенә дә сәбәп булды. Гадәттә сәгать унбер-унбер ярымда башланган Милләт мәҗлесенең утырышлары сәгать икегә, кай көннәрне сәгать өчкә кадәр дәвам итте. Аш тәнәфесеннән соң сәгать дүрттә-биштә икенче утырыш игълан ителде, аны-сы да сигезләргә кадәр дәвам итеп, күп көннәрне кичке сәгать тугызда өченче утырыш та чакырылды. Ул утырыш бик күп көннәрдә сәгать икедә, чәйни (кайчак) өчтә тәмам була торган булды. Эшнең бу кадәр күплеге, табигый, вәкилләрне арыта, ялыктыра торган булганга, мәҗлескә килми калулар булмасын өчен, төркче фракционы аерым тәдбирләр алды (чаралар күрде). Берничә вәкилне җыючы итеп сайлады, алар һәркемнең килүен-килмәвен белеп торып, әгъзаларның өйләренә кадәр барып алучан булдылар. Ишек төбендә нәүбәт саклап, фракцион һәм мәҗлеснең җыелышларыннан беркемне чыгармый торган булдылар. Нәтиҗәдә төркче фракционының әгъзалары яхшы сәгатьнең механизмы кеби эшләде. Шул зур эшне илле бер (51) көндә тәмамлый алды. Милли идарә, һәйәтләргә сайлау вакыты җиткәч, ике фракцион арасында уртак кандидатлар куеп, милли мөәссәсәләрне уртак оештыру нигезендә сөйләшүләр башланды. Ләкин тупракчыларның бил-фигыль (чынлыкта) идарәләре татар большевиклары кулында булганга, алар милли саботажны дәвам иттерделәр вә бергәләшмәделәр. Милли идарәгә һәм дә һәйәтләргә әгъзалар сайлауда берничә листә (исемлек, кандидатура) куелды. Нәтиҗәдә Милли идарәнең мөһим урыннарына төркче фракционының әгъзалары сайланды. Сайлау эшләре дә беткәч, шул карарларны вөҗүдкә чыгаруны карар өчен, икенче җыелышны беренче майга тәгаен итеп, Милләт мәҗлесенең беренче җыелышы 11 гыйнвар, 1918 елда (иске стиль) ябылды.

Милли идарә үзенең вазыйфасын башлады. Һәйәтләр үзләренең йөкләнгән вазыйфаларын үтәргә тотындылар. Ләкин большевик хөкүмәте Учредительное собраниены беренче җыелышында ук көч берлә куганга, илчелек һәйәте вазыйфасын эшләргә имкян була алмады. Милләт мәҗлесе большевиклыкны кабул итмәгәнгә, большевикларның Мөселман комиссариаты дип корган мөәссәсәләренә катышмады, читтә калды. Ал-

маннар вә иттифакчылар берлә большевиклар арасында башланган Брест-Литовск солых мәҗлесенә барырга дип солых һәйәте Мәскәүдә тупланырга карар бирсә дә, бер әгъзасыннан башкалары килмәгәнгә вә большевик хөкүмәте боларның сәфәрләренә манигъ (каршы) булганга, Брест-Литовск солых мәҗлесенә Идел-Урал төрк-татарлар исеменнән солых һәйәте иштиракь итә (катнаша) алмады. Ул аннан бер ел соң башланган Версаль могаһәдәсенә (килешүенә) генә иштиракь итәр өчен, Франсага 1920 елда гына туплана алды вә анда Идел-Урал төрк-татар милләтенең таләпләрен тәкъдим итте. Ләкин большевиклар бу мәҗлесләргә катыштырылмаганга, бу таләпләрдән билфигыль бер нәтиҗә кулда ителмәде.

Идел-Урал җөмһүрияте һәйәте Гаскәри шура берлә бергәләшеп, апрель башында Казанда Идел-Урал җөмһүриятен игълан итүне хәзерләгән булса да, большевиклар ул вакытларда куәтләнеп җитеп киткәнгә, бу эшкә имкян бирмәделәр. Һәйәтнең, Гаскәри шура әгъзаларының күбесен тәүкыйф иттеләр (кулга алдылар). Шуннан соң Мәскәүдән Казанга күндерелгән матрослар, латышлар Идел-Урал җөмһүрияте һәйәтен вә Гаскәри шураны тәмамән көчтән төшерделәр. (1918 елның) 12 апрельдә Мәскәүнең әмере берлә Уфа большевиклары Милли идарәне яптылар. Хәзинәсен талап, бик күп әгъзаларын тәүкыйф иттеләр. 1918 елның августында, Уфа чехлар тарафыннан алынгач, Милли идарә тагы җанланып хәрәкәт итте, большевикларның Уфага икенче һөҗүмнәре алдыннан Себергә, Кызылъяр шәһәренә күчте. Бер тарафтан ахмак Колчак хөкүмәте тарафыннан, бер тарафтан большевиклардан бик зур авырлыклар күреп, ел буе дәвам иткән Милли идарә, большевиклар Себергә килә башлагач та, элек Омскига, аннан Иркутскига күчеп, 1919 елның ахырына таба тәмамән таратылды. Уфада калдырылган Диния нәзарәте әгъзалары берничә мәртәбә большевиклар тарафыннан кулга алынсалар да, халкымызның ярдәме, химаясе (яклавы) аркасында 1928 елга кадәр монтазам (тәртипле) рәвештә яшәп килделәр. Аннан соң башланган большевикларның дин берлә көрәшләренең иң зур угы безнең дини тәшкилиятемезгә каршы булганга, мәхәллә тәшкилиятләре бозылганга бик авырлык берлә яшәделәр. Мөфти Ризаэддин хәзрәт үзенең мәгънәви куәте берлә милли тормышыбыздагы шул зур трагизмны озын еллар яшәтеп килде. Үткән ел ул да вафат иткәнгә, Диния нәзарәте дә авыр хәлдә калды. Ләкин илемездә Милләт мәҗлесемезнең сайлап калдырган бу мөәссәсәсенә хөрмәт беткәне юк. Халкымызның күңелендә үзенең милли, дини истикъляленә (бәйсезлегенә) хөрмәте кимегәне юктыр. Идел-Урал җөмһүрияте һәйәтенең ише йиренә большевиклар аерым Татарстан, аерым Башкортстан, аерым Чувашстан игълан итеп, безнең туп-

рак ил берлегемезне кырырга, ватарга тырыштылар. Лəкин большевикларның 17–18 еллык бу шəйтани планнарыннан да һичбер нəтиҗə чыкмаганын күземез берлə күреп торамыз. Большевиклар никадəр бүлсəлəр дə, халкымыз бердер, берлеген саклап килəдер. Шул берлекне вөҗүдкə чыгарып илемезне, йортымызны үз кулына алырга форсат кына көтəдер. Мөһаҗəрəтемез (эмиграциядегелəр) дə милли юлымызга садыйк (тугры) калгандыр. Мөһаҗəрəттəге бөтен милли оешмаларымыз Миллəт мəҗлесенең юлыннан барадыр, милли истикъляльне кыйбла итеп хəрəкəт итəдер. Олуг милли кортылыш көннəремезнең егерме еллыгын искə алганда, шул юлда большевикларның золым-җəберенə очрап вафат булган, саф башында үтерелгəн милли мөһаҗирлəремез, шəһидлəремезнең мөкатдəс рухлары алдында тез чүгеп, миллəтемез илемезнең корылты (корылу) көнене, үз тормышына үзе хуҗа булу көнене якынлатуны җəнабе хактан нияз итəмез (Ходай Тəгалəдəн сорыйбыз).

## Миллəт мəҗлесенең 20 еллык бəйрəме*

*Гаяз Исхакый*

Бер халыкның миллəт булып йитешүендə, аның тарихы һəм башыннан үткəн шатлыклы вə кайгылы вакыйгалары, шуларның халыкның күңелендə калдырган эзлəре бик зур роль уйныйдыр. Шуның өчен халыкларын бер миллəт итеп тəрбия итə торган дəүлəтлəр балаларының вə яшьлəренең тəрбиясендə тарихи вакыйгаларын нигез ташы кеби куеп килəлəр. Бик күптəнге үткəн заманаларда булган төрле-төрле күңелле вə күңелсез вакыйгаларны бер-берсенə багълап килеп, милли эшлəренең тезмəсене яшь буынның яшəгəн дəверенə кадəр китереп багълыйлар вə шуның аркасында үз яшьлеген, яши торган мохите берлə генə түгел, үзенең бабалары вə бабаларының башларыннан үткəн вакыйгалары берлə сугаралар, чын мəгънəсендə яшьлегенə халыкның бөтен үткəн вə хəзер башыннан кичə торган вакыйгаларының варисы итеп куярга тырышалар. Аурупаның олуг дəүлəтлəренең халыклары арасында бүгенге көндə миллият фикеренең куəтлелеге алардан элек килгəн берничə буынның яшьлегенə шул милли вəкаигъ (вакыйгалар), милли ганганə (гореф-гадəт) эчендə тəрбиялəп килүенə мəдьюндер (бурычлыдыр). Безнең төрк-татарларның тарихлары бик бай вə яшьлəрнең күңеллəрен җилкендерə торган вакыйгалары бик күптер. Лəкин рус истилясы (басып алуы) безнең тарихи ганганəмезне

* Яңа милли юл. — 1938. — № 3 (120). — 2–6 б.

бозуда вә бабаларымызның зурлыкларын оныттырырга бик зур көч сарыф итеп, табигый милли тәрбиямезне бозганга, хәтта тарихи китапларымызны яндырып, тарихи әсәрләремезне юк итеп килгәнгә, яшьлегемезнең милли тәрбиясе үзенең чыгырыннан чыккандыр. Мәрхүм Мәрҗаниләр, Каюм Насыйрилар яшьлегемезнең тәрбиясендәге шул җитешмәүне күреп, яшәгән буынны үзенең тарихы, үзенең элекке әдәбияты, гореф-гадәте берлә багълауны үзләренең милли вакыйгалары итеп куйганнардыр. Алар артыннан килгән егерменче гасыр башларының тәрбиячеләре шул юлда дәвам итеп, безнең Идел-Урал төркләрендә чын мәгънәсендә бер Уяну дәверен яшәтмешләр вә милли ганганәмез вә тарихи вакыйгаларымызны җанландыра торган шактый күп әсәрләр дә мәйданга китермешләрдер. Боңарга башка көннең тудырган мәсьәләләрен хәл иткәндә дә егерменче йөзнең җәмәгать хадимнәре (хезмәтчеләре) үзләренең бүгенге вә иртәгәге кылачак эшләренең тарихымызга багълануының табигый төстә булуына әһәмият биргәннәр вә рус истилясы берлә көчләнеп киселгән тарихымыз вә ганганәмезнең багъланып милли берлек төсен алуына иҗтиһад (тырышлык) иткәннәрдер. Егерменче йөзнең башында туган сәяси агымнарымыз, дәүләт Думасы әтрафында (тирәсендә) ясалган фракционнарымыз да бу гаяга (төп теләккә) садыйк (тугры) калганнардыр.

1917 ел ихтилялене (революциясен) безнең халык үзенең милли терелүенә, мәдәни инкишафына (күтәрелешенә) сонгый (ясалма) рәвештә кара руслык тарафыннан куелган киртәләрнең җимерелүе вә халкымызның табигый рәвештә үсүенә мәйданның ачылуы дип каршы алгандыр. Беренче ихтиляль көннәреннән үк рус халкы үзенең мәдәниятен җимерергә ябырылганда, безнең халкымыз үзенең милли тормышының җитешмәгән йирләрене төзергә, милли юлыны сызарга вә киләчәктәге милли дәүләтене корырга керешкәндер. 17 нче ел ихтилялененең беренче ае эчендә үк халкымызның авыллардан башлап зур шәһәрләремезгә кадәрге бер-берсенә багъланган халык комитетлары ясап өлгерүе, гаскәрләремезнең һичбер кемнең әмереннән башка үз йөрәк тибүләренең кушуы берлә генә аерым татар алайлары (полклары) төзүләре боның аяклы дәлиледер. Беренче Мәскәү корылтае менә шул халыкның милли теләкләрен мәгълүм бер шәкелгә сугарга вә боның эшләрен үзеннән сайланган һәйәтләргә (комиссияләргә) бирергә тырышты. Ләкин бу корылтай бөтен Русия мөселманнарының корылтае булганга вә төрле өлкәләрдә яшәгән кардәшләремезнең мәдәни сәвияләре (дәрәҗәләре) бертөсле булмаган кеби, мәсьәләләре дә йирле шараит (шартлар) астында төрлетөрле булганга, Мәскәү корылтаеның тугдырган башкармасы табигый бөтен вазыйфаларыны эшләп бетерүдән гаҗиз иде.

Нәтиҗәдә һәрбер өлкәнең үзендә аерым-аерым өлкә башкармалары, өлкә корылтайлары мәйданга китерелү мәҗбүрияте туды. Шуны аңлап, Идел-Урал төрк-татарлары икенче бөтенрусия мөселманнары корылтаенда Идел-Урал төрк мөселманнарының йирле эшләре берлә генә мәшгуль булачак милли мөәссисе (органы) тугдырырга вә шуны кануни рәвештә ясар өчен Милләт мәҗлесе җыярга карар бирделәр. Казанда 22 июльдә Өченче корылтайның тупланган мәҗлесендә шул эшне вөҗүдкә чыгарыр өчен махсус мохтарият (бәйсез) һәйәте дә сайладылар. Мохтарият һәйәте сайлау низамнамәләрен (шартларын, канун-кагыйдәләрен) хәзерләп, илемезне сайлау даирәләренә бүлеп, 1917 ел, 20 ноябрьгә сайланган Милләт мәҗлесе әгъзаларын Уфага дәгъвәт итте (чакырды). 22 ноябрьдә ачылган Милләт мәҗлесемез 11 гыйнвар 1918 елга кадәр дәвам итеп, Идел-Урал төркләренең дини, мәдәни мәсьәләләрене бер шәкелгә сугып, бу теләкләрне милләт исеменнән канунилаштырды. Идел-Урал дәүләте коруның нигезләрене салып, киләчәк дәүләтемезнең түмәл (гомуми) ташын корды. Милләт мәҗлесемезнең тугдырган Милли идарәсе вә аның шөгъбәләре (бүлекләре) үзләренең даирәләрендә милли эшләрене эшләп, бөтен яктан халкымызны тәшкилятләндерелгән (оештырылган) бер хәлгә китерергә һиммәт вә гайрәт сарыф итте. Рус большевик дулкыны илемезне басып киткәнгә, безнең халкымызның җаннан теләгән бу милли төзелеше үзенең бөтен эшләрен тәмам итә алмаудан туктап калырга мәҗбүр булды. Большевик дәверендәге ачлык вә төрле-төрле халкымызга юнәлдерелгән җәбер-золымнар, халкымызның 17 нче елда туган бу милли корылыш өмидене кар астында калдырды. Бу теләкләрне халкымыз күңел эчендә генә саклый алды.

Бүгенге көндә илемезнең кичергән канлы-яшьле вакыйгалары бу теләкләрне яңартып җибәрергә имкян (мөмкинлек) бирмәгән кеби, 20 еллыгы бу көннәрдә тулган шул милли вакыйгаларны истәлек төсендә үткәрергә дә ирек бирмидер. Ләкин бу зур вакыйга, халкымызның тормышында зур бер дөнүм (борылыш) башы булган Милләт мәҗлесе үз-үзеннән онытылудан өсттә тора торган тарихи бер хәлдер. Урысларның безне миллиятсезләндерер өчен сонгый (ясалма) рәвештә оныттырырга теләүләренә карамастан, тарихымызда зур бер урын тотачагы аурупалыларның биргән кыйммәтләре берлә дә мәгълүмдер. Милләт мәҗлесенең татлы көннәрене яшәгән мөһаҗирләремез табигый бу олуг көннең хатирәсе алдында сирче (сөерче) булып үтә алмый иде вә үтмәскә тиеш иде. Халкымызның шул әхвал рухиясен игътибарга алып, без «Милли юл»да («Яңа милли юл»да) бәйрәм хәзерлекләре күренү тиешлеге хакында язып үттек. Милләт мәҗлесенең мөһаҗәрәттәге әгъ-

заларына тугрыдан-тугры шул көнне уздырырга чакырып хатлар яздык. Мөһаҗирлегемезнең төрле мәмләкәтләргә таркау гөруһларына (төркемнәренә) бер көндә бәйрәм итүне тәклиф итеп (кушып), мөрәҗәгатьләр дә булындык (юлладык). Мөһаҗәрәтлегемезнең киң катлавы безнең бу мөрәҗәгатемезне сөенә-сөенә каршы алып, бәйрәм хәзерлекләренә башласа да, Милли идарәнең мәгашлы (хәлле) әгъзалары вә Милләт мәҗлесенең әгъзалары бу милли эшкә һичбер төсле иштиракь итмәделәр* (катнашмадылар). Безгә тагы шул ук милли мәсьәләне оештыру вазыйфасы төште. Бондый зур милли күләмдәге бәйрәмне үткәрү өчен кирәк сәяси яктан вә кирәк халкымызның мәдәни көчләре булынуы ягыннан зур гына берләшкән көч кирәк иде. Аурупа мөһаҗирлегемездә аз-чук бу шартларның Финляндия илдәшләремез йә Ләһстанда яшәүче илдәшләремез арасында гына табылуы мөмкин иде. Ләһстан әфкяре гомумиясенең (җәмәгатьчелек фикеренең) безнең милли эшләремезгә хәерхаһча (теләктәш) каравы, сәяси вазгыятьнең мөсагыйд (аваздаш, ярдәмче) булуы бу мөһим истәлек бәйрәмемезне Варшауда ясауны алга сөрде. Без дә Идел-Урал төркләренең милли күләмдәге беренче бәйнәлмиләл (халыкара) бәйрәмен Варшауда ясадык. Шуны да кушып китәргә кирәк ки, Ерак Шәрыктагы мөһаҗәрәтемез бу мәсьәләдә дә безнең берлә бер фикердә, бер уйда булса да, ара ераклыгыннан бу бәйрәмне үзенә аерымчада (аерым) уздырырга кирәкле тапты вә киң рәвештә истәлек бәйрәмен бөтен шәһәрләрендә уздырды. Бәйрәмемез олуг бер тарихи вакыйгамызның хатирәсе булганга, мөһаҗирлегемез никадәр йитешсезлек эчендә яшәсә дә, истәлегемезне милләтемезнең шәрәфе, хиссиятенә тап калдырмаслык рәвештә үтәргә тиеш иде. Шуны игътибарга алып, Аурупаның төрле мәмләкәтләрендә яшәүче Идел-Урал мөһаҗирләренә хосусый мөрәҗәгатьләр дә булынып (булып), матди-мәгънәви ярдәмнәрен таләп иттек. Мәҗлесләремезгә катышыр өчен вәкилләр күндерүне, милли уеннарымыз, көйләремез, музыкамызны күрсәтер өчен һөнәрле яшьләремезне җибәрүләрен риҗада булындык (үтендек). Варшаудагы яшьләремезне, мәктәп балаларымызны Милләт мәҗлесе мөнәсәбәте берлә ясалачак мәрасимнәрдә (тантаналарда) иштиракь итәргә хәзерләргә ике ай элек башладык. Варшауның Идел-Урал яшьләре, мәрасимнәрнең бөтен мәсьүлиятләрен (җаваплылыгын) үз өсләренә алып, хәзерлеккә керештеләр, төрле рәсми мөәссәсәләрдән (оешмалардан) рөхсәтләр алдылар, матбугат

---

* Мөрәҗәгатьләремез тәгаһһедле (йөкләмәле җавап белән) күндерелгән булса да, Милләт мәҗлесе әгъзасы Г.Баттал бәктән башкасыннан җавап та килмәде *(Г.И.)*.

әһеле берлә шәхсән күрешеп, аларның дустча язуларын тәэмин иттеләр, матбугатка вә һәм дә безнең мәсьәләләремез берлә кызыксынган даирәләр вә шәхесләргә тарату өчен Идел-Урал хакында ләһ (поляк) телендә мәкаләләр, рисаләләр хәзерләделәр, атналар буе вакытларын кызганмаенча, сабакларын да калдырып, шул олуг көндә йөземезгә кызыллык килмәсен өчен бөтен көч-куәтләрен сарыф иттеләр. Ләһ дустларымыз вә кардәшләремез, поляк татарлары вә башка төрк җәбһәсенең (кавеменең) мөмасилләре (вәкилләре) безнең бу авыр эшемезне җиңеләйтер өчен мәгънәви ярдәмдә булындылар. Төрле өлкәләрдәге мөһаҗирлегемез дә безнең бу бәйрәмемезгә кулыннан килгән бөтен көче берлә катышырга тырышты. Финляндиянең Тампере мәхәлләсе уенчы, җырчы төркеме берлә безгә үзенең ил картларыннан берничә могтәбәр затны да бу мәҗлескә вәкил итеп күндерде. Мәҗлесемезнең дини кыйсменә иштиракь итәр (катнашыр) өчен Финляндия имамы Вәлиәхмәд Хәким хәзрәт тә чакырылган вә килергә хәзерләнгән булса да, милли-дини бәйрәмнәргә дошманча караучы Һельсинкидагы бер-ике кызыл авызның фетнәсе берлә, ул бу дини-милли вазыйфасын үтәүдән мәхрүм ителде. Төркия мөһаҗирлегемез, сәнгать ягыннан югарыда торган берничә әгъзасын җибәреп, мәҗлесемезнең муаффәкыйтьле (уңышлы) чыгуына ярдәмдә булынды. Алманиядән дә берничә милләттәшемез иштиракь итте. Поляк татарларының һәрбер мәхәлләсе махсус сайланган вәкилләр күндерделәр. Үземезнең Варшау Идел-Урал мөһаҗирлегемез тулы сәфәрберлек (тупланыш) хәлендә булынды. Төрле йирдән тупланган уенчы, җырчы, музыкачы төркемнәремезне берләштереп, бер милли төркем ясау эше шактый авыр булды. Шулай булса да, иштиракь иткән төркемнәрнең көнне кичкә катып тырышулары аркасында, бу авыр эш тә уңыш берлә төгәлләнде.

## 6 февральдә Милләт мәҗлесенең 20 еллыгы уңае берлә Гаяз әфәнде Исхакыйның Варшау радиосы аркылы сөйләгән сүзләре*

Хөрмәтле тыңлаучылар!

Без, Идел-Урал төрк-татар мөселманнары, бүген үземезнең туган илемез Идел-Уралның беренче Милләт мәҗлесенең егерме еллык хатирәсен үткәрәмез. Халкымызның хаклы таләпләренең тәрҗеманы (белдертүчесе) булган беренче Милләт мәҗлесенең бу олуг көне, туган илемездә милли дошманнарымыз тарафыннан галякасыз (үзара элемтәсез) үткәрелергә тыры-

* Яңа милли юл. — 1938. — № 3 (120). — 28–29 б.

шылса да, безнең мөһаҗәрәтемез бу көнне Озак Шәрыкта, Якын Шәрыкта, Аурупаның Идел-Урал мөһаҗәрәте яшәгән Финляндия, Эстония, Алмания, Ләһстан мәмләкәтләрендә олуг бәйрәм төсендә үткәрәдер. Хаклык сөюче мөсафирпәрвәр (эмигрант-патриотлар) Ләһстанның пайтәхете (башкаласы) Варшау шәһәрендә бу хатирә көне Төркия, Алмания, Финляндия, Ләһстанның төрле шәһәрләреннән килгән хөрмәтле вәкилләрнең иштиракы (катнашы) берлә, кардәшләремез азәри (азәрбайҗан), Кырым вә Төркестан төркләре, Шимали (Төньяк) Кафкас мөселманнары вә җәбһәдәшләремез (көрәштәшләребез) «Прометей» милләтләренең самими дустлыклары астында тантаналы рәвешендә өч көннән бирле дәвам итәдер. Мөһаҗәрәттә тугдырылган Ерак Шәрык корылтаеның ачылуына өч ел тулу хатирәсе* дә катышканга, бүген һәрбер йирдә халкымызның барлыгы, берлеге, үзлегене саклау тартышы төсендә дәвам итәдер. Мөһаҗәрәт дулкыны берлә дөньяның дүрт тарафына сибелсә дә, күңеленнән бер калган вә милли байрагы әтрафында (тирәсендә) рухан берләшкән бөтен милләттәшләремезне шул тарихи көн берлә тәбрик итәм! Илемездәге миллионнарча милләттәшләремә мөһаҗәрәтнең милләтчелек сәламене күндерәм. Киләчәктә шундый олуг милли бәйрәмнәремезне тулы ирекле, иркенле, бай, мул туган илемез Идел-Уралда үз йир-суына, үз йортына үзе хуҗа булган халкымыз берлә исәнлек-саулык, шатлык, тынычлык эчендә каршы алырга Тәңре Тәгалә насыйп итсен! Яшәсен милләтемез, яшәсен илемез Идел-Урал!

## Нинди төскә керсә дә, асылы бер...

Алга барырга теләгән халык үткәнне өйрәнә, үзен борчыган сорауларга тарих сәхифәләреннән җаваплар эзли, булып узган вакыйга-хәлләрдән үзенә гыйбрәт ала. Шөкер, без дә әкренләп тарихыбызга борыла башладык, анда үзебез өчен сабак булырдай нәрсәләрне күреп, хәйран да калдык. Баксаң, халкыбызның каһарман уллары теләсә нинди шартларда көрәштән туктап калмаганнар икән: хәрәкәт иткәннәр, тарих, заман һәм киләчәк хакында уйланганнар, фараз да кылганнар... Әнә шундый фидакарь затларның берсе — Гаяз Исхакый (1878–1954). Хәзерге укучы инде аның олуг әдип, атаклы публицист, мәшһүр идеолог һәм җәмәгать эшлеклесе икәнлеген белә. Әмма бу белү әле, нигездә, гомуми планда, вывесканы — күрсәтмә, элмә тактадагы текстны үзләштерү күләмендә генә. Гаяз Исхакый

* Ерак Шәрык корылтае Г.Исхакый инициативасы белән 1935 елда Кытайда, Мукден шәһәрендә үткәрелгән.

язганнарның төп эчтәлеге, мәгънәсе, эшчәнлегенең асылы нәрсәдән гыйбарәт, — бу хакта әле киң катлам укучыларның гына түгел, хәтта белгечләрнең дә күзаллаулары шактый сыек. Һич шикләнүсез әйтергә кирәк, Гаяз Исхакый — ул татар тормышының феномены, ягъни гадәттән тыш сирәк очрый торган күренеше. Аны белү ул — мәдәниятебезне, тарихыбызны белүнең, милли үзаңны үстерүнең мөһим чараларыннан, факторларыннан берсе. Шуңа күрә безгә бу фидакарь затның һәр язганын, һәр эш-гамәлен өйрәнү һәм белү, алардан сабак алу — тарихи зарурият һәм рухи ихтыяҗ.

Укучыларга без Г.Исхакыйның «Бугазлар» исемле язмасын тәкъдим итәбез. 1936 елның август аенда язылган бу мәкалә «Яңа милли юл» журналының шул ук елгы сентябрь санында (№ 9 (102). — 1–8 б.) дөнья күргән.

Г.Исхакый мөхәррирлегендә 1928–1939 елларда Берлинда чыккан «Яңа милли юл» хакында инде без махсус мәкаләләр бастырган идек. Журналдагы аерым материаллар (нигездә, баш мөхәррирнең үз язмалары) да кереш сүз һәм тиешле аңлатмалар белән укучыларга ирештерелде. Безнең бу мәкалә шул эшнең дәвамы булып тора.

Англия, Франция, Италия, Япония һәм кайбер башка илләр катнашында Лозаннада уздырылган Халыкара конгресс үзенең 1923 ел 24 июль килешүе белән Төркияне Босфор һәм Дарданел бугазларына ия булу хокукыннан мәхрүм итте. Ачык диңгез юллары дип игълан кылынган бу бугазлар белән идарә итү халыкара комиссиягә тапшырылды. Әлбәттә, сугыштан, эчке һәм тышкы каршылыклардан хәлсезләнгән Төркия бу хурлыклы карар белән вакытлыча ризалашырга мәҗбүр булды.

Кәмал Пашаның (Ататөрекнең) сыгылмалы, оста сәясәте нәтиҗәсендә Төркия әкренләп ныгый, үзенең халыкара дәрәҗәсен күтәрә барды. Лозанна килешүен юкка чыгару өчен көрәш хәрәкәте төрекләр арасында киң колач алды. Ниһаять, Төркия таләбе белән 1936 елның 22 июненнән 20 июленә кадәр Швейцариянең Монтре шәһәрендә уздырылган Халыкара конгресс Лозанна килешүләрен юкка чыгарырга һәм Дарданел, Босфор бугазлары белән идарә итү эшләрен төрекләрнең үзләренә кайтарып бирергә мәҗбүр булды. Шулай итеп, табигый хаклык, иҗтимагый гаделлек, гәрчә тулысынча булмаса да, тантана итә. Г.Исхакый мәкаләсе әнә шул халыкара вакыйгага, төрек кавеменең шатлыклы, куанычлы көннәре уңае белән барлыкка килгән.

«Бугазлар» язмасы кайсы яклары белән игътибарга лаек соң? Шуларның берничәсен генә атап китик.

Мәкалә безгә дөньядагы илләр, милләтләр тормышының үзара багланышлы булуын, 20–30 еллардагы халыкара вазгыять-

нең ниндилеген, Төркиянең эчке халәтен һәм тышкы мөнәсәбәтләрен шактый дәрәҗәдә күрсәтеп тора. Рәсәй-Төркия каршылыкларын тарихи планда яктырту — язманың иң кыйммәтле якларыннан берсе.

Башка илләрне һәм халыкларны яулап алу, буйсындыру яисә үзенә бәйле итү — урыс хакимиятенә элек-электән хас сыйфат. Идел-Урал, Себер, Алтай, Ерак Көнчыгыш, Казакъстан, Урта Азия, Кавказ, Кырым, Балтыйк буе... — болар бит берсе дә урыс җирләре түгел, ә башка халыклардан тартып алынган җирләр. Шунысы гаҗәп: бу гайре табигый процесс, әхлаксыз эш-гамәлләр еш кына «ирекле кушылу», «кушылу», «үзләштерү», фәләннәрдән «азат кылу», «цивилизацияле итү», «иминлек урнаштыру», «Ватанның чикләрен ныгыту» һәм матур яңгырашлы башка шундый сүзләр белән аңлатып киленде һәм хәзер дә шулай дәвам итә. Рәсәй–Татарстан шартнамәсенә кул куелуның икенче көнендә, ягъни 16 февральдә «Останкино» каналы буенча «Яңалыклар»ны тапшыручы диктор телевизор караучыларга мондый эчтәлектәге мәгълүмат бирде: «Казан ханлыгы була. Ул Рәсәйгә кушыла (присоединилось). Октябрь инкыйлабына кадәр татарлар империя составында имин генә яшиләр...»

Татар мәмләкәтләренең, шул исәптән Казан ханлыгының Мәскәү хакимияте тарафыннан ничек яулап алынуы, татарларның дүрт гасырдан артык колониаль изелү астында нинди «имин»лектә яшәүләре* хәзерге вакытта хәтта мәктәп балаларына да мәгълүм була бара. Империя тарафдарлары өчен «бүленмәс һәм бердәм» төшенчәләре, әйтерсең дөнья яратылганнан бирле килә торган мәңгелек табигый төшенчәләр. Әйтерсең ят җирләр һәм халыклар Мәскәү хакимиятенә Ходай Тәгаләнең үзе тарафыннан бүләк ителгән...

Мәгълүм булганча, Төркия белән мөнәсәбәт — урыс тышкы сәясәтенең иң мөһим өлеше. Әмма биредә тигезлек, хезмәттәшлектән бигрәк, Рәсәй империясенең үз күршесен буйсындыру, ахыр чиктә аны тәмам юк итү максаты өстенлек итә. Петр I нең 1725 елгы яшерен «Васыятьнамә»сенә** генә мөрәҗәгать итик. Анда мондый юллар бар: «Русия мәмләкәтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга

---

* Бу хакта күзаллау тудыру өчен М.Худяковның мәшһүр хезмәтенә («Очерки по истории Казанского ханства...») һәм Р.Әмирхан, В.Имамовның «Татарларның Ватан сугышы» (Яр Чаллы: КамАЗ, 1993) һәм В.Имамовның «Запрятанная история татар» (Наб.Челны: КамАЗ, 1994) китапларына күз салу да җитә.

** Яшерен васыять // Казан утлары. — 1992. — № 1. — 166–168 б.

күчерү шарт... Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда иляһи патша булачак... Һиндстанның ачкычы — Төркиянең башкаласыдыр... Төркия дәүләтен юк итүдән элек Иранның җанын алуны киңәш итмим».

Кайберәүләр Петр I нең кан коюга, басып алуга юнәлтелгән бу әхлаксыз «Васыятьнамә»сен Рәсәй сәясәтенең хосусый бер күренеше итеп кенә күрсәтергә омтылалар. Әмма мондый караш өчен һич тә нигез юк. Чөнки Петр патша бу яшерен документны үзенә кадәрге һәм үз чорындагы урыс рәсми сәясәтенә таянып төзегән, хөкемдар Иваннардан килә торган басып алу, буйсындыру сәясәтен гамәлгә ашыруга үзе дә зур өлеш керткән. «Васыятьнамә»нең төп эчтәлеге, гомумән, күпгасырлык Рәсәй империясенең тышкы эш-хәрәкәтләренә шактый туры килә.

Мәкаләдән Г.Исхакыйның Петр I васыятен белүе яхшы аңлашыла. Әмма «Бугазлар» язмасы авторы өчен Рәсәйнең колониаль сәясәте болай да ачык. Чөнки ул бу сәясәтнең нindileген газиз халкының язмышында ачык күргән, үз җилкәсендә татыган, аңа каршы көрәше өчен төрмәләргә утыртылып, Архангел якларына сөрелгән, ахыр чиктә сөекле Ватаны — Иделйортны калдырып, чит мәмләкәтләрдә каңгырып йөрергә мәҗбүр булган. Бөек әдип, вафат булып, җәсәден үзгә илдә калдырса да, рухы, язганнары, башкарган эш-гамәлләре белән әкренләп туган җиренә — Идел-йортка кайта...

Г.Исхакый үз мәкаләсендә Рәсәй империясенең Төркиягә каршы үткәрелгән сәясәтендәге төп баскычларны атап китә. Тарихи тәҗрибәне гомумиләштерү рәвешендә ул болай ди: *«Бу васыятьне (ягъни* П е т р I *нең язмасын. — Х.М.) вөҗүдкә чыгарыр өчен, Русия һәрбер форсатдан файдаланып, бу көнгә кадәр Төркиягә һөҗүм итә килде». «Русия, теләсә кызыл төсдә, ак төсдә, берләшкән зур бер дәүләт булып калганда, турыдан-туры Ак (Урта. — Х.М.) диңгезгә чыгар өчен, бугазларын, Истанбулны алыр өчен омтылачакдыр»... «Рус дәүләте идарәсенең төрле-төрле төскә әверелүе, мәмләкәтнең бер режимдан икенче режимга күчүе генә берләшкән Русиянең бу милли сәясәтен үзгәртә алмаячакдыр** *» (ассызык безнеке. — Х.М.).*

Г.Исхакый — гомере буе халыкларның азатлыгы, тигезлеге, иминлеге өчен көрәшкән шәхес. Бу максатка исә империяләрне бетерү, бәйсез милли дәүләтләр төзү, гадел халыкара мөнәсәбәтләр урнаштыру юлы белән генә ирешергә мөмкин.

* Мәскәү хакимиятенең икенче бөтендөнья сугышыннан соң да Төркиядән бугазларны таләп итүен генә хәтергә төшерик.

Мәкалә авторы фикеренчә, Рәсәй (СССР) империясе — Төркия өчен генә түгел, ә башка күп кенә халыкларның, шул исәптән татарларның иминлеге, азатлыгы өчен дә киртә. «*Русия тарафындан бугазларның, Истанбулның әминияте (иминлеге. — Х.М.), Төркиянең үзенең бу йирләрдәге алты йөз еллык хакимиятенең тулы көенчә дәвам итдерелүе, — дип яза Г.Исхакый, — рус империализмының кырылуы берлә генә тәэмин ителә beləчәкдер. Бу да руслыкның истилясындан (басып алуыннан. — Х.М.) Украина, Кафкас, Кырым кеби Кара диңгез дәүләтләренең кортылып (котылып; корылып. — Х.М.), яңадан үз милли истикъляльләрене (бәйсезлекләрене. — Х.М.) кайтарулары берлә, үз башларына аерым милли дәүләтләр төзеп яшәүләрен тәэмин итү берлә генә мөмкин булачакдыр*» (ассызык безнеке. — *Х.М.*).

1930 елның урталарында язылган «Бугазлар» мәкаләсе күп кенә фикер-күзәтүләре белән бүгенге көнгә дә аваздаш. Һаман да Кара диңгез, Кырым, Кавказ өчен көрәш бара. СССР дәүләтенең варисы Рәсәй һаман да империя булып кала килә, милләтләрнең үзбилгеләнүенә төрле киртәләр корыла, кеше хокуклары бозыла, бәйсезлек алган халыкларның эчке эшләренә тыкшыну дәвам итә...

Г.Исхакый СССР империясе составындагы урыс булмаган халыклар арасында киләчәктә милли хәрәкәтнең көчәячәген һәм ахыр чиктә аларның бәйсезлек алачакларын искәртә. Бөек әдипнең бу фаразы, бик акрынлык һәм кыенлык белән булса да, гамәлгә аша бара. Мәкалә авторның империя көчләре белән сак эш итәргә, аларның вәгъдәләренә алданмаска чакыруы белән бүген дә актуаль яңгырый.

«Бугазлар» язмасы тарихи чыганак буларак та игътибарга лаек. Халыкара тормышның, сәяси көрәшнең үзәгендә кайнаган Г.Исхакый фикерләре, аның үткән, хәзерге, киләчәк заман турында уйланулары бүгенге тарихчылар, сәясәтчеләр өчен дә яхшы материал. Чөнки анда сабак, гыйбрәт алырлык нәрсәләр күп. «Бугазлар» мәкаләсенең, безнең уебызча, Төркия галимнәре өчен дә файдасы зур. Чөнки аның төп эчтәлеген Төркиягә мөнәсәбәтле вакыйга-хәлләр тәшкил итә.

Мәкалә Гаяз Исхакыйның тарихны, халыкара вазгыятьне яхшы белүче, сизгер, үз мәсләге ачык булган зирәк сәясәтче, дипломат икәнлеген янә бер мәртәбә раслый. Аның карашлары бүгенге милли һәм иҗтимагый хәрәкәт өчен аеруча мөһим.

*1996*

## Бугазлар*

*Гаяз Исхакый*

Төрле-төрле бик күп зур вакыйгаларга бай булган 1936 елның булып үткәнләре арасында Монтрода (Монтрё — Швейцариядәге шәһәр) тупланган бугазлар конгрессы да, шөбһәсез, киләчәктә зур бер урын тотачакдыр.

22 июньдә ачылган бу конгресс уңышлы эшләрене 20 июльдә генә тәмам итеп, үзенең карарларында 1923 ел, 24 июль тарихында бугазлар хакында Лозан(на)да (Швейцариядәге шәһәр) кабул ителгән бәйнәлмиләл (халыкара) карарларны үзгәртде. Лозан могаһәдәсе (шартнамәсе, килешүе) буенча, кирәк Чәнак калга бугазы (Дарданел), кирәк Истанбул бугазы (Босфор) ачык диңгез юллары итеп игълан ителгән вә болардан үтү-кичүне идарә итү бәйнәлмиләл бер комисионга (комиссиягә) тапшырылган, Төркия дәүләтенең бугазларны ныгыту, бугазлар тирәсендә гаскәр тоту хакы да бетерелгән иде. Нәзари (күзәтүче, контроль) уларак бугазларның саклануы, Лозан могаһәдәсенә кул куйган Ингилтәрә (Англия), Франса, Италия, Япуния мәмләкәтләренең хакы вә бурычы итеп кабул ителгән вә бу могаһәдә Җәмгыяте әкъвамның (Милләтләр лигасының) карамагына тапшырылган иде.

Лозан могаһәдәсе буенча, 1358 елдан бирле һичкем берлә уртаклашмаенча, төрекләрнең биләп килгән мәмләкәтләренең капкасы булган Дарданелның, Истанбул бугазының ачкычы кулларындан алынган, төрекләрнең каравылчылары, сакчылары бугаздан ераклашдырылган иде. Мөстәкыйль бер дәүләтнең сәламәтлеге өчен бу һичбер төрле итдереп кабул ителерлек эш булмаса да, 14 еллык сугышдан бик арып чыккан яңа Төркия, бу тарихи хакларында каты торырлык көче юклыгын белеп, теләр-теләмәс бу шартларны кабул итәргә вә бу могаһәдәне үзгәртүне киләчәкдәге бер форсатка калдырырга мәҗбүр булган иде. Яңа Төркия эчке эшләрен юлга куеп бетерер-бетермәс, бугазларның ачык калдырылуы Төркиянең истикъляле (бәйсезлеге) берлә һичбер оешмый торган бернәрсә икәнен бик ачык күрде. Бик тиз Лозан могаһәдәсенә имза атган (кул куйган) дәүләтләр арасында бугазларны саклауны Төркиягә кайтару хакында мөрәҗәгатьләр дә булынды. Ләкин төрле сылтаулар табып, дәүләтләр бугазлар хакындагы карарларыны яңадан карарга ашыкмадылар. Бугазларны ачык калдыра килделәр. Төркиягә: «Сезнең дәүләтегезнең сәламәтлеге Җәмгыяте әкъвамның фәләненче маддәләре (статьялары) берлә тәэмин ителгән фәлән», — дип, сүзне кайтара килделәр.

---

* Яңа милли юл. — 1936. — № 9 (102). — 1–8 б.

Җәмгыяте әкъвамның әгъзалары Италия берлә Хәбәшстан (Абиссиния; Эфиопия) арасында чыккан сугыш да Җәмгыяте әкъвамның көчсезлеге, зәгыйфь Хәбәшстанны куәтле Италиягә каршы химая итәрлек (якларлык) бәйнәлмиләл куәтнең мәүҗүд (хасыйл) булмавы Төркия әфкяре гомумиясене (иҗтимагый фикерен; җәмәгатьчелек карашларын) галәйанга (кузгатуга; ярсытуга) китерде. Безнең дә мәмләкәтемезне саклавымыз фәкать үз көчемез берлә генә мөмкин булачак, нә Җәмгыяте әкъвам, нә дә Лозан могаһәдәсенә кул куйган дәүләтләр, бугазлардан диңгез куәте көчле бер дәүләт, Мәрмәрәгә, Кара диңгезгә кереп, илемезгә һөҗүм итәчәк булса, безгә ярдәмгә килә алмаячаклар икән, шуның өчен бугазларның ачык булуы мәмләкәтемезнең сәламәтлеге өчен зур бер тәһләке (куркыныч) икән, боны мөхәкъкак (һичсүзсез, шикләнмичә) үзгәртергә, бугазларны саклауны үз кулымызга алырга кирәк, — диделәр. Катгый итеп могаһәдәгә имза куйган олуг дәүләтләргә һәм дә Кара диңгез буендагы дәүләтләргә Төркия хөкүмәте яңадан мөрәҗәгать итде. Бугазлар мәсьәләсен хәл итәр өчен аерым бер конгре (конгресс) ясауны таләп итде. Италия–Хәбәшстан сугышы Ак диңгездә (Урта диңгездә) инглизләрнең боңарча хаким булган вазгыятьләренә зарар китерәчәк бер төс алуы вә Ингилтәрә хөкүмәте Ак диңгездәге мовазәнәне (тотрыклылыкны; тигезлекне, балансны) саклауда үз көченә генә таяна алмаячагын күреп, Ак диңгез буенда мөһим җәгърафый урын тоткан Йунанстан (Греция) Төркиянең дә шул эшкә катышдырылуыны кирәкле табды. Төркиянең сәяси әһәмияте, кыйммәте Ингилтәрә күзендә күтәрелде; төрекләр бондан файдаланып, Ингилтәрәдән бугазлар могаһәдәсен үзгәртүгә разыйлыгын алдылар. Франса да Ингилтәрә разый булган эшкә каршы килә алмады. Япуния дә Төркиянең бу таләбене тәмамән хаклы табуын белгертде. Кара диңгез буендагы дәүләтләрдән Румыния, Болгария, СССР ризалыкларыны белдерделәр. Кара диңгез буендагы дәүләтләрдән Украина, Кырым, Гөрҗестан (Грузия) вакытлы рәвешдә большевик истилясы (баскынчылыгы) астында булганга, мөзакәрәгә (сөйләшүләргә) катыша алмадылар. Италия гына бугазлар хакында сөйләшүнең вакыты түгел дип, мөзакәрәгә катышырга разый түгеллегене белдерде. Нәтиҗәдә ун дәүләт йиренә тукыз дәүләтнең вәкилләре катышып, Исвичрәнең (Швейцариянең) Монтро шәһәрендә 22 июньдә конгре ачылды. 20 июльдә бөтен маддәләрдә килешеп, куллар куелып, бугазлар хакында яңа низамнамә (килешү, шартнамә; кагыйдә) төзелде. Монтро конгрессы могаһәдәсенең бугазлар хакындагы бөтен маддәләрене юк итеп, хисап итде. Бугазлар өстендә Төркия хөкүмәтенең һичбер чикләнмәгән хокукыны таныды. Боңарча бугазларны

идарә иткән бәйнәлмиләл комисионны (комиссияне) бетереп, бугазларны идарә итүне Төркиянең үз кулына тапшырды. Төркиянең бугазларны үзе теләгән рәвешдә сакларга, ныгытырга, гаскәрене теләгән йирендә тотарга тулы хакы барлыгыны кабул итеп, кул куелган көндә үк бугазлар тирәсенә төрек гаскәренең йирләшүен кануни табды. 15 августдан игътибарән (башлап), бугазларның бөтен идарәсе Төркиягә күчәчәк ителде.

Сугыш тәһәләкесе (куркынычы) булганда, бугазларны ябу Төркия хөкүмәтенең генә хакы икәнен конгре таныды. Солых вакытында да чит дәүләтләрнең Мәрмәрә диңгезенә, Кара диңгезгә барачак сугыш көймәләренең Төркиянең сәламәтлеге өчен хәтәрле булмауны күздә тотып, Төркиянең хәзерге диңгез көчендән бик күп түбән булу шартлары берлә тәхдид итде (чикләде). Төркия хөкүмәте үзе үк солых вакытында да, сугыш вакытында да сәүдә көймәләренең үтү-чыгуы Төркиянең карамагы астында сәрбәст (ирекле) булуын таләп иткәнгә, бу маддә һичбер тавышсыз-тынсыз кабул ителде. Фәкать Совет Русиясенең үз диңгез сугыш көймәләренә бугазлар тәмам ачык булуыны таләп итүе генә зур моназарәгә (бәхәскә) сәбәп булды. Ингилтәрә, Япуния вәкилләре боны һичбер төрле кабул итәргә тарафдарлык күрсәтмәделәр. Ахырдан Совет Русиясенең бугазлардан сугыш көймәләрене үткәрү хакы башка дәүләтләргә 15 мең тон(на)лык исәпләгәндә, 25 мең тон(на)га чыгарылды. Шулай итеп, бер ай дәвам иткән бугазлар конгрессы тәмам булды, һәм дә дөнья сугышындан соң Төркиянең бугазлар өстендәге алынган хакы кире үзенә кайтару рәвешендә тәмам булды. Конгрега катышкан тукыз дәүләт вәкилләре дә кул куйдылар, ялгыз Италия генә кул куюдан баш тартды. Могаһәдә кануни халән (законлы төс) алды, Төркия хөкүмәте имза атканның соңында ук бугазларга гаскәри куәтене кертде. Фәүкылгадә (гадәттән тыш, чираттан тыш) җыелышына тупланган Төркия Милләт мәҗлесе Монтро могаһәдәсене тәсдыйк итде (раслады) вә Төркия хөкүмәте ике бугазны да ныгытырга керешде.

Лозан могаһәдәсендәге бугазлар хакындагы маддәләр Төркиянең диңгез сугыш куәтләренең артмавыны күздә тотып эшләнгән иде. Бөтен тарафдагы диңгезләре шәрран яра ачык булганда, Төркия дәүләте, байлыгы, көче җитсә дә, сыгыначак бер урыны булмаганга, зур диңгез сугыш көче тугдыра беләчәк түгел иде. Яңа могаһәдә Төркиянең диңгез сугыш көймәләрен артдыруына, Кара диңгездә дә, Ак диңгездә дә хатири сайларлык диңгез көчле бер дәүләт була белүенә киң мәйдан ачды. Төркиянең харижи (тышкы) сәясәтендә яңа-яңа имкяннәр (мөмкинлекләр) тугдырды. Төркия хөкүмәте шуларны күздә тотып, үзенең илен саклау көчен артдырыр өчен 10 еллык

бер план хәзерләп (1936–1946), Милләт мәҗлесендән 67 миллионлык бер тәхсыйсать (программа) кабул итдергән иде. Август башындагы мәҗлесендә тизлек рәвешдә кирәкләр өчен тагын биш миллион лира бирүне Милләт мәҗлесе кабул итде. Хәзерге көндә, бер тарафдан, Төркиянең халкы һәрбер йирдә бугазларның кайтарылу шадлыгы бәйрәмене ясап кила. Икенче тарафдан, хөкүмәт көчле диңгез мәмләкәте булу чараларыны күреп ятадыр. Күптән түгел генә Алманиядән алган дүрт су асты көймәләренең берсе килеп, Төркия бәхриясе (диңгез флоты) тарафындан кабул ителде. Озакламыйча башкалары да берәм-берәм киләчәкләр вә Төркиянең флотын, диңгез көчләрене куәтләндерәчәкләр. Икенче тарафдан, Төркиянең дәүләт химаясендәге (карамагындагы) бер банкы берлә инглизләрнең дәүләт химаясендәге бер малигрупп (ширкәт) арасында Төркиядә «Тимер вә корыч» ширкәте төзелде. Боның сәрмаясе (акчасы; башлангыч капиталы) инглизләр тарафындан бирелеп, вапурлар (пароходлар, суднолар) төзетү эшләренә керешелде. Бондан соң да Төркиянең диңгез кырыендагы шәһәрләрен ныгыту, портларны юлга салу юлында хәрәкәт ителәчәк дигән хәбәрләр йөреп торадыр. Боларның барысы бергә җыелганда, яңа бугазлар могаһәдәсе Төркиянең куәте артуына, Ак диңгездә Төркия роленең зураюына, дөньяның тынычлыгын саклауда тоткан урынының ныгуына сәбәп булачакдыр вә Төркиянең бәйнәлмиләл хөрмәтене бөтен дөньяда артдырачакдыр.

Боңа башка Монтро конгрессы сугышдан соң булган бик күп конгрессларның иң муаффәкыятьлеседер (уңышлысыдыр). Бугазлар могаһәдәсе — сугышдан соңгы зиһният (фикерләү; концепция) берлә эшләнгән могаһәдәне беренче мәртәбә көчләнгән дәүләтнең хакын тану нигезендә үзгәртү, төзәтү могаһәдәседер. Төркия берлә сугышкан дәүләтләрдән Ингилтәрә, Франса арасында сугыш зиһнияте тәмамән беткәнлеген күрсәтә торган дәлилдер. Шуның өчен бу могаһәдәнең Төркия берлә Ингилтәрә, Франса, Япуния арасында самими мөнәсәбәтнең артуына сәбәп булачакдыр. Бу дәүләтләр арасында дустлык нигезендә яңа-яңа аңлашуларның вөҗүдкә (барлыкка) килүенә мәйдан ачачакдыр.

Якын көнләргә кадәр Аурупада Төркиягә каршы сугыш зиһнияте тәмамән бетмәгән кеби бер хәлдә иде. Төркиянең бик күп тәшәббесләре (үтенечләре, мөрәҗәгатьләре) шул зиһният аркасында кысыр кала иде. Бондан файдаланып, Совет Русиясе Төркияне Аурупа агымыннан читдә тотарга тырыша вә төрле ялган пропаганда, интригалар берлә аурупалашу дәверене кичерә торган Төркияне Аурупадан мәгънән (мәгънәви), мадтән (матди) озаклашдырып килә ала иде. Бу могаһәдә больше-

викның ялган пропагандасының зәминен (нигезен, җирлеген) бетерде. Эчке вә тышкы эшләрендә Аурупа зиһниятле төрек милләтенең куәтле Төрек дәүләте булуына киң офык ачты. Ак диңгез тарафыннан Төркиянең сәламәтлегенә Ак диңгездәге мовазәнә (тотрыклылык; баланс) берлә баглап, Төркиянең ул тарафы бәйнәлмиләл бер сигорта (химая, саклау, иминлекне тәэмин итү) астына керде. Калды фәкать Кара диңгез тарафыннан Төркиянең сәламәтлеген саклавы гына.

Төркиягә бу тарафдан һөҗүм итүче куәт фәкать руслардыр. 1699 елда беренче мәртәбә бу эшкә Петр башлады. Төрек гаскәрендән җиңелеп, кире чигәргә мәҗбүр булса да, Петр бугазларны, Истанбулны алуны васыять итеп калдырды. Бу васыятьне вөҗүдкә чыгарыр өчен, Русия һәрбер форсатдан файдаланып, бу көнгә кадәр Төркиягә һөҗүм итә килде. Берсендә ул Төркиядәге христианларны химая итү, икенчесендә истикъляль (бәйсезлек) сораган серблар, болгарларны яклап, өченчесендә Йунанстанның (Грециянең) аерылуына ярдәм итү кеби күренешдә инсани кеби сылтауларга буяшдырса да, асыл максады Петрның васыятен тотып, бугазларны кулда итү булып барадыр. Бу начар уй берлә руслар 1736 да, 1768 дә, 1789 да берсе артыннан берсе Төркиягә каршы сугышлар ясадылар. Бу сугышлар берлә Төркияне арытып, Төркиянең мохтар (ирекле, бәйсез) өлкәсе булган Кырым дәүләтенә, гүя, истикъляль бирдергән төскә куеп, Кырымны әүвәлән Төркиядән сәясәтән (сәяси яктан) аерып, аннары истиля итәләр (басып алалар). Кырым ханлыгының бетерелүе, русларның Кара диңгезнең иң мөһим ноктасы булган Севастопольне забыт итүләре (яулап алулары), Төркиянең Кара диңгез тарафыннан саклану вазгыятене авырайта. Русларга сугыш көймәләрене артдырырга имкян бирәдер. Шул куәткә таянып, Русия бугазларны алуны көннең мәсьәләсе итеп куядыр.

Александр I 1808 дә шул максад берлә Төркиягә каршы сугыш ачадыр. 1828 елны Русия хөкүмәте (Николай I. — *Г.И.*) Йунанстанга ярдәм итү сылтавы берлә тагы бер мәртәбә Төркиягә каршы сугыш ачадыр. Ләкин бу юлында да Истанбулга, бугазларга хуҗа булуга муаффәкъ (уңышлы, нәтиҗәле) була алмыйдыр. 1855 елны Николай I Истанбулны, бугазларны алыр өчен икенче мәртәбә Төркиягә каршы сугыш ачадыр. Ләкин Төркия тарафыннан инглизләр, французлар да катышып, руслар бик каты җиңелеп калалар. Төрекләр иттифакчылар (союзниклар) берлә Кырымга керәләр, Севастопольне алалар. Русия бу җиңелүдән тик калмый. Болгарларга ярдәм сылтавы берлә 1877 дә Төркиягә каршы тагын сугыш ачадыр. Бу юлы рус гаскәре Әдирнәне (Төркиянең Европа өлешендәге шәһәре. — *Х.М.*) алып, Истанбулның Әндәри төбенә (якынына) — Яшел

Күйгә (Аястафануска. — *Г.И.*) кадәр килеп җитәдер. Айа Суфияның манарасына тагарга дип зур чиркәү кыңгыравы берлә Истанбулга керергә тырышалар, фәкать Төркиянең соңгы көчләре берлә бик каты Истанбулны саклауларына каршы бер эш дә эшли алмыйдыр. Рус гаскәре арыйдыр, аны хәстәлек басадыр, Аурупа дәүләтләре арага кереп, Болгарстанны төрекләрдән аерып, Берлинда солых ясаталар; рус гаскәре дә иленә кайтып китәдер. 1913 елны Русия Франса берлә аңлашып бетеп, гаскәри иттифак ясап өлгергәч, бугазларны, Истанбулны алырга план корадыр. 1918 елны тәмам булырлык зур бер гаскәри план берлә якын киләчәкле шул бугазларны кулда итү, Истанбулны алу сугышына хәзерлек башлыйлар. План хәзерләнеп бетмәс борын, 1914 елда беренче августда сугыш башланадыр. Төркия үзен битараф игълан итсә дә, аңарга каршы Русия бары бер сугышчы дәүләт кеби карап киләдер, Төркияне сугышдырыр өчен төрле-төрле хәйләләр эшлидер. Кара диңгезне үз ихтыярында гына кеби тотар өчен Истанбул бугазы янына сугыш көймәләрен сакларга җибәрәдер. Алар берлә, төрек сугыш көймәләре чыгып йөрмәсен дип, Кара диңгезнең Истанбул бугазы тамагына миналар чәчәдер. Шул миналарны чәчкән чагында, 28 октябрьдә, Кара диңгездәге төрек сугыш көймәләре берлә бәрелешү ясап, беренче ноябрьдә Төркиягә сугыш игълан итәдер. Иттифакчылары Франса, Ингилтәрә тарафындан Истанбулның Русиягә бирелүенә сүз аладыр. Истанбулны басып керер өчен Одессада махсус йөз меңлек гаскәр хәзерлидер. Чәнак калга сугышларына катышыр өчен үзенең Балтыйк флотындан берничә сугыш пароходын да күндерәдер, һәм дә Кара диңгездә төрек вапурларының (судноларының) йөрүе-килүенә зур комачаулык эшләп киләдер. Бу арада Русиядә сугыш башланып, Русия сугыш сафыннан чыккач гына Төркия ул тарафдан бераз киң сулыш аладыр. Русиянең һөҗүм планы, Петр васыятен тутыру тагын бер мәртәбә соңга калдырыладыр.

Совет хөкүмәте, башка эшләр берлә бик каты мәшгуль булганга, әүвәлге елларда Төркияне бу якдан тыныч калдырып торса да, бераз баш-күз алгач, ул да Кара диңгез флотыны куәтләндерергә керешәдер. Төрле сылтаулар берлә Кара диңгезгә Балтыйкдан сугыш көймәләрен ташыйдыр; ул да бугазларны алуны максад итеп куядыр, Истанбулны кулда итәргә тырышадыр вә киләчәкдә дә тырышачакдыр.

Бер тарафдан Монтро могаһәдәсе берлә Төркиянең Аурупа дәүләтләре берлә багланышы бугазларның бәйнәлмиләл бер тәэминат астына алынуы, икенче җәһәтдән Совет Русиясенең дахили (эчке) вазгыятенең бик чуалчыклыгы Совет Русиясенең бугазларны алып, Истанбулга хуҗа булуыны, бу көнләрнең вазыйфасы итеп куюдан озакдарак торуга мәҗбүр итәдер. Шуны

аңлап, Совет Русиясе гүя Төркиягә дуст кеби күренеп, хәйлә берлә, интрига берлә Төркиянең мәгънәвиятен (рухи халәтен) корып, хаким вазгыятьле булырга, төрек милләтчелеген оетырга, йоклатырга тырышадыр. Фәкать бу асыл максаддан ваз кичү, Петрның васыятене ташлау түгелдер. *Русия, теләсә кызыл төсдә, ак төсдә, берләшкән зур бер дәүләт булып калганда, тугрыдан-тугры Ак диңгезгә чыгар өчен бугазларны, Истанбулны алыр өчен омтылачакдыр* (ассызык безнеке. — *Х.М.*). Берләшкән Русиянең (ягъни СССРның) бу тарафка таба икътисади, сәяси киңәюенә киртә булып торган Төрек хакимлегенә уртадан калдырырга (алдырырга) бөтен көче-куәте берлә тырышачакдыр. Төркиягә каршы ике йөз ел дәвам итдерелгән бу сәясәт рус империализмының анахаттый (төп, магистраль юнәлеш) рәвешене алгандыр. Рус дәүләте идарәсенең төрле-төрле төскә әверелүе, мәмләкәтнең бер режимдан икенче режимга күчүе генә берләшкән Русиянең бу милли сәясәтен үзгәртә алмаячакдыр. *Русия тарафындан бугазларның, Истанбулның әминияте (иминлеге), Төркиянең үзенең бу йирләрдәге алты йөз еллык хакимиятенең тулы көенчә дәвам итдерелүе, рус империализмының кырылуы берлә генә тәэмин ителә беләчәкдер.* Бу да руслыкның истилясыннан (басып алуыннан) Украина, Кафкас, Кырым кеби Кара диңгез дәүләтләренең кортылып (корылып), яңыдан үз милли истикъляльләрене (бәйсезлекләрене) кайтарулары берлә, үз башларына аерым милли дәүләтләр төзеп яшәүләрен тәэмин итү берлә генә мөмкин булачакдыр.

Совет Русиясендәге хәрәкәтләрнең иң куәтлесе, иң җанлысы, руслыкдан сан ягыннан күп, мәдәният ягыннан өстен, вәхшилек ягыннан гына түбән торган гайре рус (рус булмаган) милләтләрнең истикъляль хәрәкәтләре, үз мөкаддәратьләрен (язмышларын) үз кулларына алу агымнары икәнен без белеп, күреп торганга, Кара диңгезнең бу милли дәүләтләренең бәгыс бәгъдәлмәүтләре дә (теләкләре, дәгъвалары; традицияләре) табигый рәвешдә мәйданга киләчәкдер. Табигый рәвешдә Төркиягә каршы ике йөз ел дәвам итдерелгән рус империализмы, Кара диңгез сахиленддән (ярыннан) кырылып, ватылып чигенергә мәҗбүр ителәчәкдер. Бондан соң гына бугазлар вә Истанбул да Төркия хакимияте тыныч бер тормышка кавышачакдыр. Бу көн озакда түгелдер. Монтро муаффәкъкыятен (уңышын) бәйрәм иткән бүгенге төрек дөньясы озакламаенча бугазларның мәңгелек төрек кулында калу бәйрәмен дә итәчәкдер. Бу бәйрәмдә бүген Совет истилясының астында булган безнең туган илләремез (ягъни Идел-Урал. — *Х.М.*) Кырым, Кафкасның, иттифакчымыз Украина, Гөрҗестанның кортылу бәйрәменә дә тәсадеф иткәнгә (катнашканга, очрашканга), бу киләчәк бәй-

рәмнең нәшьәсе (барлыкка килүе) тагын зурраграк булачак. Чыңгыз дәверендәге кеби милли төрк бәйрәме төсене алачакдыр. Бүген һәр йирдәге мөһаҗирлегемез, туганларымызның Монтро муаффәкъкыятьләрен бер җан, бер тән кеби бәйрәм иткәндә, бу бәйрәмнең тууына сәбәбче бугазлардагы сиксән мең төрек шәһиденең рухы алдында тез чүгәмез. Аларның олуг команданы, төрк (төрки) илләренең соңгы өлкәсенең истикъляллен алып калуны төреклек каһарманы Гази Мостафа Кәмал Пашага* төрек Тәңресендән озын еллар гомер теләп, төреклек хөрмәтләремезне, сәламнәрене сонамыз (җиткерәбез).

## Милләтебезнең олуг хадиме һәм юлбашчысы

...1937 елның 5 марты. Варшавадагы Шәрык институтының зур залы. Анда алма төшәрлек тә урын юк: берничә йөз тамашачы. Бирегә Польшаның галим-әдипләре, рәсми хакимият кешеләре, җирле татарлар, Украина, Азәрбайҗан, Грузия, Кырым, Төньяк Кавказ, Идел-Урал, Төркестан һәм кайбер башка төбәкләрнең эмиграциядәге милли-азатлык хәрәкәте вәкилләре — «Прометей» әгъзалары, күпсанлы журналистлар җыелган. Арада Финляндиядән, Алманиядән, Кытайдан, Төркиядән, Румыниядән килгән татар әһелләре дә бар. Залның түрендә Идел-Урал җөмһүриятенең байрагы һәм аның астында Гаяз Исхакыйның зур бер рәсеме. Үзәкләрне өздерерлек итеп кыллы музыка кораллары уйный. Бөтен залга татар моңы, татар аһәңе тарала. Менә бөек әдипнең әдәби иҗатына 40 ел тулу уңае белән оештырылган мәҗлес башланып китә. Аны Шәрык институтының зур галиме Стефан Димушовски ачып җибәрә, юбилярны ихлас күңелдән котлый, аның Идел-Урал бәйсезлеге өчен көрәшүчеләрнең юлбашчысы булуын искәртә. Гомумән, докладта һәм чыгышларда (Гурка — институт мөдире, Сәнатур Садлатски — институт «рәисе», Иделбай — Идел-Урал вәкиле, Ибраһим Утар — Кырым татары, Мирзабала Мәхмүдзадә — кавказлы, Кжижановский — Украина лидеры, Газиз Үзәр — азәрбайҗанлы һ.б.) Гаяз Исхакыйның әдәби, иҗтимагый, сәяси эшчәнлегенә искиткеч югары бәя бирелә, аның төрки-татарлар өчен генә түгел, ә изелгән, бәйсезлек өчен көрәшүче башка халыклар өчен дә үз һәм якын булуы әйтелә. Чыгыш ясаучыларның берсе үз сүзен «Яшәсен Гаяз бәк вә яшәсен мөстәкыйль Идел-Урал җөмһүрияте!» дип төгәлли. Җыелыштан соң зур концерт булуы мәгълүм. Юбилей вакыйгалары матбугатта да яктыртылыш таба.

---

* Мостафа Гази (1880–1938) — илнең беренче президенты (ул 1923–1938 елларда мәмләкәт белән идарә итә). 1934 елда Ататөрек кушаматын ала.

Гаяз Исхакыйның 40 еллык иҗат бәйрәме Финляндиядә, Алманиядә, Эстониядә, Румыниядә, Кытайда һәм милләттәшләребез яшәгән кайбер башка мәмләкәтләрдә дә уздырыла. Чит илләрдә мин татар язучысын бу кадәр зурлаган башка очракларны белмим. Мондый бәхет, биниһая зур хезмәтләр өчен, бары Гаяз Исхакыйга гына насыйп була.

Кызганыч ки, бөек әдипнең иҗат бәйрәме хакында илдәге татар матбугатында бер сүз дә күзгә ташланмый. Әмма шунысын да онытмаска кирәк: 1937 нче еллар СССРда татар зыялыларын, әдип-галимнәрен күпләп кыру, куркыту, төрмәләргә утырту дәвере, әдип сүзләре белән әйткәндә, «очсыз-кырыйсыз үтерүләр, асулар» чоры. Күңелгә ирексездән шундый уй да килә: әгәр дә Гаяз Исхакый, эмиграциягә китмичә, илдә калган булса, аны инде, бәлкем, 30 нчы елларны көтмичә, хәтта Солтангалиевләргә кадәр үк төрмәгә аткан яисә юк иткән булырлар иде. Әмма Мәскәү хакимияте барыбер үзенең җинаятьчел эшен эшләде: әдипне илдәге, Идел-йорттагы укучыларыннан аерды, аның әсәрләрен уку, исемен телгә алу үзе үк җинаять кебек каралды. «Эш күрсәткән ирне ил онытмас», — ди М.Җәлил. Яшәвенең бөтен барлыгын, гомеренең асыл максатын үз халкына, аның азатлыгы, бәхете өчен көрәшкә биргән Гаяз Исхакыйны бернинди кара көчләр дә, тыюлар да халык күңеленнән сызып ташлый алмады. Г.Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»е кебек яңа буынның да олуг затка ихлас мәхәббәте, хөрмәт хисләре барыбер шытып, тишелеп чыкты. Инде менә без ике-өч ел буе аның исемен авыз тутырып әйтә, аерым язмаларын рәхәтләнеп укый алабыз. Әмма әле Гаяз Исхакыйны тулысынча реабилитацияләүгә кадәрге ара бик ерак. Рәсәйнең хакимият оешмалары озак еллар буе татарның рухи мирасын кырырга, җимерергә, юк итәргә остарып бетсәләр дә, кылган гамәлләре өчен гафу үтенеп, аны кабат торгызырга, үстерергә һич тә ашыкмыйлар, хәтта теләмиләр дә. Гаяз Исхакыйның да әле, үзбәкләр әйтмешли, әсман (күк) кеби биниһая зур вә бай мирасы, күпкырлы эшчәнлеге бүгенге укучыларга юньләп билгеле түгел. Безгә бөек әдипнең һәр язганын белү, гомер юлының һәр көнен, һәр атнасын күзаллау зарури.

Гаяз Исхакый — талантлы әдип кенә түгел, ә гаҗәеп сизгер сәясәтче дә. Ул һәм Октябрь инкыйлабына кадәр, һәм аннан соң иҗтимагый-сәяси көрәшнең үзәгендә кайнап, бу темага бик күп мәкаләләр язган кеше. «Үткән елның сәяси дәресләре» исемле мәкалә — әнә шундый язмаларның берсе. Ул Берлинда чыккан «Яңа милли юл» журналының 1938 елгы 2 нче санында (№ 119) баш мәкалә рәвешендә урнаштырылган.

«Үткән елның сәяси дәресләре» язмасында 1937 елгы дөнья сәяси тормышына анализ ясала, киң галәм яшәешенең тар

вакыт аралыгындагы төп көчләре, хәлиткеч тенденцияләре күрсәтелә. Автор дөнья мәмләкәтләренең һәм халыкларының үзара тыгыз бәйләнештә торуына, сәясәтнең, дипломатиянең бик күптөрле факторларга бәйле булуына басым ясый. Мәкаләдә Англия һәм Франция, Алмания һәм Италиянең, «Совет Русиясе»нең сәяси уеннары, асыл мәнфәгатьләре яктыртыла, «урта һәм кече илләрнең» «битарафлыкка» омтылу сәбәпләре күрсәтелә. Гаяз Исхакый өчен дөнья сугышының котылгысызлыгы, анда «Совет Русиясе»нең дә катнашачагы көн кебек ачык.

Бөек әдип — һәр милләтнең, зурмы-кечкенәме, азатлыгы, бәйсезлеге тарафдары, шуның өчен актив көрәшүче. «Совет Русиясе» исә — империя, рус булмаган халыклар төрмәсе. Шуңа күрә бу империянең язмышы — ул күп кенә милләтләрнең язмышы да. Гаяз Исхакый Русиянең корылышын иң зур халыкара мәсьәлә дип карый. «...*Дөньяның икътисади кризисын бетерер өчен,* — дип яза ул, — *киң Русиянең бай өлкәләрен шул өлкәләрнең чын хуҗалары — йирле халыкларга бирү берлә генә шул бай өлкәләрнең хуҗалыгын коткарып калырга мөмкин булачактыр. Бу юл «дөнья тынычлыгы өчен дә», «безнең кеби көчләнгән милләтләрнең тынычланып, мәдәният вә чәчәк ату юлларына аяк басуларына да бердәнбер чарадыр»*. Гаяз Исхакыйның бу фикере бүген дә гаять актуаль яңгырый. Һәм, гомумән, мәкаләдә сабак алырдай, хәзерге көнгә аваздаш яклар шактый.

Заманында безнең әби-бабаларыбыз төзегән Хәзәр, Болгар, Алтын Урда дәүләтләре халыкара мәйданда дәрәҗәле урынны алып торганнар. Алар белән сәяси, дипломатик бәйләнешкә керүне Мисыр, Византия, Иран, Көнбатыш Европа, Кытай, Һиндстан мәмләкәтләре үзләренә мәртәбә дип санаганнар. Әмма ул дәверләр артта калып, татарлар сәясәттән, дипломатиядән читләштерелде. Шуңа да карамастан, милләтебезнең талантлы уллары сәясәт белән кызыксынуларын дәвам иттеләр. Хәзер татар халкы, Идел-йорт, күпгасырлык изелү-сытылудан соң, әкренләп халыкара сәясәткә чыгарга омтыла. Бу эштә Йосыф Акчура, Садрый Максуди, Фатих Кәрими һәм аеруча Гаяз Исхакый кебек масштаблы фикер йөртүче милләттәшләребезнең дә мирасын файдалану нәтиҗәле булыр иде. Чөнки алар халыкара сәяси мәсьәләләр турында татар улы булып фикер йөрткәннәр. Халкыбыз күзлегеннән дөньяга карыйлар, аның мәнфәгатьләрен алга сөрәләр. Бу үзенчәлек «Үткән елның сәяси дәресләре» язмасында да ачык күренә. Анда без авторның үз халкын бөтен барлыгы белән яклавын, аның киләчәгенә ышанычын күрәбез.

Кыскасы, Гаяз Исхакыйның бу мәкаләсе — әдипнең үзен аңлауда, дөнья сәяси тарихын өйрәнүдә һәм милли үсешебез өчен гыйбрәт, сабак алуда мөһим бер материал.

*1993*

## Үткән елның сәяси дәресләре*

*Гаяз Исхакый*

Дөнья сугышы беткәннән соңгы еллар эчендә үткән 1937 нче ел иң чуалчык, иң куркынычлы бер ел булып үтте. Бүген-иртәгә дөнья сугышы башланачак дигән куркулар ел буена әллә ничә мәртәбә тәкрарланды. Испаниядәге илдәш (граждannар) сугышларын игътибарга алмаганда, Аурупа бу елны билфигыль (чынлыкта) сугышсыз кичерә алды. Ләкин бу ел сәяси оешулар, бозылышулар ягыннан бик бәрәкәтле булды. Иң әүвәл искедә Локарно** могаһәдәсе (килешүе) исеме астында, Аурупада тынычлыкны саклау өчен дип берләшкән Ингилтәрә (Англия), Франса, Алмания, Италия дәүләтләре ачык рәвештә ике сафка аерылыштылар.

Куе милләтчелек нигезенә идарәләрен корган Алмания берлә Италия бер тарафта саф тотса, иске либерал халыкчылык нигезенә дәүләтләрен корган Франса берлә Ингилтәрә икенче тарафта саф тотты. Бу ике групп (төркем) зур дәүләтләр үзләренең артыннан төрле-төрле урта вә кечкенә дәүләтләрне дә аз-маз ияртеп, бу бүленүне бөтен Аурупа күләменә кертә яздылар. 1936 елда Ингилтәрә, Франса сафына большевик Русиясе кысылып йөрештергәләсә дә, Франсада чынлап та кайбер гөруһлар (төркемнәр) Совет Русиясенең гаскәри кыйммәте бар дип уйлап, аннан истифадә итү (файдалану) фикерендә булсалар да, Ингилтәрә дә Ерак Шәрыктагы Япуниянең куәтенә каршы Совет Русиясене кулланыр өчен аңарга аз-маз кыйммәт биреп килсә дә, 1937 елдагы Советлардагы очсыз-кырыйсыз үтерүләр, асулар Советларны хисаптан чыгарырга мәҗбүр итте. Ингилтәрә, Франса сафы көннән-көн Советлардан озаклашты (ераклашты). Үзенә иттифакчыны (ишне, союзникны), җәгърафый яктан ерак булса да, идарә вә культур ягыннан якынрак булган Шимали (Төньяк) Америкада эзләде. Ингилтәрә, Франсаның бу юлдагы тырышулары нәтиҗәсез калмады. Америка рәсмән (рәсми рәвештә) Аурупа-Асия (Азия) эшләрендә битарафлыкны (нейтральлекне) саклавында дәвам итсә дә, рәисе җөмһүрнең (президентның) чыгышларында Шимали Американың дуслыгы Ингилтәрә, Франса тарафында икәнлеге кат-кат белдерелде. Ләкин демократ идарәдәге олуг дәүләт-

---

* Яңа милли юл. — 1938. — № 2 (119). — 1–8 б.

** Л о к а р н о — Швейцариядәге шәһәр. Биредә 1925 елда Англия, Франция, Германия, Италия, Бельгия, Чехословакия, Польша арасында Европа иминлеген саклау буенча килешү була.

ләрнең Аурупаның читендә иттифакчы (союзник) эзләүләре, Италия, Алманиянең дә Асиянең иң зур дәүләте Япуния берлә аңлашуларына сәбәп булды. Япуния берлә Алмания арасында былтыр ясалган антикоммунизм могаһәдәсенә (килешүенә) Италия дә катышып, дөнья күләмендә ике өчлек хасыйл булды. Бу ике групп дәүләтләр, дипломат ысулларда гына булса да, ел буе тартышып килделәр. Италия, Алмания, Япуния сафы бүгенге көннең вазыйфасы — бөтендөнья күләмендә коммунизм берлә көрәшү булырга тиеш дигән дәгъваны мәйданга атадыр. Шул көрәшкә башка дәүләтләрне дә чакырып, коммунизм таратуның мәркәзе булган Мәскәүгә каршы бөтен матди, мәгънәви көчләрне борып, дөньяны пакьләнергә чакырадыр. Ингилтәрә берлә Франсадан, әгәр шул эшкә биззат (шәхсән, чынлыкта) катышмасалар, антикоммунизм сафының шул инсани вазыйфасын үтәүгә комачаулык ясауларын таләп итәдер. Франса Совет Русиясе берлә яңлышып булса да ясаган кара-каршы ярдәм могаһәдәсе (килешүе) берлә бәгълы булганга, Ингилтәрә Совет Русиясенең мирасларыннан, Италия, Алмания, Япуниянең бик зураеп, куәтләнеп чыгуларыннан курыкканга, бу ике дәүләт хәзерге хәлдә булган хөдүдләрне (чикләрне) саклауны алга сөреп, киләчәк бәрелешләргә манигъ (киртә) булырга телиләр. Үзләрен рәсми һичбер идеоложи (идеология) тарафдарлары түгел итеп күрсәтеп килсәләр дә, нәтиҗәдә үзләренең көчләре, куәтләре берлә Совет Русиясен вә аның коммунизм җәю хәрәкәтен химая иткән (яклаган) булып чыгалар. Моның берлә генә калмыйлар, бу ике дәүләт антикоммунизм дәүләтләре берлә Совет Русиясе арасында бу тартышлар үз тупракларында булудан курыккан яшь дәүләтләрдән бер битараф саф та ясарга ярдәм итешәләр. Совет Русиясе берлә Алманиянең киләчәк бәрелешүләрендә ике арада изелеп калудан курыккан Балтыйк дәүләтләре Финляндия, Эстония, Латвия, Ләһстан (Польша), Румыниядән озын бер битараф хат (т) (сызык, линия) сызарга тырышалар, сүздә генә булса да мувәффәкъ (уңышка ирешкән) кебек булалар. Бу Балтыйк буе дәүләтләре, коммунизм, антикоммунизм тартышларында үзләренең битарафлыкларын игълан итеп, Аурупада өченче бер группа тәшкил итәләр. Шулай итеп, Совет Русиясе башкаларның аркасына качып, үзенең режимын дәвам иттерергә имкян (мөмкинлек) таба. Ләкин Совет Русиясенең эчендә башланган черү вә җимерелү 1937 елда дию адымнары берлә алга китеп барганга, Ингилтәрә, Франсаның читтән ярдәме берлә генә үзен саклатып кала белүе көннән-көн шөбһәле төскә керә барадыр. Большевик режимының көтелмәгәндә җимерелүе күршеләрнең теләр-теләмәс мөдахә-

ләсенә (катнашуына, интервенциясенә) сәбәп булачак дип уйланыладыр. Бу вазгыять (халәт, торыш) бер җәһәттән антикоммунизм сафының куәтен арттыра барган кебек, битарафлык игълан иткән дәүләтләрнең дә битарафлыкларын Италия—Алманиягә таба хәерхаһчы (теләктәш) битарафлыгына күчүенә сәбәп булып киләдер. Соңгы сафның мәгънәви көче(н) бик зурайтадыр. Үткән елның соңгы көннәрендә битарафлык җәбһәсенең (нейтральлек лагереның) әгъзасыннан Румыниянең сайлау нәтиҗәләрендә антикоммунизм җәбһәсенә күчүе башка битарафларның да эш-эшкә (иш-ишкә) килгәндә кай тарафта булачакларын күрсәтәчәк бер вакыйгадыр.

Аурупаның ике җәбһәсе (лагере; фронты) арасындагы ихтилаф (каршылык, килешмәүчәнлек) мәсьәләсенең икенче мөһим ноктасы — Урта Аурупа мәсьәләсе берлә Ак диңгез (Урта диңгез) мәсьәләседер. Алмания Урта Аурупаның иң көчле бер дәүләте генә түгел, алман халкы Урта Аурупаның иң зур күпчелек ясый торган зур милләтедер дә. Шуның өчен алман халкының Урта Аурупада беренче скрипка уйнарга теләве бик табигыйдер. Версай (Версаль) могаһәдәсе буенча, Аустриянең (Австриянең) халкы шул ук алман булса да, Алманиягә кушылуда манигъ ителгән (тыелган, мәхрүм ителгән) кебек, өч миллион ярымлык Судет алманнары да йире-суы берлә сонгый (ясалма) рәвештә Чехословакиягә кушылгандыр. Дөньяның иң мәдәни, иң көчле алман халкы миллият фикере хаким бер дәвердә табигый уларак бу хаксызлыкка каршыдыр. Табигый уларак алман халкының бу читтә калган өлешен берләштерергә, бер байрак әтрафына (тирәсенә) тупларга омтыладыр. Хосусан Чехословакия хөкүмәтенең Алманиянең кан-җан дошманы Совет Русиясе берлә кара-каршы ярдәм вә дустлык могаһәдәсе берлә багылануын Алмания һич бертөрле иттереп кабул итә алмыйдыр. Нәтиҗәдә бертуктамаенча Алмания берлә Чехословакия арасында аңлашылмаулар дәвам итеп киләдер. Алмания Чехословакиядәге Судет алманнарына үзләренең теләкләре берлә теләсәләр, Чехословакиядә калырга, теләсәләр, Алманиягә кушылырга плебисцит (референдум) ясауны алга сөрәдер вә аңарга чехлар разый булмагач, киң рәвештә Судет алманнарына мохтарият (бәйсезлек, иреклелек) бирүне таләп итеп киләдер. Франса Чехословакия берлә кара-каршы ярдәм могаһәдәсе берлә баглы булганга, Алманиянең бу халкы таләпләренә каршы төшәдер. Ингилтәрә дә Версай (Версаль) солыхы дип ясалган үрмәкүч оясы бер сүтелә башласа, үзеннән-үзе Аурупада сугыш башланып китә дип куркып, статус-квоны (билгеле бер вакытка төзелгән килешүне) булынып киләдер. Алмания дә боларга җавап итеп үзенең Урта Аурупада, Мажарс-

танда (Венгриядә), Югославиядә нофузияне (йогынтысын; үтеп керүен) арттырып, көннән-көн дустларны күбәйтеп киләдер. Ләһстан берлә дустлыкны ныгытып, ике арадагы азчылык мәсьәләсен дә мөзакәрә (сөйләшү, фикер алышу) юлында хәл итеп барадыр. Нәтиҗәдә Италиянең, Ләһстанның хәерхаһлыгына таянып, Алмания Урта Аурупада көннән-көн мәгънәви куәтене арттырып, сәяси вазгыятене сагламлашдырадыр (ныгытадыр; тәэмин итәдер).

Ак (Урта) диңгез мәсьәләсе күбрәк Ингилтәрә берлә Италиянең рәкабәтләреннән (көндәшлегеннән) килеп чыккандыр. Гасырлар буе Ак диңгездә ялгыз башына хаким булып килгән Ингилтәрә Италиянең көндәш чыгуын һәзм итә (кабул итә; таный) алмыйдыр. Аңарга каршы хәзерге көндә үз көче генә җитәрлек булмаганга, Франса вә башка Ак диңгез мәмләкәтләрен берләштереп, Италия галәйһенә (Италиягә каршы) бер Ак диңгез сафы корырга телидер. Ләкин Италиянең Хәбәшстанны (Эфиопияне; Абиссинияне) алганның соңында хасыйл булган җәгърафый вазгыяте аңарга Ингилтәрәнең диңгездән зәгыйфь нокталарын, Җәбәлтарикъ (Гибралтар) бугазын һәм дә Сүәеш (Суэц) каналын һәрвакыт хәтарәдә (куркынычта) тотарга имкян (мөмкинлек) биргәнгә, Италия кулай-кулай гына (җиңел генә) Ингилтәрәнең теләгенә баш имидер. Ул үзенең диңгез куәтен һаман куәтләндерә барып, Ингилтәрәне Ак диңгез өстендә бер базарлыкка (бәхәскә) керешергә мәҗбүр итәргә омтыладыр.

Испаниядәге илдәшләр сугышы Италиягә идеоложи (идеологик) яктан генерал Франкога кул сузарга мәйдан ачса, шул ук Франко Испаниясенең дустлыгы Италиягә Ингилтәрә, Франсаның колонияләре юлындагы мөһим нокталарны тотып, кирәк вакытта аларның җан тамырларыннан тотарга имкян дә тәэмин итәдер. Шуның өчен дә Италия генерал Франконы ачыктан-ачык Испания хөкүмәте дип танып, аңарга бик күп корал вә гаскәри көч берлә ярдәм итеп килгәндер. Инглиз, французларның зур сату-алу юлларының мөһим нокталарын үз контроле астында тотар өчен генерал Франконың җиңүенә, җиңә алмаса, җиңелмәвенә ярдәм дә булгандыр. Испаниядәге илдәш сугышыны да Ингилтәрә берлә Ак диңгез мәсьәләсен күрешкәндә (көрәшкәндә) бер базарлык (бәхәс) ителәчәк мәсьәлә төсендә булдырырга тырышкандыр. Италиянең бу җәсарәтле (кыю; куркусыз) хәрәкәте Ингилтәрәдә зур һәйҗан (борчылу, дулкынлану) уятып, Ингилтәрәне яңадан бик зур диңгез куәте ясарга мәҗбүр итсә дә, Италия дә, һаман Алмания, Япуния хәерхаһлыгына таянып, Ак диңгездә мөһим рольне уйнап килә беләдер. 1937 нче елда мөһим урын тот-

кан Ак диңгез мәсьәләсе 1938 нче елга да зур бәйнәлмиләл (халыкара) мәсьәләләрнең берсе булып керәдер. Якын киләчәктә Италия берлә Ингилтәрәнең аралары тәмамән ачылуга сәбәп булачак вазгыятьне саклап барадыр.

Аурупаның олуг дәүләтләренең бу төстә икегә бүленүе ялгыз идарәләрдәге идеоложи системларның үзгәлекләреннән килеп чыккан бер мәгънәви тартыш кына түгелдер. Бу тартыш икътисади вә сәяси мәнфәгатьләрнең кара-каршылыгыннан килеп чыккан табигый бер хәрәкәттер. Бу тартышка ике тарафның да идеоложи төс бирергә теләве киң катлау укучы халкының аңлаеш сәвиясенә (аңлау дәрәҗәсенә) карап эшләнгән бер осталык кынадыр. Шуның өчен боларның хәле дә сүз көрәштерү — моназарә кылышу бер принципның икенчесенә караганда өскә чыгуы төсендә мәгънәви җиңү кеби генә булачак түгелдер. Матди көчләрнең бәрелешүләре вә бер-берсен матди рәвештә җиңүләре төсендә хәл ителәчәктер. Вә шул матди җиңелүгә заманасына, модасына күрә принцип төсе, идеоложи буявы биреләчәктер. Бу ике зур группның бу тартышы икенче, өченче дәрәҗәдәге дәүләтләргә, дәүләт булып җитәргә өлгерә алмаган милләтләргә дә, үзләренең мәнфәгатенә карап, төрлечә ингыйкяс итәдер (тәэсир итәдер). Вә төрлечә ул дәүләтләр, ул халыклар арасында агымнар тудырадыр. Ләкин үзләренең милли вә дәүләт сәясәтләрен, үзләренең милли мәнфәгатьләре генә ноктасыннан хәл итүдән мәхрүм булып, йә ул тарафның, йә бу тарафның ярдәменә мохтаҗ булган бу икенче, өченче дәрәҗәдәге дәүләтләр дә, дәүләтен корып өлгерә алмаган милләтләр дә бер-берсенә зыйдд (каршы, капма-каршы) агымнарның тууына вә хисләрнең бүленүенә сәбәп буладыр. Кечкенә халыклар тәкъдирнең язуы буенча үзләрен көчле итәр өчен үзләренең халыкларының күпчелегенә таянырга мәҗбүрдерләр. Шуңарга боларның күпчелегенең идарәсе киң мәгънәсендә халыкчыдыр, боларда демократлык хакимдер. Бу җәһәттән болар демократ дәүләтләрнең тезмәсендәдерләр. Бу кечкенә милләтләр, үзләренең барлыкларын саклар өчен, милләтләренең хак хокукын үз дәүләт оешмаларының мәркәзи сикъләт урынына (игътибар үзәгенә; төп юнәлеш итеп) куйганга, миллиятне дәүләтләренең нигезенә куйган куе милләтче Алмания, Италиягә тагы якындырлар. Бу халыкларның дәүләт корып өлгермәгәннәренең күбесе Ингилтәрә, Франса, аларның дустлары Советларның золымы астында булынганга, боларның да зур күпчелеге соңгы групп тарафындадыр. Фәкать болар да, үзләренең максатларына ирешер өчен, үзләренең илләрендә киң халык катлавына таянырга мәҗбүр булганга, болар да халыкчыдырлар, демократ дәүләт системы кабул итүчеләрдер. Ме-

нә шуның өчен дә урта вә кечкенә дәүләтләр, дәүләтләрен корып өлгертә алмаган милләтләрнең, зур дәүләтләрнең бу ике группларыннан берсен ихтыяр иткәндә, милләтнең эчендә төрле-төрле тәзадлар (каршылыклар) чыгадыр. Шуның өчен дә мәдәнияте үсеп җиткән һичбер урта вә кечкенә халыклар бу группларның йә улысына (анысына) йә бусына йөзгә-йөз катышып китә алмагандыр вә киләчәктә дә бу вазгыять дәвам итәчәктер. Бу халәте рухия хөкүмәтләрдә икеләнүне тугдырганга, мәсьүлияттән (җаваплылыктан) курыккан бу урта вә кечек дәүләтләрнең хөкүмәтләре, милләт мәҗлесләре күп вакытта битарафлык юлына сугылырга тырышкандыр. Бондан соң да шул битарафлыкны, үзенең милләтен, дәүләтен саклар өчен, иң муафыйк юл итеп табачаклардыр. Менә шул әхвале рухиянең (рухи хәлнең) имлясы аркасында, Франса үзенең иттифакчыларының (союзникларының) сәламәте мөлкиясен (дәүләт иминлеген) саклау өчен мәйданга китергән кечек Антант(а) дәүләтләре Алмания, Италиягә каршы саф тоту күздә тотылгач та, берсе артыннан берсе сыерылып (аерылып) чыгып, сүздә дуст калып, билфигыль (чынлыкта) битарафлык җәбһәсенә (сызыгына) күчәләр (Югословия, Румыния. — *Г.И.*). Шул ук әхвале рухиянең имлясы берлә Италия Алманиягә сыенучы Маҗарстан, Аустрия, генерал Франко Испаниясе кеби мәмләкәтләр дә антикоммунизм җәбһәсенә тулы әгъза булудан тартынып, шуның хәерхаһы гына булу берлә кифаяләнәләр (канәгатьләнәләр, риза булалар). Дәүләтләрен корып бетерергә өлгермәгән милләтләрдә бу әхвале рухия тагы ачыграк мәйданга чыгадыр.

Демократ дәүләтләр Франса, Ингилтәрә, дөнья статус-квосын саклау өчен Русиянең милли дәүләтләргә аерылу хәрәкәтен вакытсыз табалар. Бу милләтләрнең хаклы таләпләренә һич колак алмаенча, Совет Русиясенә бу милләтләр берлә тартышуында мәгънән (чынлыкта) ярдәмдә булыналар. Дәүләт идеоложисы ягыннан үзләре берлә бер сахәдә (мәйданда; урында) торган бу милләтләрне диктатор большевиклык хатәрәсе (куркынычы) өчен үзләреннән ерагайталар. Куе милләтче дәүләтләр Алмания, Италия бу көчләнгән милләтләрнең таләпләрен хаклы күреп, аларның Русиядән аерылырга теләүләрен бүгенге үз мәнфәгатьләре өчен дә уйгун (уңайлы; кирәкле) табып, бу милләтләрнең истикляль (азатлык, бәйсезлек) хәрәкәтләренә хәерхаһлык күрсәтәләр. Ләкин бу зур дәүләтләр дә большевикларны бетереп, иске Русияне яңадан тудырырга теләгән ак руслар (аклар) берлә Русиядән аерылырга теләгән милләтләрнең берсене алга сөрүдә тәрәддедтән (икеләнү-шөбһәләнүдән) кортыла (котыла) алмыйлар.

Шул чуалчыклар, шул бер-берсен аңламаулар арасында да сулар ага. Дөнья үзенең алган юлыннан бара. Еллар үтә. 1936 ел үткән кеби, менә 1937 дә үтте-китте. Инде 1938 нең бер ае акты-китте. Ул еллар берлә бөтен мәсьәләләр дә бергә агып, алар да үзләренең тәкамелләренә (үсеш-үзгәрешләренә) таба зур-зур адымнар атладылар. Боларның иң күзгә күренә торганы Ингилтәрә, Франса сафындагы үзгәрешләр, бу ике мөгъзәм (бөек, зур), тук дәүләтләр үзләреннән бик күп мәртәбә зәгыйфь булган Финляндия кеби яшь дәүләтләргә кул сузарга, алар берлә кара-каршы сөйләү дәрәҗәсендә олуг башларын кече итәргә мәҗбүр булдылар. Бу дәүләтләрнең хаклы таләпләрен үзләренең таләпләре эченә керттеләр. Төркиянең сәламәтлеге өчен лязем булган бугазлар мәсьәләсен моннан өч-дүрт ел элек ишетергә теләмәгән Ингилтәрә бу ел аның кайнар хамиясе (яклаучысы) булып чыкты. Сүриядә уттимер көченнән башканы танымый торган Франса Сүрия гарәпләренең милли хакларын тану гына түгел, ике-өч йөз меңлек Санҗак (Сүриядә Госманлы империясе чорыннан калган төрекләр яши торган төбәк) төбәкләренең дә милли хакларын танырга мәҗбүр булды. Ингилтәрә империясенең хариҗия назирыны (Тышкы эшләр инспекторыны) бик күп еллар инглиз полисының (полициясенең) тәхте нәзарәтендә (күзәтүендә; контрольлеге астында) яшәтелгән Мисыр вәкиле Нәлхас пашаның Җәмгыяте әкъвамга (Халык җыелышына) беренче аяк басуына «Хуш килдегез!» сүзен балландырып, далландырып (күпертеп) сөйләргә мәҗбүр итте. Димәк, бу еллардагы әхвальнең барышы бу урта дәүләтләр яшь милләтләрнең кыйммәтләрен үстерде. Аларның сәяси сикъләте әсафиларын (дәрәҗәләрен) күтәрде. Бу дәүләтләргә үзләренең кыйммәтләрен бирергә әхвальнең кидеше (?) зур дәүләтләрне үзе кушты.

1937 ел урта күләм дәүләтләрнең алга үрләүләре берлә тәмам булды. 1938 ел безнең кеби дәүләт төзелеше өлгереп бетмәгән милләтләр хәрәкәтенең кыйммәте пәчләви (? арту) елы булачактыр. Аурупаның ике группка бүленгән олуг дәүләтләре моны теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, большевикның эченнән җимерелүе, ватылуы, киң Русиянең яңа корылуы мәсьәләсен бәйнәлмиләл, иң зур мәсьәлә итеп куячактыр. Киләчәк Русиянең корылуы, төзелүендә милләтләр мәсьәләсе иң реаль зур көч булганга, ул куәтне бер дәүләт тә читтә (читкә) быракыб (ыргытып, ташлап) китә алмаячактыр. Бу көн ике группның дипломатлары да урта үлчәү дәүләтләре артыннан, аучылык япкан кеби, киләчәктә бу милләтләр артыннан гайни (шундый ук) хәрәкәтне япачаклардыр. Чөнки дөньяның тынычлыгы боль-

шевизмның җимерелүе берлә фәкать башланачак кынадыр. Аны очлар өчен, дөньяның икътисади кризисын бетерер өчен, киң Русиянең бай өлкәләрен шул өлкәләрнең чын хуҗалары — йирле халыкларга бирү берлә генә шул бай өлкәләрнең хуҗалыгын рус хыялпәрвәрлегеннән (утопиясеннән, фантазиясеннән) коткарып, шәхси мөлкият нигезенә халыкның күпчелеге теләгән рәвештә кору берлә генә тәмам була беләчәктер. Дөнья тынычлыгы өчен дә бу бердәнбер юлдыр. Аурупаларның бер-берсе берлә аңлашуларына да бердәнбер чарадыр. Вә безнең кеби көчләнгән милләтләрнең тынычланып, мәдәният вә рәфаһ (иминлек; чәчәк ату; муллык) юлларына аяк басуларына да бердәнбер гыйлаҗдыр (әмәлдер, дәвадыр). 1937 нче ел биргән сәяси дәрес менә шулдыр.

## Пушкин «русның ... үз йимешедер»

Гаяз Исхакый рус әдәбиятын яхшы белгән, аның мәшһүр классикларын ихтирам иткән. Моны әдипнең күпсанлы әдәби әсәрләре һәм публицистик хезмәтләре, Ибраһим Нуруллинның бу темага мөнәсәбәтле мәкалә-чыгышлары раслап тора.

1937 елда дөнья күргән «Әдәбият пәрдәсе астында русчылык» мәкаләсендә дә (Яңа милли юл, 1937. — № 3 (108). — 1–4 б.) Г.Исхакый рус әдәбиятының олуг вәкиле А.Пушкинның зур талант иясе, көчле шагыйрь булуын һич тә шик астына алмый, аның рус тормышы белән табигый бәйләнгәнлеген, рус телен, рус мәдәниятен баетудагы ифрат олы хезмәтен икърар итә. Әмма бу мәкаләдә без күнекмәгән, хәтта безнең укучылар өчен ят тоелган фикерләр дә бар. Г.Исхакый Пушкинның шәхси тормышын идеаллаштырмыйча, ничек булган, шулай күрсәтергә омтыла, аның иҗатын шул чор рус мохите белән бәйләнештә карый, үзенең фикер-кичерешләрен ачыктан-ачык бәян итә.

1936–1937 еллар... Халыкка хезмәт күрсәткән каләм әһелләренең СССРда меңәрләп-меңәрләп кулга алыну, үтерелү еллары. Репрессиягә эләгүчеләр арасында аеруча рус булмаган, бигрәк тә төрк-татар вәкилләре күп. 30 нчы еллар — инкыйлабка кадәр иҗат иткән күп кенә әдип-шагыйрьләрне милләтчелектә, «буржуаз идеология»не таратуда гаепләү чоры. Шушындый шартларда СССРда — «Эшче вә авыл халкы җөмһүрияте»ндә — Пушкинның үлеменә (тууы булса, әле бер хәл) 100 еллык гадәттән тыш зур тантана уздырыла. Бу хәл Г.Исхакыйга гайре табигый күренә һәм моның сәбәпләрен ул Мәс-

кәү хакимияте уздырган сәясәттән эзли. Аның фикеренчә, Пушкинга «ясатылган бу ихтирамлар, әдәбият, шигырь берлә һичбер мөнәсәбәте булмаган гамилләрнең (факторларның. — *Х.М.*) тәэсире берлә эшләнүендә һичбер шөбһә калмыйдыр». Пушкин — чыгышы белән хәбәш (эфиоп). Рус булмаган кешенең руска хезмәт итүе, аны данлавы шул чордагы (һәм гомумән) руслаштыру сәясәтенә туры килеп тора. Пушкинны уку, өйрәнү, укучыларга җиткерү гадәти хәл. Ә инде аны үзәкләшкән рәвештә, милли шагыйрьләрне кысрыклау хисабына башка халыклар арасында пропагандалау, аның юбилейларын «көчләп ясату» — икенче күренеш. Г.Исхакыйны нәкъ менә шул хәл борчый да инде. Соңгы 50 еллык тарих әдип борчылуының урынлы булуын да күрсәтте. Безнең күпчелек татарлар хәзер дә Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Һ.Такташ кебек үз әдипләрен бөтенләй диярлек белмәү дәрәҗәсенә җиттеләр. Милли мәктәпләрнең күпләп ябылуы, татарча гәзит-журналларның, китапларның нык кимүе, татар теленең үз җирендә үги хәлендә калуы — болар да нәкъ әнә шул 30 нчы елларда көчәеп киткән руслаштыру сәясәтенең аянычлы нәтиҗәләре.

Исхакый мәкаләсендә берьяклы, бәхәсле фикерләр дә бар. Автор болай ди: *«Пушкин урысның үз баткаклыгындан чыккан үз йимешедер. Үз-үзенә ярый торган үзенең шагыйредер. Ләкин ул безнең төрк-татар халкына тәмам ятдыр. Аның ерлаган ерлары, аны дәртләндергән дәрдләр безнең халык өчен һич әһәмияте булмаган ят нәрсәләрдер»*. Тарихи тәҗрибә мондый фикернең субъектив характерда булуын ачык күрсәтеп тора.

Пушкин — «рус темасы», «рус тормышы» аркылы, гомумән, кешелек идеалларына дан җырлаган дөньякүләм бөек шагыйрь. Шуңа күрә аның иҗатында рус укучысы өчен генә түгел, башка халыклар, җөмләдән татарлар өчен дә аваздаш яклар күп. Аның әсәрләре, оригиналда укылудан тыш, узган гасырларда ук татар теленә дә тәрҗемә ителә башлаганнар. Пушкин мирасы Г.Исхакый һәрчак олылаган Г.Тукайны да иҗатка рухландырган, аны үз остазларыннан берсе итеп санаган:

> Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш,
> Ай кеби, нурны алардан икътибас иткән (алган. — *Х.М.*) бу баш.

Бөек татар шагыйренең «Теләү бетте», «Мәҗлес», «Җил», «Тәүбә вә истигъфар» һәм кайбер башка әсәрләрен Пушкиннан файдаланып язуы мәгълүм. Безнең әдәбиятның кайбер бүтән әһелләре дә Пушкин иҗатында үзләренә аваз-

даш аһәңнәр тапканнар. Әмма, Г.Исхакый хаклы әйткәнчә, төрк-татар телендә Пушкинның «татсыз-төссез тәрҗемәләре» дә шактый. Монда, әлбәттә, олуг шагыйрьнең һич гаебе юк.

Г.Исхакый мәкаләсе кискен идеологик, сәяси көрәш чорында халыкара сәясәтнең үзәгендә кайнаган кеше тарафыннан язылган. Шуңа күрә анда чор чикләнгәнлеге булу, субъектив карашларның гәүдәләнүе табигый һәм тарихи күренеш. Бу мәкалә — укучыларның фикерен кузгатуда, Г.Исхакыйның иҗат дөньясын һәм эшчәнлеген өйрәнүдә бер материал, мәгълүмат чыганагы.

*1992*

## Әдәбият пәрдәсе астында русчылык*

*Гаяз Исхакый*

Бу ел февраль аеның 10 ында, үзе рус милләтендән булмаса да, рус теленә зур хезмәт иткән, рус әдәбиятында зур әсәрләр мәйданга китергән хәбәшле (эфиопияле — абиссинияле) Александр Пушкинның үлүенә йөз ел тулды.

Александр Пушкинның бабасы Беренче Петр вакытында кол итеп сатып алынып, Русиягә кителгән булса да, ул вакытның рус задеганының (аксөякләренең) марҗалары кара коллар берлә кәеф-сафа чигүне яратуы аркасында, кара кол Русиядә бик тиз мирзалык дәрәҗәсенә мендерелгән вә рус хатынына өйләнеп, Пушкин мирза гаиләсенең карт бабасы булып өлгергән. Александр Пушкин, бабасының Африкадан алып килгән кызу канын, үткенлеген мирас итеп алып, елылы-суыклы руслыкның мәгънәви баткаклыгында колач җәеп, йөзә башлаган. Азгын бала булып үсеп, бөтен яшьлеген шау-шу эчендә үткәргән. Алла тарафыннан бирелгән шагыйрьлек куәтен дә шул чуалчык мохит эчендә эшкә ашырган. Өслүб, тел ягыннан матур-матур шигъри әсәрләр тудырган, рус телен баетырга, матурайтырга хезмәт иткән. Яшәгән алпавыт мохите безнең бабайларның «тиле бояр» тәгъбире берлә йөретә торган тиле-миле бер мохит булганга, А.Пушкин да үз тирә-юне бояр балаларының бөтен тилелекләрен тулы көенчә эшләп килгән. Тибдергән, бик күп гаилә эчендәге скандалларга сәбәпче булган. Кыска гына гомерендә егерме мәртәбә дуэльгә кереп, егер-

---

* Яңа милли юл. — 1937. — № 3 (108). — 1–4 б.

ме беренче дуэлендә бер француз забиты (офицеры) тарафыннан үтерелгән. Менә шул руслашкан хәбәшленең, әллә ничә мең рус крестьянын кол итеп тоткан боярның үтерелүенә бу ел йөз ел тулды.

Шул йөз еллык мөһаҗир руслык эчендә генә түгел, Совет Русиясендә дә зур исдәлек көне итеп каршы алынды. Үзен-үзе «Эшче вә авыл халкы җөмһүрияте» диеп йөри торган Совет Русиясендә, шул гомере буенча коллар бәйләгән (биләгән) Пушкинның исдәлек көнләре, эшче вә авыл халкының бәйрәме кеби уздырылды. Совет Русиясендә халык өчен хезмәт иткән бик күп шагыйрьләр, әдипләр, җәмәгать хәдимләренең меңләп-меңләп үтерелүен белеп торганга вә чарлык (патша) дәверендә Русиядә яшәүче милләтләрнең хөрриятләре өчен тырыша торган самими милләтчеләренә палачлык иткән әллә никадәр жандармлар, хәфияләрнең (яшерен полиция, иминлек хезмәткәрләренең) зур-зур дәрәҗәләргә мендерелүен күреп торганга, без моңа да Советлардагы тәзаддының (каршылыкларның, контрастның) берсе генә диеп, андагы мәгънәви башбаштаклыкның тугдырган яңа бер йимеше генә диеп тә китәр идек; ләкин шул руслашкан хәбәшленең үлем көнләрен, Русиядә яшәргә мәҗбүр булган төрк илләрендә көчләп бәйрәм көнләре итдерелүләре тикшермәенчә генә үтелә торган хәл түгелдер. Радио берлә багланыш мөмкин булган йирләрдә, илемездәге милли музыка, милли ерларны ишетү өчен радиомызны Казан, Әстерхан радиосы станцалары берлә берләшдердекме, Кырымның Акмәсҗед (Симферополь) радиосынамы, Бакуның, Ташкендның радиосынамы кушдык, эзләгәнемез моңлы көйләремез йиренә А.Пушкинның азгынлык берлә тулган тәрҗемәи хәленә очрадык. Яисә аны күкләргә күтәргән мәдхияләргә тап булдык. Бөтен төрк-татар җөмһүриятләре берсендән-берсе узышып, рус теленә зур хезмәт итеп, русчылыкны ныгытырга тырышкан бу шагыйрьнең әсәрләре йирле шивәләргә (телләргә; диалектларга) тәрҗемә ителүләрен игълан итәләр. А.Пушкин исеменә урамлар аталуларын белдерәләр, аның әсәрләрен мактап, сатып алуга кызыкдыралар. Хәзерге көнне үзенең кыйбласын югалткан рус большевигы боларны кылса, без аны большевизмдан туеп, руслыкның элекке буржуаз тормышын сагынуның бер төрлесе генә диеп аңлый аламыз.

Безнең халкымызның тарихы, бүген-иртәгесе берлә һичбер мөнәсәбәте булмаган бу шагыйрьне бездә болай күккә күтәрелүләренең сәбәбләрен ни дип тәфсир итәргә кирәк? Үткән ел гына безнең халык шагыйремез Габдулла Тукайның тууына илле еллык исдәлекне Татарстан, Башкортстанда бик өстдән үткәндә, Сабирның (азәрбайҗан шагыйре) вафатына ун ел тул-

ганда да мәҗмугаи әсәрләре басдырырлык хөрмәт күрсәтелмәгәндә, бу чит халыкның ят гонсырдан (токымнан, нәселдән) булган шагыйренә ясатылган бу ихтирамлар, әдәбият, шигырь берлә һичбер мөнәсәбәте булмаган гамилләрнең (хакимнәрнең, дәрәҗәле кешеләрнең; факторларның) тәэсире берлә эшләнүендә һичбер шөбһә калмыйдыр. А.Пушкин төрк-татар халкының үзенең милли шагыйрьләрен күләгәдә калдырырлык безнең Физулиемыз берлә дә, фарсыларның Фирдәүсиләре берлә дә, алманларның Гетелары берлә дә буе үлчәшәчәк дөнья күләмендәге шагыйрь түгелдер. Ул урысның үз баткаклыгыннан чыккан үз йимешедер. Үз-үзенә ярый торган үзенең шагыйредер. Ләкин ул безнең төрк-татар халкына тәмам ятдыр. Аның ерлаган ерлары, аны дәрдләндергән дәрдләр безнең халык өчен һич әһәмияте булмаган ят нәрсәләрдер. Шулай булгач, ник соң Казанда, Уфада, Әстерханда, Бакчасарайда, Бакуда, Ганҗәдә, Ташкендда, Сәмәркәнддә, Алма-Атада А.Пушкин көнләрен эшләтәләр? Ник соң аны күкләргә күтәрәләр? Чөнки ул үзе рус булмаса да, рус теленә, рус шигыренә хезмәт иткән, руслыкның мәдәни юлга чыгуына тырышкан бер русчылык хезмәтчеседер. Урыс большевиклыгы, Пушкинның шагыйрьлегенә бөркәнеп, төрк илләрендә дә шул урысчылык хезмәтчесен зурайтырга тырышадыр. Аның рус әдәбиятына иткән хезмәтен сылтау итеп, төрк-татар яшьлеге алдында аны хөрмәтле урынга менгезергә тырышадыр. Төрк-татар яшьлегенең йөрәгендән үзенең милли шагыйрьләре Габдулла Тукай, Сабирларга гына түгел, Нәвоиләр, Физулиларга каршы булган хөрмәтен дә Пушкин исеме берлә каблап китмәкче буладыр. Мәктәп балаларымызның гөнаһсыз рухларына үземезнең милли шагыйрьләремез, милли әдәбиятымыз берлә бирелә торган милли зиһенемезне йирләшдермәс өчен, аларның рухларындагы бушлыкны русчылык берлә тутырмакчы буладыр. Безнең төрк-татар балаларымызны, яшьләремезне эчдән русчылык берлә ашламакчы буладыр. Шуның өчен безнең әдәби әсәрләремезне, никадәр халкымызга якын булса да, аны язучылар Габдулла Тукай, Сабир кеби чын мәгънәсендә халыкчы, болар әйткәнчә, пролетариат булсалар да, халкымыз арасында таратмас өчен буржуаз милләтчелек әдәбияты дип басдырмыйдыр. Милли әдәбиятымыздагы бушлыкны рус халкының алпавытлар әдәбияты берлә граф Толстой, карарусчы Достоевский әсәрләре берлә тутырадыр. Милли шигыремезнең бушлыгын русчылыкны ерлаган Пушкин әсәрләре берлә алышдырмакчы буладыр. Рус большевигы безнең халык берлә мөнәсәбәткә килгәндә, үзенең руслыгын, империалистлыгын һичбер хәтерендән чыгармаенча, хәрәкәт итәдер. Ул кирәк сәясәт юлында, кирәк әдәбият, музыка

юлында безнең төрк-татар халкының үз эшләрен үз кулына бирүдән куркынадыр. Үзенең руслаштыру эшен һичбер яңлышмаенча алып барадыр. Пушкин көнләренең төрк илләрендә көчләп ясатуының, Пушкинның кирәкле-кирәксез әсәрләрен татсыз-төссез итдереп тәрҗемә итдерүләренең мәгънәсе дә шул ук Сабирлар, Тукайларны күләгәдә калдырудыр. Безнең классик әдәбиятымызны басдыртмауның сәбәпләре дә шулдыр. Төрк-татар халкын эчдән черетү аны руслашдырудыр. Ләкин боны без мөһаҗирләр күргән кеби илебездәге милләтчеләр дә күрергә тиешдер, кызыл, кара русның безгә каршы милли сәясәте бар икәнен андагы яшемез, картымыз да аңларга тиешдер вә шуңарга каршы тәдбир (чара) күрергә тиешдер.

## «...Телебезне саклаучы халкыбыз бар»

*(Гаяз Исхакыйның туууына 125 ел тулу уңае белән)*

Гаяз Исхакый — күпкырлы эшчәнлеккә ия зат. Аның үзәген, арка сөяген татар халкы өчен көрәш тәшкил итә. Әдипне милләт төшенчәсенең тел белән бәйләнешле мәсьәләсе аеруча дулкынландыра. Аның өчен тел — халык яшәешенең реаль гәүдәләнеше, кавемнең рухи көзгесе, хәтер дәвамчанлыгының мөһим факторы. Тел бар икән, милләт тә бар, тел юк икән, милләт тә юк. Бу принцип — Г.Исхакыйның иман-ышанычы, мәсләки кыйбласы.

Бөек әдип үзенең әдәби әсәрләре, публицистикасы белән татар теленең яшәүчәнлеген арттыруга, кулланылыш даирәсен киңәйтүгә зур өлеш кертте.

Телгә хезмәт итүен, газиз татар теле турында кайгыртуын ул Ватаныннан аерылгач та дәвам иттерде. Аның әдәби, сәяси, иҗтимагый, гыйльми, журналистик эшчәнлеге — моның ачык дәлиле.

Советлар Берлеге никадәр генә ябык, йомык дәүләт булмасын, аның эчке тормышы, сәясәте теге яки бу дәрәҗәдә чит ил матбугатында да гәүдәләнеш таба. Мәгълүм ки, мөһаҗир урыслар 20–30 нчы елларда гаять күпсанлы гәзит-журналлар чыгаралар. Заманында Хельсинкидагы «Славика» китапханәсендә мин аларның тупламнарын күреп шаккаткан идем. Г.Исхакый бу төр көндәлек матбугат белән даими танышып бара. Аннан соң ул төрле шөгыль ияләре (сәясиләр, галимнәр, гаскәриләр, язучылар, эшмәкәрләр...) белән очрашып, алардан да күптөрле

мәгълүматлар ала. Мәсәлән, 1931 елның декабрендә Г.Исхакый Кодес (Иерусалим) шәһәрендә мөселманнарның бөтендөнья корылтаенда катнаша. Юлда, конгресста ул гаҗәеп күптөрле кешеләр белән очрашуы, әңгәмә коруы хакында үзенең «Ислам мәмләкәтләрендә» исемле юлъязмасында тәфсилле яза. Әмма әдип өчен халык, Ватан хакындагы төп чыганак — илдәге китаплар, рәсми гәзит-журналлар, аеруча Татарстанның вакытлы матбугаты. Г.Исхакый бу төр материалларны үзенең чыгышларында, мәкалә-хезмәтләрендә даими файдалана, аларны анализлый. Бу ягы белән ул Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбияты өчен хас булган шәрехләү, интерпретацияләү традицияләрен дә дәвам иттерә. Мәсәлән, аның «Яңа милли юл» (Берлин, 1928–1939), «Милли Байрак» (Мукден, 1935–1945) һәм кайбер башка гәзит-журналлардагы күп кенә мәкаләләре Татарстан һәм Башкортстан матбугатындагы материалларга нигезләнгән. Г.Исхакый тегe яки бу күләмдә бу төр язмаларның эчтәлеген бәян итә, өзекләр китерә, аларны тәнкыйди иләктән уздыра, үзе мөһим дип санаган нәтиҗәләрен чыгара. Шундый мәкаләләрнең берсе «Тел мәсьәләсе» дип атала. Ул «Яңа милли юл» журналының 1937 ел, апрель санында [4 (109) сан. — 6–9 б.] дөнья күргән. Бу язманың үзәген Татарстан җөмһүрияте яңалиф комитеты утырышы хакындагы рәсми материаллар тәшкил итә. «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» гәзитләренең 1937 ел, 27 гыйнварында басылып чыккан мәкаләләрдә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисе Г.Байчура докладының төп эчтәлеге бәян ителә. Анда яңалифне гамәлгә куюның гына түгел, ә, гомумән, татар теленең торышы, бу өлкәдәге уңышлар һәм җитешсезлекләр хакында да сүз бара. Докладтан күренгәнчә, телне өйрәнү, укыту тармагында шактый гына эшләр башкарылган. Әмма Г.Исхакыйны болар гына канәгатьләндерми. Ул тел өлкәсендә дә «дошманнарны» эзләү белән борчыла. Әдип термин-атамаларны камилләштерү шигаре (лозунгысы) астында телебезгә «рус сүзләрен» кертү ихтималлыгын да искәртә.

Г.Исхакый фикеренчә, тел — «бу дәвернең иң авыр», «бөтенебезне куркытып» торган мәсьәләсе. *«Ләкин,* — ди ул, — *телебезне югалтабыз дигән курку урынсыз».* Авторның телгә карата мондый ышанычлы карашы ул чор өчен урынлыдыр. Чөнки узган гасырның 20–30 нчы елларында, гәрчә репрессияләр халыкка, телгә зур зыян китерсә дә, әле татар милләте, кайда гына яшәвенә карамастан, нигездә, үз телендә сөйләшә, татарча укый, аралаша. Бу чорда әле татарның күпсанлы мәктәпләре, театрлары, гәзит-журналлары бар. Әмма икенче бөтендөнья сугышыннан соң татар мәгарифе, мәдәни-

яте, әдәбияты ныклап кысыла барды, туган теленнән аерылган милләттәшләребез гаять күбәйде. Татар халкы, татар теле инкыйраз упкынына якынайды. Әгәр дә Г.Исхакый мондый вазгыятьне күрсә, тел турында башкачарак фикерләр иде...

Әдип «Тел мәсьәләсе» исемле бу язмасы белән, бер яктан, укучыларга тел, милләт хакында мөһим генә мәгълүматлар бирә, шул чордагы катлаулы, каршылыклы шартларны күз алдына китерергә ярдәм итә. Бер генә мисал: мәкаләдә телгә алынган Татарстан җитәкчесе Г.Байчура, «милләтчеләргә каршы ныклы көрәш алып барырга» чакыруына да карамастан, үзе үк шул мәсьәләдә «гаепләнеп», шул ук 1937 елда атып та үтерелә. Икенче яктан, бу мәкалә Г.Исхакыйның фикерләү рәвешен, тел-имляга мөнәсәбәт үзенчәлекләрен аңлауга да булыша.

Җөмһүрият гәзитләрендәге мәгълүматлар рәсми хакимиятнең имля турында «кайгыртучанлыгын» күрсәтә. Баксаң, шушы елларда ук урыс графикасына күчерү турында яшерен хәзерлек бара. Һәм ике елдан соң ул мәҗбүри рәвештә гамәлгә дә ашырыла. Бу уңай белән Г.Исхакый «Урыс әлифбасы» исемле мәкаләсендә [Яңа милли юл, 1939. — 6 (134) сан. — 29–31 б.] болай ди: *«Боның* (моның. — *Х.М.*) *берлә большевиклар мәшһүр төрк дошманы миссионер Ильминскийның рухын шатландырган кеби, русларның да гасырлар буе максат итеп алып килгән руслаштыру теләкләрен вөҗүдкә* (гамәлгә. — *Х.М.*) *ашырган булдылар»*. Бу сүзләр инде бернинди өстәмә аңлатмага да мохтаҗ түгел.

«Тел мәсьәләсе» язмасындагы факт-мәгълүматлар, фикерләр шактый дәрәҗәдә бүгенге милли тормышыбызга да авазлаш.

*2003*

## Тел мәсьәләсе*

*Гаяз Исхакый*

27 гыйнварда (1937 ел) «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» гәзитләрендә Татарстан рәис җөмһүре (Татарстан Республикасы рәисе. — *Х.М.*) Байчураның** Татарстан җөмһүрияте «Яңалиф комитәсе»нең (комитетының) хисабын (яңа-

---

* Яңа милли юл. — 1937. — № 4 (109). — 6–9 б.

** Байчура Гомәр Гыйлаҗеддин углы (1890–1937) — дәүләт эшлеклесе. 1934–1937 елларда Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты (ЦИК) Президиумы рәисе булып эшли. Шәхес культы корбаны.

лифнең Бөтенрусия үзәк комитәсенең 7 нче утырышы каршында) бирүе хакында бер мәкалә басылды. Әлбәттә, «Кызыл Татарстан»дагысы урыс гәзитендән тәрҗемә иде. Бу гәзитләр түбәндәге сүзләрне бирәләр (бик күп рус һәм чит тел сүзләре гарәпчә вә төркчә тәгъбирләр берлә төзәтелде. — *Г.И.*):

«Байчура яңалиф нигезендә татар телен үзләштерү уңышлы рәвештә алга баруын сөйләде. Хәзер «Яңалиф комитәсе» имля кагыйдәләре, истиляхлар (терминнар) һәм рус-татар сүзлекләре төзү һәм бастырып чыгару эшен җәелдерде. Сәяси истиляхларның имлясы сүзлеге бастырырга бирелде. 35–40 табак күләмендә рус-татар сүзлегенең беренче җилде (томы) басарга бирергә хәзерләнде. 1937 елда яңалифнең Татарстан комитәсе марксизм-ленинизм классик әсәрләреннән 11 исемдә китап бастырып чыгарырга билгеләде. Шулай ук гүзәл әдәбияттан шактый күп тәрҗемә һәм оригинал китаплар чыгарырга уйлана. Байчура хезмәт ияләрен социалист-бәйнәлмиләл тәрбияләүдә көчле корал булган татар әдәби телен эшләү өлкәсендә гаять зур бурычлар торганлыгын сөйләде. Татар әдәби теле фәнни эшләнешенең күтәрелүе, марксизм-ленинизм классикларын һәм фәнни-техник әдәбиятын тулы һәм төгәл тәрҗемә итүгә мөмкинлекләр тугдыра, диде.

Бездә тикшерү буенча гыйльми көчләргә ихтыяҗ бик зур, менә шуның өчен без 1937 елда тел һәм әдәбиятны эшләү буенча Казанда фәнни-тикшеренү институты оештырырга уйлыйбыз. Бу институт татар теле һәм әдәбияты буенча югары дәрәҗәле телчеләр хәзерләүдә яңалифнең Татарстан комитәсенең фәнни нигезе булып торырга тиеш. Татар әдәби һәм сөйләшү телен үгрәнү һәм үстерүне планлы вә системалы юлга салу Татарстан «Яңалиф комитәсе»нең эшендә үзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шушы теләк берлә 1937 елда эшчеләр һәм колхозчыларның әдәби һәм сөйләшү телләрен үгрәнү буенча һәм шулай ук фольклор материалларын үгрәнү буенча фәнни-тәдкыйк (тикшерү) сәяхәтләре оештырырга уйлыйбыз. Бу сәяхәтләр Татарстанның читтә эшләүче татар хезмәт ияләренең дә әдәби һәм сөйләшү телләрен үгрәнергә тиешләр. Шулай ук киләчәктә яңалифне телеграф бәйләнешләрендә дә, җәгърафия хариталарында (карталарында), стенографиядә дә куллану мәсьәләсен эшләүне бурыч итеп куябыз. Татар теле һәм әдәбиятының иң мөһим мәсьәләләрен киң рәвештә тикшерү өчен 1937 елда тел белгечләренең конференциясен җыярга уйлыйбыз.

Байчура яңалифнең бөтен Советлар Иттифакы Үзәк Комитәсе алдына Татарстан җөмһүриятенең полиграфия сәнагате-

нә һәм язу машиналары заводын киңәйтү һәм яңадан төзергә булышлык күрсәтү тугрындагы мәсьәләне куйды. Байчура сүзенең азагында яңалифнең Татарстан комитәсенә культур мәсьәләләрендә Ленинга каршы чыгышлар кертергә маташучы йирле милләтчеләргә каршы ныклы көрәш алып барырга тугры килүен һәм киләчәктә дә көрәшне кискен рәвештә алып барырга кирәклегене сөйләде.

Байчура мәгъррузәсе (доклады) буенча чыгып сөйләүчеләр яңалифнең Татарстан комитәсенең соңгы еллардагы уңышлары һәм җитешсезлекләре турында сөйләделәр. Бөтен Советлар Иттифакы «Яңалиф Үзәк Комитәсе» янындагы төрк-татар бүлеге мөдире Иманкол социалистик культурны үстерүгә аяк чалучы милләтче төркемнәрнең калдыкларына каршы көрәшне көчәйтергә кирәклек тугрында сөйләде. СССР Үзәк Башкарма Комитәсе Милләтләр Советы кятибе (секретаре) Хатскеевич фикер алышуларда Татарстан җөмһүрияте «Яңалиф комитәсе»нең эшендәге шактый уңышларны күрсәтеп, Татарстанда хәзергә кадәр әлифбаны сагламыллашдыруның (камилләштерүнең) тәмамланмавы, әдәби телне шөгыльгә (гамәлгә) кую эшендә гаять зур әһәмияткә ия булган Тел һәм әдәбият институтын оештырмау шикелле җитешсезлекләргә тукталды».

Телебезнең рус сәясәте коралы өчен ничек кулланылуын рәсми мәэмүр (хезмәткәр) сөйләгән сүзләрен укыганнан соң, бер тел мөгаллименең дә телебезнең хәзерге торышы хакындагы сүзләрен китерәбез:

«Ленин-Сталин милли сәясәтен тормышка дөрест ашыру нигезендә бездә тел культуры елдан-ел үсә бара. Башлангыч һәм урта мәктәпләргә татар телендә җитәрлек дәрәҗәдә дәреслекләр булдыру, татар хезмәт ияләре өчен сәяси, әдәби һәм фәнни китаплар йитештерү берлә беррәттән, телдәге сүз байлыгын да елдан-ел тирәнәйтә, киңәйтә барабыз. Дингә, иске гореф-гадәтләргә бәйләнешле сүзләр ташланып, алар урынына сыйнфый һәм сәнаигы мәхсуллары (җитештерү тармаклары) мөнәсәбәтләренә, яңача көнкүреш һәм социалистик культур казанышларына бәйләнешле булган яңа сүзләргә безнең тел елдан-ел баеп бара.

Ләкин шуның берлә бергә яңа сүзләр, яңа истиляхлар (терминнар) кулланууда бездә төрлечәлек бар. Бер үк әйберне берничә төрле атап йөретүләр яки, сүзнең эчтәлеген яхшы аңламау аркасында, яңлыш сүз кулланулар бик еш очрый. Шуның нәтиҗәсендә укучылар бер үк әйберне төрлечә сүзләр арасында укырга мәҗбүр булалар яки укылган әйбердән бөтенләй яңлыш төшенчә алалар. Бу хәл бездә бигрәк тә кагыйдәләшмәгән сүзләр һәм истилях белешмәләре булмаудан килә.

Укучыларга, язучыларга, тәрҗемәчеләргә һәм, гомумән, русча китаплар берлә файдаланучыларга бик кирәкле булган русча-татарча сүзлек юк. Татгосиздат авыл хуҗалыгы әдәбияты бүлеге тарафыннан эшләнгән истиляхлар җыентыгы бер елдан бирле инде Мәгариф халык комиссариаты тирәсендә әйләнеп йөри. Башкиров* рәислеге астында үткән елны төзелгән дәүләт истилях комиссионы да (комиссиясе дә) эшкә әле һаман тотынганы юк. Ләкин сүзлек кирәк, истиляхлар кирәк, укучылар, язучылар бу кулланмага бик мохтаҗлар» (Кызыл Татарстан, 3 февраль).

* * *

Бу телебез хакында зур бер мәэмүр вә тел белгече бер мөгаллим биргән мәгълүматларны тәфсир кылу артык булса кирәк. Фәкать бик ямьсез һәм бик куркыныч күренгән тел мәсьәләләребез, бу мәгълүматларга күрә дә, зур бер тәһликә (һәлакәт) астында булганы хәлдә, һаман да «Ленинга каршы чыгышлар кертергә маташучы йирле милләтчеләр» һәм «социалистик культурны үстерүгә аяк чалучы милләтче төркемнәрнең калдыклары» телебезнең руслаштырылуы сәясәтенә каршы мокавемәт (каршылык) күрсәтә алулары вә болар «иң зур дошман» булып күрсәтелүләренә күрә дә, бер дә «калдык» кына түгел, халыкның зур күпчелеге булуына ышанырга да күп өмидләр бирәләр. Бөтен авырлыкларга карамастан, бик күп золымларга күкрәк киереп телебезне саклаучы халкыбыз бар. Бу шундый бер халык ки, 380 елдан бирле үзенең барлыгын саклап килә. Истиляхлар, атамалар вә «әдәби тел» өчен урыс сүзләрен сонгый (ясалма) рәвештә сугып кертү ихтималлары бар. Фәкать халык — «иң зур дошман» булган халык бу чит сүзләрне йотарга теләү вазгыятендә дә түгел, аларны үзләштерү имкянендә (мөмкинлегендә) түгел.

Тел мәсьәләбез, бу дәвернең иң авыр мәсьәләләреннән берсе булып, бөтенебезне куркытып торадыр. Ләкин телебезне югалтабыз дигән курку урынсыз. Телебезне парчалыйлар, телебезнең инкишафына (үсешенә; киңәюенә) манигъ (киртә) булалар, телебезне ярлыландырырга, авырайтырга тырышалар, ләкин аны юк итәрлек дәрәҗәдә зур куәт дошман кулында юк. Киресенчә, халык, һөҗүм арта барган саен, үзенең куәтен арттыра барып, каршылыкны ныгыта бара. Шул ук халык үзе беткәнчә, телне дә бетермәячәкдер.

---

* Башкиров Шаһиварли Гали углы (1894–1938) — 1934–1937 елларда Татарстан мәгариф министры.

## Бөек шагыйрь турында бөек әдип

Тарихта тирән эз калдырган инсаннарның, аеруча Исхакый һәм Тукай кебек мөхтәрәм затларның эшчәнлегенә кагылышлы һәр фикер, һәр язма фән һәм киң җәмәгатьчелек өчен мөһим. Чөнки бу төр факт-мәгълүматлар еш кына хосусый, шәхси кысалар белән генә чикләнмичә, халыкның рухи тормышы, иҗтимагый проблемалар белән бәйләнешле булып чыгалар. Г.Исхакыйның «Тукай истәлеге» язмасы да әнә шундый материалларның берсе. Ул, шагыйрьнең үлеменә 20 ел тулуга хәзерлек уңае белән язылып, Берлинда нәшер ителүче «Яңа милли юл» журналының 1932 елгы 11 нче санында дөнья күргән (1–4 б.).

Исхакый һәм Тукай... Аларның бер-берсенә үзара хөрмәти мөнәсәбәте инде мәгълүм. Бөек шагыйрь Исхакыйны зурлый, аны «даһи» шәхес, милләтне туплауга сәләтле «чабан» (көтүче) рәвешендә күзаллый. Бөек әдип тә үз чиратында Тукайны олылый, аның шәхесе, иҗаты, әсәрләренең халык тормышындагы әһәмияте хакында махсус мәкаләләр дә яза. 1938 елда дөнья күргән бер язмасында ул Тукайны «татарның иң зур шагыйре» дип атый; аның *«Тик милләткә хезмәткә мәхәббәт миндә бар! Минчә, монда ямь дә бар, ләззәт тә бар һәм тәм дә бар!»* шигырен мисалга китерә дә, болай ди: *«Гомере буенча менә шул милләткә хезмәт аның бөтен иҗат(лар)ында Тимер Казык йолдызы булып, аның кыйбласы булып барадыр. Бөтен кыска гомере буенча ул шул милли юлдан һичбер тайпылмыйча, каберга кадәр милләт ерын ерлап, милләт кайгысын көйләп, милләт көлкесендән көлеп, үзенең иҗатын шул милләтчелек кальбенә сугып киләдер. Яңлышканда, каләме шуып кына китеп тә, ике юллык кына бер шигырьне дә шул алган юлына хилаф (каршы) төстә язмыйдыр, яза да алмыйдыр»* (Яңа милли юл. — 1938. — 4 сан. — 2 б.).

Г.Исхакыйның «Тукай истәлеге» мәкаләсе авторның бөек шагыйрьгә тотрыклы хөрмәти карашын күрсәтә. Исхакый фикеренчә, Тукай — татарның «кадерле», «халык шагыйре». Ул — халкыбызның «кайгысын-хәсрәтен әйтеп» бирүче, аның «моңын җырлаучы» әдип. Шагыйрьнең исеме, иҗаты татар язмышы белән тыгыз һәм табигый бәйләнешле. Тукай — халыкны туплаучы, саклаучы һәм яшәтүче бер көч. Шуңа күрә аны искә алу «тугрыдан-тугры» халыкның бурычы. Исхакый бу юнәлештә башкарылырга тиешле эшләргә, чараларга туктала. Оештыручы махсус комиссия төзү, Тукайның үз әсәрләрен һәм аның хакындагы язмаларны бастыру, аларны киң катлам укучыларга

җиткерү — әнә шундыйлардан. Биредә иң мөһиме — бу эшләрне «бергәләшеп», берләшеп башкару. Шунысы әһәмиятле: Тукайның үлеменә 20 ел тулуга, ягъни 1933 елда, Токиода шагыйрь әсәрләренең биштомлыгы (646 битлек «Мәҗмугаи асар»е) дөнья күрә. Бу, әлбәттә, фидакарь милләтпәрвәрләребезнең күмәк тырышлык нәтиҗәсе. (Быел шагыйрьнең тууына 115 ел тулу шактый киң күләмдә билгеләп үтелде. «Тукай укулары», фәнни конференцияләр, фестивальләр уздыру — шуның ачык билгесе. Аеруча мәктәпләр, мәгариф оешмалары бу юнәлештә күптөрле һәм игелекле эшләр башкардылар. Әмма, минем белүемчә, юбилей уңае белән Тукай китаплары чыкмады. Шагыйрьнең 120 еллыгына аның академик басмасын чыгару — зыялыларыбызның изге бурычы.)*

Г.Исхакый мәкаләсендә кызыклы фактлар бар. Автор Ерак Шәрыкта (нигездә, Харбинда) яшәүче әдип, драматург, режиссер, журналист Хөсәен Габдүш (1901–1944) тарафыннан Тукай турында бер «рисалә» язылып бастырылуы хакында мәгълүмат бирә. Әмма, кызганыч ки, без хәзергәчә бу китап белән таныш түгел. Г.Исхакый Исмәгыйль Гаспралы эшчәнлеген, аның «Тәрҗеман» гәзитен дә югары бәяли. Бу мөхтәрәм инсанны ул «бөтен төрк иленең пәйгамбәре» дип атый.

Бу мәкалә ике бөек зат — Тукай һәм Исхакый эшчәнлеген, аларның үзара мөнәсәбәтләрен, тарихтагы урыннарын аңлауда, милләт язмышын күзаллауда билгеле бер чыганак булып тора.

*2001*

## Тукай истәлеге

*Гаяз Исхакый*

*(Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә)***

Тиздән керәчәк булган 1933 нче ел безнең өчен бик зур тарихи көнләрне эченә ала. Бөтен төрк (төрки) дөньясына каратып, «телдә, фикердә һәм эштә берлек» шигаре берлә чыгарыла башлаган «Тәрҗеман» гәзитенә бу елда 50 ел тула.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле,
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы, —

---

* Татарстан китап нәшриятында шагыйрьнең тууына 117 ел тулу уңаеннан «Сайланма әсәрләр»е (2003), «Тормыш һәм иҗат елъязмасы» (2003) басылып чыкты. — *редактор искәрмәсе.*

** Яңа милли юл. — 1932. — № 11. — 1–4 б.

дип яза башлаган халык шагыйре Габдулла Тукайның үлүенә дә бу елда 20 ел тула. Аның, соң (соңгы) шигырен язып:

И мөкатдәс милли* сазым, уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы! —

дип үзенең шагыйрьлек тормышына тыныш куелганына 1933 елның 15 апрелендә 20 ел тула.

Исмәгыйль Гаспринский бөтен төрк иленең уртак пәйгамбәре булганга, «Тәрҗеман»ның 50 еллыгын бәйрәм итү — аны искә төшерү бөтен төрк кабиләләренең уртак бурычы. Олуг төрк милләтенең бер өлеше әле үз эшенә үзе хуҗа булганга, бу бурычны да ул үтәр дип ышанабыз. Тик Тукайның 20 еллыгын кем искә төшерәчәк?

Габдулла Тукай безнең Идел буе төрк-татары шагыйре булганга, ул безнең халкыбызның моңын җырлаучы, безнең дәртебезне күпләүче булганга, аны искә алу да тугрыдан-тугры безнең өстебезгә йөкләнә.

Ләкин безнең илебез, безнең йортыбыз хәзерге көндә безнең «үзлегебезне» бетерергә бил баглап керешкән кызыл урыслар кулында булганга, андагы халкыбызның бу кадерле шагыйрьне олугларга имкян (мөмкинлек) табачагы бик шөбһәле. Тукай татар халкы өчен аның кайгысын-хәсрәтен әйтеп бирә торган бер халык шагыйре булса да, Совет карашыннан, ул — мулла баласы, милләтче, динче; коммунизм карашыннан, ул — урыслаштыру тәрбиясенә киртә салып торучы бер контрреволюционерчы; илебезне-йортыбызны урыс мөһаҗире (күчеп килүчеләре) берлә тутырырга теләүче кызыл Мәскәү карашыннан, ул — шовинист милләтче; бөтен большевик сәясәте карашыннан, ул — үзенең халкы кебек, үз илендә бөтен нәрсәдән мәхрүм «хокуксыз-лишинтәс».

Моннан ике ел элек кайбер татар большевиклары Тукайның 20 еллыгына хәзерләнү өчен бер программ ясаган булсалар да, бүген ул программны ясаучыларның да бик күбесе милләтчелектә гаепләнеп, Солофкага (Соловка — төньяктагы атаклы сөргенлек җире исеме) җибәрелеп бетерелгәнгә, илебездә Тукай хөрмәтенә бернәрсә ясалуын көтүе бик читен. Шул көннең якынлашуына карамастан, большевик татар матбугатында бу турыда һич бу (һичбер) нәрсә язылмавы да бу фикердән ваз кичкәнлекне күрсәтә.

Кызыл урыс золымы астында яшәгән халкыбыз үзенең кадерле шагыйрен шул тарихи көндә рәсмән (рәсми рәвештә)

* Тукай китапларында бу сүз «моңлы» дип бирелә.

хатерли (искә төшерә, яд итә) алмаса да, халкыбызның дөньяның иркенлегендә яшәгән өлеше өчен бу тарихи көнне искә төшерергә һичбер манигъ (киртә) юк. Һәрбер төрле юлда шул көнне хатерләргә, шул көнгә карап эшләнәчәк милли эшкә киң бер мәйдан бар. Шуны «эшләү! һәм ничек эшләү?» генә кала.

Илебездән читтә яшәгән илдәшләребез, мәгаттәәссеф (үкенечкә каршы), бик таркаулыкта яшиләр, алар бер-берсендән әллә ничәшәр мең чакрымлык җир-су берлә аерылган кебек, алар мәгънәдән дә төрле-төрле чит мәдәниятләрнең тәэсирендә калалар. Бу таркау бер милләтнең балаларын берләштерә торган бер мәдәни мәркәзебез юк. Мондый уртак булган милли йөкне күтәрә торган мәдәни бер оешмабыз да юк. Шуңар күрә бу эш тә аерым-аерым гөруһларның (төркемнәрнең) тәшәббесләренә (тырышлыкларына; инициативасына) кала. Безнең мөһаҗирләребезнең гыйльми яктан көчле җире Төркия булганга, безнең андагы илдәшләребезнең мондый мәдәни эшләребездә юлбашчылык итүләре кирәк иде. Ләкин, мәгаттәәссеф, анда да мондый бер хәзерлек күренми. Кала Ерак Шәрык берлә Аурупадагы мөһаҗирләребез.

Ерак Шәрыкдан Хөсәен Габдүш әфәнде* Тукайның 20 еллыгын хатерләтеп, Харбинда бер рисалә бастырып таратты һәм бу мәсьәләгә дикъкатьне җәлеп итәргә тырышты. Хөсәен әфәнде үз тарафыннан билгеле бер программ тәклиф итмичә, фикер эшләтер өчен юллар гына күрсәтә. Ул аерым мәҗмугалар бастырып булмыймы? Тукайның аерым әсәрләрен кечкенә рисаләләр төсендә итеп бастыруны аерым мәхәллә һәм оешмалар үз өстләренә ала алмыйлармы? дип сөальләр бирә һәм шуның җавабын көтә. Аурупадагы мөһаҗирләрнең оешкан өлеше сәяси көрәш алып барырга мәҗбүр булганга, аның да үз өстенә йөкләнгән вазыйфасы бик җиткән; аның да матди-мәгънәви көче чикле булганга, бу уртак эшне аңа гына йөкләргә һәм андан гына көтәргә ярамый.

Безнеңчә, бу һичбер сәяси булмаган эш өстендә безнең бөтен мәдәни көчләребез берләшергә һәм, кайда гына булсалар да, бергәләшеп шул уртак бурычны үтәргә тиеш. Инде бу искә алуның программына килгәндә, хәзерге көндә Тукайның аерым әсәрләрен бастырып булса да, аның «Мәҗмугаи асар»ен бастырырга безнең мөһаҗәрәтдә матди көч юк дигән фикердә без. Аның кайбер әсәрләрен аерым-аерым бастыру һәм Тукайга багышлап бер китап, бер мәкалә җыентыгы чыгару эше кала. Тукайдан соң үткән ел безнең тарихыбызда бик

---

* Хөсәен Габдүш (1901–1944) — әдип, журналист, актер. (Аның хакында: Мирас. — 1998. — 7 сан.)

мөһим урынны тотканга, бу дәвердә Тукайның ролен һәм халыкның аңа карашын күрсәтә торган мәкаләләр җыентыкыны туплар өчен безнең гыйлем, әдәбият әһленең кыйммәтле язулары кирәк булган кебек, аның басылуы һәм таралуы өчен дә һиммәтле милләтдәшләребезнең матди ярдәмләре кирәк. Бу эштә юлбашчылык итәр өчен, безнеңчә, урта бер җирдә бер вакытлы һәйәт (комиссия) вөҗүдкә (мәйданга) китерү лязем. Менә шул һәйәт мәгълүм бер мөддәтдә (вакытта) алынган мәгълүматларга карап, күрсәтелгән матди ярдәмләрне үлчәп, үзенең ни төсдә хәрәкәт итәчәген кисәддерә алачак һәм матбугат аркылы бу турыда милләттәшләребезне таныштырып тора алачак.

Вакытның бик кыска икәнлеген игътибарга алып, Тукай хатирәсенә хөрмәт иткән бөтен әһле каләм һәм әдәбдән бу эшкә катышачакларын тиздән белдереп, мәкаләләрен җибәрүләре һәм һиммәт ияләренең дә (спонсорларның) үзләренең ярдәмләрен тиздән күндерүләре матлуб (сорала).

Төрле җирләргә таркалган милләттәшләребез мәҗмугабыз аркылы һәйәткә мөрәҗәгатьләрдә булсалар, шулай ук һәйәтдә үзенең эше турында илдәшләребезгә мәгълүмат биреп торырга теләсә, аларга мәҗмугамызның (журналыбызның) битләре һәрвакыт ачык.

## Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә*

*Гаяз Исхакый*

Үзләренең шәхси кабилиятләре (сәләтләре) берлә бер-берсенә охшау-охшамауларына карамастан, шагыйрьләр үзләренең багланган мәктәпләре игътибары берлә икегә бүленәләр. Бер төрлесе: үзен-үзе тирә-юньнән аерып алып, үзен чорнаган мохиттән рухан (рухи яктан) аерым була ала торган үзенең төшенчәләре, хиссиятләре эчендә генә тәҗәрред итә (ялгыз яши) ала торган вә бу вакытта гына шигырь ярата (тудыра) ала торган шагыйрьләрдер. Икенчесе: үзене тирә-юньнең, мохитнең бер өлеше итеп хис итеп, шуның бөтен күңел алышынуларына үзенең йөрәк тибүе берлә катышып, аның шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шул шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь яратучылардыр (язучылардыр). Беренчелә-

* Яңа милли юл. — 1938. — № 4 (121). — 1–9 б. (2 нче битендә Г.Тукайның рәсеме дә бар.)

ре үзләренең шәхси рухының тирәнлеге, сайлыгы, кабилиятенең көченә карап, зәмин (җирлек) — заман берлә багланмаган вә һәрберсе аерым бер шәхсиятнең төсе-исе килә торган индивидуаль шигырьләр мәйданга ташлыйдыр. Бик күп вакытта мөҗәррәд (абстракт. — *Г.И.*) мәүзугларда яисә бөтен адәмчелек өчен уртак булган мәүзугларда язып, язу теле игътибарга алынмаганда, безгә бәйнәлмиләл (интернациональ) шигырьләр бирәдер. Икенчеләре туган халкы, аның тирә-юне, яшәгән мохитенең шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәрҗеманы (күчерүчесе; тылмачы) булып, шул халыкның шатлыгын, кайгысын, өмиден сөйләүче, аның үзенең мохитенең иҗтимагый омтылышларын төсләндереп эшләүче, җәмәгать эшләренең һичбересе яныннан күз йомып, колагын тыгып үтә алмаучы җәмәгати (иҗтимагый) шагыйрьләрдер. Бу төрлесе, үзенең көче, кабилиятенең зурлыгы, кечкенәлеге, тирәнлеге, сайлыгына карап, яшәгән мохитенең термометры ролен уйнап килеп, үзенең шул термометр дәрәҗәсенең (градусының) нечкәлек-тупаслыгына карап, халкының күзендән кан-яшь агуын, йөрәк тибүен ерлап торадыр. Бездә Сәгыйд Рәми беренче группдан (группадан) булса, Габдулла Тукай менә соңгысы төсдәге шагыйрьдер. Үзенең мохитенең шатлыгын, кайгысын, дәрден шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр. Аның яшәгән, язган дәвере бездә милләтчелекнең иң кайнаган, милли теләкләрнең берсе өстенә берсе үсеп, тирә-якны тутырган вакыт булганга, ул шул теләкләргә, шул омтылышларга бер шигырь төсе бирүче, чуалчык фикерләрдән туган агымларга тугры юл күрсәтергә теләүче, милләт хезмәтчесе, милли шагыйрьдер. Шагыйрьлегенең әүвәлге дәверендә үк үзенә-үзе шул хакта сөаль биреп, шул сөальгә үзе үк тә җавап бирәдер:

> Тик милләткә хезмәткә мәхәббәт миндә бар!
> Минчә, монда ямь дә бар, ләззәт тә бар һәм тәм дә бар! —

ди. Гомере буенча менә шул милләткә хезмәт аның бөтен иҗатларында Тимер Казык йолдызы булып, аның кыйбласы булып барадыр. Бөтен кыска гомере буенча ул шул милли юлдан һичбер тайпылмаенча, кабергә кадәр милләт ерын ерлап, милләт кайгысын көйләп, милләт көлкесендән көлеп, үзенең иҗатын шул милләтчелек калыбына сугып киләдер. Яңлышканда, каләме шуыб кына китеп тә ике юллык кына бер шигырьне дә шул алган юлына хилаф төстә язмыйдыр, яза да алмыйдыр. Менә шул җәмәгатьчелеге аны бик тиз көндә ул вакытның иң зур ихтыяҗлары булган тәрбияви шигырьләр язарга алдан таләп итәдер. Ул, милли вазыйфа башындагы гаскәр кеби, берсе артындан берсе, балалар өчен кыйраәт (уку) китаплары өчен йә тәрҗемә, йә оригиналь бик күп шигырьләр, әфсанәләр, хикә-

яләр мәйданга китерәдер. Ул бу бүлек шигырьләрен, үзенең ана теленә һәймәнә (мәдхия; мактау) язу берлә башлыйдыр. Аны иң кечкенә балалар аңларлык дәрәҗәдә садә итеп эшләп, безгә телебезнең кадере, хөрмәте хакында боңарча (моңарчы) тиңе күрелмәгән бер һәймәнә багышлыйдыр.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле,
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Милли хис вә милли гакыл бергә кушылып эшләнгән бу шигырь парчасы Тукайның тәрбияви шигырьләренең иң кыйммәтлеседер. Боның аркасындадыр ки, бу шигырь бөтен мәктәпләребездә милли һәймәнә (гимн) төсен ала алмышдыр вә бу шигыре Тукайны мәңгегә безнең балаларның иң сөйгән бер ерчысы итеп куймышдыр. Ул дәвер безнең мәктәпләремезне яңа юлда миллиләшдерү, мәктәпләремезнең эченә үземезнең милли мәгънәвиятемезне йирләшдерү булганга, бу юлда бик күп дәреслекләр, кыйраәт китаплары хәзерләнеп ятып, төрле төсдәге садәчә язылган тәрбияви шигырьләргә ихтыяҗ бик зур хис ителеп, һәрбер китапчы Габдулла Тукайга шигырьләр сорап, мөрәҗәгать итеп торганга, Тукай бу вазыйфаны үти алучы иң муафикъ бер кеше булып чыккандыр. Бик күп чагында мәүзуг эзләп торырга да вакыт булмаенча, рус әдәбиятында язылган шигырьләр, әфсанәләрнең мәүзугларын алып, аларны үземезнең калыбка салгандыр. Шулай итеп, Тукайның мәҗмугасында очрый торган Пушкиндан, Лермонтовдан, фәләндән кеби бәгъзе шигырьләр йирләшкәндер. Бу шигырьләрне эшләүдә Тукай бер тиенгә бер тиен тәрҗемә итмәү берлә генә калмаенча, боларны вәзен ягыннан да, аңлаешы ягыннан да тәмамән милли төскә куеп, аларны үзләндергәндер вә аларда укучының милли зәвыкын кытыршыландыра торган бернәрсә дә калдырмагандыр.

Ул вакытымыз үземезнең мәдәни истикъляльлемезне (бәйсезлегебезне) кору дәверемез булып, руслыкдан мөмкин кадәр озаклашырга (ераклашырга) омтылу чакымыз булганга, Тукайның бу төстә шигырьләр язуы охшап бетмәгән даирәләр дә аз булмагандыр. Бу даирәләр бу кадәр күп рус исемләре берлә Тукай шигыренең бәйләнүен, Тукайның ул вакыттагы милли шагыйрьлек исеменә мөнасиб (лаеклы) күрмәгәнләрдер. Мәҗмугалар, гәзитләр, аерым рисаләләр аша гына Тукайның иҗадларын сөргендә тәгъкыйб итеп (күзәтеп; күздән кичереп) ятучы, бу сәтырларны (юлларны) язучы да 1912 елларда Фатих Әмирхан аша Тукайга шул хакта сак булуын тәнбиһ итеп (искәртеп) мәктүбләр язган, нәсыйхәтләр биргәндер. Моның кеби язучылар бер генә булмаган кеби, Тукайның дустлары үзен хөрмәт иткән кешеләре тарафындан булганга, Тукай да бо-

ларны әһәмиятсез калдырмаган. Соңгы дәверендә чын мәгънәсендә мөстәкыйльлек юлына кергәндер.

Икенче якдан Тукайның болай бик тиз рәвешдә халык шагыйре булып өлгерүе кайбер тар күңелле даирәләрдә аңарга каршы көнләшү уены уйнаткандыр. Бу хәрәкәтнең башында булган мөхәррир Галимҗан Ибраһимов аны ул заманның беренче группка кергән шагыйрьләре Сәгыйд Рәми, хосусан Дәрдемәнд берлә чагышдырып, Тукайны шагыйрьлек тәхетендән төшерергә маташкан. Аның йиренә үзе бай, үзе нашир, үзе шагыйрь Дәрдемәндне мендерергә тырышкандыр. Шул вакытларда рус әдәбияты, рус шигыре астында тәрбия ителеп, милли мәсьәләләргә феодализмның калдыклары дип карый торган, милли әдәбиятка марксизм ноктасындан дигән булып, милләтсезләнү бакышы (карашы) берлә карарга өйрәнгән яшьләр группы, башларында Хөсәен Ямаш булдыгы хәлдә, Тукайны кечеләндерергә, Тукайны дәрәҗәсендән төшерергә бер кампания ачалар вә аны гади бер тәрҗемәче, гади бер такмакчы итеп күрсәтергә теләп, Сәгыйд Рәмине күкләргә күтәрәләр. Ләкин бу групп үзләренең шул тәнкыйтьләрен язарга ул вакытның шактый бай милли матбугатында урын да таба алмыйлар. Тукайның дәрәҗәсе, хөрмәте Тукайга каршы чыккан бу агымның язучыларына милли матбугатның ишекләрен тәмам каплый. Бу яшьләр рус гәзитләрендә русча итеп тәнкыйтьләр берлә чыгалар. Русча укый, русча белә торган мохиттә генә аз-маз үзләренә иярченләр таба алалар. Ләкин халкымызның киң укучы катлавында һичбер эз калдыра алмыйлар. Тукай бу агымларга каршы нә моназарә (бәхәс) берлә чыга, нә дә аңарга көндәш итеп чыгарга теләгән Дәрдемәнд, хосусан Сәгыйд Рәмигә каршы үзенең мөнәсәбәтен боза (саклый). Ул Сәгыйдкә дуст кала. Дәрдемәндкә каршы хөрмәтен киметми. Ләкин үзенең тәнкыйтьчеләренә берничә шигырь берлә бик оста җавап бирә. Ул берсендә:

Курыкмый яңгырдан, әгәр булса табигый, чын чәчәк,
Чөнки ул яхшы белә: яңгыр аны яхшыртачак.
Ошбуның күк, куркыта алмый чын талантны интикад (тәнкыйть),
Нык үзенә игътимады (таянычы) һәм сүзенә игътикад (ышаныч):
Тик китә кайчакда кәйфең, хакимең булса ишәк,
Бер татарга ят, мәхәббәтсез, күсәк һәм килмешәк, —

ди.

*Интикадка мөтәгалликъ*[*]*, 1912*

Боның берлә бу тәнкыйтьләрнең мәгънәсен, безнең татар тормышына ят булган килмешәк фикерләр берлә кылынганын укучыга белдереп, үзенең элекке алган юлында дәвам итә.

[*] Интикадка мөтәгалликъ — тәнкыйтькә бәйләнеше.

Галимҗан Ибраһимовның тәнкыйтьләренә каршы ул тагы катгыйрак итеп, тагы кабарак (катырак) шигырьләр кулланып җавап бирә. Үзенең «Мөнтәкыйдкә» («Тәнкыйть итүчегә») дигән шигырендә (болай ди):

Йил тегермәнен күрә дә: «Ах, суы юк!» — дип куя.
Су тегермәнен күрә дә: «Пар, буы юк!» — дип куя.

Ул тота ат койрыгын да: «Бу — озын сач!» — дип куя,
«Тик ник баш түгел — тәнкыйтькә мохтаҗ!» — дип куя.

Ул күрә куй койрыгын да: «Нинди шешкән!» — дип куя,
«Рус табибка бу татарлар нинди дошман!» — дип куя.

Һәм дә боның берлә ул Дәрдемәнд, Сәгыйд Рәми кеби шагыйрьләр, бик аз итеп аз килә торган инешкә корылган су тегермәнләре һавада бушлык вакытында аз-маз тартып, шигырь чыгарып торган кеби, илнең өстендән әле төн якдан, әле көн якдан, әле сулдан, әле уңдан исә торган каты йилгә каршы корылган йил тегермәне дә (Тукай үзе дә. — *Г.И.*) ашлык тартып, шигырь чыгарып торадыр. Болар арасында бер-берсенә каршы көндәшлек юк. Тормышта су тегермәне үз урынында, йил тегермәне үз урынында булган кеби, халык шагыйре үз йирендә, индивидуалист шагыйрь үз йирендәдер. Ат коерыгының урыны артында булып, ялы алдында булса, анда тәнкыйть итәрлек нәрсә юкдыр. Бу табигый хәлдер, димәкче була. Безнең халыкның милли хайваны булган куйның коерыгы-мае ул шеш түгелдер. Ата бабаларымыз мең елдан бирле авызын-борынын майландырган, анаң-әбиенең мең елдан бирле пәрәмәче, сумсасы, бәлеше, чәкчәге, катламасы, боткасының иң кирәкле маддәсе булган — куй маедыр. Аны куллану урысның балык маен белмәгәндән килеп чыккан бер хәстәлек түгелдер. Милли тормышымызның, милли хуҗалыгымызның агымындан килеп чыккан милли ихтыяҗымызны тутыручы бер нигъмәтемездер. «Мөхәммәдия», «Бакырган»нардан өлге алып, шигырь язып, халыкның моңы-көене ерлау рус әдәбият тарихын белмәүдән килгән наданлык түгелдер. Үземезнең тормышымызга, үземезнең шигыремезне мөнасиб рәвештә эшләү генәдер. Бу көнемезне үткән көнләремезгә ялгау тәрәкъкыемездәге табигый үсүне саклау гынадыр дигән сүзләрдер. Тукайның бу җавабы ул заманның укучысында гакыл берлә, гыйлем берлә үлчәп аңлап түгел, хис берлә сизеб, зур мәкъбүлияткә (хуш күрелүгә; кабул ителүгә) кичәдер. Вә «Мөнтәкыйдкә» дигән шигырен һәрбер вакытда сөйләтәдер, ерлатадыр. Ләкин бу җаваблар бу көндә гыйльмән дә дөрест вә тугрыдыр вә киләчәкдә дә бу җаваблар тугры булып калачаклардыр.

Тукай шул тәнкыйтьләргә карап, үзе дигәнчә, үзенә ышанычын, үзенең халыкчы шагыйрь булу игътикадын сындырып, беренче групп шагыйрьләр мәсләгенә күчәргә теләсә, күчә алыр

идеме? Ул Сәгыйд Рәми кеби бер «Мин» шигырен тудыра алыр идеме? Югарыда сөйләп киткәнчә, сәнгать — сәнгать өчендер мәсләгенә кереп китеп, чын бер шагыйрь булыр өчен беренче шарт: үзенең бөтен тормышы, тән авырлыгындан ычкынып, күкләрдә оча алу, йолдызлар берлә узыша алырлык рухан тәҗәрред итә (ялгыз яши) ала белүдер. Үз милләтенең үксез тормышына үзенең ятимлеге берлә, вөҗүде берлә багланган Тукай татарның бу көнгә кадәр бар, бер булып килүендән беренче рольне уйнаган муллалыгы, остазбикәсе берлә, каны-җаны берлә берләшеп беткән мулла малае Тукай «Мөхәммәдия»нең мисраглары, «Сөбател-гаҗизин», «Бәдәвам», «Бакырган»ның моңлары-зарлары, нәсыйхәтләре, шадландырулары, өмидләндерүләре, оҗмахлары, тәмуглары берлә рухының кырык катында кырык төрле җөбләр берлә чәбәләнеп беткән Тукай, тагы бу көнге кайнаган Казанның матбугатына, көлке мәҗмугаларына, милли театрларына, милли ерлары кичәләренә, куй майлы пәрәмәчле, пилмәнле дустлар мәҗлесләренә, Печән базарының үзенә махсус исенә, сасысына баш-аягы берлә чумган Тукай фәна фиш-шигъри булып (шигърияттә онытылып), тәҗәрред итә ала идеме?! Аркасына мең төрле йеб берлә тагылган шул вакытның милли йөге, меңәр потлык милли мәсьәләләре аны күкләрдә очып, Зөһрә йолдызының нуры берлә йылытып, бер кызның күзенең тирәнлеген язарга имкян (мөмкинлек) бирә алыр идеме? Юк! Тукай әгәр дә бу юлга чыгарга теләгән булса иде, ул тутый кошының йөрүенә иярергә теләгән саескан кеби үз йөрүен дә онытачак, тутый йөрүен дә каввәлдә (тасвир) итә алмаячак иде. Бәрәкәт боерсын (? — *Х.М.*), Тукайны бу ялгыш тәнкыйтьчеләр бу хата юлларга суга алмадылар. Тукай үз юлында баручы, милләт кайгысын кайгыртучы халык шагыйре булып калды. Ләкин Тукай үзлеген идракъ итеп (төшенеп) йитмәгән руслашуны тәрәкъкый итү дип аңлаган мохитнең зарарлы һөҗүмендән үзенүзе, үзенең игътикады, иманының ныклыгы, халкын сөюенең тирәнлеге берлә коткарып калдырырга өлгерә алмады. Ул икенче бер дошманның һөҗүменә мәгъруз калды. Аның үксез тормышының мирасы булган үпкә хәстәлеге аңарга һөҗүмен куәтләтде. Болар аның тәнен кимерү берлә генә калмадылар, аның рухына да һөҗүм итделәр. Таза тәндә таза җан дигәнчә, аның хәстә тәне җанын да хәстәлеккә өстерәде:

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ (киртә) күрсәм, тибәм дә аударам.
Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим, ... —

дип башлаган батыр шагыйрьнең ерларына яңа аһәң керә, аны моңлык каплый башлый. Бу халәт аның шигъри куәтен зәгыйфьләндермәсә дә, билгакес (киресенчә) аның бу шәхси дәрде,

бу кайгысы аның сазын тагы да нечкә кылларында уйнатып, аның шигырьләрен тирәнәйтсә дә, аңарда киләчәк өчен бер курку уята. Аңарда шәхси өмидләр сына башлый. Ул:

Нинди дәрд берлә каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы, —

дип зарланып куя. Моның артындан аның өмиде азаюы үзенең рухына начар тәэсир итеп, ул тагы:

Теләү бетде хәзер миндә, теләп соңра теләкләрне;
Кире сүтдем хәзер күп эшкә сызганган беләкләрне.

...Бетердем шиндереп төрле гүзәл чәчкәмне барсын да
Явыз тәкъдир, каты тәкъдир, суык тәкъдирем астында.

Өмидсез мин, фәкать актык дәкыйкамны (минутымны) көтәм инде,
Көтәм: кайчан тавыш-тынсыз гына бер көн бетәм инде, —

дип еглап ерлый.

*«Теләү бетде», 1911*

Татарның иң зур шагыйре булып өлгергән Тукайның шул күз яшьләре укучы алдында куркынычлы киләчәктә бер хәбәр кеби каршы алынмый. Аның бу шигырьләре шагыйрьнең күңеле нечкәреп киткәндән килгән күңелнең бер гади сыкрануы кеби генә каршы алына. Хәстә Тукайны карату, аның эчен кимерүче авыру берлә чынлап тартыша башлау вакыты җиткәнлеген беркем дә күз алдына китерми. Казанның Тукай тирәсендә йөрегән төрле-төрле дустлары, мөридләре, ибдәшләреннән мөрәккәб (торган; төзелгән) тугрысы эшсез бер гөруһ (төркем) да, киң катлау халык да фаҗиганең тирәнлеген аңламый. Ул тагы көннең гайбәте, көннең мәсьәләсе берлә Тукайның ул шигыренең мәгънәсен оныта. Тукай үзе дә шуңарда туктамаенча, тагы икенче рухда шигырьләр дә яза. Ләкин вакыт, форсат бар чагында Тукайны кымызга җибәрү, Кырымга озату, бигрәк тә Тукайны сарпәсез (сарыпсыз — авыр) хәятдан тартып алып, аның шәэненә (хәләтенә) муафикъ исәнлеге-саулыгы өчен кирәкле тормыш корырга, корышырга тиеш эше башланмый. Аның шигырьләре инде китапчыларга, наширләргә меңләрле-меңләрле табышлар китерсә дә, Тукайның Уфа, Әстерханга кадәр сәяхәтенә дә акчасы булмый. Казанның үзендә меңләр-меңләр акчалар су кеби акса да, Идел буе сәүдәгәренең көндән-көн баеп, милли эшләргә бик юмардча кылана торган чаклары булса да, Тукайны Кырымга күндерү, чынлап карату кеби эшләр — һәммәсе дә акчасызлык сылтавы берлә туктап кала. Табигый, бу эшдә Тукайның үзенең кешедән акча алуга һич дә разый булмавы, үзенең нәшер эшенә юлга куярлык тормыш тәҗрибәсе булмавы да зур роль уйный. Нәтиҗәдә бөтен төрк-татар дөньясы алдында Тукай йилдә яна торган шәм кеби көн-

дән-көн аның актык сәгатьләре якынлаша. Ләкин аны саклау тәдбире (уй-нияте) иң соңгы вакытка кадәр кичектерелә. Тукайның, алдан хәбәр биргән кеби, берничә ел элек ерлаган, көйләгән:

И мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз,
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы, —

дип алдан хәбәр бирүе дөресткә чыга.

Габдулла Тукай 2 нче апрельдә (иске стиль. — *Г.И.*) Казанның бер хастаханәсендә вафат итә. Вә безгә килгән шигырьләр мәҗмугасын мирас калдыра...

Бу шигырьләрнең кыйммәте, аларның яшьлегебезгә никадәр хезмәт итүе әлегә-әле үлчәнеп йиткәне, тәкъдир ителеп өлгергәне юкдыр. Ләкин Тукайның шигырьләрендәге шул садә, матур теле, аның шарлап ага торган су кеби шигырьләренең табигый юлда, милли төсдә агуы, безнең яшьлегемезнең үз теленә мәхәббәт куюына сәбәп булды. Безнең халкымызның туган илендән читдә яшәүче яшьлегенә үзенең ана телен саклавына бик зур бер милли корал булды. Шуның өчен Тукайның телемезгә хезмәте күзгә күренгән иң зур мирасларындан берседер. Моны иҗекләп бирү телчеләремезнең җентекләүләрен көтеп торганга, бу хакта сүзне озайтмыймыз. Тукай вафатының 25 еллыгы көнендә үксез иленең бүген кызыл руслык хөкеме сөргән үксез почмагында ятим яткан кабере алдында теземезне чүгәмез. Исән вакытта кирәге кадәр кадерен белмәгән, кыйммәтен танымаган милләтнең бүгенге хөрмәтен, сөйгесен газиз рухына сонамыз (багышлыйбыз).

## Тукай турында Исхакый кызы

Мәгълүм ки, Октябрь инкыйлабыннан соң мөһаҗир милләттәшләребез, үзләренең фикерләрен белдерү һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, Аурупаның, Ерак Шәрыкның аерым мәмләкәтләрендә татарча төрле гәзит-журналлар чыгарганнар. Болар арасында Г.Исхакый мөхәррирлегендәге «Яңа милли юл» мәҗмугасы (ул әүвәл «Милли юл» исемен йөртә) мөһим урынны алып тора. Гарәп хәрефләре белән басылган бу журнал 1928–1939 елларда Берлинда нәшер ителә. Ул тематик төрлелеге, масштаблылыгы, татар язмышын үзәккә куюы белән сыйфатлана. Журнал сәхифәләрендә Тукай тематикасына да җитди урын бирелә. Андый материаллар аеруча шагыйрьнең туган, үлгән вакытына мөнәсәбәттә урнаштырыла.

Журналда Г.Тукай хакында, Г.Исхакый, Х.Габдүш, Солтан һәм кайбер башка авторлар белән беррәттән, Г.Исхакыйның кызы Сәгадәтнең дә язмалары бар. Шундыйларның берсе Ту-

кайның тууына 50 ел тулу уңае белән язылган (1936. — № 6. — 14–17 б.). Мәкалә авторы фикеренчә, «атаклы», «бөек» шагыйрь — һаман да «яшь егет кебек». Андагы бәхәсле, кимчелекле яклар да халкыбызның «үсү, алга үрләү» хосусиятләре белән билгеләнә. Сәгадәт Тукайның илле яшьлеген тиешенчә, аңа лаеклы үткәрә алмауга үкенечен белдерә һәм укучыларны шагыйрьнең «самимилегендән, милләтчелегендән бетмәс-төкәнмәс куәт алырга» чакыра. Мәкалә шушындый юллар белән төгәлләнә: «...Яшьли үлгән Тукайны яшәтү, даимән аның берлә бергә булу өчен аның шигырьләрен тагын да күбрәк укуны тәүсыя (тәкъдим. — *Х.М.*) итү иң тугрысы булыр».

Сәгадәтнең икенче язмасы бераз соңрак, 1938 елда дөнья күрә. Ул «Габдулла Тукай (үлүенә 25 ел булу уңае берлә)» дип исемләнгән (Яңа милли юл, № 4. — 9–14 б.).

Сәгадәт — Гаяз Исхакыйның бердәнбер кызы. Ул 1907 елда Чистай төбәгендәге Яуширмә авылында туа. 20–30 елларда әтисе белән Варшавада, Берлинда яши, Алманиядә югары белем ала. 1932 елның 8 октябрендә ул Гейдельберг университетын тәмамлаган Таһир Шакир Чагатайга кияүгә чыга. Күп эшләрдә, шул исәптән журнал чыгаруда да әтисенә булыша. Бераздан Сәгадәт һәм Таһир Чагатайлар Төркиягә күчеп китә. Исхакый кызы анда тюркологиядән зур белгеч, күренекле профессор буларак таныла. 1989 елда Анкарада вафат булган бу ханымны Төркия галимнәре хәзер дә хөрмәт белән искә алалар. Аның әтисе хакындагы аерым истәлекләре, язмалары соңгы дәвер татар матбугатында да дөнья күрде.

Сәгадәт Гаяз кызы милли тәрбия алган, Тукайны укып үскән. Әтисеннән, татар зыялыларыннан бөек шагыйрь хакында күп ишеткән. Башка язмаларындагы кебек үк, Тукайның үлеменә 25 ел тулу уңае белән язылган мәкаләсендә дә Сәгадәтнең олуг шагыйрьгә хөрмәт-ихтирамы гаять зур. Ул Тукайның бөек табигый талантын, «инсане гали» булуын таный. Мәкалә авторы шагыйрьдә, әтисе Исхакый кебек үк, халкыбыз рухын, «милли вөжданын» гәүдәләндерүчене күрә. Аның өчен Тукай — милләтне бергә туплаучы, «илне» танытучы «бөек мәгънәви байлык», татар яшәешенең бер символы, аның «күңел көзгесе». Тукай әдипләр алдына куела торган таләпләрнең барысына да җавап бирә. Аның идеалы — бөек, изге. Һәм шагыйрь үз әсәрләре белән укучысын да «инсане гали»леккә, югарыга күтәрә, гаделлеккә, вөҗданлылыкка өнди.

Сәгадәт аеруча Тукайның балалар өчен язылган шигырьләрен югары бәяли. Моны мәкалә авторы иҗат иясенең табигате, психологик хосусияте белән дә аңлата. *«Балалар да,* — ди Сәгадәт, — *аның төсле керсез, сафлар... Тукай шул балача сафлыгы берлә үз халкын сөя».*

Г.Исхакый язмаларында милләте өчен биниһая зур эшләр башкарган Тукайга үзе исән вакытта тиешле игътибар булмавы искәртелә. Мондый караш Сәгадәт мәкаләләрендә дә үзен сиздерә.

«Игү ат», үзеңнән соң «эз» калдыру — Урта гасыр әдәбиятында төп мотивларның берсе. «Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Рабб, гүзәл эзне!» — дип, Тукай да бу традицияне дәвам иттерә. Сәгадәт мәкаләсендә дә бу мөһим момент махсус искәртелгән.

Язма авторының Пушкин, Горький безгә «ят» диюе һәм, гомумән, аларга тискәре мөнәсәбәте, әлбәттә, чынбарлыкка туры килми.

* * *

«Нә күңелле, нә яхшы ки, — Тукаемыз бар!» — ди Сәгадәт. Чыннан да, шагыйрь татар рухына, милләтебез язмышына шулкадәр сеңгән ки, аларны аерып карау һич тә мөмкин түгел.

## Габдулла Тукай

*Сәгадәт Чагатай**
*(Үлүенә 25 ел булу уңае берлә)***

Көзге төн, мин йоклый алмыйм, өй түрендә йил елый...
Йил еламый, ач үлемнең куркусыннан ил елый.

Илемезнең иң зур шагыйре Тукайның үлүенә 25 ел тулу көнләрен дә, мәгаттәәссеф (үкенечкә каршы), чит илләрдә, төрле ихтыяҗлар эчендә үткәрергә мәҗбүрмез. Халкымызның җани мөмәссиле (җанына тиң) урынын тоткан Тукайны чит ил шәһәрләрендә чынлап искә алу бәгъзән (кайчак) безгә бөтенләй имкянсез (мөмкин булмагандай) күренәдер. Тукайны хөрмәт өчен Берлин, Парис (Париж), Токио вә башкалар муафикъ түгел, «ямьле, нурлы Казан» булса иде дигән фикер бигрәк тә күңелемезне рәнҗетә, рухымызны боекдыра. Ләкин боңа карамасдан, яшь Тукайның бондан 52 ел элек туган булып, безгә бер дәверемезнең рухын ачып калдырган мирасы мөһаҗирлек хәятемездә вә илемездәге гыйфрит көнләрендә никадәр зур бер байлык булуын игътираф итмәенчә (әйтмичә) кичә алмыйбыз.

---

* Сәгадәт Чагатай — Исхакова Сәгадәт Мөхәммәтгаяз кызы (1907–1989) — тюрколог-профессор.
** Яңа милли юл. — 1938. — № 4 (121). — 9–14 б.

Хәзерге дәверемез Тукайсыз булса, ничек булыр иде икән дигән курку сөале генә дә безне шул бөек мәгънәви байлыкдан аера кеби була. Тукай бүген яшемезне, картымызны үземездән меңләрчә чакрым еракльıкда булган илемез берлә шундый оста баглап тора ки, без аңардан да куәтле бер милли багны мөһаҗирлекдә күрсәтә алмыймыз. Илдән читтә торып үскән яшьләр Тукай аркылы илне таныйлар. Мәктәпләр ялгыз Тукай берлә генә дә үзләренең чын мәгънәсендә «милли» мәктәп кушаматларын ташый (ала) алалар. Җәмгыяте хәятемездә, кичәләремездә Тукайның йөрәккә кереп утырган берничә шигыре янә дә «милли» аң вә рух бирү өчен җитәдер.

Тукайдан бик күп мәртәбәләр югарыда торган галимләремез Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэддин Фәхреддин вә башкалар табигый шәраитләре (шартлары) эчендәге ил вә халык арасында үзләренең югары мәгънәвиятләре берлә Тукайны күләгәдә калдырырлык бөекләремез булса да, хәзерге таланган вә изелгән илемездә вә бүгенге мең бер ихтыяҗ эчендәге дөньяның төрле тарафына таралган мөһаҗир хәятемездә үзләренең урынларын Тукайга бирергә мәҗбүрләр. Мәрҗани вә Насыйри мәгънәви куәт итеп җәмгыяте хәятендә яшәтә алу өчен куәтле матбугат вә куәтле җәмгыятьләр кирәк булса, Ризаэддин Фәхреддинне яшәтү вә ул уртага аткан мәсьәләләрне тотыру өчен зур мәхәлләләр кирәк, янә дә үзенең мөнәүвирләре (зыялылары) кирәк... Шуның өчен дә без аларны «бөек илемезнең бөек мәгънәвияте» арасына һәркемгә аның эченә керү гайре мөмкин сәхифәсенә кертеп, Тукаемызның «Туган тел»ен әҗнәби (чит) илләрдә туган балаларның ямьсез тәләффыз (тавыш) берлә көйләвендән ләззәт аламыз, мәктәпләремезне, өемезне, кичә вә җәмгыятьләремезне Тукай, Тукай, Тукай берлә тутырамыз.

Тукайны безгә шулкадәр нык баглый торган куәт Тукайның милли вөҗданында дип беләмез. Бу милли вөҗдан Тукайда шулкадәр саф, шулкадәр тирән ки, аның тәэсиренә бирелмәү мөмкин түгел. 3 җилдлек (томлык) кечкенә генә күләмдәге Тукай мәҗмугасы берсе артыннан берсе беренче шикелле тезелгән, самимият вә милли вөҗдан көзгесе булган шигырьләре берлә һәрбер укучыга, бер яңа нәрсә бирү берлә бергә, бер бөтенлек вә бер культур бирәдер. Гомумән, бөек шагыйрь вә әдипнең вазыйфасы укучысыны үгрәтү, аңын күтәрү, хатасын күрсәтү, күңлен нечкәртү, мәгънәвиятен җилкендерү булса, Тукай да шул сыйфатларны бөтенесен үзенең укучысында уята. Бәгъзән, ул вазыйфасы өчен, үзенең саф вөҗданын керсез рәвешдә күрсәтүдән генә ләззәт алганга, әдәбият чәрчивәсенә (кысаларына) керми торган шигырь үлчәве

яңлышларына да исе китмичә, шигырь яза вә бөтен тышкы шәкелләрдән ваз кичә. Тукайның шигырьләре арасында бозык үлчәү берлә язылган шигырьләр дә күп. Ләкин Тукайның бөтен шигырьләрен укыган кеше өчен боның әһәмияте бик аз. Ул үзе дә, бер дә тәкәллефләнмәенчә:

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз (һаман) алга барам,
Юлда манигъ (киртә) күрсәм, тибәм дә аударам, —

ди.

*«Бер татар шагыйренең сүзләре»*

Тукай тәкәллефсез, самими, саф, динле, мәгърур, бозыклыкдан качучы әхлак сахибе (иясе), җәмәгатьче шагыйремездер вә безнең халкымызның намусын, вөҗданын үзенең күңеленең көзгесе булган шигырьләре берлә тәмсил итүчедер (гәүдәләндерүчедер). Шуның өчен дә Тукайны «милли шагыйрь» диябез, шуның өчен дә аны укыган саен укыйсыбыз килә, шуның өчен дә аны укыган саен, үзебезне күтәрелгән вә бер баскыч югарыга менгән шикелле хис итәбез. Тукай үз халкының милли вөҗданын ташучы булырга тәмамән икътидарлы (сәләтле) булуын күп хисап шигырьләрендә беләмез:

Телим булырга мин инсане гали (бөек кеше),
Тели күңлем тәгали биттәвали (даимән югары күтәрелүне).

*«Үз-үземә»*

Милли вөҗданымызның мөмәсиле шагыйрь «инсане гали» булырга теләве берлә, безне дә «инсане гали»леккә омтылырга чакыра. Ул үзе тумышдан «инсане гали» булып туган, ләкин халкымызның бәхетсезлеге, тарихымызның караңгылыгы, илемезнең шул иң пакь, иң ару күңелле углына бер яхшы мохит биреп, үзенең кабилиятенә лаек рәвешдә инкишаф итәргә (ачылырга) имкян (мөмкинлек) бирмәгән. Мәңгелек яшәячәк булган «Өзелгән өмид», «Туган тел», «Аллаһу тәбарәкә вә тәгалә», «Шүрәле», «Су анасы» вә бик күп әхлакый шигырьләр янында Тукай фөрьяд берлә «Милләтчеләр», «Чын вә ялган», «Бәгъзе зыялыларымыз», «Күрсәтә», «Яшьләр»не ачы тавыш берлә кычкыра. «Дөньяда торыйммы дип киңәшләшкән дустыма»да бу фөрьяд (аһ-зар) аның күңелендән бөтен нәфрәте берлә чыга:

Хаклык астына күмелгән шул, өстендә түгел,
Шуның өчен астка таба тарта күңел.
Хаклык берлә мәхшәргәчә бергә булыр өчен,
Син дә тиз бул, тиз бул, йиргә күмел! —

дигән.

Тукай «Чын вә ялган»да:

Көчле кулы берлә «ялган» «чын»ны бер сукган, ди дә,
«Чын» батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә! —

ди.

Хаклык сөюче, вөждан берлә генә яшәргә ашкынучы, арыган вә авыру Тукай «Дошманлар» шигырендә дөньядан туюын вә үзенең тар мохитендә вә шундагы вак кешеләр дөньясы эчендә торырга куәте юклыгын мәгърур матур сүзләр берлә:

Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна (бетә торган),
Анда тормакга һәвәслек берлә ваклар мөбтәля (дучар була), —

ди.

Шул ук елда (1912 дә) «Вакланмыйм» шигырендә янә үзенең «инсане гали» икәнлеге шөгурында (сиземләвендә) халкыбыз аңа бирә алган рухсыз, эч пошындыргыч, тар мохитдән өзелеп, үләр алдындагы теләкләрен әйтә:

Ашкынамын мин әбәд (мәңге) бетмәс урынга мәңгегә,
Мәңгелеккә, мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!
Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;
Бу кояш сүнсен, йиренә мин кояш булмак телим.

Мәңгелек рухлы, мәңге нурлы вә яшь булырга дөнья аңа ишек ачмагач, ул «үкенече» берлә янә «инсане гали» фәукылгадә (гадәттән тыш) бер саф кеше булуын ерлый: «Ак кирәк дип, пакь кирәк дип, күпме күз яшь түкмәдем!» дигәч, үзенең хаталары өчен укучыларының гафуларын сораган кеби: «Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем», — ди (1911). Йир йөзендәге керлекдән җирәнгән саф шагыйрь 1912 елда янә «Тәләһһеф»*е берлә үзенең пычрак вә ялганларны яратмавын күрсәтүдән туктамый:

Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөжданга юк,
Ни сәбәптән йир йөзендә тәнгә — мунча, җанга — юк?!

«Кыйтга» берлә шагыйрьнең саф, тәмиз (пакь) рухы (1913, 1 мартда) үзенең никадәр арулыкны, вөжданны сөюендән соңгы кат ишарә бирә:

Кайтмады уч, бетде көч, сынды кылыч, — шул булды эш,
Керләнеп бетдем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

Тукайның дөньяны пакьләргә теләве, «ак вә пакь»не эзләве — барысы да халкы өчен. «Инсане гали» Тукай тәсадеф (очраклылык), әллә керләнүдән куркуы нәфрәт дәрәҗәсендә зур булгангамы,— беренче шигыре булган «Мужик йокысы»ның соң мисрагларында ук:

---

* Тәләһһеф — йөрәк ачысы, йөрәк әрнүе мәгънәсендә.

Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә!
Бу юлда һәртөрле хурлыкка, зурлыкларга (бу очракта — кыенлыкларга) түзмәккә!* —

дип бетерәдер. Бу беренче симбол (символ) кеби күренгән сүзләрдә Тукай, күз яше түгеп, аклык-пакьлекне халкы өчен эзләнүен сөйли. Милли вөждан вә аның әсасе (нигезе; асылы) булган пакьлек Тукайда шундый зур сыйфатлардан ки, ул ансыз каләм тота алмаган.

Тукай калдырган иң кыйммәтле парчалар балалар кыйсеме (өлеше) булуы да Тукайның яшьли вөждан сафлыгы, бөтен керсезлеге шул пакь күңелләргә генә сөйли ала торган сүзләр берлә булуындан вә боның эчендә генә Тукай үзен саф вә керсез хис итә алуында, тәмам үзенең бөтен җанын, рухын бирә алуындадыр. Болар Тукайның иң якын дустлары, алар аның төсле керсез, сафлар, алар аның төсле җандан, чын күңелдән «Туган тел»не сөйлиләр, аның төсле җандан дога кыла беләләр, аның төсле саф сөя беләләр. Тукай шул балача сафлыгы берлә үзенең халкын сөя. Гасырлардан бирле дәвам итеп килә торган әсирлек чылбырының авырлыгы Тукай шигырьләренең бик күбесендә хис ителәдер, шулар эчендән еракда калмыйлар. «Көзге йилләр» — бүген дә шагыйранә тасвир гына түгел, җан ачысы берлә һәр елны халкымызда яшәп торган фаҗигаләрнең иң зурысы. Илемезнең большевик дәверендә «бик зур уңышларга ирешүен» белдереп тора торган большевик гәзитләре еш-еш кына дәшми-тынмый Тукайның ачлык хакындагы ачы фөрьядын — «Көзге йилләр»не басалар. Һәр сүзе йөрәккә ук берлә аткан шикелле әрнүле сүзләр вә:

Ач үлемнең куркусыннан ил елый...
...Җан алырга кызганудан анда Газраил елый... —

мисраглары бүген өчен, хәзерге дәвер өчен Тукай тарафыннан бер иляһи куәт берлә язылып калдырылган «Коръән» аятенә охшый... Безгә ят Пушкин, Горький вә башка урыс-улак әдәбият вә нәшрият битләрен тутырып торганда, янә бер кечкенә Тукай мисрагы теге урыс чүпләрен үзенең милли вөжданы берлә фәрештә канаты шикелле каплап куярга кодрәте бар. Бүгенге дәверне хакыйкатән дә Тукайсыз төшенү имкянсез (мөмкин түгел); Тукайсыз булу халкымыз өчен тагын да зур бәхетсезлек булыр иде дип уйлаудан тартына алмыймыз.

Нә күңелле, нә яхшы ки, — Тукаемыз бар! Халык өчен нә бөек юаныч ки, бондан 30–40 ел элек пәйгамбәрләр генә күр-

---

* Бу юллар «Мужик йокысы» шигыреннән түгел, ә «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» әсәреннән (Карагыз: Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. — I том. — К.: Тат. кит. нәшр., 1975. — 72 б.).

гән авырлыклар, сәфаләт (хурлык) вә зәхмәтләрне күреп, бала табигатендән чыгып бетмәгән яшь фидаи егет халыкның мәгънәви хакын таләп итеп, аның вөжданын уятып калдырган, балаларына туу берлә, ата-ана дине берлә үк миллият рухын бирә торган милли догалар язып калдырган. Үзе тугрында Тукай:

Минем гомерем караңгы төн, кояшлы һәм аем тугмас,
Шуңар да шөкер итәмен мин*: бу төнем йолдызлы, йолдызлы.
Озатдылар миңа күп төрле мәлгунь көч, кара көчләр,
Теләп сүндермәгә күңлемдә янган изге йолдызны...
Күзендән канлы яшь түксен иде барча шәятыйным (шайтаннарым),
Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Рабб, гүзәл эзне! —

ди.

*«Күңел йолдызы»*

Мөтәвазигъ (итагатьле) Тукай шул «гүзәл эзне» үзенең халкы арасында ничек зур, ничек тәэсирле калдырды. Үзе тасвир итә алмаган кадәр изге йолдызлар мирас итде. Керләнүдән бер бала шикелле курыкган шагыйрь: «Ак кирәк дип, пакь кирәк дип, күпме күз яшь түкмәдем!» — дисә, үлүендән 25 ел узганча аның сөйгән халкы да аның гали рухын, керсезлеген белеп, аңлап бетерде. Аның изге йолдызы төнемезнең йолдызы, аның вөжданы бөтенемезнең омтыла торган вөжданы булды.

«Бу кояш сүнсен, йиренә мин кояш булмак телим...» — диюче Тукай бүген милли вөжданымызның кояшы булды. Аның яшәгән хәяте, үзе әйткәнчә, кояшсыз вә айсыз булса да, ул үзенең иленә вә халкына иң зур теләкләрдә булынып, аңа үзенең саулыгын вә бөтен эчке барлыгын биреп калдырды. Үзен үлем, бары үлем генә хәстәлек вә хәят җәфасындан котылдыра кеби: «И үлем! Мин синдә бер хәсрәт вә шадлык күрәм»,— дип, үлем якынлашуын шадлык берлә көтде...

Бүген Тукайның үлүенә 25 ел булуын хатирәләгәндә (хәтергә алганда), Тукайның шәхси авыр хәятен искә дә алмаенча, ул никадәр зәхмәт чиксә дә, «безнеке» булуы берлә генә ифтихар итәмез (горурланабыз). Бүген инде аның хәятен озайта алмаганымыз шикелле, аның фаҗигале тормышын да тарих сәхифәсе, бәхетсез тарихымызның канлы ачы сәхифәләре эченә генә кертәмез. Һәм үзе берлә бергә: «Тик мин үлгәчдән караңыз, типмәсенләр нәгъшемә (үле гәүдәмә, мәетемә) (нәгым — җеназа) дигәне кеби: «Типмәсенләр аның мөкатдәс мирасына!» — дибез вә хәзер(ге) елымызда яктылык урынына караңгылык күндәреп тора торган «бу кояш сүнсен» дә йиренә Тукай сөйгән халкымызны яктырта торган икенче кояш чыксын! дибез.

---

* Тукай әсәрләренең дүртенче басмасында — Шуңар да шөкер итәм мин (II том, 62 б.).

## Габдулла Тукай*

*Сәгадәт Чагатай*

Бу елның ниндидер бер көнендә илемезнең бик яшьли дөньяны ташлап киткән атаклы шагыйре Габдулла Тукайның 50 яшен тутыру мөнәсәбәте берлә милли матбугатда берничә язу чыкты. Бу илле яшь берлә бергә Габдулла Тукайның шагыйрь булып танылa башлавына 30 ел кадәр вакыт кичеп китүене дә вә бу еллар эчендә Тукай әсәрләренең халкымыз арасында елдан-ел таралуыны, шуның берлә бергә Тукай да үсә баруыны да хәтерләвемез кирәк.

Үз илемездә аз гына бер хөрлек булса, бу илле яшьлек Тукай хөрмәт ителер, бу хакда күп язулар, тәнкыйтьләр, тәкъризләр (бәяләмә-рецензияләр) язылыр иде. Ләкин хәзерге дәверемез, әдәбият дәвере булудан артыграк, көндән-көн сәяси дәвер була барганга, мөһаҗир мохитендә вә мөһаҗир хәятендә Тукайны коры хәтерләү, аның хакында язылган иске сүзләрне тәкрарлаудан гыйбарәт булып каладыр. Әлбәттә, бу күп җәһәттән ноксан (кимчелекле) исә дә, Габдулла Тукайның зур «Тукай» булуына катгыян (һич тә; ахыр чиктә) зарар китерми; аның шигырьләре вә боларның эчендәге фикерләре һичбер мәгънәсен дә, киңлеген дә югалтмыйдыр.

Бик күбемезнең күңелендә Габдулла Тукай саф күңелле, киң күрешле милләтче бер... (кызганычка каршы, журналның безнең кулыбыздагы күчермәсендә 15 нче бит юк. Шуңа күрә текст бер битлек өзеклек белән бирелә. — *Х.М.*) дәверенә күрә вәгазь-нәсыйхәт, һөҗү-көлке Аллаһка, милләткә ышану куәте калдырып китде. Аның рухсыз, бәдбин (пессимистик; төшенке), тар һәм хәтта «башы — мачы, коерыгы — былбыл» булган, пешмәгән шигырьләре дә шул дәвернең көзгесе итеп каралырга кирәк. Тукайның үлүенә 23 ел булган шикелле, аның үлемендән соңгы 23 ел эчендә безнең төшенчә вә көрешләремездә 23 еллык аерма бар. Әгәр безгә Тукайның шул кыска гомере эчендә язып, нәсыйхәт итеп калдырган кайбер тар фикерле шигырьләре авыр тәэсир итсә, Тукай хәзерге хөрмәтен казана алмас иде. Әгәр шул шигырьләр хакыйкатән дә (чынлыкта да) безнең олугымызны-кечемезне үсдерүче, мөсбәт (уңай) һәм мәнфи (тискәре) якдан үзлеген онытмаучы мәгънәви азык булмаслар иде, аның күңел суындыргыч шигырьләре безгә начар тәэсир итде һәм итә дия алыр идек. Без аларны атладык. Аның бары иң яхшы шигырьләрен чүпләп, шуларны милли

---

* Яңа милли юл. — 1936. — № 6 (100). — 14–17 б. (Мәкалә Тукайның үлеменә 50 ел тулу мөнәсәбәте белән язылган.)

дога урынында йөртәбез, башкаларын Тукайга һәм аның дәверенә гаид (мөнәсәбәтле), үземезнең хаталарымызны күрсәтә торган вә авыр тормышымызның баскынлыгы астында әйтелә торган ачы фөрьядлар (аһ-зарлар) дип беләмез.

Тукай безнең каршымызда һичбер вакыт бер яшь егет булуын югалтканы юк. Бер яшь кеше, никадәр истигъдадлы (сәләтле) булмасын, күп еллар яшәгән, күп дәверләр кичергән олуг бер кеше түгел. Шуңар күрә Тукайның кайбер фикерләре, бик җанлы булуга карамасдан, тәҗрибәсез һәм соңгы ноктасына кадәр күрә алмаган булуы бик ихтимал. Ләкин безнең Тукаемыз гына түгел, бөтен халкымыз үсү дәверендә булганга, аның бәгъзе бер (кайбер) оешмаган нәрсәләрен яшь, үсү, алга үрләү вакытын кичерүче халык булуымызга багларга кирәк. Без хәзергә кадәр, никадәр зур адымлар аткан булмыйк, бөтен, тулы җитешкән бер милләт булып өлгергәнемез юк. Без шуңа омтыларак һәр көнне адымларны әйләриләтәмез (ясыйбыз) һәм бер җитешкән милләт ирешәчәк баскычларны да ирешәчәкмез. Баскычларның югарысына ирешә барган саен, бәлки, Тукайның «мачы»лыклары безгә ямьсез күренер, ләкин без аны һәрвакыт зур авырлык берлә шул баскычларга менүне җиңеләйтә башлаучы, безне матур тел, ачык каләм берлә бер тиргәп, бер вәгазьләп, бер безнең нечкә тойгыларымызга тукынып, хисләремезне артдырган кеше, «Кечкенә Апушымыз» һәм «Зур Тукаемыз» итеп күрәчәкмез.

Тукайның тәрбияче, нәсыйхәт вә вәгазь берлә кешелеккә димләве вә үзенең арасындагы бушлыкларга каты мөтаәссер булып (борчылып; тәэсирләнеп), былбыл шикелле сайраганда, мачы төсле мияулап куюы да аның бары үзенең тоткан тәрбиячелегенең яшьлеген, төшенүен генә күрсәтәдер. Тукай балалар өчен язып калдырган бик матур шигырьләре берлә үзенең бала сөючән рухын, үзенең халкының балалык дәверен кичерүен вә халык өчен бала тәрбияләү киләчәк өчен иң нык нигез булуын күрсәтеп торадыр. Бу да, фикеремчә, Тукайның иң беренче зур кыйммәтле сыйфатларындан берседер.

Ихтимал, Тукай илле яшендә булу мөнәсәбәте берлә бик күп җирләрдә Тукайны хөрмәтли алмыйбыз, Тукайның кем икәнен тулы көенчә аңлый алмадык дип уйлаучы һәм йөрәге тетрәүчеләр булыр. Бу самими Тукайны сөючеләргә җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүмат бирелә алмауны кызгансак да, Тукайның шәхсыятен хөрмәтләүдән, аның самимилегендән, милләтчелегендән бетмәс-төкәнмәс куәт алырга мөмкин булуын хатерләтеп, яшьли үлгән Тукайны яшәтү, даимән аның берлә бергә булу өчен аның шигырьләрен тагын да күбрәк укуны тәүсыя (киңәш) итү иң тугрысы булыр.

## Исхакый Татарстан хәлләре турында

Безгә, XXI гасыр кешеләренә, XX йөз татар әдәбиятын һәм, гомумән, халкыбызның рухи тормышын Гаяз Исхакыйдан башка күз алдына да китерүе кыен. Бу гаять талантлы һәм тынгысыз зат халкыбызның үзаңын үстерүгә, мәдәниятнең (сүз сәнгатенең, театрның, матбугатның һәм мәгарифнең) алгарышына гаять зур өлеш кертте, татар тормышын кузгатуга хәлиткеч йогынты ясады. Иң мөһиме шул: бөек әдип милләтебезнең үз-үзенә ышанычын арттырды, аның күңеленә бәйсезлек рухы салды. Тарихи сәбәпләр аркасында Татар (Идел-Урал, татар-башкорт, Татарстан...) мәмләкәтенең тәүге илбашы булырга лаеклы Гаяз Исхакый үз гомеренең уртасында туган Ватаныннан аерылырга, төрле илләрдә һәм кыйтгаларда мөһаҗирлекнең ачы шулпасын эчәргә мәҗбүр ителде. М.Горькийга язган бер хатында ул юкка гына болай димәгәндер: *«До сих пор жил с надеждой вернуться в Россию. Но создавшееся за последнее время положение, в особенности начавшиеся репрессии среди татар, заставляют меня надолго бросить эту мечту. Жить на чужбине слишком тягостно, слишком неприятно...»*

Әмма Г.Исхакый, кайда гына яшәмәсен, нинди генә авыр һәм катлаулы хәлләрдә калмасын, милли иманына, яшьлек идеалларына тугры кала. Аның өчен милләт мәнфәгате, татар азатлыгы өчен көрәш барыннан да өстен була. Идел-йорттан аерылса да, бу көрәшче зат күңеле белән һәрчак туган халкы белән бергә, аның йөрәк тибешен сизеп, сулышын тоеп яши.

Г.Исхакый белән аралашкан кешеләр аның халык, ил һәм, гомумән, дөнья тормышыннан искиткеч хәбәрдар булуын искәртәләр. Бу сыйфат әдипнең мөһаҗирлектәге язмаларыннан да ачык күренә. Аның мөхәррирлегендә 1928–1939 елларда Берлинда чыккан «Яңа милли юл» журналы — моның ачык дәлиле. Биредәге материалларның төп өлеше Г.Исхакый каләме белән язылган. Алар арасында нинди генә язмалар юк: сәясәт, икътисад, тарих, заман вакыйгалары, мәдәният, Аурупа, Кытай, Япония, Америка, Төркия тормышы... Әмма Исхакый, нәрсә хакында гына язмасын, һәрчак татар булып кала, терекләккә татар күзе белән карый. Аның язмаларының күпчелеге татар тематикасы белән бәйле. Шуларның берсе «Әдәбият вә нәшрият» дип атала. Ул «Яңа милли юл» журналының 1937 елгы октябрь санында басылган [№ 10 (115]. Беренче карашка бу гадәти генә материал кебек. Г.Исхакый «Красная Татария» гәзитенең 1937 елгы ике санында басылган материалны ала да, әүвәл аларның кыскача эчтәлеген сөйли, аннан үз ка-

рашларын бәян итә. Бу мәкаләләрдә Х.Туфан, Г.Нигъмәти, Ф.Кәрим, Ф.Бурнаш һәм кайбер башка әдипләрнең Язучылар берлегеннән чыгарылуы, «дошман элемент» булулары, Р.Ишморатның театрда «милләтчелек» рухындагы әсәрләр куйдыруы, шулай ук Татарстан радиосында да «сәяси черек һава» хөкем сөрүе, нәшрияттә «контрреволюцион» рухлы китаплар басылуы әйтелә.

Билгеле булганча, 1937 нче ел — Татарстанда репрессияләрнең иң котырган чоры. Г.Исхакый рәсми гәзит материаллары аша татар язучыларының, зыялыларының гаять кыен шартларда яшәвен шактый тулы итеп күрсәтүгә ирешкән: илдә хөрлекне, инсаннарны, халыкларны хөрмәтләү юк; һәркайда — шикләнү, эзәрлекләү. Иң аянычлысы — икейөзлелек, сүздә бертөрле сөйләп, гамәлдә киресен кылу. Бу мәкалә үзе генә дә Гаяз Исхакыйның аналитик фикерләвен, аерым фактлар аркылы зур гомумиләштерүләр ясавын ачык дәлилли.

Әдипнең бу язмасы, бер яктан, күренекле каләм әһелләренең эшчәнлеген, рәсми хакимиятнең куркыныч сәясәтен тирәнрәк аңларга һәм, икенче яктан, Г.Исхакыйның карашларын, фикерләү рәвешен билгеле бер дәрәҗәдә ачыкларга да ярдәм итә.

*2003*

## Әдәбият һәм нәшрият*

*Гаяз Исхакый*

3 август «Красная Татария» гәзитендә Татарстанда Совет язучылар оешмасыннан июнь ахырында Х.Туфан, Г.Нигъмәти, Ф.Кәримнәрнең чыгарылуын, июль ахырында Ф.Бурнаш, Р.Ишморадларның чыгарылган булуын яздылар. Болар контрреволюционерлар берлә дустча мөнәсәбәттә булулары һәм «дошман гонсыр» (элемент) булулары берлә гаепләнәләр. Ишморад Татар академия театрыны идарә итүче һәм драмалар язучы бер кеше булган. Гәзит соңгы чыгаручылар тугрында шул сүзләрне яза: *«Ишморад халык дошманнары берлә бөтенләй бергә иде. Һичбер вакытта ул дошманнарны күрсәтә торган чыгыш ясамаган. Ул татар театрында тар бер мохит яратырга (барлыкка китерергә) тырышып, яшь драматургларның әсәрләрен куюга манигъ (киртә) булып килгән. Эчтәлеге берлә советчыл булган әсәрләр урынына за-*

* Яңа милли юл. — 1937. — № 10 (115). — 8–13 б.

*рарлы милли әсәрләр куйдырган. Фатих Сәйфинең «Дошманлар», «Хәзинә» шикелле Советларга ифтира (яла) ягучы әсәрләр һәм Шамил Госманның (Усмановның) контрреволюцион әсәре булган «Соңга калган әмер»не (ягъни «Кичеккән фәрман»ны) театрга куйган. 1928 елда үзенең Советларга каршы булган «Йокы падишаһлыгында» дигән әсәрен куйдырган. Аннан соңгы елларда да Ишморадның үзенең бу Советларга каршы әсәрен тәнкыйть астына алырга вакыты да, егетлеге дә җитмәгән. Аның әдәби иҗат эшләренең күзгә ташланган ноктасы тар гаилә банкетларында шәраб эчкән вакытта әсәрләр хакында карар бирүедер. Шул рәвешчә, ул Кәрим Тинчура банкетында аның «Алар өчәү иде» дигән әсәре хакындагы карарларын биргән. К.Тинчура үзе өчен реклама ясаучы оста тәшкилләтче (оештыручы) булып, халык дошманнары компаниясеннән булуы да хәзер ачылды. Тинчураның бу әсәре шул банкетта Татарстанның 15 еллык юбиләсендә (юбилеена) куелырга кабул ителә һәм Ишморадка тапшырыла. Фәтхи Бурнаш буржуаз милләтче уларак ике мәртәбә фиркадән (партиядән) чыгарылган. Халык дошманнарын капалы (яшерен) рәвештә мактап язган «Миңлекәй һәм Данбулат» мәнзумәсе (поэмасы) аның каләменнән чыккан бер әсәр булуы да уртага чыкты. Бурнаш башка әсәрләрендә, мәсәлән, «Бохара», «Мөкәррәмә» мәнзумәләрендә милләтче төркче фикерләрене бирә.*

*Ишморад һәм Бурнашның Совет язучылар оешмасыннан чыгарылулары берлә генә әле Татарстан язучыларын милләтчеләр йогынтысыннан арулау беткәне юк. Халык дошманнары, япун-алман фашист агентлары шулкадәр тирән мәфкүрә (уйлы) эшләре йөреткәннәргә, аларның иярченнәре әле тагын кая булса да яшеренеп ятулары бик мөхтәмәлдер (мөмкиндер)...»*

Бу мәгълүматтан соң, әлбәттә, гәзит һәрвакыттагы шикелле татар, Совет язучылар оешмасын «шәкеле (формасы) берлә милли, эчтәлеге берлә социалистик» урыс әдәбиятын инкишаф иттерергә чакыра. Безнең дикъкатебезне җәлеп иткән нәрсә — язучыларның никадәр тәгъкыйбатлар (эзәрлекләүләр), көчләүләр астында яшәүләренә карамастан, һаман да көрәш алып бара алуларыдыр. Юкса бу «милләтче һәм милли әсәрләр» дигән нәрсәнең андагы соңгы елларда чыккан, хәтта язылган китапларда аз гына эзе дә юк. «Япун-алман фашистлары агентлыгы» дип ялганлаулары да халык арасындагы большевикларга каршы булган милләтчеләрне куркыту өчен генә сөйләнә торган шәйтани методлардыр.

Шул ук гәзитдә «Татар радио комитәсенең (комитетының) эшләре» дип тә бер мәкалә бастылар. Буңа (моңа) күрә хәзер шул туктамас тәгъкыйбат (эзәрлекләүләр) инде радиога да килеп җиткән. Анда да «халык дошманлары, дошман гонсырлар (элементлар)» идарә иткәннәр, имеш. Болар Шәфигулла углы, Миңлебай углы, Кәрим углы дигән кешеләр булып, Шәфигулла радио комитәсенең рәисе булган, хәзер урыныннан төшерелү берлә бергә фиркадән чыгарылган. Болар кайбер йирләргә «халык дошманнарының» әсәрләрен радио аркылы күндергәннәр, имеш. Мәсәлән, Бөдәйлинең әсәрләреннән парчалар бирелгән, имеш. Бөдәйлине контрреволюционер милләтче дип атыйлар. Гомумән, радио комитәсендә «сәяси черек һава» хөкем сөрә, имеш. Сталинның канунә әсаси (төп законы, конституциясе) хакында, Зиновьев-Троцкийчылар мәхкәмәләре (судлары) хакындагы мәгълүматлар радиодан бирелмәгән, имеш. Бу инде, әлбәттә, татарча бирелмәгәндер. Гомумән, Казан радиосы (яңлышмасак. — *Г.И.*) көнгә 2 сәгать кенә йирле халыкка аерылып, шул ике сәгатьтә генә татарча сөйли. Башка вакытларны һаман русча гына күндәреп тора. Урыслар шул ике сәгатьне дә күпсенәләр, күрәсең. Радионың программы (программасы) хакында шикаять итүчеләр күп, имеш. Әлбәттә, даимән мәэмүрләрне (хезмәткәрләрне) тәгъкыйб итеп (эзәрлекләп) торгач, программ хакында уйларга вакыт та калмый, аның өчен һичбер хөрлек тә юк. Балалар әдәбияты да бу шөбһә астына алу, тикшерүләрдән хөр түгел. Анда билхассә (аеруча) соңгы ике елда балаларны алдата торган пропаганда әкиятләре бастырып тарату берлә шөгыльләнәләр. Әлбәттә, буңа (моңа) каршы шөгурле (аңлы) бер хәрәкәт булса кирәк, (...) исемле (?! — *Г.И.*) бер балалар китабында большевик бөекләренең исемнәрен 10 мең нөсхәсендә дә бозып чыгарганнар, имеш. Тагын башка китапларда «фашистик» фикерләр кертелгәннәр, имеш. Тик башка балалар китапларында контрреволюцион әсәрләр тәүсия (тәкъдим) ителгән вә контрреволюцион язучылар иштиракъ итәләр (катнашалар), имеш. Балалар нәшриятын идарә итүче Зәйнәп Бәшир дигән бер хатын булып, ул «мулла кызы, җидегәнче, троцкийчы, контрреволюционер» булып гаепләнә. Ул үзе теләгән кешеләрне генә үз янына җыеп, балалар әдәбиятына Советларга каршы әсәрләр тәрҗемә иттерү һәм эшләтү берлә мәшгуль булган, имеш. Әлбәттә, бонда (монда) да Татарстан дәүләт нәшриятын төп сәбәпче итеп күрсәтеп, анда тәмам милләтчеләр тулган, алар гына идарә итәләр, дип гаеплиләр. Әдәбият һәм матбугат сахәсендәге (мәйданындагы) көрәш, әлбәттә, язучыларга вә матбугатка хөрлек бирелгәнче дәвам итәр. Большевик хөкүмәте бу хөрлекнең барлыгын да (бар

булганын) инкарь итеп торганга, хәзерге көндә Башкортстан вә Татарстанда бөтенләй «шәкеле берлә милли» булган әдәбият та тукталган диярлек. Чөнки хәзер ялгыз сәяси нәрсәләрне генә тәрҗемә итү хөрлеге бар, башкалар, ни генә булса да, шөбһә астына алынып, цензур(а)дан кичкәч тә «зарарлы» табылып уртадан алына, шул рәвешчә, матбугат, бер туктамаенча, зарарлы тамгасы салынган буш мәсраф (чыгым, продукция) ясап тора. 10 меңнәрчә басылган бозык матбугат Совет Русиясендә бернәрсә дә түгел, ул һәр ай, бәлки, берничә кат булып тора торган вакыйгалардан. Совет Русиясе шикелле коллык «бәхет» саналган бер мәмләкәт өчен әдәбият вә матбугатның кирәге дә юк. Кирәк түгеллегене ачык сөйләмәенчә, ялган күз буяулар берлә әле һаман да әдәбият вә матбугат бездә дөньяның иң яхшысы дигән дәгъваны дәвам итәләр. Безнең өчен ул авырлыклардан үз әдәбиятыбызның, бик күп зарарланмаенча, кортылып (котылып, сакланып) калуы мөһим...

## Милли кыйблабызны күрсәтүче әдип

Шушы елның февралендә Гаяз Исхакыйның тууына 120 ел тулды. Әмма ни сәбәптәндер узган ел без аның иҗат эшчәнлеге башлануга 100 ел тулу вакыйгасын онытып җибәрдек. Мәгълүм ки, әдипнең чагыштырмача җитлеккән беренче хикәясе — «Тәгаллемдә сәгадәт...» — 1897 елда иҗат ителә. Яңадан бер елдан «Кәләпүшче кыз» әсәре языла.

Халкыбыз «Соң булса да, уң булсын!» ди. Шуңа күрә 1998 елны Г.Исхакыйның тууына 120 ел дип кенә түгел, ә иҗат эшчәнлеге башлануга 100 ел дип бәйрәм итү дә хата булмастыр.

Бөек әдипкә үз гомеренең түгәрәк даталарын илдә юньләп уздыру мөмкинлеге насыйп булмый. 30 яшен ул патша төрмәсендә каршылый. 40 яше ыгы-зыгылы инкыйлаб елларына туры килә. Аннан инде мөһаҗирлек чоры башлана. Әмма илдә мөмкинлек булмаса да, читтә яшәгән милләттәшләребез Гаяз Исхакыйны онытмыйлар. Чөнки ул бу игътибарны, милләт мәнфәгатьләре өчен фидакарьләрчә көрәшеп, үзе яулап ала.

1937 елның башларында, аеруча әдипнең туган ае февральдә, Гаяз Исхакыйның әдәби иҗат эше башлануга 40 ел тулу илдән читтә яшәгән татарлар тарафыннан киң күләмдә билгеләп үтелә. Япониядә, Кытайда, Кореядә, Германиядә, Эстониядә, Финляндиядә һәм башка илләрдә төрле кичәләр, тантаналар уздырыла. Матбугатта Г.Исхакый хакында төрле язмалар дөнья күрә. Мәсәлән, күренекле шагыйрә, педагог Сания Гыйффәт «Халыкның сулый торган һавасы» исемле мәкаләсендә (ул

безнең тарафтан әзерләнеп, «Сөембикә» журналында хәзерге чор укучыларына да ирешкән иде. Карагыз: 1992. — 11 сан. — 19–20 б.) әдипнең 40 еллык әдәби иҗатына бер караш ташлый, аңа хас аерым үзенчәлекләрне күрсәтә. Юбилей тантаналарының иң зурысы 1937 елның 5 мартында Варшавадагы Шәрык институтының зур залында үткәрелә. Анда Польшаның дәүләт эшлеклеләре, галим-әдипләре, шулай ук төрле илләрдән килгән кунаклар, күренекле милләттәшләребез катнаша.

1928–1939 елларда Берлинда чыгып килгән «Яңа милли юл» журналында Г.Исхакыйның бу бәйрәменә мөнәсәбәтле шактый гына материаллар дөнья күрә. Аларда бу затның бөеклегенә, гаять нәтиҗәле һәм күпкырлы эшчәнлегенә, милли-азатлык хәрәкәтенең дөньякүләм танылган лидер булуына басым ясала.

Журналның 1937 елгы 3 нче (108) санында Финляндиянең Тампере каласында Г.Исхакый хөрмәтенә уздырылган кичә хакында мәкалә урнаштырылган. Анда бөек әдип үзе дә катнаша. Шул ук санда язучының иҗат эшчәнлеге башлануга 40 ел тулу уңае белән алынган тәбрикнамәләрнең бер өлеше урнаштырылган. Алар, нигездә, Ерак Шәрыкта яшәүче милләттәшләребезнең котлаулары. Бу аңлашыла да. Чөнки Г.Исхакый моңа кадәр генә Япония, Корея, Кытай якларында йөреп кайта, андагы милләттәшләребезне туплауга, милли рухта тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә, «Милли байрак» гәзитен оештырып җибәрә. Бу хакта Рокыя Дәүләткилде 1988 елның 19 августында Минһаҗ ага Исмәгыйлигә язган хатында (Мирас, 1996. — № 5–6. — 263 б.) менә болай ди: «Мин яшүсмер чагымда аның (ягъни Г.Исхакыйның. — *Х.М.*) әсәрләрен бик яратып укый идем. 1933 елның җәендә ул Япониягә, Токиога килде. Мин андагы татар мәктәбендә урыс һәм инглиз телләре укыттым. Бу шәһәрдә безнең халык шактый, алар сәүдә итәләр иде. Гаяз абзый килүе белән халыкны берләштерү эшенә керешә. 1935 елның февраль 4 есеннән 11 енә кадәре Япония, Корея һәм Кытайда яшәүче безнең халыкның корылтаен уздырырга муаффәкъ (мөмкин. — *Х.М.*) булды. Шунда бер атналык гәзит тә чыгарырга карар кабул ителде. Мәркәз (үзәк. — *Х.М.*) идарә төзелде. Бу эшләр барысы да халыктан җыелган акчага вөҗүдкә килде (башкарылды. — *Х.М.*). Ибраһим Дәүләткилде (бу һәм Рокыя ханым — атаклы милләттәшебез Надир Дәүләтнең эти-әнисе. — *Х.М.*) белән мине шунда эшләргә сайладылар. Гаяз абзый 1936 елның март аена кадәр Мукден шәһәрендә безнең янда булып, безне гәзит чыгару эшенә өйрәтте һәм Варшауга кайтып китте...»

Укучыларга тәкъдим ителүче бу тәбрикнамәләр Г.Исхакыйның шәхесен һәм эшчәнлеген тулырак һәм тирәнрәк аңларга ярдәм итәләр. Язучыны «бөек җитәкчебез», «юлбашчыбыз», «иң зур әдибебез», «кыйбла күрсәтүче» дип атау да күп нәрсә хакында сөйли. «Яңа милли юл» журналының 1932 елгы 2 нче санында титул биттә мондый юллар бар: «Бер милләтне юк иткән нәрсә — ул милләтнең үз-үзенә булган ышанычының югалуыдыр». Г.Исхакый, нинди генә кыен шартларга эләксә дә, оптимистик зат булып кала, шушы рухны халыкка, укучыларга да сеңдереп килә. Шунысы мөһим: тәбрикнамәләр дә татар халкының якты киләчәгенә, бәйсезлеккә ирешәчәгенә тирән ышаныч рухы белән сугарылган. Бу язмалар чит мәмләкәтләрдә яшәгән милләттәшләребезнең тарихын, мәдәни тормышын күзаллау ягыннан да игътибарга лаек.

«Яңа милли юл» — гарәп хәрефләре белән басылган татарча журнал. Биредә без мөмкин кадәр андагы язылыш үзенчәлекләрен сакларга тырыштык.

*1998*

## Гаяз әфәнденең 40 еллык хезмәте мөнәсәбәте илә тәбрикнамәләр

Гаяз әфәнденең туган көненә тугры, 10 февральдән бирле бер туктамаенча, тәбрик телеграммлары вә мәктүбләре килеп торадыр. Хакыйкатәндә (чынлыкта) 40 еллык бер дәвер аз бер заман түгел икән; мөһаҗирлекнең авырлыгына карамастан, Гаяз әфәнденең бу хатирә көненә бөтен илдәшләр мәхәббәт вә сөенеч берлә кушылалар. «Милли байрак» 26 февральдә чыга торган санын боңа багышлаячак, бөтен Ерак Шәрык мәхәлләләрендә Гаяз әфәнденең туган көненә мәрасимләр (тантаналар) уздырылачак, мөмкин кадәр үз әсәрләрендән берсе уйналачак, дип хәбәр бирәләр. Ерак Шәрык мәркәзе Гаяз әфәнденең кыска тәрҗемәи хален, әсәрләренең исемләре, язылу һәм басылу еллары берлә бергә, пөхтә бер брүшәр (брошюра) халендә кулъязма басмасы тараткан; шулай ук төрле дәверләрдә алдырган биш рәсемен дә басдырган. Гаяз әфәнде үзе Корбан бәйрәмен һәм бу көнне Финляндиянең Тампере шәһәрендә уздырырга чакырылган булганга, Тампереда 25 февральдә аның 40 еллык әдәби хезмәте башлануы мөнәсәбәте берлә бер кичә ясалачак, дип хәбәр бирделәр.

Идарәмез аркылы вә Гаяз әфәнденең үзенә килгән бик күп тәбрикләрнең бөтенесен, мәгаттәәссеф (үкенечкә күрә), мәҗмугамызда йирләшдерә алмыйбыз. Боның өчен күндерүче (җи-

бәрүче) оешма, Милли идарә, түгәрәкләр вә бик күп хосусый кешеләрнең барысының да гафуларын үтенеб, тәбрикләре өчен Гаяз әфәнде исемендән бик күп рәхмәтләр укыймыз.

***Идарәмезгә табшырылган тәбрик хатлары шулар:*** Ерак Шәрык мәркәзендән; Ерак Шәрык мәркәзе мәгариф шөгъбәсендән (бүлегеннән); «Милли байрак» идарәсендән; Харбин Милли идарәсендән; Харбин яшьләр түгәрәгендән; Мукден төрк-татар мәдәнияте җәмгыятенең яшьләр түгәрәгендән; Мукден хатын-кызлар оешмасындан; Кумамуту (Ерак Шәрыктагы шәһәр) Идел-Урал төрк-татар мәдәнияте җәмгыяте исемендән; Коби (Япониядәге шәһәр) милләтчеләре исемендән; Токио Идел-Урал мәдәнияте җәмгыятендән; Мукдендан Рокыя туташ Мөхәммәдишдән; Мукдендан Ибраһим Дәүләткилдедән (Болар «Милли байрак» гәзитен чыгаручылар. — *Х.М.*); Йукаһамадан (Япониядәге шәһәр) Габделнафигъ гаиләсендән; Нагоя Идел-Урал төрк-татар мәдәнияте җәмгыятендән; Варшаудан, шәркыятче (Шәрыкны өйрәнүче) ләһ гәнҗләре (поляк яшьләре) дәрнәге (оешмасы) Идел-Урал шөгъбәсендән.

***Телеграммлар:*** Фузан (Кореядәге Пусан шәһәре булса кирәк. — *Х.М.)* милләтчеләрендән; Ерак Шәрык мәркәзендән; Мукденда корылтай ачылуга ике ел булу сәбәпле тупланган мәҗлесдә хазир булучылар (катнашучылар) исемендән; Гирин төрк-татарлары исемендән; Шанхай мәхәлләсендән.

***Түбәндә бу тәбрик хатларының берничәсен басамыз:***

***Ерак Шәрыкта яшәүче Идел-Урал төрк-татар мөселманларының дини-милли мәркәзе башкармасы рәисемез Гаяз Исхакый җәнабларына!***

*Мөхтәрәм Гаяз әфәнде! Милләтемезнең яшь буынын милли рухда тәрбияләү вә милләтемезнең картрак гонсырлары (өлешләре, төркемнәре) арасында милләтемезнең тәрәкъкыйсе юлына киртә булып торган мөтәгассыйблыкларны (киртәләрне, артталыкны) алып ыргыту вә милләтемезнең истикъбален (киләчәген) яктырту, гаясын (теләген) үзегезнең милли вазыйфагыз диб белдегез вә шул максадыгызга ирешүгә дөньяның иң көчле коралы булган каләм, әдәбият аркылы арыган, талган, йөдәгән милләтемезгә әдиблек хезмәтегезгә бу ел кырык ел тулу мөнәсәбәте берлә мәркәз башкарма сезнең милләтемез өчен эшләгән бу әдәби хезмәтегезнең кырык еллык юбиләсен (юбилеен) җандан тәбрик итә. Шуның берлә бергә бу юбиләнең туган көнегезгә тугры килүе уңае берлә сезнең туган көнегезне дә тәбрик итеб, сезгә сәламәтлек вә максадымызга ирешүдә армый-талмый эшләргә бөек Тәңредән куәт тели. Киләсе алтын юбиләгезне мөстәкыйль илемез*

*Идел-Уралда уздырырга мөяссәр булуымызны (ирешүебезне) олуг Тәңредән ялварып сорый.*

*Мукден. 8 февраль, 1937.*
*Бөек хөрмәт вә ихтирам илә рәис өчен:*
*Әхмәдшаһ Гыйззәтулла.*
*Кятиб: Ибраһим Дәүләткилде.*

* * *

***Бөек әдимебез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабларына!***

*Хөрмәтле Гаяз әфәнде!*

*Рус истилясы (басып алуы) нәтиҗәсендә милли мәдәнияте юлында үсүдән туктаб калган милләтемезне озын йокысындан уяту эшенең зур адымлар белән алга китүенә сәбәпче булган әдәби хезмәтегезнең кырык еллык юбиләсе берлә тәбрик итү без — мәгариф эшчеләре өчен сөенечле бер вазыйфадыр.*

*Бөтен әдәби әсәрләрегез аша милләтемезне үсдерергә, барачак милли кыйбласын билгеләргә тырышуыгыз берлә сез илемезнең мәшһүр әдибләре арасында үзегезгә генә хас вә бик шәрәфле урын тотасыз. Үзегезнең кыйммәтле әсәрләрегез берлә милләтен сөйгәнләрнең күңелендә, әдәби ләззәтдән башка, милләт сәүгесе (сөюе) сызыкларын сызасыз. Сезнең әдәби әсәрләрегез садә теле, килешле җөмләләре, телемезнең матурлыгын, байлыгын көзгедә күрсәткәндәй тасвир иткәнгә, чит илдә яшьлегебезне әдәбиятымыз берлә таныштырганда, сезнең әдәби әсәрләрегез тәмәл (нигез) ташы урынын тотадыр вә яшьлегебезнең (яшьләребезнең) күңелен илемезгә вә аның тормышына баглыйдыр.*

*Милли кыйблабызны күрсәтү, дошман аягы астында табталган мөкатдәс милли байрагыбызны күтәрүдән башка, яшьлегебез өчен рухани азык хәзерләвегез, сезнең милләтебезгә иткән бөек хезмәтләрегезне тагы да йүксәлтәдер (күтәрәдер) вә милләтебезнең сәгадәте намына (исеменә, шөһрәтенә) иткән чиксез хезмәтләрегезгә бу кырык еллык әдәби хезмәтегезнең дә кушылуы яшь гонсырыбызның (буыныбызның) күңел күзендә сезнең хөрмәтегезне тагы да бөекләтәдер, сезне вә сезнең хезмәтләрегезне аларның рухани барлыкларның җанлы бер кисәге ясыйдыр.*

*Сез күрсәткән милли кыйблабызга яшь буынны җитәкләүче без, мәгариф эшчеләре, сезнең бу сөенечле бәйрәмегезгә кальбән (чын йөрәктән) кушылып, милләтебезнең сезнең кеби бөек шәхесен сәламли алу шәрәфенә ирешә алуыбыз берлә үзебезне бәхетле саныйбыз вә сезне 40 еллык юбиләгез вә туган көн бәйрәмегез берлә тәбрик итеб, киләсе 50 еллык юбиләгезне һәм күп туган көнләрегезне ис-*

*тикълялен (бәйсезлеген) кайтарыб алган үз илебездә каршы алуыгызны телибез.*

*Мукден. 8 февраль, 1937.*
*Бөек хөрмәт илә Мәркәз мәгариф шөгъбәсенең рәис урынбасары Рокыя Мөхәммәдиш.*
*Кятиб: Разия Дәүләткилде.*

* * *

***«Милли байрак» гәзитенең мәхсиссе (коручысы) мөхтәрәм Гаяз әфәнде Исхакый җәнаблары!***

*Хөрмәтле Гаяз әфәнде!*

*Милли үзлегебезне саклау юлында армый-талмый хезмәт итүегез нәтиҗәсендә мәйданга килеп, Ерак Шәрыкка сибелгән мөһаҗәрәтебезнең рухани азыгы дәрәҗәсенә ирешкән «Милли байрак» гәзитенең идарәсе сезне әдәби хезмәтегезнең кырык еллык бәйрәме берлә тәбрик итәдер вә шул юбилә көненә туры килә торган туган көнегез берлә котлыйдыр.*

*Каләм хезмәтенең орлыкларын вә истигъдадның (сәләтнең) кыйммәтен аңлаганга, сезнең бу сахәдәге (мәйдандагы) кырык еллык хезмәтегезне вә шул юлда күргән бөтен зәхмәт вә мәшәкатьләрне чын күңелдән тәкъдир итәдер. Сезгә вә сезнең хезмәтегезгә булган хөрмәтене күрсәтү йөзендән «Милли байрак» бер санына сезнең кырык еллык юбиләгезгә багышлаб чыгаруны карар итәдер. Бу озын дәвер эчендә милли матбугатымыз дөньясына чыккан әсәрләрегезнең бик азын гына кулда итә алганлыктан, сезнең бу аландагы хезмәтегезнең зурлыгын вә бу хезмәтнең биргән сәсәрәсен (җимешен, нәтиҗәсен. — Х.М.) тулы көенчә күрсәтә алмаячагына тәәссеф итәдер (үкенәдер. — Х.М.) вә сездән бу кимчелеге өчен гафу итүегезне үтенәдер.*

*Илемездән еракда бөек әдибе хөрмәтенә ясала торган зурлауның күңел теләгән кадәре зур вә бай булмавына сыкрап,сезнең әдәби хезмәтегезнең илле еллыгын вә милли истикъляллебез елында көрәшүегезнең тагы да бөегрәк юбиләсен мөстәкыйль илебез Идел-Уралда каршы алуны сорап, олуг Тәңрегә ялварадыр.*

*«Милли байрак» гәзите, Мукден.*
*Бөек ихтирам вә кардәшлек сәламе берлә «Милли Байрак» идарәсе.*
*Мөхәррире: Ибраһим Дәүләткилде.*
*Кятиб: Рокыя Мөхәммәдиш.*

* * *

*Бик мөхтәрәм вә кадерле Гаяз абзый!*

*Без, төрк-татар яшьләре, хәзерге көнне үзебезнең түгәрәкләребез, милли сәхнә вә милли көтебханәләребез ти-*

*рәсендә оешып, шулар аркылы халкыбызга мәхәббәт бәйләп, кулыбыздан килгәнчә эш күрсәтү вә милләтемез намына зуррак эшләр дә эшләргә талпынуыбыз берлә үзебезнең милли әдиб вә шагыйрьләремезгә бурычлы булсак, шулар җөмләсендән сезгә аерым рәвешдә зур бурычлыбыз. Чөнки сез, кадерле Гаяз абзый, безнең иң зур әдибемез. Без, сезнең исем вә хезмәтегезне ата-аналарыбыз, ага вә апаларыбыз авызындан ишетеп үскәнебез хәлдә, сезнең бөек хезмәтегезне хәзер үзебез дә күреп, аңлап, белеп торамыз.*

*Безнең барыбыз да диярлек сезнең бу якларга килеб чыккан вакытыгызда якындан күрү вә кыйммәтле сүзләрегезне ишетү бәхетенә дә ирешде. Шунлыкдан сезнең әдәби хезмәтләрегезгә 40 ел тулу бәйрәмендә сезнең тирәдә яшәүче милләтдәшләребез, сезнең берлә бергә янәшә утырып шадланышкан вакытда, без дә, җәгърафый араның ераклыгына карамасдан, сезне үз каршыбызда, гүя сез безнең янда булган кеби итеб күрәбез.*

*Киләчәкдә халкыбызга хезмәт итү уйлары берлә рухан (рухани яктан) канатланган бу яшьләр, әлбәттә, сезнең кеби җитәкчеләргә бик мохтаҗбыз. Безгә юл күрсәтеб, юл сызыб, дөрест вә тугры юлга димләб, шуңа өндәүче булмаса, без бер кыйблага таба бара алмас идек, яңлышыр идек, таралыр идек... Ходага шөкер, без бу якдан бәхетлеләрбез: бер Харбин яшьләренә генә түгел, мөһаҗәрәтдәге барлык яшьләребезгә исем вә хезмәтегез берлә рух биреб торучыны без сезнең кыйммәтле шәхесегездә күреб торабыз. Котлы булсын олуг бәйрәмегез!*

*Бу көндә сезгә нинди генә мәдхияләр укылса да, аздыр. Сез, кадерле Гаяз абзый, үзегезнең зур эшләрегез берлә милләтнең вә аның балаларының самими ихтирамын, мәхәббәтен бик хаклы рәвешдә казандыгыз. Яшәгез! Яшәсен Идел-Урал төрк-татар халкының милли әдәбияты!*

*Харбин. Февраль, 1937*
*Олуг ихтирам берлә Харбин төрк-татар яшьләре түгәрәге намына мувәкъкать (вакытлы) рәис: Галимҗан Таһир.*
*Кятиб: Халидә Әхмәди.*

* * *

***Бөек әдибемез Гаяз әфәнде Исхакый җәнабларына!***

*Хөрмәтле Гаяз әфәнде!*

*Без, Мукден Идел-Урал төрк-татар мәдәнияте җәмгыяте янындагы Хатын-кызлар оешмасы, әдәби хезмәтегезнең кырык еллык юбиләсе вә шул көнгә туры килә торган*

*туган көнегез берлә чын күңелемездән сөенеб вә бөтен йөрәгебездән сезне хөрмәт итеб тәбрик итәбез.*

*Без — хатын-кызлар өчен төрк-татар хатын-кызына хөрмәтле вә шәрәфле урын биргән әдибнең язучылыгының тарихи бәйрәме безнең зур шадлыклы бәйрәмебездер.*

*Сез «Кәләпүшче кыз», «Теләнче кызы» берлә төрк-татар хатын-кызының табталган намусын пычракдан тазарттыгыз, аның йөрәгенең сафлыгын, үзенең эшлеклелеген, булдыклылыгын күрсәттегез. «Мөгаллимә»гез, «Остазбикә» вә «Зөләйха»ларыгыз берлә төрк-татар хатын-кызының каһарманлыгын, фидакарьлеген җанландырып, аның хөрмәтен күрсәтдегез. Бөтен әсәрләрегездә төрк-татар хатын-кызын олуглау пәрдәсе аркылы күрсәтеб, төрк-татар хатын-кызының йөрәгендә үзегезгә тирән ихтирам уятдыгыз.*

*Дошман аягы астында табталган байрагыбызны күтәрүдә без хатын-кызларга да тигез хокук биреб, безне дә дини, милли үзлегебезне саклау көрәшебезнең җанлы әгъзалары итүегез берлә хатын-кызларның йөрәгендә тирән тәшәккер (рәхмәт) тудырдыгыз.*

*Бөтен хезмәтләрегез эчендә хатын-кызларга хөрмәтле урын бирүегез вә рухани азык бүләк итүегез өчен бу олуг бәйрәмегез көнендә хатын-кызлар исемендән самими тәшәккерләремезне гарыз итәмез (белдерәбез) вә киләчәк илле еллык юбиләгезне вә күп туган көнләрегезне хөр илебездә каршы алуыгызны телибез.*

*9 февраль, Мукден.*
*Олуг хөрмәт илә Мукден Хатын-кызлар оешмасы.*
*Рәис: Рокыя Мөхәммәдиш.*
*Кятиб: Сара Нияз.*
*Идарә әгъзалары: Мәрьям Мөдә(рр)ис, Рәкыйбә Явыш, Зәһидә Гыйззәтулла, Разия Дәүләткилде.*

* * *

*Финляндиядән телеграмм: «25 февральдә Гаяз әфәндене̣ң әдәби эшләренә кырык ел тулу мөнәсәбәт илә Тампере төрк-татарлары тарафындан банкет бирелде. Сәгать 8 дә башланган бу банкет зур бер милли бәйрәм төсендә икегә кадәр дәвам итте. Мортаза».*

## Ул татар булып калды

1993 елның 22 февралендә «Казан» милли мәдәни үзәгендә Г.Исхакыйның тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды. Киң җәмәгатьчелек вәкилләре һәм Татарстан-

ның дәүләт эшлеклеләре (Ф.Мөхәммәтшин, И.Хәйруллин, М.Таишев һ.б.) катнашкан бу чарада фән докторлары М.Хәсәнов, И.Таһиров, М.Зәкиев, И.Нуруллин, Ф.Мусин, Р.Ганиева доклад белән чыктылар. Без фәкыйрегез дә ул конференциядә Г.Исхакыйның 30 нчы еллардагы публицистик эшчәнлеге темасына доклад ясады. (Аның төп өлеше «Шәһри Казан» гәзитендә басылып та чыкты. — 17.04.1993.) Чыгыш «Яңа милли юл» журналы турында иде. Әмма бу китапта журнал хакында «Азатлык көрәшенең мөнбәре» дигән махсус мәкалә бар. Шуңа күрә без биредә конференциядәге докладыбызның «Яңа милли юл» турындагы өлешен кыскартып бирәбез.

* * *

Татар кавеме — элек-электән талантларга бай халык. Әмма шунысы аянычлы: бу сәләт ияләренең шактые инде менә 4–5 гасыр буена, милли-колониаль изелү, сәяси хокуксызлык аркасында башка милләтләргә хезмәт итә. Без еш кына урысның, төрекнең, казахның яисә үзбәкнең фәлән атаклы кешесе чыгышы белән татар булган дип мактаныргa, горурланырга яратабыз. Әмма, ныклабрак уйлап караганда, мондый күренеш — милләтебезнең фаҗигасе. Безнең халык, саксыз хуҗа кебек, үз байлыгын тегендә дә, монда да тараткан, ә үзе, тупас булса да әйтим, еш кына ыштансыз да калган. Әгәр дә Карамзин, Куприн, Рахманинов, Рәшит Рәхмәти Арат, Айзек Азимов, Роальд Сәгъдиев, Рудольф Нуриев, Мостай Кәрим, Ирек Мөхәммәдов, Гата Камский кебек йөзәрләгән татар канлы талантлар руска, төреккә, Америкага, башкортка, французга, инглизгә түгел, үзебезнең халыкка хезмәт итсә, безнең милләт никадәр үскән, баеган, шөһрәт казанган булыр иде.

Шушы айларда гына бөтен дөнья сәнгате зур югалту кичерде: атаклы балетмейстер Рудольф Нуриев, борынгылар әйтмешли, вакытлы (фани) йорттан мәңгелек (бакый) йортка күчеп китте. Авыр туфрагы җиңел булсын. Мәрхүм хакында тәнкыйди фикер әйтү әхлакый яктан, әлбәттә, кыен эш. Шулай да үземне борчыган бер мәсьәлә турында әйтмичә үтә алмыйм. Рудольф Нуриев, татарча сөйләшә белмәсә дә, татар кешесе иде бит. Узган ел ул Казанда да булып китте, безнең хәлне дә, теләкомтылышларны да күрде. Әмма, күрәсең, аның күңелендә татар җаны кабынып китмәгән. Васыяте нигезендә аны рус зиярaтына күмәләр; иксез-чиксез байлыгыннан бернинди матди мохтаҗлык кичермәгән Көнбатыш Европа, Америка сәнгатьләренә зур өлеш чыгарып та, авызын ачса, үпкәсе күренеп торган татар сәнгатен читтә калдыруы бик үкенечле һәм уйландырырлык хәл.

Үз халкыннан, үз Ватаныннан теге яки бу сәбәпләр белән аерылган, әмма аңа тугрылыклы калган, хезмәт иткән, аның тәрәккъыяте өчен армый-талмый көрәшкән татар зыялылары, татар талантлары бик аз. Шуларның иң күренеклесе һәм иң могтәбәре, әлбәттә, Г.Исхакый. Ул иң авыр вакытларда да милләтеннән баш тартмады: татар булып туды, татар булып яшәде, татар булып теге дөньяга китте.

Мәгълүм булганча, икенче бөтендөнья сугышыннан соң читтәге татарларның күпчелеге гаять кыен хәлгә төшә: Кытайда, Кореяда, Польшада, Болгариядә, Румыниядә яшәүче милләттәшләребезнең бер өлеше Мәскәү һәм аңа буйсынучы илләрнең хакимият органнары тарафыннан кулга алына йә юк ителә, яисә төрмәләргә утыртыла, Колымаларга сөрелә. Икенче бер өлеше Төркиягә, АКШ-ка, Көнбатыш Германиягә, Канадага һәм кайбер башка илләргә качып яисә күчеп китәргә мәҗбүр була, Төркия, Алмания, Америка кешесенә әверелә. Г.Исхакыйның Идел-Урал җөмһүрияте, татар иреге өчен көрәшүче сафташлары арасында пессимизм, төшенкелек көчәя, үз юлбашчыларына шелтә белдерүчеләр, аны ташлап, башка милләткә хезмәткә күчүчеләр арта. Президент, илбаш булырдай кеше, гаскәрсез калган генералдай, ялгыз кала.

Финляндиядә яшәгән бер милләттәшебез миңа шушындый бер эпизодны сөйләгән иде: «40 нчы еллар азагында — 50 нче еллар башында Төркиягә барган идем, — диде ул. — Шунда Гаяз ага белән очраштык. Аның матди яктан авыр хәлдә икәнлеген күрдем. Олуг әдипнең мондый хәлдә калуы мине гаҗәпләндерде. Шунда ул, эчке сизгерлек белән минем уйларымны белгәндәй, болай диде: «Безнең шактый кешеләр төрек булып китте, хәзер әйбәт торалар. Хәтта үз кызым да инде мине: «Ни дип татарга шулкадәр ябышып ятасың», — дип шелтәли. Татар булуы авыр. Әмма мин татар булдым һәм теләсә нинди шартларда да татар булып калырмын», — дип төгәлләде үз сүзен Гаяз ага».

Татар тарихында олуг язучылар, олуг җәмәгать эшлеклеләре, олуг сәясиләр, олуг галимнәр һәм журналистлар күп. Әмма аларның күпчелегендә олуг булган һәм бу һөнәрләрне бер шәхескә туплаган талант ияләре тарихыбызда бик күзгә ташланмый. Г.Исхакый — бу яктан да милләтебез яшәешендәге уникаль, ягъни сирәк очрый торган күренеш. Шунысы үзенчәлекле: аның эш-гамәлләрендә әдәби иҗат, сәяси һәм иҗтимагый як, оештыру эшчәнлеге, публицистика һәм фән шулкадәр табигый керешкәннәр ки, аларны бер-берсеннән бары шартлы рәвештә генә аерырга мөмкин. Г.Исхакыйның искиткеч талантлы табигате, ихтыяр көче, укымышлылыгы һәм барыннан да элек үз халкы өчен янып-көюе аның күпкырлы эшчәнлегенә бөтенлек, эчке бердәмлек бирә.

Г.Исхакый — «Тәрҗеман»ны исәпкә алмаганда, татар матбугатына нигез салучыларның, аның үсешенә зур өлеш кертүчеләрнең берсе. Ул «Учительская школа»да укыган елларда (1898–1902) ук «Тәрәкъкый» исемле яшерен гәзит чыгаруда актив катнаша. 1906 елда «Таң йолдызы»н нәшер кылуга керешә. Эмиграциягә кадәр Г.Исхакый Казан, Питер, Мәскәү кебек калаларда дөнья күргән «Тавыш», «Ил», «Сүз», «Ил сүзе» һәм кайбер башка гәзит-журналларны чыгаруда баш мөхәррир, автор буларак төп авырлыкны үзе күтәрә. Аның бу еллардагы ялкынлы публицистик сүзе татарның үзаңын иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни дәрәҗәсен үстерүдә, халыкны милли-азатлык көрәшенә туплауда гаҗәеп зур роль уйнады.

Менә Г.Исхакый мөһаҗәрәттә, ягъни эмиграциядә: Харбин, Япония, Париж, Берлин, Төркия, Варшава... Нишләргә? Саф әдәби иҗат, фәнни эш белән генә шөгыльләнергәме? Әмма Г.Исхакый табигате белән андый кеше түгел. Аңа матбугат кирәк. Чөнки инде ул гәзит-журналның иҗтимагый-сәяси тормышта нинди зур роль уйнавын үзенең күпьеллык журналистлык эшчәнлегендә күргән, кичергән кеше. Чит илләрдә бу эшкә ничек керешергә? Ул Ерак Шәрыктагы татарча гәзит-журналларда да, төрек матбугатында, җөмләдән күпчелек авторлары татар булган «Төрек йорды» мәҗмугасында да, эмиграциядәге рус басмаларында, «Яңа Кафкасия», «Азәри Шәрык» кебек журналларда да язышa. (Шунысын да әйтик: Г.Исхакыйның 20 нче елларда дөнья күргән кайбер мәкаләләре Галимҗан Ибраһимовның да игътибарын үзенә җәлеп итә. Аның 1924 елда чыккан «Кара маяклар яки ак әдәбият» исемле хезмәтендә шул хакта сүз бара. Әмма кызганыч ки, Галимҗан Ибраһимов үзенең элекке остазын, каләмдәш дустын бары кара яктан гына яктырта. Күрәсең, чор, вазгыять шуңа мәҗбүр иткәндер.)

Әмма Г.Исхакыйны башкалар чыгара торган төрле мәсләкле гәзит-журналлар гына канәгатьләндерми: аңа үзенең уй-фикерләрен, теләк-омтылышларын тулырак, эзлеклерәк чагылдырырлык, милләттәшләрен Октябрь хәл итмәгән мәсьәләләргә тупларлык үз басмасы кирәк. Олуг әдип шундый гәзит яисә журналны оештыру өчен комга атылган балык кебек чын мәгънәсендә бәргәләнә: төрек һәм кайбер башка мәмләкәтләрнең рәсми хакимиятләренә дә, читтәге милләттәшләребезгә дә кат-кат мөрәҗәгать итеп карый. Әмма эш вәгъдәдән, коры сүздән ары узмый. Г.Исхакый эшне икенче яктан башларга мәҗбүр була. Аның инициативасы белән 1928 елда Варшавада төрк-татар милли-азатлык көчләренең корылтае була һәм анда гәзит-журналлар чыгару бурычы бөтен кискенлеге белән куела. Бер төркем милләттәшләренең матди һәм рухи ярдәме белән Г.Исхакый үзе «Милли юл» мәҗ-

мугасын чыгаруга керешә. Аның тәүге саны 1928 елның 23 декабрендә, ә икенчесе 1929 елның 15 гыйнварында дөнья күрә. Журнал 1930 елга кадәр айга ике мәртәбә «Милли юл» исеме белән чыга, ә инде алга таба ул «Яңа милли юл» атамасын ала һәм, кагыйдә буларак, айлык мәҗмугага әверелә. 11 еллап вакыт эчендә журналның барлыгы 136 саны дөнья күрә, шуның берничәсе — куш саннар. Текстлар — гарәп графикасында...

Г.Исхакыйның 30 нчы еллардагы публицистик эшчәнлеге, әлбәттә, «Яңа милли юл» белән генә чикләнми. Аның күпсанлы мәкаләләре чит илләрдә, аеруча Кытайда чыккан газит-журналларда бар. Төрек, читтәге кырымтатар, төркестан, азәрбайҗан, рус, инглиз, немец, поляк, француз, гарәп телләрендәге матбугатта да әдипнең чыгышлары, аның хакында мәгълүматлар булуын әйтәләр. Әмма, кызганыч ки, әле аларның күпчелеген табу безнең өчен гаять кыен эш. Моның өчен чит илләргә бару, хәзергә кадәр яшерен фондларда эшләү зарури.

Дәрдемәндтә мондый юллар бар:

Ил — мөмтаз (гакыллы. — *Х.М.*), аңлау ул тиз,
Син аны сизмәс димә!
Илдә бер дуст булмаса гәр,
Ил бөтен — дошман түгел!

Г.Исхакый бу хакыйкатьне яхшы аңлаган. Аны күпме генә каралтырга, халыкка дошман итеп күрсәтергә тырышсалар да, олуг әдип Идел-йортка хыянәт итмәгән, туган халкына тугрылыклы калган, асыл Ватанын сагынып, милләтенең киләчәге өчен янып-көеп яшәгән.

Һавадагы киек каздан
«Син кайдан?» дип сорадым.
Каз кычкырып җавап бирде, —
Мин утырып еладым.

Төркиләрнең даһи шагыйре Йосыф Баласагунлы үзенең «Котадгу белег»ендә болай ди (тәрҗемәдә):

Сөйгән кешеңнең йөзе үк ишарә булу,
Телен тибрәтсә, сүзенең мәгънәсе ишарә бирер.
Сөя микән, юк микән, димсең икән,
Сиңа бер тутырып караса, күзе ишарә бирер.

Шуның кебек үк Г.Исхакый китергән җыр да әдип күңеленең ниндилеген, халәте рухиясен ачык күрсәтә. Анда исә никадәр сагыш, никадәр фаҗига!

***Олуг әдипкә мөнәсәбәтле берничә тәкъдимем бар:***

1. Г.Исхакыйның барлык язганнарын туплап, тиешле аңлатма-шәрехләр белән укучыларга мөмкин кадәр тизрәк, тулырак җиткерү шарт.

2. Әдипнең иҗат мирасын гыйльми, комплекслы өйрәнү эшен активлаштыру сорала. Дөньяда Г.Исхакыйны күргән, белгән кешеләр көннән-көн азаеп бара. Алардан әдип хакында истәлекләр яздырып яисә сөйләтеп алу — кичектергесез бурыч. Гомумән, Г.Исхакый хакында истәлекләр китабы чыгару шарт.

3. Әдипне хәзер күпчелек кеше белми. Шуны күздә тотып мәктәпләрдә, уку йортларында аның эшчәнлеген һәм иҗат мирасын ныграк өйрәнү — бүгенге көннең зарури таләбе.

4. Г.Исхакыйның үзенә, әсәрләренә мөнәсәбәтле фильмнар эшләү.

5. Олуг әдип — татар милләтенә иң күп хезмәт итүчеләрнең берсе. Бәлкем, Милли китапханәгә аның исемен бирү кирәктер?! Уфада әнә Үзәк китапханәләренә Зәки Вәлиди исемен бирделәр бит!

6. Казанда Г.Исхакый музее ачу, башкалабызның үзәк урамнарыннан берсен аның исеме белән атау.

7. Минем уемча, Казан шәһәренең үзәк өлешендә Г.Исхакыйның мәһабәт һәйкәле булырга тиеш. Ул моңа лаек зат һ.б.

Г.Исхакый — халкыбызның мәдәниятен үстерүгә, үзаңын күтәрүгә, милли-азатлык көрәшенә туплауга үзеннән искиткеч зур өлеш керткән кеше. Без аның алдында гаять бурычлы. Шуңа күрә минем тәкъдимнәр ул бурычларны кайтаруның тик бер өлеше генә итеп кабул ителергә тиеш.

## Янә Сания Гыйффәт хакында

Узган елгы (1991) «Сөембикә» журналының февраль, «Шәһри Казан» гәзитенең 4 апрель саннарында инкыйлабтан соң эмиграциягә киткән Сания Гыйффәт (1899–1957) турында безнең кечерәк кенә мәкаләләр басылган иде. Шул ук саннарда без шагыйрәнең берничә әсәрен дә укучыларга җиткергән идек. Күрәсең, бу материаллар укучыларда, аеруча Финляндиядәге һәм Төркиядәге милләттәшләребез арасында кызыксыну тудырган. Редакциягә, мәкаләләр авторына хатлар килү, үтенечләр белән мөрәҗәгать итү нәкъ әнә шуңа ишарә ясый. Аларда Сания Гыйффәтнең башка әсәрләре белән танышырга теләк белдерелә, шагыйрәнең ире — Закир Кадыйри (1877–1955) белән дә ныклап кызыксыну сизелә.

«...Хәзергә кадәр безгә, — дип яза Әхәт әфәнде Хәкимов, — Закир Кадыйриның язмышы билгесез иде. Ул безнең авылдаш. Ул хәзерге Ульяновск өлкәсенең Чердаклы районы Аб-

дулла авылында Хәлим мулла гаиләсендә туа. Аның бертуган энесе — Кадыйров Мәннан хәзерге вакытта Ашхабад университетында профессор булып эшли». Чирмешен районының Иске Кади авылында яшәүче Җәүдәт әфәнде Сәйфиев әнисенең Закир Кадыйри сеңлесе булуын искәртә, абзасы хакында тагын да мәгълүматлар бирүне үтенә.

Бу мәкалә язылып беткән көннәрдә, Бөтендөнья татар конгрессында катнашу өчен ерак Ашхабадтан Габделмәннан ага Кадыйров үзе дә Казанга килеп төшә. 82 яшьтә булуына карамастан, җыйнак кына гәүдәле бу олы кеше гаять кызыксынучан, хәрәкәтчән булып чыкты. (Күз тимәсен үзенә!) «Сөембикә» редакциясендә дә булды, туган-тумачаларын да эзләп тапты, минем белән дә берничә мәртәбә очрашты. Сөйләшүләр вакытында ул үзе, туганнары хакында кайбер кызыклы мәгълүматлар бирде.

Габделмәннан ага 1910 елгы. Сигез туганның җиденчесе (хәзер ул гына исән) Закир белән Габделмәннан агаларның әниләре башка. Әтиләре — Мөхәммәтхәлим мулла — гаять укымышлы, дәрәҗәле кеше була. 20—30 нчы елларда эзәрлекләнә, төрмәдә дә утырып ала, өеннән мәхрүм ителә, гаять бай китапханәсен, шул исәптән улы Закирның китапларын да яндырып, юкка чыгаралар. Мөхәммәтхәлим ага олы яшькә җиткәч, күп кыенлыклар күреп, 1952 елда Абдулла авылында вафат була.

Габделмәннан ага Мәләкәстәге татар мәктәбендә укыганда, мулла баласы дип, уку йортыннан чыгарыла. 1929 елда Бакуга Әфтәбруй апасы янына китәргә мәҗбүр була. Биредә укый, эшли. Читтән торып Ленинград университетының астрофизика бүлегендә укый. 1937 елда, көчле репрессияләр башлангач, Төрекмәнстанга күчеп китә. Ашхабад пединститутының физика-математика факультетын тәмамлый. 1987 елга, ягъни пенсиягә чыкканчыга кадәр, Төрекмәнстан Фәннәр академиясенең астрофизика лабораториясендә, Ашхабад педагогия институтында, университетта эшли. Профессор вазыйфаларын да башкара.

Габделмәннан ага күренекле тюрколог, профессор, милләттәшебез Әхмәд Тимер чакыруы буенча 1991 елда Анкарада булуын да сөйләде. Әхмәд Тимернең беренче хатыны (Азат) — Сания Гыйффәт һәм Закир Кадыйриның өлкән кызлары (ул инде күптәннән вафат).

Габделмәннан ага биргән мәгълүматлар, нигездә, менә шулардан гыйбарәт. Ул кечкенә вакытта гына Закир абыйсын күргән. Соңгы елларга кадәр аның язмышын, эшчәнлеген бөтенләй диярлек белмичә яшәгән.

Закир Кадыйри — татар халкының мәгариф, фән, иҗтимагый хәрәкәт тарихында билгеле зат. Заманында ул Бохара, Мәдинә, Каһирә уку йортларында белем алган. Гаять укымышлы, берничә телне белүе мәгълүм. 1906 елда Россиягә кайта. Петербургта Рәшит Ибраһим тарафыннан гарәпчә нәшер ителүче «Әт-тилмиз» («Шәкерд») журналында эшли. Аннан Оренбургтагы «Хөсәения» һәм Уфадагы «Галия» мәдрәсәләренең атаклы мөдәррисе. 1917 елгы Бөтенроссия мөселман төрк-татар корылтайларын оештыруда актив катнаша. Милләт мәҗлесенә, мәгариф нәзарәтенә әгъза итеп сайлана. Уфада чыга торган «Тормыш» гәзитенең мөхәррире дә була. Әмма гражданнар сугышы елларында, Мәскәү хакимияте белән каршылыкка кереп, эмиграциягә китәргә мәҗбүр була. Аның Кытайда, Финляндиядә, Төркиядә һәм кайбер башка мәмләкәтләрдә яшәве мәгълүм. Кабере — Анкарада. Эмиграциядә вакытта Закир Кадыйри, нигездә, педагогик, гыйльми эшләр белән шөгыльләнә. Гаяз Исхакый белән инкыйлабка кадәр генә түгел, аннан соң да аралашып, хәбәрләшеп тора.

Закир Кадыйри — илдә һәм чит мәмләкәтләрдә басылган күпсанлы мәкаләләрнең, китапларның авторы. Мәсәлән, Казан университеты китапханәсендә аның «Гарәп нәхүе», «Куәт һәм рух», «Мәмләкәт идарәсе рәвешләре», «Гаилә» китапханәсе сериясендә чыккан «Кызлар дөньясы», «Хатын-кыз мәсьәләсе» һ.б. китаплары бар. Закир Кадыйриның 30 нчы елларда Финляндиядә дөнья күргән төрк-татар тарихы дәреслекләре читтәге милләттәшләребезнең шактыена хәзер дә мәгълүм. Кыскасы, бу зат, аның эшчәнлеге, хезмәтләре махсус һәм җентекле өйрәнүгә мохтаҗ.

Әйткәнебезчә, күпчелек укучылар Сания Гыйффәтнең башка әсәрләрен дә укырга тели. Шуны күздә тотып, без аның ике язмасын тәкъдим итәбез. Алар Берлинда 1929—1939 елларда нәшер кылынган «Яңа милли юл» журналында басылган.

Сания Гыйффәтнең «20 ел элек ил» шигыре дә, Гаяз Исхакый хакындагы мәкаләсе дә истәлекле вакыйгаларга мөнәсәбәттә туган.

Мәгълүм булганча, 1938 елның гыйнвар һәм февраль айларында Милләт мәҗлесенең 20 еллыгы чит мәмләкәтләрдә, җөмләдән Кытайда, Япониядә, Төркиядә, Финляндиядә, Алманиядә, Эстониядә зур күләмдә билгеләп үтелә. Тантаналарның үзәге Гаяз Исхакый яшәгән Варшава каласында була. Биредә 4—6 февраль көннәрне, чит илләрдәге милләттәшләребез һәм төрле милли-азатлык хәрәкәте вәкилләре катнашында, төрле чараларның уздырылуы мәгълүм. 6 февраль көнне Гаяз Исхакый Варшава радиосыннан чыгыш ясый.

1936–1944 елларда Сания Гыйффәт Һельсинкида яши, педагогик эш, әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Инкыйлаб чорында төзелгән Милләт мәҗлесенең үзәгендә кайнаган Закир Кадыйри һәм Сания Гыйффәт 20 еллык юбилей уңае белән күптөрле чаралар оештыралар. «20 ел элек ил» шигыре дә нәкъ менә шул шартларда туган. Анда Милләт мәҗлесе төзелгән көннәрнең күтәренке рухы, гомуми атмосферасы шактый тулы гәүдәләнә.

1897 елда Гаяз Исхакый «Тәгаллемдә сәгадәт...» исемле хикәясен яза һәм шартлы рәвештә шушы елны үзенең иҗат башлангычы итеп кабул итә. Шуңа мөнәсәбәттә 1937 ел читтәге татарлар тарафыннан Гаяз Исхакый эшчәнлегенең 40 еллыгы рәвешендә бәйрәм ителә. Юбилей кичәләренең Харбинда, Мукденда, Токиода, Истанбулда, Берлинда, Таллиннда һәм башка күп төбәкләрдә уздырылуы мәгълүм (әмма СССРда — юк). Тантаналарның үзәге янә Варшавада була. 20–30 нчы елларда Гаяз Исхакый Польшаның Шәрык институты белән хезмәттәшлек итә. Шуңа күрә 1937 елның 5 мартында Шәрык институтында рәсми рәвештә Гаяз Исхакыйның юбилее үткәрелә. Анда институт профессорлары Польшаның дәүләт эшлеклеләре, чит илләрдәге милләттәшләребез, Кырым, Төркестан, Украина, Кавказ һәм башка халыкларның милли-азатлык вәкилләре катнаша. Бу истәлекле вакыйганы дөнья матбугаты да яктырта. Чыгышларда Гаяз Исхакыйның бөек әдип икәнлегенә, дөньякүләм танылган лидер, төрк-татар милли азатлык хәрәкәтенең юлбашчысы булуына басым ясала, аның иҗтимагый, сәяси һәм әдәби эшчәнлегенә гаять югары бәя бирелә.

Юбилей тантаналары аеруча Финляндиядә зур күтәренкелек белән уза. Аларда Гаяз Исхакый үзе дә катнаша.

Гаяз Исхакыйның 40 еллык иҗат бәйрәмен оештыруда Сания Гыйффәт башлап йөрүчеләрдән була: нотыклар сөйли, балалар белән кичәләр үткәрә, шигырьләр иҗат итә. Мәкалә дә шушы вакыйгаларга мөнәсәбәттә языла.

Сания Гыйффәтнең Гаяз Исхакый хакындагы язмасы берничә яктан игътибарга лаек. Беренчедән, ул әдипне, аның иҗатын яхшы белгән талантлы каләмдәше, күренекле педагог тарафыннан язылган. Икенчедән, мәкаләдә әдип иҗаты тарихи контекстта, иҗтимагый вакыйгалар, авторның шәхесе белән тыгыз бәйләнештә карала. Өченчедән, автор Гаяз Исхакый иҗатының аерым үзенчәлекләрен (фикри якның үзәктә торуы, заманчалык, тәнкыйди башлангычының көчле булуы һ.б.), әдәбият һәм, гомумән, татар тормышындагы урынын билгеләргә омтыла.

Шунысын да әйтик: Сания Гыйффәтнең аерым фикерләре бәхәсле, берьяклы. Мәсәлән, ул татар әдәбиятында госманлы, ныгыта (иске үзбәк) тәэсирләрен күпертә. Чынлыкта исә «тәэсир» дигәннәренең күбесе — безнең үз әдәбиятыбызның урта гасырлардан ук килә торган традицияләре.

Сания Гыйффәт Гаяз Исхакый иҗатының үлемсез, халык белән бергә яши торган күренеш булуын искәртә. «Ул, — ди мәкалә авторы, — халыкның сулый торган һавасы вә эчке тормышының азыгы булып тора. Шуңа күрә халык аны бер дә онытмаячак вә аңар мәңге бурычлы калачак...»

*1992*

**Гаяз әфәнденең әдәби хезмәтенә 40 ел тулу мөнәсәбәте берлә.**

*(Бераз кыскартып бирелә.)*

*Сания Гыйффәт*

Егерменче йөзнең 17 нче елы безнең күз ачу, өмид, уяну, алга китү, чын мәгънәсе белән үземезне тану чагыбыз булып беркетелә. Шулай ук яңа әдәбиятыбызның туып үсә башлавы да егерменче йөзнең башларында була.

Шиһабеддин Мәрҗани белән башланган телебездәге яңалык Каюм Насыйрида көчәя, Гаяз Исхакыйда өр-яңа бер төс ала.

Каюм Насыйридан соң әдәбият өч тармакка аерылып китә: 1) Госманлы тәэсирендә язучылар булып Муса Акъегет, Заһир Биги, Галимҗан әл-Баруди вә кыйсмән (өлешчә) Риза казый вә әлегәчә дәвам итеп килмәкдә булган муллалар язу ягыннан бу юлда йөриләр; 2) Чагатай әдәбияты тәэсирендә язучылар булып бу юлдан йөрүчеләр: Дәрдемәнд, Галиәсгар Чагатай вә башкалар...; 3) Идел буе Казан төрекчәсен (төркичәсен) нигез итүчеләр: Каюм Насыйри, Гаяз Исхакый вә башкалардыр.

Гаяз Исхакыйның язучылыкда ике йөзе бар: берсе сәяси, икенчесе әдәби. Мин монда аның әдәби йөзе тугрысында гына берничә сүз язмакчы булам.

Берничә сүз генә дим, чөнки аның, Гаяз Исхакыйның, бу юлдагы эше ул хәдле тулы, ул хәдле күп вә бу юл өстендә йөреше ул хәдле озын ки, аны берничә сүз яки берничә бит язу белән генә сөйләп вә аңлатып бетерерлек түгел. Ул яңа әдәбиятыбызның элек атасы булмаса да, һәрхәлдә, бу әдәбиятны тудыручылар белән бер рәттә вә аталык урынындадыр.

Аның бер-ике китабын аерып алган чакда, калганнары ба-

рысы да саф Идел буе Казан төркчәсе белән язылганлыгын күрәбез.

Ул әсәрләрен тик бер әдәбият, коры матурлык тудыру гыйшкы белән генә язамы, ул әдәбият матурлык тудырудан бигрәк фикер тудыра: әсәрләрен бер исляхатчылык (үзгәртү, камилләштерү) нигезендә барлыкка китерә; бер фикерне эшкә ашыру, бер яңлыш адымны төзәтүне күздә тотып кына яза; матурлык-сәнгатьне ул икенче урында йөретә.

Әнә аның 1899 елда басылган әсәре — «Тәгаллемдә сәгадәт...» («Белем алуда — бәхет»). Монда аның халкының наданлыгына эче пошканлыгы вә аңар уку-гыйлем дәрте бирүне ният итеп язганлыгы күренә.

Мондан соң яшь язучының үткен күзенә, эшлекле миенә халкының җитешсезлекләре-авырулары берәм-берәм чагылалар; ул аларны фотограф машинасы төсле элек үзенә мал итә, андан соң эчдән туган җанлы омтылышлар белән каләм очыннан кәгазьгә түгә башлый. «Кәләпүшче кыз», «Бай углы», «Өч хатын белән тормыш», «Теләнче кызы», «Алдым-бирдем», «Ике йөз елдан соң инкыйраз» вә башкаларын ул шулай итеп барлыкка китерә. Аның 40 ел эчендә вә әдәби юлда язган 40 дан артык әсәре — барысы да тел ягындан ни хәдле җанлы вә бай булсалар, кирәк театру драма мәгънәсендә вә кирәксә роман вә хикәяләренең каһарманлары да ул хәдле чын вә теремдер.

Ул мәүзугъларын (темаларын, сюжетларын) вә каһарманлыкларын Идел буеның үз халкыннан вә тормышыннан ала. Боларны укыган вә караган чакда син чит бернәрсә күрмисең вә таймыйсың; анда ирексезләнеп эшләнергә тырышылган ясалма бернәрсә белән очрашмыйсың. Алар бар да җанлы, бар да тормышдан алынган нәрсәләр генә.

Ул «Кәләпүшче кыз», «Бай углы» исемле хикәяләре, «Теләнче кызы» исемле романы, «Өч хатын берлә тормыш» атлы театру китабы белән Казан сәүдәгәре әхлакының бозык якларын вә түбән сыйныф — ярлы, яклаучысы булмаганнарның кызганыч хәлләрен күрсәтә; монда ул гавам хатын-кызларының җан ягыннан булган хәлләрен иң нечкә катлауларына хәдле ачып күрсәтә. Ул бигрәк дә шәкердләр тасвирында (шәкертләрне тасвирлауда), мәдрәсә гамәлен җанландыруда, муллалар тормышын вә эч йөзен күрсәтүдә искиткеч җанлы теле вә тулы күрсәтүе белән, әйтергә була, кешене хәйран итә. «Тормышмы бу?» атлы әсәрендә бик озын, еллар буенча сузылган мәдрәсә тормышының мәгънәсезлеген, бушлыгын бик оста итеп җанландыра. «Мулла бабай» исемле романында дини мәдрәсәләребез тарихы күренә. «Кыямәт», «Җәмгыять» исемле комедия-

ләрендә ул иске йолалар, черек ышанулардан көлә. Иҗтимагый тормышның көлке якларын мыскыллый, «Мөгаллим» атлы драмында бер идеалны вә ул идеалның аңлашылмау вә эшкә аша алмавыннан туган ачыны күрсәтә вә аны ул хәдле җанландыра ки, аны карауче ул изтыйрабны (газаплануны), ачыны кулы белән тотып атасы килә.

Гаяз Исхакыйның «Алдым-бирдем» белән «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле әсәрләре безнең милли тормышыбызны, әйтергә ярый, астын өскә китерә. «Алдым-бирдем» ирләрнең тәгассыбен (фанатизмын), хатынларга каршы булган золымын, 20 нче гасыр хатынына хакларыннан файдалана белүнең тиешлеген вә файдалануын тасвир итә. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле китабы халкыбызның өч йөз еллык хәлен сөйли. Аның әйтүенә караганда, әгәр халкыбыз 19 нчы йөздәге наданлык вә кирелекләренең бетүенә тырышмасалар вә әхлакларын төзәтергә җилтенмәсәләр (җилкенмәсәләр), 21 нче йөзнең соңында бөтенләй бетәчәкләр. Вә аларның тик хәрабәләре генә калачак була. Аның башка әсәрләре дә шулай ук бик көчле тәэсирләр ясый; бер чак килә, әйтергә ярый, Идел буе Казан халкы Гаяз Исхакый белән генә сулыйлар. Гаяз Исхакый вә әсәрләре ул халыкның сулый торган һавасы вә эчке тормышның азыгы булып тора.

Әнә аның шаһ әсәре «Зөләйха», бу тарихи вә үлми торган әсәрдә безнең куркыныч вә йотылырга мәхкүм (дучар булган) чагыбыз җанландырыла; вә шундый типлар белән җанландырыла ул, шул хәлне яратучыларга каршы кешенең чәчләре ирексез үрә тора, йөрәге әйтеп бетергесез нәфрәт вә гыйсъян (каршылык, баш күтәрү) тойгылары белән тибә...

Җанлары Гаяз Исхакыйның әсәрләрендәге илһам белән сугарылган Идел буе Казан төркләре моның өчен аны бер дә онытмаячак вә аңар мәңге бурычлы калачакдыр...

## «Татар театрының атасы» һәм Исхакый

Саный башласаң, татар әдипләре, сәнгать әһелләре берничә меңнән артып китәдер. Әмма алар арасында Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Гомәр Бәширов кебек йөзгә якынаеп, якты дөньядан китүчеләр, мөгаен, бармак белән генә санарлыктыр. Күпчелеге яшьли үк мәңгелеккә күзләрен йомган: Г.Тукай — 27 яшьтә, Ш.Бабич — 24 тә, Һ.Такташ — 30 да ... Шунысы гаҗәп: мондый затлар, әйтерсең үзләрен әҗәл сагалап торганын белеп, яшәргә, иҗат итәргә ашкынганнар, кыласы гамәлләрен, сөйләр сүзләрен

алдагы сәгатькә, туар көнгә калдырырга тырышмаганнар. Аларның гомере ничектер вакыт ягыннан тыгыз: көне атнага, атнасы айга туры килерлек. Бәлкем, шуңа күрәдер дә ир уртасы яшенә дә җитмичә китеп барган олуг талантларның эш-гамәлләре, иҗади җәүһәрләре өзек-төтек түгел, ә чагыштырмача бербөтенне тәшкил итә. Габдулла Кариев та (1886–1920) шундый затларның тәүге дистәсендә мөхтәрәм урынны били. Ул Тукайның яшьтәше генә түгел, ә дусты, фикердәше, мәсләктәше. Аларның берсе Казан артыннан булса, икенчесе — Фуад Туктарларны, күренекле руханиларны биргән Кулбай Мораса якларыннан. Язмыш дулкыннары ике «Габдулланы» Җаек төбәгенә илтеп ташлый. Алар бергәләп әдәби-музыкаль кичәләр оештыралар, икесе дә шигырьмәзәкләр сөйли, җырлый, кәмит күрсәтә. Җаектан киткәч тә, бу ике талант арасында элемтәләр өзелми, бер-берсе белән кызыксыну, теләк-киңәшләр бирү дәвам итә. Апушның Тукай, Миңлебайның Карый булып җитешүендә аларның үзара дустанә, иҗади мөнәсәбәтләре дә билгеле бер роль уйнагандыр.

Мәгълүм ки, Г.Кариев татар профессиональ театр сәхнәсенә 1907 елның җәендә аяк баса һәм тиз арада «Сәйяр»нең төп артистына, җитәкчесенә әверелә. Монда, әлбәттә, көчле табигый таланттан тыш, андагы үҗәтлек, Җаекта туплаган сәхнә тәҗрибәсе, әдәбиятны яхшы белү һәм оста вәгазьче, карый булуы да мөһим урынны били. Коръәнне яттан укуда, көйләүдә ул яшьтән үк мәшһүр руханиларны да таң калдыра.

Профессиональ театрда эшли башлавына биш ел да үтми, 26 яшьлек Г.Кариев «татар театрының атасы» дип рәсми рәвештә игълан ителә. Мондый дәрәҗәле исем аңа 1912 елның 5 мартында Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Ибраһимов, Ф.Туктаров, Х.Ямашев, С.Гыйззәтуллина һәм башка бик күп билгеле шәхесләр кул куйган махсус адрес рәвешендә бирелә.

Г.Кариев — барыннан да элек гаять көчле талантка ия булган артист. Ул башкарган Кәрим бай («Бәхетсез егет»), Сираҗеддин («Банкрот»), Городничий («Ревизор»), Хәмзә бай («Беренче театр»), Лопахин («Чия бакчасы») һ.б. образлар замандашлары тарафыннан олуг вакыйга, искиткеч яңалык рәвешендә кабул ителгән.

Г.Кариев — бөек режиссер, оста оештыручы да. Аның эшчәнлеге «Сәйяр»не генә түгел, гомумән, татар театрын үстерде, заманга лаек дәрәҗәгә күтәрде. Татар театры исә үз чиратында кайбер төрки халыкларның театрларына да зур йогынты ясады.

Г.Кариевның шәхси язмышы, иҗади эшчәнлеге шактый катлаулы. Гомере дә фаҗигале чикләнә. Аның үлеме, гәрчә рәсми хакимият теләмәсә дә, киң җәмәгатьчелек тарафыннан Тукай-

дан соң икенче зур югалту дип билгеләнә, бөек артист, режиссер хөрмәтенә мәрсияви язмалар, шигырьләр басыла. Аларда Г.Кариев «татар сәхнәсенең атасы», «гайрәтле каһарман» дип сыйфатлана, исеме «миллион айлар үтсә дә, онытылмаячагы» ассызыклана.

Г.Кариевның тормышы, эшчәнлеге, татар театрындагы роле хакында шактый гына мәкалә-хезмәтләр бар. Аларда бу олуг затның күренекле шәхесләр белән аралашуы турында да кызыклы факт-мәгълүматлар китерелә. Әмма совет чоры язмаларында аның Г.Исхакый белән мөнәсәбәтләре хакында материаллар юк дәрәҗәсендә. Булганы да тискәре планда гына. Мәсәлән, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре әзерләгән «Татар совет театры» исемле академик басмада (Казан, 1975. — 494 б.) мондый юллар бар: «Сыйнфый көрәшнең бөтен тирәнлеген аңлап җитмәгән кайбер театр әһелләре, милли буржуазиянең мәкерле ятьмәсенә эләгеп, Г.Исхакыйның «Зөләйха»сы кебек эчтәлек ягыннан зарарлы пьесаларны да куйгалады» (36 б.). Ә инде «Зөләйха»ны тәүге сәхнәләштерүче режиссер — Г.Кариев.

Исхакый һәм татар театры мөнәсәбәтләрен ачыклау — әле күтәрелмәгән чирәм. Бу олуг әдип татар профессиональ театрының барлыкка килүендә, үсешендә бәһаләп бетергесез роль уйнады. Шуңа күрә аның театр, артист-режиссерлар турындагы карашлары аеруча кыйммәтле. Г.Кариев Исхакыйны хөрмәт иткән, остазы дип караган, аның күп кенә әсәрләрен сәхнәләштергән, үзе дә аларда уйнаган. Бу ике олуг шәхес арасындагы иҗади хезмәттәшлек татар театрын яңа баскычка күтәргән. Тукай, Исхакый, Кариев — болар үзара бәйләнгән, янәшә торырлык, әмма һәрберсе үз тармагында бөек, беренче затлар.

Г.Исхакый милләткә хезмәт итүчеләрне, дусларын һич тә онытмый: алар хакында җылы сүзләр әйтә, аналитик мәкаләләр яза. «Артист Габдулла Карый» материалы да — шундый язмаларның берсе. Ул бөек актер һәм режиссерның тууына 50, үлеменә 16 ел тулу уңае белән язылган һәм Берлинда нәшер ителүче «Яңа милли юл» журналының 1936 ел, 12 нче санында дөнья күргән (12–18 б.). Бу мәкалә кайсы яклары белән игътибарга лаек соң?

Г.Исхакый Г.Кариевның тормыш юлы һәм эшчәнлеге хакында гомуми мәгълүмат бирә, үзенең бу зат белән кайда, кайчан, ничек аралашуы турында бәян итә. Мәкаләдән күренгәнчә, алар тәүге мәртәбә 1913 елда Мәкәрҗәдә, соңгы тапкыр 1918 елның ахырларында Кызылъярда очрашалар.

Совет чорындагы язмаларда Г.Кариевның Октябрь инкый-

лабыннан соңгы бер-ике елы бик буталчык, томанлы яктыртылып килде. Г.Исхакый мәкаләсе бу мәсьәләгә дә шактый ачыклык кертә. Баксаң, бөек артист Сембер, Самара аша Уфага килә. Биредә бераз вакыт яшеренеп ятарга да мәҗбүр була. Аннан Кызылъярга барып чыга. Шунысы мөһим: Г.Кариев кайда гына булмасын, үзенең профессиональ вазыйфасына тугры кала, теләсә нинди шартларда да уйнаучылар туплый, тиз арада спектакльләр куя. Мәсәлән, Уфада вакытта ул «Зөләйха»ны, Кызылъярда «Таһир берлә Зөһрә»не сәхнәләштерә. Г.Кариевның Себер шәһәрләрендә дә спектакльләр куеп йөрүе мәгълүм.

Мәкалә бу ике олуг затның бер-берсенә хөрмәт белән каравын, алар арасында тыгыз иҗади хезмәттәшлек булуын янә бер мәртәбә раслый. Г.Исхакый фикеренчә, Г.Кариев — «тормышыбызга яңа милли барлык тугдыручы кадерле милли хезмәтче», «...мәдәни үсү тарихымызда һичбер онытылмаячак эзләр калдыручы». Язмада татар театры, аның аерым артистлары, бу чордагы мәдәни, сәяси тормыш хакында да кызыклы факт-мәгълүматлар бар. Аеруча «Зөләйха»ның Казанда һәм Мәскәүдә куелуы, спектакльнең гаять зур уңыш белән баруы турындагы фикерләр әһәмиятле. *«Мин,* — ди Г.Исхакый, — *«Сәйяр» труппасын Мәскәүдә беренче майда башланачак Бөтенрусия мөселманнары корылтае вакытында чакырдым. Габдулла Карый бөтен труппасы берлә бергә килеп, корылтай вакытында Мәскәүнең иң зур «Корш театры»нда «Зөләйха»ны дүрт мең халык алдында куйды...»*

Мәкалә Г.Исхакый эшчәнлеген ачыклауда да билгеле бер әһәмияткә ия. Бөек әдип, татар театрының авыр хәлен аңлап, куелган әсәрләре өчен гонорар алмаган, булдыра алган кадәр театрга үзе ярдәм итеп торган. Язмада «Сөембикә» әсәре хакында да телгә алына. Күрәсең, Г.Исхакый Г.Кариев белән әңгәмә вакытында «Сөембикә» исемле пьеса язарга ниятләвен әйткәндер. Мөгаен, бу чордагы ыгы-зыгы аркасында әдипнең бу теләге гамәлгә ашмый калган. Кызганыч, әлбәттә. Мәкаләдә Г.Исхакый иҗатына мөнәсәбәтле янә бер мөһим факт бар. *«Кызылъярда вакытта,* — ди автор, — *Г.Кариев минем яңа язып бетергән «Юлсызлар»ымны үгрәтергә тотынды».* Тиз арада спектакль әзер була. Әмма, бина юклык аркасында, ул куелмый кала. *«Мин,* — ди алга таба Г.Исхакый, — *үземнең соңгы әсәремне сәхнәдә күрми калдым. Ләкин вакыты, форсаты булганда уйнарга дип, «Юлсызлар»ны Габдулла Карыйда калдырдым. Үзем ... Аурупага киттем».* Бу нинди әсәр? Аның язмышы ничек? Бәлкем, ул башка исем белән мәгълүмдер? Кыскасы, бу төр сорауларга хәзергә җавап бирү кыен.

ХХ йөз башы — татар мәдәниятенең алтын чоры. Аны бу дәрәҗәгә күтәрүдә Исхакыйлар, Тукай, Карыйлар хәлиткеч роль уйнаган. Бу хакыйкатьне без XXI йөз башында да күңелләребездә тотарга бурычлы.

*2004*

## Артист Габдулла Карый*

*Гаяз Исхакый*

Милли театрымызның тууында, үсүендә мәгълүм бер юлдан баручы, театр уйнаучыларымызның җитешеп, «Сәйяр» труппа булып өлгереп, сәхнәмезнең милли төстә гәүдәләнүендә Габдулла Карыйның уйнаган роле Габдулла Тукайның шигырь сәхнәсендә уйнаганнан ким түгелдер.

Габдулла Карый таркау театр һәвәскәрләремездән, үзенең коручы, төзүче көче берлә, үзләре дә белмәгән теләкләрен вөҗүдкә чыгаручы, тормышымызга яңа милли барлык тугдыручы кадерле милли хезмәтчемездер. Үлгәненә 16 ел гына үткән бу бөек артистымызның туганына да илле генә ел. Ул үзенең кыска тормышында безнең мәдәни үсү тарихымызда һичбер онытылмаслык эзләр калдырды. Безнең яшь театрымызның үсүен, алга китүен һичбер аерылмый торган итеп үзенең исеме берлә баглады һәм аны мәдәни тормышымызда мәңгеләшдерде. Соң Габдулла Карый кем иде? Бу зур көчне ул каян алды? Бу сөальләргә җавап бирү бүген минем максадым түгелдер. Бу хакта киләчәктә мөтәхассыйслар (белгечләр) язарлар. Мин Габдулла Карый берлә үземнең театр китаплары язучы сыйфаты берлә бәгланышымны вә шул арадагы тәэсирләремне генә бераз сөйләп үтмәкче булам.

Габдулла Карыйның чын исеме Миңлебай, гаилә исеме — Хәйрулла. Атасы-анасы фәкыйрь авыл кешеләре генә булсалар да, угылларын авылның галим имамы Фәсах Хаҗи (Фуад Туктарның атасы) мәдрәсәсендә укытканнар. Аннан соң Җаек шәһәренә барып, анда бер мәдрәсәгә кергән вә шунда Коръәнне яттан укучы исемен алгандыр. Габдуллага үзенең исеме Миңлебай мәдрәсәдә үк бик ямьсез сизелгән, ул шуңардан качарга иҗтиһад иткән (тырышкан). Гаилә исеме Хәйрулла да мужик исеме төсле күренгәнгә, ул аны да бер дә сакларга теләмәгән. Хәтта үзенә шундый тупас исемне биргән өчен авылның имамы Фәсах хәзрәткә үпкәли иде. Шул үпкәсен

* Яңа милли юл. — 1936. — № 12 (105). — 12–18 б.

аның угылы Фуад Туктарга каршы да саклап килә иде. Артистлыкка кереп китәргә имкян (мөмкинлек) булгач та, ул иң элек җаны сөймәгән исемен үзгәртеп, Габдулла Карый (Кариев) булып киткәндер*. Ул шул исемдә бөтен төрк дөньясында танылып, шул исемдә милли театрымыз берлә баглангандыр.

Мин шәхсән Габдулла Карыйны беренче мәртәбә сөргеннән кайткач, 1913 елның көзендә Мәкәрҗәдә (Түбән Новгород янындагы Мәкәрҗә ярминкәсе күздә тотыла. — Х.М.) очраттым. Аның оештырган «Сәйяр» труппасы** берлә дә шунда гына таныштым. 1907 елда мин, Казанда кулга алынып, Архангел губернасына 3 елга сөргенгә күндерелгән идем. Шул сөргеннән качып кайтып, Петербургта, Истанбулда, Финляндиядә яшәсәм дә, Казанга килә алмаган идем. Габдулла Карыйның милли театр ясаудагы уңышларын вә минем бик күп әсәрләремне куюларын гәзитләрдә укып, ишетеп белсәм дә, нә театрны күргән идем, нә Габдулланың үзе берлә, нә труппасы берлә танышырга форсат булган идем (форсат булмаган иде).

Габдулла Карый бүлмәмә күрешергә килгәндә, оялчан гына, тәрбияле генә бер яшь егет хисаятен (күзаллавын) калдырды. Озын сөйләшеп ултыра алмадык, әллә кемдер килде. Берәр көннән соң ул үзенең труппасының икенче дәрәҗәдәге рольләрдә булына торган артисты Вәлиулла Мортаза берлә килде вә мине театрга чакырды. Минем хөрмәтемә дип минем бер әсәремне куярга теләүләрен сөйләде. Бераздан соң минем «Алдым-бирдем»не куеп, минем хөрмәтемә бер зыяфәт тә (кунак итү дә) ясадылар, труппа исеменнән бүләк бирделәр. Мин беренче мәртәбә үземнең әсәремнең милли труппа тарафыннан уйналуларын шунда күрдем. Бу күрешүдән соң без киләчәктә милли репертуар ясау хакында күп сөйләштек. Мин боңарчыга кадәр «Сәйяр» труппаның уйнауларыннан үземнең әсәрләрем өчен һонорар*** алмаган кеби, бондан соң да алмаячагымны сөйләдем. Габдулла Карый минем яңа әсәрләремнең басылмас борын ук үзенә бирелүен риҗада (үтенүдә) булынды. Мин дә берничә әсәремне бирдем. Үз тарафымнан «Сәйяр» труппа хөрмәтенә мин дә бер зыяфәт бирдем. Бу вакытларны

---

* Казанда 1926 елда «Татар театры» исеме берлә чыккан китапта хәлфәсе Зариф мелла үз мәдрәсәсендә үк аның исемен Габдулла исеме берлә алыштыра һәм Миңлебай дип өндәүчеләргә җавап кайтармаска кушкан дип язылган.

** Бу исем «Тәрҗеман»да Исмәгыйль бәк тарафыннан бирелгән.

*** Театрлар уйналган әсәрләрнең мөхәррирләренә каләм хакы түләп киләләр *(Г.И.)*.

«Сәйяр» труппа инде Казанда йирләшеп уйный башлаган вә сәйярлеге (күчеп йөрүе) җәйге айларда гына калган иде. Мәкәрҗәдә Самакат дигән бер йирдә бер иске театрны тотканнар иде. Беркөнне, әллә ниндидер эшем чыгып, Габдулла Карыйны театрда очратырмын уе берлә көндез театр бинасына киттем. Ишекне ачып эчкә керсәм, көтелмәгән бер манзара (күренеш) алдында калдым. «Сәйяр» труппаның зур артистларыннан Гөлсем Болгар, Мәрфуга Мортаза, Сара Байки куллларын сызганганнар да, театрның идәннәрен юалар. Кәрим Тинчура, Вәлиулла Мортаза, тагын берничә артист чиләк-чиләк су ташыйлар. Габдулла Карый да урындыкларны күчерә. Бүген булачак театрга бинаны пакьләү, арулар өчен кирәк булганда, кеше яллап эшләтергә акчалары юк күрәсең дә, үзләре шуны эшләп яталар. Минем шундый хәлдә үзләрен очратуыма труппа әгъзалары, хосусан хатын артистлар оялдылар. Ләкин мин үзем боларның ничек труппа булып яши булуларының төп мәгънәсен аңлап, боларның һичбер эштән бу «кара» дип тартынмауларын күреп, киләчәктә дә үсәчәкләренә сөендем. Вә аларның күңелләрен күтәрә торган сүзләр сөйләдем.

1915 елның башлары иде. Г.Карыйның авырып китүе һәм дә бугаз чахоткасы алуы хәбәре йөри иде. Габдулла берлә язышкан мәктүбләремездә аның дәвалануына ихтыяҗ зурлыгы, Кырымга китәргә кирәк булуы, ләкин акча юклыгы тотып торуы мәгълүм булып кала иде. Мин дә Кырымга китәргә димләдем, акча табуда берәр төрле ярдәм ителүнең чараларын эзләүне белдерә идем. Көннең берендә идарәмезгә Габдулла Карый килеп керде. Ябыккан, рухы төшенке бер хәлдә, авыруының начарлыгыннан зарлана. «Тузан эчендә урамнан җыйнаган егет-кызларны уйнарга үгрәтә-үгрәтә, аларга кычкыра-кычкыра мона (менә) шулай булдым, моңа инде тавышым бетте, артистлыгым сынды» кеби өмидсез-өмидсез сөйләнә иде. «Ил» идарәсендә* ул вакытта кятиб (секретарь) булып Нәҗиб Гасрый эшли иде. Ул әдәбият, театрны бик сөюче, нәфасәтне аңлаучы, Истанбул дарелфөнүненең (университетының) әдәбият шөгъбәсен (бүлеген) тәмам иткән бер егет иде. Габдулла Карыйны бик таный, аңар бик зур хөрмәт итә иде. Сөйләшүләремездә ул да бергә иде. Без Нәҗиб берлә күзгә-күз карашып, Габдулланың рухын күтәрү кирәклеген аңладык. Нәҗиб әдәбияттан, театрдан әллә нинди көлкеләр сөйләргә тотынды. Мин шуны форсат булып (форсаттан фай-

---

* «Ил» — 1913–1918 елларда әүвәл Петербургта, аннан Мәскәүдә Г.Исхакый мөхәррирлегендә чыккан гәзит. Ул бераз вакыт «Сүз», «Безнең ил» исемнәре белән дә дөнья күрә.

даланып), телефонга чыгып, мәрхүм Габдулла Бурнашка («Ил» гәзитенең нашире) телефон берлә Габдулланың хәлен аңлаттым вә аны бүген кичке ашка чакырырга, үзара утырышырга дәгъват итәргә үтендем. Яшьләрнең шул арада бер мәҗлесләре булачак иде, Шәйхулла Алкинга телефон итеп, алардан да чакырырга вә тиз үк рәсмән (рәсми рәвештә) килеп күрешергә әйттем. Тагын кемгәдер, театр сөйгән яшьләрдән берсенә, Мәскәүнең зур театрларыннан берсенә билет тәкъдим итүне риҗада (үтенечтә) булындым. Үзем, берни булмаган кеби бүлмәмә кереп, сүзгә кушылдым. Сөйләшү дәвам итеп, берничә минут вакыт кичмәде, телефон килде. Идарәдәге эшләүче аны минем бүлмә берлә берләштерде. (Телефоныбыз ике япьле иде.) Телефонда Габдулла әфәнде Бурнаш Габдулла Карыйны сорый иде. Электән таныш булганга, шактый озын сөйләштеләр. Хәл-әхваль сорады. Кайвакыт вакыты барлыгын белеште. Аның артыннан берничә минут үтмәстән, Мөршидә ханым Бурнаш телефон итеп Габдулла Карый берлә сөйләшеп, безне кичке ашка дәгъват итте. Ул бетмәгән иде, Шәйдулла берлә бер студент килеп, Г.Карыйны үзләренең яшьләр мәҗлесенә чакырды. Берничә минуттан берсе килеп Мәскәүнең «Сәнаигы нәфисә театры»на («Художественный театр»га) берничә көнгә билет китерә килде. Өйлә ашына чыгамыз дип торганда гына, Гали Кормай килеп керде, безне Мәскәүнең зур бер ресторанына алырга килүен белдерде. (Аларны Нәҗиб телефон итеп өлгергән икән.) Чыга башлаганда инде Габдулла бик күп үзгәргән, йөзенә көләч чыккан, күзләре нурланган иде. Ишек төбенә җиткәндә, Габдулла күзе берлә бер нәрсә эзләргә тотынды. Әллә берәр киемен-фәләнен эзлиме дип сорадым. «Юк, ул түгел, бонда бер серле нәрсә булырга кирәк, шуны эзлим», — диде. Күзе безнең телефон чоланына очрап: «Таптым, бүгенге бу эшләрне барысын да шул эшләде, бик шәп нәрсә икән, савыгып кайткач, мин дә телефон куйдырам», — диде.

* * *

1917 нче ел ихтилялы (фетнәсе; революциясе) булу берлә Габдулла Карый үзенең портфеленнән минем күптән биргән «Зөләйха»мны чыгарып, ихтилялның беренче атнасында ук цензур тарафыннан мәнгъ (тыю) беткәч тә, Казанда «Зөләйха»ны куйды. Мин ул вакытта Мәскәүдә җәмәгать эшләре берлә бик мәшгуль идем. Ләкин гәзитләрнең язуыннан һәм дә ике атна эчендә «Зөләйха»ның шушы театрда дүрт мәртәбә куелуыннан «Зөләйха»ның зур уңышын аңлап алган идем. Тизрәк Казанга

барып, шуны күрәсем дә килә иде. Сөргеннән 13нче елны кайтсам да, Казан губернаторы мәнгъ иткәнгә, мин боңарча рәсмән Казанга керә алмый идем. Берничә мәртәбә берәр көнгә кереп үткән булсам да, болар да качу-посу төсендә генә иделәр. Тагын сөйләнәчәк сүзләр, төзеләчәк планнар да Казанда бик күп иде. Габдулла Карый да «Зөләйха»ны күрергә вә шулай уйнарга ярау-ярамау хакында фәтва алырга чакыра иде. Апрель башында Мәскәүдән Казанга киттем. «Зөләйха»ның куелуы игъълан ителде. Ләкин «Сәйяр» труппа бу вакытка кадәр соңгы — фәрештәле пәрдәсен куя алмаган иде. Мин аның куелуына исрар иттем (ышандырдым; зарурилыгын раслалым). «Зөләйха»ның уйналуы зур бер бәйрәм төсен алды. Фәүкылгадә (гадәттән тыш) муаффәкыятьле (уңышлы) чыкты. Мин «Сәйяр» труппаны Мәскәүдә беренче майда башланачак Бөтенрусия мөселманнары корылтае вакытына чакырдым. Габдулла Карый бөтен труппасы берлә бергә килеп, корылтай вакытында Мәскәүнең иң зур «Корш театры»нда «Зөләйха»ны дүрт мең халык алдында куйды. «Зөләйха»да уйнаучылар бик күп булганга, Габдулла корылтайга килгән вәкилләр арасыннан әллә никадәресен сәхнәгә чыгарган вә туй сәхнәсен бик матур җырчылар, биючеләр берлә баеткан иде. «Зөләйха»ның Мәскәүдәге уңышы һәм дә Мәскәүдә урысның үзәгендә «Зөләйха»ны куя алу аның рухын бик күтәргән, цензурның бетерелүе аңар киң имкян (мөмкинлек) ачкан иде. Ул «Зөләйха» берлә Кафкас, Төркестан, Кырымда турне ясарга хәзерләнә вә миннән берничә әсәр таләп итә иде. «Сөембикә»не тизрәк язарга кызулый иде. Ләкин ихтилял һаман тирәнәеп китеп, җәмәгать хадимнәрен (әһелләрен) биниһая күп эшләр берлә томалап килгәнгә, мин дә ул әсәрләремне яза алмадым. (Бу биттә Г.Карыйның фотосурәте дә бирелгән. — *Х.М.*) Юллар бозылып, дөнья большевиклашып киткәнгә, Габдулла Карый да турнесына (гастрольләргә) чыга алмады. Без инде аның берлә 1918 елның көзендә Уфада очраштык. Казанда большевиклар берлә чехлар сугышы көннәрендә Г.Карый кемнән курыкканын белмәенчә, кемнән качканын да уйламаенча, вапура (пароходка) утырып, Казаннан Сембергә киткән, аннан акрынлап Самар аша Уфага килеп чыккан иде. Ләкин бөтен труппасы, ун елдан артык җыйган репертуары, «Сәйяр» труппаның баеп өлгергән театр өчен кирәкле кием-салымы, театр әсбабы — бар да Казанда калганга, күңеле бер дә тыныч түгел иде. Һәм дә мөмкин кадәр тиз Казанга омтыла иде. Карарсыз көенчә Уфада яшәп тора иде. Шул вакытта Уфадагы күңеллеләрне (доброволецларны) оештырып, «Зөләйха»ны бер мәртәбә уйнады. Без, Милли идарә әгъзалары, Себергә күчеп китә башлагач, Уфада калырга булды. Больше-

викларның керүе көне-көне берлә көтелгәнгә, беренче көннәрдә үтерелеп ташланмас өчен Г.Карый әллә нинди начар киемнәр киенеп йөрергә башлады. Урынын да шәһәрдән күчереп, Уфаның Идел (Агыйдел) буендагы, Иделдән ага торган салларны угырлый (урлый) торган караклар мәхәлләсенә күчте. Агач, утын угырлап кына көнен кичерә торган, һичбер «буржуй» булмаган бер урыс әбисендә кечкенә бер бүлмәгә йирләште. *«Мин инде бонда большевиклар кергәнен көтеп калам да Казанга китәм»,* — диде. Без Себергә киттек. Кызылъярда (бу шәһәр Петропавловск исеме белән дә йөртелә. — *Х.М.*) урынлашып, Милли идарәне корып, «Маяк» гәзитен тәэсис итеп (оештырып), милли эшкә керештек. Көннәрнең берендә Кызылъяр шәһәрендә өемдә утырганда, янындагы бер иптәш артисты берлә Габдулла килеп керде. Мин дә гаҗәпкә калдым. *«Нишләп йөрисең, ник Казанга китмәдең?»* — дидем. «Уфада адәм гакыллы кеше калмады, большевиклар шәһәрне алалар дип көтеп тордым- тордым да, туйдым. Сал караклары берлә тору да бик шәптән түгел икән. Тагын большевиклар Чишмә ягындагы сугышта җиңелеп-җиңелеп киттеләр. Мин фронтны ярып кайтырга курыктым. Бонда килдем, минем бондалыкны беркемгә белдермик әле», — диде. Шул арада Иркутскиның бер сәүдәгәре: «Мин китеп барам, күрешергә кердем», — диде. Мин дә аның артыннан Иркутскига хатлар биреп, сәламнәр әйтеп, тагын кайчан киләсең, дип сорашып, аңар Иркутскидан чын чәй («Кытай чәе») китерергә куштым. Габдулла безнең бу сөйләшүләрдә бер сүз дә дәшмәенчә, үзенең исемен дә яшереп, тик кенә торды. Теге чыгып киткәч: *«Йә, сөйлә, планың ничек?..»* — дидем. Габдулла: «Мин әле синең Иркутскига чәйләр асмарлавыңнан бонда андый-бондый курку юклыкны күрдем. Тынычланып киттем, алай булса, бонда әле бүген-иртәгә үзара сугыш булмый дип уйлыйсыз», — диде. Мин, юк, юк, дип, килгән-килгән, бондагы бик күп яшьләрне оештырып бер труппа ясап, театрлар куярга киңәш бирдем. Үземнең яңа бер әсәр язып ятуымны аңлаттым. Икенче көнне инде Г.Карый, йирле һәвәскәрләр берлә сөйләшеп, «Таһир берлә Зөһрә»нең хәзерлекләренә башлады. Аны бик зур муаффәкыять (уңыш) берлә үткәрде. Минем яңа язып бетергән «Юлсызлар»ымны үгрәтергә тотынды. Игълан чыгарды, билет сата башлады, театр алды. Бер-ике көннән уйналырга хәзерләнеп җиткәндә генә театрның бинасын гаскәрләр үз кирәкләренә алдылар вә әллә нинди гаскәр кирәкярагын тутырдылар. Башка бина Кызылъярда табылмады. Габдулла Карый «Юлсызлар»ны уйный алмый калды. Мин дә үземнең соңгы әсәремне сәхнәдә күрми калдым. Ләкин вакыты, форсаты булганда уйнарга дип, «Юлсызлар»ны Габдулла Карыйда

калдырдым. Үзем солых һәйәте* әгъзасы сыйфаты берлә Япуния аша 1919 елның башларында Аурупага киттем.

Габдулла, Омск, Томск, Иркутскиларда театрлар куеп йөрергә булып, Кызылъярда калды. Бу минем Габдулла Карый берлә соңгы вә актыккы күрешүем булды. Ул бик озак төрле йирләрдә әллә кемнән куркып, әллә кемнән качып йөргәннең, большевиклар йирләшеп беткәннең соңында Казанга кайткан. Анда тиф берлә авырган. Большевиклар аны терелер-терелмәс, «Себердә акларга уйнап йөрдең бит, бонда пролетариатка уйнарга кирәк теләмисең», — дип куркытып, ачыклы-тишекле салкын театрда сәхнәгә чыгаралар. Шунда ул бик каты азык тидереп өзлегеп китә вә, савыга алмаенча, 1920 елның 28 гыйнварында вафат итә. Минем дә аның берлә танышлыгым шунда өзелә.

## Рухи бәйләнешләр турында Исхакый

Үзара багланышлар, тәэсир, йогынты мәсьәләләре һәрчак актуаль. Ни өчен? Чөнки алар яшәешкә хас сыйфатлар. Бер генә адәм баласы да, кавем һәм ил дә үз кысаларына гына бикләнеп гомер кичерә алмый, — яшәеш, тереклек аларны үзара мөнәсәбәтләргә керергә, бер-берсеннән өйрәнергә, тәҗрибәхәзинәләрне уртаклашырга мәҗбүр итә. Бу хакыйкать, тормыш кануны, аеруча рухи кыйммәтләр әдәбият өлкәсендә ачык күренә. Тәүрат, Инҗил, Коръән китаплары, мәсәлән, дөньяның бик күп халыкларына үтеп кергән, аларның рухи тормышына гаять зур йогынты ясаган. Низами, Шекспир, Гёте әсәрләре дә җиһан сүз сәнгате үсешендә мөһим урын били. Әмма сәнгать өлкәсендә бер хакыйкатьне һәрвакыт истә тоту зарури: иҗатта башкалар тәэсире, йогынтысы хәлиткеч түгел; үзәктә — үзеңнең эчке ихтыяҗларың, теләк-омтылышларың, хис-тоемың, әбибабаларыңнан килгән рухи тәҗрибә, милли тормыш. Башкалар тәэсире синең күңелеңне теге яки бу дәрәҗәдә кузгатырга, иҗади бөреләрнең ачылып китүенә өлешчә ярдәм итәргә генә мөмкин. Әгәр дә үзгәләрнең йогынтысы хәлиткеч була икән, ул вакытта оригиналь, мөстәкыйль әсәр туа алмый. Янә тагын бер хосусиятне онытырга ярамый: башкаларның иҗади казанышларын үзләштерү, кабул итү өчен үзеңнең һәм халкыңның эчке үсеше, ихтыяҗы да кирәк. Үзгәләрдән өйрәнү, гадәттә, әдәбиятның шәкелләшү-формалашу дәверендә, бер этаптан икенчесенә күчү чорында ныграк күзәтелә.

---

* Мәгълүм булганча, Милләт мәҗлесе С.Максуди, Г.Исхакый, Ф.Туктар составында Версаль сөйләшүләрендә катнашу өчен комиссия төзегән була.

Татар сүз сәнгате үзенең мең елдан артык тарихында мөселман Көнчыгышының рухи хәзинәләре белән тыгыз бәйләнештә үскән. Реаль багланышлар, объектив фикерләр, аеруча дини уртаклык, Шәрык-татар әдәби элемтәләрен дәвамлы тәэмин итүдә мөһим роль уйный. Урта гасыр татар һәм гарәп, фарсы, төрки рухи кыйммәтләре кайчак шулкадәр нык һәм табигый керешкән ки, монда хәтта еш кына кайсы татарныкы, кайсы Шәрыкныкы дип аеру да мөмкин түгел. Мондый хәл әле XIX йөздә дә дәвам итә.

Безнең халык элек-электән урыслар белән янәшә, аралашып яшәгән. Әмма татар әдәбиятында урыс сүз сәнгатенең йогынтысы күп гасырлар буена бик сизелми. Киресенчә, татар тормышы, татар фольклоры урыс әдипләрен ныграк кызыксындыра. «Игорь полкы турында җыр», «Казанская история» (XVI йөз), Фатыйма-солтан (бу ханбикә хакында шигъри трагедия дә язылa) һәм Сөембикә турындагы әсәрләр һ.б. — моның ачык мисаллары. XIX гасырда исә аерым татар авторлары, гәрчә бик аз булса да, урыс әдәбияты белән кызыксына башлыйлар. М.Иванов, К.Насыйри хрестоматияләрендәге аерым тәрҗемәләр — бу өлкәдәге беренче карлыгачлар. Гасырның соңгы чирегендә әдәбиятка килеп кергән Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев инде урыс әдәби казанышларын да билгеле бер дәрәҗәдә файдаланалар. Боларга бераздан М.Өметбаев, Г.Исхакый, Г.Тукай һәм башкалар килеп кушыла. XIX йөзнең соңгы чирегендә — XX гасыр башларында татар әдипләре госманлы сүз сәнгате аша Аурупа, аеруча француз әдәби кыйммәтләрен дә ныклап файдалана башлыйлар. Әмма ничек кенә булмасын, Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты, гомумән, традицион Шәрык кысаларында кала. Күпчелек татар зыялылары Шәрыкка, исламга тугрылыкта үзләренең милли барлыгына, менталитетына да тугрылык күрделәр. Г.Исхакый, Г.Тукай, М.Гафури, Дәрдемәнд иҗатлары — шуның күркәм мисаллары.

Әдәби бәйләнешләр хакында галим-голәма фикерләре кызыклы. Әмма үзләре әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләрнең, ягъни әдипләрнең, бу мәсьәлә турындагы карашлары, язмалары тагын да кызыклырак. Әгәр дә ул Г.Исхакый кебек бөек һәм тәҗрибәле каләм әһеле дә булса, андыйларның фикерләре аеруча кыйммәт. «...Инкыйраз» авторының «Толстойның татар әдәбиятына тәэсире» язмасы да шул ноктада торып бәяләнергә тиеш. Бу мәкалә «Милли юл» журналының 1929 елгы 8 нче санында басылган. Ул бөек әдип Лев Толстойның тууына 100 ел тулу мөнәсәбәте белән дөнья күргән. Язма мөһим факт-мәгълүматларга, оригиналь, хәтта урыны бе-

лән бәхәсле фикерләргә бай. Анда без Г.Исхакыйның теге яки бу күренешкә ачык мөнәсәбәтен, симпатия-антипатияләрен, иҗатының һәм, гомумән, эшчәнлегенең әһәмиятле якларын күрәбез.

Мәкалә авторы иң әүвәл Советлар Берлегендә Толстойның тууына 100 ел тулуны билгеләп үтүнең сәбәпләрен ачыклый. Г.Исхакый фикеренчә, Толстой бөтен Аурупада «зур урын тота». Нәкъ менә шуңа күрә дә большевиклар аны үз мәнфәгатьләренә хезмәт иттерергә, аны «ярты большевик» итеп куярга омтылалар.

Алга таба Г.Исхакый татар матбугатына күчә, бөек әдип хакында җибәрелгән аерым төгәлсезлекләрне тәнкыйтьләп ала. Төп игътибарын ул Хәйреддин Вәлинең (1893–1969) «Безнең юл» журналында (8 нче сан) басылган мәкаләсенә юнәлтә. Шунысын да әйтик: Х.Вәли — узган гасырның 20 нче елларында шигырь төзелеше турында җитди генә хезмәтләр биргән автор. Ул бары соңгы елларда гына тиешле бәясен ала башлады. Г.Исхакый да Х.Вәли хакында «большевиклар арасында бик сирәк очрый торган... ак карга» дип, кызыклы гына уңай фикер әйтә. Әмма бөек әдип Толстой турындагы мәкаләгә «берничә төзәтү» кертә, урыны белән Х.Вәлине кискен тәнкыйтьли дә.

Г.Исхакый карашынча, «Гафил бине Габдулла» (ягъни Ризаэддин Фәхреддин) иҗатын, аның «Сәлимә...» әсәрен Толстой белән бәйләп карау нигезсез. Шулай ук «...Инкыйраз» авторы үз иҗатына Толстой тәэсире темасына да туктала. Г.Исхакый үзенә урыс әдәбиятының йогынтысын кире какмый. Әмма бу мәсьәләдә ул Толстой һәм Достоевскийны аерым куюга каршы. Киресенчә, мәкалә авторы бу ике әдипнең үзе өчен ятрак булуын искәртә. *«Минем рухыма иң якын рус язучылары, иң сөйгәннәремнең берсе,* — ди ул, — *әле дә Тургенев, икенчесе — Чехов вә өченчесе — Гогольдер»*. Г.Исхакый бу авторларда үзенең рухына якынлык, татар яшәешенә аваздашлык күрә. Ул үзенең аерым әсәрләрендә («Тәгаллемдә сәгадәт...», «Кәләпүшче кыз», «Бай углы» һ.б.) төзек, аның аша француз әдәбиятының роле зур булуын ассызыклый. «Теләнче кызы» романын төрек язучысы Нәсиб Вәҗиһинең «Чубан кызы» китабы йогынтысында иҗат итүен искәртә. (Бу ике әсәрне чагыштырма тикшерү кызыклы булыр иде!) *«Жюль Верн, Виктор Һюго, Мопассан, Доде һәм Дюмалар берлә мин,* — ди Г.Исхакый, — *төрекчәдән таныштым»*. Бу юллар «...Инкыйраз» авторын гына түгел, ә, гомумән, XX йөз башы татар әдәбиятын аңлауда һәм бәяләүдә дә мөһим. «Бездәге аерым хезмәтләрдә әле һаман да татар сүз сәнгатен

«өлкән туган» әдәбиятына мөнәсәбәттә карау гына өстенлек итә.

Г.Исхакый мәкаләсендә, әйткәнебезчә, бәхәсле урыннар да бар. *«Толстой миңа һәрвакыт ят булып килде...»* дип яза автор. Биредә, әлбәттә, Г.Исхакый, иң беренче чиратта, үз иҗатын, үз зәвыгын күздә тота. Ә, гомумән, Толстой иҗаты XX йөз башы татар рухи тормышына көчле йогынты ясый. Моның сәбәпләре, әлбәттә, күптөрле. Беренчедән, Толстой — олы язучы, кодрәтле талант иясе. Икенчедән, аның әсәрләрендә гомуминсан мәнфәгатьләрен яклау, хаклык, гаделлек өчен җан ату, урыс булмаган милләтләргә, шул исәптән татарларга теләктәшлек өстенлек итә. Өченчедән, Толстой самодержавиене, рәсми чиркәү сәясәтен тәнкыйтьли. Дүртенчедән, урысның бу бөек әдибе һәм философы татар һәм, гомумән, мөселман дөньясында киң таралган фәлсәфи, суфичылык карашлары белән мавыга. Бу факторлар һәммәсе дә Толстойның татар тормышында абруен арттыралар.

Инде мәкаләгә янә кире кайтыйк. Татар әдәбиятында Толстойга охшаш якларның сәбәбен Г.Исхакый бөек урыс әдибенең тәэсирендә түгел, ә, иң беренче чиратта, үзебезнең яшәештә, җирлектә, милли һәм рухани кыйммәтләрдә күрә. (Охшашлыклар бар икән, алар, нигездә, типологик характерда.) Г.Исхакый фикеренчә, әгәр дә Х.Вәли бу хакыйкатьне аңлаган булса, *«Гафил бине Габдуллаларны Толстой коерыгына тагарга мәҗбүр булмас иде. Мине дә Толстой өмәчесе итмәс иде; минем дә, Тукайның да үскән үз милли җимешемез икәнен ап-ачык күрер иде»*.

Г.Исхакыйның методологик характердагы бу төр фикерләре хәзерге көн өчен дә актуаль. Татарда «Бай кисә — котлы булсын, ярлы кисә — каян алдың?» гыйбарәсе бар. Шуның кебек, аерым зыялылар бездә берәр юньлерәк әйбер, яңарак нәрсә күрсәләр, аны хуплыйсы, татарның үз зәмин-җирлегенә нисбәтән аңлатасы урында, бу төр күренешләрне урыс, Аурупа... тәэсире нәтиҗәсе дип тәкрарлый башлыйлар. Әйтерсең татарның үз акылы, үз тормышы, үз барлыгы юк. Гаяз Исхакый әйтмешли, мондый алым *«гыйлем, фән ягыннан бик зур хата»*. Һәм, гомумән, бөек әдип тәкълидчелеккә, совет җәмгыятендә киң таралган «цитатачылыкка» тискәре мөнәсәбәттә.

Г.Исхакый мәкаләсендә башка мөһим факт-мәгълүматлар да бар. Мәсәлән, Хөсәен Ямашев, «ортодоксаль» сәяси булудан бигрәк, толстойчы шәхес рәвешендә дә күзаллана. Мәкалә авторы белән аның дустанә мөнәсәбәтләре сизелеп тора. Рәсми хакимият никадәр тырышса да, илдә Г.Исхакыйны «онытты-

ру» җиңел генә бармый. Татарның аерым зыялылары узган гасырның 20–30 нчы елларында да бөек әдип исемен, аның әсәрләрен каралтмыйча телгә алып торалар. Х.Вәли язмасында да бу тенденция күзәтелә. Г.Исхакый үз мәкаләсендә «Утыз елым» исемле хатирәләр язуын искәртә. Киләчәктә бу әсәрнең язмышын, эчтәлеген ачыклау да һәм фән, һәм киң җәмәгатьчелек өчен мөһим булыр иде.

Күп кенә чыганаклар, истәлекләр Г.Исхакыйның туры сүзле, ихлас күңелле, катгый бәя-хөкемле, ачык мөнәсәбәтле шәхес булуы хакында сөйлиләр. Бу хакыйкатьне әлеге язма да куәтли. Күргәнебезчә, ул Толстой һәм Достоевскийны абруйлы затлар дип тормый, үзенең эчке ихтыяҗы, инанычы белән кискен тәнкыйтьли дә. Мөстәкыйль иле, азат халкы булмаса да, мөһаҗирлектә, үз сүзләре белән әйткәндә, «гаҗизлектә» (игътибар итегез: бу сүздә никадәр сагыш, аянычлы хәл!) каңгырып йөрсә дә, халкының киләчәгенә тирәнтен инанган Г.Исхакый үз бәясен үзе белә, үз акылы, үз карашы белән эш итә. *«Мин,* — ди ул, — *үз фикеремә үзем хуҗа, үз тойгыма үзем ия. Үзем белгән юлдан үзем барыйм».* Икенче бер урында әдип «дөньяның мәгънәви талчыгуында» йөри торган фикерләргә мохтаҗлыгы юклыгын искәртә. Кыскасы, Г.Исхакый бу язмасында да үзе булып, чын милләтпәрвәр булып кала, үзенчә фикерле, үзенчә бәя бирә. Мәкаләнең кыйммәте, барыннан да элек, нәкъ әнә шунда.

*2004*

## Толстойның татар әдәбиятына тәэсире*

*Гаяз Исхакый*

Үткән ел көз (ягъни 1928 елда) Толстойның тууына йөз ел тулу уңгае берлә Толстой хакында бөтен телләрдә бик күп китаплар, мәкаләләр язылды. Безнең большевик матбугатта да большевикның иң зур дошманы булган Толстойны — Столыпинның 4–5 йөз кешене асуына каршы «Не могу молчать!» («Дәшми түзә алмыйм!» — *Г.И.*) дип, дөньяны шаулатып, Русиядәге сәяси үлем җәзасына каршы бөтен дөнья балаларыны күтәргән Толстойны олугладылар. Кеше үтерүне чебен үтерү дәрәҗәсендә күрмәгән большевиклар, ун еллык гомерләре(н)дә иң азы ун миллион халыкның төрле җәза вә җәфалар берлә үлүенә вә үтерелүенә сәбәп булган большевиклар буржуа-

* Милли юл. — 1929. — № 8. — 9–13 б.

ның буржуасы булган граф Толстойны күтәрергә вә зур итәргә мәҗбүр булдылар. Ник? Чөнки Толстой Европа әфкяре гомумиясендә (җәмәгатьчелек фикерендә) шундый зур урын тотканга, аңарга хөрмәтсезлекне бөтен дөнья вәхшилек вә барбарлык (варварлык) дип аңлаячак иде. Шуңа күрә большевиклар мадамки (мадам ки, чөнки) Толстой үлгән, мадамки (шуңа күрә) Русиядә Толстой хакындагы ялганларга каршы чыгып язарга, сөйләргә имкян (мөмкинлек) юк (дип уйлаган. — *Х.М.*). Ник Толстойны ярты большевик итеп куймаска? Һәм шулай иттеләр дә.

Безнең татар коммунистларына да бит Мәскәүнең коерыгындан кулны ычкындырырга ярамый. Үз юллары юк, күзләре сукыр булганга, хәзер юлны югалталар вә адашалар. Шуның өчен аларда Толстой хакында русчадан тәрҗемә мәкаләләр яздылар. Аның рәсемнәрен төшерделәр. Үзләренең мәдәнилекләрен күрсәтергә тырыштылар. «Безнең юл» да (хәзерге «Казан утлары» журналы — аның дәвамчысы. — *Х.М.*) артта калмады. Ул да язды, сызды. Журналның 8 нче номерындагы Толстойга багышланган мәкаләнең башына «Толстой үлүгә йөз ел тулу уңае берлә» дигән хатага, Толстой 1628 (1728. — *Х.М.*) елда туды дип, ике йөз яшьле итүгә дә бәхәс итеп тормыйбыз. Коммунист булган кеше бит андый вак-төяк тарихи цифрлардан югары тора. Бигрәк тә ул татар коммунисты булса, аңарга инде ул закон язылмаган. Ләкин шулай булса да, татар мәдәнияте исеменнән сүз сөйли торганнар Толстой кебек бөтен дөнья күләмендә зур, танылган бер кеше турында бераз саграк булырга кирәк иде. Толстойның татар матбугатында бәхете бигрәк юк инде. Ул үлгән вакытларда (охранкада хезмәте өчен патша тарафыннан мөфти итдерелеп куелган, 17 нче ел ихтилялыннан соң милләтчеләр тарафыннан себереп чыгарылган, бүген большевик ЧКасында хезмәт итә торган. — *Г.И.*) Сафа Баязидов (1887–1937) (1918 елдан Петроград мәчетенең имамы. — *Х.М.*) үзенең «Нур» гәзитендә «Җуан (юан) Арыслан үлде» дип язып чыгарган иде. Ярый әле татар большевиклары берничә ел эчендә үзләренең остазларыннан үсә төштеләр. Һәр яшел каз... булмаганы кебек, һәр ләфнәк дә (?) арыслан булмаганын белгәннәр. Монысына да рәхмәт! Без Толстой хакында татар большевик малайларының Маркс әйткән, Ленин тәфсир иткән дигән лыгырдамаларына туктап тормыйбыз. Андый большевик такмазасы бит ул һәрбер эшкә, һәрбер нәрсәгә китерелә торган вә үз уе, үз фикере булмаган мескинләр өчен ясалган схоластик(а) формулалары гына. Без, Х.Вәли [Хәйреддин Вәли (1893–1969) — әдәбият галиме, шигырь белгече. — *Х.М.*] дигән әфәнденең «Толстойның татар әдәбиятына тәэ-

сире» хакындагы мәкаләләренә туктап, шуларга берничә төзәтүләр генә кертмәкче буламыз. Шуны әйтергә кирәк ки, бу егет һичбер лыгырдап тормаенча, әллә нинди ялган күзлекләр кигән булып кыланмаенча, туп-туры мәүзугъны (теманы) ала да, тәхлиленә (тикшерү-анализлауга) керешә вә бу юлда тәмамән европалы кебек обжектиф (объектив) булырга тырыша. Большевиклар арасында бик сирәк очрый торган бу ак карганың кайдан чыгуына гаҗәпсенүебезне изһар итеп (белдереп), вазыйфамызга башлыймыз. Иң әүвәл шуны әйтергә кирәк ки, Х.Вәли мәкаләсендә күрсәтелгәнчә, «Сәлимә...»не язучы Гафил бине Габдулла (ягъни Ризаэддин Фәхреддин. — *Х.М.*) берлә «Рәхмәте иляһия»не язучы Муса Бигиев арасында һичбер мөнәсәбәт юкдыр. Боларның икесе дә хәзерге көндә исән булганга, моны мәүзугы мәсьәлә иттереп торырга да урын юк. Икенчедән, «Сәлимә...»не язучы мөхәррир һичбер вакыт рус әдәбияты берлә мәшгуль булган кеше түгел. Толстойның, бәлки, һичбер әсәрене укый да алмагандыр. Аның бөтен мәнбәгъләре (чыганаклары) гарәпчә, фарсыча, төрекчә берлә бетә. Русчадан үз тәгъбиренчә «казангаласа да», болар да тарихи әсәрләр өчен генә. Шуның өчен ул затны «татар әдәбиятына толстойчылыкны кертүче» дип санау тарихин (тарихи яктан) хата. Инде Х.Вәли әфәнденең дидеге кебек, Гаяз Исхакый әсәрләренә Толстойның тәэсирләренә килсәк, монда да бик күп изах ителәчәк (аңлатылачак; ачыкланырга тиешле) нокталар (фикерләр, карашлар) бар. Миңа, гомумән, рус әдәбиятының, әлбәттә, тәэсире бик күп булгандыр, ләкин минем авызлануым рус әдәбияты берлә түгел(дер), госманлы төрек әдәбияты берләдер. Үземнең «Утыз елым» дигән хатирәмдә мин бу хакта бик озын мәгълүматларны биреп киләм. Ләкин әле ул әсәрем басылмаган булганга, укучыларга мәгълүм булмаган мәгълүматларын бераз тәкрарларга мәҗбүр булам. Әүвәлән минем «Тәгаллемдә сәгадәт...», «Кәләпүшче кыз», «Бай углы», «Өч хатын берлә тормыш» әсәрләрем рус әдәбиятлары берлә таныш булмаган дәверемдә язылган. Ул вакытта минем укыган әдәбиятым госманлы әдәбияты вә төрекчә аша тәрҗемә француз әдәбиятыдыр. Жюль Верн, Виктор Һюго, Мопассан, Доде [А.Доде (1840–1897) — «Нума Руместан», «Набоб» романнары, Тартарен турындагы трилогиясе белән мәшһүр. — *Х.М.*] вә Дюмалар берлә мин төрекчәдән таныштым. Икенчедән, «Теләнче кызы»ның басылуы бик соң булып, бигүк якын дәвердә булса да, аның минем башымда эшләнүе дә беренче дәверемдәгедер. Ул вакытта миңа иң зур тәэсир итә торган төрек мөхәррире Нәсиб Вәҗиһи бәк иде. Аның «Чубан (көтүче) кызы» дигән сентименталь әсәре миңа тәэсир итеп, минем башымда «Те-

ләнче кызы»н 1898 елларда гәүдәләндергән иде — вә шул хикәяне үземнең ул вакыттагы гадәтем буенча иптәшләремдән мәрхүм Хөсәен Ямаш, мәрхүм Хөсәен Әбүзәр, Садрый Максуди, Гомәр Тәңреколыйларга әллә ничәшәр мәртәбә сөйләгән дә идем. «Теләнче кызы»ның беренче бүлегенең язылуы да рус әдәбияты берлә бик аз таныш була башлаган дәверләремдә язылган иде. (Кулымда әсәрем булмаганга, тарихын катгый күрсәтә алмыйм. Икенче-өченчеләре — бик соң. — *Г.И.*) Шуның өчен бу беренче дәвер әдәбиятыма, гомумән, рус әдәбиятының тәэсире гаять аз булган дигән фикердәмен.

Инде минем Толстойны укуыма, сөюемә килсәк, минем Толстойны бик күп укуым хакындагы риваять вә шуңарга мәкаләдә дәлил иттереп алынган Җәмаледдин Вәлидинең Гаяз әфәндегә Толстой вә Достоевскийларның зур тәэсире күренә дигән казыяда да (тезиста да; җөмләдә дә) бик күп төзәтеләчәк нәрсәләр бар. Әүвәлән Толстойны мин бервакытта да башка рус мөхәррирләреннән артык укымадым вә аны бервакытта да «фәна фи-т-Толстой» булып (Толстойга мөкиббән китеп, аның белән онытылу дәрәҗәсендә. — *Х.М.*) сөймәдем. Мин үзем табигатем буенча бернәрсәне сөйсәм, даимән фәна фи-Аллаһи дәрәҗәсенә ирешми калмыйм. Толстой миңа һәрвакыт ят булып килде, аның чуалчык фәлсәфәсе, аның мәдәниятне инкарь итеп маташуы, аның ишан булып кылануы, аның «Kreutzer Sonate»дагы адәмнең адәмлеген инкарь иткән булып маташуы, мәраилыгы (кыланышы; төрле рәвешләргә керүе) табигатьтән бирелгән минем туп-туры иттереп уйлый торган башым вә нәселдән килгән төркчә сизүем, хис итүем берлә һичбер вакыт үзләшә, берләшә алмады. Толстойны хөрмәт итсәм, әдип ударак хөрмәт иттем. Толстойчы булмадым. Безнең арамызда ул вакыт Толстойчы диеләчәк бер кеше булса, ул да мәрхүм Хөсәен Ямаш иде. Аның мистик рухына сөйләгәне берлә кылганын һичбер вакыт бер юлга сөрә алмаган башына Толстойның керделе-чыктылы, тәүбәче, елак фәлсәфәсе хуш килә иде. Бәгъзән (кайчак) минем Толстойдан көлүемдән мәрхүм рәнҗи иде. Хосусан «Kreutzer Sonate»дагы фикерне «картлык галәмәте» генә дип каравым аны бик кәефсезләндерә иде. Достоевскийга килгәндә, бу мөхәррир кадәр миңа тәэсир итмәгән һичбер рус язучысы юк. Мин Достоевскийны сөймәгәнгә түгел, мин аңарга чиркәнмәенчә якын килә алмыйм. Аны уку минем рухымны гына рәнҗетми, ул миңа җисмани авыру да бирә. Мин аның китабы эченә кереп киткәч, үземне-үзем әллә нинди һавасыз бер бина эчендә кебек хис итәм. Аның славянча иттереп душа, душа... дип, грех дип кылануларыннан чиркәнәм. Аның мөраилыгыннан җирәнәм. Мин һичбер вакыт үземне көчлә-

мәенчә, аның бер әсәрен укып чыкканымны хәтерләмим. Хәзер Достоевский дигән сүзне ишетсәм, күңелем өшеп китә. Минем рухыма иң якын рус язучылары, иң сөйгәннәремнең берсе әле дә Тургенев, икенчесе — Чехов вә өченчесе — Гогольдер. Беренчесенең Европа мәдәнияте берлә сугарылган татар рухында мин үземне-үзем таныйм. Икенчесенең һичбер төрле славянча ялганы, риякярлеге (икейөзлелеге) берлә пычранмаган рухында үземнең тугрылык сөюемә азык табам. Өченчесенең юморында бабамыз Хуҗа Насреддиннан килгән юморчылыкта мөштәрәк (уртак) нокталар табам. Шулай булгач, Җәмаледдин Вәлидинең минем хакта «ул философ Толстойны әдип Толстойдан артык күрә» дигән сүзе минем бөтен әдәби дәверем өчен хата. Мин Толстойның «Анна Каренина», «Война и мир»ларның берәр өзеген генә дә Толстойның вак-төяк чиркәү лыгырдамаларына алыштыра торган кеше дә, язучы да түгелмен. Гомумән, минем иң нәфрәт иткәнем мөраилык (икейөзлелек) булганга, рус язучыларының иң мөраилары булган бу затларны, әлбәттә, сөя алмый идем. Шулай булгач, ничек соң фәлсәфә берлеге килгән? Әхлак, вөҗдан, намус, тугрылык вә хезмәт минем элекке әсәрләремдә маяк булып барганнар вә алар кайдан алынганнар, димәкче буласызмы? Татар хәрәкәтенең юлын күрмәгән, белмәгән кешеләр мондый ахмак сөальне бирү ихтималлары юк түгел. Ләкин безнең балалыгымыз, яшьлегемез үткән, фикерләремез, тойгыларымыз гәүдәләнгән вакытларны, мохитне белгән кешеләр мондый сөальне бирмәсләрдер дип беләм. Бирәләр икән, менә аның җавабы: ул фикер вә фәлсәфәләрне без мөстәкыйльләп (мөстәкыйль рәвештә) үземезнең остазбикә әбиләремездән, әниләремездән алдык. Без аларны әниләр, әбиләрнең «Дәртел-җалис», «Нәсыйхәтес-салихин», «Тәнбиһел-гафилин» кебек вәгазь китапларыннан, хатыннарга сөйләгән вәгазь, нәсыйхәтләреннән алдык. Без алар берлә Төркестанның инкыйраз дәверендәге тәсауф (суфичылык) әдәбияты берлә сугарылдык. Шул моральне һичбер Толстойны белмәгән, укымаган Гафил бине Габдулла үзенә бертөрле төскә кертсә, мин үзем бертөрле төскә керттем. Аны үземчә «чәйнәп», үземчә һәзм итеп (эшкәртеп), үземчә эш иттем; шуның өчен миңа Толстойның тәэсире бөтен дәверләрем өчен Тургенев, Гоголь, Чеховларныкыннан ким дип уйлыйм вә үземне һичбер вакыт «толстойчы» булу дәрәҗәсенә төшкәнемне, Аллага шөкер, белмим. Картая-картая гакыл, фикер зәгыйфьләнеп, баш эшләми башлагач, бәлки, ясап куелган, талчукта йөри торган берәр фикерне алырга мохтаҗ булырмын. Имам Әгъзам әйткән икән, әмма мин (имам мин), дигән икән, Маркс сөйләгән, Ленин лыгырдаган икән дип ру-

хан улып, фикрән кол бәндәләр кебек, бәлки, мин дә бәндә булырмын. Ләкин хәзергә әле, Аллага шөкер, үз фикеремә үзем хуҗа, үз тойгыма үзем ия. Үзем белгән юлдан үзем барыйм. Дөньяның мәгънәви талчугындагы төрле яһүди кибетләрендәге «иске»ләрне алмыйм, сатмыйм. Үземнең халкымның бөтен яңа агымнарыны гәүдәләндергән кебек, тарихын, аның иске тормышын җанландырырга сөйсәм, искелекне сөюдән түгел, халкымның «үзлегене» сөюемнән, аны эзләнүемдән генә шулай эшлим. Мин аның иске тирән катларында (чыганакларында), рус тәэсире булмаган даирәләрендә төрк-татарның «үзен», «үзлеген» табам, тапмыйм дип уйлыйм вә аны табу вә тануның урыны аның үз кырында гына мөмкин булганга күрә, Х.Вәли әфәнде кебек әдәбиятта казына торган егетләремезгә шул юлны тәүсыя (тәкъдим) итәм. Әгәр ул Идел буе әдәбиятының яңа дәверенең Төркестанның тәсауф әдәбияты берлә багланган йепләрен күрә белгән булса иде, әгәр ул безнең Идел буе төрк-татарының мәгънәви барлыкларын, морален, әхлакын, дөньяга карашын русларның тәэсиреннән башка мөстәкыйльләп тәмамән эшләнеп беткән икәнен сизә белсә иде, ул Гафил бине Габдуллаларны Толстой коерыгына тагарга мәҗбүр булмас иде. Мине дә Толстой өмәчесе итмәс иде; минем дә, Тукайның да үскән милли җимешемез икәнен ап-ачык күрер иде. Ләкин, мәгаттәәссеф (үкенеч ки), безнең тикшерүчеләремезнең иң күбесе шул тугры юлдан адашып, русларның мәшһүр Иловайскилары тарафыннан мәйданга атылган: татарның бер нәрсәсе булмаган, бер нәрсәсе юк, бер нәрсәсе дә булачак түгел; ул рус булыр өчен хәзерләнгән бер чи таслак кына дигән фикердән чыгалар да, үз бакчамызда үскән, үз малларымызның нәселене, төбе-тамырыны табар өчен күрше рус авылының түтәе бакчасында, дуңгыз аранында, чиркәвендә, кабагында танытып бетерәләр. Ничек булса да, шул чиркәүгәме, кабаккамы, җүләрләр йортынамы илтеп, татарның эшләрене эшләтеп бәйләүдә бер батырчылык күрәләр. Бу бит гыйлем, фән ягыннан бик зур хата булган кебек, бик зур реакционерлык та икәнен игътибарга алмыйлар. Шуның өчен үз халкына дошманлыкны мәсләк итеп куймаган кешеләр, коммунист булсалар да, тарихымызга, халкымызга, әдәбиятымызга, мәгънәви барлыкларымызга караганда, иске вә яңа Иловайскиларның күзлегеннән карамаенча, фәнни, гыйльми ноктадан карарга өйрәнергә кирәк. Шул барлыкларымызга Иловайскиларның сөюсөймәүләренә әһәмият бирмәенчә, үзеңдән-үзең хак, бәһа бирергә кирәк вә үз базарыңа үзең хуҗа булырга кирәк. Матди коллык никадәр начар булса да, мәгънәви коллык бит андан йөз мәртәбә начар.

# Васыятьнамә

## Гаяз Исхакый хаты

Октябрьгә кадәрге татарча гәзит-журналларны, басма һәм кульязма китапларны актарганда, Г.Исхакый (1878–1954) исеме белән еш очрашасың, аның татар мәдәни дөньясында төп фигураларның берсе булуына тиз ышанасың. 1906 елда ук Йосыф Акчура* «Казан мөхбире» гәзитендә, Г.Исхакый иҗатын күздән кичереп: «Яңа бөек истидат (талант. — *Х.М.*) туды», — дип яза. Бер елдан соң С.Рәмиев Г.Исхакыйны сирәк очрый торган бер әдип, аның булуы татар халкы өчен бик кирәк, дип бәяли. Г.Ибраһимов бу язучыны үзенең дәреслек-хрестоматияләрендә, мәкаләләрендә еш телгә ала, аны «бөек вә мөмтаз (үзенчәлекле, аерылып торган. — *Х.М.*) бер язучы» дип атый. Г.Тукай вафаты алдыннан язган шигырьләренең берсен (ул «Мөхәрриргә» дип атала)** Г.Исхакыйга багышлый. Шагыйрь, үзенең каләмдәшен, остазын сагынып, болай дип яза:

> Кайт әле монда, Ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
> Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия.***

Әмма илдә Сталин хакимияте урнашкач, татар халкы Г.Исхакый әсәрләрен укудан мәхрүм ителде, әдип исеме бары кара буяулар белән генә телгә алына башлады.

Озак еллар буе без әдәбият тарихын аның күп кенә төп ядкәрләреннән, үзәк фигураларыннан башка гына өйрәнеп һәм өйрәтеп килдек. Инде менә, ниһаять, үзгәртеп кору, демократия шартларында укучылар элек тыелган исемнәр, әсәрләр, шул исәптән Г.Исхакыйның иҗат мирасы белән дә турыдан-туры таныша башладылар.

Г.Исхакыйның (ул эмиграциядә вакытта Иделле псевдонимын да йөртә) тормыш юлы гаять катлаулы, каршылыклы һәм сикәлтәле. Ул — татар вакытлы матбугатына, реалистик әдәбиятына нигез салучыларның берсе. Татар халкының тәрәккыяте, бердәмлеге өчен көрәш — аның әсәрләрендә һәм, гому-

---

* Йосыф Акчура (1876–1935) — әүвәл Россиядә, аннан соң Төркиядә яшәгән мәшһүр дәүләт эшлеклесе, публицист. Г.Исхакый аның белән еш аралашкан.

** Өземтәләр түбәндәге җыентык аша китереләләр: Muhammad Ayaz Ishaki. Hayati ve Faaliyeti. 100 dogum yili dolayisiyla. — Ankara: Ayyildiz Matbaasi, 1979. — S. 36–37.

*** Тукай Г. Әсәрләр: Дүрт томда. — 2 т. — Казан, 1976. — 288 б.

мән, эшчәнлегендә үзәк мотив. Әмма гомер агышы, язмыш еш кына көтелмәгән борылышлар, адымнар ясый. Патша хакимиятенә каршы милли-азатлык көрәшенең алгы сафында торган, үзенең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге өчен берничә мәртәбә төрмәләрдә утырган Г.Исхакый инкыйлабтан соң башка мәмләкәтләргә китәргә мәҗбүр була, үзенең 35 ел гомерен чит илләрдә уздыра һәм җисмани яктан мәңгелеккә шунда торып та кала. Әдипнең кызы, профессор Сәгадәт Чагатай болай яза: «Ул хәяты буенча Идел-Урал фикере илә яшәде... Соңгы сулышынача шуңа хезмәт итте. Милләткә хезмәт аның өчен яшәү чыганагы булды».* *«Үз мәмләкәтемдә булсам, тагын да әйбәтрәк әдәби әсәрләр биргән булыр идем»,* — ди әдип вафатына өч көн кала. Үкенечле сүзләр, гыйбрәтле язмыш...

Г.Исхакый 1919 елның ахырларында Себер аша Россиядән чыгып китә. Париж, Варшава, Берлин, Хельсинки, Токио, Харбин, Мукден, Лондон, Истанбул, Анкара һ.б. — менә аның яшәгән, булган калалары. Эмиграциядә ул читтәге татарларның юлбашчысы, мәшһүр әдибе буларак таныла, гәзит-журналлар чыгара, күпләгән әдәби әсәрләр иҗат итә, актив иҗтимагый, сәяси эш алып бара.

Г.Исхакый аеруча Финляндия белән тыгыз бәйләнешләрда торган. Биредә аның инкыйлабка кадәр үк булганлыгы мәгълүм, Октябрьдән соң да ул бу илгә кат-кат килә, андагы татарлар белән очрашып, хәбәрләшеп тора. Биредә аның әсәрләре яратып укыла, сәхнәләштерелә. Аеруча әдипнең биш пәрдәлек «Җан Баевич» драмасы популярлык казана. Аның редакциясендә Берлинда чыккан «Яңа милли юл» журналы (1928–1939) фин татарлары арасында киң тарала. Аның төпләмнәре хәзер дә Финляндиядәге аерым шәхси китапханәләрдә очрый. 1937 елны Берлинда Г.Исхакыйның «Дулкын эчендә» дигән биш пәрдәлек драмасы басылып чыга (әсәр 20 елларда ук иҗат ителгән). Аның титул битенә «Тампере милләтчеләренең һиммәте (теләге, тырышлыгы. — *Х.М.*) белән нәшер ителәдер» дип язылган.

Финляндиянең өлкән буын татарлары хәзер дә Г.Исхакыйны яхшы хәтерлиләр, аны олылап искә алалар. Пенсионер Мөнир әфәнде Җамалетдин болай ди: «Мин Гаяз Исхакый белән Суомида да, Төркиядә дә кат-кат очраштым. Ул бик татар җанлы иде. Күп кенә татарлар төреккә авышты, ә ул татар булып

* Казан утлары. —1974. —12 сан. — 23 б.

калды. Шуңа күрә аңа Төркиядә, бигрәк тә гомеренең соңгы елларында авыр булды... Истанбулда ул сабан туйлары оештыра иде. Минем дә аларда катнашканым булды. Гаяз әфәнде уртача гәүдәле, ачык йөзле, сүзгә тапкыр кеше иде. Урысчага, аеруча алманчага бик оста иде». Мөнир әфәнденең туганы Әнвәр ага 20 нче елларда Берлинда укыган. Шул вакытта ук ул Г.Исхакый белән аралаша. Алга таба да аларның мөнәсәбәтләре өзелми. Әнвәр аганың һәм аның мөлаем хатыны Галия ханымның әдип турында сөйләр сүзләре күп. «Гаяз әфәнде сөйләргә бик оста, гел авызына каратып тота иде», — ди Галия апа. Хельсинкида яшәүче Халидә апа Таһир да (заманында ул Муса Бигиевта укыган) Г.Исхакый белән күп мәртәбәләр очрашкан. Анда әдипнең фотолары, истәлек дәфтәренә теркәлгән язмалары саклана.

Мәгълүм булганча, Финляндия татарларының бер өлеше (якынча 150–160 кеше) Тампере каласында яши. Биредә татар телендә мәҗмугалар, китаплар нәшер кылынган, әдәби-музыкаль кичәләр оештырылган (мәхәллә рәисе Әсәд ага Байбулат җитәкчелегендә биредә хәзер дә мәдәни чаралар үткәрелә). Г.Исхакый бигрәк тә шушы Тампере татарлары белән якын мөнәсәбәтләрдә торган, хатлар алышкан. Шундый хатларның берсе имам Хәбибрахман Шакирга (1903–1975) адресланган. Үләренә өч көн кала (ягъни 1954 елның 19 июлендә) язылган бу хатның төп эчтәлеге инде аерым галимнәрнең хезмәтләре аша фәнгә таныш. Биредә Г.Исхакый үзенең авыр хәлен (берничә көннән үләчәген) искәртә, үзенең иҗтимагый эшчәнлеген кыскача гына бәян кыла. «*Мин,* — ди ул, — *бөтен гомерем буена төрк-татар халкының бәхете, иркенлеге өчен көрәштем... Тәңре сезләргә Ватаныбыз Идел-Урал азатлыгын күрергә насыйп итсен*».

Г.Исхакыйның икенче бер мөһим хаты Тампере кызы Халидә Вафинага адресланган. Ул 1954 елның 12–18 апрелендә Истанбулда язылган. Хат шактый зур күләмле, эчтәлекле. Әдип юкка гына аны «мәгънәви васыятем кебек калсын» дип әйтмәгән. Язма шәхси хат кысаларыннан чыгып, киңрәк катлау укучыларга да адресланган. «Мин үлеп китсәм, форсаты килгәндә, бу хатымны бөтен халыкка бер мәртәбә укыгыз», — дигән искәрмә дә әнә шул хакта сөйли.

Хатның төп эчтәлеген ярты гасырдан артык әдәби, мәдәни, иҗтимагый, сәяси, халыкара тормышның үзәгендә кайнаган иҗат кешесенең шәхси уйланулары, карашлары, гомер сабаклары тәшкил итә. Аларның инде кайберләре безгә, белгечләргә, әдипнең

мәкалә-хезмәтләре һәм китаплары («Максатымыз», «Идел-Урал» һ.б.) аркылы билгеле бер дәрәҗәдә таныш. Әмма биредә Г.Исхакыйның татар халкының тарихи язмышы, хәзергесе хакындагы уйланулары бергә тупланып, система рәвешендә бирелгән. Аларда субъектив, бәхәсле фикерләрнең булуы табигый. Әмма шуңа да карамастан, бу хат фән өчен мөһим бер чыганак булып тора. Ул, бер яктан, әдипнең тормыш юлын, иҗат мирасын ачыкларга ярдәм итсә, икенче яктан, төрк-татар халкы тарихын, шул заманда илдәге иҗтимагый, сәяси хәлне ачыкларга да булыша.

Хатның адресаты Халидә Вафина һәм аның әти-әнисе Зиннәтулла ага (1886–1941), Мөшфика апа (1886–1966) Г.Исхакый белән күптәннән таныш булалар. 1951 елда Халидә туташ, Истанбулга баргач та, әдип белән очраша. Шул вакытта Г.Исхакый кызның хатирә дәфтәренә түбәндәге юлларны язып куя: *«Илемезнең хөрмәтле гаиләләреннән Зиннәтулла Вафа, Мөшфика Вафа ханымның кызлары Халидә туташның атасы, анасы кебек туры дөрес булуын күреп сөендем. Халкымызның киләчәге уңышлы чыгачагына шундый йитешкән кызларның Финляндия кебек илемездән ерак йирләрендә үсүе, зураюы зур сөенечле галәмәттер. Тәңре шундый яшьләремезгә, хосусан Халидә туташка шәхси тормышында бәхетле булып, милләтенә файдалы булуны вә бик күп төрк-татар яшьләренә үрнәк булырлык хәерле эшләр эшләвене насыйп итсен. 1951 ел, 28 июнь. Рамазан ае. Истанбул».*

Халидә апа хәзер дә Тампереда яши. Туганнары, Финляндиядәге милләттәшләр Халидә апаны бары уңай яктан гына телгә алалар, аның телебезне, мәдәниятебезне саклауда, үстерүдә игелекле эшләр башкаруын сөйлиләр. Димәк, ул әдипнең өмет-ышанычларын аклаган.

Хат, Халидә апа Вафинаның үтенече белән машинкада күчерелеп, 1966 елда Тампереда берничә данәдә күбәйтеп төпләнгән. Төпләмнең тышлыгында Г.Исхакыйның 1910 еллардагы фоторәсеме урнаштырылган. Аның астында «Мәрхүм Гаязның Халидә туташ Вафинага язган иң соңгы һәм иң мөһим мәктүбәләрендән» диелгән. Ә инде беренче битендә хат алдыннан мондый сүзләр бар: *«Идел-Урал төрк-татарларының атаклы лидеры вә өнле (исемле, мәшһүр. — Х.М.) мөхәррире вә әдибе мәрхүм Гаяз Исхакыйның иң соңгы вә иң мөһим бер язуы».*

Төпләмнең 9 нчы битендә берничә сүз танылмый. Хатның текстын без укучыларга кыскартусыз тәкъдим итәбез. Орфо-

графия дә, нигездә, үзгәрешсез калдырылды. Бары аерым урыннарда гына хәзерге язылыш алынды (мондан — моннан, чыккайлар — чыкканнар һ.б.).

Г.Исхакый «төрек» сүзен традицион мәгънәдә куллана. Хәзер исә бу сүз, кагыйдә буларак, Төркия кешеләренең атамасы рәвешендә алына. Ә башка төрки халыкларга карата «төрки» сүзе кулланыла. Моңа кадәр безнең илдә «милләтче» сүзе, нигездә, тискәре мәгънәдә йөрде. Хат авторы исә аңа патриот, үз милләтен яратучы, аның тәрәккыяте өчен көрәшүче эчтәлеген сала.

Бу төпләмне миңа Хельсинкидагы мәхәллә архивыннан «Ислам җәмгыяте»нең рәисе Окан әфәнде Таһир һәм сәркатибе Хөсәен әфәнде Хәмидулла бирде. Моның өчен аларга ихлас рәхмәтемне белдерәм.

*1990*

## **Мәгънәви васыятем кебек калсын**

*Гаяз Исхакый*

*Истанбул, 12.04.1954*

*Хөрмәтле Халидә туташ! Сезнең мәктүбегез килгәнгә шактый вакыт кичсә дә, күндергән бүләгегез бүген-иртәгә килеп чыгар, бердән (бу урында «берьюлы» мәгънәсендә) җавап язармын дип тордым. Пакет өч-дүрт көн әүвәл генә миңа китерелеп бирелде. Бу юлы мәшәкате-фәләне булмады. Мәсрәфе (масраф — чыгымнар) дә күп чыкмады. Ялгыз өч лира 31 грош (Төркиядә акча берәмлекләре. Бер лира 100 куруштан гыйбарәт) кына алдылар. Маегыз бик урынына төште. Юлда бик озын (бу очракта «озак» мәгънәсендә) йөргән булса да, бер дә бозылмаенча килеп чыкты. Хәзер, шул майны ашап, сезгә рәхмәт укып ятам. Моңгынча монда гомум Төркиядә һавалар бик суык булып килгәнгә, андый май пакетлары бозылырга вакыт таба алмады. Моннан соң инде, әгәр дөньяның төзелеше тәмамән юлыннан чыкмаган булса, Төркиядә яз килергә вакыт. Бу ел Төркиядә кыш инде күптән алты аен тутырып, җиденче айга керде вә халык өчен бик зур авырлыкларга, санап бетермәслек хасталыкларга сәбәп булды. Бүген дә әле тыш бер яктан бик суык, шималь (төньяк) җилле суык; бөтен*

*кеше кышкы киемдә калтырана-калтырана йөри, утыны, күмере булса, көн буе мичне яга. Безнең кебек картлар, көннәр буе ятагыннан борынын чыгарырга куркып, юрганы, өстенә өелгән төрле сәләмә-сүләмә киемнәре астында борылып ята. Мин дә менә бүген, хезмәтче хатыным килмәгәнгә, иртә торып, мең бәла белән мичемне яктым. Сезнең май берлә, бер ярым пискви (бискви(т) — печенье) берлә ике финҗан (чынаяк) төрек каһвәсе эчтем дә, сезгә шул хатны язарга утырдым. Миндә аш үтмәү, үткәне сеңмәү авырусы дәвам итә. Соң атналарда ул хасталык тагын көчләнде. Ашаган нәрсәмне бик тиз косам. Ашказаным бик авыртып, ятакка ятарга мәҗбүр булам. Элгәре шурпа, чәй, сөт кебек сыек ашлар болай борчымый иде. Хәзер алар да, бик азлап кына алынганда гына, ашказанымда кала алалар. Докторлар гасабили (ялкынсыну; невроз) бар, нервлар бик бозык, диләр. Никадәр дөрестер, Аллаһ белә. Ләкин көннәр ачык булып, дуст-ишләр белән сөйләшеп утырганда, мәҗлесләрдә ашаганымның күбесе сеңеп китеп, мине борчымый. Хәерле булсын, тәкъдирдә ни булса, шул булыр.*

*Мин беренче мәртәбә Финляндиягә 1908 елның ахырында яисә 1909 елның башында берничә иптәш берлә Иматраны (Финляндиянең көньяк-көнчыгышындагы шәһәр. Ул Выборгтан (Випуридан) ерак түгел) күрергә килдем. Өчдүрт көн Иматрада калдык. Тирә-юньдәге берничә авылга да бардык. Бер йирдә фин театрысыны тыңладык (театрын карадык). Ул вакытта миңа фин халкы фәүкылгадә (гадәттән тыш) яхшы тәэсир калдырды, фин театрысыннан бернәрсә дә аңламасак та, фин теленең һармониясе (гармониясе), сүзләренең, тавышының агышы мине хәйран калдырды. Миңа фин сәхнәсеннән сөйләнгән сүзләр минем ана телемдә сөйләнә кебек күренде. Аңламавыма, ялгыз колагым яхшы ишетерлек озакта (ераклыкта) булганлыгына кебек хис быракты (җиткерде; бирде; китерде). Бу хис миңа соңыннан япун халык җырларының җырлануында да, мангулларның озактан көйләнүендә дә, курияләләрнең курай кебек бернәрсә уйнауларында да гайни (шундый; тәңгәл; охшаш) тәэссоратны бирде. Мин (миңа. — Х.М.) ул вакытта ук бу халыклар моннан өч мең елмы бер төптән чыкканнар икән дигән фикерне бирде. Халыкларның бик яраткан культур васиталарының (бәйләныш) иң зурысы вә иң озын яшәүчесе — телләре вә көйләредер.*

*Тормышларының башка яклары күршеләренең, икълимнең (климат), диннәрнең тәэсире берлә, төрле-төрле юллар алып, искелектән озаклашалар. Хәтта бер-берсенә ят халык булып та күренәләр. Мәсәлән, Балкандагы болгарлар безнең Идел-Урал буендагы Болгар дәүләтеннән Балканга күчеп килгән гаскәриләр вә мөһаҗирләрнең балалары булдыклары хәлдә, күрше милләтләре — юнаннар, итальяннарның тәэсире астында христианлыкны кабул итеп, күрше славяннар, хосусан, серблардан славян телен алып, ят вә безгә дошман бер халык булып өлгергәннәр. Ләкин халык җырларында, көйләрендә иске уртак мотивларын бүгенгә кадәр саклаганнар. Менә бу халыкларны, бердән, беренче корун (гасыр) — икенче корун иранилары (ул вакытта иң мәдәни халык булганнар) Туран халкы дип исем биргәннәр. Бу халыкларның телләрендә уртак тел кагыйдәләре бүгенгә кадәр саклануыннан (мәсәлән, аһәң кагыйдәсе, сүз агышындагы һармони* ) боларның телләренә Аурупа галимнәре Урал-Алтай телләре дип исем биргәннәр. Маҗар сәясиләре (венгр политиклары), кыйсмән (өлешчә) фин сәясиләре дә, пангерманизм, панславизмга каршы куяр өчен, пантуранизм дигән бер культураль-сәяси агым да мәйданга чыгарырга маташтылар. Моның төрк илләрендә дә бер вакытка аз-маз тәэсире булды. Ләкин бер тарафтан төрекләр, икенче тарафтан (яктан) япуннар бу агымны тотмаганга, бу агым пангерманизм, панславизм кебек куәтләнеп китмәде. Китә алмады. Хәзерге дәвердә тәмамән үле туган бала халене алды. Бу эштә төрек кабиләләренең моннан берничә гасырлык сәясәттән аерылып китүләре аркасында килгән бер-берсенә ышанмау, япуннарның үзләрен, курияләрен (ягъни кореялыларны. —* Х.М.*) мангулларга каршы югары бер халык дип карап, бу озак кардәшләренә йүксәктән (түбәнсетеп, кимсетеп) мөгамәлә итүләре, аларны икенче, өченче дәрәҗә халыклар кебек караулары зур роль уйнады. Бу көн пантуранизм тарихка карышкан сәяси һичбер көчкә таяна алмаган әдәби бер тәгъбирдән башка бернәрсә түгелдер. Ләкин халыклар да үзләренең озак вә якын кардәшләрен һаман эзләүдәдерләр. Хосусан күрше халыклардан золым күргән милләтләр бу эштә үз-*

---

* Биредә сүз сингармонизм хакында бара.

*ләренә ярдәмче кардәшләрен эзлиләр. Төрк халкының таралып киткән кабиләләре арасында урыслардан бертуктамый золым күргән Идел буе төрк-татарында беренче буларак якын кардәшләрен эзләү, уртак бер көч ясап, урысларга каршы тору хисе уянадыр. Бу хисне кара халык төрек падишаһларыны үзенең Казан ханлыгы вакытында дин башы, хәлифә дип тануыннан калган дини хис берлә милли хисне берләштереп, Төркия солтаннарыны бик зур көчле дәүләт дип уйлап, күңеле берлә алардан котылу ярдәмене көтәләр. Вакыт-вакыт хаҗилар аркылы Истанбулга урыслардан шикаять (жалоба) кәгазьләре күндерәләр, ярдәм өмид итәләр. Кайвакытлар урысны җиңеп булмый инде, дип, милләтне, динне саклау нияте берлә авылы-авылы Төркиягә һиҗрәт итеп (күченеп) китәләр. Бәрәкәт бирсен, Төркиядәге тормыш шартлары безнең халыкның Идел буенда үзе төзегән мәдәни сәвиядән (дәрәҗә, югарылыктан) бик түбән булганга, бу меңләп-меңләп киткән мөһаҗирләр (күчүчеләр) Төркиянең сатма (сатлык; изү; деспотизм) хасталыгыннан бик күп кардәшләрен, якыннарын үле итеп калдырып, йөзләп-йөзләп элекке илләренә — Идел буена качып кайталар вә шуның аркасында, Кырымның башына килгән, туган илен бушатып, урысларга мең еллык туфракларын бушлай биреп китү бәласеннән*, безнең Идел-Урал сакланып каладыр. Идел буеның укыган халкы, бигрәк тә дин галимнәре, күзе ачык сәүдәгәрләре тәмамән башка юл тоталар. Алар Сибириядәге, Төркестандагы, урыс губерналарындагы ана иленнән (туган иленнән) озаклашып калган төрк-татар халыкларына, диндә, телдә берлекне алга сөреп, бер милләт итү юлыны тоталар. Ана илдә — Казан әтрафында әллә никадәр мәдрәсәләр мәйданга китерәләр. Алардан һәр елны меңләп-меңләп мулла, мөәзин, мөгаллим вә укытучы булырлык шәкертләр йитештереп, боларны бөтен күрше илләргә мөәзин, мөгаллим итеп күндерәләр. Урыс эченә (урыслар яшәгән җирләргә) байларымыз мәсҗедләр салып, андагы халкымызны да сакларга тырышалар. Бер мәдрәсәдән, бер системлы укудан чыккан төрле кабиләләрнең башкорды, типтәре, мишәре, ка-*

* Мәгълүм булганча, XVIII гасырның ахырларында Кырым Россия тарафыннан яулап алына. Шул вакытта Кырым татарлары бик күпләп Төркиягә күчеп китәләр.

*занлысы (ягъни иске болгар-хәзәр балалары) халыкны бертөсле дини хисләрдә тәрбия итеп киләләр. Бу эш элекке Казан ханлыгының даирәсендә булган халыклар арасында бик тиз эшләнгәч, Идел буе мөнәүвире (зыялы, укымышлысы) күрше казакъ, кыргыз, төркестанлы кабиләләрне гайни юлдан милли тәрбия системына алырга башлыйдыр. Ләкин Идел буе мөнәүвиренең бу хәрәкәтене урыс хөкүмәте бик тиз сизеп ала да, Русия эчендә бөтен халыкның дүрттән берсен тәшкил иткән төрк гонсыры (кавеме) берләшеп, урыс хөкүмәте, урыс мөнәүвиренең бу халыкларны урыслаштыру сәясәтенә каршы зур бер куәт берлә чыгачагыны күреп, бик тиз вә бик каты тәдбир аладыр (тиешле чаралар күрә). Төркестан, казакъ, кыргыз илләрендә, Казанда, Казан әтрафында укыган мөгаллимлек, имамлык вә мөәзинлек итүне, Идел буеның сәүдәгәренә Төркестанда йорт-туфрак алуны мәнгы итә (тыя), казакъ-кыргызның буш сәхраларына Идел буенда йирсез-сусызлыктан аптыраган төрк-татарларга күчеп баруга каршы законнар чыгарып, казакъ-кыргыз сәхраларына миллионлап урыс мөһаҗирен йирләшдерәдер. Казакъ-кыргыз арасында Идел буе төрк мөнәүвиренә мөгаллимлек, муллалык итүне дә тыядыр. Ләкин Идел буе мөнәүвире, Идел буеның аңлы сәүдәгәре үз илендә — Казан, Оренбур, Уфа, Троицк, Кызылъяр кебек шәһәрләрдә — бик күп мәдрәсәләр ачып, аларга йөзләп-йөзләп казакъ, кыргыз шәкертләрен ашатып-эчертеп, укытып, бу халыклардан мөгаллимлек, муллалык кадрулары (кадрлары) хәзерләвендә дәвам итә. Яз көннәрендә, мәдрәсәләр тәгътыйль (каникуллар) булгач, меңләп Идел буе шәкертләре казакъ-кыргыз сәхрасына йөрүче вакытлы мөгаллим, мулла булып, вак сәүдәгәр сыйфатында күп вакытлар кыргыз куйунларын (куйларын) көтүче булган булып, бу кара халыкны агартырга хезмәт итәдер. Төркестанга Идел буе мөнәүвиренең мәктәп ачуы(на), мөгаллим булуына каршы урыс хөкүмәте бик каты тәдбирләр алып, андый мөгаллимнәрне бик тиз тотып япканга, йирле халыкны да шундый Идел буенда хәзерләнгән мөнәүвирне мөгаллим итеп китергән өчен бик каты җәзаландырганга, Идел буе мөнәүвире Төркестан өчен яңа план татбикъ итәргә (корырга, яраклаштырырга) башлый. Ул ир мөгаллимнәр йиренә (бу очракта «урын» мәгънәсендә) мәктәптә йитешкән Идел буе мөгаллимәләр, кызлар вә хатыннарны Төркестанга күндерә башлый. Аларны, урыс полици-*

*янең дикъкатеннән озак (ерак) тотар өчен, күп вакыт йирле төркестанлы берлә, ялгандан булса да, өйләнгән итеп күрсәтеп, Идел буе мөгаллимәсенә төркестанлы сыйфатыны бирәдер. Кайвакытларда бу мөгаллимәләр чынлап та төркестанлы берлә өйләнеп китеп, гайни юлдан хезмәтне дәвам иттерәдер. Бу эшләр XIX гасырның соң чирегендән башланып, XX гасыр башларында бик киң булып китәдер. 1905 елында урыс гаскәре япунларга каршы бик каты җиңелгәнгә, урыс эчендә баш күтәрү, ихтилял (чуалыш) башланадыр. Урыс хөкүмәте 1905 елның 17 октябрендә парламентлы идарә вәгъдә итәргә, матбугатка азмаз хөррият бирергә, төрле дин халкыны, шулар арасында без мөселманны чукындырып, урыс ясауны яшерендән йөртергә мәҗбүр була. Матбугат хөрриятеннән файдаланып, Идел буе төрк-татары үз шәһәрләрендә бик күп гәзитләр, мәҗмугалар чыгарырга башлый. Бу гәзит вә журналларны үз илләрендә гәзит вә мәҗмуга чыгара алмаган төркестанлы, казакъ-кыргыз арасында меңләп-меңләп тарата. 1905 елга кадәр бөтен Идел-Урал тупрагында бер гәзиткә дә, бер журналга да рөхсәт бирелмәгән, ялгыз Бакчасарайда Исмәгыйль бәк атналык «Тәрҗеман» гәзитен чыгара иде. Идел-Урал милләтчесе Русиягә мәхкүм (буйсынган) утыз миллионлы бер төрек гөруһын (халкын), фикердә, телдә, сәясәттә берләштереп, зур бер сәяси куәт ясарга сызганып тотына. Шул мөкаддәс эшләрнең башлануында, Аллага шөкер, мин дә шәхсән роль алам. Бөтен яшьлек куәте, иман батырлыгы берлә милли тартыш мәйданына атылам. Шул эшне вакытында башлый алып, бүгенге көнгә кадәр дәвам иттерә алуым өчен үз-үземне бәхетле саныйм. 1906 елны Русия парламенты — Думага сайлау була. Бу эштә дә Идел-Урал төреге беренче рольне уйнап, бөтен мөселман депутатларыны (кырыкка якын) берләштереп, мөселман фракциясе кора. Вә бөтен төрк өлкәләренең сәяси эшләрен бер мәркәздән алып барырга тырыша. Рус хөкүмәте бу берләшүдән курка, Идел-Уралдагы гәзит вә мәҗмугаларның күбесене яба. Бик күп мөнәүвирне Себергә сөрә. Шулар арасында мин дә өч мәртәбә төрмәдә утыртылып, 1907 елында Архангел вилаятенә (губернасына) сөргенгә җибәреләм. Шул арада яңа бер тарихи вакыйга мәйданга килә. Төркия хөкүмәте дә мәшрутиять (конституция) дәверенә керә. Төркиядә дә матбугатка хөррият бирелә, безнең гәзит вә мәҗмугалар Төркиягә сәрбәст (ирек-*

*ле, иркен) кергән кебек, төрек матбугаты да безнең илләргә сәрбәст керә, фикерләр якынлаша. Төрек культур берлеге агышы мәйданга туа. Бу яңа җәрәянның (агым, юнәлешнең) Төркиядә туурына безнең илдәшемез Йосыф Акчура беренче рольне уйный. Идел буе матбугаты да төрек берлеге җәрәяныны кабул итә. Йосыф Акчураның Истанбулда корган «Төрек йорды» мәҗмугасы оренбурглы миллионер Мәхмүд бәй Хөсәеновның (мәшһүр татар бае, меценат) акчасына чыга вә «Төрек йорды» мәҗмугасы Төркиядән артыграк безнең Идел буенда укыла, тәк-тук (бераз, аз-маз) Төркестанда да укыла. Ул дәвердә Идел буе мөхәррирләре Төркестанда «Тәрәкъкый» (прогресс) исемендә бер гәзит чыгара башлыйлар. 1910 елларда Идел буенда бик күп матбагалар корылып, бик күп китап мәгазәләре (кибетләре) ачылып, Идел буе мөнәүвире үзенең мәдәни юлбашчылыгыны Төркестан, казакъ-кыргызлар илләрендә, Сибирия сәхраларында дәвам иттерә. Төркия төрекчеләре берлә фикерән (фикердә) якынлаша. Ягъни Төркияне идарә итүче Тәлгать, Әнвәр пашалар кебек идеалист адәмнәр берлә фикердә берләшә. Урыслар, бу хәрәкәткә пантуркист исеме биреп, шул эшнең башында йөргән без мөнәүвирләрне төрлечә җәзаландырып килсә дә, милли хәрәкәтне туктата алмый. 1914 елда башланган беренче дөнья сугышына кадәр бу хәл шулай дәвам итеп килә. Төркия Русиягә каршы сугышка кергәч, Идел буе төреге 17 мең төрек гаскәри әсирләренә химая итә (ярдәм итә), аларны ачлыктан, үлүдән коткара. Кием бирә, Мәскәүдә безнең корган яшерен Кызыл Ай җәмгыятемез бик күп (берничә йөз) әсир төрек забитларын (офицерларын; гаскәриләрен) Иран аша Төркиягә качыра. Бу эшләрдә мин тагын зур авырлыкларга очрыйм. Мәскәүдә чыга торган «Ил» гәзитем кафкасларны котырту сылтавы берлә (аҗарлар мәсьәләсендә) хөкүмәт тарафыннан ябыла. Аннан соң чыгарылган «Сүз» гәзитем, төркестанлыларны котырта дип (Җизак мәсьәләсендә), ябыла. Вә миңа гәзит вә мәҗмуга чыгарырга мөсагадә (рөхсәт; мөмкинлек) ителми. Бервакыт мине, төрек җасусы (шымчысы) дип, диване гаскәригә (хәрби трибуналга) мәхкәмәгә (судка) дә бирделәр. Әгәр 1917 ел ихтилялы башланмаса иде, бик ихтимал, мине үтерәчәкләр иде. Большевик дәвере ничек дәвам иткәне үзегезнең күз алдында булганга, аны үзегез дә беләсез.*

*Инде килик безнең Идел-Урал халкына. Болар төрек-*

*ме, татармы? Идел буенда милади бишенче гасырда Болгар, Хәзәр дәүләтләре корыла (VI—VII гасырларда төзелә). Бу ике дәүләтнең бөтен халкы төрк нәселеннән. Болар, ул вакыттагы Аурупа берлә Кытай арасындагы сату-алу юлында зур роль уйнаган Идел елгасының тынычлыгын саклап, зур мәдәни бер мәмләкәт булып, сигез йөз елга якын мөстәкыйль яшиләр. Болар тукыз йөз егерме икенче (922 нче) елда ислам динен кабул итәләр. Исемнәре болгар, телләре төркчә. XIII нче гасырның әүвәлге чирегендә Идел буена Чыңгыз гаскәре егерме төмән (ун мең кешелек гаскәр) берлә килеп, Болгар илене үз мәмаликына (мәмләкәтенә) куша. Бу егерме төмәннең күбесе Идел буенда утырып кала. Боларның 18 төмәне төрле кабилә исемендә йөргән төрекләр иде. Ике төмәне татар исемендә йөргән мангуллар иде. Чыңгыз үзе татар, янындагы зур түрәләре татар булганга, урыслар да килгән халыкка һәммәсенә бердән «татар» исеме бирәләр, алардан ишетеп, аурупалылар да безне татар дип йөртә башлыйлар. Ләкин бу ике төмән, татар-төркләр арасында бик тиз телләрен югалтып, диннәрен онытып, төркләр арасында эриләр. Мөселман диненә керәләр. Шуннан безнең ни дәрәҗәдә төрк, ни дәрәҗәдә татар икәнемез үзеннән-үзе мәгълүм буладыр. Без Идел-Урал халкы — төркләрмез. Төрек милләтенең төрле кабиләсеннән килгән халыклар өстенә безнең эчемездә бернечә процент мангуллар, калмаклар (калмыклар) һәм дә бернечә процент фин-угор халыклары, мукшылар, арлы (удмуртлы), марилар, бераз да урыслар эреп киткәннәр. Ләкин бу халыклар арасында иң зур күпчелек, иң мәдәни гонсыр (биредә: өлеш, компонент) шул төрек-болгар ханлыгыны сигез гасыр алып барган болгарлар булганга, бөтен халкымызның күңелендә төрклек хисси хаким (хисләрне биләүче) булып килә. Бүген үзен төрек дип йөргән госманлы төрекләреннән, Төркестан вә Кафкас төрекләреннән төреклек каны һәммәсеннән бездә артыграк. Маҗарларның (мадьяр, венгрларның) туранчы галимнәре Төркиядә, Төркестанда, Идел-Уралда безнең халыкның каныны тикшергәннәр. Аларның тикшерүләренең нәтиҗәсен миңа туранчы бер маҗар галиме шулай аңлатты: Идел буендагы халыкларда Туран каны 96%, Төркестанда 50—60%, Төркиядә 16%, Кафкас, хәтеремдә калмаган, аларда 50% тан түбән. Ләкин тарихымызның китеше аркасында, бу зур төрк дөньясы*

*бик киң йир йөзенә таркау хәлдә йирләшкән булып чыгалар. Хосусан, урыс дәүләте ныгып җиткәч, бу халыкларның арасына әллә никадәр урыс мөһаҗирләре тутырып, бер-беремез (и)лә корыдан [коры җир (?); турыдан-туры (?)] бәйләнуымызны кисәләр. Төрле дини мәзһәбләргә аерылу Иран-Кафкас төркләренең шигый булып, Төркия төрекенең сөнни мәзһәбендә булуы дини мәдәниятне, дини бәйрәмнәрне, дини гореф-гадәтләрне бер-берсеннән аера. Надан галимнәр(нең) ике арага дошманлык орлыгы чәчүе, бу ике мәзһәбтәге мөселман төрк халыклары арасында бик күп канлы сугышлар чыгарып, араны бик каты бозалар. Бу кардәш гаугасыннан дошманларымыз, аурупалылар, хосусан урыслар бик оста файдаланалар. Төркестан төрекләренә Иранның күрше булуы вә Иранның Урта гасырда мәдәният ягыннан өстен булуы, Төркестанга төрле юллардан шигый фарсыларының күчеп йирләшүе Төркестанның хакыйкый төреклек йөзене боза, аларның шәһәр халкы әхлак җәһәтеннән бик түбән булган фарсыларның бик күп начар гадәтләрен, ялганчылыкларын, мөраилыкларын (икейөзлелек) алалар. Фарсылардан әфьюн куллану, авызына тәмәке салу кебек милләтне җисмән вә рухан (тән һәм рухи яктан) зәгыйфьләтә торган хасталыкларга шәһәр халкы мөбтәля (дучар) буладыр. Мөтәгассиб (надан; фанатик) муллалары халыкның яртысы булган хатыннарымызның, бер өлешене аналарымыз, бер өлеше апаларымыз, кызларымыз икәнене игътибарга алмаенча, хатыннарымызны бөтен мәдәни хокуклардан мәхрүм итеп, коллык дәрәҗәсенә иңдерәләр вә аларны ятак такымы (әйбере), мендәр-юрганның бер өлеше хәленә китерәләр. Нәтиҗәдә балалар тәрбиясе бик начар юлга куеладыр. XX гасырда бу мәгънән (чыннан да) таркаулашкан, җәгърафый яктан бер-берсенә озаклашкан бу төрк өлкәләренең мөнәүвирләре, һәр тарафтан дошман куәтләренең, хосусан урысларның һөҗүменә мәгъруз («дучар» мәгънәсендә) калдыкларыннан берләшү кирәклеге канәгатенә киләләр. Ләкин болар халыкның кечкенә зөмрәсе (төркеме) генә булганга, киң халыкны аркасыннан йөртә алырлык зур бер куәт эзләргә мәҗбүр була. Бу куәтнең мәгънәвисе һәм төрек илендә, аз-маз булса да, мондый таркау халыкны берләштереп, бер сәяси көч хәленә китерүгә бу көч кенә җитмидер. Зур бер мадди көчкә, дәүләт куәтенә ихтыяҗ бик каты сизелә, алман мил-*

*ләте кебек тирән мәдәниятле бер таркау халык та Бисмаркның[*] дәүләт куәтене кулына алуы аркасында гына берләшкәнгә, безгә дә шундый берләштерүче бер дәүләт куәтенә ихтыяҗ беренче мәртәбә фарыз бер эш булып чыга. 1908 елдагы Төркиядәге иттихаде тәрәккъкый (тәрәккъкыять оешмасы) агымы, аларның Төркия идарәсенә кулга алулары безгә үземезнең үлчәвемездә бер Бисмарк хөкүмәте бирелә кебек хис тудыра. Без дә шуңарга сөенеп, төрле төрек илләренең төркчеләре Истанбулны кыйбла итеп эшкә башлыймыз. Хосусан без, Идел-Ураллы, бу эштә Русиягә мәхкүм (буйсынган) төрк илләре арасында беренчелекне алып барамыз. Ләкин дошманнарымыз, хосусан инглизләр, бигрәк тә урыслар, безнең бу берлек юлымыздан фәүкылгадә куркалар. Иттихаде тәрәккъкыйнең идарәсендәге төркче Төркиягә каршы кылмаган интригаларын калдырмыйлар. Беренче дөнья сугышында гарәпләрне дә котыртып, Төркияне җиңәләр вә Төркияне өченче, дүртенче дәрәҗәдә көчсез бер дәүләт хәленә китерәләр. Русиядә башланган сәвит режимы, гайни (аеруча) кара урыс сәясәтен алып барып, безнең Идел-Урал мөнәүвиренең мең бәла берлә йирләштерергә тырышкан вә шактый зур мәгънәви берлекне яраткан берлек агымыны балталарга тотыналар. Бөтен Русия төркләренең матбугат, китапчылык, мәдрәсәчелек мәркәзе Казан шәһәрен зәгыйфьләтер өчен бөтен матбагаларын, гәзитләрен урысларның кулына йә урыс бәндәсе ахмакларының кулына бирәләр. Бөтен тарихы буенча бергә килгән Казан халкы, башкортлар, типтәрләр, мишәрләр арасына кабилә аермасы орлыкыны аталар. Чарлар (цар — патшалар) дәвеpенең урыс ажаны (агенты), Шәриф Манатов[**], Зәки Вәлидиләрне[***] котыртып, Идел-Уралның сәяси берлеген бозар өчен аерым Башкортстан, аерым Татарстан төсендә дәү-*

---

[*] Бисмарк Отто фон Шенхаузен (1815–1898) — князь, 1871–1890 елларда Германия империясенең беренче рейхканцлеры.

[**] Манатов Ш. (1892–1936) — Башкортстан җөмһүриятен төзүдә актив катнашучыларның берсе. Милләте — башкорт. 1928 елда Ш.Манатов Төркиягә китә. Биредә аңа «совет агенты» дип карыйлар. Шуннан ул СССРга кире кайта. Монда исә «төрек агенты» дип гаеплиләр. Аның турында тулырак: Давлетшин Т. Советский Татарстан... — Лондон, 1974. — С. 141.

[***] Вәлиди З. (1890–1970) — егерменче елларда эмиграциягә китә. 1935–1939 елларда — Бонн һәм Геттинген университетларының профессоры. 1939 елдан Истанбул университетында гомумтөрки тарихын укыта.

*ләт механизмы коралар. Төркестанны да биш-алтыга бүлеп, алар арасында кабилә дошманлыгы орлыгы чәчәләр вә бөтен Төркестан милли мәктәпләрендә без — Идел-Ураллыга каршы бик каты (күп) дошманлык пропагандасы алып баралар. Империалист итеп күрсәтеп, безнең халыктан биздерергә тырышалар. Хәтта татар әлифбасы, башкорт әлифбасы дип, латинча исемендә аерым-аерым әлифбалар чыгаралар. Идел-Уралның берләштерү нигезендә корган дини берлекне Русиядәге бөтен сөнниләрне берләштерүне күздә алган вә хакыйкатән казакъ, кыргызларны, Төркестанның зур өлешене берләштерергә муафыйк булган бөек галимнәремез Галимҗан әл-Баруди*, Ризаэддин бине Фәхреддин хәзрәтләренең җан-тән берлә тырышкан диния нәзарәтемезне зәгыйфьләндерер өчен сатлык муллалардан башкортлык мөфтисе тудыралар. Казанда мәркәзе булган ике йөз меңлек бер гаскәрнең берләшүенә тырышкан гаскәри Шураны да, татар гаскәре, башкорт гаскәре дип, икегә бүләләр. Бу арада Төркия дә Аурупа дәүләтләренә каршы сугышта җиңелеп чыкканга, без — төркчә милләтчеләрнең һичбер таяначак куәтемез мәйданда калмый. Без, гаскәре югалган генераллар кебек, чит илләргә качарга, анда мәгънәви берлегемезне саклар өчен бөтен гайрәтемезне, көчемезне сарыф итеп тырышырга мәҗбүр каламыз. Ләкин безнең әүвәлге гасырлардагы мөһаҗәрәтемезнең (күченүебезнең) барысы да Төркиягә, гареб (көнбатыш) мәмләкәтләренә генә булганга вә болар да заман үтә-үтә йирле төрекләр арасында эреп китеп, аларның балаларының балалары туган илләрен тәмамән оныткانга, без бөтен дөньяда арка таяначак бер милли мөһаҗир көтәлесене (тупламын; терәген) таба алмыймыз. Яһүдиләр, украиналылар, әрмәниләр кебек Аурупага, Америкага йирләшкән вә үзенең анда тормышын корса да, туган иленнән, туган туфрагыннан ваз кичмәгән бер куәткә очрый алмыймыз. Ялгыз сәяси кыйммәтемезне аңлаган Ләһстан (Польша) хөкүмәте генә безгә аз-маз кулны суза ала. Аның аркасында мәмләкәттә күтәрелгән берлек байрагымызны йиргә иңдермибез. Фәкать эшләвемез көчемез кадәр генә булып, уникенең берсе юк мохиттә милли барлыгымызны Аурупа дәү-*

---

* Галимҗан әл-Баруди (1857–1921) — мәгърифәтче, дин галиме, мөфти.

*ләтләренә күрсәтеп, милли истикъляль (бәйсезлек) дәгъвамызны анда-монда качып чыккан Финляндия, Эстония, Япуния, Кытай мәмләкәтләрендәге илдәшләремезгә аз-маз өйрәтүдән уза алмыймыз. Икенче дөнья сугышы безне бу калунияләремездән [(колония) бу очракта «читтә халкыбыз тупланып яшәгән төбәк» мәгънәсендә алына] дә мәхрүм итә. Озак Шәрыктагы калуниямез, Маньчжурия, Курия (Корея), Кытайдагысы икенче мәртәбә урысларның кулына эләгәләр. Аурупадагы Ләһстан, Эстония юк булып китә. Җиңелгән Япуния берлә җиңелгән Финляндия дә бик күп зарар-зыянга очраган; большевиклык көч-куәтеннән куркып калган, бер-ике мең мөһаҗиремез генә җисмән (физик яктан) сау-сәламәт калса да, алар да, мәгънә ягыннан бик зәгыйфьләнеп, сугыштан чыгалар. Беренче вазыйфалары үз гаиләләрен аякка бастыру икәнене аңлап, табигый уларак, шул юлда хәрәкәт итәләр. Зур милли мәсьәләләр берлә уграшырга (шөгыльләнергә) көчләре дә калмаган була, иманнары да зәгыйфьләнгән булып кала. Без, милләтче төркчеләр, һич булмаса, Ләһстан дәрәҗәсендә бер арка таянычак көч эзлиләр; үземез төрк, үземез мөселман, үземез урысларга-большевикларга бик дошман булганга, бу көчне христиан дөньясында таба алмыймыз. Ислам галәме үзе корылып, олуг юлга чыкмаган, большевикның ялган пропагандасына ышанып, күбесе безгә дошман вазгыять (торыш, хәләт) ала. Төркия үзенең беренче дөнья сугышыннан алган җәрәхәтләрен әле дә булса төзәтә алмаган. Тагы мондагы төрк булмаган яһүди, бошнак (боснияле), хәтта гарәпләр, төркчелек агымыннан куркып, чит төркләргә (Төркиядән читтәге төркләргә) дошман киселгәннәр (дошман каралганнар). Аларның шул хисләреннән файдаланып, мондагы мөнәүвирләр арасында бик нык тамыр җәйгән сүздә инсаниятче, эштә большевик дуслыгы алып барган массун (масон; яшерен) оешмалары без төрк милләтчеләренә аяк чалуны үзләренә вазыйфа итеп алганнар. Менә шул шартлар эчендә без төркче милләтчеләрнең милли эшләре, безнең мишәрләр әйткәнчә, кругом кармазин («бары да ал да гөл» мәгънәсендә) булып чыккан. Вә сез финляндиялеләргә килгәндә, сез дә юлны югалткан кышкы бурандагы юлаучы кебек аптырап калгансыз. Бер өлешегез Төркиядән килгән төрле-төрле, үз илендә эш таба алмаган шарлатаннарны сыйлауны төркчелек ясыймыз дип, үз-үзегезне (үз-үзлегегезне) онытткансыз. Бер төрлегез ике мәхәлләне көрәште-*

*реп, әтәч сугыштырыр («сугыштырган» мәгънәсендә) кебек, муллаларыгызны бозыштырырга керешкәнсез вә арагызда әүвәлге берлек йиренә эчегезгә нифак (икейөзлелек, әшәкелек) сугылганга, шул ярыктан арагызга оста(ча) большевик ажанларының кереп йирләшүен дә сизми калгансыз. Төрк милләтчесенең башына килгән бу бәла-казадан безне коткарачак чара тагы милли төркчелек, милли төркчелегемезне җанландыру вә иске юлымызны табып, һәрбер гөруһның («төркем» мәгънәсендә) үз иленә, үз туган йортына күңелдән баглану, киң дөньяда шул мөкаддәс эшкә дустлар табу гынадыр. Без, иске милләтчеләр, бу көннең туачагына иманымыз камил булып, көчемез кадәр эшләүдә дәвам итәдербез. Ләкин кирәк Финляндиядә, кирәк Япуниядә, кирәк яңа мөһаҗирләремез арасында бу милли иманның көннән-көн зәгыйфьләнүенә, хакыйкый иман йиренә (...)* ялган иманның берләшүенә шайтаный бер куәтнең бик тырышуын күреп, бик борчыламыз. Хушыгыз, Халидә туташ, мин бу арада бик каты хаста булганга, бу хатны берничә мәртәбә бүлеп яздым. Бу хатымны мөмкин кадәр саклагыз! Мин, бәлки, соңгы атналарымны яши торгандырмын. Шулай булып чыкса, бу хатым мәгънәви васыятем кебек калсын! Әгәр мөмкин булса, бу хатым... хәзрәткә дә укыгыз, ул да күчереп алсын! Мин үлеп китсәм, форсаты килгәндә, бу хатымны бөтен халыкка бер мәртәбә укыгыз! Хушыгыз, бөтен гаиләгезгә хөрмәтләр вә сәламнәр.*

*Һамиш**. Исәнлегем бик начар булганга, Аурупага дарулану өмиде берлә барырга план корып йөрим. Әгәр шуның юлларын таба алсам, майның яртысыннан соң чыгарга хәзерләнәм. Ләкин Төркиядән акча чыгару бик авыр булганга, бу эшне ничек башкарырмын, әле мәгълүм түгел.*

## Исхакый васыятенең иясе

### I

Азия һәм Аурупа кыйтгаларын тоташтыручы, миллионлаган инсаннарны яшәтүче, ыгы-зыгылы Истанбул каласы. Бу «мәңгелек шәһәр»нең (К.Маркс) кечкенә генә бер фатирын-

---

* Биредә дүрт сүз танылмый.
** Һамиш — өстәмә.

да бөек Исхакыйның гомер шәме сүнеп бара. Күпме кешегә рухи ярдәм, яшәүгә көч биргән 76 яшьлек бу зат хәзер япа-ялгыз, матди кыенлыкта, каты авыру. Янында гына Газраил йөрүен инде ул тирәнтен аңлый. Соңламаска! Гомер юлына йомгак ясарга кирәк! Әмма ничек, ни рәвешле? Менә ул, үзендә көч табып, кулына каләм ала. Хат рәвешендә үзенең бүгенге хәле, тормыш юлы, халык тарихы, милләт, җәмгыять турында уйлануларын бәян итә. Кайчандыр көненә дистәләгән бит язган әдип бу хатын атна буе, ягъни 1954 елның 12–18 апрель көннәрендә яза (хат 21 апрельдә Финляндиягә барып җитә). Бу хакта ул үзе дә искәртә. «...*Мин бу арада бик каты хаста булганга,* — ди әдип, — *бу хатны берничә мәртәбә бүлеп яздым. Хатымны мөмкин кадәр саклагыз! Мин, бәлки, соңгы атналарымны яши торганмындыр. Шулай булып чыкса, бу хатым мәгънәви васыятем кебек калсын! Мин үлеп китсәм, форсаты килгәндә, бу хатымны бөтен халыкка бер мәртәбә укыгыз!..*»

Берничә битлек хатның атна буе язылуы, әлбәттә, иң беренче чиратта, әдипнең «хаста»лыгына бәйле. Әмма хикмәт анда гына түгел. Исхакый бу хатын «бөтен халыкка» җиткерергә теләгән соңгы сүзләре, киңәш-теләкләре, «рухи васыяте» рәвешендә карый. Хатның озак язылуы билгеле бер дәрәҗәдә шуның белән дә аңлатыла.

Әдипнең кызы, кияве, туган-тумачалары бар, билгеле, танышлары, аркадашлары да шактый. Ә васыять хаты аларга түгел, ә Финляндиянең Тампере каласында яшәүче гадәти татар кызы Халидә Вафага (Вафинага) адресланган. Бу очраклылыкмы, әллә моның берәр хикмәте, сере бармы?

Мәгълүм булганча, Г.Исхакый Суоми мәмләкәтен ярата, анда яшәүче милләттәшләребез белән күптәннән аралашып тора. Бирегә аның Октябрь инкыйлабына кадәр дә, аннан соң да күп мәртәбәләр килүе билгеле. Әдипне Архангел сөргененнән азат итүдә дә Финляндиядә яшәүче татарларның катнашы бар. Әдип гәзит-журналлар чыгаруда, китаплар нәшер итүдә дә биредәге милләттәшләребезнең ярдәмен тоеп яши. Мәсәлән, «Яңа милли юл» журналының (1928–1939) төп химаячеләре (спонсорлары) — Финляндия татарлары. Аның битләрендә бу мәмләкәт, андагы милләттәшләребезнең тормышы хакында шактый гына материаллар бар. Аларның күбесе баш мөхәррирнең үзе тарафыннан язылган. Хельсинки, Тампере, Випури (Выборг) һәм башка шәһәрләрдә гомер кичерүче татарлар Г.Исхакый язмаларын даими укып торалар, аның драма әсәрләрен

сәхнәгә куялар. Әдипнең 60 яше, иҗатының 40 еллыгы бирედә зур күләмдә билгеләп үтелә. Г.Исхакый Финляндиядәге милләттәшләребезне туплауда, рухи яктан тәрбияләүдә остаз ролен үти. Аны олысы да, кечесе дә ярата, хөрмәт итә. Бирედә әдип аралашкан, озак еллар буе бәйләнеш тоткан берничә гаилә була. Шундыйларның берсе — Вафиннар (Вафалар).

Унтугызынчы гасырның соңгы чирегендә туып, 1941 елда вафат булган Зиннәтулла Вафа — Сергач төбәгендәге Яңапар (Актук) авылының атаклы Аюханнар нәселеннән. Ул яшьли үк Финляндиядә сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Нигездә, Тампере каласында тора. Випури тирәсендәге Тирйокида җәйге утарлары да була. Аның энергияле эшмәкәр, гаять милләтпәрвәр зат икәнлеге мәгълүм. Зиннәтулла Вафаның хатыны — Мөшфика ханым (1886—1966). Күпләр аның киң күңелле, ярдәмчел, зыялы инсан булуы хакында сөйлиләр. Мөшфика ханым вафатының кырыгынчы кичәсендә эшмәкәр һәм үзешчән шагыйрь Гайсә Хәкимҗан (1896–1972) болай ди: «Без бүген бу хөрмәтле ананың кырык кичәсенә җыелдык. Бу ана белән 50 елдан артык шул Тампере шәһәрендә бер гаилә кебек бергә яшәп килдек. Бу ана ялгыз балалар анасы гына түгел иде. Бу ана халык анасы иде һәм милләт анасы иде...» Г.Хәкимҗанның «Мөшфика тутай хатирәсенә...» дигән махсус шигыре дә бар. Аның бер строфасы болай яңгырый:

Һич сүнмәслек хәсрәт ялкыннарын
Өстәдең син минем бәгъремә.
Гомерлеккә сулмас гөл орлыгын
Утыртам мин синең кабреңә.

Зиннәтулла һәм Мөшфика Вафалар җиде бала тәрбияләп үстерәләр: Сәмигулла, Фатыйма, Алия, Халидә, Кадрия, Наилә, Гөлсем. Гаиләдә дустанә мөнәсәбәт, туган телгә, төрки-татарга, мәдәнияткә мәхәббәт хөкем сөрә. Ата-ананың матур сыйфатлары, игелекле эш-гамәлләре балаларына да күчә. Мәсәлән, 1990 елда бу гаиләнең бер әгъзасы — Алия апа белән миңа да очрашырга туры килгән иде. Бу зыялы, итагатьле, ачык йөзле инсанның хатирәсе (ул моннан берничә ел элек вафат булды) хәзер дә күңелдә саклана.

Гаяз Исхакыйның Вафиннар гаиләсе белән озак еллар буе аралашып торуы бик күп фактлар, җөмләдән хатлар, фотосурәтләр, төрле истәлекләр белән раслана. Мәсәлән, 1927 елның мартында язылган бер открыткада Г.Исхакый бу гаиләне «Бәйрәм мөбарәк булсын!» дип котлый. Икенче бер язмада әдип

Вафиннарны «илемезнең хөрмәтле гаиләләрендән берсе» дип атый. Димәк, бөек әдипнең васыять хатын нәкъ менә шушы гаилә әгъзасына адреславы һич тә очраклы хәл түгел. Аннан шунысы да бар: Халидә Вафа — чагыштырмача яшь буын вәкиле. Г.Исхакый исә милләт тәрәккыяте, киләчәк өчен көрәштә һәрчак яшьләргә күңел баглый. Димәк, хатның аңа адреслануы билгеле бер символик мәгънәгә дә ия.

Гыйльми һәм популяр әдәбиятта Исхакыйга мөнәсәбәттә Халидә Вафа исеме сирәк булса да, телгә алына. Әмма аның хакында мәгълүматлар юк диярлек.

Мин 1990 елда Финляндиягә баргач, үкенечкә каршы, Халидә апа белән очраша алмадым. Татар акылы төштән соң дигәндәй, әле анда вакытта бу мөхтәрәмә зат белән очрашуның зарурлыгын да аңлап бетермәдем булса кирәк. Чөнки васыять хатының машинкада басылып, брошюра рәвешенә китерелгән нөсхәсе (ул гарәп язуында. Күләме — 11 бит. Анда Г.Исхакыйның 1951 елгы тәбрик хаты да бар) 1990 елда Финляндиядән китәр алдыннан гына кулга керде. Мин аңа «Ислам җәмгыяте» архивында тап булган идем. (Бу кыйммәтле материалны бирүләре өчен мин җәмгыять җитәкчеләре Окан әфәнде Таһирга һәм Хөсәен әфәнде Хәмидуллага янә бер мәртәбә ихласи рәхмәтләр юллыйм.)

Казанга кайткач, Г.Исхакый хатын мин кереш мәкалә һәм тиешле шәрех-аңлатмалар белән матбугатка әзерләдем. Әле ул вакытта СССР чоры иде. Аерым кысу-тыюларга да карамастан, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире кыюлык күрсәтте: мин тәкъдим иткән материаллар журналның 1991 елгы 5 нче санында басылып чыктылар. Татарның киң җәмәгатьчелегенә соңарып ирешкән васыять хаты укучылар арасында зур кызыксыну тудырды. Бераздан аны күчереп тә бастылар. (Сәхапов Ә. Исхакый иҗаты. — Казан, 1997. — 336–352 б.; Мирас, 1999. — 2 нче сан. — 42–49 б.) Әмма текстка, васыять адресатына карата туган аерым сораулар җавапсыз кала килде.

## II

Халидә апаның 1991 елда Идел круизы вакытында Казанга килеп чыгуы да соңрак кына мәгълүм булды. Мин инде, әгәр дә Суомига янә барырга туры килсә, Халидә апа белән очрашуны тәүге бурычларымның берсе итеп куйдым. Менә, ниһаять, 2000 елның җәендә (төгәлрәге, 18 июль — 5 август көннәрендә)

«Ислам җәмгыяте» чакыруы буенча кызым Гөлназ белән янә Финляндиядә булырга туры килде. Милләттәшләребез безне ачык йөз белән зурлап каршы алдылар, хөрмәт иттеләр, озаттылар. Мин берничә көн буена аларга Хельсинкида, шәһәр янындагы Трэскулла ял йортында әдәбият, халык тарихы, рухи мирасыбыз хакында лекцияләр укыдым, семинар-әңгәмәләр үткәрдем. Кызганыч, ун ел эчендә элек мин күреп аралашкан шактый гына мөхтәрәм затлар китеп барган: Халидә һәм Гомәр Таһирлар, Нурмөхәммәд һәм Сафия Сәмәрханнар, Лотфулла һәм Халисә Байбулатлар, Госман ага Али, Гәүһәр апа Туганай, Алия апа һ.б.

Бу сәфәремнең ике көнен, алдан ук ниятләгәнчә, Хельсинкидан 165 чакрым ераклыктагы Тампере каласына багышладым. Гаҗәеп итагатьле, милли җанлы, чын татар егете Алтан Каадәр ярдәме белән шәһәрнең истәлекле урыннарын да карадык, элеккеге танышыбыз, милли җәмгыять җитәкчесе Әсәт ага Байбулат белән дә гәпләштек, иң мөһиме — «Ислам мәхәлләсе» йортында Халидә апа Вафина белән очраштык («Өемдә ремонт бара», — диде). Өлкән яшьтә булуына карамастан, шактый хәрәкәтчән, җитез табигатьле, җанлы. Зиһене, хәтере әйбәт, җөмләләре төзек, мөгамәләсе зыялы, тактлы. Ике арада сүз иярә сүз китте. Сорыйсы, ачыклыйсы әйберләр күп. Әмма вакыт аз. Икенче көнне китү алдыннан янә очраштык. Халидә апа ничектер яшәреп киткәндәй булды. Дулкынлана-дулкынлана хатирәләрен искә төшерде. Үзе дә: «Зур рәхмәт сезгә, яшьлегемә кайткандай булдым», — диде. Хельсинкига да миңа берничә мәртәбә шалтыратты. Алтан әфәнде аркылы янә берничә фото, язма материал һәм хат та җибәргән иде. Соңгысында мондый эчтәлектәге юллар да бар: «*...Хельсинкига сезнең чыгышларны тыңларга бару мөмкинчелеге булмаган иде. Аллаһының рәхмәте бөектер: сез, кыйммәтле вакытыгызны бүлеп, минем белән күрешү өчен үзегез Тамперега килдегез. Бу минем өчен иң бөек шәрәфтер. Олуг галимнәр тарафыннан күрсәтелгән мондый хөрмәтне мин бары тик әти-әниемнән генә күрдем. Бу очрашуда сез, бөек, мәшһүр милләтче, тарихчыбыз булган Гаяз Исхакыйны да шәрәфләндердегез. Мин шушы изге эштә арадашчы булуыма шатмын... Сезнең белән очрашуга ни дәрәҗәдә сөенүемне белсәгез иде! Мин сезне иске бер дустым кебек кабул иттем, уй-кичерешләремне, ачылып, сезгә сөйләдем. Күз алдыма яшьлек хәятым килде, кальбемдәге кыйммәтле хатирәләр яңарды*». (Хат ни сәбәптәндер төрекчә язылган.) Хәзер Халидә апа сөйләгәннәрдән аерым өзекләр,

фикерләр китерәм. Алар бу затның үзен, тормышын да билгеле бер дәрәҗәдә күзалларга ярдәм итәр дип ышанам.

*«Мин,* — диде Халидә Вафа, — *сезнең инкыйлаблар елында туганмын: төгәлрәк әйткәндә, 1917 елның 23 маенда, Тирйокида. Әмма даими яшәү урыным Тампереда булды. Шактый хәлле, җиту тормышта үстем. Гимназия тәгәлләдем. Үзебезнең динне, телне, әдәбиятны, тарихны өйдә һәм җәйге курсларда өйрәндем. Татар, фин, швед, алман һәм кайбер башка телләрне беләм. Гадәттә, Тирйокида уздырылган җәйге курсларга эшкә күренекле галимнәр, билгеле шәхесләр чакырыла иде. Безне, мәсәлән, Муса Ярулла, Абдулла Баттал, Галимҗан Идриси һәм башкалар укытты. Тирйокидагы дачабызда һәм Тампередагы йортыбызда халкыбызның бөек кешеләре Г.Исхакый, Рәшит Рәхмәти һәрчак булып торды. Аларның милләт турындагы сүзләре кечкенәдән үк күңелгә сеңеп барган. Чит илгә тәүге сәфәрем 1938 елда булды. Берлинга электән үк танышыбыз, гаилә дустыбыз Галимҗан Идрисиләргә кунакка бардым. Алманча белүемне камилләштердем.*

*Сугыш башлангач, әти дә үлгәч, яшәү кыенлашты. Совет очкычлары Тампереңы көчле бомбага тотып тордылар. Янгыннар чыгып, күп зыян күрдек. Сугыштан соң, бераз аякка баскач,1951 елда чит ил сәфәренә юнәлдем. Әүвәл Ромада (Римдә. — Х.М.) булдым. Аннан — Мисырга. Биредә Г.Идрисинең улы Урхан каршы алды, Әл-Әзһәр университетын һәм Каһирәнең башка истәлекле урыннарын күрсәтте. Мисырдан Төркиягә килдем. Измир, Истанбул калаларында берничә ай булдым. Төрекчәне 30 нчы елларда Абдулла Батталдан (аның белән шактый хатлар алыштык) өйрәнә башлаган идем. Төркиядә аны тагын да камилләштердем. 50 нче еллардан башлап Төркия-Финляндия арасындагы рәсми, эшлекле сөйләшүләрдә, шул исәптән ил башлыклары очрашуларында да, берничә мәртәбә тәрҗемәче буларак катнаштым».*

Халидә апа Муса Ярулла Биги, Садрый Максуди һәм кайбер башка галимнәрнең хезмәтләрен фин теленә тәрҗемә итүен дә искәртте.

Күп кенә хатлар, фотолар, башка төр материаллар Халидә Вафаның күп кенә күренекле затлар (галимнәр, әдипләр, дәүләт эшлеклеләре һ.б.) белән аралашуын раслыйлар. Мәсәлән, аның Финляндия президенты Кекконен белән төшкән рәсеме бар. Халидә ханым күп мәртәбәләр Садрый Максуди һәм аның гаиләсе белән очрашып, хатлар алышып тора.

Илгаз Ваһаб Нәүрүзхан безнең укучыларга «Сөембикә» әсәре белән таныш. Бу тарихи роман татар телендә 1992 елда Чаллыда нәшер ителгән иде (тәрҗемәчесе — Рәис Сабиров). Милләттәшебез Нәүрүзхан (нигездә, ул Измирдә яши) төрек әдәбиятында башка әсәрләре белән дә мәгълүм. Баксаң, Халидә Вафа бу әдип белән дә дустанә мөнәсәбәтләрдә торган. Илгаз Нәүрүзханның 50–60 нчы елларда аңа язган бик җылы эчтәлекле хатлары бар. Халидә апа миңа бу авторның 1949 елда Измирдә иҗат ителгән бер хикәясенең күчермәсен дә бүләк итте. «Завалле аннәчегем» («Фәкыйрь әнием») дип исемләнгән бу әсәрдә бөтен барлыгын гаиләсе, балалары өчен сарыф иткән ананың ахыр чиктә фәкыйрьлектә, ялгызлыкта яшәп, вафат булуы шактый үтемле итеп тасвирлана.

Халидә апа Вафа 1941 елдан «Истәлекләр дәфтәре» алып бара. Анда килгән кунакларның кызыклы язмалары бар. Төрек әдибе Урхан Каравәли 1962 елның августында Тампереда була. Шунда Халидә апа белән дә очраша. Аның хатирә дәфтәренә мондый сүзләрне язып калдыра: «Халидә ханым кебек соң дәрәҗәдә айдын (зыялы. — *Х.М.*), соң дәрәҗәдә зирәк, милләтче вә Ататөреккә ихтирамлы бер төрек кызының хатирә дәфтәренә... язу миңа бик уңайсыз... Аның белән танышуыма, аралашуыма бик шат булдым. Аңа карап хәйрәт (таң. — *Х.М.*) калдым». Бу истәлек дәфтәре хәзер дә гамәлдә. Тамперега, зур халыкара фәнни конгресска (2000 ел) АКШтан килгән милләттәшебез, күренекле профессор Азадә-Айшә Рорлих та, Халидә апа белән очрашып, мондый сүзләрне теркәп калдырган: «Сезнең белән очрашу минем өчен бик кыйммәтле хатирә булып калды. Тарихыбызны яратып, тарихи материалларны саклавыгыз өчен сезгә чын күңелдән рәхмәт укыйм...» Без фәкыйрегез дә бу хатирә дәфтәренә түбәндәге сүзләрне язып куйды: *«...Сез — безнең халыкның билгеле кешесе. Чөнки бөек шәхесебез Гаяз Исхакый сезне хөрмәт иткән, соңгы васыятен дә сезгә атап язган. Сезнең белән танышуга мин бик шат булдым. Үзегезгә рәхмәтләр укыйм, исәнлекләр телим...»*

## III

Халидә апа белән булган әңгәмәнең үзәгендә, әлбәттә, Гаяз Исхакый торды. *«Мин,* — диде ул, — *бу бөек затны кечкенәдән үк ишетеп, күреп беләм. Чөнки ул безнең өебездә гаять абруйлы, мөхтәрәм кеше итеп йөртелә иде. Гаяз әфәнде минем күңелемдә ничектер озын буйлы, горур табигатьле,*

*кешеләрне, аеруча хатын-кызларны үзенә магнит кебек тартып торучы кеше рәвешендә калган. Аны гел тыңлыйсы гына килеп тора. Гаяз әфәнде аеруча безгә, яшьләргә илтифатлы иде. Шундый олуг затның безне тиң күреп сөйләшүе безгә рәхәт иде.*

*1937 елда минем апам Алия белән Әнвәрнең туе булды. Анда Гаяз Исхакый да катнашып, бөтен мәҗлесне бизәп торды. Ахырда без аның белән урамда да йөреп кердек. Гаяз әфәнде белән янәшә бару, аның игътибарына ия булу минем өчен бөек бер дәрәҗә, онытылмас бер хатирә иде. Мин бу әдип язган әйберләрнең күпчелеген укып барырга тырыштым. Әңгәмәләр вакытында алар хакында да еш кына сүз кузгала иде. Гаяз әфәндегә мин һәрвакыт соклану, инсани сөю хисләре белән карый идем.*

*Бөек әдип Алманиядә, Польшада яшәгән вакытында Финляндиягә еш килә иде. Әмма икенче бөтендөнья сугышы башлангач, ул Төркиягә күчеп китте. Хат-хәбәрләр алышкаласак та, мин аны озак еллар күрә алмадым. Ниһаять, 1951 елның июнендә без аның белән Истанбулдагы бер бакчада очраштык. Ак, пөхтә костюмнан иде. Кулында таяк. Ябыккан, олыгайган, хәлсезләнә төшкән. Күңеле төшенкерәк булса да, милли мәсьәләләрдә иман-ышанычы нык иде. Без аның белән бик озак сөйләштек. Хатирәләрне яңарттык. Бу безнең соңгы очрашу булды. Йә Аллаһ, нинди истәлекле вакытлар бар иде, кадерен белмәгәнмен!*

*Тампере шәһәренең имамы Хәбибрахман Шакир иде. (Ул чыгышы белән Туймазы татары иде бугай. Әмма озак еллар Пакистанда яшәгән.) Безнең яхшы танышыбыз, бик мөхтәрәм зат. Ул да Гаяз әфәнде белән яхшы мөнәсәбәттә иде. Бервакыт имамыбыз миңа болай ди: «Гаяз Исхакыйның хаты килде. «Авырыйм, Ватан ризыкларын ашыйсым килә» дип язган. Шуннан мин, карабодай, май һәм кайбер башка азык-төлек әйберләре алып, Истанбулга берничә пакет (посылка. — Х.М.) җибәрдем. Абыем Сәмигулла өс киемнәре салды. Бераздан Гаяз әфәнденең шул васыять рәвешендә язылган хаты килде. Моннан тыш та без 1954 елда янә берничә хат алыштык».*

Гаяз Исхакый васыять хаты белән бергә, үзенең иң соңгы фотоларының берсен дә җибәрә. Аның артына мондый сүзләр язылган: *«Җитмеш җиденче яшемә баскан, 1954нең 23 февралендә алдырган рәсемемне, бер хатирә булсын дип, Зиннәт Вафа әфәнденең кәримәсе* (кызы. — Х.М.), *милләтче*

*Халидә туташка бүләк итеп күндерәм. Гаяз Исхакый, Истанбул, 18 апрель, 1954».*

*«Гаяз әфәнденең үлем хәбәрен,* — ди Халидә апа, — *безгә Гали Акыш ирештерде. Без моңа барчабыз да бик кайгырдык. Аеруча миңа авыр булды. Гаяз әфәнденең үтенечен исәпкә алып, Хәбибрахман Шакир (1903–1975) белән берлектә васыять хатын машинкада бастырып төпләттек, берничә дистә данә күбәйттек. Милләттәшләребезгә өләштек. Чит мәмләкәтләргә дә бераз җибәрдек».*

Бу урында шунысын да әйтү урынлы булыр: машинкада басылган, төпләнгән васыять хаты илдәге, шул исәптән Казандагы аерым татар зыялыларының да кулына эләгә. Әмма сәяси якны күздә тотып, бу хакта алар һич тә дәшмиләр. Әгәр дә хак булса, шушындый хәлне дә сөйлиләр: имеш, СССР дәверендә Финляндиягә барган бер галимгә бу хатны биргәләр. Ә ул аны, кайту белән, КГБга илтеп тапшыра.

Халидә апа васыять хатының оригиналдан күчермәсен миңа бирде. Мин аны машинкада таралган нөсхәсе белән чагыштырып чыктым. Аерма юк дәрәҗәсендә. Хатның соңгы өлешендәрәк күп нокталар куелган юл бар: *«Әгәр мөмкин булса, бу хатым... хәзрәткә дә укыгыз».* Оригиналда бу урында *«Хәбибрахман»* диелгән. Шундагы ук абзацта күп нокталар куелган җөмләне түбәндәгечә уку лязем: *«Ләкин кирәк Финляндиядә, кирәк Япуниядә, кирәк яңа мөһаҗирләремез арасында бу милли иманның көннән-көн зәгыйфьләнүенә, хакыйкый иман йиренә русның аракысы илә дуңгыз мае сеңдерелгән ялган иманның... йирләшүенә шайтаный бер куәтнең бик тырышуын күреп бик борчыламыз».*

Халидә апа Вафа миңа Г.Исхакыйның янә берничә хатының күчермәсен бирде. Мәсәлән, аларның берсе 1954 елның 13 февралендә, икенчесе шул ук елның 8 маенда язылган. Боларда, васыять хатындагы кебек, тарихи, иҗтимагый, сәяси мәсьәләләр күтәрелми. Әмма шуңа да карамастан, бу хатлар бөек әдипнең көндәлек тормышын, авыр язмышын, кешеләр белән мөнәсәбәтен ачыклау ягыннан мөһим. Минем уемча, киләчәктә Г.Исхакыйның җентекле биографиясе, тормыш һәм иҗат хроникасы язылырга тиеш. Бу төр материаллар шул җәһәттән дә игътибарга лаек. Безнең кулыбызда шулай ук Гаяз Исхакый һәм Халидә Вафа мөнәсәбәтләренә кагылышлы кайбер башка хатлар һәм материаллар да бар. Мәсәлән, 1951 елның 28 июнендә Г. Исхакый тарафыннан язылган бер истәлек тексты мондый эчтәлектә: *«Илемезнең хөрмәтле гаиләләрендән Зин-*

*нәтулла Вафа, Мөшфика Вафа ханымның кызлары Халидә туташның атасы-анасы кебек туусы(н), дөрест булуын күреп сөендем, халкымызның киләчәге уңышлы чыгачагыны, шундый йитешкән кызларның Финляндия кебек илемездән ерак йирләрендә үсүе, зураюы зур сөенечле галәмәтдер. Тәңре шундый яшьләремезгә, хосусан Халидә туташка, шәхси тормышында бәхетле булып, милләтенә файдалы булуыны вә бик күп төрк-татар яшьләренә үрнәк булырлык хәерле эшләр эшләвенә насыйп итсен!*

**Рамазан ае, Истанбул».**

(Бу язу Г.Исхакый белән Халидә Вафаның Истанбулда очрашу вакытында теркәлә.)

Гаяз Исхакый һәм Садрый Максуди — бер даирә, әйтергә ярдса, бер когорта кешеләре. Аларның берсенә мөнәсәбәтле мәгълүмат теге яки бу дәрәҗәдә икенчесенә дә яктылык сирпи. Халидә апаның бу яктан да роле зур. Әйткәнебезчә, ул Максудилар гаиләсе белән шактый аралаша. Бу аеруча 50 нче елларда көчәеп китә. Чөнки бу вакыттан башлап Халидә Вафа, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «һәр ел саен диярлек Төркиягә бара, андагы мәшһүр милләттәшләр белән аралаша». Хат алышулар да булып тора. Халидә Вафаның 1953 елның 18 мартында язган хаты кызыклы гына. Ул саф татарча язылган. Анда татар кызының Садрый Максудига тирән хөрмәте ачык сизелә. Финляндия-Төркия мөнәсәбәтләре дә телгә алына. Садрый Максуди үзенең 1953 елның 18 июнендә язган җавап хатында Халидә Вафага гаять тә игътибарлы булуын күрсәтә, төрек милләтенең олылыгы, китап укуның файдалы булуы хакында фикерләрен белдерә. Укучыларга тәкъдим ителә торган бу хатлар да җәмәгатьчелек һәм фән өчен мөһим бер факт булыр дип уйлыйм.

Кызганыч, ремонт булу һәм вакытның тарлыгы аркасында Халидә апаның китапханәсе, шәхси архивы белән ныклап танышып булмады. Әмма ул җиткергән мәгълүматлар, биргән материаллар да фәнебез, милләтебез өчен мөһим һәм әһәмиятле. Моның өчен аңа күпме рәхмәтләр укысаң да, аз тоелыр. Бөек әдибебезгә авыр вакытларда таяныч, сердәш булганы һәм аның үтенечләрен гамәлгә ашырганы өчен Ходай Тәгалә аңа исәнлекләр бирсен. Халидә апа ничектер дәртләнеп, яшәвеннән мәгънә табып калды. «*Әле тагын материаллар җибәрермен*», — дип вәгъдә дә итте.

Шунысы да мәгълүм булсын: Халидә апа үзенең шәхси

архивының бер өлешен Хельсинки университетының китапханәсенә бүләк иткән. Тапшырылган китапларның күпчелеге татарча һәм төрекчә басмалар. Арада Г.Исхакыйның Казанда нәшер ителгән китаплары, «Өйгә таба»ның төрекчә басмасы (Истанбул, 1941), «Көз» һәм «Дулкын эчендә» әсәрләренең Алманиядә 1937, 1938 елларда дөнья күргән нөсхәләре бар. Халидә апа аерым кулъязма материалларның да күчермәләрен университет китапханәсенә тапшырган.

* * *

Гомер уза. Дөньяга килгән һәр инсан китеп бара. Әмма язган сүзләр, хатирәләр кала. Алар — тарих, алар — язмыш. Яшәгән һәр кешегә үзгәләрнең язмышы гыйбрәтле. «Инкыйлаб» яшьтәше Халидә апа Вафа — безнең халкыбызның бер зыялы вәкиле, аның язмышы да безнең гомуми язмышыбызның бер өлеше.

*2000*

## Халидә Вафа архивыннан хатлар

**Хөрмәтле Халидә туташ!**

Сезнең 27 гыйнвар тарихлы (ягъни 27 январьда язылган. — *Х.М.*) мәктүбегез (хатыгыз. — *Х.М.*) берлә күндергән бүләк пакетыгызны* бүген үзем постаханәгә (почта йортына. — *Х.М.*) китеп (кереп. — *Х.М.*) алдым. Пакет килү хакында күнderелгән кәгазе гыйлем (мәгълүмат; извещение. — *Х.М.*) хәбәре алган вакытымда бик каты авырый идем. Өч атна ятакда калып, бүген беренче калыкдым вә беренче эшем бүләгегезне барып алу булды. Ләкин монда андый эшләр бик мәшәкатьле, зәхмәтле (кыен. — *Х.М.*) булган икәнене белгәнгә, яныма бер аркадашымны (иптәшемне. — *Х.М.*) алдым. Иртәдән алып өйләгә кадәр постаханәнең бер катындан икенчесенә, өченчесенә аркадашым менеп-төшеп, пакетны алырлык хәлгә китерде. Мин хәлсез, көчсез булганга, кул кую вакытыны көтеп утырып кына тордым. Мин дә әллә ничә йиргә куллар куеп, тамож (таможня. — *Х.М.*) акчасын түләп, бүләгегезне алдым. Күнде-

* Төрек телендә пакет сүзе посылка, бандероль мәгънәләрен дә белдерә.

рүегез өчен бик зур рәхмәт. Пакетның эчендән хатыгыз берлә бергә өчпочмаклы пәйнир (сыр), бер пар елы оек, ярты кило кадәр ак май чыкды. Боларның һәммәсе минем өчен файдалы бүләкләрдер... Тагы бер мәртәбә күндерүегез, мине уйлавыгыз өчен рәхмәтләремне укыйм. Ләкин алуы, йөрүе бик мәшәкатьле, зәхмәтле булганга һәм дә бик күп тамож акчасы түләргә тиеш булганга (мин үзем унҗиде лира түләдем. Янымдагы иптәш дә өч-дүрт лира, мине борчымыйм дип, әйтми-нитми түләде булырга кирәк), поста берлә мондый пакетлар йөретү бик мәгазле (файдалы; килешле. — *Х.М.*) эш булмый, ахрысы. Сәмигулла да (Халидә Вафинаның бертуган абыйсы. — *Х.М.*) күндергән, имеш. Аныкы әле килмәде. Ул да шундый ук булып чыгар инде. Шуларны ихтыярыма алып, поста берлә хатдан башка бернәрсә күндермәвегезне вә башкаларга да шуны белдерүегезне үтенәм. Тагы бер мәртәбә бүләкләрегезгә рәхмәт укып, хөрмәтләр илә

***Гаяз Исхакый.***

Мөшфика ханымга (Халидә Вафинаның әнисе. — *Х.М.*), сеңелләрегез, туталарыгызга сәламләр, хөрмәтләремне сөйләгез. Хушыгыз. ***Гаяз.***

***13 февраль, 1954, Истанбул***

**Хөрмәтле Халидә туташ!**

Сезнең күндергән бер килолык май бүләгегезне алдым. Тәшәккер идәрем (рәхмәт белдерәм. — *Х.М.*). Көнләр кызу булганга, үзем бик авыр хаста булу сәбәпле, һичбер майлы нәрсә авызым ала алмаганга, мондый бүләкләрне(ң) хәзергә туктатып торуыгызны үтенәм. Үземне дустларым, докторларым бер хастаханәгә кертергә тырышалар. Ләкин хастаханәдә йир (урын. — *Х.М.*) таба алмыйлар. Чит мәмләкәтдән килеп хастаханә ачкан докторларның хастаханәләре бик кыйммәт. Финляндиядән һичбер суыкда да, елыда да бозылмый торган, һәрбер эшкә ярый торган бер бүләк дә килеп чыкды. Кем күндергәндер, — аңарга да рәхмәт*. Минем хәлемдә шундый суыкда да, эсседә дә бозылмый торган бүләкләр тагы яхшырак.

Хушыгыз, һәммәгезгә сәламнәр (и)лә ***Гаяз Исхакый.***

Халидә Вафаның 1953 елның 18 мартында Тампередан Садрый Максудига язган хаты. (Гарәп язуында, татарча.)

---

* Хатның читенә адресат иясенең кулы белән «күндерүче Халидә Вафина» дип язылган. Бу бүләк, мөгаен, спирт булгандыр.

**Бик хөрмәтле вә сайгылы** (мөхтәрәм. — *Х.М.*) **милләттәшебез Садрый бәй!**

Туганым Галия илә киявебез Әнвәргә биргән кыйммәтле «Төрек тарихы вә хокукы» китабын кулыма алып укыгач та, бөтен кимчелекләремә карамастан, ихтыярсыз саф күңелемдәй чыккан рәхмәтләремне укырга теләдем. Чөнки безнең кебек Җир шарының нинди генә төрле тарафка таркау хәлдә таралган булсак та, башкалар кебек күкрәк киереп яшәргә хакымыз барлыгын, кыйммәтле китабыгызны укып, бик ачык рәвештә аңладым. Аллаһы Тәгалә сезнең кебек милләт аталарына озын гомер, бәхетле тормышлар бирсен иде, дип саф теләктә калам.

Сез, мөхтәрәм бәй абзый, безләрне танымасагыз да, безнең гаиләмезнең телендә еш кына буласыз. Әти мәрхүм (Зиннәтулла Вафа) сезләрне һәр заман сагынадыр иде вә бүгенгәчә үз кулыгыз илә язылган гаилә рәсемегез дә диварымызда торадыр. Димәк ки, күздән еракда торсагыз да, калебләремезгә якындыр. *М*әгаттәәссеф (кызганычка каршы. — *Х.М.*), мин Төркия сәяхәтемдә сезләрнең кулларыгыздан кысып сәлам бирергә форсат булмады. Чөнки мосафир өе — хуҗасының кулыдыр. Икенчедән, бәлкем, форсат булып та, үземнең сезнең каршыгызда данә (бөртек. — *Х.М.*) кадәр гайрәтем булмаган булыр иде. Сезне болай, хатым илә рәхәтсез итсәм дә, халкымызның яшерелгән җәрәхәтле сызлауларын аңлап, гафу итәрсез дип өметтәмен. Югарыдагы әйткәнем кеби, без кайсыбер чит мәмләкәтдә яшәсәк тә, халкымызны шул ук кайгылар, шул ук шадлыклар бер-берләренә баглыйдыр.

Бу сәнә (ел. — *Х.М.*) бөтен төрекләр өчен сөенечле булган Истанбулның 500 еллык бәйрәменә мин дә шушы рәвештә кальбән (күңелем белән. — *Х.М.*) катнашып, изге теләкләр илә котлыйм. Бу мөнәсәбәт илә төрле милләтләрдән дә мосафирлар киләчәкдер. Кем белә, бәлкем, кечкенә Финляндиямезнең дә милләт вәкилләре арада булачак. Шуңа күрә сезгә Финляндия парламент барышында язылган кечкенә дәфтәрне хатирә уларак күндерәм. *М*отлакан (шиксез. — *Х.М.*), арада кальбән төрек дустлары да булачак. Бәгъзән, мондагы утырышларга кызыксынып тыңларга барганда да, безләргә «төрек» уларак бик хөрмәт вә ачык йөз күрсәтәләр. Без дә, бер кечкенә колония генә булсак та, шул кадәрле [кадерле (?). — *Х.М.*] милләтнең ачысын вә чөчесен (төчесен. — *Х.М.*) бәрабәр күреп, кыйммәтле корбанлар да бирдек. Бонлар да халкымызга самимият илә Ватан хокукларын бирделәр. Бу яшь бер милләт булса да, бөтен дөнья каршысында да хөр, бәхетле, үз илендә

яшәргә хаклы булганын күрсәтте. Аллаһы Тәгалә мондан соң да һәр заман ярдәме илә булсын иде!

Бөтен кадерле гаиләгезне гаиләмез исемендән кальбән сәламлим. Тирән хөрмәт вә сайгыларым илә ерак илләрдәге кече кардәшегез

*Халидә Вафа.*
*8 май, 1954, Истанбул*

Садрый Максуди-Арсалның 1953 елның 18 июнендә Истанбулдан язган хаты. (Ул төрек телендә латин хәрефләре белән язылган.)

**Хөрмәтле Халидә туташ!**

Финляндия парламенты чыгарган брошюра вә гүзәл рухлы хатыгызны алдым. Рәхмәт белдерәм. Төркиядән читтә тууыгызга һәм үсүегезгә дә карамастан, төрклек вә төрклеккә бәйлелек тойгысын саклавыгызны күреп бик шат булдым. Әйе, кызым, төрек милләте дөньяның иң бөек вә иң парлак (күренекле; мәшһүр. — *Х.М.*) тарихка ия милләтләрнең бередер. Төрек милләте бердер, төрле исемнәр белән йөртелгән төрк кавемнәре бөек төрк агачының ботакларыдыр.

Хатыгызны укып, мине хөрмәт итүегезне аңладым. Хезмәт вазыйфаларын үтәүдән соң иң асыл вә иң файдалы ял — китап укудыр. Инсанның рухын күтәрә, рухи офыгын киңәйтә торган чара — укудыр.

Хатыным Камилә ханымнан вә үземнән мөхтәрәм әниегез Мөшфика ханымга хөрмәт вә сәламнәремне, кыз туганнарың Алия вә Наилә ханымнарга, вә абыгыз Сәмигулла бәйгә, вә җизнәгез Әнвәр бәйгә сәламнәремне белдерүегезне үтенәм.

Уңышлар теләп, профессор

*Садрый Максуди-Арсал.*

## Х.Миңнегуловның Г.Исхакый турында һәм аңа мөнәсәбәтле язмалары

1. Г.Исхакый хаты: Рухи васыятем кебек калсын // Казан утлары. — 1991. — № 5. — 160–169 б. Шушы ук материалның бер өлеше «Социалистик Татарстан» гәзитендә дә дөнья күрде (19.10.1990).

2. Бер ана йортының балалары («Милли байрак» гәзитенең 1935 елгы 1 нче саны турында) // Татарстан яшьләре. — 1990. — 27 декабрь.

3. Сания Гыйффәт // Сөембикә. — 1991. — № 2. — 20 б.

4. Янә Сания Гыйффәт хакында // Сөембикә. — 1992. — № 11. — 18–20 б. Биредә шагыйрәнең «Гаяз әфәнденең әдәби хезмәтенә 40 ел тулу мөнәсәбәте берлә» дигән мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл. — 1937. — № 4 (109). — 13–16 б.].

5. Фәнгә — яңа сәхифәләр (Финляндиядә татар мәдәнияте турында): Интервью // Татарстан. — 1992. — № 11–12. — 69–75 б.

6. Г.Исхакый фаразлары // Татарстан. — 1992. — № 9–10. — 49–52 б. Биредә әдипнең «Бүгенге вазгыять вә безнең вазыйфамыз» мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл. — 1935. — № 8 (91). — 1–6 б.].

7. «Милләт бетмәсә, аның теле вә әдәбияты да яшәр!» (Ерак Шәрыкта татар китабы һәм матбугаты) // Шәһри Казан. — 1992. — 13 июнь.

8. Таныш проблемалар, таныш бәхәсләр // Шәһри Казан. — 1992. — 5 ноябрь. Биредә Г.Исхакыйның «Рус мөһаҗир матбугатында миллият мәсьәләсе» дигән язмасы да урнаштырылган [Яңа милли юл. — 1938. — № 1 (118). — 17–19 б.].

9. «Казан» журналы (Төркиядә чыккан) // Кызыл Таң (Уфа). — 1992. — 10, 12, 15, 16, 17, 19 сентябрь.

10. Азатлык көрәшенең мөнбәре («Яңа милли юл» журналы турында) // Казан утлары. — 1993. — № 3. — 122–135 б. Биредә Г.Исхакыйның «10 нчы елымыз» [Яңа милли юл. — 1938. — № 1 (118). — 1–5 б.] һәм «Мөфти Ризаэддин хәзрәт» [Яңа милли юл. — 1936. — № 7–8 (101). — 2–6 б.] мәкаләләре дә бар.

11. Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты // Казан утлары. — 1993. — № 7. — 154–163 б.

12. Ул татар булып калды // Шәһри Казан. — 1993. — 17 апрель.

13. Милли бәйсезлекне кыйбла итеп (Милләт мәҗлесе хакында) // Мирас. — 1993. — № 2. — 38–45 б. Биредә Г.Исхакыйның «Яңа милли юл» журналында [1938. — № 1 (108). — 5–11 б.] басылган мәкаләсе дә урнаштырылган.

14. Гаяз Исхакыйның көрәштәш дусты (Фуад Туктаров хакында) // Татарстан. — 1993. — № 4. — 22–31 б. Биредә әдипнең «Солых һәйәте әгъзасы Фуад Туктар бәк вафат» мәкаләсе дә [Яңа милли юл. — 1939. — № 2 (130). — 1–6 б.] бар.
15, 16. Пушкин «русның үз йимешедер» // Идел. — 1993. — № 2. — 27–28 б. Биредә Г.Исхакыйның «Әдәбият пәрдәсе астында русчылык» мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл. — 1937. — № 2 (108). — 1–4 б.]. Шушы ук материаллар «Русизм под литературной вывеской» исеме астында, русчага да тәрҗемә ителеп, «Идель» журналында да басылды [1993. — № 2–3. — С.29–30].
17. Милләтебезнең олуг хадиме һәм юлбашчысы // Шәһри Казан. — 1993. — 20 февраль. Биредә Г.Исхакыйның «Үткән елның сәяси дәресләре» мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл. — 1938. — № 2 (119). — 1–8 б.].
18. «Йөрәк һаман сиңа ашкына...» («Kazan» журналы турында) // Казан. — 1993. — № 1. — 164–167 б.
19. «Обретет душа, стремясь к тебе, свободу» (О журнале «Kazan») // Казань. — 1993. — № 1. — С.158–161.
20. Исхакый томнарын чыгаруны тизләтик // Татарстан хәбәрләре. — 1994. — 25 май.
21. «Милли сафлары... гранит ташы кеби» // Мирас. — 1994. — № 2. — 31–35 б. Биредә әдипнең «Финляндиядә» мәкаләсе дә [Яңа милли юл. — 1937. — № 4 (109). — 1–6 б.] басылган.
22. «Нинди төскә керсә дә, асылы бер» // Казан утлары. — 1996. — № 10. — 172–179 б. Биредә Г.Исхакыйның «Бугазлар» мәкаләсе дә урын алган [Яңа милли юл. — 1938. — № 1 (108). — 17–29 б.].
23. «Их шатланам... татар булуыма!» (Минһаҗ Исмәгыйли: тормышы һәм иҗаты) // Мирас. — 1996. — № 5–6. — 252–264 б.
24. Аерылмас төшенчәләр («Kazan» журналы турында) // Мирас. — 1997. — № 11. — 71–83 б.
25. Гаяз Исхакый бәк Тампереда // Мәгърифәт. — 1998. — 28 февраль. Бу материалның чыганагы: Яңа милли юл. — 1937. — № 3 (108). — 21–24 б.
26. Милли кыйблабызны күрсәтүче әдип // Мәдәни җомга. — 1998. — 27 февраль. Биредә Г.Исхакыйның 40 еллык әдәби иҗаты уңае белән аерым тәбрикнамәләр дә бирелә [Яңа милли юл. — 1937. — № 3 (108)].
27. Исхакый мөһаҗирлектә. — Казан: Таң–Заря, 1999. — 84 б.
Рецензияләр: Кәримова А. Мөһаҗирлектә дә йөрәгендә халкы булган // Шәһри Казан. — 1999. — 1 октябрь; Га-

ли Б. Язмышын җиңеп // Мирас. — 1999. — № 10. — 153–154 б.

28. «Дөньяда сүземез бар...» — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. — 334 б. Биредә Г.Исхакыйга теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәтле «Фәнгә — яңа сәхифәләр» (184–193 б.), «Чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугаты» (194–209 б.), «Казан» һәм «татар» — аерылмас төшенчәләр» (210–232 б.) һ.б. язмалар да урнаштырылган.

Рецензияләр: Н ә ф ы й г о в Р. Халык язмышы турында // Ватаным Татарстан. — 2000. — 19 апрель; Г а т а ш Р. Төрки дөньяга гашыйк галим // Заман–Татарстан. — 1999. — 10 декабрь.

29. Яшәү мәгънәсенең асыл гәүдәләнеше («Олуг Мөхәммәд» драмасы) // Мирас. — 1999. — 44–50 б.

30. Язмышлар дулкынында (Г.Исхакыйның «Дулкын эчендә» драмасы) // Мирас. — 1999. — № 2. — 53–58 б.

31. Гыйбрәтле тамаша (Г.Исхакыйның «Җан Баевич» комедиясе) // Мирас. — 1999. — № 5. — 38–42 б.

32. Исхакый һәм татар әдәбияты // Мәгариф. — 1999. — № 9. — 24 б.

33. Милләтпәрвәрләр һәм шаһгалиләр // Шәһри Казан. — 2000. — 14 октябрь. Биредә Г.Исхакыйның «Казан китүгә 383 ел үтде» мәкаләсе дә бар [Яңа милли юл. — 1935. — № 11 (93). — 1–5 б.].

34. Уяну һәм асылга кайту (Г.Исхакыйның «Өйгә таба» повесте) // Татарское возрождение. Эпоха и личности (М.Хәсәнов эшчәнлегенә багышланган җыентык). — Казан: Фән, 2000. — 256–267 б.

35. Бөек шагыйрь турында бөек әдип (Тукай турында Исхакый) // Мәдәни җомга. — 2001. — 3 август. Биредә Г.Исхакыйның «Тукай истәлеге» дигән мәкаләсе дә бар. [Яңа милли юл. — 1932. — № 11].

36. «Яңа милли юл» журналы һәм Тукай // Казан утлары. — 2002. — № 1. — 168–179 б.

37. Исхакый васыятенең иясе (Халидә Вафина турында) // Казан утлары. — 2002. — № 6. — 178–185 б.

38. Тукай турында Исхакый кызы / КДУ. Фәнни язмалар, 2001. — Казань: Школа, 2002. — 246–253 б. Биредә Сәгадәтнең «Габдулла Тукай (үлүенә 25 ел булу уңае берлә)» мәкаләсе дә [Яңа милли юл. — 1938. — № 4 (121). — 9–14 б.] басылган.

39. Исхаки о падении Казани // Звезда Поволжья. — 2002. — № 8 (112). Биредә әдипнең «Казань — символ тюркского единения» мәкаләсе дә [Азат Ватан (Мюнхен). — 1952. — № 8 . — 2–3 б.] бар.

40. Мөһаҗирнең җан авазы (Алманиядә — татар журналы) // Татарстан. — 2003. — № 2. — 58–62 б.

41. Азат Ватан: Скорбь и надежда (Татарский журнал в Германии) // Татарстан. — 2003. — № 2. — С.58–62.

42. Гаяз Исхакыйның тууына — 125 ел // Мәдәни җомга. — 2003. — 21 февраль. Шунда ук әдипнең «Әдәбият һәм нәшрият» мәкаләсе дә [Яңа милли юл. — 1937. — № 10 (115)] басылган.

43. Гаяз бабайның мәсләки кыйбласы // Шәһри Казан. — 2003. — 21 февраль. Биредә әдипнең «Тел мәсьәләсе» мәкаләсе дә [Яңа милли юл. — 1937. — № 4 (109). — 6–9 б.] бар.

44. Гасырлар өнен тыңлап... — Казан: Мәгариф, 2003. — 336 б. Биредә Г.Исхакыйга мөнәсәбәтле «Яңа милли юл» журналы һәм Тукай» (163–174 б.), «Яңа милли юл» (218–219 б.) мәкаләләре дә бар.

45. «Аһ, бу язмыш... ник шулай?» (Шагыйрә Сания Гыйффәтнең иҗат портреты) // Мәйдан. — 2004. — № 3. — 96–113 б.

46. Гаяз Исхакыйның Мөселман Көнчыгышына сәяхәте // Казан утлары. — 2004. — № 4. — 140–146 б. Биредә (146–153 б.) һәм шушы ук журналның 6, 7 нче саннарында әдипнең «Ислам мәмләкәтләрендә» язмасы да бар [Яңа милли юл. — 1932. — № 2–8, 10, 12; 1933. — № 1, 3, 5, 7, 8–10, 12.].

47. Гаяз Исхакый. Ислам мәмләкәтләрендә (Юл истәлекләре). — Казан: «Иман» нәшрияты,2003. — 101 б.

## Эчтәлек

**Кереш сүз** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

**I. ӘДӘБИ ИҖАТЫ**

Кайда да милләтпәрвәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Язмышлар дулкынында (*«Дулкын эчендә» драмасы*) . . . . . . . . . 25
Уяну һәм асылга кайту (*«Өйгә таба» повесте*) . . . . . . . . . . . 35
Аянычлы һәм гыйбрәтле тамаша (*«Җан Баевич» комедиясе*) . . . . . 44
Яшәү мәгънәсенең асыл гәүдәләнеше (*«Олуг Мөхәммәд» драмасы*) . 52
Гаяз Исхакыйның Мөселман Көнчыгышына сәяхәте . . . . . . . . . 65
Ислам мәмләкәтләрендә (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . . . 75

**II. ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ПУБЛИЦИСТИКАСЫ («ЯҢА МИЛЛИ ЮЛ» БИТЛӘРЕННӘН)**

Азатлык көрәшенең мөнбәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
«Яңа милли юл» журналы тышлыгындагы кайбер эпиграфлар . . . . . . 147
10 нчы елымыз (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Мөфти Ризаэддин хәзрәт (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . . . 154
Бер ана йортының балалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Гаяз Исхакыйның көрәштәш дусты . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Солых һәйәте әгъзасы Фуад бәк Туктар вафат (*Гаяз Исхакый*) . . . . 168
Таныш проблемалар, таныш бәхәсләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Рус мөһаҗир матбугатында миллият мәсьәлә(се) (*Гаяз Исхакый*) . 188
«Милли сафлары... гранит ташы кеби» . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Финляндиядә (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Гаяз Исхакый бәк Тампереда (*Мәхрүсә Вафа*) . . . . . . . . . . . . 199
Тампереда милли кичә (*Мәхрүсә Вафа*) . . . . . . . . . . . . . . . 200
Гаяз Исхакый фаразлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Бүгенге вазгыять вә безнең вазыйфамыз (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . 204
Милләтпәрвәрләр һәм шаһгалиләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Казан китүгә 383 ел үтде (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . . . 210
Милли бәйсезлекне кыйбла итеп... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Милләт мәҗлесенең 20 еллыгы (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . 219
Милләт мәҗлесенең 20 еллык бәйрәме (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . 230
6 февральдә Милләт мәҗлесенең 20 еллыгы уңае берлә Гаяз әфәнде Исхакыйның Варшау радиосы аркылы сөйләгән сүзләре . . . . . . . . 234
Нинди төскә керсә дә, асылы бер... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Бугазлар (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Милләтебезнең олуг хадиме һәм юлбашчысы . . . . . . . . . . . . . 247
Үткән елның сәяси дәресләре (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . 250
Пушкин «русның... үз йимешедер» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 257
Әдәбият пәрдәсе астында русчылык (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . 259
«...Телебезне саклаучы халкыбыз бар» (*Гаяз Исхакыйның тууына 125 ел тулу уңае белән*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 262
Тел мәсьәләсе (*Гаяз Исхакый*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264

Бөек шагыйрь турында бөек әдип . . . 268
Тукай истәлеге *(Гаяз Исхакый)* . . . 269
Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә *(Гаяз Исхакый)* . . . 272
Тукай турында Исхакый кызы . . . 279
Габдулла Тукай *(Сәгадәт Чагатай) (Үлүенә 25 ел булу уңае берлә)* . . . 281
Габдулла Тукай *(Сәгадәт Чагатай)* . . . 287
Исхакый Татарстан хәлләре турында . . . 289
Әдәбият һәм нәшрият *(Гаяз Исхакый)* . . . 290
Милли кыйблабызны күрсәтүче әдип . . . 293
Гаяз әфәнденең 40 еллык хезмәте мөнәсәбәте илә тәбрикнамәләр . . 295
Ул татар булып калды . . . 300
Янә Сания Гыйффәт хакында . . . 305
Гаяз әфәнденең әдәби хезмәтенә 40 ел тулу мөнәсәбәте берлә *(Сания Гыйффәт)* . . . 309
«Татар театрының атасы» һәм Исхакый . . . 311
Артист Габдулла Карый *(Гаяз Исхакый)* . . . 315
Рухи бәйләнешләр турында Исхакый . . . 321
Толстойның татар әдәбиятына тәэсире *(Гаяз Исхакый)* . . . 325

**III. ВАСЫЯТЬНАМӘ**
Гаяз Исхакый хаты . . . 332
Мәгънәви васыятем кебек калсын *(Гаяз Исхакый)* . . . 336
Исхакый васыятенең иясе . . . 348
Халидә Вафа архивыннан хатлар . . . 358

Х.Миңнегуловның Г.Исхакый турында һәм аңа мөнәсәбәтле язмалары . . . 362

Научно-популярное издание

**Миннегулов Хатип Юсупович**

**Творчество Гаяза Исхаки в эмиграции**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.М.Касыймова*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Л.Ш.Шәфыйкова, С.Н.Мифтахова, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.07.2004. Форматы 84×108 $^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 19,32 + вкл.0,84 + фор.0,21. Шартлы буяу-оттиск 0,21.
Нәшер-хисап табагы 21,95 + вкл.0,85 + фор.0,36. Тиражы 2000 д. Заказ Э-502.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.